А. Г. ЯХИН

Әдәбият
11



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
11

31
ДЕКАБРЬ
ОПТИМИСТ


БӘЙЛӘНЕШ


ИДЕОЛОГИЯ КӨЧЕ


ИДЕЯ

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек

ӨЧЕНЧЕ БАСМА

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
рөхсәте белән басыла

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2008

УДК 373.167.1:821.512.145*11
ББК 83.3(2Рос=Тат)-93 я721
Я89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Укытучылар игътибарына!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «11 нче сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2008.— 463 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-7761-1771-8

ISBN 978-5-7761-1771-8

© «Мәгариф» нәшрияты, 2003
© «Мәгариф» нәшрияты, 2008, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2008

КЕРЕШ

Быел сез татар әдәбиятының сугыш һәм аннан соңгы еллардагы үсешен өйрәнәчәксез.

Бу вакыт эчендә илдә зур үзгәрешләр булды. Сугыш, партиянең XX съездында шәхес культын фаш итү, 90 нчы елларда башланган реформа — бу вакыйгаларның һәрберсе кешеләрнең дөньяга карашын бик нык үзгәртте. Җитмеш ел буе социализм идеяләре белән яшәгән ил кинәт кирегә борылды. Тормыш буталды, халыкның кыйбласы югалды.

Халык гел ялган белән билгесезлектә генә яши алмый. Ялганны фаш итеп, барыр юл күрсәтү эшен бу юлы да әдәбият үз өстенә алды. Ул — тормыштагы һәр үзгәрешнең иң актуаль темасын таба, иң әһәмиятле проблемасын куя белде. Заман үзгәрешләре белән бәйле рәвештә әдәбиятның да эчтәлеге үзгәрде. Шул үзгәрешләргә карап, ул — чорларга бүленде. Быел сез шул чорларның үзенчәлеге белән дә танышачаксыз.

Дәреслекнең фәнни нигезе. Әдәбиятны өйрәнү өчен кирәк булган төп атамалар һәм анализ кагыйдәләре белән сез алдагы сыйныфларда таныштыгыз. Бу уку елында аларның һәммәсе кирәк булачак. Әдәбиятны тирәнрәк өйрәнгән саен, аның серләренә күбрәк төшенәбез. Әдәбият серләренә ныграк төшенгән саен, әдәби әсәрләрнең матурлыгы күбрәк ачыла. Быел да әлегә сезгә очрамаган яңа атамалар, кагыйдәләр белән танышачаксыз.

Әсәр турында бик җиңел генә дә әйтеп була. Бу әсәр фәлән турында дип, нинди дә булса хәбәр әйтәсең дә дәлилгә өзек-цитата китерәсең. Өзек-цитата башка берәүнең фикере, әсәрдән бер өзек, авторның үзе турында әйткән сүзе булырга мөмкин. Бу юл белән китсәк, әдәби әсәр бөтен катлаулы төзелеше белән әлеге хәбәрдән читтә кала. Чөнки әсәрнең ниндидер бер өлеше бервакытта да бөтен эчтәлеген бирә алмый. Әдәбиятны бу рәвешле өйрәнү өчен гомумән белем кирәкми. Тулы эчтәлек әсәрнең барлык вакыйгалары, чигенешләре, образлары, детальләре арасындагы бәйләнешләрне тапкач кына беленә. Дәреслек-

хрестоматия әдәбиятны шул принциптан чыгып өйрәнә: тарката, җыя, гомумиләштерә. Сезне дә, шул рәвешле, фикерләргә өйрәтә. Анализ нәтиҗәсендә әсәрдә сурәтләнгән табигатьнең, кеше сыйфатларының, хыялның матурлыгы белән бергә авторның фикерләү матурлыгын да күрергә өйрәнәбез. Кеше фикеренә соклана белү — бик зур бәхет ул.

Кереш, нәтиҗәләр. Алдагы сыйныф дәреслекләрендәге кебек, бу китапта да өйрәнелә торган һәр чор кереш белән башланып китә һәм йомгак-нәтиҗә белән тәмамлана. Керештә әдәбиятка тәэсир итәрлек тарихи шартлар, чор һәм әдәбият проблемалары, әдәбиятның шул чорга хас фәлсәфәсе хакында сөйләнә. Йомгакта анализ нәтиҗәләре гомумиләштерелә, чорга хас иң әһәмиятле сыйфатлар әйтелә.

Биремнәр, сораулар. Биремнәр һәм сораулар өйрәнгән материалны хәтердә калдыру һәм сезгә мөстәкыйль эшегездә ярдәм итүне күздә тотып төзелде. Әдәбиятны тирәнрәк өйрәнергә теләүчеләр өчен дәреслектә катлаулырак биремнәр дә бар.

Һәр бирем — анализның яки гомумиләштерүнең бер адымы. Шуңа күрә алар бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнештә торалар. Бер биремгә җавап табу икенче биремне күзалларга ярдәм итә, ә өченче биремгә җавапны алдагы бирем җавапларын белгәннән соң гына табарга мөмкин.

Бирем-сораулар — дәреслек-хрестоматиянең бик әһәмиятле өлеше. Алар сезне мөстәкыйль фикерләргә өйрәтәләр, сезнең булышчыларыгыз.

Китаптагы әсәрләр. Күләмнәре зур булмаган шигырьләр, хикәяләр дәреслек-хрестоматиягә тулы килеш кертелделәр. Ләкин роман һәм повестьларны, пьесаларны аерым бүлекләрен укып кына өйрәнеп булмый. Шуңа күрә китапка кертелгән күләмле әсәрләр кыскартылсалар да, аларның сюжетлары, төзелешләре, төзелештә катнашкан метафоралары, персонажлары — барысы да сакланды. Әсәрнең эчтәлеге тулысынча бирелә.

ХАКЫЙКАТЬ ЭЗЛӘҮ

Идеология. Партия үзенең идеологиясен бәхәссез хакыйкать дип белдерде. Аңа тел-теш тидерүчеләр халык дошманы дип гаепләнделәр. Дөньяны ул ике каршы якка бүлде: партия идеологиясен яклаучыларны «без», калган кешеләрне «алар» дип атады. Шул рәвешле, кешеләр фәкать үз фикерләре булган өчен генә дә дошманга әйләнделәр. «Дошманнарны юк итәләр»,— дип белдерде партия. «Алар» ягында торган дошман кешеләр миллионлап юк ителделәр. Бу эш сугыш елларында да, аннан соңгы елларда да дәвам итте. «Тормышның мәгънәсе — сыйныфлар арасындагы көрәш. Ул көннән-көн кискенләшә бара»,— дип игълан итте партия. Шуңа күрә бу хакыйкатьнең нәтиҗәсе — кешеләрне бер гаепсезгә юк итү хаклык дип саналды.

Сугышка ил иң акыллы кешеләрен, иң сәләтле командирларын юк итеп килеп керде. Шуңа да карамастан Кызыл Армия дөньядагы иң көчле армия дип макталды. Макталган Кызыл Армия аз санлы халкы булган Финляндияне җиңә алмады. Немец гаскәрләрен дә һичничек аклап булмаслык корбаннар исәбенә Мәскәү янында гына туктата алды. Әмма уйлап торырга вакыт юк. Дошман җиңәргә өлгергәнче, аның үзен тармар итәргә кирәк иде. Бөтен халык изге сугышка күтәрелде.

Иҗтимагый аң. Иҗтимагый аң — нәрсәгәдер ышану, нәфрәт, мәхәббәт кебек, гадәт булып урнашкан гамәл, дигән идек.

Күп еллар буена көн дә алып барылган пропаганда гомуми хәерчелекне — тигезлек, хокуксызлыкны партиягә ышаныч дип аңлатты. Мәгариф, мәдәният өлкәсендәге уңышлар, әледән-әле төзелеп торган яңа завод-фабрикалар, кырыс чаралар күрү нәтиҗәсендә җинаятьнең күзгә күренеп азаюы идеологиянең чынлык булуына дәлил рәвешендә кабул ителделәр. Ышану партиягә һәм юлбашчыларга мәхәббәт хисен тудырды.

«Чыннан да, хакыйкатькә ия булган юлбашчыларның бөтен нияте халыкны бәхетле итү икән, нигә дип әле мин үткән көннәр, бүгенге мәшәкатьләр, иртәгә туасы көннәр турында

уйланып борчылырга тиеш? Иң алдынгы идеология белән коралланган түрәләр теләсә нинди сорауга миннән дөресрәк итеп җавап бирәчәкләр бит». Шулай уйлау кешеләргә уңай иде.

Язмышны тулысынча юлбашчыларга тапшырып, фикерләүдән бизү сугыш алды иҗтимагый аңының җитди үзенчәлеге булды.

Илдә тормыш хәлләре яхшырмады, кулга алулар, сөргенгә сөрүләр артканнан-арта барды. Әмма шулай булуга да карамастан 20 нче елларда ук башланган хезмәт энтузиазмы сүнмәде генә түгел, көчәйгәннән-көчәя барды. Тормышның фаҗигале бу каршылыгын иҗтимагый аңдагы үзенчәлек белән генә аңлатырга мөмкин.

30 нчы елларда энтузиазм тудырган күтәренке хис (пафос) белән чынбарлык уяткан курку, борчылу хисләре арасындагы каршылык тотрыклы эчке драма булып күңелләргә кереп бикләнде. Чишелеше түгел, аңлатмасы 90 нчы еллар башында гына кычкырып әйтелгән бу проблема җавабы әйтелмәгән сорау булып буыннан-буынга күчеп килде. Тотрыклы борчу булуы белән эчке драма иҗтимагый аңның бер өлеше, яңа эчтәлеге иде.

Гадәттә, үзгәрешкә бик аз бирелә торган иҗтимагый аң Бөек Ватан сугышы елларында шактый үзгәрешләргә дучар булды.

Һәр сугышта халык үзенең полководецларын зурлый. Сугышның бу мәҗбүри таләбе юлбашчыларга табыну дәрәҗәсен тагын да арттыра төште. Сыйнфый көрәш идеясе хәзер басып алучы явыз немец гаскәрләренә каршы сугыш эчтәлеге белән кушылды. Сыйнфый дошманга булган нәфрәт авылларны, шәһәрләрне яндырып, коралсыз кешеләрне үтереп, талап һөҗүм итүче фашистларга юнәлдерелде. Патриотизм идеясе халык күңелендә мәңге сүнми торган туган җиргә мәхәббәт хисе булып дөрләп яна башлады.

Шул эчтәлеге белән иҗтимагый аң әдәбиятка да килеп керде.

Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Сугыш вакытында пьесалар күп языла. Гражданнар сугышы еллары да драма әсәрләренә бай иде. Бөек Ватан сугышының дүрт елында унбишләп пьеса, язылып, сәхнәдә уйналды. Бик кыен шартларда ашыгып язылу сәбәпле, аларның барысы да сәнгать ягыннан югары дәрәҗәгә менә алмадылар. Ләкин һәр чорның

үзенә генә хас әһәмиятле проблемалары була. Сугыш елларында ил бөтен Европаны диярлек басып алган мәкерле, гаять көчле дошманны тар-мар итү проблемасы белән яшәде. Татар драматурглары халыкны дошманнан курыкмаска өйрәттеләр, фашистларның ерткычлыкларын күрсәтеп, аларга нәфрәт тәрбияләделәр. Тылдагы хезмәткә багышланган пьесаларда халыкны авырлыкларга түзәргә, хезмәттә фидакарьлек күрсәтергә чакырдылар.

Күләмле романнар, повестьлар язу өчен уңайлы шартлар да, вакыт та юк иде. Кулларына корал тотарлык язучылар фронтка киттеләр. Күпчелек әдипләр фронтта сугышты, яу кырында әдәбиятка яңа каләм осталары килде. М. Җәлил, А. Алиш һ. б. фашистлар төрмәсендә әсирлектә җәфа чиктеләр. Сугышка кадәр үк ирекләреннән мәхрүм ителгән дистәләрчә әдипләр совет төрмәләрендә интектеләр. Ләкин исән калучылар кая һәм нинди шартларда яшәүләренә карамастан иҗат иттеләр.

Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Н. Баян, Х. Мөҗәй, Р. Ильяс кебек танылган язучылар сугыш кырларында һәлак булдылар. Исән чакта алар да, ашыга-ашыга, очерклар, шигырьләр, пьесалар, поэмалар яздылар.

Истә калдырыйк.

***Очерк* дип тормыш вакыйгаларын үзгәртмичә, ул вакыйгаларда катнашкан кешеләрнең үз исем-фамилияләрен саклап язылган, күләмнәре зур булмаган әсәрләргә әйтәләр.**

Фронтларда һәм төрмә-лагерьларда исән калган язучылар бу елларның авыр фаҗигасен, җиңү, очрашу шатлыкларын кәгазьгә теркәп калырга тырыштылар. Шигырьләрен, күзәтчеләрдән яшереп, папирос кәгазьләренә яздылар. Сугыш елларында бигрәк тә поэзия киң үсеш алды. Муса Җәлил һәм Хәсән Туфан әсәрләре белән бөтен дөньяга танылды. Ләкин сугыш еллары әдәбияты Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзи, Хатип Госман, Габдрахман Әпсәләмов, Шәрәф Мөдәррис, Атилла Расих, Әхмәт Исхак, Фатих Хөсни, Таҗи Гыйззәт, Мирсәй Әмир, Салих Баттал кебек язучылары белән дә хаклы рәвештә горурлана ала.

Сугыш бит ул — бер үк вакытта исән калу шатлыгы да, үлем кайгысы да, җиңү дә, җиңелү дә, явызлык та, шәфкатьлелек тә, хаклык та, хаксызлык та, батырлык та, куркаклык та. Шундый киеренке, катлаулы вакытта кешеләрнең тыныч тормышта күзгә чалынмый торган сыйфатлары аеруча калку булып күренә, чиктән тыш киеренке хисләре тышка бәреп чыга.

Татар әдәбиятының безгә таныш ике юнәлеше бу кырыс, катлаулы вакытта бер юнәлеш булып кушылдылар. Реализм юнәлеше сугышны ачы хакыйкать итеп кабул итте һәм аны бөтен катлаулы төсмерләре белән сурәтләргә омтылды. Романтизм юнәлеше үзенең революцион-җимергеч гайрәтен тулысынча дошманны тар-мар итүгә юнәлтте. Бу юнәлештә иҗат итүчеләр совет сугышчысын әкият каһарманнарына охшаттылар. Батырлык дәрәҗәсен ышандырырлык итеп сурәтләү өчен, дастан, әкият сюжетларыннан, тарихи вакыйгалардан файдаландылар. Алар, сугыш тудырган нәфрәт, ачу, үч хисләрен чиктән тыш арттырырга тырышып, пафос белән яздылар. Бу пафоста элеккеге елларда күренгән кылану да, мактану да, ялган да юк иде.

Әдәбиятның бу ике юнәлеше сугыш елларындагы кешеләр язмышын ничек күрсәтә алды? Анысын әсәрләр һәм аерым язучыларның иҗаты белән танышкач күрерсез.

Биремнәр һәм сораулар

Кабатлау өчен

1. Хакыйкать дип нәрсәгә әйтәләр?

2. «Идеология» дигәндә нәрсәне күз алдында тотабыз?

3. 30 нчы еллардагы идеология һәм чынлык хакыйкатьләре турында сөйләгез.

4. 30 нчы еллардагы репрессияләр турында сөйләгез. Бу хаксызлыкка идеологиянең катнашы турында әйтегез.

5. Сугыш елларындагы идеология 20—30 нчы еллар идеологиясеннән кай ягы белән аерыла?

6. «Иҗтимагый аң» дип нәрсәгә әйтәләр? Иҗтимагый аңның сугыш елларындагы идеологиягә нинди бәйләнеше бар?

7. Сугыш елларында әдәбияттагы ике юнәлеш турында сөйләгез.

8. Бу елларда иҗат иткән әдипләрдән кемнәрне беләсез? Санап чыгыгыз.

Уйлану өчен

1. Өйрәнәсе чорга «Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты» һәм «Хакыйкать эзләү» дип ике исем бирелгән. Моның сәбәбе нәрсәдә?

2. Без бит матур әдәбият өйрәнәбез. Ни өчен сугыш вакыйгаларын искә аласы урынга иҗтимагый аң аерым бүлек булып килә?

3. 20—30 нчы елларда бик аз вакыт эчендә илдә, шул исәптән Татарстанда да, бер-бер артлы яңа завод-фабрикалар төзелә, искеләре яңартыла. Аларны ачлы-туклы яшәгән халык төзи. Әйтергә кирәк, үзләрен аямыйча, үз теләкләре белән ару-талуны белмичә эшлиләр. Бу еллардагы хезмәт энтузиазмының нигезе нәрсәдә булырга мөмкин?

4. Сугышлар вакытында патшалар, ханнар, полководецлар ни өчен мактала?

5. Иҗтимагый аң үзенең иҗтимагыйлыгы белән халыкка, ягъни барлык кешеләргә хас булырга тиеш. Шулаймы?

6. 20—30 нчы еллардагы эчке драма эчке конфликт дип тә карала ала. Ни өчен бу конфликт эчке конфликт булды?

7. Сыйнфый көрәшнең көннән-көн кискенләшә баруы турындагы тәгълимат сугыш елларында үзгәрәме? Әдәбиятта сугышка кадәр тасвирланган нәфрәт хисе белән сугыш елларында тасвирланган нәфрәт хисе арасында аерма бармы?

8. Ни өчен сугыш елларында очерк, нәсер кебек кыска жанрлар да күп языла? Сәбәбен әйтегез.

9. Ни өчен сугыш елларындагы иҗат эше сугышчы батырлыгы белән тиңләшә ала?

Практик эш

1. «Идеология», «Иҗтимагый аң», «Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты» бүлекләренең һәрберсен аерым темаларга таркатыгыз.
2. Табылган темаларның үзара бәйләнешен күрсәтегез.

Әхмәт Ерикәй
(1902—1967)

КЫЯ

Мәгърур кыя ялгыз тора,
Биек һәм текә.
Шаян диңгез, күккә карап,
Кемнедер көтә.

Мин карыйм ялгыз кыяга
Диңгез буенда.
Шунда сугышып үткән егет
Минем уемда.

Ярлар буйлап, таулар буйлап
Шул батыр егет
Дошманнарга каршы барган,
Өермә кебек.

Батыр егет баскан җирдән
Дошман үтмәгән,
Үлгәндә дә кулларыннан
Байрак төшмәгән.

Диңгезнең текә ярына
Кагыла дулкыннар,
Дулкыннар батыр егеткә
Мактау җырлыйлар.

Мин барам мәгърур кыяның
Ташын уярга,
Диңгез җырын ташка уеп
Язып куярга.

Шул җыр кыя күкрәгендә
Ялтырап торсын,
Минем батыр иптәшемне
Искә төшерсен!..

1941 ел

Биремнәр

1. Шигырьне ике өлешкә бүлегез.
2. Һәр өлешнең эчтәлеген ачыклагыз.
3. Өлешләрнең уртак якларын табыгыз һәм шуннан соң шигырьнең эчтәлеген (темасын, хис сәбәбен, идеясен) таба аласыз.

Кыенрак биремнәр

1. Шигырьнең нинди метод белән язылуын аңлатыгыз.
2. «Кыя» шигырен әдәбият юнәлешләренең кайсына кертер идегез?

* * *

Кырлар көйдерелгән җиргә киттем,
Метеор кебек, үземә юл сызып;
Барган юлларымда маяк иттем
Хакыйкатьнең якты йолдызын.
Синең күкрәгеңдә, Туган илем,
Кубарыла давыл, җил, төтен...
Бу җир — мин туган җир, шунда минем
Омтылышым, иркем, өметем.
Дошман яуларына ташланам мин,
Гайрәтләнеп, ярсып киләм мин;
Балаларны дардан коткарам мин,
Туган илем, синең белән мин!

1942 ел

Шигырьгә анализ

Әхмәт Ерикәй бу әсәренә исем куймаган. Ләкин аны «Хакыйкать» дип атаганга, мөгаен, риза булыр иде. Әсәрдәге һәр фикер, һәр образ җепләре нәкъ менә шул төшенчәгә килеп тоташа.

Әсәрнең темасын табыйк. Беренче строфада сүз 1) кырларның көйдерелүе; 2) лирик геройның шунда килүе; 3) аның үзенә хакыйкать табуы турында бара.

Бу өч хәбәрне үзара бәйләп була, әмма кушарга, гомумиләштерергә мөмкин түгел. Аның каравы аларның икесе башка строфаларда кабатлана.

Икенче строфада көйдерелгән кырлар кубарылган җил, давыл, төтен дип тулыланып килә, бу җирнең туган җир булуы турында әйтелә. Өченче строфада әйтелгән дошман,— билгеле,

ут ягучы, давыл кубаручы, ягъни туган илгә басып керүче. Аны да, кырлар көйдерүче буларак, беренче хәбәр эченә кертәбез. Төрле урыннан җыелган бу хәбәрләрне, кыскартып, «Туган илгә килгән куркыныч» дип, тагын да кыскартыбрак «Туган ил» яки «Фаҗига» дип кенә атый алабыз.

Лирик геройның сугышка килүе өченче строфада тагын кабатлана. Хәзер ул — геройның ярсуы, гайрәтләнүе, сугышка керүе турында әйтеп тулыландырыла.

Хакыйкать Миннең сугышка килүе белән бәйләнгән, чөнки Миннең барыр юлында ул маяк булып тора. Икенче строфа тулысынча хакыйкатьнең эчтәлеген ачу өчен язылган. Монда, Туган ил фаҗигасе — Минем үз фаҗигам, дип әйтелә. Әсәр ахырында бу фикер «Туган илем, синең белән мин!» дип тагын бер мәртәбә кабатлана.

Икенче хәбәрне Мин яки лирик герой дип кыскартып әйтергә мөмкин.

Шагыйрь лирик героеның сугышка килү вакыйгасын Туган ил фаҗигасе белән бәйләде. Ә менә юлда маяк булган хакыйкать читтә калды кебек. Аны ни эшләтәбез?

Хакыйкать турында лирик герой «үземә юл сыздым», ягъни хакыйкатьне үзем таптым, ди. Без бу юлга игътибар итәргә тиеш булабыз, чөнки ул юлда тагын бер хакыйкать булуына киная бар.

Хакыйкать дип автор Туган ил өчен сугышучы кешенең бер үк вакытта үзе өчен дә сугышуын атый. Шуңа күрә бу әсәрнең төзелешен хакыйкать һәм аның ачылган эчтәлегеннән гыйбарәт дия алабыз. Бу төзелеш, күреп торасыз, фикер төзелеше генә. Лирик шигырьдә эчтәлеге ачылган хакыйкать хиснең сәбәбе генә була ала. Ә без хис сәбәбенең әсәр эчтәлеге булуын беләбез инде.

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьгә ясалган анализ эзлекчелелеген бик гадиләштереп әйтеп бирегез.

2. Сугыш сугыш инде ул. Берәү дә анда шатланып китми. Ә менә лирик герой шатлана. Нигә шатлана?

3. «Кыя» шигыре эчтәлегендә лирик герой тапкан хакыйкатьне табып буламы?

ҖИЛ

Сөмбелләрнең кыягында
Таң чыклары мөлдери;
Таң чыкларын коя-коя,
Арып-талып, җил йөри.

Йөрсен, йөрсен, монда килсен,
Ач тәрәзәң, керсен ул;
Бөтенесен сөйләп бирсен,
Кайдан килгән җил соң ул?

Бәлки, таң кебек байракны
Җилфердәтеп йөргәндер;
Бәлки, җан тирле солдатның
Тирләрен киптергәндер.

Бәлки, кырда урак урган
Кызларны күзләгәндер;
Бәлки, сугышта егылган
Батырны эзләгәндер...

Бәлки, Карпат тауларына
Менеп юллар яргандыр;
Бәлки, дошман яуларына
Бомба булып яугандыр.

Мин беләм: ул күп йөргәндер —
Ил гизеп, җиһан гизеп;
Минем кебек күп күргәндер,
Авырлыкларга түзеп.

Тик бүген ул килә сарып
Йөри бирә, кабарып;
Ары барып, бире барып,
Гөлләр белән шаярып.

Капшап чыга безнең өйне,
Кагыла күршеләргә;
Бик күп нәрсә сөйләр иде,
Теле булса сөйләргә...

1944 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Җил сыйфатларын күздән кичерегез. Аның башка мәгънәсен табыгыз һәм бер сүз белән әйтегез.

2. «Җил» шигыренең сезгә таныш «Хакыйкать», «Кыя» шигырьләре белән бәйләнешен эзләгез. Алар арасында уртаклык юкмы?

* * *

Караңгыда гына сугыш тынды.
Авыр хәлдә сине таптык без;
Җылытыр өчен сине куыш кордык,
Синең өчен учак яктык без.

Шинельләрне салып сиңа бирдек,
Барлык дуслар янына тезелдек;
Өзелеп төшкән яшел яфрак кебек,
Якты гомерең синең өзелде...

Учак сүнде кинәт. Сүнәр-сүнмәс
Мөлдерәп калды күктә йолдызлар;
Онтылмассың, дускай! Син саклаган
Кояш кебек азат илебез бар!..

1944 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьдәге фикерне ике өлешкә бүлегез.

2. Бүленгән өлешләр арасындагы бәйләнештән чыгып, шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.

3. Бу шигырьнең эчтәлегендә хакыйкать темасы бармы?

Гомумиләштерү

Әхмәт Ерикәйнең дәреслектәге шигырьләре арасында һичнинди охшашлык та, бәйләнеш тә юк кебек. Берсе сугышчы батырлыгы турында, берсе — хакыйкать, берсе — җил, берсе үкенечле үлем турында. Төрле тема, төрле хис.

Алай да бу шигырьләр бер-берсенә охшыйлар да, үзара бәйләнешкә дә керәләр. Беренчедән, бу әсәрләрнең барысында да батыр сугышчы образы бар. Берсендә ул үзе теләп сугышка килә, берсендә батырларча сугыша, берсендә батырларча сугышып үлә, ә берсендә аның каберен җил эзләп йөри. Төрле шигырьләрдә сугышчы турында әйтелгәннәрне җыеп, «Сугышчы язмышы» дип исем дә бирергә мөмкин.

Шигырьләрдә сүз меңнәрчә, йөз меңнәрчә сугышчыларның батырлыгы һәм үлеме турында бара. Сугыш бит ул — батырлык, җиңү генә түгел, чигенү дә, михнәтләр-җәфалар да, үлем дә. Моны һәркем белә. Алай да кеше үзе теләп сугышка бара, соңгы патронына кадәр сугыша. Нигә шулай итә?

Әдипләр сугышның беренче көненнән үк кеше күңелендәге шул каршылыкны үзләренчә аңлатмакчы булалар. Икенче төрле әйткәндә, сугышның фәлсәфәсен табарга тырышалар.

Әхмәт Ерикәй үз фәлсәфәсен «хакыйкать» дип атый. Әдип күз алдында торткан хакыйкать — Туган илне дошманнардан сакларга омтылу, һәм шул омтылышның гамәлгә ашуы аның һәр шигырендә бар. Туган илне саклау ихтыяҗы шигырьләрдә кешенең горурлыгы, шатлыгы, асылы буларак бәяләнә. Ә үлем? Сугыштагы үлемгә нинди бәя бирергә?

Онтылмассың, дускай! Син саклаган
Кояш кебек азат илебез бар!..—

ди шагыйрь. Батыр үлемен, шул рәвешле, ил яшәве белән аклый. Илдә аның рухы, җаны яши, ди. Сугыштагы үлем шулай үлемсезлеккә әйләнә.

Әхмәт Ерикәйнең бу фәлсәфәсе сугыш еллары әдәбияты фәлсәфәсенең бер чагылышы гына булды.

Бирем

Фатих Кәримнең сезгә таныш түбәндәге шигыренә анализ ясагыз һәм аның әчтәлеген Ә. Ерикәй фәлсәфәсе белән чагыштырыгыз.

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул:
Күп яшәргә теләсәң,

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

1942 ел

Шәйхи Маннур
(1905—1980)

ЧӘЧӘКЛӘР ҺӘМ СНАРЯДЛАР

Снарядлар төяп, бер машина
Яңгыр үткән юлдан килгәндә
Кереп батты үзән уртасына,
Җәһәт кенә чыгыйм дигәндә.

Ничек кенә шофер тирләсә дә,
Йөк кузгалмый, ята үзәндә...
Тирә-юньгә карап тилмерсә дә,
Һичнәрсә юк алга түшәргә.

Тик бер оя шомырт, матурланып,
Ап-ак чәчәк белән киенгән.
Исертерлек хуш исләре аның
Бөтен үзән буйлап сибелгән.

Шул шомыртка таба китте егет,
Кузгалды аның нечкә хисләре.
Һәм, гомерендә әүвәл күргән кебек,
Чәчәкләрне йотылып иснәде.

Исерде ул язның саф исеннән,
Гашыйк егет кебек сөйләнде...
Аерылалмый шомырт тирәсеннән,
Әллә ничә тапкыр әйләнде.
Әйләнде дә...
балта белән кырып
Илтеп салды шиннар астына
Һәм газ бирде, ике күзен йомып,
Карамаска теләп алдына.

Чәчәкләрне шытырдатып изеп
Чыгып китте авыр машина...
Снарядлар өлгерделәр килеп
Һәм яудылар дошман башына.

1942 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәр исемендә образлар каршылыгын күрәбез. Образлардан төшенчәләргә күчегез, каршылыкны фәлсәфи (гомуми, абстракт) атамалар белән әйтегез.

2. Шигырьдәге вакыйгаларны, образларны, фикерләрне ике өлешкә җыегыз.

3. Ике өлеш арасындагы бәйләнешне әйтегез.

4. Бәйләнеш әчтәлегеннән чыгып, шигырьдәге фәлсәфи фикерне әйтегез.

Шәрәф Мөдәррис
(1919—1963)

ПАРЧА

Үстем синең юмарт кулларыңда,
Туган илкәй, минем хисем пакь,
Әткәм, бабам йоклый туфрагыңда,
Иң гадел хак җирдә — синең хак!

Сугыш сулый иркен күкрәгеңдә,
Елый кырда кышкы буран, җил...
Ут бар җанда, яшь бар күзләремдә,
Әй газиз җир, минем туган җир!

1942 ел

Бирем

Шигырьне Ә. Ерикәйнең «Кырлар көйдерелгән җиргә киттем...» шигыре белән чагыштырыгыз. Уртак якларын һәм аермаларын табыгыз. Охшашлыкның сәбәбен әйтегез.

МИНЕМ МОҢЫМ

Сөйлә бүген йөрәк серләремне,
Әй син, җаным, минем гармуным...
Басам тагын синең телләреңне,
Басылмасмы, димен, зар-моңым...

Синең җырны әүвәл вакытларда
Тыңласалар барсы, таң калып,—
Тугыз ертык хәзер кабыргаңда,
Бөтен җирең бетте таушалып...
Мин дә, җаным, хәзер синең кебек,
Тугыз яктан тәнем сипләгән...
Бөдрә чәчкә ак чал сибелдереп,
Башкаемнанниләр кичмәгән!
Сугыш шул ул,— яшьлек гүзәллегем
Тузан-сөрем белән каплаган...
Шуңар микән минем күгәрченем
Язмый сәлам, язмый хат һаман...
Сөйлә бүген йөрәк серләремне,
Җырла, җырла, минем гармуным.
Биетә бүген синең телләреңне
Бөтен хисем, бар уй, бар моңым...

1943 ел

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз. Анда хакыйкать темасын табыгыз.

Сибгат Хәким

(1911—1986)

КУЛЛАР

Булмә син фикерен аның, әй
Кояшым, иртә батып.
Күр, ничек ихлас белән ул
Хат укый, кырын ятып.

Күп сәлам сезгә, дип язган
Хөрмәтле юллар да бар,
Ниндидер рәссам төшергән
Бик нәни куллар да бар.

Мин, димен, нигә юлыктым,
Сызланам, аны күреп,
Бер ача, иплəп, хатын ул,
Бер куя, кире төреп.

Чәнчә бармаклар микән ул,
Дип куям — бигрәк нәни.
Рәссамы инде моның, дим,
Күп гомер иткән әби.

Кулларын үбә аның ул
Сак кына, йомшак итеп,
Яшьләре тама рәсемгә,
Күңеле йомшап китеп.

Кояшым батты еракта,
Әй туган, җитәр, димен,
Бергәләп инде карарбыз
Калганын иртән, димен.

1942 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Лирик герой кичерешләренең сәбәбен табыгыз.

2. Лирик геройның юанычын күрсәтегез.

3. Шигырь ни өчен «Куллар» дип атала? Кулларның мәгънәләрен әйтегез.

4. «Куллар» шигырен бу еллар әдәбиятына хас хакыйкать темасы белән бәйләп буламы?

Әхмәт Фәйзи

(1903—1958)

ӘҮХӘДИНЕҢ ХАТЫНЫ МАЙШӘКӘР БЕЛӘН САУБУЛЛАШУЫ

Болай булды беркөнне:
Кайтып керде Әүхәди,
Хатынына дәшәргә
Базмый йөрде Әүхәди.
Үзе болай ни өчендер
Шатланган да шикелле,
Хатыны белән сөйләшүдән
Сакланган да шикелле:
— Хатын,— диде,— ачуланма,
Күңелемне күр, кадерлә,
Мин... Мин китәм... Кыскасы,
Чемоданны әзерлә.
Хатын әйтте:— Кая соң?
Командировкагамы,
Мәскәүгәме, Уфагамы,
Минзәләгә табамы?
— Фронтка! — дип, Әүхәди
Әйтте салды тиз генә.
Ышанмады хатыны,
Карулашты иренә:
— Бетмәс синең лыгырдавың,
Фронтка да фронтка!
Инде бер ел шул сүздән
Кайнатасың син ботка.
Кайчан беркөн минем белән
Чынлап сөйләшер икән,
Кайчан мине хатыны итеп
Иплән серләшер икән?

Әйтте салды Әүхәди:
— Уйнап әйтмим бу сүзне,
Хатынкаем, Майшәкәрем,
Чынлап әйттем бу сүзне.
Ышанмасаң, мә, укы! —
Кесәсендә чуалды.
Бик күп кәгазь арасыннан
Бер документ чыгарды.
Коелып төште хатыны.
Ни әйтергә белмәде,
Кинәт булган бу эшкә
Күңеле белән күнмәде.
Һәм ахырдан, аптырап,
Әйтеп салу кирәкме:
— Әйт, Әүхәди, чакыралармы,
Әллә... Үзең теләпме?
Чакырсалар нишлисең,
Бармыйнча чараң юк.
Үзең теләп китсәң әгәр,
Җибәрергә чамам юк.—
Кызып китте Әүхәди:
— Аңламыйсың, Майшәкәр,
Нәрсә булыр, һәркайсыбыз
Өйдә утырсак әгәр?
Юк, мин китәм, үзем теләп,
Йортымны яклар өчен,
Иремне, хатынымны,
Баламны саклар өчен.

Шулай дигәч, Майшәкәр
Йомшый төште, уйлады.
Яулыгының читен кабып,
Шыпырт кына елады:
— Аямыймын, Әүхәди,
Берни илем өчен мин.
Мин тик кара акылым белән
Шуны гына төшенмим...
Ялгызыңны фронтта
Кем кайгыртыр, яратыр,
Кем йокыңнан торуыңа
Сиңа кофе кайнатыр?
Кем әзерләр җылы су,
Кем җыяр урыныңны?
Төймәң төшсә, кем тагар,
Кем типчер оегыңны?—
Болай диде Әүхәди:
— Рәхмәт, хатын, ансына,
Мине назлап, тәрбияләп
Каравыңа, барсына.
Мин кешеләр татыганны
Татып карыйсым килә
Һәм, кыскасы, фашистка
Атып карыйсым килә...
— Аттың! — диде хатыны,—
Атып нишли аласың,
Бомба төшеп, ватып куйса
Күзлегең пыяласын?
— Дәшмә, хатын, күз ягын
Инде анда рәтләдем,
Мин просто күземнең
Рәтсезлеген әйтмәдем.

* * *

Төне буе йокламады,
План корды Әүхәди,
Әмма шуңа карамастан
Иртүк торды Әүхәди.
Аңардан да иртә торып,
Караңгылы-яктылы,
Юл кирәген әзерләп,
Төйнәп куйды хатыны.
— Кая,— диде Әүхәди,—
Әзерләгән әйберең?
Гадәтеңчә артыграк
Салмадыңмы кайберен?
— Юк-юк,— диде хатыны,—
Һич артыгын салмадым...
Хәтта әле куркып торам,
Җитәрме дип салганым.
Чемоданда юл кирәгең,
Зур төендә киемең,
Менә монда чәй белән
Шикәр салган төенең.
Саквояжга тавык белән
Куырылган каз салдым,
Сарык ите кило ярым,
Курκам, ахры, аз салдым.
Менә бусы бик кечкенә
Җиңел генә төенчек:
Кырык күкәй, бер кило май,
Ике кило эремчек.
Бу сумкада котлет белән
Егерме биш пәрәмәч...
Менә монсы әче кәнфит,
Пәрәмәчне тәмләгәч...
Менә бусы...
— Җитәр, хатын,
Тилергән дип белдеңме,
Әллә миңа аерым вагон
Бирерләр дип белдеңме?..—
Төеннәр янә чишелде,
Чемоданнар ычкынды,
Әйберләрне Әүхәди
Бушатырга тотынды.
Бушатылды каз, тавык,
Киметелде май, шикәр,
Ул бушатты, бушатканын
Кире салды Майшәкәр...
— Лыгырдама, Әүхәди,
Бер дә юкка ярсыма,
Юл газабы — гүр газабы,
Кирәк булыр барсы да...—

Сатулашты Майшәкәр, —
Карулашты Әүхәди.
Багаж шактый шиңгәч кенә,
Татулашты Әүхәди...

Кинәт кенә таралды
Куерып алган болытлар,
Шулай булмый, килеп җитте
Аерылышыр минутлар...

Майшәкәрен кочып алды,
Кадерлесен, якынын,
Һәм Әүхәди чын күңеленнән
Кысып үпте хатынын...

Озак үпте, дулкынланды,
Йөрәк леп-леп сикерде,
Иң беренче кавышканда
Кысып үпкән шикелле...

1944 ел

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Әмирхан Еники

(1909—2000)

БЕР ГЕНӘ СӘГАТЬКӘ

Авылдан ике километр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә. Авыл очындагы Галимҗан абзый йортының тәрәзәсеннән карасаң, кечкенә кирпеч станция бинасы күренә. Станциядән ике якка сузылган берничә рәт юллар кайчак буш була; кайчак исә ул юлларга озын-озын эшелоннар килеп туктый. Күп вакытта вагоннарның ишекләре ачык була, һәм аннан кешеләр сикерешеп төшеп, арлы-бирле йөри башлыйлар. Кайвакытта исә вагоннар ябык була, һәм алар җепкә тезгән уенчык вагоннар төсле булып күренәләр.

Галимҗан абзыйның хатыны Мәрьям абыстай өйнең кечкенә тәрәзәсеннән шул күренешкә карап торырга ярата иде. Элек аның мондый гадәте юк иде. Станциягә, поездларга күптән ияләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми һәм тәрәзәдән карап тору теләге бервакытта да күңеленә килми иде.

Инде сугыш башлангач, өч улы шул кечкенә станциядән, кызыл вагоннарга утырып, кояш батышына таба фронтка киттеләр. Мәрьям абыстайның исәбенчә, алар кайчан да булса шул ук юл белән, шундый ук вагоннарга утырып, шушы кечкенә станциягә кире кайтып төшәргә тиешләр иде. Һәм менә ул күңеле моңсу сагыш белән тулган яки бер дә сәбәпсез эче пошкан минутларда тәрәзәдән тимер юл буена карап торырга гадәтләнде. Ул сырт буйлап станциягә таба килгән

озын эшелонны күрә. Сырт өстеннән караган кояштан кечкенә вагоннарның зур кыек күләгәләре авыл ягына таба төшкән, һәм бу бер-берсеннән тигез яктылык белән аерылган кыек күләгәләр яшел чирәм өстеннән бик кызу куып баралар. Мәрьям абыстайның колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп ишетелә. Бу тавышны ул салкын кан белән тыңлый алмый, бу тавыш аның йөрәгенә төшә. Ул, поезддан кешеләрнең төшүен һәм авыл юлына кемнең дә булса килергә чыгуын көтеп, күзләренә җәелгән яшь томаны аша озак карап тора. Өч улының кайсысы булса да, кайчан да булса бер, килгән поезддан төшеп, авыл юлына чыгар бит!

Бүген исә Мәрьям абыстайның кәефе бигүк әйбәт түгел иде. Аның бөтен тәне авыраеп, башы томаланып тора, һәм кул-аяклары хәлсез яналар. Кәефе начар булуга карамастан, килене белән картының тышкы эшләрен бетереп керүләренә чәй урынын әзерләп куйды.

Карты белән киленен эшкә озаткач, Мәрьям абыстай иренеп кенә чәй урынын җыештырырга кереште. Килененең ун яшьлек кызы Зәйнәп кызу-кызу гына идәнне себерде дә каядыр чыгып йөгерде. Мәрьям абыстай ялгыз калды. Аның бары урынга гына ятасы килә иде. Ул хәтта, гадәте буенча, тәрәзәгә барып, тимер юл буена карарга да иренде. Чәй урынын җыештырып бетерүгә, мич буендагы сандык өстенә менеп, аркасын мичкә терәп, бөрешеп кенә ятты. Күпме-азмы ятканнан соң, ул йокыга талган кебек булды. Ләкин бу таза йокы түгел иде.

Менә бервакытны аның колагына «Әни!» дигән тавыш ишетелде.

— Әни!

Мәрьям абыстайның бөтен тәне буйлап кискен калтырау йөгерде.

Аның өстенә иелеп, кече улы Гомәр елмаеп карап тора иде. Мәрьям абыстайның күзләрендә бер секундка саташулы курку кабынган кебек булды. Гомәр һаман елмайган килеш, тыныч кына:

— Әни, курыкма, бу мин,— диде.

Мәрьям абыстай, терсәкләренә таянып, урыныннан күтәрелергә тырышты. Аның иреннәре кызу-кызу кыймылдый башлады:

— Улым, йа Алла, Гомәрем, синме бу?!— дип кенә әйтә алды.

Гомәр, әнисенең ике кулыннан йомшак кына алып, аны урыныннан торгызды.

Шул арада ишек бусагасында Зәйнәп күренде. Ул бер генә секундка тукталды һәм, өй эчен яңгыратып:

— Абый!— дип, бер кычкырды да яшен тизлеге белән ишектән кире тышка атылды.

Зәйнәп тавышы Мәрьям абыстайны, ниһаять, йокылы-уяулы хәлдән тәмам чыгарды. Ул күзләрен сөртә-сөртә сөйләнә башлады:

— Менә рәхмәт яугыры! Төшемме бу, дип торам. Поезд кычкырганны да ишетми калганмын лабаса... Йа Раббем, догаларымны бушка куймадың, инде Шакир белән Фатихымны гына күрәселәрем калды.

Шул арада тыштан кызу атлаган аяк тавышлары ишетелде һәм, ишек ачылып, Галимҗан абзый белән килене Камилә һәм Зәйнәп килеп керделәр.

Галимҗан абзыйның йөзе җыеп ала алмаслык тоташ бер елмаюга әйләнгән...

Ул, ике кулын сузып, каршысына күтәрелгән улына таба атлады.

— Улым, Гомәр! Бәрәкалла! Куаныч белән күрешер көннәр бар икән.

Камилә дә каенесе белән ике куллап күреште. Ул, чак ишетелерлек итеп:

— Исән кешеләр бер кайталар! — дип үксеп елап та җибәрде.

Галимҗан абзый битен сыйпагандай итте дә:

— Килен, балам, елама! — диде.— Менә берсе кайтты, синеке дә кайтыр. Хәбәре юк-югын, ләкин бит әле еларга да сәбәбе юк. Сабыр бул! Улым, бөтенләйгәме?

— Мин бик азга.

— Шулай да ике айгамы, бер айгамы, күпмегә?

— Юк, әти... мин бик аз вакытка, бары бер генә сәгатькә!

Бу хәбәрнең тәэсире барысына да шундый булды ки, гүя ул Гомәрнең авызыннан чыкмады, ә кайдандыр, стена аша килгән ят, ямьсез бер тавыш булып ишетелде, һәм алар бу тавыштан, ничектер, барысы берьюлы кинәт катып калдылар.

Гомәр хәлне төшендерергә ашыкты:

— Безнең эшелон станциядә, әти... Без госпитальдән фронтка китеп барабыз. Поезд бераз торасы булганга, мине менә сезнең белән күрешеп чыгар өчен бер генә сәгатькә җибәрделәр. Мин үзебезнең поездга өлгерергә тиешмен!

Барысы да бераз вакыт нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап тордылар. Алар шундый көтмәгәндә очрашу шатлыгы белән шундый тиз, кинәт аерылышу авырлыгын бер үк вакытта аңлау, тоюдан гаҗиз иделәр. Алар бу бер-берсе белән сыеша алмый торган ике капма-каршы хиснең кайсын чынга алырга, кайсына ышанырга, кайсысы белән бу минутта яшәргә кирәклекне белмиләр иде.

Галимҗан абзый карчыгы белән килененә карап алды һәм, тавышын күтәрә төшеп:

— Йә, нәрсә, мәрткә киткән шикелле катып калдыгыз? — диде.— Кешенең минутлары санаулы...

Уңган килен өй эшен бер итеп эшләргә керешге. Ул иң элек Зәйнәпне, читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте, самоварны җилтерәтеп идәнгә куйды, су өстәп, ут салып җибәрде. Учак астына ут якты...

Мәрьям абыстай, бер улына, бер картына карап, акрын гына тавыш белән:

— Ходаем, мунча да кереп өлгермәс микәнни!— ди.

Гомәргә әнисенең бу гаҗизлеген карау бик авыр иде. Аның йөрәге әнисен кызганудан сызлана башлады һәм күңеленә ихтыярсыз «Юкка үзләренә күрендем» дигән уй да килеп куйды. Ләкин ул күптән түгел генә кадерле күрешү минутларын уйлау белән тулы, йөрәге күпме шатлыклы хисләр татуны сизү белән бәхетле иде. Хәзер исә бу шатлык елмаерга өлгермәгән кояшның кара болыт артына яшеренүе кебек иде. Бигрәк тә әнисенең зәгыйфь йөрәген шундый капма-каршы тойгылар утына салуда үзен гаепле дип белү аның өчен авыр иде. Шуңа күрә ул күңелендә булган янә бер кадерле теләген — яратып йөргән кызы Заһидәне күрәсе килүен әтисе белән әнисенә сиздерүдән куркып утыра. «Заһидәне телгә алсам, бары аның өчен генә кайткан булып күренермен»,— дип уйлый иде ул. Тик җиңгәсенең Зәйнәпне, чакырып алып, каядыр йөгертүе аңарда бер өметле сизенү тудырды.

Менә төрле хәбәрне һәркемнән элек ишетеп, һәр урында бөтенесеннән алда килеп өлгерүче авыл малайлары һәм кызлары җыела башладылар.

Мәрьям абыстай Гомәрнең кесәсеннән өстәлгә бушаткан шикәрен балаларга:

— Менә, балам, Гомәр абыегызның күчтәнәче,— дип өләшә башлады.

Мәрьям абыстайның шулай, улым кайтты дип, балаларны сөендерергә тырышуыннан Гомәр әнисенең үзенә булган мәхәббәтен аеруча тирәнлек белән сизеп алды. Кайтып кергәч, беренче тапкыр диярлек ул күңеле нечкәрүен тойды һәм, күзләренә килмәкче булган яшьләрен тыяр өчен, ашыгып, маңгаен ышкырга тотынды.

Менә Камилә кайнап чыккан самоварны җитез генә өстәлгә алып куйды.

Мәрьям абыстай һаман сыеның ярлы булуына өзгәләнә:

— Ичмасам, тавык та суеп өлгерә алмадык! — ди.

Барысы да чәй эчәргә утырдылар. Гомәрне кыстау, аның ашау-эчүе турында сорашу белән җанлы сөйләшү башланды. Бу сөйләшү менә хәзер алда торган аерылышуны онытгырган кебек булды.

Гомәр фронтта башыннан кичергәннәрне кыска гына сөйләп алды. Мәрьям абыстай ахырда чыдамады, калтыранган тавыш белән:

— Әй улым, ничек исән калгансың! — диде.

Галимҗан абзый да, улының ашыкмыйча, сабыр гына сөйләвен, һәркемгә туры карап, тыныч елмаюын күргәч: «Малай башка-а!» — дип уйлап куйды.

Гомәр кул сәгатенә карап ала.

— Миңа кузгалырга вакыт җиткән икән, әти, рөхсәт итегез... Бик зур рәхмәт сый-хөрмәтегезгә, әйе. Сезне бик сагынган идем. Инде тиздән бөтенләй кайтуымны көтегез.

Мәрьям абыстай елый башлый:

— Газиз йөзләреңне күргән кебек тә булмадым.

Галимҗан абзыйның да йөзе караңгылана.

Нәкъ шушы минутта, ишекне киң ачып, Мәрьям абыстайның агасының улы, былтыр фронттан агач аяк белән кайткан Шәрифулла килеп керә. Ул, кочагын ачып, туры Гомәргә таба бара:

— Һо, Гомәр туганым! Мәрьям түти, бәгырем, нигә елыйсың? Шатлык бит бу!

— Әй Шәрифуллам, китә бит, китә!

Гомәр, ни өчендер, көчәнеп елмайган була:

— Шулай, Шәрифулла абый, безнең эшелон станциядә тора. Азрак булды, нишлисең...

Шәрифулла катгый рәвештә:

— Не смеешь, брат, не смеешь! — ди.— Без болай шаяруны яратмыйбыз. Кайткансың икән, торырга тиеш. Точка. Әйдә,

утыр! Син, брат, минем команданы тыңларга тиешсең! — Һәм чәшкәне тутырып аракы куя.

— Шәрифулла абый, син бит үзең армиядән кайткан кеше. Приказны үтәмәскә ярыймы?

Алар берничә секунд бер-берсенең күзләренә туры карап торалар. Ахырда Шәрифулла, уң кулын күтәреп:

— Да,— ди,— приказ — закон! Җизни, син аңлыйсыңмы, приказ — закон! Старшина Сәлимов дөрес әйтә. Ул китәргә тиеш! Ну, Гомәр, яңадан әйләнеп кайтырга...

Чәшкә белән аракыны суза. Гомәр ала.

— Мин дә шулай дим, Шәрифулла абый. Менә күп тә үтмәс, яңадан кайтып килербез.

— Обязательно кайтасың! Мәрьям түти, бәгырем, мәрҗән яшьләреңне юкка түкмә! Кайтам, ди, ишетәсеңме, кайтам, ди.

Мәрьям абыстай сүзсез, акрын гына елавыннан тәмам кечерәеп кала. Яшьләре аның, ана йөрәгендә изге бер чишмә ачылган шикелле, туктаусыз агалар.

Гомәр аракыны беткәнче эчеп куя.

— Әти, әни бәгырем, сез минем өчен артык янып көймәгез! Шәрифулла абый менә бик тиз аңлады. Сез дә аңларга тиеш — мине фронт көтә. Гитлерның эшен бетерәсе бар.

«Гитлер» дигән сүзне ишетүгә, Шәрифулланың күзләрендә хәтәр бер ут кабына:

— А, мин ул Гитлерны!

Ишек төбендә балалар күбәя. Күрше хатын-кызлар җыела башлый. Бу хәл Гомәрне шактый уңайсыз хәлгә куя. Ул соңга калудан чынлап курка башлый һәм тизрәк китәргә ашыга.

Ахырда алар тышка чыгалар. Гомәрне бала-чагалар, хатын-кызлар һәм кайбер авыл агайлары урап алалар. Исәнләшү һәм саубуллашу башлана. Гомәр агайларның төрле яхшы теләкләрен, мактап әйткән сүзләрен игътибар белән тыңлый. Шул ук вакытта ул, кешеләрнең башлары өстеннән тирә-ягына карап, кемнедер эзли. Ләкин ул юк, ул күренми...

Гомәр беренче тапкыр җиңгәсенә сорау белән карады. Камилә, өзгәләнеп:

— Зәйнәпне йөгерткән идем бит. Нишләп һаман юк икән? Кырга ук китеп барды микәнни?! — диде.

Гомәргә җиңгәсенең бу кадәр аның өчен өзгәләнүе кызганыч иде. Ул, күрешер өчен ике кулын сузып, акрын гына:

— Җиңги, борчылма,— диде.— Бик зур рәхмәт сиңа... Күп итеп сәлам әйтерсең!

Соңра Шәрифулла абыйсы белән үбешеп күрешә һәм, кискен генә борылып, иңбашындагы капчыгын рәтли-рәтли, юлга таба атлый. Аның артыннан Галимҗан абзый һәм, вак-вак кызу атлап, Мәрьям абыстай, янә бала-чагалар ияреләр.

Авылдан чыгуга, алар артыннан колхоз председателе җибәргән, җиңел тарантаска җигелгән туры ат килеп җитте. Кузлада председательнең ундүрт яшьлек улы Әдһәм утырган.

Соңга калудан куркып, ләкин хәлсез әнисен кызганып акрын барырга мәҗбүр булган Гомәр өчен бу атның көтмәгәндә куып җитүе бик урынлы булды. Ул этисе белән әнисен тарантас түренә утыртып, үзе кузлага менеп, артка карап утырды. Менә хәзер аның алдында туган авылы тоташы белән ачылды. Бер караш ташлау белән, ул авылның бөтен тыкрыкларын, таныш өй түбәләрен, авыл каршындагы сөзәк тауны, тау астындагы вак куаклыклар арасыннан боргаланып, яшеренеп аккан кеч-кенә елгачыкны, аның чәчәкле тар тугаен һәм авылның ике очыннан башланып киткән тигез, киң иген кырын күреп алды. Аның өчен туган җирнең бу күренеше йөргән юлларында күп очраткан, күреп күнегелгән гадәти генә бер күренеш иде. Ләкин җәй башының яшь, тансык, сөйкемле матурлыгы белән балкыган шушы тау битләре, шушы кырлар аңа атасы йорты кебек үк үтә таныш, аеруча якын иде. Ул, бу җирләргә карау белән, кайда нинди юл үткәнен, нинди сукмакларның кая алып баруын, кайда нинди чокыр, нинди куаклык, ничек дип аталган басу, печәнлек барлыгын бик ачык хәтеренә төшерде, күпме генә читтә йөрсә дә, аларны бервакытта да онытмаячагын аңла-ды. Янә үткәннең бер кадерле хатирәсе аның исенә төшмичә кала алмады. Әнә шул тау итәгендәге куаклар арасында, печән чапкан вакытларда, ул һәм Зәһидә ничек бер-берсе белән очра-шырга теләп йөриләр иде. Кызык, алар аулакта очрашкач, бер-берсенә сер сынатмаска тырышалар. Ул вакытта алар, берсе икенчесенең йөрәгендә нәрсә ятканын бик яхшы сизеп торса-лар да, бер-берсенә «сөям» дигән сүзне әйтә алмыйча калдылар. Тик Гомәр фронтка китеп, хат яза башлагач кына, алар үзен-нән-үзе туган кыюлык белән мәхәббәтләрен бер-берсенә ачкан-нар иде. Шуңа күрә ничек итеп, нинди караш, нинди тавыш белән бу сихри сүзне әйтүен ишетмәгән, инде минеке дип йөрәге белән тойган, ләкин үзенеке булуына күзләре белән күреп ышан-маган Зәһидәсен аның гаять күрәсе килә иде. Хәзер дә ул ерак-лаша барган авыл очына, Зәһидә күренмәсме дип, һаман карый бара, ләкин юл буш, авылдан ашыгып килүче күренми иде.

Гомәр, әти-әнисен ияртеп, үз вагонына якынлашуга, аларны солдатлар сырып алдылар. Киң илнең төрле якларыннан җыелган һәм кайсыдыр шәһәрләрдә, авылларда шундый ук карт әти-әниләре калган бу солдатлар чал кергән түгәрәк кара сакаллы, таза бәдәнле Галимҗан абзый белән ак йөзле, кечкенә буйлы Мәрьям абыстайга олы кызыксыну һәм эчке уйчанлык белән карыйлар иде. Гүя алар да хәзерге минутта күрешүне күз алларына китереп, шуның сагынычлы куанычын тоеп торалар кебек.

Мәрьям абыстай Гомәргә булган дуслык, якынлыкны ачык сизә, күңеле аның бу кешеләргә карата рәхмәт белән тула; эченнән: «Иптәшләре, Ходайга шөкер, әйбәт кешеләр икән!» — ди һәм улының киләчәк гомере, саулыгы өчен тынычлану тоя.

Ниһаять, паровоз озын итеп кычкырта һәм, көч җыйгандай, бераз бик куәтле шаулап тора. Соңра поездны акрын гына урыннан кузгата...

Гомәр, бу очрашу дәвамында беренче тапкыр бик җитди чырай белән:

— Йә, әти! — ди һәм әтисенә ике кулын суза.

Соңра Гомәр әнкәсенә карый. Ул, татар улларына хас тыйнаклык белән, бары күрешмәкче генә булган иде. Ләкин әнисенең шундый бер тирән газаплы мәхәббәт белән сүзсез караган яшь тулы күзләрен очраткач, ирексездән алга омтылып, аның кечкенә гәүдәсен күкрәгенә кыса... Ниһаять, ул, әнисеннән сак кына аерылып, ераклашып барган вагон артыннан йөгерә. Инде вагон ишегенең кырыена бөтен гәүдәсе белән туры басып артына караганда, аның йөзе гаепле сыман, кичерү сорагандай елмая, кысылып караган күзләре дымланып ялтырыйлар төсле.

Поезд кызулый. Мәрьям абыстай улының бөтен сыны күренеп барган вагон ишегенә йотлыгып карый. Ләкин аның күз аллары томалана. Вагоннар, бер-берсе белән кушылып, бик кызу алга шуган тоташ бер кызыл стена булып күренә башлыйлар. Гомәр шул тоташ кызыллык эчендә югала.

Авылдан станциягә таба, йөгерә-йөгерә, Заһидә белән Зәйнәп киләләр. Заһидә өстендәге җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган... Аның кыска калын толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалыйлар, кыр җиленнән һәм кояштан янып каралган киң маңгаена, борын очына тир бөртекләре чыккан.

Ул поездның киткәнен белә. Ул аның тавышын ишетте. Кызыл эшелонның сырт артына яшеренүен күрде. Гомәрне

алып киткән поездның ак төтеннәре, вак болытлар булып, станция өстеннән акрын гына йөзеп үтәләр — ул шуларны да күреп бара. Ләкин бара. Бу баруда, үз-үзенә хисап бирмичә, чынлык белән килешергә теләмәү тискәрелеге сизелә иде. Чыннан да, аның Гомәре шундый көтмәгәндә кайткан иде, аның Гомәре шундый тиз китеп тә барды. Ул, Заһидә, аны күрми дә калды. Болар бар да дөрес бит! Ләкин ни өчен дөрес? Ни өчен дөрес?..

Менә аларга станциядән кайтып килгән туры ат очрады. Галимҗан абзый кызның йөрәгендә ниләр кайнаганын бик яхшы сизеп алды. Ул, йомшак тавыш белән, ата булып, бары:

— Кызым, Заһидә, утыр безнең янга!— диде. Заһидә әүвәл башын селкеп куйды, соңра кискен генә бары бер сүз ташлады:

— Кайтмыйм!

Алар кузгалып киткәч, Заһидә, янә бераз бара төшеп, юл буена чирәмгә утырды. Ул беркемгә үпкәләми дә, беркемгә ачуланмый да иде. Ул бары йөрәге төбеннән күтәрелгән, бөтен тәне буйлап йөргән тиле ярсуны баса алмыйча азаплана. Ул янындагы үләннәрне йолкып-йолкып ала, аларны тешли яки калтыранган бармаклары белән бик вак итеп өзгәли. Янә ул һаман бугазына күтәрелгән төерне кире йота алмаудан гаҗиз иде. Ул тырыша, ачу белән башын селкеп куя, аскы иренен тешләп тора, ләкин юк — төер һаман бугазына килә. Ахырда ул башын кинәт тезләре өстенә сала һәм һичбернинди тыелусыз, иңбашларын калтырата-калтырата елап җибәрә.

Икенче көнне Галимҗан абзыйның йортында гадәттәге тормыш, үз ярлары эченә кайткан елга кебек, акрын гына ага башлады. Ләкин бу тыштан гына шулай иде. Асылда өй эче Гомәрнең күзгә күренмәс рухы белән тулы кебек, һәм кешеләрнең шул рухның әсирлегеннән чыкканнары юк иде. Гомәрнең җанлы кыяфәте һаман басып тора, башларыннан аның турында уйлау чыкмый.

Галимҗан абзыйның гадәтендә хыяллану булмаса да, ул да улы турында уйланудан туктамый иде. Ул аңа буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ир-егет булып күренде. Ул Заһидә турында да уйланып куйды.

Камилә килендә Гомәрнең кайтып күренүе сүнеп барган өметләрен яңадан тергезде. Ике елдан бирле хәбәре булмаган ире Фатих исән-саудыр төсле булып тоелды. Аның да шулай көтмәгәндә кайтып керүенә ышанасы килде.

Мәрьям абыстай исә, бичара, Гомәрнең һәр сүзен, һәр карашын, һәр хәрәкәтен күз алдыннан һич югалтмаска тырыша. Өй түре тәрәзәсенә барып, тимер юл буена карый. Менә аның каршында карт юкәләр ышыгына яшеренгән кызыл түбәле станция һәм станциядән ике якка сырт буйлап еракка, бик еракка сузылып киткән тимер юл... Станция буш... Көмеш дилбегә шикелле ялтырап яткан тимер юл тыныч... Күк аяз. Ерак кырлар түрендә күгелҗем сыек томан. Бу томан, эчендә исәпсез күп энҗе тузаны йөзгән шикелле, җем-җем килеп, күзләрне кытыклап тибрәнә... Һәм күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора.

Мәрьям абыстайның иреннәре акрын гына кыймылдыйлар:

— Кайтыр, күз нурым, кайтыр!

1944 ел

«Бер генә сәгатькә» хикәясенең төзелеше

Анализ әсәрнең төзелешен табудан башлана. Төзелешен табу өчен, хикәяне бик гадиләштереп күз алдына китерергә кирәк. Төзелеш ике вакыйганың үзара мәгънәле бәйләнешеннән дә, хисләр, фикерләр каршылыгыннан да торырга мөмкин. Хикәяне, шул рәвешле, гадиләштереп күзаллау өчен, андагы охшаш урыннарны җыеп гомумиләштерик.

Ә гомумиләштерергә мөмкин булган урын — күпчелек персонажның уртак теләге. Галимҗан абзый да, Мәрьям абыстай да, Камилә дә, Зәйнәп тә — бар да Гомәрнең өйдә озаграк торуын телиләр. Уртак теләк әле үкенеч, әле гаделсезлек, әле өмет булып әсәрнең буеннан-буена сузыла.

Изге теләккә сугышның кырыс мәҗбүриятлеге каршы тора. Гомәр аңа сүзсез буйсынырга тиеш. Сугышның инде безгә таныш хакыйкате шуннан гыйбарәт. Гомәр үзе, аның командиры, фронтовик Шәрифулла, вагондагы башка сугышчылар да сугышның бу таләбе хакыйкать булуына аз гына да шикләнмиләр. Приказның үтәлергә тиешлеген Гомәр берничә мәртәбә кабатлый. Гомәрне азга гына булса да калдыру теләге, ләкин аның кала алмавы хикәя драмасын тудыручы каршылык.

Хикәя төзелешен тәшкил иткән бу ике өлешне әдип хисләр каршылыгы итеп тә ача. Очрашу һәркемгә шатлык белән бергә хәсрәт тә китерә. Шундый каршылыклы хисне Гомәр үзе дә

кичерә: бер яктан, кайтуына чиксез шатлана, икенче яктан, кайтуы белән башкаларга хәсрәт тудыруын күреп хәсрәтләнә.

Бер-берсен яраткан кешеләрнең очрашуы кебек гадәти вакыйга сугыш шартларында көтелмәгән эчтәлек ала. Персонажларның һәркайсы бу очрашуның соңгы очрашу булу мөмкинлеген бик яхшы аңлый. Башкалар — Гомәргә, Гомәр туганнарына онытмаслык итеп карап калырга тырыша. Бер очрашу — бер гомер, ди халык. Шул рәвешле, Гомәр карамагындагы бер сәгать эченә кешеләрнең бөтен бер гомере сыя. Бер сәгать белән бер гомер озынлыгы каршылыгы да хикәя төзелешенең бай эчтәлеген ача.

Хикәядә сөйләнгән вакыйга гади генә: Гомәр бик аз вакытка гына өенә кайтып китә. Әмма шул гади генә вакыйга эчендә дә әдип сугыш һәм тормыш хакыйкатьләренең каршылыгын фәлсәфи проблема итеп күтәрә алган. Бу проблема бөтен әсәр үзәгендә тора. Әмма аны автор Заһидәдән әйттерә.

Сөйгәне белән күрешү бәхетенә ирешә алмагач, кыз, бу кырыс, рәхимсез чынлыкның хакыйкать булуына аптырап: «Болар бар да дөрес бит!» — ди. «Ләкин ни өчен дөрес? Ни өчен дөрес?..» — дип, үзе әле генә таныган дөреслекне юкка чыгара. Заһидә сугыш хакыйкатенең аерым шәхесләр, гаиләләр бәхетенә каршы, хаксыз, табигый булмаган, гаделсез хакыйкать булуын әйтә.

Кызның ачынып әйткән бу сүзләрен автор хикәясендәге һәр персонажыннан әйттерә алыр иде. Алар бар да Заһидә кебек уйлыйлар, шул ук фикерне башка сүзләр белән генә әйтәләр яки уйларында калдыралар.

Сугыш елларында иҗат ителгән әсәрләрнең төп темасы батырлык булуы гаҗәп түгел. Әдәбият та дошманга каршы сугышты. Үзенчә сугышты. Исән калган язучылар барысы да диярлек фронтта. Бар да дошманга булган нәфрәтләре, батыр сугышчылар турында яздылар.

Әмирхан Еники дә — сугышчы. Ул беренче хикәяләрен генә яза әле. «Бала» хикәясе ут эченә керергә ашыгучы рота солдаты Зариф турында. Ул, адашкан бала күреп, стройдан рөхсәтсез-нисез китә дә баланың әнисен эзләп чаба. «Ялгыз каз» хикәясендә сугышчылар адашкан казны иялəштереп, аның бәбкәле булуына ихлас шатланалар. «Мәк чәчәге»ндә сугышчы бомба шартлап ясаган чокырдагы мәк чәчәген күреп, аның батырлыгына, матурлыгына сокланып туя алмый. Ә чәчәк аңа якын

дусты итеп сүз ката. «Бер генә сәгатькә» хикәясе сугышчы егетнең сугышка үтеп барышлый, өенә кайтып, аз гына арада туганнары белән очрашуы турында.

Әмирхан Еники сугыш еллары турында тагын-тагын язачак әле. Ләкин әнә шул баштагы хикәяләрендәге темага тугры булып калачак. Әсәрләрдә сугышчылар сугышмыйлар. Ярата-лар, сагыналар, сокланалар...

Әмирхан Еники иҗатының башында ук сәнгать мәйда-нында үз сукмагы белән киткән. Ә сукмагы аны сугыш гәрел-теләре арасында күзгә чалынмый яшәгән, хәрәкәте ишетелми торган хәтер, күңел дөньясы эченә илткән.

Әмирхан Еники гап-гади татар егетләре батырлыгының нигез ташы булган күңел дөньялары турында яза.

Биремнәр һәм сораулар

1. Хикәядә персонажлар теләгенең һәм мәҗбүриятлекнең кабатла-нуын исбат итегез.

2. Әсәр ни өчен «Бер генә сәгатькә» дип аталган? Аның әсәрдәге бар-лык бәйләнешләрен санап чыгыгыз.

3. Бер сәгатьнең әсәрдә бер гомергә торуын исбат итегез.

4. Хикәя вокзал күренеше белән башлана, шул ук күренеш белән тәмамлана. Бу кабатланган күренеш әсәр эчтәлегенә нинди фикер өстәргә мөмкин?

Муса Җәлил
(1906—1944)

Муса Җәлил элеккеге Оренбург губернасының Мостафа авылында туа. Башта Муса үз авылында, аннары Оренбургтагы танылган «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Хәрби-партия мәктәбен, рабфак, ә аннары Мәскәү дәүләт университетының әдәбият факультетын тәмамлый.

Шагыйрь гомеренең шактый өлешен комсомол белән бәйли. Үз авылларында комсомол комитеты төзүдә катнаша, Орск, Оренбург, Мәскәүдә комсомол комитетларында эшли. Берничә ел буена Мәскәүдә чыга башлаган «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларында җаваплы редактор, «Коммунист» газетасының бүлек мөдире вазифаларын башкара. Татар опера студиясе оеша башлагач, газета эшен калдырып, студиянең әдәби бүлек җитәкчесе була. Студия белән бергә Муса Җәлил дә, ниһаять, 1938 елда Казанга кайта. Монда шагыйрь, җиң сызганып, опера театрын булдыру эшенә керешә. «Алтынчәч» исемле сценарий яза һәм аны сәхнәләштерүгә булыша.

Әдипнең зур планнарын сугыш өзә. Ул сугышның башында ук фронтка китә. Муса Җәлил Волхов фронтындагы 2 нче удар армия сафында сугыша.

1942 елның җәендә армия чолганышта кала. Утлы боҗраны вак-вак төркемнәргә бүленеп өзәргә дигән приказ була. Бер төркем сугышчылар белән утлы боҗраны өзгән чакта, шагыйрь каты яралана һәм аңын югалта. Шул хәлендә аны дошман әсир итә.

Фашистлар әсирлегендә Муса Җәлил 791 фаҗигале көн үткәрә. Бу көннәрдәге төрмә авырлыкларын, сагыну газапларын сөйләп кенә бетерерлек түгел. Бу җәфаларга тагын

шагыйрьнең рухи газабы да өстәлә. Әсирлеккә төшү төрле шартларда була. Әмма идеология шартларны исәпкә алмый. Аның өчен әсирләрнең барысы да — хыянәтчеләр. Моңа кадәр Муса Җәлил үзе дә шул фикердә торган булырга тиеш. Ул иҗатының буеннан-буена Туган илгә тугрылыгы турында язды. Туган иле өчен соңгы тамчы канын да кызганмаячагына антлар итте. Хыянәтчеләрне, әсир төшүчеләрне нәгъләтләде. Хәзер менә үзе әсир хәлендә. Аның турында илдә ни диләр?

Фашистлар тоткынлыгында шул уйлар белән яту Муса Җәлилгә үлем көтү газабыннан да авыррак булган.

Муса Җәлил тоткында да дошман белән көрәшүне дәвам итә. Ышанычлы иптәшләре белән берлектә яшерен оешма төзи һәм татар әсирләре арасында пропаганда алып бара. Нәтиҗәдә Туган илгә каршы көрәшергә тиешле татар батальоны, үзләрен саклаучы немецларны кырып, тулы килеш безнең якка чыга.

Фашистлар яшерен оешманың эзенә төшәләр. Муса Җәлил үзенең унбер иптәше белән үлемгә хөкем ителә. Унбер батыр хөкемнең гамәлгә ашырылуын җиде ай буена көтә. Җәлилчеләрнең башларын 1944 елның 25 августында кисәләр. Җәза вакытында катнашкан руханиның әйтүенә караганда, «татарлар елмаеп үләләр».

Муса Җәлил «Бәхет!» исемле беренче шигырен унөч яшендә үк бастыра. Бу шигырендә ул үзен гражданнар сугышының бер батыры итеп хис итә. Халыкны ирек өчен көрәшкә чакыра һәм соңыннан күп мәртәбә кабатлаячак фикерен әйтә: ирек өчен көрәшеп үлү — зур бәхет ул, ди.

Ирек өчен көрәшүче батыр — эдипнең аеруча яратып язган героена әйләнә.

Соңрак ирек Муса Җәлил өчен Туган ил белән тиңләшәчәк. Сугышка кадәр иҗат иткән шигырьләренең күбесен ул Туган илгә дан җырлауга багышлый.

Туган ил дигәндә, әдип гомумән совет илен күз алдында тота. Совет илен дөньяда иң бәхетле, иң ирекле, иң көчле, иң алдынгы ил дип мактый.

Илнең яшәү рәвеше көрәш булганга, халыкның бәхете көрәшче булудан гыйбарәт. Әдип үзен бәхетле дип саный, чөнки көрәшчеләрнең алгы сафында баручы кеше дип исәпли.

Туган илен ул, Мин һәм Туган ил дип, икегә аермый:

> Минем гомерем кирәк бер таш булып
> Кереп ятты шул йорт нигезенә,—

дип яза.

Шуңа күрә Туган ил эчтәлегенең күп өлешен идеология алып тора дигән нәтиҗәгә килә алабыз.

Идеологиянең хакыйкать булуына Муса Җәлил шикләнми. Идеология кеше гомерен бервакытта да санга сукмады. Шуңа күрә әдип Туган ил өчен үләргә әзер торуы турында кат-кат яза. Моның белән ул үзенең илгә тугрылыгын һәм мәхәббәтен исбат итә. Ләкин шуның белән бергә, идеологиягә ияреп, Ил өчен үлүнең бәхет булуын хакыйкать итеп раслый.

Бөек Ватан сугышын Муса Җәлил танылган шагыйрь, тормышка гашыйк бәхетле кеше булып каршылый. Әмма Ватанга тугрылыгын бөтен иҗаты буенча хакыйкать итеп исбат иткән шагыйрь күп тә үтми әсир төшә.

Шундый фаҗига Муса Җәлил шигырьләрендә ничек чагыла? Җавапны әдипнең сугыш елларында иҗат иткән шигырьләреннән эзлибез. Әйдәгез, шул шигырьләрне өйрәник.

ӘЙДӘ, ҖЫРЫМ!

Җырым, синдә минем гәүдәләнде
Илне сөйгән йөрәк тибешем.
Җырым иде антым:
«Яшәсәм дә,
Үлсәм дә тик Туган ил өчен!»
Сугарылып халкым назы белән,
Җимешләнеп, җырым җитеште.
Чагылдырды җырым шат илемдә
Данлы, иркен, рәхәт яшәүне.
Чишмә төсле җырым тамчысыннан
Яшь күңелләр үсте, яшәрде...

Килде фашист...
дуңгыз борны белән
Керде җимереп илем капкасын.
Эшкә җикте
бөтен Европаны
Ваткан, кискән канлы балтасын.
Вакыт җитте...
хәзер ярты юлда
куеп торып тыныч эшемне,
Багышларга Ватан сугышына
Үземне һәм каләм көчемне...

1941, август

Биремнәр һәм сораулар

1. Галиәсгар Камал гражданнар сугышы елларында язган шигырьләрен, эчтәлекләре өндәү, чакыру, дошманны мәсхәрәләүдән гыйбарәт булганга, «декламация» ди. «Әйдә, җырым!» шигыре дә, лирик булудан бигрәк, декламациягә тартым. Шуңа күрә аны, беренче фикер, икенче фикер дип, төрле фикерләргә бүләбез.

Шигырьне, ике генә өлешкә калдырып, фикерләргә бүлегез.

2. Беренче фикерне, шигырьдә әйтелгәнчә, тулыландырып сөйләгез.

3. Дәреслектә шигырьнең яртысы гына басылды. Икенче яртысында Муса Җәлил ни язган? Калган өлешнең эчтәлеген төзек итеп сөйләргә әзерләнегез.

ЧУЛПАНГА

Постта торып, бүген таң аттырдым,
Чулпан йолдыз калыкты, нурланып.
Чулпан кызым шунда күз алдыма
Килеп басты, сузып кулларын.
Киткән чакта, кызым, нигә шулай
Күзләремә әрнеп карадың?
Сизденмени әткәң йөрәгенең
Синең янда өзелеп калганын?
Сизденмени синнән аерылуның
Үлем төсле ачы булганын?..
Сизденмени синнән аерылганга
Әткәң күңеле шулай тулганын?..
Тәрәзәдән озак карап бардым,
Шәүләң торды күзем алдында.
Син янгансың икән йолдыз төсле,
Нурың сибеп гомрем таңында.
Әниең белән, кызым, сез икегез
Тормышымның нуры идегез.
Сокланырлык матур тормыш безгә
Бүләк иткән иде илебез.
Фашист керде басып җиребезгә,
Аркасына асып балтасын...
Ул яндыра, вата илебезне,
Ничек шуңар түзеп ятасың?..
Киттем, кызым, якты бәхтебезне
Бирмәс өчен фашист кулына;
Егылсам да алга егылырмын,
Киртә булып дошман юлына.

***

Мин саклармын, йөрәк каным белән,
Илемне һәм сезне, аппагым!
Шатланырмын күреп һәр таң саен
Үз илемдә Чулпан калыкканын.
Мәңге сүнмәс минем каным белән
Җиргә туган якты Чулпаным;
Сиңа биреп йөрәк тибешемне,
Мин гүремдә тыныч йоклармын;
Ян, йолдызым, якты нурларыңда
Чагылдырып минем гомерне!..
Синең бәхтең өчен һич сызланмый
Каршы алам көлеп үлемне...
Хуш, аппагым, алсу таң атканда,
Нурлар сибеп Чулпан калыкканда,
Мин кайтырмын сиңа,
Җиңү даным —
Автоматым булыр аркамда,
Без аталы-кызлы кавышырбыз,
Яшь аралаш көлеп, шатланып,
Һәм карарбыз илдә давылдан соң
Матурланып ал таң атканын.

1941, 19 август

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьнең фокусын табыгыз. Шигырь эчтәлеген фокус аша табып карагыз.

2. Әсәрне «Әйдә, җырым!» шигыре белән чагыштырыгыз. Эчтәлекләрендәге охшашлыкны табыгыз.

3. «Чулпанга» шигырендәге Туган ил эчтәлеген табыгыз.

Әсәргә анализ

Шигырьнең эчтәлеге лирик герой хисенең сәбәбе, дәрәҗәсе һәм юану булуын беләбез. Безгә таныш юл белән барыйк һәм әсәрне хиснең шул өч өлешенә бүлик. Бу очракта автор кызын үз исеме белән атый, шуңа күрә лирик геройны Муса Җәлилнең үзе белән тиңләштерә алабыз.

Безне шигырьнең сәбәбе — сагыну дию генә канәгатьләндерми. Шуңа күрә әсәрдә сагыну-аерылу турында әйтелгән урыннарны игътибар белән тагын бер кат күздән кичерик.

Муса Җәлил кызы Чулпанны кулын үзенә таба сузган килеш күз алдына китерә. Бу хәрәкәтне фәкать чакыру, үз яныннан җибәрергә теләмәү, кочакларга омтылу дип кенә аңларга мөмкин. Шуңа күрә кызның сурәте аның хисләре турында сөйли дип нәтиҗә ясыйбыз. Аерылу вакыты турында сөйләгәндә, Муса Җәлил үз хисләренең дәрәҗәсен күрсәтә кебек. Йөрәгенең өзелеп калуы, аерылуның үзенә үлем кебек ачы булуы, күңеле тулуы турында әйтә. Ләкин авторның бу кичерешләре постта торган вакыттагы кичерешләре түгел — хәтердә сакланганнары, искә төшкәннәре. Монда да сүз кыз хисләре турында бара. Чулпанны искә алганда, Муса Җәлил кызының, этисе хәсрәтен күреп, «күзләренә әрнеп каравы» турында әйтә.

Шуларны ачыклаганнан соң, әдип кызы белән хушлашу минутларын искә алганда үз хисенең ике сәбәбе турында яза: 1) кызын күрәсе килү (сагыну) һәм 2) кызының этисен сагынып хәсрәтләнүе дип нәтиҗә чыгарабыз.

Әмма Муса Җәлил бу ике сәбәп белән генә дә канәгатьләнми, кичерешләрен тагын да тулырак ачу өчен тагын бер сәбәп әйтә. Кызына мөрәҗәгать итеп:

Син янгансың икән йолдыз төсле,
Нурың сибеп гомрем таңында,—

ди. Кызына булган мәхәббәтенең вакыт үткән саен көчәя баруы — постта күккә карап моңаеп торган шагыйрь хисләренең өченче сәбәбе.

Әсәр соңындагы көрешү хыялларының юану булуын белү кыен түгел.

Туган ил темасы «Чулпанга» шигырендә дә кабатлана. Монда да әдип Туган ил темасын аның иреге өчен үлү шатлыгы белән бәйли. Ләкин хәзер, ил турында сөйләгәндә, кызы Чулпанны да күздә тота:

Синең бәхтең өчен һич сызланмый
Каршы алам көлеп үлемне... —

ди.

Туган ил эчтәлеге бу шигырьдә, шул рәвешле, конкретлаша төшә, кешегә якыная.

Табигать матурлыгы буларак йолдыз шагыйрьне сокландыра, уйландыра, аның уй-хисләрен туган якларына алып китә.

Исемнәре уртак булу сәбәпле, йолдыз шагыйрьнең кызын алмаштырып килә. Матурлыгы, еракльиы, нурлары белән шагыйрьнең сагышын арттыра төшә.

Чулпан йолдыз әсәрдәге Туган ил темасы белән дә бәйләнешкә керә. Ул Муса Җәлилнең җиңүгә нык ышануын күрсәтә:

Шатланырмын күреп һәр таң саен
Үз илемдә Чулпан калыкканын,—

ди автор һәм әсәрен:

Һәм карарбыз илдә давылдан соң
Матурланып ал таң атканын,—

дип тәмамлый. Ал таңның шулай ук Чулпан йолдыз белән бәйләнештә торуын искә төшерик. Ал таң, таңда туган Чулпан йолдыз Туган илнең матур киләчәгенә метафора булып килә.

Чулпан йолдызының биеклек, яктылык, ераклык кебек метафора вазифасын үтәрлек үз сыйфатлары да җитәрлек. Ләкин шулар өстенә аның халык биргән башка эчтәлеге дә бар. Халык җырларында Чулпан йолдыз аерылу, ялгызлык, сагыш билгесе булып килә. Эчтәлегендәге шундый өстәмә байлыклары белән Чулпан йолдыз фокус вазифасын менә дигән итеп үти.

ХУШ, АКЫЛЛЫМ

(Әминәгә истәлек)

Хуш, акыллым, соңгы сәламемне
Юллыйм сиңа җилләр аркылы,
Барсын сиңа, кайнар сәлам булып,
Йөрәгемнең сүнмәс ялкыны...

Киттем, дускай, кайнар өмет белән,
Дошман явын җиңеп кайтырга.
Батырларча каты сугышырга,
Тап төшерми изге антыма.

Бик күңелле булыр җиңеп кайтып,
Бил кысышып җылы күрешү;
Өмет, җаным, болай шәп шәбен дә,
Ләкин... сугыш уен түгел шул!..

Хуш, акыллым, әгәр кайталмасам,
Яраланып юлда егылсам,
Йөрәгемдә саклап ялкынынны,
Акрын-акрын тәнем суынса,
Хуш, акыллым!..

Соңгы кабат назлап үбүеңне
Мин тоярмын салкын иренемдә.
Син татлы су миңа эчергән күк
Авыр сулап яткан җиремдә.

Йолдызларга карап, мин сагынырмын
Күзләреңнең җылы карашын,
Җилләр сыйпар, синең кулың булып,
Күкрәгемнең тирән ярасын.

Ахыр чиктә синең саф сөюең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын.

Татлы булыр йокы...
Тормышымны
Батырларча бирсәм ил өчен,
Тормыш дустым, синең йөрәгеңдә
Дәвам итсә йөрәк тибешем.

1941, 9 сентябрь,
Марьино

ОКОПТАН ХАТ

(Гази Кашшафка)

Кадерле дус!
Кайнар йөрәгемдә
Дәрт кабызган җылы хатыңны
Укыдым да, тотып мылтыгымны,
Кабатладым изге антымны.
Мин кечкенә кеше, тар окопта
Кечерәям булыр тагын да.
Ә шулай да бөтен дөнья бүген
Урын алган минем аңымда.
Тар окобым —
чиге капма-каршы
Ике көчнең, ике дөньяның.
Хәл ителә анда кешелекнең
Киләчәге, якты идеалы...

Юк, мылтыгым,
		синең утың белән
Мин сакламыйм бары үземне,
Мин кабатлыйм Гитлер бандасына
Халкым кушкан җавап сүземне.
Күңел тоя:
		илнең көчле тавышы
Яңгырый һәрбер мылтык атуда.
Күңел тоя:
		миңа терәк булып,
Бөек халкым тора артымда...
Канат җәеп, үлем куркынычы
Торган саен окоп алдымда,
Мин көчлерәк тоям ирек тәмен,
Яшәү дәртен кайнар канымда,
Күзләрдә яшь,
		беләм: алар горур
Яшәү хисе белән яшьләнгән.
Нәрсә артык җирдә,
		илне саклап,
Тар окопта батыр яшәүдән?!

* * *

Рәхмәт, дустым,
		салкын чишмә төсле
Татлы сүзең җанга көч бирде,
Илдәге дәрт, ирек, яшәү хисен
Хатың аша миңа күчерде.
Кил, дускаем, шушы хат аркылы
Саубуллашып, кайнар үбешик,
Соңгы теләк:
Җиңеп фашизмны,
Якты илдә тагын күрешик.

1941, октябрь

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьләргә анализ ясагыз.

2. Шигырьләрендә Муса Җәлил биргән анты турында сөйли. Әдип нинди анты турында әйтергә мөмкин?

3. Бу ике шигырьне «Әйдә, җырым!», «Чулпанга» шигырьләре белән чагыштырыгыз һәм аларның уртак якларын, аермаларын табыгыз.

4. Бу шигырьләрдә Туган ил эчтәлегенең ачыклана баруы турында сөйләгез.

5. Шигырьләрнең уртак якларын һәм аермаларын тапканнан соң, кыска гына итеп нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

Анализлар нәтиҗәсе

Нәтиҗә ясар өчен, шигырьләрнең уртак якларын һәм аермаларын табабыз.

1. Әсәрләренең өчесендә дә шагыйрь Туган илгә тугрылыгы һәм мәхәббәте турында яза. Шулай итеп, сугышка кадәр иҗат иткән шигырьләренең эчтәлегенә салган бу темасына фронтта да тугрылыклы булып кала.

2. Шигырьләрнең өчесендә дә лирик герой хисенең эчтәлеге туган яктан аерылу булуын күрәбез. Әмма бу әсәрләрдә Туган ил гомуми төшенчә генә түгел. Аның эчтәлегенә кызы да, хатыны да, дусты да керә. Туган илгә мәхәббәт, шулай итеп, кызына, хатынына, дусларына мәхәббәт белән тиңләшә. Туган ил эчтәлеге конкретлаша, шагыйрьнең хисе һәм күз хәтере саклаган чынлык белән байый.

3. Әсәрләрдәге аерымлык та беренче чиратта эчтәлектә күренә. «Чулпанга» шигырендә әдип Туган ил өчен үлүнең бәхет, шатлык булуын, нәкъ беренче шигырендәгечә, пропаганда рәвешендә яза. Шуңа күрә шигырьдәге бәхет һәм шатлык хисе, хис булудан бигрәк, идеология рәвешендә кабул ителә. «Әйдә, җырым!» шигырендә инде лирик герой үләргә атлыгып тормый. Үлем куркынычы әдипне шомландыра. Ә менә «Окоптан хат» шигырендә Муса Җәлил үзендә яшәү дәрте янганга шатлана.

КИЧЕР, ИЛЕМ!

Кичер мине, илем, синең бөек
Исмең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым.
Волхов шаһит, изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез сакладым.

Мин курыкмадым, өстән яңгыр төсле
Яуганда да туплар, ядрәләр,
Каушамадым, кан һәм үлек белән
Тулганда да тирә-әйләнәм.

Алда, артта, уңда һәм сулымда
Киселсә дә юлым, күкрәгем
Яраланып канга төрелсә дә,
Көчсезләнеп, мин яшь түкмәдем.

Мин алдымда күрдем шыр сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары гомрем
Коллык белән төгәлләнмәсен!

Мин түгелме дуска хат язучы:
«Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!»

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
«Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта».

«Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын».

«Тыныч булыр йокы, тормышымны
Бирсәм, диеп, Туган ил өчен».
Ышан, илем, шушы ант сугарды
Йөрәгемнең соңгы тибешен!

Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан, минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш ияргә шуннан башкага?!

Ышан, илем, шундый бөркет идем
Мин дә, соңгы минут килгәндә,
Әзер идем, мәгърур канат җәеп
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым — пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән.

Көн чыгышы дуслар кулындагы
Байрак булып көн дә кызара.
Белмисез лә, дуслар, тоткын күңел
Күкрәктәге җәрәхәттән түгел,
Канлы үчтән шулай кыза ла!

Тик бер өмит: кара август төне
Илтер мине шунда, җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.

Тик бер өмит, дуслар, сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

1942, июль

Шигырьгә анализ

Шигырь озын, катлаулы. Гадирәк итеп күзаллау өчен, аның охшаш урыннарын бергә җыеп, исемнәр бирик.

6, 7, 8, 9 нчы строфаларын Муса Җәлил шигырьләрендә күп тапкырлар язган антларын искә төшерүгә багышлый. Уртак эчтәлекләреннән чыгып, бу өлешкә «Ант» дип исем бирәбез.

1, 10, 13, 14, 15 строфаларында шагыйрь «хурлыклы юлдан атлавы», әсир төшүе, ягъни күп тапкырлар биргән антын үти алмавы турында яза. Шуңа күрә бу өлешкә «Үтәлмәгән ант» дип исем бирә алабыз.

Икенче строфада Муса Җәлил, «Изге сугыш антын / Соң чиккәчә керсез сакладым» дип, гомуми сүзләр белән әйтә дә 3, 4, 11, 12 нче строфаларда гомуми сүзләрен *курыкмадым, зарланмадым, каушамадым* дип ачыклый. Әсирлеккә төшүенең сәбәбен әйтә: пистолетым итте хыянәт, ди. Бу өлешкә «Элек биргән антка тугрылык» дип исем бирә алабыз.

Шигырьдә беренче карашта башка өлешләренә бәйләнешсез булып тоелган бишенче строфа бар. Муса Җәлил әсәрендә иң кыен чакта да сер бирмәве турында сөйли-сөйли дә, «Кил син миңа, үлем, бары гомрем Коллык белән тәгәлләнмәсен!» дип, көтмәгәндә башка темага күчә. Шагыйрьнең үлем турында күп язуын яхшы беләбез. Әмма бу юлы үлемне әдип һичнинди идеологик төсләргә буямый, пропаганда вазифасыннан арындыра. Хәзер үлем шәхси юаныч, хурлыктан котылу чарасы булып, ягъни үзенең төп эчтәлеге белән килә.

«Кичер, илем!» шигырендә Муса Җәлил антына тугрылыгы һәм хыянәт итүе турында сөйли, дидек. Әмма әдип әсир төшүнең ачы хакыйкать булуын яза да шунда ук әсирлекнең һәр очракта да хыянәт була алмавын исбат итә.

Бу шигырендә Муса Җәлил беренче мәртәбә аерым шәхес хакыйкатен чын хакыйкать югарылыгына күтәрә. Ләкин шуны ничек башкаларга җиткерергә һәм шуңа башкаларны да ышандырырга?

Шигырьнең күп өлеше шуңа багышлана да: исеме дә, әдип намусының керсез булуын, авыр чакларда каушап калмавын, дошманга үче артканнан-арта баруын кат-кат кабатлавы да шул хакта сөйли. Муса Җәлил илдә үзенә нинди бәя бирәчәкләрен бик яхшы белә. Сугышның рәсми хакыйкатьтән үзгә башка хакыйкате булуына һәм шуңа башкаларны ышандыра алуына бик нык шикләнә. Әмма ышандыра алмау — хыянәтче исемен йөртү дигән сүз. Шуңа күрә бу шигырьдәге лирик герой хисенең төп сәбәбе — кешеләрне ышандыра алуга шик, дия алабыз.

Биремнәр

1. «Шигырьгә анализ» бүлегенең кыскача планын төзегез. Планыгызда әсәргә ясалган анализ алымнарын ачыклагыз.

2. Шигырьдәге лирик герой кичерешенең бер генә сәбәбе әйтелде. Калганнарын табыгыз.

3. Шигырь өлешләре кабатланган урыннарны җыеп таптык. Муса Җәлилгә кабатлаулар нигә кирәк булган?

4. Лирик герой кичерешләренең дәрәҗәсен күрсәткән урыннарны табыгыз.
5. Шигырьдә интонация үзгәргән урыннарны күрсәтегез.

СОҢГЫ ҮПКӘ

Эчем тулы каргыш, үпкә белән
Китәм инде җирнең өстеннән.
Мескен әни мине юкка гына
Күз нурларын түгеп үстергән.

Юкка гына күкрәк сөтен имезеп,
Бишек җыры җырлап тирбәткән.
Дөньясына нәфрәт, каргыш булып
Чыкты ул җыр минем йөрәктән.

Әйтче, дөнья, синең газабыңа
Түзмәдемме хәлем җиткәнче?
Түзмәдемме, иксез-чиксез сабырым
Яшем белән агып беткәнче?

Һәр хәшәрәт җирдә теләгәнчә
Суда йөзде, суда җебенде.
Ә мин менә соңгы сулышымда да
Чылаталмыйм кипкән иренемне!

Үләм, дидем, ярый, тик кайгырдым,
Күреп үлсәмче, дип, кызымны!
Анам кабре — туган туфрагыма
Куеп үлсәмче, дип, йөземне!

Нигә миңа төрмә кабер булды,
Ник кан юды йоклар урнымны?
Җирне әллә артык сөйгән өчен,
Җылысыннан мәхрүм булдыммы?

Дөнья, сине, Ләйлә төсле күреп,
Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым.
Ә син минем керсез йөрәгемне
Вәхши этләреңнән талаттың.

Аерып мине анам-Ватанымнан,
Кай җирләргә китереп ташладың?
Еласам да үксеп, үз илемнең
Туфрагына таммый яшьләрем.

Туган илем, үксез улың булып
Үләм инде читтә, тилмереп.
Яшем барсын сиңа елга булып,
Каным шытсын кызыл гөл булып.

1943, октябрь

Биремнәр һәм сораулар

1. Лирик герой нигә үпкәли? Аның үпкәсенең сәбәпләрен бер өлешкә җыеп, исем бирегез.

2. Кеше хаксызлыкка үпкәли. Хаксызлыкка, бераз гадиләштереп, яхшылыкка яманлык эшләү дип билгеләмә бирсәк, шигырьдә шул ике каршылыклы якларны табыгыз.

3. Шигырьдәге «дөнья» сүзен нинди башка сүз белән алыштырырга мөмкин?

4. Шигырь эчтәлегеннән чыгып, әдипнең яшәү һәм үлем турындагы фәлсәфәсен үзегез аңлаганча сөйләгез.

5. Шигырьдән интонация үзгәргән урыннарны табыгыз. Шул урыннарны үзегез ничек кирәк тапсагыз, шулай укып күрсәтегез.

6. Муса Җәлил шигырен ни өчен «Соңгы үпкә» дип атаган?

7. Бу әсәрдә дә хакыйкатьне илгә ирештерү теләге бармы?

ЫШАНМА

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Ул егылган арып»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр.

Байрагыма каным белән язган
Антым чакыра алга барырга,
Хаккым бармы минем абынырга,
Хаккым бармы арып калырга?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.

Илдән киттем ил һәм синең өчен,
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгъърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

1943, 20 ноябрь

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ ясагыз. Эчтәлеген, ягъни лирик герой хисенең сәбәбен табыгыз.

2. Муса Җәлил «ышанма» дип хатыны Әминәгә мөрәҗәгать итә. Нигә шулай итә?

ДУСКА

(А.А.)

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе,
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне,
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү.

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер —
Ил гомеренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда.

1943, октябрь

«Дуска» шигыренең дә төп темасы яшәү һәм үлем фәлсәфәсеннән гыйбарәт. Бу шигырендә дә Муса Җәлил үлем турындагы уйларын якын кешесенә әйтә. «Ышанма» әсәрендә әдип үз хакыйкатен хатынына ярсып-ярсып, кабатлап-кабатлап аңлатса, Абдулла Алишка багышланган әсәрендә интонациясен үз язмышы турында сөйләгәндә генә күтәрә. Дустына турыдан-туры мөрәҗәгать итеп сөйләгән урыннарында салмак, сабыр тон сайлый.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Дуска» шигырендә Муса Җәлил үлем һәм яшәү темасын сугышка кадәр иҗат иткән әсәрләрендәгечә чишә кебек. Шулай итәме?

2. Ни өчен әдип көрәштәшенә багышланган шигырен салмак, сабыр тон белән яза?

3. Дүртенче строфада Муса Җәлил көтмәгәндә башка нәрсә турында сөйли башлый. Нигә шулай итә? Шигырендә илнең уңышлары турында язу нигә кирәк булган?

ҖЫРЛАРЫМ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю —
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр
Шигыремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны иткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

1943, 26 ноябрь

КОШЧЫК

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз,
Әйтерсең лә тирес корты без.

Кояш чыга койма аръягында,
Күрше кырлар нурга коена.
Тик нигәдер аның нуры безгә
Тими үткән төсле тоела.

Ерак түгел урман, кыр,
Кемнеңдер
Ишетелә чалгы кайравы.
Кичә шуннан бер кош очып килеп,
Шул коймага кунып сайрады.

Чакырсам да, кошчык,
Син бу йортка
Үзең теләп очып кермәссең.
Керә күрмә, безнең кан-яшь йотып
Интеккәнне үзең күргәнсең.

Сайра безгә, шушы нәләт төшкән
Койма аша гына булса да,
Шунсы да бит безгә зур юаныч,
Җырларыңнан күңел тулса да.

Син очарсың, бәлки, минем илгә,
Син иректе, җитез канатлы.
Тик әйт, кошчык,
Синең минем янга
Бу килүең соңгы кабатмы?

Соңгы кабат булса, тыңла, кошчык,
Соң теләген мәгърур җанымның.
Оч син илгә нәфрәт һәм мәхәббәт
Җыры булып тоткын шагыйрьнең.

Ук шикелле үткен канатыңнан,
Таң шикелле якты җырыңнан
Таныр сине халкым: «Бу, дип, аның
Соңгы җыры көрәш кырыннан.

Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә,
Дип, шагыйрьнең аяк-кулларын,
Бер көч тә юк җирдә богауларлык
Аның кайнар йөрәк моңнарын».

Оч син, кошчык,
көчле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән?)
Барсын илгә минем йөрәгем.

1942, август

Истә калдырыйк.

Язучы иҗатына бәя биргәндә, аның үзенчәлеген әйтү өчен, барлык әсәрләренә дә анализ ясау мәҗбүри түгел.

Язучы иҗатының үзенчәлеге дип әсәрләрендә кабатланган эчтәлегенә һәм алымнарга әйтәләр.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Җырларым», «Кошчык» шигырьләренең эчтәлеген сөйләгез.

2. Бу ике әсәрдә хакыйкатьне илгә җыр һәм кошчык җиткерергә тиеш. Ни өчен әдип шундый җаваплы эшне җыр белән кошчыкка тапшырырга мөмкин?

3. Һәр ике шигырьдә дә сүз күбрәк лирик геройның юанычы турында бара. Шуннан чыгып, бу әсәрләрне Муса Җәлилнең юаныч шигырьләре дияргә мөмкинме? Җавабыгыз нинди булса да, дәлилләргә тырышыгыз.

4. «Җырларым», «Кошчык» әсәрләрендә дә әдип үлем турында яза. Бу шигырьләрендә үлемгә нинди эчтәлек сала?

ТӨРМӘДӘ ТӨШ

Төштә миңа нәни кызым килде,
Чәчләремне сыйпап тарады.
— Ай-һай, эти, озак йөрдең,— диеп,
Күзләремә сөеп карады.

Мин кызымны кыстым күкрәгемә,
Шатлыгымнан шашып, исереп.
Шунда сиздем нинди көчлелеген
Мәхәббәт һәм сагыш хисенең.

Чыгып киттек шуннан без болынга,
Гизеп йөрдек чәчәк диңгезен.
Нинди татлы — яшәү, көчле — сөю!
Нинди якты, иркен — Җир йөзе!..

Мин уяндым. Урным шул ук төрмә,
Кулларымда шул ук богаулар,
Баш очымда шул ук кайгыларым,
Уяныр дип көтеп торганнар.

Аһ, ник үрти мине хыял белән
Тик тилертеп кайтмас язларым,
Ник төш кенә минем шатлыкларым,
Ник бетмәс өн — кайгы, газабым?!

1943, сентябрь

«Төрмәдә төш» шигыренең эчтәлеге

Шигырьне лирик геройның шатлыгы һәм хәсрәте дип ике капма-каршы якка бүләбез. Шатлыкны — юану, ә хәсрәтне ачы хакыйкать дип ачыклыйбыз. Шулай итеп гадиләштергәннән соң, шигырьнең безгә таныш төзелешен күреп алабыз. Шәехзадә Бабичның «Шатлык җыры» шигырен искә төшерик. Анда әдип:

Чайпалышып, шатлык дулкыннары
Чәп-чәп бәрелә күңелем ярына;
Шул шатлыклар белән каршы торам
Бу дөньяның барлык зарына,—

дип язган иде.

Шагыйрь бу дүртьюллыгында хәтере тудырган шатлык хисен тормыш тудырган хәсрәтенә каршы куеп юана, дигән идек. Аннан соң да шундый ике хис каршылыгына корылган шигырьләрне күп очраттык.

«Төрмәдә төш» шигырендә Муса Җәлил дә күңел хәтере белән юана. Ләкин төшендә генә юана. Лирик герой хәсрәтен хәтта шундый матур төш тә җиңә алмый. Киресенчә, хәтер «уяныр дип көтеп торган» хәсрәтне арттыра гына төшә. Шуңа күрә бу шигырьдә лирик герой кайгысының сәбәбе — төрмә авырлыклары һәм матур төш, дибез. Матур төш, мәңге тормышка ашмас хыял булганга, лирик геройның хәсрәтенә хәсрәт кенә өсти.

КҮЛМӘК

Җырлый-җырлый, Дилбәр күлмәк тегә,
Кулларында көмеш инәсе.
Җырлар түгел, җилләр җитә алмас
Ерак җирдә күлмәк иясе.

Кулы йөгрә ефәк сатин буйлап,
Тирән сагыш уйчан йөзендә.
Ефәк чигеш булып ятып кала
Йөрәк сере инә эзендә.

Атлас белән кайый ул якасын,
Ука белән тота җиң очын.
Шул күлмәккә җыйнап биргән төсле
Йөрәгенең бөтен җылысын.

Һәр чигештә күпме яшь тамчысы,
Күпме сагыш һәрбер җөендә.
Шул күлмәкме булмас яшь егетнең
Йөрәк дусты йөргән җирендә!

Җырлый-җырлый, Дилбәр күлмәк тегә,
Күлмәккәем дустын тапсын дип.
Шул күлмәкне киеп сөйгән егетем
Сугышлардан җиңеп кайтсын дип...

* * *

Ашыгып шунда берәү килеп керде,
Хат тоттырды Дилбәр кулына.
Хатта язган: «Егетең батырларча
Үлде, диеп, сугыш кырында».

Озак торды Дилбәр сүзсез катып,
Каны качты юка ирненнән.
Тик күкрәге еш-еш күтәрелде,
Күл тирбәнгән кебек җил белән.

— Юк, ышанмыйм...— диде,
тавышы чыкты,
Калтыранып, авыр көрсенеп.
Ике генә тамчы яшь чылатты
Гөл чуклары төсле керфеген.

Ә аннан соң тиз-тиз пөхтә итеп
Төрде дә ул зәңгәр күлмәкне,
Китте ашыгып почта бүлегенә,
— Алыгыз,— диде,— минем бүләкне!

— Ул бит үлгән,
ничек илтик аңа?
— Сез илтегез, үлгән булса да!
Кигерегез аңа бу күлмәкне,
Тәнен туфрак күмгән булса да.

Ул терелер кигәч бу күлмәкне,
Йөрәк уты тагын кабыныр.
Мин бит аны сөйдем чын күңелдән,
Мин бит аны көттем сагынып...—

Тыңладылар аны. Сөйгән кызның
Сүзе чындыр кебек күренде.
Һәм күлмәкне илтеп яшь егеткә
Кигерделәр... Егет терелде.

Кояш калка, Дилбәр тәрәзәдә,
Ул ашкынып көтә сөйгәнен.
Егет кайта, йөзе кояш төсле,
Ә өстендә зәңгәр күлмәге.

Әкиятме бу?
— Әйе.
Тик әйт миңа,
Йөрәгемнең назлы иркәсе!
Син түгелме сөю нурың белән
Кабызучы гомрем иртәсен?

Азмы күрдем окоп алларымда
Мин үлемнең кыргый биюен,
Йөз үлемнән мине тартып алды
Синең керсез, кайнар сөюең.

Йөз үлемнән калдым, йөз үлемнән
Терелеп бастым аякларыма.
Яшең белән чиккән күлмәгеңне
Киеп кайттым менә яныңа.

1943, октябрь

Биремнәр һәм сораулар

1. Символ билгеләмәсен исегезгә төшерегез һәм күлмәкнең ни өчен символ булуын исбат итегез.

2. Күлмәк символы шигырьдә ике мәртәбә кабатлана. Соңгы юлда кабатланган күлмәкнең мәгънәләрен әйтегез.

3. Күлмәкне символ дидек. Символны Дилбәр дә, лирик геройның яраткан кешесе дә чигә. Димәк, чигү дә өстәмә мәгънә ала дигән сүз. «Чигү» сүзе, шулай итеп, образга әйләнә. Бу образның мәгънәсен үзегез аңлаганча әйтегез.

4. «Күлмәк» шигыре дә тоткынлыкта иҗат ителгән. Ләкин ул без өйрәнгән башка әсәрләрдән үзенең шатлыклы булуы, җылылыгы белән аерылып тора. Бу шатлык хисе бөркеп торган әсәр белән Муса Җәлилнең хәсрәт тулы шигырьләре арасында нинди дә булса бәйләнеш табып буламы?

ГАШЫЙК ҺӘМ СЫЕР

Мин чәчәкләр җыйдым сөеклемә,
Бәйләм итеп бәйләп китердем.
Күрсен иркәм аның кулдалыгын
Йөрәгемнең, бәхтем, иркемнең.

Аһ, ни гарьлек! Кызым чәчәкләрне
Тәрәзәдән тышка ыргыткан.
Ә аларны сыер ашап киткән...
Ничек түзим үлми хурлыктан?!

* * *

Гашыйк сүзен сыер ишетте дә,
Гаҗәпләнеп, башын селкеде.
Исем китә, диде, бу гашыйкка,
Карап торсаң кеше шикелле!

Аңламыйча, ахмак, эшнең төбен,
Нигә шулай кыза, тузына?
Мин ашасам аның чәчәкләрен,
Сөт бирәм бит сөйгән кызына.

Минем сөттән аның йөзе алсу,
Минем сөттән — таза, сөйкемле,
Тәне йомшак аның, тешләре ак,
Яңа сауган сөтем шикелле...

***

Уйга калды гашыйк...
— Чын да, диде,
Ник тиргим мин бу сөтбикәне?
Ул бит көн дә, кырдан үлән җыеп,
Каймак белән сыйлый иркәмне!

Азык булсын гөлем сыерына,
Мин теләмим артык һичкемне!
Миңа шул да бәхет, әйдә, иркәм
Каймак итеп эчсен гыйшкымны...
Һәм юанды гашыйк...
Хәзер көн дә
Чәчәк җыеп чишмә буенда,
Кызга түгел, китереп, чәчәкләрне
Ул ашата икән сыерга.

1948, май

Биремнәр һәм сораулар

1. Юмористик әсәрләрнең уртак төзелешен (яки аларга анализ ясау үзенчәлеген) исегезгә төшерегез. Шигырь төзүче өлешләрне аерып күрсәтегез. Алар арасындагы бәйләнешне табыгыз.

2. Бу шигырьнең матурлыгы нәрсәдә булырга мөмкин?

3. «Гашыйк һәм сыер» әсәре дә тоткынлыкта иҗат ителгән. Аны да Муса Җәлилнең безгә таныш башка шигырьләре яктылыгында карагыз.

4. Муса Җәлил тоткынлыкта тагын берничә юмористик шигырь иҗат итә. Аларны язганда әдип үлем җәзасы көтеп ята. Шуны истә тотсак, юмористик әсәрләр язган әдипкә нинди бәя бирер идегез?

ЙОМГАК

Без Муса Җәлилнең берничә шигырен генә өйрәндек. Бу шигырьләр әдип иҗатының эчтәлеген шактый тулы ачсалар да, берничә шигырь фәнни нәтиҗә ясау өчен нигез була алмый әле. Шуңа күрә, нәтиҗә ясаганда, әдипнең барлык әсәрләрен күз алдында тотарга тиеш булабыз. Шагыйрь әсәрләрен күздән кичергәннән соң, аларның уртак сыйфатлары барлыгын белдек: күбесенең темасы — Туган ил.

Муса Җәлил иҗатындагы төп тема төрле елларда төрлечә ачыла. Шул үзгәрешләрне нигез итеп, әдип иҗатын, 20—30 нчы еллар, сугыш башланган еллар һәм тоткынлыкта иҗат иткән әсәрләр дип, өч чорга бүлдек. Һәр чорны төп тема ачылу

үзенчәлеге белән бәйләп өйрәндек һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: 20—30 нчы елларда Муса Җәлил Туган илне, идеология өйрәткәнчә, дөньядагы иң бәхетле, иң иркле, иң бай ил итеп сурәтләде. Аның төп темасы совет иле булды. Бу тема каршында аерым шәхес берни дә түгел иде. Муса Җәлил лирик героена артык әһәмият бирмәде. Шуңа күрә Туган ил өчен үлү бәйрәм, шатлык дип саналды.

Бөек Ватан сугышының беренче елларында да Муса Җәлил Туган илне идеологик бизәкләргә төреп язуын дәвам итә. Әмма сугыш аны да дөньяга үз күзе белән карарга өйрәтте. Туган ил хәзер өзлексез сагындырып торучы якын кешеләр, туганнар, яшьлек үткән урыннар булып конкретлаша. Лирик герой сугыш кырыслыгы тудырган хисләре белән башын калкыта, турая һәм Туган илне үзе күрергә теләгәнчә күз алдына китерә. Шуңа күрә әдипнең сугышта иҗат иткән әсәрләре лирик герой хисләренең ихласлыгы белән аерылып тора.

Тоткынлыкта Муса Җәлилнең хакыйкатькә карашы бик нык үзгәрә. Идеологиянең «Әсир — хыянәтче» дигән хакыйкатенә каршы нинди дәлилләр табарга? Шагыйрь калган гомерен үзен һәм үзе кебек йөз меңнәрчә әсирләрнең нахакка гаепләнүен исбат итүгә багышлый. Муса Җәлил яклаган хакыйкать тормышның үз хакыйкате иде. Бу хакыйкатьне ул фикер көче белән дә, фактлар белән дә, хисләренең ихласлыгы белән дә исбат итте. Меңләгән гаепсез әсирләр аның хакыйкатен үз хакыйкатьләре, хисләрен үз хисләре итеп кабул иттеләр. Муса Җәлил шигырьләреннән яшәү көче алдылар.

Муса Җәлил бер генә шигырендә дә ике хакыйкать каршылыгын ачыктан-ачык язмый. Ул үз хакыйкатенең яшәргә хаклы булуын гына әйтә. Аерым кешенең горурлыгын, хисен, фикерен, язмышын яклый. Әдип ил белән шәхес мөнәсәбәтендә үзара ышаныч, хөрмәт булырга тиешлеге турында яза. Ышаныч Муса Җәлил иҗатында ил — шәхес мөнәсәбәтен ачуда үзәк төшенчәгә әйләнә. Бу төшенчә эчтәлегенә илнең — шәхескә, шәхеснең илгә ышанычы да керә. Ышаныч төшенчәсе аша шагыйрьнең өмете, теләге, ягъни әсәрләрендәге төп идеясе ачыла.

Муса Җәлил бу каршылыкны укучыларына төрле алымнар белән җиткерә. Укучы шигырьдә әйтелеп бетмәгән фикерне үзе аңларга тиеш була. Мондый әсәрләргә диалог белән язылган әсәрләр диләр. Диалог рәвешендә төзелгән шигырьләрен Муса Җәлил тоткынлыкта яза башлый.

Муса Җәлилнең лирик герое төрмә авырлыкларыннан, күп айлар буена үлем җәзасы көтеп ятудан, якыннарын, туган җирен сагынудан җәфа чигә. Әмма аны, барыннан да бигрәк, исеменә кара тап төшү борчый. Иптәшләре белән бергә фашист балтасы астына башны елмаеп куюны илгә ничек ирештерергә? Хаклы булуыңны башкаларга ничек белдерергә? Лирик герой хәсрәтенең төп сәбәбе менә шунда. Димәк, тоткынлыкта иҗат ителгән шигырьләрнең төп эчтәлеге дә шул.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре күргән җәфаларны хәзер күз алдына китерү дә кыен. Әмма шундый шартларда да Муса Җәлил көлкеле шигырьләр, мәхәббәтнең бетмәс-төкәнмәс көче турында романтик пафос белән балладалар[1] иҗат итә. Мондый шигырьләр әдипнең үзен һәм иптәшләрен тынычландыру, юату өчен кирәк булдылар. Фашистлар төрмәсендә көлкеле шигырьләр һәм романтик балладаларны көчле рухлы, батыр кешеләр генә яза ала. Муса Җәлил шундый кеше булган.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Йомгак» бүлеген өлешләргә таркатыгыз. Өлешләргә аеру принцибын аңлатыгыз.

2. Бу бүлектә әйтелгәннәрдән чыгып, йомгакның (нәтиҗәнең) язылу принцибы турында сөйләгез.

3. Муса Җәлил иҗаты ни өчен өч чорга бүленде? Аңлатыгыз.

4. Язучы — укучы диалогы рәвешендә иҗат ителгән әсәрләрнең типик төзелеше турында әйтегез.

5. Муса Җәлил шигырьләренең кайсында шундый типик төзелеш бар?

6. «Йомгак»ка, әйткәннәрдән тыш, тагын ниләр өстәр идегез?

Ятлау өчен

БЕР ҮГЕТ

(Кешелек турында)

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне,
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле,
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

---

[1] Баллада дип героик яки фантастик сюжетлы гыйбрәтле хикәяләүгә корылган шигырьгә әйтәләр.

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк көчен күрсеннәр,
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

ХАКЫЙКАТЬ ТУДЫРГАН ФАҖИГА

Тилмереп көткән җиңү көне дә килеп җитә. Бәхетлеләр өйләренә әйләнеп кайталар. Ләкин бик кыйммәткә төшә бу сугыш. Һәр гаилә диярлек сагынып көткән якыннарын бүтән күрә алмый. Җиңү шатлыгы күз яшьләренә манчылып килә. Исәннәр йөрәген үлгәннәр хәсрәте телгәли. Еллар үтә, әмма хәсрәт картаймый, ил хәсрәте булып кешеләр йөрәгенә ныклап кереп урнаша.

Кеше өметсез яши алмый. Ничәнче кат инде ач, ялангач килеш кабат илне торгызырга керешә. Тиздән тормышлар рәткә салыныр, тамак туяр, балалар ялангач калмаслар дип ышана. Ә идеология һаман иске җырын җырлый: тормыш авырлыгын элеккечә объектив сәбәпләргә сылтый. Фашистлар тар-мар ителгәч, дошманнарны илнең үз эченнән эзләргә керешә. Сугыш елларында беркадәр басылып торган репрессия яңадан куәт ала. Әсирлектә булучылар да, саксызлык белән ялгыш үз фикерен әйтеп ташлаучылар да, гомумән, идеология ялганын күрә алган акыл ияләре, күршесе, ачудан гына яла ягып, тиешле оешмаларга хәбәр иткән теләсә нинди очраклы кешеләр меңәрләп-меңәрләп төрмәләргә озатыла башлый. 1938 елгы фаҗига кабат әйләнеп кайта. Ләкин 50 нче елларның ул еллардан җитди аермасы да бар.

Төрмәләр, лагерьлар халыкка хакыйкатьне ачу мәктәпләренә әвереләләр. Үзләренең каршылыклы уйлары белән аларга Европа илләрендәге тормышны күреп кайткан сугышчылар да өстәлә.

Рәсми хакыйкать янында, яшертен рәвештә, кешеләр аңында чын хакыйкать яши башлый. Бу хәл Сталин үлгәнче үк башлана.

Илдәге һәм кешеләр аңындагы бу үзгәрешләр сугыштан соңгы татар әдәбиятының төп эчтәлеген тәшкил иттеләр.

Сугышларда һәм төрмәләрдә бик күп талантлы каләм осталарын югалткан татар әдәбияты бушап калган сафларын яшь әдипләр белән тулыландыра. Алар, өлкәннәр белән бергәләп, җиң сызганып, эшкә керешәләр. Бу авыр елларда да күләмле

әсәрләр — романнар, повестьлар, драмалар — бер-бер артлы басыла тора. Татар егетләренең һәм кызларының сугышта күрсәткән батырлыкларын романтик буяулар белән буяп, Г. Әпсәләмов «Алтын йолдыз», «Газинур» исемле романнарын иҗат итә. Г. Бәширов «Намус» романы, М. Әмир «Тормыш җыры» драмасында авыл халкының сугыш елларындагы фидакарь хезмәтләре, югалту хәсрәтләре турында язалар. Үзләрен борчыган катлаулы сорауларга җавапны Ф. Хөсни «Җәяүле кеше сукмагы», «Авыл өстендәге йолдызлар», Ә. Еники «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», Р. Төхфәтуллин «Авылдашым Нәби» әсәрләрендә төрле еллардагы авыл тормышыннан эзлиләр. Шагыйрьләр Ә. Давыдов, Ә. Фәйзи, Ә. Исхак, Ш. Маннур, драматургия өлкәсендә Н. Исәнбәт, Г. Насрый, Х. Вахит аеруча актив иҗат итәләр.

Бу елларда да әдәбият тормыш фаҗигасенә әйләнгән хакыйкать темасын үзенең төп темасы итеп күтәрә. Әдипләрнең берише әлеге теманы, сугыш елларындагыча, илгә тугрылык белән бәйләп чишә. Ә. Еники кебек кыюрак әдипләр аны тормышның үзендә күрергә тырыштылар.

«Кояш баер алдыннан» исемле китабында Әмирхан Еники бу еллардагы дөньяга карашы турында болай язды:

«Хуш, дөньяны таң калдырган Бөек Җиңү исән калганнарга нәрсә бирде соң?.. Тугызынчы май Җиңү көнен халык шашынып елый-елый, көлә-көлә бәйрәм итте. Мәгәр бу бер көнлек шатлык тантанасы иде — шулай күңелләрдә уелып калды да... Инде шуннан соң Җиңү халыкка нәрсә бирергә тиеш?..

Мин үзем, озын фронт юлларын үткән кеше буларак, шуны әйтә алам: солдатларның форсат чыккан саен бөтен сөйләгәннәре сугыш беткәч иркенлек, җиңеллекләр киләчәге турында хыяллану иде.

Ә Сталин һаман шул ук Сталин иде... Әсирлектән кайтканнарның бик күбесен утыртты. Авылларда өелеп калган тол хатыннарны, ятим балаларны тагын 7—8 ел буена ач тотты. Җиңү аркасында әзрәк ачыла башлаган фикер хөрлеген шунда ук буды, бетерде».

Алай да хакыйкатьнең чынын үз күзләре белән күреп, үз җилкәләрендә татыган әдипләрнең тоткыннар арасында булуы гаҗәп түгел. Хәсән Туфан һәм Ибраһим Салахов — ике хакыйкать тудырган фаҗигане ачыктан-ачык күрсәтеп биргән язучылар.

Сугыштан соңгы елларга әдипләрнең күбесе большевиклар илганына ышанычларын югалткан хәлдә керәләр. Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Саз чәчәге», Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» кебек тормышның тар мәйданында гына булса да гаделсезлекне фаш иткән әсәрләре Н. С. Хрущев идарә иткән елларда гына укучыга барып ирештеләр.

Ләкин җитәкчеләр алышына тора, ә илдә үзгәреш һаман күренми: тоталитар режим яши бирә, басыласы әсәрләр цензура аша үтәләр.

Татар әдәбияты алдагы чорга яңа тема белән килеп керде. Хәзер гаделсезлекне фаш итү темасына кешеләрнең үз-үзләренә кайту темасы өстәлде.

Мин үземнән үз-үземә кайтам,
Китмәсеннән өчен башкалар,—

дип язды Мөдәррис Әгъләмов «Кайтып барам» шигырендә.

Татар әдәбиятында «үземнән үз-үземә кайту» вакыйгасы, тормыштагы үзгәрешләрнең үзе кебек, фаҗига булып сурәтләнде.

Арыслан ята күңелдә,
Кулымда куяным бар,—

дип язды Гамил Афзал.

Равил Фәйзуллин, вулканнарның күңел төпкелендә генә дулавына үкенеп: «Вулканнар бар диңгез төбендә...» — дип язды.

Илдар Юзеев исә тормыштагы гаделсезлекләр турында:

Шушы хәлләргә калуда
Минем дә катнашым бар,—

дип борчылды. Ә бу шагыйрьләрнең берсе дә большевиклар идеологиясенә ябышып ятучылар түгел иде.

Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» пьесасындагы персонажлар өчен үз асылларына кайтудан да зуррак фаҗига юк. Пьесаның төп конфликты персонажларның, үз асылларын белә торып, үз-үзләренә кайтмас өчен эчке көрәшеннән гыйбарәт.

Илдәге күзгә чалынмаган, ләкин тормышның үзе булган милләтнең рухи дөньясы татар әдәбиятында шулай сурәтләнде. Үсешкә ныклы нигез салынды.

Ибраһим Салахов
(1911—1998)

ТАЙГАК КИЧҮ

(Роман-хроника)

Юл башы

I

Институтның тулай торагыннан чыкканда, таң атып, кояш инде күтәрелә дә башлаган иде. Көн җылы, матур булыр, ахрысы. Иртәнге салкын һәм дымсулык, мөгаен, кичәге яңгырның сулышы гынадыр. Бүген октябрьнең егерме бише бит инде. Бәйрәмгә дә ерак калмады. Быелгы бәйрәм аеруча тантаналы, күңелле булыр — Бөек Октябрьгә егерме яшь тулачак.

Безнең институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгуны ректор быел да миңа тапшырды. Ни генә әйтмә — командир кисәге бит мин. Институтка килеп кергәндә шинель петлицаларымда чия кызыл өчпочмаклар яна иде... Әле дә өстән хәрби мундир төшми.

Ә менә кичә төнлә үзен, ректорны әйтәм, кулга алганнар, халык дошманы булган, ди. Болай үзе бик Совет яклы булып сөйли иде. Кем әйтмешли, кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый.

— Борыл уңга!

Кырыс әмер уйларымны бүлдерде. Мин ялгыз гына түгел, өчәү барабыз икән ләбаса. Сул яктагы солдат минем бер кочак китапларны, кульязмаларны күтәреп бара. Җәймәгә төреп бәйләнгән хәзинәдә, Кукчәтауда вакытта ук язылып, калын-калын дәфтәрләргә күчерелгән шигырьләр, поэмалар, хикәяләр

дә бар. «Тау гыйшкы» дигән хикәянең тышлыгына Нури Арсланов кыя ташлар ясаган иде. Алар арасыннан ике ачулы күз карый. Күзләр арасында хәнҗәр. Хәнҗәрдән кан тамчылый. Менә хәзер шул «контр кәгазьләрне» солдат күтәреп бара.

Әй әкәмәт тә булды инде тентүләре. Опер дигәне һәр китапның бит араларын карап утыра. Көләсем килә: ни эзли? Кыяфәте! Актара да актара. Әйдә, бер рәхәтләнсен, ни табар икән!

Бервакыт чират гарәп хәрефләре белән язылган карамаларыма килеп җитте.

— Бу ни бу?— Опер сикереп торды.— Бу нинди кырыгаяк эзләре?

— Бу бит безнең элекке алфавит.

— Конспирация! — Опер солдатка текәлде.— Кара, бу конспиратив кәгазьләрнең барысын да җыеп бәйлә!

— Ә менә монда... Нинди хәнҗәр? Нигә кан? Ә? Димәк, террорга өндисез!

Моннан соң опер үзе дә караватастына кереп китте. Мин тәрәзә төбенә менеп утырдым — әйдә, рәхәтләнеп бер тузанга буялыгыз.

Әүвәле иртәдәге лекцияләргә әзерләндем — укыдым, конспектлар яздым. Аннан «Мәхәббәт һәм өмет»кә тотындым.

Язучы иҗатында гаҗәп кызык хәлләр була икән. Менә романның кереш өлеше һәм ахыры язылып беткән. Ә уртасы юк.

Сәбәп? Романның баш герое политрук Гыйльманов, чик буе бәрелешләренең берсендә яраланып, японнар кулына әсирлеккә төшә. Аны төрмәгә ябалар, сорау алулар башлана.

Менә шушы бүлекләрдә вакыйганы нәкъ япон төрмәләрендәге кебек итеп, бар вәхшәтлеге белән тасвирларга кирәк бит. Ә ничек? Мин бит үз гомеремдә төрмә, камера, карцер, сорау алу, надзиратель дигәннәрне күргән кеше түгел. Язучы бары үзе күргәнне-белгәнне генә язарга тиеш. Дөресен генә әйткәндә, мин инде эчемнән, Печән базарына барып, берәр вак-төяк әйбер урлап тотылырга да төрмәгә эләгергә дип, план корып йөри идем.

Ә монда, көтмәгәндә, Ходай үзе төрмә капкаларын ачты. Тик менә төрмәгә кертмичә кайтарып җибәрмәсәләр генә ярар иде.

— Тукта!

Алдыбызда бихисап зур ишек. Мин бусаганы атлап эчкә үттем.

Ишекләр шыгырдап ябылдылар.

II

Черек кул бакчасында тынлы оркестр «Амур дулкыннары»н уйный. Танцы мәйданчыгы хәзер яшьләр белән шыгрым тулыдыр. Зәйтүнә бүген килде микән? Юктыр ла, кем белән килсен, мин киткәндә, ничек үксеп елап калды ич ул. Күңел дулкынлана, тулып ташый. Мин очам...

— Күтәр башыңны, контр кисәге!

Чү, мин кайда? Ниндидер бер кул җилкәмнән кысып, умырып алып артка тартты. Кинәт алга таба этеп куйды. Башым шак итеп таш диварга бәрелде. Күзләремнән утлар чәчелде. Авыр дагалы солдат итеге аркамны изә, әллә умырткаларым чатный.

Инде икенче тәүлек мине шулай стенага каратып үрә катырып тоталар. Борылырга да, утырырга да бирмиләр. Балтырларым итек куныччларына сыя алмый, шартларга җитешеп шешкән. Кургаш булып катканнар.

Стена кинәт чайкалды. Томан.

III

— Рәхим итегез,— Бикчәнтәев, өстәл аша үрелеп, миңа папирос сузды,— тартыгыз.

Мин, «юк, тартмыйм» дип, башымны чайкадым.

— Сез, Ялтада дәваланып кайттым, дисез. Кемнәр белән очраштыгыз?

— Ялтада халык җитәрлек.

— Мин язучылар турында фикер йөртәм.

— Ә-ә-ә. Галимҗан ага Ибраһимовның хәлен белергә бардым.

— Путевканы кайдан алдыгыз?

— Кайдан булсын. Язучылар союзыннан. Кави ага бирде.

Бикчәнтәев тагын елмайды. Кара, бу тикшерүче начар кеше түгел икән, әнә ничек ипле сөйләшә. Мөгаен, гаебем юклыгын төшенеп, инде кайтарып җибәрергә ниятлидер.

— Так, так. Хәзер сез менә мондый логик нәтиҗә ясагыз. Сезгә путевка бирүче Кави Нәҗми — халык дошманы. Хәзер ул төрмәдә утыра. Ә сез барып күргән Галимҗан Ибраһимов та — халык дошманы, хәзер Пләтән төрмәсендә ята.

— Булмас!— Мин, җан тавышым белән кычкырып җибәреп, аягүрә басарга омтылган идем, тора алмадым — аякларым кузгалмады.

— Тәк, нинди нәтиҗә: бер халык дошманы сезгә путевка бирә, икенче халык дошманы сезне каршы ала, нигә?

Следователь сикереп торды, йөзе агарып, күгәреп китте. Кашлары салынды, күзләр акайдылар. Танымаслык вәхши бер җанга әверелде.

— Син бит, хәшәрәт, алар арасында связной булгансың. Ну-ка, әйт әле: Кави белән Галимҗан сиңа нинди контрреволюцион йомышлар куштылар?

Аптырап калдым, нәрсә таныргга?

— Йә, признаваться итәсеңме, юкмы?— Ул сугарга дип кулын күтәргәндә, күзем өстәлдәге мәрмәр пресс-папьега төште, ничек шуңар сузылганымны белмичә дә калдым, Бикчәнтәев сукканчы, мәрмәр пресс-папьены, эләктереп алып, аның яңагына бәрдем.

IV

Бу елның уникенче мартында Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулды. Гаҗәпкә, бу көннәр бик «тыныч» үтте. Хәтта газета-журнал битләрендә дә гадәттәге тәбрикләүләр, сәламләүләр күренмәде.

Бу хәл мине аеруча борчый иде. Чөнки матур әдәбиятның беренче онытылмас ләззәтен мин аның әсәрләре аша татыдым, сихерләндем.

Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлау белән, тизрәк Казанга китәргә ашкынуымда да, һичшиксез, олы әдипнең тәэсире бар иде.

Казанга килдем. Педагогия техникумына укырга урнаштым. Әмма Галимҗан аганы күрү сөенеченә ирешә алмадым. Ул, үпкә чире белән җәфаланып, Ялтага дәваланырга киткән иде.

Менә шулай җәфаланып йөргән көннәрнең берсендә Язучылар союзы идарәсенә чакырдылар.

— Ибраһим, сине неврастения белән авырый дип ишеттек. Менә Ялтадагы Сеченов исемендәге санаторийга путевка,— диде председатель Кави ага Нәҗми. — Үзең беләсең, быел Октябрьгә егерме яшь тула. Шул уңай белән дүрт альманах чыгарырга җыенабыз. Проза альманахын Галимҗан ага Ибраһимов әсәре белән ачып җибәрергә уйлыйбыз. Ялтага бару белән, аның янына кер — хәлен бел, безнең сәламне тапшыр һәм менә хәзер мин әйткән фикерне җиткер. Яңа әсәре өлгерсә, бигрәк әйбәт булыр иде, әгәр инде юк икән, Галимҗан ага, үзе карап, басылганнардан берсен тәкъдим итсен.

Мин Галимҗан ага Ибраһимов янына барам! Мин Ялтага китәм! Бу күтелмәгән тау хәтле сөенечне кемгә булса да әйтергә, шатлыкны бүлешергә кирәк. Тизрәк! Тизрәк!

Ялтада мин менә шушы мәһабәт кешене, атаклы әдипне эзләп киттем.

Ниһаять, менә ул мин эзләгән йорт. Чәчәкләр белән тулы ачык верандага кердем. Бүлмәгә уздым. Тәрәзә каршына куелган зур язу өстәле янындагы камыш урындык-креслодан Галимҗан ага күтәрелде.

— Хуш килдегез.

V

— Үләксә! — Бикчәнтәев кара көеп, урындыгыннан сикереп торды.— Сволочь! Мин сиңа халык дошманы Ибраһимовның контрреволюцион йомышлары турында язарга куштым. Ә син... Тукта, мин сиңа әле күрәчәгеңне күрсәтермен, кичә камерада егетләр аз биргәннәрдер... (Бирүен бирделәр, бөтен тәнем күгәргән. Көчкә күтәрелеп чыктым монда.) Бүген тагын өстәрләр! Язасыңмы, юкмы?

— Нәрсәне?..

Әйтеп тә бетерә алмадым, әле генә шыгырдап, үчекләп торган итекләрнең берсе очы белән тез астыма батып китте. Чалкан барып төштем.

— Дежурный! Карцер режимына. Кичә аз биргәнсез. Авызы ачылырлык итеп эшләгез. Ха-ха!— тагын Бикчәнтәевнең кыргый көлүе кабатланды. — Тукта, мин сиңа пресс-папьены хәтерләрмен әле...

VI

«Кара козгын», чайкалып, әле бер, әле икенче якка авып-авып китә. Кая алып баралар соң тагын? Нишләтмәкче булалар соң мине? Ни булса да булсын, тик Бикчәнтәевтән еракка алып китсәләр генә ярар иде. Менә инде тугызынчы тәүлек ни көндез, ни төнлә керфек кактырмый, тутый кош сыман, һаман бер сүзне кабатлый: «Халык дошманы Галимҗан Ибраһимов кушкан контрреволюцион эшләрне сөйләп бир!» Нинди эшләр? Һич төшенә алмыйм. Нинди тозакка төштем? Белмим. «Иптәш Сталин күрсәтмәләре»,— диләр. Ай-һай, иптәш Сталин бер гаепсез кешеләрне газапларга кушар микән? Булмас! Монда ниндидер өер үзләренең явыз ниятләренә юл салмакчы

буладыр. Юк, ничек кенә кыйнасалар да, ялган күрсәтмәләр бирмәм, бигрәк тә Галимҗан ага турында.

VII

Ниһаять, мин — Пләтән төрмәсенең өченче катындагы арестантлар белән шыгрым тулы камераларның берсендә. Казанда ун ел торып, мондый төрмә булуын ишетеп тә белми идем. Аслы-өсле сәкеләрдә укмашып, тыгызланып утырган шыр ялангач кешеләр. Сакал-мыеклары җиткән, күзләре акайган, үзләре шабыр тирдә.

— Ибраһим,— алдагы сәкедән, томан эченнән кемдер миңа таба үрелде.— Ибраһим... бу син түгелме?

Имәнеп киттем. Алдымда институтның тел-әдәбият факультеты деканы, профессор Галимҗан Нигъмәти. Галимҗан ага Нигъмәти, минем яныма идәнгә утырып, аркамнан какты: «Йә, тавышланмыйча гына сөйлә әле... Институтта ни хәл? Тагын кемнәрне кулга алдылар?»

Мин, ниһаять, аңыма килеп, белгәннәремне сөйләргә керештем.

Бу камера дүрт тоткын утыра торган бүлмә булган. Хәзер инде монда дүрт түгел, егерме дүрт тоткын утыра. Ятканда кабыргага гына яталар икән. Сәке башкача сыйдырмый, һава җитми. Менә ни өчен монда тынчу һәм мунчадагы кебек пар, бу икән. Кемдер, торып, параша янына китеп, миңа урын бирде. Өске сәкедән кемдер бер сынык икмәк сузды.

— Сез допростан бит... Бераз тамак ялгап алыгыз.

Икмәк күргәч, йолкып диярлек алып, авызыма каптым — чәйнәдем. Кемдер кружка төбендә калган чәен бирде.

Миңа үз сыныгын сындырып биргән теге кеше югары сәкедән идәнгә сикереп төште. Түм-түгәрәк кара сакаллы. Чандыр. Ничектер таныш сыман. Кайда күрдем соң бу кешене?

— Таныйсыңмы?— диде Галимҗан ага Нигъмәти, теге кешегә карап.— Бу бит иптәш Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәр комитеты секретаре.

Хәтерем ачылып китте. Әйе, әйе! Әле яз башында гына язучыларның һәм артистларның берләшкән җыелышында доклад сөйләгән иде бит.

— Габдулла, син «бүре күзе»н каплап тор әле. Соңгы хәбәрне,— ул миңа карап елмайды,— шагыйрьнең килүен иптәшләргә белдерергә кирәк.

Алкин идәнгә җайлабрак утырды да торбага чиертә башлады.

VIII

Коридорда ыгы-зыгы, йөгергән, ыңгырашкан тавышлар ишетелде. Ишектәге йозак шалтырап ачылды. Кемнедер сөйрәп камерага керттеләр.

— Бу бит Мәхмүт Баһаутдинов,— диде Алкин.— Комсомолның өлкә комитеты секретаре. Мескен, аңын югалткан. Шулкадәр кыйнаганнар.

— Алкин, допроска!

Камера калтыранып киткәндәй булды — сулыш өзелде. Ә Алкин, сәйранга гына җыенгандай, пальтосын киеп, эшләпәсен кулына алды, елмайды.

— Йә... пока!

IX

Алкин сорау алудан көч-хәл белән кайтып керде. Бит-авызы күгәргән, сул күз кабагы канаган иде.

— Йә, дуслар,— диде дә, елмая биреп, итеген салмакчы булды, әмма кире турайды, йөзе чытылды.— Булмый икән. Сул итекне салдырыгыз әле. — Мин, йөгереп килеп, итекне салдырырга омтылган идем, кая. Балтырлары, шешеп, итегенең кунычын киергәннәр. Тәнем тетрәп китте. Аны да тенозын бастырып тотканнар, кансызлар.

Күрше дивардан чакыру сигналы чиерттеләр. Алкин шундук, идәнгә шуып төшеп, стенага колаган куйды.

— Октябрьнең егерме еллыгы хөрмәтенә моңа кадәр һич күрелмәгән зур амнистия әзерләнә. Барлык сәяси тоткыннар азат ителәчәк.

— Ура!

Дөресен әйткәндә, күрше камерадан алган хәбәр яңа түгел, ул инде ай буенча кабатлана. Әмма хәзер — бәйрәм алды тәнендә! Бусы инде, һичшиксез, нигезле өметләнү.

Бөек Октябрьгә егерме ел тулганда, ничек инде шул революцияне үз куллары белән барлыкка китергән, аны саклап калу өчен кан түккән ветераннар, аларның эзбасарлары — яшьләр, комсомоллар төрмәдә утырсын? Акылга сыймый.

Барыбыз да ул көннең тууына ышана идек. Без бит ят түгел, үги түгел. Барыбыз да — Совет иленең тугрылыклы фидакарь балалары. Шулай булгач...

Камерага, атылып, ике хәрби кеше керде.

— Тикшерү,— диде майорларның берсе.— Тизрәк! Берәм-берәм минем алга басыгыз да исем-фамилиягезне, кем булып эшләвегезне әйтеп, сәкеләргә менеп, капланып ятыгыз.

— Алкин, ВКП(б)ның шәһәр комитеты секретаре.

— Галимҗан Нигъмәти, профессор.

— Камай Гыйлем, профессор, Казан дәүләт университеты ректоры.

— Сәләх Атнагулов, профессор...

Гадәттә, барлауда саныйлар да чыгалар иде, болай мәсхәрәләп яткырмыйлар, стенага терәмиләр иде. Бу ни бу?

— Отбой. Ятыгыз. Тавышланмагыз,— диде алдагы майор.

— Ә кичке аш?

— Бүген анысы юк,— диде дә башлык ярдәмчесе ишекне япты.

Кемдер буылып йөткерде. Кемдер авыр көрсенде һәм тавышланып рәнҗеде-газапланды:

— Йа Алла, бу нинди хаксызлык!

Чыннан да, нигә мондый гаделсезлек, ә?

Зәйтүнә хәзер нишли икән, ә?.. Күңелем тулып китте — күзләремнән яшь коелды.

Нигә мондый хаксызлык?..

— Елаудан файда юк,— диде Алкин.— Ялгыз син генә түгел бит.

— Алай да... Мин нинди халык дошманы булыйм ди, Алкин абый? Мин бит балтачы малае.

— Ә менә Гыйлем Камай? Ул кем? Фабрикант баласымы? Аның әтисе гомер-гомергә бурлак булган. Гыйлем үзе пристаньнарда йөк бушатып йөргән. Совет хөкүмәте аркасында гына, укып, утыз яшендә профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән.

— Шундый галимне нигә соң төрмәгә япканнар?

— Бу сорау мине дә борчый,— диде Алкин, көрсенеп, сүздән язып. Аннары өстәде:— Иптәш Сталин бу башбаштаклыкка юл куймас, тикшерер.

Коридорда тагын нindидер ыгы-зыгы. Ашыгып атлап, коридорны дер селкетеп, әле бер, әле икенче якка узалар. Инде бит таң алдыдыр? Бу нинди вакытсыз ыгы-зыгы? Алкин ишек төбенә чүгәләде.

— Каршыдагы камера ачылды,— ди ул. — Бер, ике, өч... Өч кешене алып чыктылар.

Алты аяк адымы түбәнге катка төшә торган баскычка таба кузгалды. Дөп. Дөп. Тынлык. Баскыч ягыннан ашыгып

атлаган дагалы итекләр тавышы ишетелде. Якынлашты. Узды. Туктады.

— Сизәсезме,— диде Алкин,— үлем камерасына килделәр.— Барыбыз да сикереп торып утырдык. Ни була? Нинди җинаять эшләргә җыеналар анда бәйрәм таңында?

Ыңгырашу. Нindiдер кагылу-сугылу. Өстериләр иде, ахры.

— Ип-тәш-ләр... Буа-лар...

Җан тетрәткеч ачы тавыш бөтен төрмәне телгәләде. Ишеккә өелдек. Коридордагы ыгы-зыгы көчәйгәннән-көчәя бара.

— ...Ип-тәш-ләр,— тагын гырылдап, буылып чыккан тавыш.—А... атарга а-лып ба-ра-лар... Без га-еп-сез... Сталин... Сталинга...

Тавыш гырылдап киселде. Тагын ыгы-зыгы.

Төрмә артында мылтык аткан тавыш ишетелде.

X

Ниһаять, зарыгып көткән бәйрәм көне. Бу иртәдә беренче сюрприз безнең камераны иртәнге баландадан мәхрүм итү булды.

Таныш булмаган берәүне керттеләр. Яшь егет. Йөзендә ару, борчылу. Алкин, аның янына килеп:

— Син кайдан иптәш? Нинди яңалык?— дип сүз башлады.

— Яңалык чамалы,— диде егет.— Бүген төнлә мин бер укытучы белән утырдым. Әлмәттән. Аны Атласов төркемендә судлыйлар икән. Менә шул укытучы гаҗәпләнеп, хәвефләнеп сөйләде. Һади Атласов соңгы елларда Бөгелмәдә укытучы булып эшли иде, ди. Үзе бик тәрбияле, нәзакәтле, югары белемле галим. Француз, немец, инглиз телләрендә яхшы сөйләшә, китаплар тәрҗемә итә иде, ди.

— Әйе, әйе, беләбез,— диде Камай ага,— талантлы кеше. Шуннан...

— Трибунал аны, Бөгелмәдә контрреволюцион оешма төзеп, Совет хөкүмәтен җимерүгә әзерләнүдә гаепли. Бу оешманың актив членнары дип. Бөгелмәдән, аның тирәсендәге авыллардан алтмыштан артык мулла, мәзин, укытучыларны кулга алганнар. Минем янымда утырган укытучы да шул исәптән икән. «Дөресен әйткәндә, Һади аганы судта гына күрдем»,— ди үзе. Атласов судта менә ничек сөйләде, ди: «Сталин милли сәясәтне Маркс-Энгельс тәгълиматларыннан ераклаштыра бара. Милли кадрларның үсүенә, аларның мөстәкыйль фикер йөртүләренә киртә куя».

— Молодец,— диде кемдер урта сәкедән.

— Ахырда ул сүзен болай тәмамлаган: «Әгәр иптәш Сталинның кайбер фикерләре белән килешә алмау җинаять икән, мин сезнең хөкемдә».

Кинәт, каерып, ишек ачылды.

— Төшке аш.

Исебез китте. Ишек төбендә — ризык кисмәге. Пар чыгып тора — чумар. Чүлмәк кулга тиюгә чөмерә башладым. Төбендә кашык белән бутарлык бер чумар да юк иде.

Тамак ялгаганнан соң теге егетне дә алып чыгып киттеләр.

Кичке аш алдыннан торбаны шакыдылар. Алкинга төбәлдек.

— Три-бу-нал Ат-ла-сов-лар тәр-ке-мен... Атласовның үзен дә а-тар-га хө-кем ит-кә-н.

Алкин, хәбәрне әйтеп бетерер-бетермәс, идәнгә утырды. Электр тогы суккандай катып калдык.

— Йә Алла, бу нинди бәйрәм бу?

XI

Яңа ел алды төне. Тиздән 1938 ел туачак.

Утыз җиденче ел бөтен ниятләрне туздырып ташлады. Өмет өзелде.

Юк, өзелми икән ул тоткын өмете. Аның бүгенге көне нинди генә авыр булмасын, ул әле иртәгә якты сибеләсенә ышана.

Ул көн килер. Ирек-азатлык килер, һичшиксез, менә бу туасы елда. Яңа елда!..

Ә тәрәзә артыннан, ерактан Кремль сәгатенең сукканы ишетелде.

Бераздан Лебедев Кумачның «Нинди иркен Туган илем» җыры яңгырады.

XII

Яңа ел үтте. Сорау алулар көчәйде. Киткәннәрнең күбесе кайтмый. Әллә шулай озак бастырып тоталар, әллә башка камераларга күчерәләр, әллә?..

Ә «чыбыксыз телефон» һаман тек-тек берсеннән-берсе хәвефле хәбәрләр бирә:

— Га-лим-җан Иб-раһи-мов тәр-мә боль-ни-ца-сын-да үлде... Кә-рим Тин-чу-рин ач-лык игъ-лан ит-те. Үт-кән төн-дә е-гер-ме җи-де ке-ше-не ат-кан-нар.

Яз килде. Сандугачлы таңнар белән яз килде — 1938 елның язы.

Бүген инде унберенче май. Былтыргы бишенче ноябрьдән бирле мин менә шушы Плэтән төрмәсендә. Өченче каттагы тар камерада. Ә бер тапкыр да төрмә ишегалдына атлап чыкканым юк. Мин кергән вакытта утырган тоткыннарның берсе дә юк. Китәләр. Кайтмыйлар.

Ә шулай да нигә мине сорау алырга чакырмыйлар икән, нигә?

Йозак шалтырады. Ишек ачылды.

— «С» хәрефенә кем?

— Салахов Ибраһим Низамович.

— Әйберләреңне ала чык.

Әйбер дигәннәре — итек кунычыма кыстырылган китек агач кашык.

— Хушыгыз, иптәшләр.

Мин ишеккә атлыйм. Йә Хода, нинди язмыш көтә мине алда — яктылыкмы, әллә дөм караңгылыкмы?..

Кояшлы бүлмә

Мине «кара козгын»га төртеп керттеләр. Машина Печән базарына юл тотты. Бауман урамын үтеп, тауга — Чернышевский урамына күтәреләбез. Шыгыр-шыгыр капка ачылды. Уздык.

— Чык, җәфа! — Конвой «табут»ның ишеген ачты.

Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзәсе юк, җир астында ул. Түшәмдә челтәр эчендә кечкенә бер лампочка яна. Цемент идәнгә беркетелгән карават. Аның өстендә киез. Сары одеял, ап-ак җәймә. Ак тышлы мендәр. Аптырап калдым. Сигез ай буе Плэтән төрмәсендә тыгыз камераның идәнендә ятарга урын таба алмый үткәргән тоткынга бу урын-җир оҗмах булып күренде.

Надзиратель белән бергә камерага ак халат кигән берәү керде. Кулында чәч алу машинкасы. Сигез ай буена бритва күрмәгән сакал-мыек, гәрчә үзем күрмәсәм дә, бер ел мәгарәдә ятып чыккан Әбүгалисинаныкыннан калышырлык түгел иде, мөгаен.

Сакал-мыекны алдырып, кәефләнеп утыра гына идем, тагын ишек ачылды.

— Чык! — дип ымлады надзиратель.

Ярым караңгы коридор буенча барып сулга борылдым — ачык ишектән кердем. Душ. Тагын рәхәт: сигез айда беренче тапкыр җылы су белән сабынлап юындым. Бер кат тирем

кубып төште, ахрысы. Камерага кайтсам, тумбочкада ике җәмаяк. Берсендә итле токмач, икенчесендә бәрәңге боламыгы белән ике зур котлет йомарламы. Ул гынамы. Күзләремә ышанмыйм, бармакларым белән капшап карыйм — өч папирос! Бу нинди җәннәт? Токмачы шундый тәмле, телеңне йотарсың.

Камерага хәрби киемдә ике кеше атлады. Алдагысы ишеккә көчкә сыеп, кысылып, бөкрәеп керде. Шинеленең петлицаларында икешәр ромб.

— Мин — хәрби прокурор,— диде ромблы ир, калын тавыш белән миңа ачулы төбәлеп.— Жалоба бармы?

— Мин үземнең нигә монда булуымны төшенмим,— дидем, исемне җыеп.

— Капитан, сез аңа гаепләү кәгазен бирегез,— диде прокурор. Теге, папкадан бер кәгазь алып, миңа сузды. Прокурор ишеккә атлады һәм инде миңа бөтенләй карамыйча гөрелдәде:— Укы! Нигә утыруыңны төшенерсең.

Укый башлауга чәчләрем үрә торды.

«...Контрреволюцион милләтче оешманың актив члены. Оешма, Совет хөкүмәтен җимереп, Бөек Туран дәүләте төзергә әзерлек алып барган. Бу явыз милләтчеләр партия җитәкчеләрен, беренче чиратта иптәш Сталинны физик юк итәргә план корганнар... Шушы явыз ниятне тормышка ашыру юлында оешманың актив әгъзасы Салахов Ибраһим Низамович яшь язучылар, студентлар арасында контрреволюцион үгет җәелдергән...» һәм башкалар.

Ахырда статья, пунктлар.

«Явыз ниятләрен, контрреволюцион эшләрен өстенә алмаса да, студент Алмакаевның күрсәтүләре белән аның җинаятьләре исбат ителә, һәм ул РСФСР Җинаять кодексының илле сигезенче статьясы нигезендә гаепләнә».

Бу ни бу? Һич төшенә алмыйм. Куркыныч төшме әллә?

Бу нинди хаксызлык?

Кайда, кайда син дөреслек?!

— Ялган! Ял-ган! Мин һичбер вакытта да, һичбер вакытта да Туган илемә хыянәт итмәдем! Хыянәт итмәдем, ишетәсезме...

Хәлсезләнеп, цемент идәнгә егылдым. Шалтырап, камера ишеге ачылды.

— Чык! Нәрсә катып калдың, атла!

Ниһаять, исемә килеп, коридорга чыктым. Бер конвоир алга чыкты, икенчесе артта.

— Атла!.. Уңга борыл!.. Туры алга!.. Тукта! Кер! Бик зур бүлмә. Ике якта өчәрдән — дәү-дәү алты тәрәзә. Күтәрелгән язгы кояш әнә шул тәрәзәләрдән бүлмәгә үрелгән.

— Нәрсә катып калдың, атла! Атла!

Күзләремне кулларым белән уа-уа атладым.

Алдымда кызыл постау ябылган өстәл. Кояш нурларында ул якып-ялкынланып торган учак булып чагылды. Аның артында өч кеше утыра. Өчесе дә хәрби киемнән.

— Гаепләү кәгазен алдыгызмы?

Төксе эндәшү. Кайсысы сорады, аптыраудан абайламый да калдым. Алай да җавап бирергә ашыктым.

— Мин халык дошманы түгел, бервакытта да...

— Җитәр! — Уртада утырган хәрбинең кара сакалы сикереп китте.— Син әле суд алдында да җинаятьче булуыңны танырга теләмисең?

— Мин...

— Молчать! Судка нинди үтенечегез бар?

Хәзер менә шушында, шушы мизгелдә бөтен киләчәгем хәл ителәчәк. Димәк, ашыгырга! Акылны, зиһенне җыярга. Барысын да, барысын да яшермичә әйтергә — тикшерүченең кыйнауларын, уйдырма документларга кул куйдырырга тырышуларын, ялган шаһитлар китерүләрен... Үземнең балта остасы малае булуымны. Пионерда, комсомолда, партия сафларында тәрбияләнүемне, барлык иҗатымны Совет иленә багышлавымны...

— Соңгы тапкыр сорыйм: судка үтенечегез бармы?

— Мин... мин...— нигәдер калтыранам.— Мин... гаепгаепле түгел... Мин... Совет...

— Җитәр!— Калын бас башыма тукмак белән ордымыни, тагын күз алларым караңгыланды.

— Конвой!— Бүлмә калтыранып китте. Ишек ачылды.— Алып китегез.

Мине тагын теге табутка яптылар. Әллә нәрсә булды — хәлем китте. Бу ни? Суд дигәннәре шушымы?

— Чык!

Мине тагын теге якты бүлмәгә — суд залына кертеп, чытык йөзле хәрбиләр алдына бастырдылар. Шундук өстәл артындагылар аягүрә басып кадалып калдылар. Уртадагы хәрби кеше алдында яткан кәгазьне үрелеп алды да боз төсле салкын бас белән, сүзне сүзгә бәреп, ашыгып укый башлады:

— «СССР Югары суды Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе...» — Тезеп китте — аяз көндә боз явамыни! Ә ачык

форточкадан тынлы оркестр тавышы ишетелә. Ә суд рәисе һаман борынын тарта-тарта укый: «...илле сигезенче статьяның беренче, җиденче, сигезенче, унынчы, унберенче, унҗиденче пунктлары буенча гаепләнеп, ун ел аерым режимдагы төрмәгә ябылу һәм, төрмә срогын тутырганнан соң, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдыруга хөкем ителә».

Алла йортында

I

Судтан соң мине икенче төрмә каршындагы кызыл чиркәүгә күчерделәр. Ни өчен чиркәүгә, диярсез. Шәһәрнең барлык төрмәләре тоткыннар белән лык тулган.

«Алла йорты»на беренче атлап кергәндә хәйран калдым. Йә Ходай, бу нинди мәхшәр! Ыгы-зыгы, шау-шу. Камера түгел, нидидер зур ярминкә. Кайдан бу хәтле халык?

— Кара әле, Ибраһим, бу синме?

Борылды. Кочаклаштык. Бик озак бер-беребездән аерыла алмыйбыз.

— Кара, бу синме, Сөббухмы?

— Ә мин сине атканнар дип уйлаган идем.

— Әлегә без исән! Исән!

Камера гырылдый, мышный, сүгенә, саташа. Ә без Сөббух белән икәү, параша төбендә утырып, икебезгә бер папирос тотәтәбез.

Кемнәр генә юк,ниләр генә эшләмиләр бу гыйбадәтханәдә. Бер поп, Гайса пәйгамбәрнең тәрегә кадакланган сурәтенә карап, бертуктаусыз чукына. Ап-ак сакаллы бер татар карты тастымалын намазлык итеп җәеп утырган да пышылдап кына дога укый, ара-тирә сәҗдәгә китә. Ә алар өстендәге сәкедә бер төркем күлмәк-ыштансыз тоткын акырып-бакырып карта суга. Монда үтенеч язып бирүче адвокатлар да, законны яттан белүче прокурорлар да бар. Җырчылар, биючеләр, артистлар,— таракта уйнаучы музыкантлар... Соңгылары — һәвәскәр артистлар — күбрәк түрдәге иң киң, иң якты сәке тирәсендә әйләнә. Чөнки монда камераның патшасы — староста ята. Урта буйлы, тыгыз бәдәнле, кап-кара сакаллы чегән — ат карагы. Унбиш елны алган. Төрмә түрәләренең таянычы. Ул монда хуҗа — теләсә, хөкем итә, яткызып суктыра яки туйганчы икмәк, баланда белән сыйлый ала.

II

Сагыну!

Татлы да, ачы да син, сагышлы сагыну. Синнән качам, сине онытырга тырышам. Әмма... Әмма үзем тагын-тагын кочагыңа — кайнар, назлы, гөләп куагы төсле гүзәл, чәнечкеле кочагыңа омтылам. Көнбагыш чәчәге төсле сокландыргыч син, сары сагыну. Синдә кояш чаткылары һәм әрем тәме. Биш йөз тоткынлы камерада болай да тынчу. Уранып яткач, тын кысыла, шабыр тиргә батам. Алай да битемне ачмыйм. Уранып яткач тынычрак: камера, андагы ыгы-зыгы ераклаша, үземне аулак бер җирдә хис итәм. Рәхәт, тылсымлы бер дөньяга күчәм һәм сине күз алдыма китерәм.

...Исәнме, Зәйтүнә! Хәтерлисеңме, Зәйтүн гөлем, былтыр язгы зачетларга ничек әзерләнгән идек икебез?

...Ботакларын киң җәйгән нәфис алма агачлары, мәһабәт юкәләр шау чәчәктә. Хуш ис! Ә без шул агачлар күләгәсендә — йомшак чирәмдә бер кочак китапларны, конспектларны чәчеп ташлап, аунап укыйбыз, укыйбыз. Зачетны да алдан бирәбез. Билгеләр дә иң югары. Башка студентлар безгә соклана, кайберәүләре хәтта көнләшә дә иде бит, әйеме? Бигрәк тә Фазыл. Ул гел безнең тирәдә чуала. Йә китабы юк, имеш, йә конспекты югалган. Ышанасыңмы, Зәйтүнә, менә шул дус булып йөргән Фазыл турсаеп кына калмаган, өстемнән донослар да язып торган. Чын, чын! Кулъязмаларын, әләк хатларын үз күзләрем белән күрдем. Нәрсәләр язган бит әле, имеш, мин контрреволюцион оешмада член булганмын. Имеш, аны да шул оешмага керергә өндәгәнмен! Менә бит нинди җаһил! Син, Зәйтүнә, аның белән сөйләшмә. Ул — хаин! Ышанма! Их, жәл, син бит хәзер бу сүзләремне ишетә алмыйсың.

Их, белсәң иде, шундый-шундый сагындым үзеңне, бәгырьләрем өзелә. Ә син, Зәйтүнә? Син дә сагынасыңмы мине?

III

Хәбәр яшен тизлеге белән телдән-телгә, сәкедән сәндерәгә күчте.

— Күрешү! Очрашу рөхсәт иткәннәр.

Хәйран калмаслык та түгел бит, бу чиркәү төрмәгә әйләнгәннән бирле, мондый хәлнең һич булганы юк.

Бу сөенечле хәбәрне ишетүгә, бөтен камера, чират торып, мине тәбрикләргә кереште.

— Беренче эшлисе эш,— диде камерадагы блатнойларның атаманы Папа Пий II, үзенең аеруча булдыклы, ышанычлы «мөрит»ләрен җыеп алып,— күзге һәм каләм[1]. Егетебезне тулысынча тәртипкә китерү хаҗәт.

Кичә генә монда килеп эләккән бер «медвежатник» (фатир карагы) килеп, өстендәге өр-яңа күк сатин күлмәген салып бирде. Камера старостасы чегән аягындагы хром итекләрен салып миңа тоттырды. «Әй Петушок»,— дип, ул минем чамалы блатной егетне туктатты да: «Күгәрченем, яле, сал чалбарыңны»,— диде. Минем трусикны аңа бирде дә кара постау чалбарны миңа кидерде.

«Чикерткә», дөресен әйтергә кирәк, хәленнән килгәнчә авырттырмыйча, шома итеп кырырга тырышты. Кыяфәт яхшы якка үзгәрде. Аннан соң староста, баш надзиратель белән сөйләшеп, бер чиләк су алдырды. Кемдер сабын белән мунчала да китерде. Суд алдыннан бер юындырганнар иде, шуннан бирле тән су күрмәгән.

Кичке аш вакытында староста миңа «үз хәзинә»сеннән өстәмә рәвештә бер өлеш баланда, бер өлеш галушка бирде. Үзе янында гына йоклата торган Петушокны куып төшерде дә миңа шул урынны күрсәтте: «Ят рәхәтләнеп, аяк сузып йокла, кыз белән күрешер алдыннан сине идәндә аунатып булмас».

IV

Иртәнге баландадан соң киенү байтак вакытны алды.

— Күрешү вакыты биш минут. Очрашуга килгән кешеләргә якынлашырга, кул бирергә ярамый. Төшендеңме?

— Төшендем.

— Атла!

Кузгалдым — тез буыннарым калтырый. Йа Алла, өнемме, төшемме? Чыннан да, хәзер мин аны... күрерменме? Каушама күңелем! Син, син бәхетле. Ул, ул саф мәхәббәт, керсез-изге мәхәббәт бу ишек артында бит. Ул, мөгаен, минем кочагыма ташланыр.

Ишек ачылып китте.

Мин бусагадан атладым да сын булып катып калдым.

Бу ни бу? Әллә инде күзләрем буыла? Нинди оятсызлык бу, нинди мәсхәрә?

— Нигә ул монда?— дип кычкырып җибәрдем.

---

[1] Каләм — пәке (жаргон).

— Зәйтүнә — минем хатыным,— диде Фазыл, күзләрен тозландырып. Ә аның янында басып торган Зәйтүнә башын иде.

— Булмас, булмас!— Бер-ике адым алга атладым да бизгәк тоткандагы кебек туңып, чирканып дерелди башладым.— Ул — хаин! Ул минем өстән ялган әләк язган.

— Хатыным алдында хурлама!— диде Фазыл, кара көеп.

— Ә-ә, хурламамы?— Бүлмә уртасында миңа утырырга куелган табуретканы, күтәреп алып, Фазылның башына сугарга омтылган идем, надзиратель, йөгереп килеп, кулымнан тотып калды.

Зәйтүнә кычкырып елап җибәрде.

— Күрешү тәмамланды! — диде дежурный надзиратель, табуретканы идәнгә куеп.

Очрашу бүлмәсеннән мине туп-туры карцерга алып киттеләр.

V

— Әй күзлекле!— кара сакал-староста чакыра икән.— Сине китап яза диләр, дөресме? Мин сиңа бер эш таптым, үзе ашлы, үзе тузансыз, кичен яныма кил, туйганчы ботка ашарсың. Килештекме?

Менә бит уйламаганда эшләр җайланды да китте. Ә эше? Нәрсә эшли, дисезме? Сөйлим. Көн дә кичке баландадан соң хикәят сөйлим. Кече яшьтән үк «Әлфе ләйлә вә ләйлә», «Кырык вәзир», «Шаһнамә», «Әбүгалисина», «Тутыйнамә», «Салсал» кебек гарәп әкиятләрен укып үскәнгә запас җитәрлек. Көн дә бер яңа әкият сөйлим. Тоткында утырган халык гарәп әкиятләренең гүзәллегенә, андагы батыр шаһзадәләргә, сылу кызларга, бигрәк тә тәмледән-тәмле нигъмәтләргә, шәрабларга хәйран калып, хыял дөньясында йөзеп, үзенең бүгенге кызганыч хәлен бик азга гына булса да онытып тора.

Камерадагы биш йөз мәхбүс мине белә, килә башласам, торып, сәкесеннән урын бирә.

Сигез ай Пләтән төрмәсендә көне-төне сорау алуга йөреп, карцер паегында торып, коры сөяккә калган идем. Хәзер чиркәүдәге бер ай эчендә тазарып, тулып киттем.

VI

— Сез җинаятьчеләрне төрмәдән качарга өндәгәнсез һәм, шул явыз ниятегезне тормышка ашырыр өчен, төркем туплагансыз, чиркәү идәне астыннан Казанка елгасына таба подкоп ясарга әзерләнгәнсез. Бу җинаятегезне таныйсызмы?

— Гражданин тикшерүче... Нинди подкоп?

— Молчать! Безнең күз җир астыннан да күрә. Конвой! Менә бу адәм актыгын карцерга! Гаебен өстенә алганчы чыгармаска.

Озынлыгы биш, киңлеге өч метр чамасындагы таш капчык. Тәрәзәсез дүрт цемент стена. Тынчу. Тора торгач, бераз күз ияләште.

Отбойдан соң кем кайда торса, шунда утырып, чүгәләп йоклап китте. Бары хәзер генә мин үсмер малайларның нигә шыр ялангач булуына төшендем. Бөтен киемне бет сырып алды. Күлмәк үзеннән-үзе кыймылдый.

Ниндидер тавышка сискәнеп уяндым. Карцер буп-буш, бер кеше калмаган. Ишек каерылып ташланган. Надзиратель басып тора.

— Әй, мондагы тоткыннар кайда?

Озакламый карцердан качкан яшүсмерләрне берәм-берәм өстерәп-кыйнап китерә башладылар. Ишек, урынына куелып, тагын ябылды. Үсмерләрнең кул-аяклары яраланган, тәннәре кара көйгән. Әмма берсе дә еламый. Бары тик сүгенәләр, ишекне кагалар. Ул арада карцерның түшәмендәге люк ачылды да шлангтан су сиптерә башладылар.

Төнозын бил тиңентен суда тоттылар. Шул юеш, өстән су саркып торган килеш, төрмә кәнсәсенә алып киттеләр. Күзлекле тикшерүче, башын да күтәрми, миңа:

— Ничек, җинаятеңне таныйсыңмы?— дип эндәште.

— Нинди җинаять?

Күзлекле урыныннан сикереп торды да акырды:

— Конвой, алып китегез, карцерда чересен!

Хәзер җәйнең иң матур чагы — июль уртасы. Ә мин менә инде сигезенче тәүлек тынчу карцерда җәфаланам. Көн дә тикшерүче чакырта. Ә минем башым әйләнә. Нинди качу? Нинди төркем? Нинди җинаять? Конвоирлар мине кыйнарга тотыналар. Ә тикшерүче һаман бер сүзне кабатлый:

— Әйт, төркемеңдә кемнәр бар? Кемнәр?

Чиркәүдә әкият сөйләгәндә мин, тыңлаучыларны мавыктырыр өчен, пиратлар турында, аларның замоклардан, ныгытмалардан качуларын да тасвирлый идем. Кемдер «чирткән». Менә шуны инде «подкоп»ка хәтле куперткәннәр. Ә мин хәзер шул юк «подкоп»ны, «төркем»не табып бирергә тиеш. Халыкның кан дошманнарын төрмәдән алып чыгарга «җыенган» кеше бит мин... Ә бу җинаять тагын кимендә ун ел төрмә өстәячәк миңа. Булмаса — ату!

Менә ни өчен мин аңлы рәвештә ашау-эчүдән ваз кичтем. Бу — соңгы таянычым. Мин инде икенче яланы — нахак гаепне җентекләп тикшереп аклауны таләп итәм.

Карцерда инде берничә тапкыр тоткыннар алышты. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, мине бер генә карак та, бер генә рецидивист та рәнҗетмәде, киресенчә, миңа ятарга урын бирделәр. Паекларымны, ач булуларына карамастан, гадел рәвештә кире кайтаралар һәм хәзер, чиратлашып, ишекне кагалар.

— Кеше үлә, врач килсен!

Иреннәремдә кан. Авызымда тоз тәме. Их, бер генә йотым су...

— Ибраһим, ач күзеңне. Менә бераз су йот. Курыкма, мин, мин бу. Имәнкулов Зариф. Хәтерлисеңме, Беренче татар полкы комиссары...

VII

— Надзирательнең әйтүенә караганда, сине ике тапкыр следовательгә күтәреп алып барганнар. Тугызынчы тәүлектә температураң кырыкка күтәрелгән. Төрмә врачы сине, карцердан алып, больницага салырга кушкан. Әмма тикшерүче, ул гаебен өстенә алмады дип, рөхсәт бирмәгән... Менә ни өчен безнең камерада син, Ибраһим,— диде Имәнкулов.

Таныш түгел дус

I

Мин кабат 1938 елның май аена әйләнеп кайтам. Унбишегерме көн эчендә ашык-пошык, аеруча бер салкын канлылык, игътибарсызлык, хәтта җирәнүле караш белән, халыкның 1905—1917 еллар революцияләре дулкынында күтәрелеп чыгып, шул революция җиңүе өчен фидакарь көрәшкән, кан койган, әмма бөгелмәгән, һаман әле бөек көрәш сафында калган газиз уллары һәм кызлары бер гаепсез, нигезсез «халык дошманы» дип гаепләнделәр. Азларына гына «шәфкать» күрсәтеп, аларны ун-унбиш ел төрмәгә, әгәр дә инде аннан үлмичә алай-болай чыга калса, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән хөкем чыгардылар.

Мин, мөгаен, яшь булуым аркасында, төрмә җәзасына тартылганнар арасына эләктем. Казаннан соң Бөгелмә, Уфа, Свердловск, Чиләбе, Төмән төрмәләрен кичтем.

Бу юл бик авыр узылды. Һәрбер төрмә йөрәктә кан саркып торган төзәлмәс ачы яра булып калды.

Казан төрмәсеннән бу юлны без, «аеруча куркыныч биш җинаятьче», бергә башладык. Беренчебез — яңак сөякләре калкып торган, зур кара күзле, калын кара чәчле Мәхмүт Әбҗәлимов. Һич борын төшерми, кайгырмый, уен сүз табып кына тора. Икенчебез — Гений Измайлович Республиканец — Казанда В. И. Ленин музеен оештыручы, аның беренче директоры.

Өченчебез — атлет гәүдәле Николай Васильевич Акимов.

Дүртенчебез — Ардалион Михайлович Нижегородцев, киптерелгән балык төсле ябык. Сары чәчле. Зур пыялалы күзлектән. Гел хәвефләнеп, тынычсызланып тора.

Бишенчебез — үзем. Алда бер әйткән идем инде: Мәхмүт тә, Николай да, Ардалион да — бу хәлләр килеп чыкканчы, комсомол җитәкчеләре булып эшләгән егетләр.

Без беренче тапкыр 1938 елның көзендә Казан вокзалындагы Столыпин вагонының бер караңгы, тар камерасында очраштык. Менә шуннан башлап бик күп еллар бергә булдык. Колыма приискаларына кадәр барып җиттек.

II

Поезд Төмән станциясенә килеп туктады. Атылып-бәрелеп, тамбурга чыгуыбыз булды, күзләребез чагылды: перрон ап-ак, беренче күбек кар төшкән.

Без — биш тоткын. Ә безне, каравыллап, төрмәгә алып барырга алты конвоир һәм бозау хәтле эт килгән.

Төрмә капкасы янына җиткәч, конвой башлыгы безне туктатты да вахтага керде.

— Алло, алло, иптәш начальник, аеруча хәтәрләрне алып килдек. Кая олактырырга?

Без кычкырып көлеп җибәрдек. Конвой шашып калды.

— Тезләнегез, контр кисәкләре!

Көлүебез хәерлегә булмады — кар эчендә тезләнеп, сәгатьтән артык көтәргә туры килде. Тешләр тешкә сугылып, шакылдап, калтырап, туңып, күтәреп беттек.

«Кара козгын» чайкалып кузгалды. Без тагын киттек. Кая? Билгесез. Бара торгач, тын кысыла, баш чатный башлады. Өстә форточка булган. Ләкин хәзер ул бозланып каткан.

— Ачыгыз, һава җитми!

Үпкәм бугазыма тыгылгандай булды — чыдый алмадым, укшып, косып җибәрдем. Дерелдәп, туңып, күзләремне ачсам, кар өстендә ятам. Тирә-якта, минем кебек үк сузылып, иптәшләрем ята.

...Бер төн, бер көн сугылып, авырып, үлә язып, Тубыл төрмәсенә килеп егылдык. Беренче әмер:

— Чишенегез! — булды.

Суык ишегалдында шыр ялангач калып чишендек тә бозланып каткан цемент идәнгә бастык. Ниһаять, алу-бирү, тентү бетте. Коридорның аргы башындагы бер ишекне ачтылар.

Йа Алла, бу көнне дә күрәсебез бар икән — мунча! Пар. Җәннәт. Бер-беребезне тырнакларыбыз белән кырып юабыз.

Безгә өр-яңа төрмә киемнәре: бушлат, гимнастерка, чалбар, колаклы бүрек бирделәр. Алар барысы да күксел калын киндердән тегелгән һәм барысында да канәфер төсендәге «ямаулар». Бу «ямаулар», качып китсәләр, әллә кайдан аның кемлеге кычкырып торсын өчен.

Кем белә, яңа төрмәдә, бәлки, тормышыбыз яңача — җайлырак китәр. Әмма, кышын ашыгыч салынган яңа корпусның бусагасыннан атлауга, бар өметләр чәлпәрәмә килде.

— Бу минуттан башлап сез бары үзегез утыра торган камера саны һәм ятак саны белән генә аталасыз. Барысын да монда мин хәл итәм. Инде төшендегезме?

Төрмә башлыгының безне — аеруча куркыныч бии сәяси җинаятьчене — беренче кабул кылуы шуның белән тәмамланды.

Туксан алтынчы номерлы камера. Камераның авыр ишеге ачылды.

— Керегез.

Монда атлауга, күзләребез чагылып китте: каршы стенада зур-зур өч тәрәзә. Унике караван. Шуларның бишесе пөхтәләп җыелган. Бүлмә уртасында озын өстәл, тирәли ике эскәмия. Менә шушы өстәлгә ризык килде — зур җамаяк тулы уха. Кичерәгендә солы боткасы. Бер чәйнек чәй, берәр шакмак шикәр.

Мондый тәмле уханы, мондый тәмле ботканы, мондый тәмле күмәчне, мондый тәмле чәй-шикәрне минем моннан соң төрмәдә дә, төрмәдән чыккач та һичбер ашаганым, эчкәнем булмады.

IV

Гений Измайлович икенче көнне, бик җитди кыяфәт белән:

— Минем башта бер даһи план туып килә. План мондый: һәр иртәдә физзарядка. Аннан соң дәрес.

— Укытучылар?!— диде Ардалион.

— Беренче укытучы — син, физикадан. Ибраһим әдәбияттан, Николай математикадан, Мәхмүт тарихтан. Ә мин культура тарихыннан лекцияләр укый алам.

«Дөнья культурасы тарихы» буенча беренче лекцияне Гений Измайлович үзе башлады.

Шулай итеп, безнең биш факультеттан торган университет эшли башлады.

V

Башта кизү торучы надзиратель әйткәндә, бу хәбәргә ышанырга, ышанмаска да белми аптыраган идек.

Хәзер менә бишебез дә өстәл янында утырабыз. Һәрберебезнең алдында бер табак ап-ак кәгазь һәм карандаш. Рәхәтләнеп күңелне бер ачып җибәрәсе иде. Ярамый! Ярамый! Ә нәрсә турында гына язарга соң алай булгач?

Әнием әле мин бала чакта ук үлде. Шуның өчен хатны этигә язам.

VI

Белмим, нигәдер, Яңа ел якынлашкан саен, күңел иләсмиләс килә. Кем белә, 1939 ел кинәт өр-яңа, якты, сөенечле ел булыр.

Нәкъ утыз бере көнне иртәнге чәйдән соң, камераның ишеге ачылып, өч надзиратель килеп керде дә:

— Туксан алты-беренче, тиз киен, коридорга чык,— дип боерды.

Мәхмүт, киенеп, һәрберебезнең кулын кысты: «Хушыгыз, иптәшләр».

Мәхмүт артыннан бер-бер артлы Ардалион Нижегородцев, Гений Республиканец, Николай Акимов күрешеп чыгып киттеләр. Кая? Билгесезлек. Нинди авыр газап бу — билгесезлек. Шалтырап, чинап, ишек ачылды:

— Туксан алты-бишенче, чык!

Соңгы тапкыр зур, якты камерада бушап калган биш караватка карадым да күзләремә яшь тулды.

VII

Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзә юк. Камераның сул почмагында цементтан катырылган берсе биек, берсе тәбәнәк тумба. Биеге өстәл, тәбәнәге урындык. Ә ятагы кая соң бу хөҗрәнең[1]? Кинәт түшәмдәге электр лампасы өч тапкыр күзен кысты. Уем эчендәге ятьмәләр, сикереп, идәнгә төште — ятак пәйда булды. Шундук ишектәге форточка ачылды. Надзиратель:

— Йокла! Башыңны ачык калдырып чалкан ят. Өч яктылык сигналы бирелгәч, тор. Тиз тор. Караватавтомат рәвештә җыела! Ят! — дип акырды.

Ә Яңа ел? Ул кайда? Уздымы? Килеп җитмәдеме?

VIII

Дүрт якта да сары таш стена. Мин япа-ялгыз. Нишләргә? Беркем белән сөйләшми, көне-төне утыра, уйлана торгач, акылдан язу да ерак түгел. Аптырагач, ишекле-түрле йөри башлыйм. Дүрт адым алга, дүрт адым артка. Шулай баш әйләнгәнче. Хат барып җиттеме икән, ә? Куанганнардыр. Мин бит этинең бердәнбер улы. «Улым, инде син укы. Тырыш. Кеше бул!»— дигән иде ул, мин Күкчәтаудан Казанга укырга киткәндә.

Тырыштым. Казан педтехникумына кердем. Алдынгы тырыш комсомол дип, партия сафларына алдылар. Техникум бетерүгә, өлкә комсомол комитеты мине (беренче секретаре бичара Мәхмүт Бәһаутдинов иде) Акташ районына, иптәш Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе чыкканнан соң, ялгышларны төзәтергә, колхоз оештырырга җибәрде. Илтән-Бута авылында балалар укыттым. Кулаклар мәктәпне яндырдылар. Төнлә тәрәзәдән аттылар — чак кына үлемнән калдым.

Тагын Казан. «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр», «Пионер каләме» редакцияләре. Шигырьләр, хикәяләр. Беренче китап, икенче китап басылып чыкты. Кызыл Армия. Пединститут.

Стенадагы уемга ябылган урын-җирдән бер җеп асылынып тора. Аптырагач, шул җепне тарта башладым. Сузыла. Кызык. Җепне бармакка урый башладым. Ә бераздан форточка ачылды.

---

[1] Хөҗрә — аерым бәләкәй бүлмә.

— Яле, бармакларыңны күрсәт әле!

Надзиратель тавышланып кычкырды:

— Бу нәрсә? Чык! Кулларыңны артка куй, марш!

IX

Дөм караңгы. Тикшереп карарга кирәк — мин нинди капчыкта? Стена буйлап капшанып алга таба үреләм. Идән боз. Карцер идәнен тезләнеп йөреп чыктым — урындык юк. Каяндыр җил өрә сыман. Өрә, җил өрә. Кайдан? Стенада торба сыман тишек. Дер-дер киләм. Башта өер-өер уйлар. Куркыныч уйлар. Юк, юк! Ничек тә бу уйлардан арынырга кирәк.

Күңелдән, әз генә пышылдап, Такташның «Мокамай» шигырен сөйли башладым. Тынычланып киттем. Уйлар таралды. Дежурный:

— Чык! — дип боерды.

Чыктым. Надзиратель мине ишегалдына алып чыгып китте. Әле генә кар явып үткән. Хуш ис! Яңа кар исе. Каршыда карцер корпусының бер як стенасына бастырып-тезеп куйган табутлар. Боерык:

— Менә шуларның берсен күтәр дә камерага! — Каһәр төшкерене көч-хәл карцерга өстерәп кертүгә, ишек ябылды. Отбой. Табут эченә кереп сузылдым. Дер-дер киләм. Баягыдан да көчлерәк туңа-калтырый башладым. Астан суык килә. Табутның төбен капшый башладым — бу ни бу? Исем китте. Табутның төбендәге такта тишек-тишек. Бу ястык ике төпле икән. Арасына йомычка тутырылган. Ул көнозын тышта торып суык җыя, ә монда китергәч, шул суыкны чыгара.

Өченче тәүлек дигәндә, мине төрмә башлыгы кабинетына китерделәр.

— Сез, йөз алтмыш сигезенче тоткын,— диде түрә,— өч тәүлеккә карцерга ябылган идегез, срок тулды. Карагыз аны, тагын да тәртипне бозсагыз, катырак җәза кулланырмын. Алып китегез.

Үземнең йөз алтмыш сигезенче икәнемне белеп, камерага кайттым. Кара, нинди якты, нинди иркен икән минем бу куышым.

X

Иртәнге чәйдән соң шәфкать туташы күренә башлады. Форточка нибары ике-өч минутка гына ачыла. Менә шушы минутлар хәзер минем өчен иң кадерле, иң сөенечле минутлар.

Бары тик ике-өч минут. Әмма аларда никадәр илаһи көч һәм тылсымлы канатлар...

Һәр иртә, паекны икегә сындырып, яртысы белән бер кружка чәйне эчәм дә ишек янына басып көтә башлыйм — җанымтәнем белән көтәм.

Надзиратель форточканы ачты.

Менә ул зур соргылт күзләр. Бик нәфис, бит алмалары алсуланып торган түгәрәк йөз. Алсу иреннәр һәм гаҗәеп бер елмаю. Ул якты да, татлы да, тылсымлы да.

— Хәерле иртә! Берәр җирегез авыртмыйммы?

Иртәгә тагын килер микән? Бу кабер тынлыгы, ялгызлык кайчанга хәтле сузылыр икән? Бер ай? Өч ай? Бер ел? Ун ел?

Юк! Юк! Ун ел бу ләхеттә түзә алмам, акылдан шашармын!

Менә шушы фаҗигале язмышта зур соргылт күзле кыз! Ул — фәрештә! Ул — мине яшәргә өндәүче бердәнбер изге көч!

Ниһаять, китап укырга рөхсәт иттеләр. Көне-төне укыйм.

— Хәерле иртә!

Менә шушы шәфкать туташы күренә башлаган көннән башлап, үземдә гаҗәп бер үзгәреш сиздем. Иртә белән автоятактан сикереп төшүгә, элеккедәй йокымсырап утырмыйм — гимнастика белән шөгыльләнәм. Чын-чынлап сабынлап юынам, тешләремне дә чистартам. Гимнастерка белән чалбарымны да киез астына җәеп үтүкли башладым.

XI

Бүген, бәхетсезлегемә, күзлегемне цемент идәнгә төшереп җибәрдем. Челпәрәмә!

— Хәерле иртә. Сезгә ни булды, һаман түбән карыйсыз?

— Ялгыш күзлегемне ваттым. Хәзер күзлексез карый алмыйм.

— Алайса, мин сезне күз врачына язам.

Күзләрем кырып, чәнчеп авырта, яшь ага. Шул ук көнне төшке аштан соң надзиратель мине күз врачына алып барды. Врач күзлек алырга рецепт язды да, кырыс кына:

— Счетыгызда акчагыз бармы?— диде.

— Юк,— дидем, аптырап һәм борчылып.

— Һәрбер арестантка күзлек алып бирергә төрмә приют түгел. Төшендеңме?

XII

Форточка ачылды. Теге йомшак, нәфис тавыш:

— Сез күзлек алдыгызмы?

Күзләремнең авыртуына чыдый алмый, сөлге белән башымны урап утыра идем, сикереп тордым.

— Юк, счетымда акча юк бит.

Зур соргылт күзләр миңа текәлде. Нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, бик серле итеп, яратып, пошынып карады алар миңа.

Форточка ябылды. Күзләремнән мөлдер-мөлдер яшь ага башлады. Әллә авырткангa, әллә...

Әтигә хат язганга инде бүген сиксән алтынчы көн, һаман җавап юк.

Шулай беркөнне төшке аштан соң форточка ачылды да баш надзиратель миңа ниндидер кәгазь сузды.

— Сезнең лицевой счетка илле сум акча килде. Кирәк әйберләрегезне бу бланкка языгыз.— Бер генә сүз яздым да бланкны, карандашны надзирательгә кайтарып бирдем. Йа Алла, теләгем кабул булган. Хатым барып җиткән! Камера буенча әйләнәм, йөгерәм, сикерәм.

XIII

Күзлекне бер киям, бер салам. Күрәм. Күзләрем авыртмый. «Әти җаным, сиңа мең-мең рәхмәт. Мине иң авыр газаптан коткардың. Тик менә нигәдер хатыңны бирмәделәр».

Форточка ачылды.

— Ничек, күзләрегез авыртмыймы?

Көлеп җибәрде. Мондый да гүзәл җан булыр икән дөньяда. Әнә күз врачы. Ул да — медицина әһеле. Ә үзе аю кебек акырып тора.

XIV—XV—XVI

Бу ни бу?

Коридорда шыгырдап, чинап, камера ишекләре ачыла башлады. Минем камераның да ишеге ачылып китте. Камерадан чыгуга, зур-зур сакаллы өч кеше мине кочаклап алды.

Көчкә таныдым үзләрен. Мәхмүт, Ардалион, Николай. Туп төсле тәгәрәп, Республиканец килеп чыкты, уртабызга ташланды.

— Ирек! Ирек!

Беренче ташкын! Сөенү ташкыны! Ярты елга якын кешене күрми, бер кеше белән сөйләшми ләхеттә яткан кешеләргә кинәт ишекләр ачылсын да, кинәт бу хәтле халык белән очраш.

Монда кем күпме һәм ничек кычкыра ала — кычкыра, кочаклый, үбә һәм тыела алмый елый.

Гений, тамагын кырып, көр тавыш белән җырлап җибәрде:

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы...

Шау-шу тынды. Бөтен коридор бары бер җыр — «Интернационал»ны җырлый башлады.

XVII

Төрмә ишегалдына чыгуга — башыбызга таш төшкәндәй булды. Канатланып оча да башлаган идек... Ә хәзер? Хәзер алдыңда ачы хакыйкать: калын таш стеналар. Чәнечкеле тимерчыбыклар.

— Өченче кат, каптеркага!

Зур таш келәтнең бер почмагында тау булып эреле-ваклы капчыклар ята. Үткән көзне төрмәгә килеп төшкәч, үзебезнең сәләмәләрне салып, капчыкларга тутырган идек. Чират миңа да җитте: йөз алтмыш сигез саны сугылган кечерәк кенә биштәр дә килеп чыкты. Биштәремне актара башладым. Менә күн тужурка. Гимнастерка, чалбар. Ә итек? Итекнең кунычлары җәелеп ята — үрә бастырып торгканда, балтырлар шешкәч, телеп алганнар иде бит...

Чү, шул итекләр эчендә ниндидер кәгазьләр. Берсен күтәреп селкедем — теге кәгазьләр коелды. Хатлар, үземнең хат! Әтигә язган хат. Икенче итекне селеккәләдем. Аннан да хатлар төште. Минем хатлар.

— Ичмасам яндырсалар, белмәс идек, көтәр идек... Ә монда иң әшәке рәвештә мыскыл итеп, үз хатыңны бер елдан кулыңа тоттыралар! — диде Мәхмүт, ярсып.

XVIII

Башта гомуми камераларга ябылган мәхбүсләрне егермешәр-егермешәр кеше утыртып озата башладылар. Иң соңгы булып килгән унбиш «одиночник»ны йөк машиналарына утырттылар.

Машинабыз, таудан төшеп, Тубылның зур урамыннан бара. Урамның ике ягында, капка төпләрендә халык. Тынлык.

Пристаньга килеп туктадык. Безне ниндидер бер иске, кара майга буялып беткән баржаның трюмына төшерделәр. Каядыр алып киттеләр.

Кояш баеганда

Һәр көнне кояш үзенә хас бер тантана белән байый. Әмма бу тантанада һәрвакыт ниндидер олы бер сагышның шәүләсе ята. Нинди сагыш икән ул? Мөгаен, аерылышудыр. Аерылышудан да газаплырак нәрсә бармы икән бу дөньяда? Бармы икән?

Кояш көнозын, иркен күктә йөзеп, Җир шарын яктырта, җылыта, аны зәбәрҗәт яшел үсемлекләр белән, аллы-гөлле чәчәкләр белән бизи. Ә аннары? Аннары ул, Җир шарын ташлап, каядыр еракка — офык артындагы мохиткә китә. Бата. Югала. Менә шуның өчен, ахрысы, кояш офыкка якынлашкан саен, аерылышу минутлары җитә барган саен сүрәнләнә, моңаеп кызара башлый.

— Шәфәкъ елый, хәерлегә генә булсын инде, ди торган иде мәрхүмә әнкәм, кояш баеган якка карап, дога укый-укый.

Мин үзем дә бала чактан ук кояшны озатып калырга яратам. Озак, бик озак торам мин, ул сагышлы тантананы карап. Уйга чумам. Бигрәк тә, нахак рәвештә тоткынга әләккәч, кояш белән бергә баеган, еракта калган гомер искә төшә. Һәм эчтән генә «Зәңгәр шәл» көен шыңшыйм:

Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үтә гомерем бигрәк җәл...

Менә хәзер дә нәкъ шундый шәфәкъ баеган сагышлы чак иде. Әмма, кояш сүрелсә дә, вагон эчендәге эсселек сүрелми. Монда чамасыз ягылган кара мунчадагы төсле, эссе, тынчу. Кырык мәхбүс лычма тир эчендә. Җитмәсә, вагон ярыкларыннан тузан тула. Сулыш алып булмый.

Безне Тубылдан Иртеш буйлап Омскига китерделәр. Андагы озату төрмәсендә бер атна тоткач, шушы эшелонга төяп алып киттеләр. Юлда коры паек — илле грамм икмәк һәм бер порция — ике йөз грамм чамасы горбуша кисәге бирәләр. Бу балык үзе чи тоз. Кимереп куясың, аннан соң ул су сорый башлый. Конвой башлыгының кәефе яхшы булса, һәр вагоннан ике кеше төшереп, икешәр чиләк су алалар. Ә инде аның кәефе кырылган булса — вагон ишекләре ачылмый. Сусау түгел, җаның чыксын.

Бер йотым су

I

Лагерь администрациясе безне тукланудан төшергән. Ә яңа түрә — конвой башлыгы, бер урынга алып барып япканчы, тоткыннарның ашау-эчүе белән кызыксынмый. Ә соң без кая барабыз?

Имеш, портта «Джурма» исемле бик зур океан корабы тора, ди. Безне шул корабка төяп алып китәчәкләр. Кая? Нинди икән ул Бөек Тын океан?

Ә шулай да ашыйсы килә, эч борып-борып ала.

II

Колонна — ун мең тоткын — ереле-ваклы сопкалар арасындагы тар юлдан портка таба агыла — очы-кырые юк. Кояш кыздырганнан-кыздыра бара. Бөркү. Тузан. Эчәсе килә. Тел авызга сыймый. Иреннәр чатнаган.

Эчәсе килә.

Инде юл читендә егылып калган тоткыннар да очрый башлады. Аларны этләр сөйри.

Мин саф кырыенда басып барам. Конвой нигәдер арттарак калды. Алда ике катлы йорт. Аның баскычында бер хатын басып тора. Мин, соңгы көчемне җыеп, башымны күтәрдем һәм ишетелер-ишетелмәс ендәштем:

— Су, су...

Хатын ачык ишегеннән йөгереп, өчкә кереп китте. Нәкъ өйалды турысыннан атлаганда, миңа бер чүмеч мөлдер тулы су сузды...

Салкын су! Туйганчы, туйганчы...

Чүмечне авызыма китерергә дә өлгермәдем, аркама приклад белән китереп тондырдылар. Мин баскыч төбендәге ташка барып бәрелдем.

Линкольн прискаларында

I

1940 елның көзендә безнең колоннаны Линкольн приискасына күчерделәр. Колымада Америка президенты исемендәге приискамы? Гаҗәп шул.

Алдан җибәрелгән бригада безгә инде ышанычлы урын — ике рәт чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган лагерь да

эшләп куйган. Ниһаять, төн уртасы узгач кына, алыш-биреш мәшәкате очланды. Барак дигәнебез киндер чатыр булып чыкты. Идән — җир. Ике як стена буенда икешәр катлы сәкеләр (такта урынына урталай ярылган каен бүрәнәләр түшәлгән). Урталыкта ике тимер мичкә. Алар мич хезмәтен башкарачак икән.

Вахтер һәрбер мичкә берәр кочак утын бирде. Ягып җибәрдек. Менә кайда ул дөньяның рәхәте — җылынып туя алмыйбыз.

Ләкин мич кызган саен, палатка түбәсе өстендәге кар күбрәк эри. Тамчы шыбырдый гына. Тышта буран, ә палатка эчендә яңгыр.

II

Бөтен тирә-як ап-ак томан эчендә. Суык — ут кебек көйдерә. Бармаклар бияләй белән бергә катканнар, лом тотарга бөгеп булмый. Баскан җирдә тыпырдыйбыз, юкса аяклар ЧТЗга (Чиләбе заводы тракторының көпчәгеннән укмаштырылган резин ботинкалар) ябышып катып калачак. Кызык холыклы кеше бу конвой башлыгы. Әле генә ул мине теләгәнчә сүгеп, сугып егарга омтылган иде, хәзер инде учакларны күчерергә кушты. Кисәүләрне күчергәндә, арлы-бирле йөренеп, җылынып алдык.

Мин тагын шурф казырга тотындым. Җир корыч булып каткан. Суккан саен, лом зыңлап сикереп китә. Шулай азаплана торгач кына, бер кыйпылчыгы кителә. Тагын, тагын сугам.

— Йа Хода, ни өчен мине болай газаплыйлар? Ни өчен?

III

Белмим, әллә инде түрәләрнең рәхиме килде, әллә инде кеше җитешмәү — мине «ипподром»га күчерделәр. Монда, шурф казыгандагы кебек, смена буена бер җирдә кадалып тормыйсың. Ә Колыма шартларында бу инде ярыйсы җиңеллек.

Карцер, паектан мәхрүм итү, ору-сугу, һәрхәлдә, тәэсирсез калмый — мәхбүс йә үлә, егыла, йә шурфны бер метр тирәнлеккә төшерә. Шуннан соң бу бригаданы башка участокка тагын шурф — чокыр казырга күчерәләр. Тегендә шартлатучылар килә. Тар-мар ителгән грунтның бер кыйпылчыгын да калдырмыйча җыеп, читкә илтеп өяргә кирәк. Грунтны ташыр өчен махсус чаналар эшләнә. Аларның табаннары бүрәнә. Менә шушы әрҗәле чана «колымашка» дип атала.

Грунт шартлатылган участоктан өемгә хәтле боз юл. Аның озынлыгы ике-өч чакрымга җитә. Һәр колымашкада биш тоткын. Өчәү алдан тарта, икәү арттан этеп бара. Менә шулай колымашкага җигелеп җир ташу «ипподром»да эшләү була инде.

Безнең бишлектә гел яшьләр. Звено башлыгы — Әбҗәлимов Мәхмүт. Аның ярдәмчесе — Акимов. Звеноның өченче әгъзасы— Ардалион Нижегородцев. Дүртенчебез — Гений Республиканец.

Беренче колымашканы түбәсеннән өеп төядек.

— Бер, ике, өч, киттек!

Колымашканы боздан һич кубарып алып булмый. Табаннар бозга ябышып катканнар. Бик озак азаплана торгач кына, чана кузгалды.

IV

Кайбер кешеләрне бәхет дигәне үзе эзләп таба. Менә архитектор Алексей Николаевичны алыйк. Линкольнга килгән көнне ул, машинадан егылып, аягын сындырган иде. Шуның аркасында өч ай рәхәтләнеп авырулар чатырында ятты. Аннан чыккан иде, безнең палаткага кизү итеп куйдылар. Алексей Николаевичка һичбер арестант үчекми. Аны барысы да ярата.

Ул үзе болай буе-сыны белән әллә ни күзгә ташланырлык кеше түгел. Тәбәнәк. Ябык. Җитмәсә, аз гына бөкресе дә бар. Ап-ак кәҗә сакалы сузылып төшкән. Яше җитмешләр тирәсендә булыр.

Ул һич тик тормый, һәрвакыт үзенә бер эш таба. Чатырда берәр тоткын авырый икән — аның янында. Компресс куя, яфраклар кайнатып, чәй эчерә. Берәү өметсезлеккә бирелеп ята башласа, карт аңа да җитешә — көлә-көлә эчең катарлык мәзәкләр сөйли.

Күптән түгел эштән кайтсак, аш өстәлендә ак һәм кара шахмат фигуралары. Буш вакытларда чиратлашып уйный башладык. Чираттагы тентүләрнең берсендә шахматларны, табып, мичкә яктылар. Безнең чатыр өч тәүлек карцер режимына куелды.

Тик Алексей Николаевич бирешми. Тагын да кызыграк яңалыклар уйлап таба.

V

Торган саен суык көчәя. Зонага йөгерәбез. Тын алып булмый. Яндыра. Атлаган саен абынабыз. Конвой сүгенә, акыра, егылганнарның аркасына — приклад.

Үзебезнең палаткага якынлашкач, гаҗәпләнеп туктап калдык. Безнең чатыр алдында, башын югары күтәреп, мәһабәт болан басып тора.

— Карагыз әле, иптәшләр,— диде Алексей Николаевич, кечкенә баланданы чөмереп бетереп, шау-шу басыла төшкәч,— әгәр дә вахта капкасыннан чатырларга килә торган юлга аллея эшләсәк, ничек булыр? Мин кардан, су сибеп катырып, төньяк хайваннарының сыннарын эшләп куярга уйлыйм.

— Әйбәт бит, нигә эшләмәскә?

— Аларны эшләргә байтак кар кирәк булыр. Зонадагы карны инде эчеп бетереп киләбез ич.

— Болай итик,— диде бригадирыбыз Зариф Имәнкулов.— Ягарга ботак-санак алып кайтабыз бит. Икенче култыкка карбоз кантары кыстырыйк.

Бу эшкә күрше чатыр тоткыннары да кушылды. Имәнкулов бу турыда лагерь һәм конвой башлыкларына әйтеп рөхсәт алды.

Ил төкерсә, күл була, диләр бит, кар-боз өеме көннән-көн үсә башлады.

Башта Алексей Николаевич карны, палаткага кертеп, тагаракка сала да су коеп изә. Аннан ул бу измәне, өстәлгә алып, камыр әвәләгән кебек әвәли, өя. Бәйләүче, ныгытучы материал итеп таяк, чыбык-чабык, чүпрәк-чапракны да файдалана. Менә шушы хәлендә сын чатыр алдына чыгарыла. Ул анда шыкырдап ката.

Бу эш ике айдан артыкка барды. Һәм, ниһаять, Яңа елга — 1940 елның утыз беренче декабренә — «мәрмәр сыннар аллеясы» әзер булды.

VI—VII

Бу аллея лагерыбызны җылытып, яктыртып җибәрде. Җанварлар, кошлар иртә белән безне эшкә озатып кала, ә кичен алар, ерактан үрелеп карап, безне каршы ала.

Мин үзем дә, аз гына буш вакытым булды исә, аллеяга чыгам. Озак, бик озак карап торам бу салкын, әмма күңелгә бик җылы сыннарга. Казакъ далаларында калган туган Күкчәтавым күз алдыма килә минем. Дөнья нинди зур, нинди гүзәл.

Анда хайваннарга, кошларга урын бар. Ә кешеләргә нигә тар бу киң дөнья?

Мин үзем ешрак болан алдына килеп туктыйм. Аның белән сөйләшәм. Менә шушы боланга атланып, туган җирләргә очсаң иде. Оч, алып оч мине, толпарым, туган якларга!

VIII

Март башында Магаданнан өлкән бер түрә килә икән дигән хәбәр таралды. Чәч-сакалны кырыктылар, юылган күлмәк-ыштан бирделәр. Алексей Николаевич постаментларны төзәтте, сыннарның кителгән, кырылган җирләрен ямады-сылады.

Унөченче март көнне иртән, эшкә чыгармыйча, вахтадан кире бордылар. Таныш әмер: «Рота-рота булып тезелергә!» Тезелдек.

Менә бервакыт вахта ишеге ачылды. Бер төркем хәрби киемдәге кешеләр безгә таба атлады. Алда озын буйлы, тулы гәүдәле кеше атлый. Аллеяга якынлашуга, түрә кинәт туктап калды.

— Бу нәрсә, Петергоф?!

— Иптәш генерал...— безнең түрә каушап, тотлыгып калды.— Лагерьда бер скульптор бар...

— Яле, кайда ул скульптор? Күрим әле.— Алексей Николаевич, чакырганны да көтмичә, генерал алдына килеп басты:

— Гражданин генерал!

Тынлык. Кинәт генерал кычкырып җибәрде:

— Нәрсә?! Сине монда Колымага яңа Петергоф салырга җибәрделәрме? Әллә алтын казыргамы?— Генерал муенын безнең лагерь башлыгына таба борды.

— Яле, ыграк бер күсәк китерегез әле! — Лагерь башлыгы үзе вахтага йөгереп керде дә кисәү агачы күтәреп чыкты.

— Скульпторга бир!— диде генерал, ачулы тавыш белән.— Яле, син, скульптор булмыш... Хәзер үк бу чучкаларны күздән югалт!

Башыбызга тукмак белән суктылармыни — иелеп төштек. Мескен Алексей Николаевич хәлсезләнеп бөгелде, кулындагы таягы төшеп китте.

— Вахтер! Әнә җирдәге таякны алыгыз да бу хайваннарны күздән югалтыгыз. Лагерь кешеләр өчен, хайваннар өчен түгел.

Күзләремне ачканда аллея урынында инде челпәрәмә кителгән, ватылган боз кисәкләре генә ята иде...

Кара сакаллы кеше

I

— Ха-ха-ха!

Сискәнеп куркып уяндым. Озын барак. Мич сүнгән. Суык. Минем каршыдагы сәкедә яткан башкорт егете Фәнүн бөгеләбөгелә көлә, терсәктән киселгән чулак куллары, бер күтәрелеп, бер төшеп, буш калган күлмәк җиңнәрен арлы-бирле җилфердәтә. Башымны сул якка бордым. Бу кем тагын? Күршем Герман кайда? Аның урынында бөтен битен кара сакал баскан, тузган кара чәчле бер ят кеше ята. Куллары исән-сау. Аяклары исән-сау! Гаҗәп. Җыен гарип арасына ничшләп килеп кергән? Эчем жу итеп китте — мөгаен, «стукач»! Телне теш артында тотарга кирәк бу хаин янында.

Ишек ачылды, үргылып кар бураны керде. Ишектән ике кеше керде. Алдагысы ак якалы, мичкә сыман юан. Аның артыннан кара бәрән тиресеннән тегелгән папаха кигән озын, чандыр ир күзлеген салып сөртергә кереште.

— Гражданин начальник, санбаракта җитмеш сигез авыру. Барысы да ята. Бүген өч мәет чыкты!

Түрә күзлеклегә борылды.

— Бу әрәмтамаклар монда күпме хөкүмәт акчасын ашап ята инде? Забойда эш тукталып тора, доктор, ә?

— Гражданин начальник, болар бит авариядән соң... Аяккулсызлар...

— Алай булгач, алардан ни файда?

Врач, аптырап, җавапсыз калды. Начальник кинәт минем яндагы теге кара сакаллы кешегә текәлде, кычкырып җибәрде:

— Ә, Стоянов әфәнде! Нәрсә, син монда аунарга килдеңме?

— Юк, гражданин начальник. — Күршем торып утырды.— Аягыма агач төшеп яраланган идем.

— Менә... Ходай сине каргаган. Инде аягыңа баскач, алай саранланма.

II

Колонна башлыгының санбаракка обход ясау миссиясе икенче көнне үк үзен сиздерде: гадәттә, авыруларга бирелә торган биш йөз граммлы паек дүрт йөз граммга калды. Болай да тамак туймый иде. Ә хәзер?

Ул арада шыгырдап-чинап ишек ачылды. Югары сәндерәдән берәүне, өстерәп төшереп, носилкага салдылар. Ике ел бер

забойда эшләгән дусны — Морозны алып киттеләр. Икебез дә бер забойда ишелгән җир астында калдык. Икебезгә дә бер көнне ампутация ясадылар — минем сул аякны тубыктан кистеләр. Морозның уң аягын — балтырдан. Әмма икенче көнне үк икебездә дә гангрена башланды. Ә мине нинди язмыш көтә?

Ә менә теге фаҗигале иртәдә шахта башлыгы, үзе килеп, инде шартлау алдыннан тышка чыгарылган бригадаларны кире лавага куды.

— План тулмый, алар монда бот күтәреп яталар.— Эшкә тотындык. Мороз шурф тишә. Мин лавада яткан токымны вагонеткага тутырам. Вагонеткамны, этеп, тышка чыгарырга гына керешкән идем, күрше лавадагы шурфлар шартлый башлады. Аркама, аягыма ниндидер авыр нәрсә ишелергә тотынды, мин, егылып, аңымны югалттым.

Бригада егерме җиде кешедән иде, баракка нибары тугыз кешене китергәннәр. Башкалар ишелгән җир астында күмелеп калган.

III

— Күрше, хәлең ничек? Ягез әле, аягыгызны күрсәтегез. Карыйм әле.

— Сез кем, врачмы?

— Хирург.

Күрше, шуышып килеп, культяны чорнаган бинтны сүтә башлаган иде, авыр ис борынга сукты. Ә аягым киселгән җиреннән кара янган.

— Гангрена! Хәзер үк ампутация ясарга! Хәзер үк!

— Инде бит ике тапкыр ампутация эшләделәр.

— Наркоз беләнме?

— Хлороформ юк, диде баш врач. Наркозсыз гына кистеләр.

— Кабахәт! — Күршем Георгий (кара сакалның исеме шулай икән) медпункттан, бер аяк белән сикергәләп барып, йод, марля алып килде, киселгән урынны йод белән майлап, чиста марля белән яңадан урады.

IV

Без төн буе сөйләшеп чыктык.

Георгий Стоянов, Софиядәге медицина институтының хирургия факультетын бетереп, врач булып эшли. Соңгы елларда Мәскәү больницаларының берсендә хирург булып хезмәт итә. Ә менә 1937 елның башында аны кулга алалар. Һәм, шпионлыкта гаепләп, ун ел төрмәгә хөкем итәләр.

— Менә шулай итеп, мин Колымага килеп чыктым һәм больницада баш врач булып эшләдем... Бер генә операция дә, укол да спиртсыз — дезинфекциясез башкарылмый. Больницада һәрвакыт таза спирт була. Түрәләр кичләрен миңа «авыз чылатырга» килә башлады. Бигрәк теңкәгә тигәне каравыл башлыгы Волков булды. «Бирә алмыйм»,— дим. Ә ул җикерена. Мин, кызып китеп, аны куып чыгардым.

Мине икенче көнне үк, врачлыктан алып, кара эшкә — утын ташырга кудылар. Ике айдан соң бу приискага җибәрделәр.

V

Икенче көнне Магаданнан ике хәрби кеше,— мөгаен, Гулаг (лагерьларның Баш идарәсе) вәкилләре, килеп, безнең санбаракны карап, авария турында сорашып йөрделәр. Менә шушы комиссия рөхсәте белән, Георгий миңа ампутация ясарга әзерләнә башлады. Бак төне буе кайнады. Георгий эш коралларын кайнатты, урын-җирга дезинфекция ясады.

Өченче көнне мине, култыклап, операция бүлмәсенә китерделәр. Ниһаять, күзләремне ачтым. Кушетка кырында, идәндәге ләгәндә, ярты сыйрагым ята. Ул көнне Георгий тагын өч тоткынга ампутация ясаган.

Бер атнада аягымның ярасы бөтәйде. Мине гомуми баракка чыгардылар. Георгий, хушлашканда, кулларымны кысып:

— Кайгырма! Хаклык беркөнне килер,— дип, соңгы тапкыр кочагына алды.

Менә инде ничә ел протезда йөрим. Киселгән урында бер шеш, яра юк! Һәр көнне иртән торып, протез кия башлагач:

— Мең рәхмәт сиңа, еракта гы дус!— дип, Георгий Стояновны искә алам.

Ике очрашу

Көнозын туңган тән хәзер мич кызуында да җылына алмый. Бушлатны баштан ук уранып, калач булып бөкләндем.

— Магаданнан этап килде!

Сөйләшәләр. Кычкыралар. Сәкедән урын эзләп тыкшыналар. Менә минем янымa да берсе килеп тыкшынды. Озын коры сөяк — шалдыр-гөлдер. Үзе суык. Аягым белән этеп җибәрдем. Читендә — тавышланмады. Мин йоклап киттем.

— Этапныкылар, тышка чыгыгыз! — Тагын ыгы-зыгы. Ишек төбендә конвой башлыгы этапчыларның «гамәл дәфтәрләрен» укый.

— Петров Иван Иванович — илле сигез-унынчы. Пятница Миколь Кузьмич...

— Мутин Мохтар!

Күршем ишетелер-ишетелмәс кенә җавап бирде:

— Мин!

— Мутин Мохтар, илле сигезенче статья, ... пункт, ун ел төрмә... Чык, әйдә!

«Мохтар! Мутин!» Яшен суккандай, аңгы-миңге булып киттем. Аннан, сикереп торып, ишеккә таба йөгердем. Ишек ябылды. Йозак шалтырады.

Бөек артист, гали җан, татар халкының даны, сөенече — бүген арестант. Колыманың җан тетрәткеч зәмһәрир суыгында, этап белән куылып, бер приискадан икенчесенә сөрелә. Ни өчен?

Бу очрашылмаган очрашудан соң ике елга якын вакыт үтте.

— Даң-доң! Даң-доң!

Уяну. Вахта. Конвой. Тентү. Карцер һәм... тагын этап. Өмет. Ышану. Көтү. Мәхбүс шулар белән яши дә, мескен. Менә шулай михнәт чиккәндә, ниһаять, мин, агач аякка калып, инвалидлар колоннасына килеп эләктем. Кәрзин үрүчеләр бригадасында эшли башладым.

Сул якта эштән чыкканнар зонасы.

— Әй, карагыз әле,— дип кычкырып җибәрде кемдер,— әнә кыр казлары килә.

Аптырап, тавыш килгән якка борылдым. Зона аръягындагы үрдән, кыр казлары кебек тезелешеп, бер төркем гарип-гораба төшеп килә: бөкрәйгәннәр, көчкә-көчкә атлыйлар, җилкәләрендә коры-сары каен ботаклары. Нишлисең, Колымада май аенда да мич ягарга кирәк! Төркемнең иң соңында ава-түнә килгән озын, ябык бер инвалид вахта капкасына да җитә алмыйча, абынып егылды. Овчарка, бәе бушауга, бер генә сикереп, җирдә яткан теге утынчының өстенә ыргылды һәм талый башлады. Конвойчылар бу тамашаны карап көлә башладылар. Бер конвойчы теге мескенне тибә-тибә тарткалады:

— Тор, тор, контр! Зонага кергәч иркәләнерсең.

— Әй Мутин!— Бу яктан вахтер кычкыра-сүгенә башлады.— Тагын комедия башлыйсыңмы? Мин сиңа хәзер театрны күрсәтермен.

«Мутин! Мохтар ага!» Мин, чәчрәп, урынымнан тордым. Ашыгып, вахтага таба атладым (каһәр төшкере агач аяк атлаган саен сөртенә).

— Мохтар ага!

Ул минем тавышны ишетте, ахрысы, борылды:

— Сез кем? Кайдан?— дип инәлде.

— Мин... Мин... Казаннан.

— Зона яныннан кит!

Мохтар ага зонага кергән иде инде, тагын теге овчарка өстенә ташланды. Манарада мылтык шартлады. Минем сул җилкәм көеп китте.

Ун көн карцерда утырганнан соң, мине, качарга әзерләнүдә гаепләп, бөтенләй гариплар зонасына күчерделәр.

Зонага кергә, вахтердан: «Мутин Мохтар кайда?»— дип сорадым.

Ул кулын селтәде:

— Ишетмәдеңмени, ул артистка инде әллә кайчан «агач бушлат» кигезделәр ләбаса.

Юлның соңы

...Ниһаять, ирек!

Өнемме, төшемме? Мин хәзер, чыннан да, иректәме? Күләгә булып артымнан калмый «тиз! тиз!» дип әтә-төртә сүгеп йөргән автоматлы сакчылар да, өскә ыргылып торган овчарка этләр дә күренми. Чыннан да, алар инде юкмы?

Нинди матур тирә-як! Җем-җем итә, гүя энҗе сипкәннәр. Хуш ис, беренче кар исе!

...Казан. Көз. Алтын көз. Мин егерме алты яшьлек, таза, типсәм тимер өзәрлек егет,— Казан педагогия институтының дүртенче курс студенты. Биек, киң ишектән кереп, инде менә бу иләмсез тәбәнәк вахтаның тар капкасыннан кысылып чыкканчы, бары тик ун ел гомер узган. Ун ел! Егерме алты белән утыз алты арасындагы алтын еллар!

Яшьлегемнең иң гүзәл, иң шаулы, иң мөкатдәс көннәре! Алар шушы ике ишек арасында калды... Нигә?

Юлдан атылып килгән бер «Москвич» чак кына үземне таптап китмәде.

— Ачык авыз! Йолкыш! Юньсез аксак! Нәрсә комачаулап йөрисең! Читтән барырга ярамыймы әллә? Синең аркада яхшы кешеләр бәлагә юлыгыр!— Машина эчендәге адәм, тәрәзәсеннән башын сузып, әнә шулай тиргәп-сүгеп китте.

Ә мин, көрткә бата-чума, көчкә күтәрелдем.

— Тукта, нигә рәнҗедем соң әле мин — дөресен әйтте ич. Сул аяк урынына чыпта белән бәйләнгән бүкән башы. Өстә ертылып-таланып беткән тоткын бушлаты һәм ертык балаклы

чалбар. Ялгыз аякта ямалыр урыны калмаган ЧТЗ. Иреккә чыгасымны ишеткәч, барактагы иптәшләрнең берсе посылка белән алган чалбарын, икенчесе өстендәге яңа бушлатын салып биргән иде. «Безгә ярар, ә син инде — иреккә! Артык мескен күренмә»,— дип сөендергәннәр иде. Бүген вахтадан узганда сакчы: «Лагерьдан яңа кием белән чыгарга рөхсәт юк! Яле, хәзер үк сал»,— дип чишендерде дә, яңаларны үзенә алып, почмакта яткан ертык-портыкны миңа ташлады: «Мә, йолкыш, мыштырдамый тизрәк эл дә сыздыр. Юкса хәзер, лагерь милкен урлаган өчен, икенче срок бирермен».

Мондыйлардан булыр да. Каушавымнан киенер-киенмәс, вахтадан атылып чыктым.

Ә шулай да нигә соң мин аксак? Нигә мин йолкыш? Ун ел элек мин аксак та, йолкыш та түгел идем ич. Нигә?

— Әй бабай, Мариинскигамы?— Бер йөк машинасы шып итеп минем янга туктады.— Әйдә, утыр. Иреккә ашыгасыңмы, батя?

Өрәңгеләр яфрак койганда

Мәскәүдән ерак түгел, урман эчендә язучыларның иҗат йорты урнашкан. Һәр ел саен диярлек мин монда ял итәргә, язарга киләм.

Язып, укып арысаң, әйдә, ял итәргә рәхим ит, каршыңда кара урманга тиң парк. Мин түтәлләр каршындагы урындыкларга утырып ял итәм.

Җил исеп китте, агачлар чайкалды, шаулаштылар. Каеннардагы соңгы яфраклар, кинәт нәрсәдәндер куркышып кузгалган саргылт күбәләкләр кебек, көтүләре белән күтәрелделәр дә ашыгып җиргә кундылар.

Ә икенче агачтагы яфраклар тиз бирешмәде, боргаланды, ботакларыннан аерылмаска тырышты. Ә шулай да әнә берсе өзелде, әмма җиргә ашыкмады, очты, хәтта туган өрәңгесеннән дә биегрәк күтәрелде һәм әле бер ягын, әле икенче ягын күрсәтеп чайкалды, әйтерсең лә канатларын ал, кызыл, алтын төсләргә манган тылсымлы ярканат. Җәйге төсеннән чагыштырмаслык дәрәҗәдә матур, сокландыргыч бу яфраклар — карт өрәңгенең күзге яфраклары.

Ниһаять, шул гүзәл «ярканат» минем алдымдагы урындыкка кунды. Түзмәдем, алыйм дип кулымны суздым... һәм туктап калдым.

1957—1981 еллар

«Тайгак кичү» (Колыма хикәяләре) әсәренең эчтәлеге

Ибраһим Салахов әсәрен «фаҗига-хроника» дип атаган.

«Хроника» дип күргән-белгәнне, ишеткәнне бер тәртипкә китереп язылган мәкаләгә әйтәләр. Хроникада автор пассив сурәтләүче, читтән күзәтеп торучы кеше. Бу очракта ул мәкаләсендә вакыйгаларга бәя дә бирми, үзенең тәэсирләрен дә сөйләми.

Күргән-ишеткәнне язу хакыйкать үзе була кебек. Әмма хакыйкать, кагыйдә буларак, күзгә күренми. Күргән-белгәнне үзгәртеп язу өчен, әдипләр сәнгать алымнары кулланалар. Сәнгать алымнары хакыйкатьнең тирәндә ятканын күрергә ярдәм итә дә инде. Шуның өчен без әсәрләргә анализ ясаганда шул алымнарны эзлибез һәм шулар аша әсәрнең эчтәлеген табабыз. Әсәрнең үз хакыйкате шул рәвешле табылган эчтәлегендә була. Чынлыкка охшатып, хыял белән тудырылган әсәрдәге вакыйгаларга **сәнгать хакыйкате** диләр.

Ибраһим Салахов әсәрен «фаҗига» дип тә атаган. Фаҗига — (трагедия) безгә таныш әдәби жанр. Димәк, әдип башыннан кичергәннәрне түкми-чәчми, арттырмый-киметми сөйләп чыгарга вәгъдә итә. Шуның белән бергә, сөйләгән вакыйгаларны тудырган сәбәпләрне, ягъни тирәнрәк яткан хакыйкатьне дә күрсәтәчәген кисәтеп куя.

Авторга әсәрнең хроника өлеше нигә кирәк булган соң?

Әсәр 30 нчы еллар ахырын, Ватан сугышы һәм аннан соңгы берничә еллардагы вакыйгаларны эченә ала. Әсәрнең башында автор, үзе язганча, төрмәгә шатланып китә. Монда язарга керешкән романы өчен материал табармын дип ышана. Ә языла башлаган романы советлар иленең башка илләрдән өстенлеген раслауга багышланган була. Әдип Япония төрмәсендәге хаксызлык, явызлык турында язарга ниятли. Ләкин тоткынлыкта үзе инанган хакыйкатьнең нәкъ киресен күрә. Японидә түгел, нәкъ менә безнең илдә тоткыннарны эт урынына да күрмиләр. Безнең төрмәләрдә тоткыннарның аз гына да хокукы юк. Бер гаепсез миллионлаган кешеләрне бездә аталар һәм җәзалыйлар икән.

Әсәрдә күрсәтелгән вәхшилек дәрәҗәсен әдәби алымнар белән арттыруның кирәге юк, чөнки аның чынын язсаң да кеше ышанмаслык хәл бит. Хроника жанрында язу авторга әсәрендә сөйләгән вакыйгаларны, үз күзе белән күреп, үз җилкәсендә татуын, ягъни аларның хакыйкать булуын исбат итү өчен кирәк.

Бу алым белән Ибраһим Салахов бездә ике тормыш — халыкның бер өлеше яшәгән ирек һәм икенче өлеше яшәгән тоткыннар тормышы барлыгын күрсәтә. Әсәр язылган елларда бу хакыйкать турында язу шулай ук җинаять саналган. Шуңа күрә күп еллар буена автор аны бастырып чыгара алмаган. Алай гына да түгел, язган романын берәүгә дә әйтмичә, бик ерак яшереп куйган. Әсәр, дөньялар үзгәреп, кешеләр беркадәр иркен сулыш ала башлагач кына, дөнья күрде.

«Тайгак кичү»дәге персонажлар халык дошманнарына һәм аларны фаш итеп хөкемгә тартучыларга бүленә. Әсәрдәге вакыйгаларны үзенең катнашы белән бәйләп торучы персонаж-автор әсәр герое дәрәҗәсенә күтәрелми. Ул башкалардан бер ягы белән дә диярлек аерылып тормый. Әсәр персонажы — Ибраһим Салахов авыр җәзаларга түзә, ләкин тикшерүчеләр таләп иткәнне үтәми: берәүгә дә ялган яла якмый. Моның өчен аны мактарга гына була. Бик авыр шартларда да төшенкелектән чыгарга үзендә көч таба. Ләкин әсәрдә андый персонажлар бер Ибраһим Салахов кына түгел. Автор-персонаж әсәр ахырында дөньяга карашын үзгәртә һәм хакыйкатьне үзенчә аңлый башлый. Әсәрдә башкалар да шундый эволюция кичерәләр. Күрәбез, «Тайгак кичү»дә максатына ирешү өчен көрәшүче геройны язмышлары, максатлары, гамәлләре уртак кешеләр — тоткыннар төркеме алыштыра. Шуңа күрә фаҗигане хөкемдарлар төркеме белән тоткыннар төркеме арасындагы конфликт тудыра дигән нәтиҗәгә киләбез һәм, гадәттәгечә, бу ике өлешне аерым-аерым өйрәнергә керешәбез.

Хөкемдарлар төркеменең (кулга алучылар, тикшерүчеләр, хөкем чыгаручылар, төрмә башлыкларының) сәяси максатлары — каршы якны юк итү, рухын сындыру, кешелеген бетерү. Социаль максатлары — халык дошманнарына карата кансызлык күрсәтеп, үзләренә карьера ясау. Психологик максатлары — үзләренең әсирләрдән өстенлекләрен күрсәтеп канәгатьләнү. Бу максатларның беренчесе генә — рәсми һәм ачыктан-ачык әйтелә торган максат. Калганнары әсәрнең эчтәлеге булып килә. Шуңа күрә бу төркемнең тоткыннарга каршы көрәше хаклы көрәш, хезмәт вазифасы булып санала.

Тоткыннар үзләренең хокуксыз тоткын булып яшәүләрен факт буларак кабул иткәннәр. Ләкин бу хәлләре белән килешмиләр. Хаклык өчен көрәшүнең лагерь шартларында мөмкин булмаган эш икәнлеген дә яхшы аңлыйлар. Аларның төп максатлары икәү: исән калу һәм намусларын саклап калу.

Күрәбез, фаҗига-хроника төзелешендәге төп конфликт катлаулы һәм үзенчәлекле. Бәянең беренчесе: хөкемдарлар хаклы, ә тоткыннар хаксыз, чөнки беренчеләре законга таянып эш итәләр, икенчеләре — закон нигезендә хөкем ителгән кешеләр. Шул ук вакытта хөкемдарлар төркеме хаксыз, ә тоткыннар хаклы да, чөнки беренчеләре — ерткычлар, ерткыч буларак ил дошманнары. Ә икенчеләре — илнең асыл кешеләре, бөтенләй гаепсез кешеләр.

Шундый капма-каршы эчтәлеккә ия булган төзелеше әсәрне хроника дәрәҗәсеннән әдәби әсәр югарылыгына күтәрә. Бер ук вакытта кешеләрнең хаксыз да, хаклы да булуы үзеннән-үзе хакыйкать проблемасына әйләнә.

Ибраһим Салахов, әлбәттә, үзе һәм үзенең күргәннәре турында яза. Әсәрне авторның биографиясе дияргә була. Ләкин аны әсәрдәге персонаж белән тиңләштермик. Китап авторы — икеләнү, шикләнүләрне күптән узган кеше. Хакыйкатьне гомеренең иң гүзәл вакытын корбан итү бәрабәренә тапкан аксакал. Бик кыйммәткә төшкән хакыйкатьне әдип башкаларга да җиткерергә тиеш иде.

Әсәрдәге өч төрле фаҗига нәкъ менә шуны ачып бирә.

1. Хакыйкатькә ирешү шәхес фаҗигасенә әйләнә.

Совет иленең иң бәхетле, иң иркле ил булуы турындагы миф[1] әсәрнең төп персонажы булган Ибраһим Салахов аңына да бәхәссез хакыйкать рәвешендә кереп урнаша. Бу хакыйкатькә чиксез ышану авторның иманына әйләнә. Мифларның миф булуын аңлау аңа авыр эчке көрәш — үз иманын әкренләп-әкренләп юкка чыгару нәтиҗәсендә генә килә.

2. Бер гаепсез кешеләрнең көн дә исән калу өчен тырышуы һәм меңәрләп, миллионлап үтерелүе — халык фаҗигасе (социаль фаҗига).

3. Өченчесе — ил фаҗигасе (сәяси фаҗига). Күпме генә интектермәсеннәр, асыл ирләр тоткында да асыл булып калалар. Алар бер-берсенә ышанып, бер-берсеннән үрнәк алып яшиләр: тоткыннар, шул рәвешле, эчтән иркле булып калалар. Ә менә төрмәдән чыккач, Ибраһим Салахов иректәге кешеләрнең һәрнәрсәдән куркып, вак кына чиновниклар алдында да баш иеп яшәүләрен күреп аптырашта кала.

---

[1] **Миф** — *бу урында:* ялган. *Халыклар дуслыгы, тигезлек, иң иркле* кебек штампларга ышану.

Иректәге кешеләрнең күптән инде колга әйләнгәнлекләрен күреп борчыла. Нәтиҗәне автор укучысыннан ясата.

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәрнең сезнең дәреслеккә керми калган ахыры бар. Төшеп калган бүлекләрендә автор, өенә кайтып, туганнары, дуслары белән күрешүе һәм тормыш итүе турында яза. Әсәрнең сезгә таныш эчтәлегеннән чыгып, ахырын сөйләгез.

2. Фаҗига-хрониканың сюжетын сөйләгез. Сюжетны кабатланган урыннар исәбенә бик нык кыскартыгыз.

3. Сюжетны бик аз гына өлешләргә бүлегез.

4. Табылган темаларны тагын да гомумиләштереп, әсәрнең ни турында булуын бик аз сүз белән әйтеп карагыз.

5. Дәреслектәге «Әсәрнең эчтәлеге» бүлеген җентекләп укыгыз. Анда язылган нәтиҗәләрне үзегезчә исбат итегез:

а) Ни өчен автор төп персонажын башкалардан аерып куймаган?

ә) Персонажларның кичерешләре ни өчен шәхси фаҗига диелә?

6. Агач яфрагын өзеп очыручы җил вакыйгасын автор кайта-кайта сөйли. Кабатлавы белән автор бу вакыйганың метафора булуына киная ясамыймы? Ясаса, агач, яфрак һәм җил нәрсә булырга мөмкин? Шуларның мәгънәсен әйтегез.

7. Әсәрнең исемендәге «тайгак» сүзе аңлашыла. Ә менә «кичү» дип кыен урыннан үтүгә дә, ара ераклыгына да, кешенең кайдадыр еракта булуына да, гафу итүгә, кичерүгә дә, елганың җәяүләп чыгарлык сай урынына да әйтәләр.

Бу күп санлы мәгънәләрнең кайсылары әсәр эчтәлеген баетуга ярдәм итә һәм ничек баета?

Хәсән Туфан
(1900—1981)

АГЫЛА ДА БОЛЫТ АГЫЛА

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Нәрсә әйтсен: берни белми ул,
Хәбәре юк минем йөрәктән.
Мине бары чылатып үтте
Кукурузлар белән беррәттән...
Нәрсә әйтсен: берни белми ул.

Роман кебек күңелле син, юл!
Азмы синдә гомер уздырдым,
Ничә кием чабата синдә,
Ничә кием итек туздырдым!
Роман кебек күңелле син, юл!

Ә син, яңгыр, искә төшермә
Итегемнең ничек икәнен...
Яланаяк килдем дөньяга,
Шулай гына, бәлки, китәрмен,
Ә син, яңгыр, искә төшермә!

Зират бит ул Сабантуй түгел,
Нигә анда киенеп китәргә?
Бу дөньяның бер пар итеген
Нигә юкка әрәм итәргә?
Зират бит ул Сабантуй түгел.

Агыла да болыт агыла
Таулар аша Казан артына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
...Агыла да болыт агыла...

1951 ел

Шигырьгә анализ

Проблема. Анализны нәрсәдән башларга? Хиснең дәрәҗәсе, сәбәбе, юану дип, өчкә бүлү бик кыен. Өлешләрнең берсе дә күзгә ташланып тормый.

Ни эшләргә? Шигырьне, лирик герой һәм болытлар, лирик герой һәм юл дип, икегә бүлә алабыз. Анализны исеменнән башларга була. Алай итәргә дә хакыбыз бар, чөнки «Агыла да болыт агыла» сүзләре әсәрнең үзеидә дә дүрт мәртәбә кабатлана. Анализны фокусны табып башларга да мөмкин. Бу өч юлның һәркайсын сайларга була.

Фокус. Шуңа күрә соңгысын сайлыйк һәм фокусны табыйк. Фокус — әсәрнең барлык өлешләрен үзенә җыеп торучы урын. Шундый урын «Нәрсә әйтер туганнарыма?!» дигән юл түгелме? Беренчедән, ул юлны әдип ике тапкыр кабатлый. Икенчедән, тонны күтәреп, тавышны арттырып әйтергә куша — берьюлы сорау һәм өндәү билгеләре куя. Хәзер бу сорауның әсәрдәге барлык өлешләрне җыеп торуын гына раслыйсы калды.

«Нәрсә әйтер туганнарыма?!»— дип, автор болытка карата әйтә, әмма үзенең хәлен күз алдында тота. Ә кукуруэлар, яңгырлар, ертык итекләр, юллар лирик геройның хәлен күрсәтәләр. Шигырьдә башка деталь юк та. Димәк, «Нәрсә әйтер туганнарыма?!» юлы — фокус, һәм әсәр эчтәлеге нәкъ менә шул сораута җавап та булырга тиеш. Хәзер фокуска бәйләнештә торган өлешләрне берәм-берәм өйрәник.

Болыт. Болыт — лирик геройның якын кешесенә хәбәр илтерлек бердәнбер чара. Ләкин лирик геройның аңа үпкәсе зур. Беренчедән, ул геройның хәлен белми, икенчедән, аның язмышына битараф (кукуруз ни, ул ни), өченчедән, болыт өзлексез агыла һәм шуның белән бик күп вакыт үткәнлеген, гомер узуын күрсәтеп, символ буларак, кеше гомерен алмаштырып килә.

Юл. Юлны, дөресрәге үзе үткән юлны, Хәсән Туфан күңелле ди һәм шунда ук газаплы булуын белдерә. Гомер юлда узган,

гомер хәерчелектә үткән (чабата киеп), хәзерге көндә дә кигән аяк киеме ертык. Аягына су үтә.

Әдип бу авырлыкны мактый, димәк, үз хәленә ирония белән бәя бирә дигән сүз. Шул ук стильне дәвам итеп, итегенең ертыгын да хәерчелегеннән күрми, теге дөньяга киткәндә яхшы итекнең кирәге юк бит дип, үлеменә дә көлеп кенә карый кебек.

Ә зират каян килеп чыкты соң әле? Ул фокуска бәйләнгәнме?

Зират — лирик герой үткән һәм үтәсе юлның ахыры. Димәк, юл да лирик герой язмышы урынына килә, язмыш символы вазифасын үти.

Әсәр өлешләре арасындагы бәйләнешләр символ мәгънәләрен барлап чыкканнан соң гына табылалар.

«Нәрсә әйтсен туганнарыма?!» — дип сорый лирик герой, һәм бу сорауга болыт та, юл да җавап бирә. Болыт герой хәлен белми генә түгел, белергә дә теләми. Җитмәсә, геройга яңгырлары белән зыян ясап китә. Болыт лирик геройның ялгызлыгын, чарасызлыгын ачыклап килә. Болыт аша лирик герой үзенең Җир йөзендә кешеләр рәтендә йөрмәвен аңлата. Ә болытның болыт буларак эчтәлеге — лирик геройның юаныч эзләп сүзсез, күзсез, җансыз болытка мөрәҗәгать итүе — юанычның бервакытта да була алмавы турында сөйли.

Лирик герой: «Нәрсә әйтсен туганнарыма?!» — дип сорау бирә дә, болыт әйтергә мөмкин хәбәрләрне юл вакыйгаларына бәйләп сөйли башлый. Юлда үткән гомере турында герой вак детальләр аша гына хәбәр бирә. Ләкин тузган чабаталар һәм ертык итек образлары шулкадәр күп нәрсә турында сөйлиләр, эчләренә бөтен бер бәхетсез язмышны сыйдыралар.

Юл чаты — зират якын, чөнки геройга башка итек кирәкми, дөресрәге, ул көтелми дә. Герой әйтерсең лә үзенең шул язмышына риза булган. Тиздән үлүе турында гадәти бер хәл итеп, юк нәрсә турында сөйләнгәндәй, уены-чыны белән, елмаеп сөйли. Шигырьдән сабырлык, шомлы тынлык бәреп тора.

Мондый сабырлыкның нинди бәя белән саклануын шагыйрь соңрак: «Бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте», — дип аңлатачак.

Үз фаҗигасен гадәти бер хәл итеп көлеп сөйләү бу шигырьдә лирик геройның хис дәрәҗәсен, бәхетсез язмышына бәясен күрсәтә. Моннан чыгып, лирик шигырьләргә хас хис дәрәҗәсен һәм сәбәбен табабыз.

Герой хисенең сәбәпләре дә, дәрәҗәсе дә, болыт аша туганнарга хәбәр ишеттереп, якыннарын да, үзен дә юатырлык түгел. Өстәмә хәсрәт кенә китерер иде ул хәбәр. Шуның өчен «Нәрсә әйтер туганнарыма?!» сүзләренең эчтәлегенә болытның «хәбәрсезлеге» дә, бар булган хәбәрнең әйтә алмаслык авыр хәбәр булуы да керә.

Нәтиҗә

Лирик шигырьләргә хас өч өлеш табылды. Әмма лирик герой хисенең сәбәбе гомуми планда гына әйтелә. Интегүләр түгел, интегүләрнең нәтиҗәсе, хәсрәтләр түгел, хәсрәтләрнең нәтиҗәсе белән генә танышабыз.

Без Хәсән Туфанның яшьлеге төрмәләрдә, лагерьларда үткәнлеген беләбез. Шуңа күрә лирик герой хисенең чын сәбәбен үзебезчә сөйләп тә бирә алабыз. Әмма безгә шагыйрьнең үз сүзләрен ишетү әһәмиятле. Шуңа күрә безне кызыксындырган сорауга җавапны әдипнең башка әсәрләреннән эзлибез.

ТЫНМА, ДАВЫЛ!

Агыйм дисәм, барыйм дисәм,
Аккош бүлә юлымны.

Халык җыры

Таллар кистем, баулар иштем.
Саллар салдым суларга.
Китәр ягым — уңда да бит,
Җилләр исә сулларга.

Өстә — дулкын,
Астан упкын
Куллар сала салыма.
Сукма, дулкын, упма, упкын:
Кайтыйм ярым янына.

Давыл тынды, дулкын тонды,
Аккош бүлә юлымны:
Юксындыр син, сизәдер кош
Юлым бушка булуны...

Тынма, дәрья, айка, чайка:
Күнмәгәнмен тынлыкка.
Упкыннарың берни түгел,
Батырма тик моңлыкка...

1951 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьгә анализ ясагыз. Анализ тәртибен дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

2. Бу шигырь «Агыла да болыт агыла» шигыренә ачыклык кертә. Ничек ачыклый?

3. «Тынма, давыл!» шигырендәге табигать күренешләрен «Агыла да болыт агыла»дагы табигать күренешләре белән чагыштырыгыз. Аермаларын һәм охшашлыкларын күрсәтегез.

* * *

И диалектик кануннар,
Сездә әхлак кайда соң?
Яратырга өйрәтә бит
Мескен адәм — баласын.

Хакыйкатьнең этикасы
Һәм әдәбе кайда соң?
Ярашырга өйрәтмәкче
Мине — татар баласын...

Язылган елы юк.
50 нче еллар булуы мөмкин

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ ясагыз.

2. Аның «Агыла да болыт агыла», «Тынма, давыл!» шигырьләре белән бәйләнешен табыгыз.

ИЛДӘ НИЛӘР БАР ИКӘН?

Тышта нләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Боз тәрәзә алсулана,
Пожар микән, таң микән?
Тышта нләр бар икән?

Бездә дә таң тугандыр,
Инде ул да торгандыр,
Бергә чаклар исенә төшеп,
Күңелләре тулгандыр...
Бездә дә таң тугандыр.

Уйлыйдыр ул: «Сау микән?
Эче тулы зар микән?
Хәсрәтләрен таратырга
Тәмәкесе бар микән?
Исән микән, сау микән?»

Аклы киемен кигәндер,
Бәлки, кайтыр, дигәндер,
Зәңгәр карны ера-ера,
Вокзалларга килгәндер...
Бәлки, табылыр, дигәндер...

Илдә нләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Һавадагы алсу шәүлә
Пожар микән, таң микән?
Илдә нләр бар икән?

1944 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Беренче һәм соңгы строфаларның эчтәлеген вакыйга итеп күз алдыгызга китерегез һәм шул вакыйга-сурәтне мөмкин кадәр тулырак итеп сөйләгез.

2. Бу кабатланган строфаларның аеруча киеренке, каршылыклы урынын табыгыз. Ул урынның ни өчен киеренке булуын аңлатыгыз.

3. Беренче һәм соңгы строфалар эчтәлекләрендәге аерманы сөйләгез.

4. «Пожар микән, таң микән?» соравы тыш белән ил хәлен үзара бәйләп куйды. Бу юллар шигырьнең башка өлешләре белән дә бәйләнешкә керәме?

5. Лирик герой хисенең сәбәбен «сагыну» дип тә әйтергә мөмкин. Ләкин «сагыну» сүзе шигырьдә сөйләнгән сәбәпне ачып бетерә алмый. Сәбәпнең ачылып бетмәгән эчтәлеге турында сөйләгез.

6. Шигырьдә хис дәрәҗәсе ничек күрсәтелә?

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы?—
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

— Кайт!..— дип, хатлар
килделәр...
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
— Бусы — алкалары,
Бусы — кабере... — диделәр.

Әгәр тагын килсәләр,
— Сау!— дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
— Шундадыр ул...— дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?—
Бәйлисе бар йөрәкне...

1956 ел

Шигырьгә анализ

Проблема. Шигырьнең беренче һәм соңгы строфаларында лирик герой хисенең сәбәбен, дәрәҗәсен һәм юануын күрү кыен түгел. Әмма шигырьдә бу ике строфа белән бәйләнешләре тиз генә абайланмый торган башка строфалар да бар. Шуларның бәйләнешләрен ничек табарга? Моның өчен, димәк, анализның башка юлларын сайларга кирәк. Нинди юл сайларга?

Алдагы дәресләрдә күреп үткәнебезчә, Хәсән Туфан шигырьләре үзара бик тыгыз бәйләнештә торалар. Бер-берсен ачыклап, тулыландырып киләләр. Димәк, бу шигырь дә башка шигырьләр белән ниндидер бәйләнешкә керә. Шул бәйләнешне ничек табарга?

Фокус. Фокусы ачык күренеп торганда, анализны фокус табудан башлыйбыз. Әсәрне тагын бер тапкыр укып чыгыйк һәм андагы иң киеренке, өстәмә эчтәлеге күзгә бәрелеп торган урынны табыйк. Иң киеренке урын — «еламаска өйрәтте» гыйбарәсе[1]. Беренчедән, ул шигырьнең башка өлешләре белән каршылыкта тора (лирик герой хәсрәте артканнан-арта бара, ә ул еламаска өйрәнгән), икенчедән, соңгы строфада аңа яңа эчтәлек өстәлә, өченчедән, аның бәйләнешләре күп (күзгә бәрелеп торганы: беренче һәм соңгы строфада ул тыш белән ил хәлен бәйли). Хәзер фокуска ялганган өлешләрне табыйк.

Шигырьнең ике өлеше. Шигырьне, лирик геройның даими хәсрәте һәм башына төшкән яңа хәсрәте дип, ике өлешкә бүлә алабыз. Беренче, икенче һәм соңгы строфаларны лирик геройның күпьеллык интегү нәтиҗәсенә багышланалар дип әйтергә мөмкин. Икенче строфада сүз күпьеллык йөрәк яраларын дәвалау турында барганга, ул да әсәрнең беренче өлешенә керә.

Ә менә өченче һәм дүртенче строфаларда сүз әле яңа гына өстәлгән яңа хәсрәт турында бара. Шуңа күрә алар аерым өлешкә бүленеп чыгалар.

Хәзер өлешләрне аерым-аерым өйрәник.

Даими хәсрәт өлеше. Шигырь башындагы ике юл укучыны күп мәгънәлелеге белән үзенә тарта. Башта ул, еламаска өйрәнүне туры мәгънәсендә аңлап, лирик герой чыныккан, ихтыяр көчен арттырган дип, тыныч кына укый. Ләкин өченче юлдан башланган сүзләр әлеге романтик халәтне җимерә.

---

[1] Гыйбарә — текст, җөмлә өзеге.

Чыныгуы, ныклыгы белән мактанган кеше йөрәген күлмәк җиңен ертып бәйләү хәленә төшә алмый.

Соңгы строфа, «Дөнья мине үзгәртте» сүзләрен «Бирде дөнья кирәкне» сүзләренә алмаштырып, ачыклык кертә. Еламаска өйрәнүнең чыныгу, ныклык түгел, бик югары дәрәҗәдәге хәсрәт булуы беленә. «Күлмәк җиңен ертасымы?» сүзләрендә чарасызлык халәтен абайлап алабыз һәм үз сүзебез белән лирик геройның юану эзләве, үзен үзе тынычландырырга тырышуы дибез.

Соңгы строфада Хәсән Туфан дүртенче юлны «Кайсыгызның кулы җылы?» дип үзгәртә. Нигә шулай итә? Бу сорауга шигырьнең икенче өлешен җентекләп өйрәнгәч җавап бирә алабыз.

Яңа хәсрәт өлеше. Бу өлешнең үзен икегә бүлеп өйрәнәбез. Дүртенче строфа лирик геройның бик авыр хәбәр ишетүе турында сөйли. «Бусы — алкалары. Бусы — кабере...— диделәр» сүзләре — бу хәбәрнең иң киеренке урыны. Бу кечкенә генә юлда матурлык, яшьлек, хәтер үлем белән янәшә куела, һәм шул янәшәлек, бер үк вакытта бер-берсе белән каршылыкка килеп, килешеп (үлгән кеше алкалары бит), лирик герой хисенең әллә никадәр әйтелми калган эчтәлеген уйлап табарга ярдәм итә.

Дүртенче строфа тулысынча лирик герой югалткан кешенең ни дәрәҗәдә якын һәм кадерле булуына багышлана.

Өлешләр арасындагы бәйләнеш. Менә хәзер дүртенче строфадагы «Кайсыгызның кулы җылы?» соравы да, «Еламаска өйрәтте» гыйбарәсе дә аңлашыла.

Өлешләр арасындагы бәйләнешне хәсрәт өстенә хәсрәт өстәлү дияргә була. Беренче өлештә Хәсән Туфан лирик герое кичерешләренең нәтиҗәсе турында сөйли. Күп еллар дәвамында артканнан-арта барып, аның хәсрәте даими рухи халәткә әверелде, ди. Ул үзенең бу халәтен (бу очракта лирик геройны авторның үзе белән тиңләштерә алабыз) сабыр гына, хәтта беркадәр елмая төшеп сөйләп бирергә көч таба. Үлем белән яшәү чигендә яшәргә күнеккән шагыйрь хәтта шул хәлендә дә үзен үзе юата алырына ышана.

Ләкин шигырьнең икенче өлеше бу ышанычка җитди үзгәреш кертә: яшәешнең үзенә әйләнгән даими хәсрәткә тагын берәү — бу юлы иң зурысы өстәлә. Күп хәсрәтләр өстенә нибары тагын берәү генә өстәлә! Ләкин нindие бит!

Лирик герой хәзер дә еламый. Аның күз яше күптән кипкән инде. Хәсрәтенең ни дәрәҗәгә җитүен йөрәге әйтеп бирә:

соңгы ярасы даими халәтне үзгәртә. Хәзер аны дәваларга читтән ярдәм кирәк була. Анда да теләсә кем түгел, фәкать җылы куллы шәфкать иярләре генә.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Шигырьгә анализ» бүлеген укып, анализ эзлеклелеген дәфтәрегезгә язып куегыз.

2. «Еламаска өйрәтте» гыйбарәсенең даими авыр хәсрәтне аңлатуын исбат итегез.

3. «Еламаска өйрәтте» гыйбарәсен автор беренче строфада да, соңгысында да кабатлый. Соңгы мәртәбә кабатлаганда бу гыйбарәнең эчтәлеге үзгәрәме?

4. «Күлмәк җиңен ертасымы?» гыйбарәсенең мәгънәсе нинди булырга мөмкин?

5. Икенче строфадагы «сугыш», «дала», «яралар» сүзләренең мәгънәләре турында сөйләгез.

6. «Бәйлисе бар йөрәкне»,— ди Хәсән Туфан. Метафораның мәгънәсен әйтегез.

ТАМЧЫЛАР НИ ДИЛӘР?

Луиза Салигаскәровага

Сандыгында ята
Синнән калган
Белешмәләр салган ридикюль:
Миннән сиңа — гомер юлдашыма
Иң беренче бүләк иде ул.

Ридикюльдә калган белешмәләр...
Алардагы кайбер билгеләр
Тормышыңның соңгы хәбәрләрен
Бүген миңа сөйләп бирделәр...

Һәркайсында
Тамчы-тамчы эзләр,—
Алар нинди тамчылар икән?
Болыттанмы алар,
Әллә синең
Керфекләрдән тамдылар микән?..

Тәрәзәңә «җилләр» бәрелгәннәр,
«Сагынма!»— дип янап киткәннәр,
Күнмәгәнсең... Эштән сөрелгәнсең...
Еллар сине донор иткәннәр...

Посылкалар белән ярдәм иттең:
— Без бит илдә... өйдә бит...— дидең.
Ә ул ярдәм
Каныңа алыштырган
Паекларың икән бит синең...

Алдарсың дип уйлый идеммени?—
Ә син мине алдагансың ич:
Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син
Җаның белән ялгагансың ич!

Соңгы таңың беленеп килгәндә дә
Күрешү көнен көткәнсеңдер дә,
Ләкин Ирек
Бераз кичегеп килеп
Эзләп тапты мине Себердә...

Баш иям дә рәсмең каршында мин,
Күзләреңә багам тилмереп,
Яшьле күзен Мадоннага текәп
Сусез калган Рафаэль кебек...

Тирбәлешеп куя
Уйчан гөлләр
Бер-беренә хәбәр биргәндәй:
«Кеше булсак әгәр,
Без дә шулай
Сыкрар идек, бәлки...»— дигәндәй...

1957 ел

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

УРАЛДАН ҮТЕШЛИ

...Җырлый-җырлый үттем Барабаны,
Җырлый-җырлый үтәм Уралны,—
Европаны Азиягә илткән,
Декабристлар йөргән юлларны.

Кочаклыйсы килә шул Уралның
Яшьлек эзем калган һәр төшен...
Каршыларга чык син вокзалларга,
Очрашырга кил син, яшьлегем!

Бер карауда сине табармын мин,
Бер карауда сине танырмын:
Төсең генәмени синең миңа,
Йөрешең дә таныш, акыллым.

Ә син мине таба алмассыңдыр,
Юк, син мине таный алмассың:
Тик аз гына синең төсле чалны
Үзең итеп саный алмассың...

Син карарсың
Һәрбер чал абыйга:
— Мин боларның кайсы икән?— дип,—
Шушы олы юлчы агайларның
Кайсысында мин дәвам итәм?— дип...

Каршыларга чык син вокзалларга,
Очрашыйк бер тагын, яшьлегем...
Кочаклыйсы килә шул Уралның
Яшьлек эзем калган һәр төшен...

1956 ел

Бирем

Шигырьнең эчтәлеген табыгыз.

Нәтиҗә

Хәсән Туфан илдә хаксызлык хөкем сөрүен кулга алынганчы ук белә. Әдип 1937 елда ук «Ә йолдызлар дәшми» шигырендә:

Дене түгел, көне өчен генә
Яшәп илнең кайбер кибәге
Дегетли дә дөмгә сөрә бүген
Иң кадерле эре ирләрне,—

дип, хакыйкатьне ачыктан-ачык язган иде.

Баштарак ул иҗатында, Муса Җәлил кебек, үз хакыйкатен башкаларга ирештерү нияте турында сөйләде, үзенең Туган иле өчен утка-суга керергә әзер торуын әйтеп:

Сораучылар булса, җиткерегез:
Менә шундый ирләр идек без...—

дип белдерде. Ләкин Хәсән Туфан хакыйкатьне үзенчә тасвирлады. Аның һәр шигыре хакыйкать, хаклык турында. Хаклык һәм хаксызлык — әдип хисләренең сәбәбе, уйларының темасы.

Хәсән Туфан лирик героеның кичерешләрен үткән вакыйга турында сөйләгәндәй, җай белән генә, бик якын кешесенә серен ачкандай сөйли. Күпчелек шигырьләрендәге строфалар эчендә беренче һәм соңгы юлларның кабатлануы сабырлыкны билгеле бер дәрәҗәдә сакларга ярдәм итә.

Сугыштан соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре белән Хәсән Туфан татар әдәбиятын моңа кадәр күренмәгән хис эчтәлекләре һәм ул хисләрне сурәтләү алымнары белән баетты.

ХАКЫЙКАТЬНЕ ТАРИХТАН ЭЗЛӘҮ

И. Сталинның үлүе халык өчен кайгы да, шатлык та булды. Кайберәүләр хәзер илдә зур үзгәрешләр булыр дип өмет иттеләр. Чыннан да, шулай булды. Шәхес культы явызлык дип бәяләнгәннән соң, сәяси тоткыннарның күбесе гаепсез табылды һәм азат ителде. Ил аз булса да иркен сулыш алды.

Ләкин идеология үз көчендә кала бирде. Ил элеккечә үк иң ирекле ил, хокуксыз халык иң бәхетле халык дип саналды. Рәсми хакыйкать аз гына да үзгәрмәде. Иң акыллы, иң изге, иң тугрылыклы дип күкләргә чөелеп макталган юлбашчылар алмашына торды, алар урынына шундый ук булдыксызлар менеп утырдылар.

Элеккечә үк идеология белән риза булмаучылар эзәрлекләнделәр. Төрмәләргә, юләрләр йортларына озатылдылар, чит илләргә куылдылар. Дошманнар белән көрәшү дә дәвам итте.

Ләкин бу елларда хакыйкать бәйдән ычкынган иде инде. Исән калып ирекә чыккан тоткыннар үзләре өчен бик кыйммәткә төшкән хакыйкатьләрен илгә таратырга мөмкинлек алдылар. Бер-берсенә капма-каршы булган ике хакыйкать барлыкка килде. Аларның берсе — рәсми, ялган хакыйкать, ә икенчесе тыелган, ләкин көннән-көн киңрәк таралган төрмә-лагерьлар хакыйкате иде.

Хаклык, хакыйкать темасы 60—70 нче елларда да халыкны, димәк, әдәбиятны да борчыган иң актуаль тема булып калды.

Хаклыкны ачыктан-ачык сөйләргә ярамаган бу елларда да әдипләр үз сүзләрен әйтергә җаен таптылар. Идеологиягә каршы чыгу булмаса да, аны кабатлаудан качу юлларының берсе үткән заман вакыйгаларын язу иде. Хәзер шундый әсәрләрнең өчесе белән танышыйк.

Гомәр Бәширов

(1901—1999)

ТУГАН ЯГЫМ — ЯШЕЛ БИШЕК

Җирән кашка сагышы

I

Аякны-кулны, ботны-чатны, дигәндәй, малайларча як-якка ташлап, өйалдында йоклап яткан чагым.

Менә ачык ишектән әти тавышы колакка чалынды:

— Һи! Бу малай һаман тормыймыни әле? Нигә уятмыйсың? Бия аңа колын алып кайтты бит!

Колын! Шуны гына ишетүем булды, ялт итеп сикереп торуым булды. Шулай булмый соң! Авыл малаеның иң мавыктыргыч, иң матур хыялларының берсе шул колын лабаса инде!

Ишегалдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын! Үзе җирән, аркасыннан бармак иңлеге коңгырт тасма сузылып киткән, алгы аякларының балтырына тикле ак оек кигән. Маңгаенда йолдызы да бар.

Өммикамал апай зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер тагып җибәрдек.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көннең көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Иртә тордыммы, иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы әләктерәм дә колын янына чыгам.

Ике-өч айдан колыныбыз зерә дә чаяланып китте. Ул хәзер инде, элекке шикелле, тәртәгә ышкылып йөрми, эт өргәннән дә курыкмый. Пыр туздырып, этләрнең үзләрен куып йөри. Капка ачылдымы, иң элек ул чыгып чабар. Колынның, сабыйлык җиңеллеге белән, койрыгын-ялын тузгытып, сикергәләп, уйнап йөрүен карап тору үзе бер рәхәт!

Мин инде киләсе елга, колын тайдан кырыкмышка чыккач, аңа атланып, малайлар белән узышулар, аны коендырып кайтулар турында хыяллана башлаган идем...

Әмма көз көне, кырпак төшеп, кар яуганны көткән бер вакытта, колыным базарга барган җиреннән әйләнеп кайтмады. Мин аңа нидер булуын биянең авыл буенча кешникешни кайтуыннан ук сизенгән идем. Ул ишегалдына кайтып кергәч тә тынычлана алмады.

Мин үземне кая куярга да белмәдем. Бөтен дөньямны авыр кайгы басты, колын булмагач, бернәрсәнең дә кызыгы калмаган иде. Бер ишеккә, бер тәрәзәгә атылып, ярсый-ярсый, аранда кара бия кешни, лапас артында, тыела алмыйча, мин елыйм.

Шунда әни килеп чыкты.

— Тукта, улым, тагын булыр колының, булыр,— диде, башымнан сыйпап, аркамнан сөйде.— Менә күрерсең, бия тагын алып кайтыр, боерган булса...

— Кайчан?— дип кенә сорый алдым.

— Язган булса, яз көне! Быел булмаса, яренгә[1].

Колынсыз калу хәсрәте бераз гына җиңеләя төште. Шул вакытта кабынып калган якты өмет озак еллар күңелне балкытып торды: кара биябез җәйнең бер кояшлы иртәсендә болыннан, теге чактагы шикелле, тагын бер матур колын ияртеп кайтмасмы икән?

Мин шул бәхетне чын күңелдән ышанып, зур булганчы көттем.

V

Пәнҗешәмбе кичне, ашап-эчкәннән соң, без һәммәбез дә түр як сәкенең уртасында эленгән җиделе лампа тирәсенә җыела торган идек. Бүген дә шулай булды. Әти үзе түр башындагы ястыкта кырын ята. Ята торгач, ул абыйдан ничек укуы турында, мәдрәсә турында сорашырга тотына.

Верстагы янында көне буе кисеп, юнып, ышкылап, әллә никадәр эш эшләгәннән соң, түр башындагы ястыкта кырын ятуы аңа бик килешә иде.

Берәүнең дә атасы, безнең әти шикелле, аркасы сырлы урындыклар, рамнар, такта умарталар ясап, пыялалар куя белми.

VI

Ул вакытта инде апай да, вак-төяк өй эшләрен бетереп, шул ук лампа яктысына килә. Алсу төсле ситсыга чынаяк өстеме, нәрсәме чигәргә тотына. Ул яз көне, менә хәзерге шикелле,

---

[1] Ярен гә — киләсе елга.

башын да күтәрмичә, айлар буе киндерләр, чүпләмле сөлгеләр суга, кыш буе намазлыклар, өстәл япкычлары, кулъяулыклар чигә, һәммәбезгә дә пирчәткәләр, оекбашлар бәйләп бирә.

Безнең өйдә эти белән абыйның гына җире бар. Хатын кешеләргә җир бирмиләр, ә мин, җир өләшкәч туганлыктан, бөтенләй җирсез калганмын.

Әни орчыгын берничә мәртәбә зырылдатып алуга, апай аңа әллә ничек кенә итеп ым какты.

Әни күз кырые белән генә этигә карап алды:

— Баягынак Мәликә аулак өй сакларга Өммикамалны да чакыра кергән иде дә. Иптәш булыр дип...

Бу юлы этинең тавышы кырыс ишетелмәде:

— Ярар, керсен...— диде.

Апай кеше әле шуннан соң да, ашыкмаган кыяфәт белән, беравык тын утырды. Бераздан аны әни үзе кыстый башлады:

— Бар инде, кер! Кара аны, узынасы түгел! Иртә белән яктырганны көтеп ятма, эш күп.

VII

Абый әллә кайчан ук әзер иде инде. Ул катыргы тышлы бер-ике калын китапны янына куйган да кыяр-кыймас кына этигә карап алгалый. Эти нәрсә укырга куша бит.

Бу юлы эти аңа китапның зәңгәр тышлысын укырга кушты.

Нәрсә укуларын аңламасам да, мондый кичәләр миңа бик күңелле тоела иде. Тышта суык. Ә без менә шулай, бәйрәм алды кичәсе итеп, җылы өйдә, якты лампа тирәсендә рәхәтләнеп китап укып утырабыз.

Сандугачны кем үтергән?

Мин белә башлаган вакытларда эти илле яшьләрдән узган, киң җилкәле, таза гына бер кеше иде. Ул йомшаклыкны, изелеп торуны, җебегәнлекне һич тә яратмады. Уңмаган, булдыксыз кешеләрне җене сөйми иде.

Миннән олы абыйны — Хәмзәне өч-дүрт яшьлек чагында, ут белән шаярган өчен, ыштанын салдырып, кычыткан белән чапкан. Үлә-үлә дип, төннәр буе саклап чыкканнар.

Мин аның нинди генә кыен чакларда да зарланганын белмим.

I—VI

Безнең урам буендагы агач бакчасына сандугач иялəнгəн иде. Аны ел саен көтеп ала торган булдылар. Əгəр берəр кичне сандугач моңы ишетелми торса, борчыла башлый торганнар иде.

Җəй башының бер иртəсендə сандугачны үле хəлендə таптылар.

— Кайсы имансызының эше бу? Кемгə дөнья тарайган? Муеннары сынгыры! — ди əти.

Озак кайгырышкан, уйлашканнан соң, сандугачны Əхəт үтергəндер дигəн фикергə килделəр. Аларча, моның нигезе дə бар икəн. Безнең апайның кичке уеннарда шул усал егет белəн бергəрəк булуы минем дə күзгə чалынганы бар. Моны əти белəн əни да белəлəр, тик апайның бу эшен һич тə өнəмилəр икəн. Шул йортсыз-җирсез батрак егеткə кияүгə чыгып харап булмагае дип куркалар.

Менə шул Əхəт кичен апай белəн сөйлəшеп утырганда, сандугач тавышы боларга сөйлəшергə уңайсызлаган да, янəсе, егет аны агач башыннан бəреп төшергəн була.

Сандугачны шомырт төбенə əти үз кулы белəн күмде. Əхəтлəр ягына йодрык күрсəтеп, тагын бер янап алды:

— Бер килеп капмассыңмы əле, ристан! Мин сине!..

Əти лапас тирəсенə китеп күренмəс булуга, югары өйдəн, елардай булып, апай килеп төште. Əнинең иңбашына ябышып:

— Нахак бит, нахак!— дип пышылдады.— Ходаем! Белмəгəн, күрмəгəн көйгə! Ничек кулы барсын!

Əни белəн апай шуның белəн баш ватып торганда, күрше кызлары, койма ярыгыннан пышылдап, мине үз яннарына дəштелəр.

— Гумəр, җаным!— дилəр болар.— Сандугачның канатымы, йə булмаса берəр каурыемы төшеп калмадымы икəн? Бик тə кирəк иде.

Миңа моның сəбəбен соңыннан əйттелəр, сандугач канаты сөйдергеч икəн! Əгəр сандугачның йə каурые, йə канаты белəн егетнең берəр җирен сыйпасаң, ул егет кызны тəкатьсезлəр булып ярата башлый икəн.

Язгы Сабантуйлары

II

Иртəгə Сабан туе дигəн кичне кем генə тыныч йоклый алды икəн! Таң тишегеннəн торып, күрше кулəнгə кереп-чыгып йөри торгач, кояш чыга. Капка төплəре тулы бала-чага. Тагын

бераздан урамнар атларының ял-койрыкларына кызыл чуклар таккан егетләр, үсмер малайлар белән тула. Шул арада гармун тартып, җырлап та җибәргәлиләр.

VI

Бакча артына йөгереп чыксак, аргы якның җил тегермәне янында мәхшәр! Ындыр артлары, киндер җирләрен, тегермән тирәләрен — бөтенесен халык каплаган. Шул халык диңгезе өстендә иң күзгә бәрелгән нәрсә — озын колга, аның башында, бөтен дөньясына ямь биреп, көрәшкә дәшеп җилфердәп торган аллы-гөлле Сабан туе бүләкләре.

Хәкимҗан белән без уртага узарлык буш ара эзләп арлыбирле сугылган арада, байтак вакыт узды. Ул арада кайсыдыр: «Һайт!»— дип кычкырып та җибәрде, һавада ике аяк айкалып та китте, аякларның хуҗасы «дөп» иттереп барып та төште.

Җиңүче егет, сөлгесен кулында бөтерә-бөтерә, күкрәк киереп, мәйдан уртасында айкалырга тотынды.

Әмма озак көттермәделәр. Гәүдәгә базык кына, киң җилкәле бер егет чыкты.

— Кәче егете чыкты. Кәче! — диештеләр.

— Менә бу Албанның сыртын сындыра да сындыра инде!

— Һа! Сындырмаска,— диде Сарник Галимҗан, тыңкышланып,— егерме потны уйнатып кына йөртә ул.

Ләкин без, күз дә алмыйча карап торсак та, барыбер күрми калдык. Халык аһ итеп, бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда, Айбан егете әллә кая, мәйдан кырыена ук барып төшкән иде.

Мөхәммәтҗан җизни, Кәче егетенә каршы көрәшкә чыгучы һаман да күренмәгәч, пошынып: «Һи, эшмени бу? Кая соң безнең егетләр?» — дип кычкырды.

Шунда барысы берьюлы Әхәт абыйны димли башладылар:

— Йә, чык инде, Әбделәхәт, хур итмә Яңасаланы!

Күп кыстый торгач, Әхәт абый күнде. Ашыкмыйча гына мәйдан уртасына юнәлде.

Ул сөлгене кулына ашыкмыйча гына урады-урады да, теге егетнең билен алыр алдыннан, тегермән ягына күз салды. Безнең апай да күреп тормыймы икән дип, өметләнеп карагандыр инде.

Мәйдандагы халыкның һәммәсе дә диярлек, куәт биреп, төрле яктан кычкыра башлады:

— Бирмә билне, Әхәт, бирмә!

Кәче егете күтәреп алмакчы булып карый да, шуа китә тегенең кулы. Әхәт абый салмак кына тирбәлгәләп йөрде-йөрде дә кинәт тегене бөтереп тә алды. Халык дәррәү урыныннан торды. Инде тотып ата дигәндә, Кәче егете кулын күтәрде.

Бөтенесе мәйдан уртасына ташландылар.

— Ай, маладис, Әхәт туган! — диештеләр.— Ай, куандырдың!

IX

Мәйдан беткәннән соң, көн кичкә авышкач, өйгә кереп кенә чыктык та, ал-кызыл, яшел, зәңгәрдән киенгән чуп-чуар кыз-хатыннар төркеменә ияреп, бормалы су буена — Бөйдә болынына киттек.

Мин Хәкимҗанны тауга түбән төртеп җибәрдем дә, үпкәләмәсен өчен, аның артыннан үзем дә тәгәрәп киттем.

Хәкимҗан, миннән бер яшькә олырак булса да, шуның өстенә сөйләшмәве белән ачуны китерсә дә, бик әйбәт малай. Без аның белән гел бергә уйный торган идек. Бәлки, ул үзенең әрсез түземсезлеге белән ошагандыр? Шуның өстенә Хәкимҗан иптәш малайларын сыйларга бик ярата. Менә бүген дә әле ул миңа чуклы конфетлар белән ике-өч кызыл билле прәннек алып төшкән. Егетләр, кызлар тирәсендә буталып йөри торгач, бер шәльяулык читеннән, очкын чәчрәгәндәй, сөрмәле күз сирпелеп китте. Карасам, үземнең апай! Аның янында бая гына мәйдан тоткан Әхәт абый басып тора. Якын тирәдән узган яшьләр һәммәсе аңа якын итеп елмаеп үтәләр. Мин инде Әхәт абыйның җизни булуына да каршы түгел идем.

«Бәбде бәҗвин»[1]

Ул көнне әни мине көндәгедән иртәрәк уятты.

— Тор, улым! Бүген мәдрәсәгә барасың бит!— Үзем дә сизмәстән, йокым берьюлы ачылып, күңелем күтәрелеп китте. Шәкерт булам бит, шәкерт!

---

[1] Бәбде бәҗвин — хәтерләргә ансат булсын өчен, саннарны сүзләргә әйләндереп төзегән гарәпчә тапкырлау таблицасы.

II

Хәлфә мәдрәсә турысына килеп җиткәндә, әле генә шау-гөр килеп якалашкан, кычкырышкан малайлар, бик әдәпле, тәти малайлар кыяфәтенә кереп, «песием» генә булып калалар. Тезелешеп утыралар.

Зәбихулла абый, үзе кадим мәдрәсәсендә укыган кеше булганлыктан, яңача укытуны белеп җиткермичә, кайчакларны, күрәсең, кадимен-җәдитен бергә бутап та укыткандыр. Шулай да без җәгъръфия, үзебезнең тел, хисап шикеллеләрне яратып укыдык.

Хисап дигәне кызык кына укытыла торган иде. Хәлфә абый чыгарасы гамәлләрне әйтә башлый. Без кара тактаны тезгә куеп язарга тотынабыз.

— Әүвәл баштა алдым дүрт баш куян тиресе, дип язасың. Берсе ун тиеннән — бәһасе буладыр кырык тиен. Янә алдым алты баш сыгыр тиресе...

Зәбихулла абый безнең кара тактага күз салгалап әйләнә дә алга басып сорау бирә:

— Җәмгысе күпме була?

Кыш буена без бу куян тиресе белән сыгыр тиресенең байтакка кадәр башларын әйләндердек.

Ул заманда китапларның беренче битендә һәм төсле шәмаилләрдә[1] бары тик хыялда гына яки төштә генә күренүе мөмкин булган сокланргыч матур бакчалар, бай шәһәрләр, зиннәтле сарай сурәтләре бирелә торган иде. Ихтимал, җәгъръфия укыганда хыялны үстереп җибәрүгә әнә алар да ярдәм иткәндер.

Хәлфә абый, дин сабагын элеккечә бик тырышып өйрәтсә дә, укуның икенче елында татарчага күбрәк урын бирә башлады.

Сабак бетеп кайтыр алдыннан, ул үзенең көн буе утырган миндәреннән кузгалып китә дә тәрәзә янына барып сөяләә. Кайсы малайга булса да берәр хикәя, мөнәҗәт йә шигырь укыта.

Бер генә шаяручы да юк. Малайларның кайсы уйга калган, кайсы, тезләнеп утырган килеш, идәнгә тегене-моны сызгалый. Әмма һәркайсы нидер уйлый, һәркемнең күңелен нидер кытыклый.

---

[1] Шәмаил — рәсем. Бизәп язылган догалыклар.

X

Быел Зәбихулла абый базарга барган саен нинди дә булса бер яңа китап алып кайта торган булды. Шигырь китабы икән, ул аны сабак бетәр алдыннан мәктәптә кычкырып укыта, хикәя-фәлән икән, өйгә биреп җибәрә иде.

Бер базар көнне, без мәдрәсәдә котырынып уйнап ятканда, кайсыдыр:

— Кайткан! — дип кычкырып җибәрде.

Ләкин ул яңа китапны кайтыр алдыннан гына күрсәтте:

— Кем укый?— диде. Китапны миңа сузды. Шатлыктан кулларым дерелдәп китте. Китапта мондый шигырь дә бар иде:

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Бу шигырьне миңа тагын бер кат, аннан соң тагын бер кат укыттылар.

XI

Хәлфә абый, кичен бер кереп чыкканнан соң, яңадан мәдрәсәгә кереп тормый. Кайсыдыр җырлап җибәрә йә кубыз чиртә.

Аннары ничектер үзеннән-үзе әкиятләр башланып китә. Әхмәт тезләрен кочаклап, мичкә аркасын терәп утыра да күзләрен йома төшә. Шуннан китә сөйләп, китә тезеп! Ниләр генә ишетмисең, кайларда гына булып кайтмыйсың!

Шул гаҗәеп дөньядан элеге тузанлы мәдрәсәгә кайтып төшкәч, мондагы көнкүрешең ярлы да, кызыксыз да булып кала, каядыр китәсе, нидер илдә булмаганны эшлисе килә башлый.

Кунак кызлар килде утырмага

I

Менә беркөнне иртән торып чыгасың — бөтендөнья ап-ак! Кич-иртә урамнан шыгырт та шыгырт аяк тавышлары ишетелә башлый. Менә кайчан кузгала төрле өмәләр: каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе. Шул вакытка турылап, күрше авыллардан кунак кызлар килә. Байга да килә, ярлыга да.

II

Шул көннәрдә күрше Гыйльми түтиләргә кергән идем. Аның улы, зурлар күрмәгән арада, кече яктан мине үз янына чакырды. Фазулланың муеннары, күкрәкләре, тамак аслары —

бөтен җире бәйләүле. Үзе коточкыч ябык. Озынча күкшел битендә кан әсәре калмаган.

Фазулланы ниндидер «тамыр чире» белән авырый дип әйтәләр. Ул почмак яктан чыкмый, бүтәннәр белән бер табынга утырмый. Гыйльми түтинең үзенең дә әйткәне бар:

— Арча больнисенә алмыйлар. Казанга алып барырга хәлебез җитми. Япь-яшь көенчә шушы почмакта сүнә инде, балакаем...

Сорый Фазулла миннән, шыпыртлап:

— Хат башы ясый беләсеңме? Миңа берне ясап бирче, бик матурлап. Мин сиңа гармун кычкыртырга бирермен.

Ул — бик оста гармунчы. Ул шундый матур уйный, җәй көннәрендә кулына гармун алса, аның тәрәзәсе янына әллә никадәр кеше җыела.

Фазулла хат башын әйләндерә-әйләндерә карады да яңадан миңа сузды.

— Буш урыннарын язып та бир инде. Хат... Кызларга...

Нишләмәкче була бу? Аңардан кем хат алсын?! Ияк очында ике-өч сакал бөртеге тырпаеп тора. Муены көзге чебешнеке шикелле нәп-нәзек.

Фазулла миңа таба иелде.

— Минем көннәрем санаулы. Егет көе үләм. Минем кордашларым әллә кайчан кызлар белән йөри, кайсылары өйләнде дә инде. Ә минем кызларның кулларын да тотканым юк.

Баш тартырга көчем җитмәде:

— Кемгә язарга соң?— дидем.

— Теләсә кемгә! Миңа хат кына булсын.— Ул бераз уйланып торды да тагын әйтеп куйды: — Яз үзегезгә килгән кунак кызга! Минем үлгәнче бер кызлар хаты аласым килә. Бер генә сүзле булса да! Бер генә тапкыр булса да.

Мин ул хатны яздым. Хатны мин, аулак урында туры китереп, кунак кызга бирергә тиеш идем. Ярый әле, вакытында тыелып калганмын.

Җавап хатны үзем язармын да, кунак кыз киткәч, аныкы итеп бирермен дигән уйга килдем. Шулай да Фазулланың бүтән үтенечләрен үтәмичә булдыра алмадым.

— Озакламый үләсе егет инде ул, апай,— дидем.— Бик кызганыч. Су китергәндә аларга да берәр көянтә су кертеп чыкмасылармы дигән иде.

Кунак кызым, борчылып, ни әйтергә белмирәк торды.

— Ай, Гумәр генәм! Кеше теленә кереп хур булсам, ни хәлләр итәрмен?

— Актык сүзен дә әйтим инде, апай! «Су кертмәсәләр, безнең өй түреннән үткәндә, ичмасам, тәрәзәгә генә карап алмасмы икән?»— дип тә ялынды.

Кунак кызым кинәт битен каплады да, йөгереп, түбән өйгә төшеп китте.

III

Мин Фазуллаларга йөгердем. Нишләрләр икән, керерләрме икән кызлар, юкмы икән?

Фазулла өстенә өр-яңа зәңгәр сатин күлмәк, башына хәтфә кәләпүш кигән. Гыйльми түти өйнең ике ягын да бик пөхтәләп җыештырып куйган. Ул яшь килен төшерәсе каенанай кебек дулкынлана. Әле улының алдына япкан чуар юрганын, мендәрләрен төзәткәләп чыга, әле чаршауны ачып куя.

Янымнан узышлый колагыма пышылдады:

— Ярабби, күңелләренә мәрхәмәтләр салып, кереп кенә чыксаларчы! Керә алмасалар, бигрәк тә нәүмиз була инде!..

Аңа кунак кыз сүзләрен ничек әйтим? Телем үзеннән-үзе бөтенләй бүтәнне тезәргә тотынды:

— Әйттем, Гыйльми түти, әйттем. Керми калмаслар.

Менә урамга шәфәкъ нуры иңә башлаганда, тыкрыкта бик күп аяк тавышлары шыгырдарга тотынды. Ул да түгел капка ачылып китте, ишегалдына кызлар тавышы кереп тулды.

Фазулла тетрәнеп китте:

— Әни, яндыр утны!

Кызлар көр тавыш белән һәммәсе берьюлы хәл белергә тотындылар:

— Исәнмесез, саумысез? Әйбәт кенә торасызмы?

— Гыйльми түти! Шунда берочтан сине дә сулы итик дип йөрүебез инде бу!

Гыйльми түти, нишләргә белмичә, каушап, арлы-бирле килде:

— И җанкисәкләрем! Ниләр генә әйтим?! Нинди изгелекләр белән генә кайтарыйм?

Авыл кызлары шаулап сөйләшә-көлешә су бушаткан арада, кунак кыз, кыюсызланып кына, почмак якка борылды. Кибәхуҗаларча ягымлы гына көйли төшеп, бәгырьләрне эретеп җибәрердәй йомшак тавыш белән Фазуллага дәште:

— Нихәлләр бар соң, Фазулла абый? Ходаем, шулай сырхаулап торасыңмыни? Менә син, ә? Тизрәк сихәтләнә күр инде!

Фазулла коточкыч күзләре белән йотардай булып кунак кызның алсу битенә, зифа буй-сынына текәлгән дә катып калган.

Кунак кыз, почмак якка текәлгән килеш, бер сүз әйтә алмастан, арты белән чигенде-чигенде дә кинәт өйалдына чыкты һәм битен каплап иңрәп куйды.

Шаң-шаң итеп ни шаңгырдый

I

Беркөнне җәй башында, кармакларны күтәреп, капкадан гына чыгып бара идем, өйалдыннан дәшеп, апай туктатты:

— Гумәр, дим. Минем яныма керче!

Апай, зәңгәрсу-яшькелт күзләрен бик ягымлы мөлдерәтеп, миңа таба килә. Өстендә иңбашлары белән җиңнәре күпертмәле юка гына яшел күлмәк, колакларында ярты ай сыман көмеш алкалар җемелди. Апайның әнә шулай матур итеп киенүе дә, бик сөйкемле итеп, яратып каравы да мине эретә башлый. Мин аны хәтта бераз кызганып та куям. Җәйнең шундый матур вакытында иртәдән кичкә кадәр тузан эчендә бөкреңне чыгарып, киндер сугып утыру җиңел эш түгел. Ул да иректә баштан утырмый. Мин булышмасам, ул нишли генә ала?

Капкадан Кибәхуҗаның Ерак әби килеп кермәсенме! Ул килгәч кая инде...

Әбинең кечерәк кенә түгәрәк бөкресе дә чыккан инде, тешләре дә берән-сәрән генә калган. Шулай да аның кодрәте белән дәрәҗәсе искитмәле. Уллары-кызлары, аның белән киңәшмичә, бер генә зур эш тә кузгатмый диярлек.

Әби сәке түрендә иркенләбрәк, аякларын сузып утырды да, тәсбихен тарта-тарта, күзләре белән апайга ишарә итте.

— Утыр әле, кызым,— диде.

Апай сискәнеп киткән сыман күренде.

Әби сөяклә́ч куллары белән мине этебрәк җибәрде:

— Син бар, уеныңда бул!

II

Кая инде ул уен! Миңа шунда ук эш табылды — каз көтәргә куштылар. Шунда берочтан киндерне дә саклыйсы.

Үзем терлек-туар тирәсендә чуалам, әмма күңелдә гел апай. Өйдә нәрсәләр бар? Әби нинди уйлар белән йөри икән? Апай нигә сискәнде икән?

III

Менә бервакыт түбән очтан кызларның, дәртле бер уенчак көйгә салып, шыңгыр-шыңгыр киндер тукмаклаган тавышлары ишетелә башлады. Кичке тынлыкта ул бер акрыная, аннары тагын көчәеп китә иде.

Җыр түгел, гармун тавышы да түгел, шулай да тансык иде бу киндер тукмаклаган аваз. Ул, шаң-шаң итеп, авыл өстенә саф тавышлы яшь егет җырыдай шатланып күтәрелә. Бу яңгыравыклы шат көй һәммәсен дә искәртеп уза кебек:

— Мондый кичләр гел генә булып тормый, кызлар да киндер йомшартырга көн саен җыелмый. Тыңлап карале син: яшь йөрәкләр ни әйтә, кызлар күңеле ниләр дип сайрый икән?

Шаңгырдап чыккан шул агач көе ничек шулай бөтен авылны дулкынландыра ала икән? Әллә югыйсә яшь кызларның кичке моңнары, тыелгысыз яшьлек дәртләре, ни икәнлеген үзләре дә аңлап җиткермәгән ниндидер куанычлы һәм тынгысыз хыяллары шундый яңгыравыклы авазга әверелеп, көй булып чыга да бүтәннәрнең дә яшьлеген уятып йөриме икән?..

Монда чыгар алдыннан, әни бик сәер нәрсәләр әйтте:

— Ниең, апаең тирәсендәрәк йөрсәнә, кызлар арасында булсын, берүк читкә тайпылмасын!

Мин килгәндә, апайның нәкъ әнә шул «тайпылган» чагы иде. Ул, бераз читкәрәк китеп, Әхәт абый белән сөйләшеп тора. Тегесе киртәгә ике куллап чытырдатып ябышкан да, терләй йотардай булып, апайга текәлгән. Апай, башын түбән иеп, яулыгының почмагын авыз кырыена эләктергән килеш, гаепле кеше сыман, аска караган. Әллә югыйсә әби бүтән егеткә димләргә килгәнме?

V

Лапастагы йомшак печән өстенә кайтып сузылуыма төрле-төрле хуш ис эчендә калдым. Күңел тыныч түгел. Ерак әби килгәннән бирле, апай үзен кая куярга белми. Бәлки, ул Әхәтне бик, бик ярата торгандыр? Нишләптер әни дә бик борчулы.

Ул да түгел югары очта егетләр гармун уйнап җибәрде. Шундук, чулпыларын чылтыратып, апай да чыгып җитте. Безнең турыга җитәрәк, егетләрнең берсе (мөгаен, Әхәттер!) гармун көенә сәер генә җыр да әйтте.

Авыл күптән йоклаган иде инде. Бераздан кечкенә капка чыелдаган тавышка уянып китсәм, апай бакча ягына чыгып бара. Мин, йокыдан арынмаган иләс-миләс килеш, куркуымнан кычкырып җибәрдем:

— Апай, апай! Кая киттең?

Апай, җилтерәп килеп, мине кире яткырды:

— Ни пычагыма акырасың? Кара аны! Тының чыкмасын!

Әмма соң иде инде. Күрәсең, өйдә йокламаган булганнардыр, кинәт безнең янга ап-ак күлмәктән әти килеп чыкты. Аның сүзе кыска булды. Ул апайга:

— Өйгә кер!— диде дә, аны ишектән кертеп җибәреп, үзе баскыч төбенә килеп утырды.

VI

Берзаман белешү, сорашулар туктады, икеләнүләр бетте, апайны ярәштеләр.

Ярәшүен ярәштеләр, әмма булачак туй йортка куаныч белән килергә җыенмый.

Беркөнне төнлә йоклар алдыннан әти, ниндидер кыштырдаган тавыш ишетеп, бакчага кергән икән, апай йоклый торган кече якның тәрәзәсенә үрелгән бер карамчык күргән. Караса, Әхәт, ди. Әхәт, чуен багана шикелле, әтинең алдына килеп баскан:

— Менә монда ул минем! — дип, дөп-дөп күкрәгенә суккан.

— Юк шул, зимагур! — дигән әти.— Андагысы җил генә аның, бер атнадан фи-ит, оча да китә! Өйләним дисең икән, иң элек менә монда булырга кирәк!— Әти шап-шап иттереп кесәсенә сугып күрсәткән.— Йә, ни җаным белән мин баланы сиңа тоттырып чыгарыйм? Кая алып кайтырмын дип уйлыйсың? Нәрсә ашатырмын дип?

Әмма Әхәт әтигә бик каты әйткән:

— Белеп торыгыз! Үкенерсез дә, соң булыр! — дигән.

VIII

Менә туй көне дә килеп җитте.

Көтә торгач, югары очтан кыңгырау тавышлары ишетелә башлады. Китте каушау, йөгереш, кабаланыш. Җыелды капка төбенә халык. Мулла белән мәзин килеп җитте. Гөрләп торган өй эче шундук тын калды. Мулла абзый озак кына итеп никах укыды.

IX

Бу араларда мин апай янына менгәләп йөрдем. Ул тәрәзә каршысына утырган да, кечкенә киергесен тезенә куеп, кулъяулык чигә. Күршеләргә хәтле һәммәсе тынгысызланып, ни дә булса кайгыртып йөри. Тик апай гына тыныч күренә. Көлми, елмаймый. Әллә аны биргәннәр кияүгә, әллә бүтәнне.

Мин апай янына чүгәләп утырдым:

— Апай, син миңа үпкәлисеңме? Теге кичне мин кычкырганга әти чыкмаса, син... ниме... ябышып чыгар идеңме?

Апай башын чайкады.

— Бәлкем, чыккан да булыр идем. Бәлки, китмәгән дә булыр идем.

— Әтидән курыктыңмы?

— Юк, үзеннән түгел, каргышыннан. Аның рәнҗүе гомер буе баш түбәңдә кара болыттай асылынып торасы булса, дөньяларда ничек яшәрсең?

Ул арада яулыкның дүртенче почмагы да чәчәк ата башлаган иде инде. Никадәр тыелырга тырышсам да, яулыкның кемгә буласын сорамыйча түзә алмадым.

— Җизнигә инде бу, име? Монысын бигрәк тә матур итеп чиктең инде. Кадерен белсәләр ярый да бит!

— Матур итмичә... Аның егете дә бик чибәр бит.— Апай чигүеннән туктады. Бик ягымлы һәм үз итеп, зәңгәрсу-яшькелт күзләрен мөлдерәтеп, миңа карап тора башлады.— Кадерен дә бик белер шикелле күренеп тора. Аннары мин киткәч, ул егетнең яулык бирерлек бүтән апае да калмый.

Минем, тагын да кечкенәрәк чагымдагы шикелле, апайның муенына асылынасым, култык астына сыенасым, үзен дә иркәлисем килеп китте. Ләкин булмады, оялдым. Берни әйтә алмыйча, як-ягыма бәрелә-сугыла, ишегалдына чыгып йөгердем.

XI

Кияү төшәсе көнне кичкә таба Хәкимҗан белән мине яшь җизнине каршы алырга җибәрделәр. Йөгерә-йөгерә, басу капкасыннан чыгып, урман ягына күз салсак, пар ат җиккән тарантас тузан эченнән бәреп тә чыкты, килеп тә туктады.

Җизни кеше, минем абый кебек ук, мыексыз-нисез, яшьрәк кенә бер егет икән. Буйга-сынга да ярыйсы гына икән, төскә-биткә дә бик чибәр. Яратсын иде үзен апай, яратсын гына иде!

Караңгы төшәр-төшмәстә Гыйльми түти килеп керде!

— Илчегә үлем юк! Әхәт китә!— диде.

— Кая китә? Ничек?

— Кая китсә дә барыбер түгелмени? Туган авылы шулай мәсхәрә иткәч, чит-ят җирдән ни көтсен?!

Кичен караңгы төшкәч, барлык авыл егетләре Әхәт абыйны гармун белән уйнап-җырлап озата бардылар.

Өйдән өйгә

I

Мин күкеле сәгать сукканга уянып киттем. Бу ниткән сәгать? Кайда соң әле мин? Шундук исемә дә төште. Әнә шул сасы туладан кичә без чикмән тегә башладык. Шушы кырык-маса-кырык тула кисәгеннән чикмән оештырырга кирәк. Бөтенесен дә инә белән тегәсе, бөтенесе дә кулдан. Менә хәзер кара төнгә кадәр шул сасы тула белән җәфа чигә башларга кирәк. Каян исләренә төште дә нишләп мине тегүгә җибәрделәр соң әле?

Тегүгә чыгып китәр алдыннан, әти белән Сафа абый чәй янында минем турыда озак сөйләштеләр.

— Укытып булмый инде малайны, чама юк. Әнә бит, абыйсын укытып, ничә ел чиләндек! Барыбер солдатка алдылар. Ичмасам, монысы һөнәргә өйрәнсен.

— Кеше бәясе булыр,— ди Сафа абый.

«Кеше бәясе» дигәннәрен мин соңыннан гына белдем. Өйрәнчек малайга кыш буе эшләгән өчен йә бер ситсы күлмәк, йә бер ыштан бирәләр икән.

III

Авыл тегүчеләренең ул вакыттагы гадәтләре буенча, без өй борынча йөреп тегә идек. Иң кыены останың аз сүзлелеге иде. Көннәр буе авызыннан сүз чыкмый, ничек эшлисен күрсәтеп тә бирми. Үзең өйрән! Элекке заманда осталар, үзләренә көндәш булмасын өчен, һөнәрләренең серен ачарга яратмыйлар иде.

IV

Беренче көннәр бик авыр узды. Куллар күнекмәгән. Эшнең җаен тапмыйсың. Шулай да бер атна да узды, ике атна да, өченчесе дә. Мин акрынлап күнегә башладым. Менә озакламый бер ае бетә дә инде, аннан соң өч ай гына кала. Әти Сафа абыйдан беренче чәй янында ук сорар!

— Йә, берәр эш киләме бу малайның кулыннан? Әллә килмиме? Бик җебегән нәрсә булып чыкмадымы?

Юк! Минем һич кенә дә җебегән, уңмаган малай буласым килми. Юк! Мин андыйны ишетмәм!

Аннары болай да була иде.

Эшеңне кире сүттергәнгә гарьләнеп, үпкәләп утыруыңны беркем дә күрмәде шикелле. Син кемгә кирәк?

Ләкин озак та үтми, хуҗа апаның үз анаң шикелле үк рәхимле һәм шәфкатьле кеше булуына игътибар итә башлыйсың. Ул сиңа табын янында ризыкның иң тәмлесен куя. Ул сиңа урынны йомшак итеп җәя, юрганыңны япкан булып, үзеңә дә артык сиздермичә, анаң кулы шикелле йомшак куллары белән аркаңны сыпырып уза.

Андый яхшы күңелле, бала җанлы апалар һәммәсе дә бер кыяфәттәрәк иде. Йөзләре талчыккан, шулай да ягымлы, күзләре сине якын итеп, мәхәббәт белән көлемсерәп карыйлар.

XII

Ике-өч айдан мин бу чегән тормышына ияләшә төштем. Эшнең тәмен белә башладыммы, ничекме, хәзер инде тегү эше баштагы кебек үк өркетми иде. Ничек булса да булгандыр, тумыштан килгән оялчанлыгым хәзер ул кадәр үк үзәккә үтми башлаган иде.

Әмма юанычларның иң зурысы шул булды: мин яңадан китап дусларым белән серләшү җаен таптым. Яңа хуҗага керү белән, аз гына җай чыгуга, сәке өстенә менеп, китап шүрлегендә актарына торган булдым.

Тегүченең ял сәгатьләре бар. Бу — җомга вакыты һәм эңгер-меңгер чак. Шул минутлар килеп җитүгә, уймагын кәтүк кадагына элеп куя да тегүче, китә урамга чыгып.

Сафа абыйның күләгәсе күмелүгә, мин китабымны алып, кая да булса тәрәзә янына яки учак яктысына барып утырам. Шул минуттан башлап мин — дөньяда иң бәхетле кеше.

Минем күз алдыма бөтенләй яңа һәм мавыктыргыч бер тылсымлы дөнья килеп баса. Китапта язылган кызык вакыйгалар мине, дөя дигән өркәчле хайваннарга атландырып, ком чүлләренә яисә кеше аяк басмаган яшел урманнарга алып китә. Мин гомеремдә бер тапкыр да күрергә туры килмәгән зәңгәр диңгезләрдә йөзәм.

Китап җене кагылган малай

I

Ямаширмәгә икенче елны да бардык. Тагын шулай дүрт-биш ай өй борынча йөреп уздырдык. Ул кышны оста мине зуррак эшләргә дә кушкалый башлады.

Өченче елны мине тегүгә җибәрәсе итмәделәр. Нишләп? Ул хакта әйтүче булмады. Моның сәбәбен мин болай гына чамаладым. Ул елларны әти, еракка таба уйламый, бүгенгесен ничек үткәрәсен белмичә, бөлгенлектән иза чигә башлаган иде.

Хәер, тормыш як-якка каранырга да, балалык уеннары белән онытылырга да вакыт калдырмады. Ул кышны минем кулдан дилбегә төшмәде, ярты гомерем Арча юлында узды. Күрше Гайни абзый белән без, байга ялланып, урманнан Арчага утын ташыдык.

Безнең казанга атналар буе итле аш керми башлады. Җир аз булганлыктан, үз икмәгебез бервакытта да яңага җитми торган иде. Әти исә хәзер верстагында бераз кыштыр-мыштыр килгән була да, тыны бетеп, сәкегә ава.

Аның соңгы вакытта саулыгы гына түгел, күңеле дә сынган, гомер буе инанып йөргән изге иманы да җимерелеп төшкәнгә охшый иде.

II

Беркөнне кичкә таба кайчандыр Төркиягә алып китәм дип акча җыеп та, аны кайтарып бирмәүче карт хәзрәт каядыр узып барышлый кунарга безгә төште. Караңгы төшүгә карамастан, әти сарыкны суйды. Хәзрәтне ит белән дә сыйлады, һич караңгы чырай күрсәтмәде. Әмма иртәгесен озатканда, әти саубуллашырга кулын суздь.

— Хушыгыз, хәзрәт. Моннан соң очрашмавыбыз хәерлерәк булыр. Минем рияланасым килми,— диде.

Шуннан соң әти бик каты рәнҗеп, бик яман хәтере калган сыман йөри торган булды. Мөхәммәтҗан солдат белән сөйләшкәндә дә ул, өметсез кыяфәт белән кулын селтәп, әледән-әле:

— Җыенысы ялган! Бөтенесе алдакчы, оятсыз! — дип әйткәли иде.

Шул араларда булып узган тагын бер хурлыклы хәл картны аеруча какшатып җибәрде.

Безнең бер еллык имана акчасы түләнмәгән икән. Авылда андыйлар күбәеп киткәнлектән, староста Арчадан урәтник чакырткан. Анысы, җәмәгать җыены җыеп, түләмәүчеләрнең исемнәрен укырга тотынды.

III

Җыен таралды, староста белән дисәтникләр, ат җигеп, имана түләмәүчеләрнең йорт әйберләрен җыярга чыктылар. Безгә дә керделәр. Староста әтинең каршысына ук килеп басты.

— Исеңдәме? Мине бәреп төшермәкче булдың! — ди староста.— Йә кем аста калды да кем өскә чыкты? Кем яши белә дөньяда? Әнә, минем йортым гөрләп тора, эче тулы мал-туар, ашаганым синең төшеңә дә керми. Ә син, көне-төне чиләнеп, тамагыңны да туйдыра алмыйсың.

Моңарчы әтине берәүнең дә болай мыскыллаганы юк иде әле. Мондый әшәке сүзләргә ничек түзәр икән?

Ул, аягын киң җәеп, өйалды идәненә төбендә басып тора, муен тамырлары бүртенеп чыккан, артына яшергән йодрыгы сизелер-сизелмәс кенә калтырана иде.

— Аның каравы минем күңелем ак, эчемне кеше хакы тырнамый. Мин бит мир җирен попларга сатып эчмәдем!

Староста, як-ягына карангалап, тамагын кыргалады.

— Һаман да шул кәпрәю. «Мин кешегә баш имим дә сер бирмим!» Менә хәзер килеп каптың лабаса инде! Нишлисең хәзер? Йә тугыз сумны чыгарып саласың, йә самоварыңны алып чыгабыз!

— Самоварны бирмәм инде анысы, Йосыф! Акчам булу белән түләрмен. Аннары бик үк якын да килмә син миңа. Яшь чакларны онытмагансың бит? Минем бармак эзләре теге вакытны синең яңагыңда бер атна күпереп торды диделәр.

Теле белән рәнҗетсә дә, староста эшне зурга җибәрергә батырчылык итмәде. Әмма әти бу хәлне бик авыр кичерде.

IV

Безнең йортта тоташ күңелсезлек башланды. Егылам-егылам дип торган шушы чирле хуҗалыкны ничек кенә булса да аудармыйча сөйрәп бару хәзер әни өстендә калды. Миңа болар ниндидер вакытлы бер хәл булып кына тоела. Менә киләсе елда игеннәр дә уңар, мин дә, кыш буе Арчага утын ташып, күп кенә акча эшләрмен дә, без тернәкләнеп китәрбез, кеше шикелле, итле аш та пешерә башларбыз, яңа бишмәт, яңа күлмәкләр дә алырбыз... Тик алай булып чыкмады. Күңел канәгать түгел, ул, яңа гына канат чыгарган кош баласыдай, өзлексез талпына, нидер эзли, каядыр омтыла иде. Мин яңадан китапка ябыштым.

VIII

Карлар эреп, юллар өзелә башлаган вакыт иде, базарга атка атланып кына китәргә туры килде.

Пычрак дип тормаган, китапчы агай килгән иде, рәхмәт төшкере. Мин аның кызыл бәс тышлы туньн, озын гәүдәсен ерактан ук күрдем. Бүген нигәдер аның тирәсенә халык күп җыелган булып чыкты.

Хәнәфи абзыйда бүген китап сату кайгысы юк иде шикелле. Аның чырае шултикле кайгылы, әйтерсең минә хәзер елап җибәрер шикелле.

Әле генә килеп кушылган кайбер агайлар, үзара пышылдап, күршеләреннән сорашырга керештеләр:

— Кемне әйтә, кем үлгән?

Хәнәфи абзый бу пышылдауларны ишетеп төшендереп бирде:

— Габдулла Тукаев вафат, шигырьләр язучы. Изге җан иде ул безнең Габдуллабыз. Әйдәгез, җәмәгать, аның рухына бер дога кылыйк. Авыр туфрагы җиңел булсын!..

Китапчыны төрле яктан әйләндереп алган агайлар, дәррәү чүгәләп, ихлас күңелдән дога кылырга тотындылар. Агайлар ачык кабер янынннан киткәндәй, тирән кайгы баскан хәлдә, башларын иеп китә торалар, алар урынына бүтәннәре килә. Хәнәфи абзый, аларга да шул ук хәбәрне әйтеп, кайгысын белдерә.

IX

Мин юл буе иләс-миләс хәлдә кайттым. Мин узган авылларда кар эченә уелып төшкән тәбәнәк өйләрне дә шул ук хәсрәт баскан иде. Каенсардан узганда да миңа мәдрәсәдән бик моңлы булып, күңелләрне тетрәтеп әлеге «Туган тел» шигыре ишетелде.

Тора-бара минем китаплар белән мавыгуым бөтенләе белән Габдулла Тукайга күчте. Хәзер алны-ялны белмичә, тоташтан Тукай шигырьләрен укый башладым. Аның сүзләре нәкъ кирәк вакытында, күктән иңгән кебек, ничектер үзеннән-үзе күңелгә килеп керә башлады. Күбәләк яисә карлыгач күзгә чалындымы, аның шигырьләре искә төшә. Берәр агайның сука артыннан икегә бөгелеп атлавын күрдеңме, тагын аның шигырен хәтерлисең. Ул үзенең әлеге «Бетте көч, сынды кылыч. Шул булды эш...» дигән шигырен язганда да, мөгаен, безнең әти кебекләр булып та уйлагандыр. Япь-яшь башы белән нинди

вакытта нәрсә әйтәсен каян белә алган? Ничек ул боларның һәммәсен дә күреп, белеп бетергән? Ничек ул шигырьләрен бер үк вакытта үз авылына да, безнең Яңасалага да охшатып, нәкъ минем сүзләрем белән, күңелнең түренә үк кереп утырырдай итеп яза алган?

XII

Иртән иртүк, әтинең иске алмазын алып, кечкенәрәк пыяла кисәкләре тутырган әрҗәне култык астына элдем дә кәсепкә чыгып киттем.

Бер йортка, ике, өч йортка кердем. Эшем ярыйсы гына бара. Кесәдә акча да чылтырый башлады. Шул урамда Сәлимәләргә дә бер өлге куеп чыгарга кирәк иде. Бәлки, үзе дә өйдәдер?

Безнең әлеге Вәли абый, узган ел сабан урагына төшүгә, яшьләр өмәсе ясады. Мин башта ук иң кырыйда Сәлимә янында булып чыктым. Бәлки, аның биленә төшеп җиткән кара-коңгырт чәч толымнары күзгә чалынгандыр? Әллә иягенә таба очлаеп килгән матур коңгырт битенә ялгыш кына ябышып калган мәк орлыклары кебек вак кына сипкелләре сөйкемле күрендеме? Ул ягын тикшереп торган юк. Сәлимә ура, мин урам. Бер үк вакытта учмабыз тула, бер үк вакытта, селтәнеп, аны артка салабыз, бер үк вакытта бер-беребезгә карашып, елмаешып алабыз. Безнең икебезгә дә бик күңелле, бик рәхәт.

Кичен кайтырга җыенганда, мин аны, кулыннан кысып, арбага, үз яныма тартып алдым. Ындыр артына кайтып җитәрәк, минем иңбашыма иелеп:

— Син зерә дә әйбәт малай,— дип пышылдады. Тагын бераз чабата башына карап кайтты да:— Матур да...— дип өстәде.

Аннан соң без Сәлимә белән ничә тапкыр аулак өйләрдә, су буйларында, җиләк җыйган чакларда очраштык. Ничә мәртәбә хатлар алыштык.

Өйгә кергәч, Сәлимә, кечкенә яктан чыгып, сизелер-сизелмәс кенә миңа баш иде:

— Нихәлләр әле, Гумәр?— диде.

Анасы, аңа кырыс кына итеп:

— Бар, эшеңдә бул! — дигәч, Сәлимә, нәүмизләнеп, теләр-теләмәс кенә яңадан кече якка кереп китте.

Мин үз эшемдә булдым. Пыяланы сәке тактасына салдым. Алмазны күкрәк кесәсеннән чыгарып, бик кадерләп төргән ак яулыгымнан алдым да пыяланы кирәк урыныннан чыжылдатып кына сыздым. Сәлимәне шаккатырып, «келт» иттереп кенә

сындырып алдым да үзенең урынына иңдереп, замазка белән сылап та куйдым.

— Менә, рәхәтләнегез, апай. Өегез җылы булсын, көн буе кояшлар төшеп торсын!— дидем.

Бу апайдан котылганнан соң, тау аслатып кына күрше урыс авылына сыпырттым. Анда боз бик каты эләккән дә тәрәзәләр күп ватылган икән. Әти каршысына кайтып кергәндә, минем кесәдә, элек җыелган бакырлардан тыш, бер-ике кәгазь дә кыштырдый иде.

XIV

Шулай нәрсәдер эзләнеп, тынгысыз җанга азык таба алмыйча иләс-миләсрәк йөргән көннәрдә Арча юлындагы чардуган янын-нан узарга туры килде. Каенсарның бер агае кышкы буранда адашкан да үзләренең зиратларына кайтып җитәр-җитмәс кенә кырда өшеп үлгән. Электән килгән гадәт буенча, аны шул үлгән урынында күмгәннәр дә кабере өстенә чардуган корганнар.

Бу хәлне мин элек үк ишеткән идем. Әмма бу фаҗига мине нигәдер менә хәзер дулкынландыра башлады. Беркөнне шушы хакта хикәя сымак бернәрсә яздым. Ул язмада әлеге агайның Арча базарыннан кайтканда адашуы, кычкыра-кычкыра, бата-чума юл эзләве, ахыр чиктә, арып-талып чанасына килеп утыр-гач, тәнендә рәхәт бер җылы сизә башлавы, бу вакытта авыл кешеләренең манара тәрәзәсеннән фонарь белән яктыртулары, хатыны белән балаларының әтиләрен елый-елый көтүләре шактый ук тәфсилләп, булдыра алган кадәр кызганычрак итеп язылган иде.

Мин аны башта әнигә укып күрсәттем. Ул борынын тартка-лап елап алды:

— И бичаракай, үзе дә бик кызганыч, хатыны белән балала-ры да,— диде.

Бер-ике көн үткәч, эштән кайтуга, атны капкадан гына кер-теп җибәрдем дә Вәли абыйларга төшеп киттем. Әлеге нәрсәне аңа да укытасым килә иде. Каян беләсең? Бәлки, ул берәр нәрсә төшендереп бирер.

Әмма дәү абый, ул турыда сүз кузгатуга, мине орышып чыгарды:

— Нинди малай син, әй! Шундый чакта ниндидер әкият күтә-реп килгән. Йөгер хәзер үк өегезгә!

Мин кайтып җиткәндә, лапаста, тау кадәр күперең, безнең бердәнбер сыерыбыз үлеп ята иде.

Башлана башлады

I

Сыер да үлеп киткәннән соң, безнең хәл авырайды. Шуннан соң әти бик сыкранып, җәберләнеп булса да, келәтне Арчаның Иван исемле сатучысына азык-төлек кибете ачарга бирмәкче булды. Кибетче үзе бала-чагасы белән безнең югары өйдә яшисе дип сөйләшкәннәр иде.

Келәттә кибет ачыласын алдан ук белсәм дә, хәзер менә ишегалдындагы сары башлы ике малайның әле җимеш бакчасына кереп, әле яшелчә түтәлләрен таптап йөрүләрен күргәч, бик күңелсез булып китте.

Ике ел чамасымы, күпме матапып, ара-тирә итәк астыннан тегесе-монысы белән сату иткәләсә дә, Иванга барыбер баеп китәргә насыйп булмады. Күрәсең, Яңасаланың суырыр мае калмаган идедер.

II

Көн урталарында рәхимсез җил исәргә тотынды. Басуда идек. Тоташ тузан эченнән авылга чаптык.

Менә урман өстендәге аклы-каралы калын болытлар үзара болганырга, кайнашырга тотындылар. Бик яман давыл кузгалды. Бөтен тирә-якны томалап, түбәләргә чатыр да чотыр таш кисәкләре сипкән тавыш чыгарып, эреле-ваклы боз яварга тотынды. Озак та үтмәде, ялт итеп тагын кояш чыкты.

Урамдагы гөрләвекләр тынарга да өлгермәде, кайсы җәяү, кайсы атка атланып, басуларга ашыктылар.

Безнең игеннәрнең байтак өлеше көтү таптап узганга охшап изелеп, чәбәләнеп беткән иде.

Иске бетеп, яңа өлгергәнче, ел саен авылны соранучы баса иде. Бу елны алар бигрәк тә күп йөрделәр. Әни аларның берсен дә буш кул белән чыгармады.

— Мәгез, сынык, кечкенә дип гаеп итмәгез. Сезнең өлешегезне әнә Ходай үзе алды.

III

Әмма бәланең иң зурысы ул түгел икән әле. Анысы — иң куркынычы, бөтендөньяны утка салганы — атка атланып, волостьтан ияреп кайтты:

— Герман сугып башлаган!

Безнең эти, үзен үзе кая куярга белмичә, ишегалдында арлы-бирле сугылып йөрде дә, капкадан Мөхәммәтҗан җизни күренгәч, туктап бот чабып куйды:

— Хәмзәне күрми калабыз. Ул хезмәт иткән җиреннән генә сугышка китәр. Вәли китә, ике кияү китә. Бөтен авыл баласы ятим кала. Кемгә төшәр аларның күз яше, ә?

Аргы якның бер төркем кызмача егетләре, җырлый-җырлый, Фазулланың тау астындагы кечкенә өе янына килеп чыктылар.

— Әй Фазулла! Әйдә, гармун уйнап, урам әйләндер әле!

— Күрәсез ич, Фазулла урыныннан да тора алмый!— дидем.

— Ул авырый гына әле, ә без менә үләргә барабыз. Чык, давай!

Бусагада кәфен төсле ак чырае, бөкрәя төшкән озын-ябык гәүдәсе белән муенына ак сөлге ураган Фазулла күренде. Егетләр аның аркасыннан кагарга тотындылар.

— Менә, маладис, күптән шулай кирәк! Син дә үләсе, Фазулла туган, без дә үләсе! Давай, агай-эне, бер әйттереп кал әле.

Фазулланың зәңгәрсу төскә кергән озын бармаклары гармун телләре өстендә уйнаклый башлауга, бөкресе языла төшеп, гәүдәсе тураеп киткән кебек күренде. Ул йөрәкне сыкрата торган кайгы көйләре уйнарга тотынды. Егетләр:

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар!—

дип сузып җибәрделәр.

Ул көнне кичен капка төпләрендә, тыкрыклардагы өянке асларында егетләр соңгы мәртәбә сөйгән ярлары белән хушлаштылар.

IV

Ирләр артыннан ук сугышка байтак кына атларны да кудылар. Ир-ат юклыгы кайбер хуҗалыкларны беренче елда ук какшатып ташлады. Сугышның икенче елында ук әйбер бәяләре өскә сикерде. Керосин бөтенләй бетте.

Кайбер солдат хатыннарына беренче елны ук кара пичәтле кәҗүнни кәгазь килде.

V

Арча Иванның келәтебездә кибет ачуы хәлебезне җиңеләйтмәде. Иван, кибетенең калдык-постыгын Чистай ягыннан килгән бер исеректә сатып, озакламый чыгып тайды.

Әни белән без, үзебезнең арыш урагын бераз җиңеләйткәч, чәй-шикәргә булса да ярап куяр дип, күршедәге Цызгановка, көнлекләп, уракка йөри башладык.

VI

Озак та үтмәде, безгә соңгарак калган бер төркем яшьләр килеп кушылды. Алар арасында Сәлимәне күрүгә, куанудан мин кая басканымны белми башладым. Менә бәхет! Ничә көннән бирле очрашканыбыз юк иде бит!

Ялга туктауга, безнең ише яшь-җилбәзәк якындагы Арпа елгасына, битләрне юып, су эчәргә йөгерештек. Минем белән янәшә торып, битен чылатканда Сәлимә, чигүле җиңсәсеннән алып, миңа кәгазьгә төргән бер кечкенә әйбер сузды.

Ихтимал, ул чагында миннән дә бәхетлерәк бер генә кеше дә юк идедер. Кечкенә кәгазьдән минем исемем язылган көмеш йөзек килеп чыкты. Сәлимә үз кулы белән вак кына итеп җыр да язган:

Мамык пирчәткә эчендә
Көмеш балдак шәүләсе;
Күзем йомсам, күз алдымда
Син җаныйның гәүдәсе.

Күк капусыннан нилэр күренә

I

Сугышка һәркем үзенчә көйләнде. Элек-электән түрәләрне майлап-җайлап, җиңел көн итәргә күнеккән чибәр тормышлы кешеләр хәзер дә җаен таптылар. Андый әйләнеч юлларны белмичә, туры юлдан гына йөрүче гадел кешеләр, берсе-бер калмыйча, баштан ук сугышка киттеләр.

Мине сугышның беренче елларыннан ук солдатларга хат язарга дәшкәли башладылар. Болай хат язарга йөрүләр минем үземә дә ошап китте. Кеше яраткач, нигә язмаска? «Гумәр, җаным! Сиңа гына әйтәм!» — дип, кемнәр генә миңа иң газиз күңел серләрен әйтеп яздырмады!

II

Җәй башындарак, үләннәр чәчәк аткан вакытта, Фазулла да чакыртты. Ул да берәрсенә хат яздырамы дисәм, төнлә белән урманга алып баруымны үтенмәкче икән.

— Барабыз да, син мине абага янында калдырасың,— ди.— Абага чәчәк атканда теләк телим, чиремнән котылыйм дип. Тик анда ялгыз гына утырырга кирәк.

Фазулланың бу нияте мине дә кызыктыра башлады. Ләкин төнге сәгать уникедә кап-караңгы урманга курыкмыйча кем бара? Уйладым-уйладым да тәвәккәлләргә булдым. Кайсы малайның андыйны күргәне бар? Чын әкият инде бу, серле, тылсымлы...

IV

Фазулланың үтенечен тыңламыйча булмады. Кадер кичне, ястү вакыты җиту белән, мин аны, җитәкләп, мәчет янына алып мендем. Аның тыны бетә, дүрт-биш адым атлаган саен туктап ял итә иде.

Безнең шикелле күк капусы ачылганны күрергә килүчеләр арасында шул сылтау белән мәчет янында очрашып калырга җыелучы яшь-җилбәзәк тә күп кенә иде.

Фазулла юл буе калтыранып, авыз эченнән нидер укынып менде. Бүгенге кичне нилектән шулай түземсезләнеп көтүен ул теге көнне үк сөйләгән иде. Аның өмете һич тә зурдан түгел икән. Аңа хәзер бераз аякка басып, кеше кыяфәтенә керергә генә кирәк. Бары шул гына! Аякка басып аумыйча тора алса, аңа шул җитә. Шул көнне үк ул сугышка чыгып китәчәк. Ничек кенә булса да. Анда үлсәң, ичмасам, кара пичәтле булса да кәгазь җибәрәләр, кеше исәбенә кереп каласың. Әмма Фазулланың иң якты өмете, кыяр-кыймас кына күз алдына китергән иң матур хыялы, яраланып, Мәскәү больницасына эләгү икән. Әгәр Мәскәүнең иң зур, иң чын докторына эләксәң, тазартмаслар дип уйлыйсыңмы? Булдыралар, валлаһи, тазарталар! Мәскәү ич ул, Мәскәү!

Шушы татлы хыялларына Фазулла мине дә ышандыра язды. Мин инде, үземне бөтенләй онытып, күк капусы ачылганда Фазулла өчен теләк теләргә җыенган идем. Ул үзе искә төшерде, колак төбемдә үзе пышылдады:

— Син дә буш калма, яме? Өстең-башың бик тузган. Кышка яңа бишмәт сора. Кайтарма якалыны! Белмәссең... Фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килсә...

Менә караңгылык куерганнан-куера барды. Мәчет әйләнәсендәге карчыклар, догаларын укып, күккә текәлделәр. Шулвакыт күкнең иң өсте, нәкъ көймәсе, кинәт кенә актырып киткән сыман күренде. Шундук, кайсы тезләнеп, кайсы чүгәләп, мыдыр-мыдыр догалар укырга керештеләр.

Белмим, Фазулла ничә генә сүз әйтеп өлгергәндер, әлеге төркемнән куркынып һәм ашыгып:

— Ябыла, ябыла! — дигән тавыш ишетелде.

Күк йөзендә, чыннан да, нидер булды, ахрысы, ул нигәдер караңгыланыбрак киткән сыман күренде.

Фазулла, ыңгырашып, җиргә капланды.

— Нәстә инде бу? Ник шултикле кабалана! Авызымны ачып ике-өч сүз әйтергә өлгермәдем бит! — диде.

Шулай диде дә егылды. Без иптәш малайлар белән Фазулланы көчкә генә өенә кайтарып җиткердек.

Давылдан соң

I

Вәли абыйның кайтасы күптән үк билгеле булса да, ул һич көтмәгәндә кайтып төште. Аның, кулын өздереп, госпитальдә ята башлавына, шәт, биш-алты ай булгандыр.

Вәли абыйны да әти көчләп өйләндергән. Абыйның Кибәхуҗада сөйгән кызы бар икән. Аңа сөйгәнен түгел, шуның апасын алып биргәннәр. Җиңги бик яраткан, абый яратмаган. Сугышка киткәнче кичләрен абый иптәшләренә үзе үк яшермичә сөйли торган иде: «Сөймәдем булгач сөймәдем. Аңа орынсам, каз тәне чыга торган иде».

Бик озак шулай азапланып, ахыр чиктә авырый башлаганнан соң, җиңгине аталары алып киткәннәр. Шуннан соң абый, үзе табып, хәзерге Миңзифа җиңгигә өйләнгән.

Абый кайтасы көнне иртәнге чәйне эчеп утырганда, Миңзифа җиңги безгә менгән иде. Әтидән тел яшергәнлектән, әйтәсе сүзен, почмак якка чыгып, әни колагына пышылдарга тотынды. Әни әтигә әйтеп торды. Тик ул куанычлы хәбәр алып менмәгән икән. Иртүк староста белән дисәтник кергәннәр. Ике сарыгының берсен йә кәҗәсен казнага сорыйлар икән. Балаларның аякларына итеге, кулларына бияләе тузган. Берсен алсалар, ул бер сарык белән генә нишләрсең? Кәҗәне бирсәң, балалар сөтсез кала. Җиңги киңәш сорап менгән икән.

— Җитәр, балалар хакына керергә ярамас, — диде әти. — Әле дә кара җәяү калып барабыз. Ул нинди закун? Солдатны да бир, патшаның бөтен чирүен дә без туйдыр. Биргәне җиткән! Бернәрсә бирәсе булма, сыңар тавык та!

IV

Хәмзә абый, яраланып, ике-өч айга ялга кайткан иде дә, әти аны, вакыты җиткәч, ат белән Казанга илтте. Әти шуннан нишләптер бик йомшап, күңеле нечкәреп кайтты. Ашамады, эчмәде, стенага борылып ятты да тын гына еларга тотынды.

Әни, моңа бик борчылып, сәбәбен сорашкан иде, әти яшермәде:

— Хәмзәне актык күрүем бит. Бүтән күрүләр насыйп түгел бит инде,— диде.

Чәй янында абый телгә алынса да, хаты килгәндә дә әти еламыйча түзә алмый башлады.

Беркайчан да күз яше күрсәтмәгән каты холыклы кешенең, үзен үзе тыя алмыйча, әледән-әле елап җибәрүе бик кызгандыра иде. Күрәсең, ул абыйны аеруча нык яраткандыр.

Менә бермәлне кинәт башында базарга бару уе кузгалды. Элегрәк атна саен барыла торган Арча базарына болай, бәйрәмгә җыенган сыман хәстәрләнүе берникадәр сәеррәк тоелды. Әни, күрәсең, аның кылларын тартып карамакчы булгандыр:

— Хәзер базарда бернәрсә дә сатмыйлар бит! — дип әйтеп карады.

Әти аңа бераз көттеребрәк җавап бирде:

— Тәрәзә ясарга вәгъдә итеп, акчасын алдан алган кешеләрем бар. Өстемдә кеше хакы калдырасым килми. Кулыма акча төшкәндә кайтарырга булдым. Каян беләсең...

Әти төнлә белән берничә тапкыр ишегалдына чыгып, һаваны чамалап, атның ашарына өстәп керде. Таң беленеп яктыра башлаганда, төньякның шыксыз җиле, агач башларын дуылдатып, койма ярыкларында сызгыра башлаган иде. Әти, бик озак уһылдап, икеләнеп ятканнан соң, атны җигәргә кушты. Үзе бишмәтен кигән килеш сәкегә ятып торды.

Шулай ята торгач, ул, кемгәдер рәнҗегән тавыш белән, авыр ыңгырашып:

— Булмый... Тугар атны,— диде.

Шул ятуыннан тора алмады.

Төрле үлән чәйләре дә эчереп карадылар, сөлек тә салдылар. Ләкин әти тазармады. Аның хәле көннән-көн начарлана барды.

Шундый көннәрнең берендә әни мине өйалдына чакырып кертте.

— Атаң чакыра,— диде.— Тыңламаган чакларың булды. Бар, бәхиллеген ал.

Янына барып тезләндем, кулларымны аңа суздым. Ул кулын минем беләгемә куйды.

Мин, күз яшенә буылып, шулай да яшемне күрсәтмәскә тырышып, әни искәрткәннәрне әйтә башладым:

— Берәр вакытны рәнҗеткән булсам...— Әти мине бүлдерде:

— Ярар... Үткән эшкә салават. Балалык белән... Менә мин әйткәнне тыңла, язып ал.

Мин тиз генә кәгазь-каләм алып килдем. Әти, бераз тын алганнан соң, өзеп-өзеп әйтеп торды:

— Бирәчәкләремне үз кулым белән тапшыра алмый калдым... Алар синең өскә төшә. Син бу йортта бердәнбер ир заты. Барысын да түлә. Болай чамаң җитмәсә, сарыкларны сат, шулай да түләмичә калма. Васыятем шундый.

Аннары ул, кипкән иреннәрен ялаштырып, кыенлык белән генә исенә төшерә-төшерә, бирәчәге булган кешеләрнең исемнәрен, авылларын яздырды.

Бүтәннәр белән чыгып барганда, мине яңадан үз янына чакырып алды.

— Абыең кайткач... уйлашырсыз... кем төп йортта каласын. Абыеңа язмыйчарак тор... минем хакта. Башта «авырыбрак тора» дип яз. Икенче хатыңда «бик үк өметле түгел» диярсең. Ике-өч айдан соң гына ни дип... Ишеттеңме?

Минем күзләргә яшь тулды. Чак кына кычкырып елап җибәрми калдым.

— Ишеттем...

VI

Ярты авылны авыр кайгы басты. Мәет чыккан йорт... Хәзер әтәчләр дә элекке кебек шатланып кычкырмый, тавыклар да бөтен ишегалдын тутырып җырлап йөрмиләр.

Җир, хөррият!

I

Югары очтан кайтып килгәндә, Сәлимәләр ишегалдыннан кызлар тамак кырганы ишетелде. Минем йөрәк дуылдап алды. Тәгаен миңа инде бу, миңа! Шунда койма өстеннән җилкәмә бер йомарлам кар килеп төште. Инде дә кермәсәң!

Анасы Каенсарга киткән, боларда аулак өй икән. Сәлимә белән аларга туган тиешле Сәхипҗамал сүс түяләр икән. Сәлимә миңа шундый яратып карады, шуның рәхәтеннән мин аның яз кояшында коңгырт төс иңә башлаган сөйкемле йөзен-

нән күземне ала алмыйча сихерләнеп калдым. Сәлимә оялчанланып башын иде.

Яшьлекнең бу исерткеч тойгысына бирелеп, сүзсез генә карашып торганда, безне шул ук Сәхипҗамал уятты.

— Әллә бер-берегезне күрүгә, һушыгыз китеп, телегезне йоттыгыз инде! — дип шаркылдап көлде дә икебезне ике якка төртеп җибәрде.— Йә, егет кыйпылчыгы, әйт тизрәк! Сугыш бетәме? Ярый ла сез пар килгәнсез. Менә миңа дигән кияү кайчан кайта? Гәҗит укыйсың бит.

Без кызып сөйләшкәндә, Сәлимә, сагаеп, нидер тыңлый башлаган иде. Урамда ниндидер сәер тавышлар ишетеп, һәммәбез дә капка төбенә атылдык.

II

Чыксак, урамда — мәхшәр! Түбән очтан, урам тутырып, әллә никадәр халык менеп килә. Керәшен ягының Кируш үзе уйнап, үзе биеп килде-килде дә ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Микулайны бәргәннәр! Дөмектергәннәр! Әйттер-сиптер, юк патша!

Төркемдәге кешеләр, кайнашып, төрлечә аваз салдылар:

— Патша төшкән! Слабода!

— Хөррият! Патша юк! Әй, чыгыгыз урамга, ишетегез! Патшаны төшергәннәр!

Оялчанрак солдаткалар, бер-берсенең капка төпләренә җыйналышып, куанычларын уртаклашырга тотындылар.

— Һай, шул слабода дигәне тизрәк сугышны да бетерсәче!

Минем Сәхипҗамал белән Сәлимәне аеруча куандырасым килә иде.

— Болай булгач, сезгә дә җир бирәләр инде, әйе бит? Йә, бәлкем, кызлар мәктәбе ачарга да рөхсәт итәрләр.

Сәлимә:

— Күлмәк тегәргә ситсы белән бишмәтлек тә булыр бит?— диде, үзе ямаулы бишмәтенә күз салып кызарды.

VII

Шул ук көннәрдә Әхәт абый кайтып төште. Теге вакытта чыгып китүеннән ул кайдадыр озак кына югалып торган иде. Тора-бара сугышка барып эләккән икән. Әхәт абый күп сөйләшергә яратмый иде. Ул бик кыска тотты:

— Алпавытларын да чурту, министрларын да. Җирне үзебезгә алырга! Чын рвалутсия менә шул буласы инде.

VIII

Иртәгесен яктырыр-яктырмаста бөтен авыл аякка баскан иде. Иптәшләр белән без дә, аннан-моннан гына тамакка капкалап, халык җыела башлаган урынга — ындыр артына чыктык. Яраланып кайткан солдатлар, яшүсмерләр дә җыелган. Эшкә ярардай картлар кайсы тимер сәнәк күтәргән, кайсы билбавына балта кыстырган. Ара-тирә иңнәренә куян мылтыгы элгән кешеләр дә күренгәли. Күрше урыс авылының башында үзенең җимеш бакчалары, ак һәм кызыл калай түбәле биек каралтылары, зур ап-ак тәрәзәләре белән масаеп утырган алпавыт биләмәсенә бераз шигәебрәк карыйлар.

Халык кинәт җил килеп бәргән урман кебек гүләп куйды. Сәнәкләр, күсәкләр айкалып китте. Бөтен халык: яше-карты, киң бер агым булып, уҗым басуы өстеннән туп-туры алпавыт йортына таба кузгалды. Кырау төшкән уҗым өстендә ямьяшел булып яңа киң юл сузылды.

Алпавытның ригасы[1] ягына күз салсак, Әхәт абый белән аның иптәшләре андагы кечерәк кенә агач өйне сүтеп, арбаларга төяп яталар.

Кемнәрдер Цызгановның ат көтүеннән атлар куып кайтып килә. Алпавытның бик шәп имән урманы барын да онытмаганнар икән. Халык ашыга төште:

— Әйдә тизрәк! Хөррият урманын да кисәсе бар бит әле!

IX

Без иң башланган вакытына өлгерә алмадык. Ишегалдында ыгы-зыгы, шау-шу, бөтен тирә-як гүләп тора. Кайсылары дөбершатыр китереп йозак вата, амбар ишекләрен каера, берәүләр лапастан арбалар, яхшы тарантаслар, сабаннар тартып чыга.

Ишегалдында кемдер урысча:

— Разобрать!— дип кычкырып җибәрде. Шунда Әхәт, кулын болгый-болгый, ишегалдындагы халыкка кычкыра иде:

— Сүтәргә, диләр, сүтәргә! Эзе дә калмасын!

Әхәт артыннан мин дә өй түбәсенә менеп киттем. Ничектер, бакча ягына күзем төште. Бер читтәрәк кызлар арасында, безнең бу эшкә шаккатып, Сәлимә карап тора икән. Мин ак калайны аның саен җилкенебрәк каерам, түбә калае аның саен аска күбрәк оча.

---

[1] Рига — өсте ябулы зур эвен.

Көн кичкә авышкач, арып, ачыгып кайтырга чыктык. Алпавыт йорты урынында нигез ташлары өелеп калган да ишегалдында ватык йорт җиһазлары гына аунап ята иде.

X

Әхәт абыйның күп еллар буш торып, әрем белән алабута баскан йорт урынында күршеләре белән туганнары өмә ясап, өй җиткереп яталар иде. Бер кырыйдарак киртәгә бәйләгән зур гына алпавыт аты печән көйшәп тора, тагын да читтәрәк ике-өч баш кара сарык күренә.

Әмма мине куандырганы ул гына да түгел иде. Моннан өч-дүрт көн генә элек Әхәт абый күзле-башлы булды. Шушы яңа йортның бикәсе, шундый батыр егетнең бичәсе булуына куануыннан Сәрвәрнең дә кулы кулга йокмый, аның яшь, сылу гәүдәсе уйнаклап кына тора иде. Ул мине сокландырды да, куандырды да.

Мин алып кайткан шыксыз дәү тай дугасы белән ниндидер зур сурәттән бушаган алтын бизәкле кызыл рамны күргәч, әни, көлемсерәп, башын чайкады.

— И бала, бала...

Менә, кояш баеп, шәфәкъ нурлары да сүнде. Аның урынына кояш баешыннан, җир белән күк арасында эленеп торган киң бер нур булып, Казан өстендәге кичке яктылык балкый башлады.

Без, бер-беребезнең иңнәренә таянып, әнә шул нур балкыган якка карап барабыз. Яңа тормышның ничек буласын без әле күз алдына да китерә алмыйбыз алуын. Безнең өс-башыбызның да рәте-юне юк, иске-москы гына. Тамагыбызның да тук чагыннан ач вакыты күбрәк. Шулай да хәзер безгә бик рәхәт. Әнә шул еракта балкыган якты нур безнең киләчәгебезгәниләрдер вәгъдә итә, ниләргәдер ымсындырып, өмет чаткылары белән күңелләребезне җылытып тора иде.

Аккош күле — Казан, 1965—1968 еллар

«Туган ягым — яшел бишек» повестена анализ ясау юллары

Анализны эш планы төзүдән башларга мөмкин. Мәсәлән: 1. Анализ алымы. 2. Метафора өлеше. 3. Кабатланган вакыйгаларны аерым-аерым өйрәнү. 4. Повесть эчендәге башка бәйләнешләр тудырган эчтәлек.

Планны анализ нәтиҗәсеннән соң, эчтәлегеннән чыгып та төзергә мөмкин.

Мәсәлән:

1. Гумәрнең балачак өмете.

2. Халыкның яшәү көче буларак өмет.

3. Повесть ахырында тасвирланган бәхеткә (өметнең тормышка ашуына) бәя.

4. Повестьның әдәби чор тематикасы һәм проблемасы белән бәйләнеше.

Әсәргә анализ ясар алдыннан, безгә планның — беренчесе, ә бу әсәргә бәйләнешле инша язганда, икенчесе кирәк булачак.

Истә калдырыйк.

Аерым әсәргә багышланган иншаның эчтәлеге анализ нәтиҗәләреннән һәм шул нәтиҗәләрне исбатлаучы анализ алымнарыннан гыйбарәт.

Хәзергә безгә планның беренчесе кирәк.

Планда күрсәтелгәнчә, башлап анализның уңайлырак юлын сайлыйбыз. Анализны әсәр исеменең мәгънәсен табудан да, метафора-вакыйга, фокус эзләүдән дә, охшаш вакыйгаларны табып гомумиләштерүдән дә башларга мөмкин. Ләкин кайсыннан гына башласак та, әсәрнең жанр үзенчәлеген ачыклап китәргә тиеш булабыз. Шулай итик тә.

Повесть белән танышкач, анда, И. Салаховның «Тайгак кичү» әсәрендәге кебек, истәлек-хроника өлеше барлыгын беләбез. Аны әдипнең бала чагы турындагы хатирәләре дип аерып куябыз. Бу өлештә укучылар үткән замандагы авыл тормышы белән таныша. Яшь буынга бабаларыбызның гореф-гадәтләре, тормыш итүләре белән танышу гыйбрәтле һәм кызыклы. Бу урыннар — әсәрнең информация өлеше.

Ләкин әсәрнең информация өлешендә дә әдипнең бала чагыннан күңелендә сакланып килгән шатлыгы, хәсрәте, үкенече, горурлыгы, хисләре һәм шул хисләр уянуыннан туган бөтенләй башка, олы яшьтәге әдип белән очрашабыз.

Әдәби әсәр эчтәлеге катлаулы. Күрәсез, нинди дер вакыйгалар тудырган хисләр берзаман үзләре вакыйгага әйләнәләр һәм башка хисләр туууына сәбәп булалар.

Әмма әсәр эчтәлеген укучы үзе дә баета бит әле. Укучы әсәрдә язылган вакыйгаларны кайчандыр үзе күргән һәм үзенә нык тәэсир иткән вакыйгаларга охшата. Хәтерендә сакланган хисләрен уята. Шул рәвешле, әсәрдәге автор хисләрен үз

хисләре белән баета. Алай гына да түгел. Укучы әсәрдәге Гумәр язмышын да күңеленә якын ала, аның өчен дә борчыла, хәтта әдипнең бик күптән башыннан кичкән вакыйгаларны бүген күргәндәй тәфсилләп яза алуына да соклана.

Без әсәрдәге лирик геройның хис сәбәпләрен табарга тиеш булабыз. Кичереш дәрәҗәсен беләбез. Аннары үзебездә туган хис сәбәпләрен ачыклыйбыз.

Повестьның хис эчтәлеге шул рәвешле табыла.

Күрәсез, әсәр эчтәлеге, аны кем укуына карап, күп мәгънәгә ия.

«Туган ягым — яшел бишек» повестеның хатирә өлешен өйрәндек. Хәзер төзелешен, ягъни авторның укучысы белән сөйләшүен (диалогын) табыйк.

Төзелешен табу өчен, без әсәрне өлешләргә бүлә идек. Бу юлы да шулай итик.

Повесть башындагы колын югалу вакыйгасы башка вакыйгалардан читтәрәк торуы белән аерылып тора. Бу вакыйганы исегезгә төшерегез. Аңа «Өмет» дип исем бирә алабыз. Аннан соң әсәрдә, Гумәрнең үзе кебек, ялган өмет белән яшәүче башка кешеләр язмышын эзлибез. Ул язмышларны да вакыйгалар дип атыйбыз. Бу вакыйгалар кешеләрнең үзләренә өмет уйлап чыгарып, шул өметкә ышанып яшәүләре турында дибез.

Хәзер повестьны, колын вакыйгасы һәм халык язмышы дип, икегә бүлә алабыз. Аларның янәшәлеге тудырган өстәмә эчтәлекне табасы гына кала. Әсәрнең фәлсәфи эчтәлеге шул бәйләнеш-янәшәлектә дә инде.

Биремнәр һәм сораулар

1. Гумәр хисләренең сәбәпләрен табыгыз. Бертөсле хис сәбәпләрен гомумиләштерегез.

2. Повесть авторы Гомәр Бәшировка персонажы Гумәр хисләре ничек тәэсир итә?

3. Повестьны укыганда сезгә кайсы вакыйгалар ошады?

4. Колын вакыйгасы, метафора-вакыйга буларак, үзенә охшаган башка вакыйгаларның эчтәлеген тулыландыра. Шуны исбат итегез.

5. Охшаш вакыйгаларны табыгыз. Аларны без кабатлану дип тә бәяли алабыз. Охшаш вакыйгаларда кабатланган эчтәлектән чыгып, автор әйтәсе килгән фикерне сөйләгез.

6. Повесть исемендәге «бишек» сүзе «Бәбде бәҗвин» бүлегенең X бүлекчәсендә кабатлана. Габдулла Тукайның бу сүзгә салган эчтәлеге, димәк, повесть исемен ачыклап килә. Ничек ачыклый? Әллә бу охшашлык-кабатлану очраклы гына бер хәлме?

7. Гомәр Бәширов әсәрен персонажы исеменнән сөйләп килә-килә дә соңгы битендә кинәт үз авызыннан сөйли башлый. Шундый чакта интонация үзгәрде диләр.

Интонация әсәрнең мөһим урынында, авторның үз сүзен ачыграк итеп әйтәсе килгән урында үзгәрә.

Авторның бәхет турындагы сүзләре белән вакыйгаларда кабатланган өмет темасы арасында нинди дә булса бәйләнеш табып буламы?

8. Авторның бәхет турында пафос белән әйткән сүзләренә үз бәягезне бирегез.

9. Гумәрнең әтисе Бәшир картка бәя бирегез. Аның язмышын әсәрнең төп темасы булган өмет белән бәйләгез.

10. Әдипләр бу елларда үткән заман тормышын чагылдырган әсәрләр күп язалар. Гомәр Бәширов та шулай итә. Аларның үткәнгә әйләнеп кайтуларын сез ничек аңлатыр идегез?

11. Укыган китаплары турында Гомәр Бәширов болай яза:

«Күбрәк укый торгач, миңа бу китапчыкта язылган чыпчык борыны тикле хикәяләр берничә катлы кебек тоела башлады. Кыска гына итеп, сүз белән әйтеп биргәне бер. Әмма аның эчендә ачыктан-ачык әйтеп бетермәгән, әмма тагын да әһәмиятлерәк, монысыннан да кызыграк тагын нәрсәдер бар иде».

Гомәр Бәширов әдәби әсәрнең нинди сыйфаты турында яза?

12. Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда да, әлеге китапчыклардагы кебек, «әйтеп бетермәгән» «нәрсәдер» бармы? Булса, нәрсә ул?

Нурихан Фәттах
(1928—2004)

Нурихан Фәттах (Садрилмән улы Фәттахов) Башкортстанның Яңавыл районы Күчтавыл авылында туа. 50—60 нчы елларда иҗат итә башлаган күпчелек әдипләр кебек, ул да Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Китап нәшриятында — редактор, район газетасында журналист булып эшли.

Шул елларда иҗат иткән әдипләрнең күбесеннән Нурихан Фәттах ике сыйфаты белән аерылып торды. Ул үзенең эчке ирегеп беркайчан да яшермәде, әйтәсе сүзен берәүдән дә курыкмыйча турыдан-туры әйтте. Үзе инанган фикерен әсәрләрендә дә язды. Шуңа күрә хакимият даирәләрендә аның күп еллар буена абруе булмады, ышанычсызлар рәтендә йөрде. Әдипне җыелыш саен тәнкыйтьләделәр. Әсәрләрен бастырмадылар. Ләкин Нурихан Фәттахны буйсындыра алмадылар. Ул шушы көнгә кадәр үзе булып калды. «Сезнеңчә ничек?» романы автор үзе бик яхшы белгән студентлар тормышына багышланган. Чирәм җирләрдә татар яшьләренең хезмәте турында язар өчен, ул шул җирләргә үзе барып, башкалар белән беррәттән, гади крестьян булып эшләп йөрде. Ә «Ител суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», «Кол Гали» исемле тарихи романнарын һәм пьесасын иҗат итү өчен, бөтен эшен ташлап, тарих өйрәнде. Телләр тарихына багышланган гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле фәнни хезмәтен язар өчен, тел гыйлемен өйрәнүгә әллә ничә ел гомерен сарыф итте.

Без әдипнең «Ител суы ака торур» романын өйрәнәчәкбез. Кызганычка каршы, бу әсәр дә дәреслектә кыскартып бирелә. Ә сез аны тулысы белән укып чыгарсыз, дип уйлыйк.

ИТЕЛ СУЫ АКА ТОРУР

(Тарихи роман)

Ител суы ака торур,
Кыя төби кака торур.
Балык тәлим[1] бака торур,
Күлең тәкый күтәрер.

Борынгы заман татар халык җыры

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар Болгарга.
Кызганам моңлы баланы,
Үзем моңлы булганга.

Хәзерге заман татар халык җыры

Сүз башы

Татар халкының бай тарихы бар. Диңгездән бер тамчы алган кебек, менә шул бай тарихтан мин дүрт-биш елны аерып алдым.

Ул — Болгар чоры. Ачыграк итеп әйткәндә, Идел буенда Болгар йортының туу, оешу чоры.

922 елның маенда Болгарга ерак Багдадтан илче килә. Болгар рәсми төстә ислам дине кабул итә һәм заманында иң зур, көчле дәүләтләрнең берсе белән дипломатик мөнәсәбәт урнаштыра.

Багдад илчелегенең секретаре Әхмәт ибн Фадлан шул чордагы болгарлар һәм башка халыклар турында истәлекләр язып калдыра. Романда мин, нигездә, менә шул кыйммәтле истәлекләргә таянып, Болгарга ерак илчеләр килер алдыннан һәм килгәч булган хәлләрне тасвирладым.

Шулай итеп, тугыз йөз дә унсигезенче елга аяк басабыз.

Түрдән уз, хөрмәтле укучы, изге Болгар җиренә!

Апрель, 1969 ел. Казан

Беренче баб

I

Менә тагын яз җитте. Сулар акты... Дөнья яралганнан бирле сулар кая таба аккан булса, быел яз да сулар шул бер якка юнәлделәр. Инешләр, елгалар, ермаклар, ташулар...— барысы да

---

[1] Тәлим — күл.

Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар... кушылдылар, көчәйделәр, ургып-шаулап, алга ыргылдылар. Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш. Алар шунда кавышалар, бергәләшеп, кочаклашып, көн ягына юл тоталар. Кайнар ком, кояш илендә Ител-Чулман суын ямансулап иксез-чиксез диңгез, төпсез диңгез көтеп ята. Хазар диңгезе көтеп ята. Анда изге Хазар җире, анда изге каган[1].

Сулар ага... Җир йөзендә сулар бертуктаусыз агалар да агалар. Агым сулар кешеләрнең, киекләрнең чир-чорларын, кайгыларын, языкларын алалар да еракларга, упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. Шулай ел да җир яңара, җир яшәрә.

Җир яңара, җир яшәрә... Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Ител кебек, көн-төн җирдә тормыш ага.

Утташ кам[2], туры караган кояшка күзләрен кысыштырып, җиңел генә атына атланды да ишегалдына чыкты.

II

Акбүре ыруының башы Күрән би үзенең ырудашлары белән яши торган Кызыл Яр катау[3] Чулманның уң ягына текә ярга урнашкан иде. Күрән би манарага менеп карарга ярата иде. Бөтен катауда бу иң биек җир иде. Менә бүген дә ыру башы ерактагы күк читен шактый озак күзәтте. Күпме генә караса да, су өстендә би бернәрсә дә күрә алмады. Ул, аптырап, тәннек[4] каршында басып торды-торды да, авыр аякларын көчкә кузгатып, тар, текә баскычтан аска төшә башлады. Илле яшьләр чамасындагы Күрән би таза, имәндәй төз, озын буйлы иде. Тик бу тыштан караганда гына шулай. Таза «имән»нең эченә корт төшкән иде. Кыш урталарыннан бирле инде бине ниндидер яман чир тынгысызлый. Аның эче авырта. Аның көннән-көн сүлпәнләнә баруын, ыру эшләре, катау эшләре белән бик үк кызыксынмый башлавын якын кешеләре күрми калмадылар.

Чулманда боз кузгалу белән, ул көн дә шулай манара башына менде, киң болыннарга җәелгән су өстен күзәтте. Башка

---

[1] Каган— борынгы төркиләрдә дәүләт башлыгы.

[2] Кам — йола-дин башлыгы.

[3] Катау — коймалар, сулы тирән канаулар белән ныгытылган торак урын.

[4] Тәннек — тәрәзә.

елларда инде алар күптән килеп җитә торганнар иде. Быел менә юк... күренмиләр. Ни булды аларга?

Инде нишләргә? Нишләтергә барлык товарыңны? Киштәләрне сыгып төшкән төлке, кеш, ас, кондыз тиреләрен, тәпәнтәпән балларны, таудай өелгән ул күннәрне, савыт-сабаны, агач-ташны нишләтергә? Шулай үз-үзен кая куярга белми басып торганда, ул Яр капкага якынлашып килүче Утташ камны күреп алды. Утташ камны ул үзенең бабасы буларак кына түгел, ыруда беренче урынны яулап алырга, ыру башы булырга омтылучы көндәше, ягысы[1] буларак да куралмады, шулай да түзде.

— Яңа ай туар алдыннан барлык эшләрне тәгәлләргә кирәк, кияү,— диде Утташ кам.— Чокырларда пычрак сулар торып калды, агачларга чүп-чар эләгеп калды. Җыл яман килә. Йолык[2] туен быел зурлап ясарга туры килер, кияү!

— Зурлап ясарбыз,— диде би, килешеп.

Шулай диде дә кинәт сагаеп калды. Бабасының нинди уй белән килүен ул әлегәчә белә алмый интегә иде.

— Бүген төш күрдем, кияү,— диде Утташ кам, беравык тынып торганнан соң.— Атка атланып, үзебезнең Басу капкадан күпер аша чыгып барам, имеш. Каршыма Әрлик хан ялчысы Октуга килеп чыкты. Тешләрен ырҗайткан, күзләре уттай яна. Йолаларны бозасыз, ди, йолык бирмисез, ди. Атыңны бирәсеңме, ыруыңны, җиреңне-суыңны бирәсеңме, ди...

— Нинди атка атланганыең соң син, кам баба?— диде Күрән би, ачыктан-ачык мыскыл сиздергән бер тавыш белән.

— Мин, кияү, Йолдыз-кашкага атланганыем,— диде Утташ кам, тыйнак кына.

IV

Акбүре ыруының башы Күрән би белән Утташ кам туганнан туганнар иде. Бинең өлкән хатыны үлгәч, аның урынына өлкән хатын булып Каракүз калырга тиеш иде. Каракүз Утташ камның кызы иде. Каракүз бераз гына аңгырарак иде. Күрән би өлкән хатыны итеп Каракүздән яшьрәк Койтым бикәне билгеләде. Бинең бетмәс-төкәнмәс көндәлек эшләрен Койтым бикәдән башка беркем дә башкара алачак түгел иде.

---

[1] Ягысы — дошман.

[2] Йолык — корбан чалу.

Өлкән хатын булып Койтым бикәнең билгеләнүен белгәч, Утташ кам ачуыннан шартлый язды. Күктәге тәңрегә, җирдәге ияләргә таянган, шуңа күрә үзенең көченә кирәгеннән артык ышанган Утташ кам ырудашларын ачыктан-ачык та, яшертен дә бигә каршы котырта башлады. Әле генә Йолдыз-кашканы йолыкка соравы аның менә шул астыртын эшенең бер чагылышы иде.

Күп тә үтмәде, басмалар буенча би үзенең урдасына кайтып керде. Өлкән хатынына ул үзенең әлерәк кенә Утташ кам белән очрашуы турында сөйләде.

— Мин каршы түгел,— диде Койтым бикә, иренең сүзләренә артык куаныч белдермичә.— Тугач та Йолдыз-кашканы Тотышка үзең атадың. Ул аны карап үстерде. Инде килеп, берни әйтми тартып алсак, ни дияр ул бала? Аңа инде бала дип тә булмый...

Йолык туеның кайчан буласы билгеле булгач та, катау кешеләрен күңелле бер күтәренкелек биләп алды. Күңелле ыгы-зыгы башланды. Капка төпләренә, урам якка байраклар чыгарып куйдылар; баганалардан баганаларга, өйләрдән өйләргә ыру тамгалары төшерелгән чүпрәкләр, агач, сөяк кисәкләре бәйләнгән баулар суздылар.

Еракта, йөрәкләрне җилкетеп, кам бабаның:

— Уяныгыз — көн тугды! Уяныгыз — йолык туе,— дигән сүзләре яңгырап торды.

VI

Кояш су астыннан чыгып бер-ике таяк күтәрелгәндә, сәрәнчеләр, Яр капкага җитеп, кире борылдылар. Күрән би урдасы янында аксакаллар төркеме туктап калды. Капка сакчылары, каерып, имән капкаларны ачтылар. Капкадан би углы Тотыш күренде.

Атасы кебек, ул таза, эре сөякле иде. Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк иде. Ул кайгылы иде, ул ачулы, ул ярсулы иде. Сул кулына ул яшел төстәге йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесе Йолдыз-кашканы җитәкләгән иде.

Тотыш җитәкләгән яшь айгыр искиткеч матур иде. Ул уттай янып торган җирән төстә иде. Маңгаенда аның уч төбедәй генә ак табы — йолдызы бар. Аның күкрәге киң иде, нечкә нык аяклары озын иде. Ялт-йолт килеп, очкынланып торган күзләре зур, матур иде.

Барлык кешенең күзе бары Йолдыз-кашкада гына булды. Күрән бинең мактанычы, яшь Тотышның куанычы булган атаклы чаптарның бүген менә йолык туенда чалыначагына беркемнең дә ышанасы килмәде.

Сөекле чаптарын кызганудан Тотышның күзләренә яшьләр килде.

VII—VIII

Аланның тач уртасында ялгыз нарат үсеп утыра иде. Монда йолык урыны иде. Ыруның барлык язгы, җәйге, көзге туйлары шушында уздырыла иде.

Аксакаллар, йөзләре белән кояшка таба борылып, изге нарат ботаклары аша күккә карап, йолык келәне әйттеләр. Ул арада ирләр Йолдыз-кашканың алгы аякларына бәйләнгән арканны берьюлы тартып җибәрделәр. Йолдыз-кашка, гөрселдәп, җиргә ауды. Йолдыз-кашкадан соң ике карт үгезне, аннары унлап тәкәне чалдылар.

Күп тә үтмәде, дөрләп янган учакларда итләр пешеп чыкты.

Язгы кояш кичкә авышу белән, тамаклары карлыгып беткән кешеләр кайтырга җыена башладылар.

Күрән би, юл читендә туктап торган килеш, үз кешеләрен күздән кичерде.

— Тотыш юк,— диде ул, Койтым бикәне куып җитеп.— Төштән соң мин аны күрмәдем.

Атасы белән анасы үзе турында шулай борчылып кайтканда, Тотыш изге алан янындагы тәбәнәк чыршы астында утыра иде. Түземсезлек белән ул кешеләрнең тизрәк изге аланнан китеп бетүләрен көтә иде.

IX

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, Күрән бинең капка төбенә Утташ кам килеп җитте. Ул чамадан тыш ачулы иде.

— Эш чыкты, би... кияү!— дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән. — Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Изге нарат төбендә үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән. Тотыштан башка...

— Күрдеңме?— диде әкрен генә би.— Күрүчеләр булганмы?

— Юк,— диде кам, мыгырданып. Күрән би җиңел сулап куйды.

— Бу турыда беркемгә лыгырдыйсы булма! — диде ул, боерып, янап.— Син минем Йолдыз-кашкамны алдың — каршы килмәдем. Инде минем углыма теш кайрыйсыңмы?! Әллә син үзең кыргансыңдыр ул бүреләрне... юрамалый...

Утташ кам, бинең үзенә якынлашуын күреп:

— Кычкырам! Сөрән салам! — диде, ишеккә ташланып.

— Бар, кычкыр! — диде би.— Синең миңа аяк чалырга маташуыңны ырудашлар белмиме әллә? Бар, ник кычкырмыйсың?! Шунда ук муеныңа элмәк салып, агач башына асып куярга боерырмын.

— Юк, болай булгач, сөрән салмыйм, кияү,— диде Утташ кам. — Шулай да куркыттым дип уйлама. Синең углың башкисәр булып үсә. Йолаларга төкереп карый. Агач башында мин түгел, синең углың асылынып торыр, кияү!

— Җитәр! Кеше-кара күргәнче, аларны юк итәргә кирәк, бабай,— диде би.

Кешеләр торып йөренә башлаганчы, коллар бүре үләксәләрен урман арасындагы тирән чокырга илтеп ташладылар. Күрән би үләксәләргә ут төртергә кушты.

Өенә ул бик күңелсезләнеп кайтты. Кайткач та ул Койтым бикә белән Тотыш угланны үз янына чакыртты.

— Кем эше булыр бу?— диде ул авыр гына, изге аланда күргәннәрен сөйләгәч.

— Мин! — диде Тотыш, өй эчен яңгыратып.

Күрән би тораташтай катты да калды. Кинәт ишек ачылып китте, күзе-башы акайган яшь сакчы, тамак ярып:

— Сөенче!— дип кычкырып җибәрде.— Киләләр! Каеклар килә!

X

Би дә, бикә дә шундук терелеп киткәндәй булдылар. Бүреләр кайгысы онытылды.

Күрән би үзенең өлкән углы, каравыл башы Акбогага төтен үрләтергә, икенче углы субашы[1] Котанга кунакларга каршы китәргә боерды.

Кояш төшлеккә күтәрелеп җиткәндә, ерактан килүче җилкәнле каеклар катауга килеп җитә яздылар. Бу кунаклар сартлар да, румнар да, гарәпләр дә түгел иде, ахрысы.

---

[1] Субашы — гаскәр башлыгы.

— Базарганнар[1] түгел, атай! Ямгырчы би килә! — диде Тотыш.

Каек күпер читенә терәлеп, чайкалудан туктап калгач та, унлап кеше аягүрә басты. Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше, елмаеп, Акбүре ыруының башы алдында бүреген салды, башын иде.

— Казаяк ыруының башы Ямгырчы би синең җиреңә килде,— диде ул, Күрән бигә эндәшеп.

— Төкле аягың белән, туганым Ямгырчы би! — диде Күрән би, бозылган йөзенә елмаю билгесе чыгарып.

Кунаклар үз каекларыннан өч сандык төшерделәр. Ямгырчы би Акбүренең өлкәннәренә бүләкләр өләшә башлады.

Казаяк ыруының башы Ямгырчы би белән йөзләп кораллы ир килгән иде. Бер хатын-кыз да бар иде. Ул да булса Ямгырчы бинең кызы Тәңкә иде.

XII

Казаяклар өчен Күрән би үз урдасында киез өйләр кордырды, казан асарга дип, бер көтү сарык бирде.

Икенче көнне Күрән бинең ак өендә зур сөйләшү булды.

— Син, Күрән би, базарганнарны көтәсең булыр?— диде Ямгырчы.— Көтмә. Быел алар килмәячәк. Сартларны үз теләкләре белән килмәгәннәрдер дисезме. Юк, бикә, аларны монда Алмыш хан җибәрмәде. Алмыш! Юл бикле, Чулман[2] ябык! Чулман баш бирми, Чулман калан[3] түләми. Шуңа ачу итеп, быел Алмыш хан барлык сатучыларны Ител буйлап югары җибәрде... үзенә буйсынган ыруларга.

— Күреп торам: син миңа яңалыклар алып килгәнсең,— диде Күрән би кунакка.— Шулай да турысын гына әйт: уең ни?

Ямгырчы би, җентекләп, акбүреләргә карап чыкты, тирән итеп тын алды да:

— Уем шул,— диде.—Алмыш хан көчәйгәнче, безгә берләшергә кирәк. Бөтен Чулман бер булып, безгә болгарларга каршы чыгарга кирәк. Сез көчле, бай. Сез кузгалсагыз,

[1] Базарганнар — чит ил сатучылары.

[2] Чулман — Кама.

[3] Калан — җиңелүче җиңүчегә түли торган ясак.

башкалары да кузгалачак. Мин сине үземнән өстен итеп таныйм, Күрән би! Болгарларның муенын сындырсак, Иске йортның... Чулман йортының ханы ясыйбыз сине, Күрән би!

XIII

Төн урталарында кунаклар кайту ягына кузгала башладылар. Күрән би, кунакларга, үз кешеләренә тыныч йокы теләсә дә, үзе бик озак тынычлана алмый ятты. Әйе, яшь чагында ул да болгарларны Чулман, Ител буйларыннан себереп түгү турында татлы уйлар уйламады түгел. Ул да тач Ямгырчы би кебек коткы таратып йөрде! Аннан-моннан ике-өч мең кеше җыеп, ат менделәр, болгарларга каршы яу чаптылар. Ямгырчы бинең атасы Кылыч би ул чакта беркемгә катнашмыйча читтә калды. Әйе, орыштылар... җиңелделәр... Биш йөздән артык кеше җирдә ятып калды. Менә ничә ел инде ул күршеләре белән тату гына, тыныч кына яшәп ята.

Ник кычытынып йөри соң әле бу Ямгырчы би? Аңа никтер булып кирәк. Юк, юк, алдыннан арты яхшы. Казаяклар өчен кан коярга монда....

Шул ук көнне Күрән би, Акбүренең өлкәннәрен — аксакалларны, авыл башларын чакырып, тартыклар[1] җибәрде. Икенче көн туды дигәндә, чакырылган кешеләрнең барысы да катауга җыелып бетте.

Күпчелек картларны, куркагракларны, шулай ук белеклерәкләрне тыңлады. Акбүре ыруы болгарларга каршы яу чыгудан баш тартты.

XIV—XV—XVI

Казаяклар акбүреләрнең соңгы сүзен аяк өсте тыңлап тордылар. Җыенның нинди карарга килүен ишеткәч тә, кунакларның йөзләре бозылды.

Юк, Ямгырчы әле әз генә дә чигенергә теләмәде. Койтым бикәнең үзе генә өйдә чагын белешеп, сагалап торды да ялгыз өйгә юнәлде.

— Тәңре сиңа күп яшь бирсен, саулык-байлык бирсен, бикә! — диде Ямгырчы би, бикәнең чибәрлегенә соклануын яшермичә.

---

[1] Тартыклар — йомышчылар.

— Синең миңа йомышың бар бугай, би?— диде бикә, туры сүзгә күчеп.

— Тәңкә — минем бердәнбер кызым,— диде Ямгырчы би.— Ул иректә үсте. Анасыннан иртә ятим калганга, мин аны бернидән тыймадым, кысмадым. Алмыш ханның күзе төшкәнче дип... Сезнең белән килешеп булса...

— Син кемне күз алдында тотасың, би?— диде Койтым бикә.

— Синнән туган Тотыш угланны күз алдында тотам мин, бикә! — диде Казаяк ыруының башы.

Койтым бикә телен тешләгәндәй сүзсез калды.

Аның углы арыслан булып үсте... беркем сүзен тыңламыйча, беркемгә баш бирмәенчә... йолаларны, түрәләрне санламыйча... кыргый булып, усал булып үсте. Тугач, аның зурлыгына, көрлегенә таң калдылар. Үсә төшкәч, аның көченә, кыюлыгына... башсызлыгына шаккаттылар.

Ник шулай ул? Нигә шулай кире, үҗәт, башсыз? Анда, күрәсең, ике төрле кан шулай талашадыр. Әллә Тәңре аны болгарлардан ата-баба каны өчен үч алырга шулай көчле итеп, кыю итеп яратканмы?

Ни генә булмасын, менә шул Тотышны өйләндерер чак та җиткән!

— Мин каршы түгел,— диде бикә.— Анасыннан башка аның әле атасы да бар.

XVII

Өлкән хатын Әди Койтым бикәне аеруча яратмады. Аңа төрле яман сүзләр белән эндәште. Әледән-әле кырпаклыгы[1] белән йөзен ертты.

Куркып-өркеп, кыерсытылып яшәгән ананың углы да баштарак куркып-өркеп үсте. Аннан да бигрәк, ул үзенең «кырпак баласы», «кимчелекле бала» икәнлеген аңлап үсте. Аның моңа ачуы килде, үч аласы килде. Күкрәгендә, беләгендә көч барлыгын тоя башлагач, ул, бер дә юктан кабынып китәргә генә торган ярсуына, кимсенү тойгысына ирек биреп, үзен кыерсытучыларны еш кына тәпәләп тә ташлады.

Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, илле йөк мал

---

[1] Кырпак — кол кыз, җария.

белән төн кешеләренә сату-алуга барды. Тотыш углан биш ай дигәндә кире кайтып төште. Баеп, кырысланып, олыгаеп кайтып төште.

Көтмәгәндә Ямгырчы бинең килеп төшүе, акбүреләрне болгарларга каршы яуга өндәве Тотыш угланны канатландырып җибәрде. Ул инде үзен чын-чынлап яуда итеп күрә башлады. Тик аксакаллар киңәше ул көткәнчә төкәнмәде.

XVIII

Ашагач-эчкәч, ул тынычланып калды. Учак янында беравык тынып утырды да кызыксынып, кечкенә тураннарының уенына карап тора башлады. Шул чакны ул балалар арасында, ярым караңгыда ниндидер ят кыз күреп алды. Моңарчы ул аны читтән генә күреп калган иде. Озынча ак битле, кара кашлы бу чандыр кызның күз карашы учак җылысы кебек җылы да, ягымлы да иде.

— Абый, бу — Тәңкә! Кунак кызы!— диештеләр энеләр-сеңелләр.

— Исәнме, Тотыш,— диде кыз, йомшак кына, оялчан гына елмаеп.

— Исәнме, Тәңкә,— диде Тотыш.

XIX

Төн уртасы якынлашып, балаларның кайсы йокыга киткәч, кайсы уеннан арып-талып йокыга җыена башлагач, Тәңкә дә үз өенә кайтып китмәкче булды.

— Кал бездә генә! — диде Тотышның Айсылу атлы зур сеңлесе.

Ярым караңгыда Тотыш кунак кызның беләгеннән тотып алды да, колагына пышылдап:

— Калма! Үзем озатып куям,— диде.

Пышылдаган чакта аның маңгае кызның кайнар чигәсенә тиеп китте. Кыз берни әйтмәде. Тотышка ул бик озак эндәшми торды шикелле тоелды.

— Кайтам,— диде Тәңкә Айсылуга, калтыранып чыккан пышылдау белән.

Язгы төн караңгы иде, салкынча иде. Өй эчендә юаш, тыйнак тоелган Тәңкә тышка чыккач бер дә юкка көлеп җибәрде. Тотышның янбашына төртте дә, җегет аны-моны абайлап өлгергәнче, караңгыда юк та булды.

— Тоталмыйсың, тоталмыйсың!— диде ул, әкрен генә көлеп.

Тотыш үзенең тиле көченә ышанып, ярсып куа башлады. Ул кисәк кенә Тәңкәгә ташланды. Кунак кызы бары көчсез бер тавыш белән «ах!» диярга генә өлгерде — җегет аны тотып алды да, кочып, кысып, җирдән күтәрде.

— Җибәр! — диде кыз, аның башыннан кочып.

Кулыннан ычкындырмыйча гына Тотыш кызны җиргә бастырды. Берара каушап-калтыранып торгандай итте. Бар кыюлыгын бергә җыеп, аны яңадан кочып алды.

— Минеке буласыңмы?— диде ул, пышылдап, кайнар сулышын өреп.

Тоңык кына йолдызлар яктысында кыз, үзенең яратуын белдереп, аның яңа мыек чыгып килгән сылу йөзенә карады.

XX

Бүлмәгә каравыл башы Акбога килеп керде.

— Менә, атай, бау баскыч,— диде ул, кулындагы бауны идәнгә ташлап...— Киртәдә эленеп калган. Чулман ягында... Текә яр өстендә!

— Тагын Тотышмыни?— диде ата кеше.

— Кем булсын башка — шул! Каекчылар менеп әйтте: Ямгырчы бинең кызы Тәңкәне алып киткән,— диде Акбога.

— Тәңкәне?! — диде би, күзләрен шар итеп.— Урлап?

— Ах! — диде Койтым бикә, йөрәк ачысы белән.— Нишләтергә ул баланы?!

Өйалдында икенче бер кешенең кереп килгәне ишетелде. Ишек сакчысы, ишектән башын тыгып:

— Ямгырчы би килгән, керсенме?— диде.

Ямгырчы би, сулуы кабып, эчендәге бар нәрсәне түгәргә кереште.

— Мин синең кунагың, Күрән би,— диде.— Кунактан болай көлмиләрие. Углың минем йөземне каралтты. Калым түләмичә, юлбасар кебек! Изге йоланы, изге түрәне бозып...

— Әйт: күпме сорыйсың?— диде Акбүре ыруының башы.

— Мең тиен. Булмаса — йөз төлке, булмаса — утыз кеш,— диде кунак.— Белегез: бу — калым түгел. Кызымны мин үзем белән алып китәм.

— Ярар,— диде Күрән би, килешеп.— Талау күргән өчен, сиңа миннән йөз төлке. Калым турында аерым сөйләшербез. Быел көз мин сиңа кодалар җибәрермен.

Көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте — качакларны эзләргә киткән Котан белән Акбогадан бернинди яңалык ишетелмәде. Ул арада сабанга төшәр көн дә килеп җитте. Язгы сабанда бөтен ыру, бөтен катау катнашты. Берәүләр сөрде, икенчеләре арттан тырмалап барды. Өченче берәүләр, иңбашларына тубаллар асып, шунда ук чәчә бардылар.

Шундый көннәрнең берсендә, кич караңгы төшкәч, Кызыл Яр катау турысына бер көймә килеп туктады. Көймәдән төшкән кешеләр, бер-берсенә тотынышып, текә баскыч буенча әкрен генә югары үрмәләделәр.

Ярым ачык капка төбендә аларны сакчы туктатты.

— Тотыш, сезме?— диде ул, әкрен генә.

Кайттылар... Алар катаудан ике көн ераклыктагы балыкчы Карынчык өендә тукталып калдылар. Яр буенда, урман эчендә балыкчы аларга ялгыз өй корып бирде, көн дә аларны яңа тотылган балык, яңа суелган ит белән сыйлады. Тотыш, Тәңкә белән бергә тора башлагач, үзенең барлык кайгыларын, барлык үпкәләрен онытты. Чулман буенда мәңге торып калуга да каршы килмәс иде. Карынчык качакларга әйтте, болай качып йөрү би углына килешми. Кайтырга кирәк, диде.

Менә алар кайттылар.

— Атам, анам, мин ир булдым,— диде ул, идәннән күзен алмыйча.— Барысы өчен дә кичерегез мине! Кичер мине, Ямгырчы би!

Икенче баб

I

Беренче тапкыр бүген күк күкрәде, яшен яшьнәде. Күп тә үтмәде, томалап, яңгыр килеп җитте. Шулай итеп, Акбүре иленә җәй килде, җылы килде.

Кешеләргә, бигрәк тә Утташ кам яклыларга күзекмәсен дип, Күрән би Тотышны Чулман аръягындагы Талкысык авылына озатты. Аның күңелен бертуктаусыз нидер борчып торды.

Иртән аны ниндидер дөбердек уятты.

— Бу мин, каравыл Чынтап! — диде тыштагы ир кеше. — Улакчы[1] килде. Ашыгыч битек[2] китергән. Менә.

---

[1] Улакчы — ашыгыч хәбәр китерүче.

[2] Битек — хат, язу.

Би каравылчы кулыннан битекне тартып алды да җепне тешә беләп өзде, аксыл каен тузына төрек хәрефләре белән язылган түбәндәге сүзләрне укыды: «Атай! Алмыш хан килә. Төшкә монда булыр. Елга аша күпер салалар. Көче күп. Мин Чулманга чигенәм. Шуннан кайтырмын. Алай башы Күзәмеш углан».

Күрән бинең чәчләре үрә торды. Идәнгә егылды да ике кулын күккә сузып, күз яшьләрен түгеп ялвара башлады.

— Тәңрем! Ата-баба! Көч бирегез, кыюлык бирегез! Яу килә, яу! — диде.

II—III

Икенче көнне каравыл өендә йокымсырап утырган Күрән би, тояк тавышлары ишетеп, сискәнеп, урыныннан торды.

— Киләләр! — диде шунда кемдер, басу ягына күрсәтеп.

Иң элек аларның иртәнге кояш яктысында ялт-йолт килгән сөңге очлары, күк төстәге озынча байраклары калкып чыкты. Баштанаяк коралланган, көр-таза атларда нык утырган ул ят кешеләр тыныч кына киләләр иде. Алар күп иде, бик күп иде. Юлда, тар аралыкта яхшы акбүз атка атланган бер кеше күренде. Ул бик таза, көчле кеше күренә иде. Кара сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп киселгән иде.

Эре сөякле, бай киемле бу ир-ат Алмыш хан иде. Төз атылган ук каравыл өенең ишек башына килеп кадалды. Укка каен тузы бәйләнгән, тузга шундый сүзләр язылган иде:

«Мин, Болгар йортының башы Алмыш хан, синең җиреңә килеп урда кордым. Атам Шилке үлгәч, син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Шуны алырга килдем. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?»

Акбүре ыруында барлыгы ун мең өй санала иде. Берәр кештән бер елга ун мең кеш, өч елга утыз мең кеш. Каян алырга утыз мең кешне? Булган барлык байлыгыңны чыгарып салыргамы, әллә соң булган барлык көчең белән каршы торыргамы? Би аксакалларга, кораллы ирләргә күтәрелеп карады.

— Нишлибез?— диде ул, карлыккан тавыш белән.

Тынлык шактый озакка сузылды. Беренче булып Утташ кам авыз ачты.

— ...Бөтен ыруның язмышы кыл өстендә торганда... безгә йолык бирергә кирәк! Башкача котылу юк! Кичәгенәк төш күрдем. Октуган якамнан алды. «Йолык! Йолык! Йолык!» —

диде өч тапкыр. Өч тапкыр әйттеме, ул кеше сорый. Явыз Октуган йолыкка кеше сорый!

— Йолык! Йолык! — дип кычкырдылар Утташ кам янындагы кешеләр.

— Явыз Октуган синең углың Тотышны сорады, Күрән би! Кая качырдың углыңны — кичекмичә тотып бир безгә!

— Ашыкма, кам баба,— диде аңа каршы Күрән би.— Йолыкка кеше биреп кенә Алмыш ханнан котыла алабызмы без?

— Йо-ок!— диделәр акбүреләр беравыздан.

— Шулай булгач,— диде Күрән би,— йолык бирү-бирмәү турында сөйләшкәнче, калан түләү-түләмәү турында сөйләшсәк, яхшырак булмасмы?

— Шула-ай!— диделәр кораллы ирләр, катауны яңгыратып.

— Алайса әйтегез: утыз мең кеш түлибезме, ягы белән орышабызмы?

— Ыхым-ыхым,— диде Майчан аксакал.— Оланнар, ырудашлар! Утыз мең кеш безне аяктан җыкмас, Алмыш ханның кылычы җыгар. Эт күңеле бер сөяк. Алсын да китсен!

— Алсын да китсен! — диештеләр кешеләр, шау-гөр килеп.

— Юк, түләмибез! — диде шул чакны кемдер, шау-шуны күмеп.

Кешеләр тавыш килгән якка — койма өстенә күтәрелеп карадылар. Анда баштанаяк коралланган яшь бер углан басып тора иде.

— Тотыш!

Утташ кам, үз-үзен белешмәстән, тыгыз төркем арасыннан Тотыш ягына ташланды.

— Тотыгыз, тот! Аяк кулларын бәйләгез! — дип кычкырды ул, явыз бер сөенеч белән.

— Сөйлә, углан! — диде Майчан аксакал.

— Атам, анам! Ил агалары! — дип кычкырды Тотыш, көр, яңгыравыклы тавыш белән.— Көч алар ягында, ырудашлар. Тик шулай да мин утыз мең кеш түгел, ягыга бер тиен дә бирмәскә димен! Мин Алмыш ханның иң көчле алыбы белән очрашырга телим! Җиңсәм, болгарлар буш кул белән китәр, җиңеләм икән — калан түләрсез!

Бинең күзләренә яшьләр килде.

— Углым! — диде ул, Тотышны кочагына алып.— Бүгеннән башлап син — сугышчан ир! Орыш, углым, ягы белән, күрсәт ирлегеңне!

— Ак юл сиңа, Тотыш углан!— диделәр аксакаллар.

Күрән би, углының теләген белдереп, болгарларга ук атарга кушты.

Күп тә үтмәде, болгарлардан икенче ук килеп төште. Каен тузына ике генә сүз язылган иде: «бергә өч» дигән сүзләр иде. Димәк, Тотыш бер-бер артлы өч алыпны җиңәргә тиеш, бары шул чагында гына ул җиңүче булып саналачак.

Яшь егетнең иреннәре калтыранып китте. Ул озын итеп, күп итеп бер тын алды да:

— Мин орышам!— диде.— Мин сүземнән кайтмыйм.

— Юк! — диде Күрән би, болгарларның битеген урталай ертып.— Бу тигезлек түгел. Алар бездән юри көләләр.

Акбүреләр аптырабрак калган бермәлдә, койма өстенә Койтым бикә килеп менде.

— Углым!— диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер өн белән.— Мин барысын да күреп, ишетеп тордым. Углым, күземнең яругы... бавыр итем, йөрәк маем! Бар, орыш! Мин сиңа изге теләктә булырмын. Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!

— Мин курыкмыйм, анам!— диде Тотыш, елмаеп.

V

Тотыш җиңелчә генә киенергә булды. Кыска тунның күкрәк турысына юка тимер кисәкләре тегелгән иде. Аның өс киемендәге тимер бары шул гына иде. Кысып, билен буды да кылычын такты. Шуннан соң ул бер кулына калкан, икенче кулына сөңгесен алды. Тотыш Ташбәкәлнең тезгенен бушайтып җибәрде. Ул туп-туры хан чатырына таба карап чапты.

Шул чакта ул үзенә таба якынлашып килгән болгар алыбын күреп алды. Болгарларның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт[1] иде.

Чәкән алпагыт богадай[2] таза, арысландай көчле иде. Баштанаяк ул тимергә төренгән. Бу усал, кансыз, коточкыч алпагыт турында: кылыч белән бер сукса, тимер киемле кешене урталай ярып төшерә, дип сөйлиләр иде. Аның белән орышкан бер генә батырның да әле исән калганы юк дигән сүзләр дә йөри иде. Чәкән алпагыт, гыжылдавык бер ямьсез тавыш белән:

— Әй син, Камырбатыр! Бар, кайтып кит. Синнән өлкәнрәк килсен! — дип кычкырды.

---

[1] Алпагыт — батыр, алып, көрәшче.

[2] Бога — үгез.

VI

Атлар арт аякларына басып, усал итеп кешнәп җибәрделәр. Чәкән алпагыт шаярткан кебек кенә сөңгесе белән төртеп алды. Сөңге башы Тотышның тимер калканын тишеп чыкты. Җегет тиз генә калканын тартып алды. Чәкән алпагыт, «сәләмә» батырны бер селтәнүдә сөңге очына эләктерә алмавына ачуы килеп, күрәсең, монысында чынлабрак орды. Яшь җегет шулай да аның сөңгесеннән өлгеррәк булып чыкты. Ияреннән шуышып, уңга ташланды.

Икенче тапкыр оятка калу алпагытны чын-чынлап котыртып җибәрде. Ул, кыя таудан ычкынып киткән иләмсез зур таш кисәге сыман, Тотыш өстенә килә башлады. Тотыш углан үзенә төбәлгән сөңгене калканы белән читкә тайпылдырып җибәрде. Чәкән алпагытны узып киткәч, ул атын борып тормады: сикереп, кинәт ияргә басты, артына борылды... борылды да, күз ачып йомган арада, сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды. Туры ыргытылган саллы сөңге тимер киемне, тимерсөякләрне җимереп, киң арканы үтә-сүтә тишеп керде. Чәкән алпагыт, барлык авыр киемнәре, кораллары белән гөрселдәп, ишелеп, җиргә төште.

Акбүреләр ду килеп шауларга тотындылар.

Ул арада Тотыш углан, сөенеченнән очынып, катау ягына чабып килде. Тузан туздырып, баш очында сөңгесен уйнатып, яңадан хан чатырына якынлашты.

Яңа орыш башланганлыгын белдереп, тагын быргылар кычкырды. Яланга Будрач сукман[1] килеп чыкты.

— Мин кылыч белән орышман!— диде Будрач сукман.

Тотыш берни әйтмәде, атыннан сикереп төште дә кылычын кыныдан алды. Будрач сукман буйга калку түгел иде. Ул бик таза, нык, авыр сөякле иде. Чәкән алпагыт кебек, ул да баштанаяк тимергә төренгән иде. Карар күзгә авыр күренсә дә, Алмыш хан батыры да бик җитез, өлгер кыланды. Тотыш кысрыклауга чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп чигенә барды. Будрач исә шулай кысрыклап килде-килде дә кинәт кылычын, ике куллап тотып, бар көченә орды. Тотыш җиргә егылды. Будрач сукман яңадан өстенә килә башлагач, ул тиз генә читкә сикерде. Ул моны берничә тапкыр кабатлады. Тотыш углан тиен кебек җитез иде. Будрач сукман, чалгы белән печән

[1] Сукман — батыр сугышчы, алып.

чапкандагы кебек, Тотышның кай төшеннән генә булса да урталай кыеп төшермәкче булды. Тик ул Будрач сукман уйлаганча уңга да, сулга да тайпылмады, туп-туры аның аяк астына ташланды. Үткер кылыч аның баш өстеннән ыжгырып үтте. Шул ук мәлдә бөтен яланны тутырып, йөрәк ачысы белән:

— А-а-а! — дип кычкырып җибәрде.

Тотыш кулындагы үткер тимер астан күкрәгенә таба шуышты.

VII

Берьюлы ике батырыннан колак каккан Алмыш хан, Тотыш угланга тын алырга да ирек бирмичә, өченче кешесен чыгарды, Монысы Корыч-Тимер дип аталган яшь, чибәр алып иде. Тотыш кебек үк, ул да бик җиңел сөякле иде, шуның өстенә ул әле әз генә дә көчен түкмәгән иде. Тотышка ул күтәрелеп карарга да ирек бирмәде.

Тотыш ярсый башлады. Күз алдында ялт-йолт килгән кылыч йөзе торган саен аның ачуын китерде. Кәтмәгәндә, ул нәрсәгәдер абынып китте. Шул чагында Корыч-Тимер ач бүредәй аның өстенә ташланды. Аның кылычы Тотыш кулындагы калкан читен уеп төшерде, сул як беләкне кисеп керде, сөяккә җитеп тәртелеп калды. Тотыш углан чайкалып китте. Киселгән беләктән кайнар кан агарга тотынды.

Корыч-Тимер, бер селтәүдә Тотышны юк итмәкче булып, кылычын, ике куллап, югары күтәрде. Тотыш углан җиргә егылып калды. Тик монысында ул баягыча ягының эчен айкый алмады. Сырты белән терәлеп яткан килеш, ул аңа бары кушаяклап тибеп кенә җибәрә алды. Авыртуга түзә алмыйча, болгар батыры чинап җибәрде, җиргә барып төште.

Җирдән алар икесе дә бер үк мәлдә сикереп тордылар.

Тотышның кулында корал юк иде.

— Ы-ы-ы!— дип үкерде кара мыеклы чибәр алып, куанычыннан нишләргә белмичә.

Ул инде орган да булыр иде, Корыч-Тимернең үкерүеннән дә көчлерәк булып, көтмәгәндә, әйтерсең күк күкрәп җибәрде.

— Тукта! — дип кычкырды кемдер аның артында гына.— Тукта! — диде Алмыш хан, кабатлап.— Син җиңдең!

Акбүреләр, караларына коелып, беравык аңламыйчарак тордылар да, барысы берьюлы диярлек кычкырып җыларга тотындылар.

VIII

Орыш урынына имчеләр чыкты. Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләген карадылар; яраны салкын су белән юдылар да киселгән иткә яра ташы кырып салдылар. Шул эшләрне башкаргач, төсе качкан, агарынган яшь җегетне кабыкка салдылар да каядыр алып киттеләр.

Ике як арасында кыскача гына сөйләшү булып алды. Күрән би Алмыш ханның катау янындагы яланнан үзе урда корган җиргә — Тәкәшүр болынына кайтып китүен теләде. Тиешле бурычны дүрт көндә үзем илтеп түләрмен, диде. Алмыш хан үз чирүенә[1] шундук кире борылырга боерык бирде.

Ике көн эчендә акбүреләрнең бурычы тулысынча түләнеп бетте. Амбарлар белән бергә Күрән бинең күңеле дә бушап калды. Җиңелүе, амбарларның бушап калуы өчен күңелен игәгән кайгысы йомшарга да өлгермәде, аны инде яраланып теге якта калган углы өчен борчу тынычсызлый башлады. Ни булды аңа? Ник бирми аны Алмыш хан?

IX—X

Чулман буеның чык каплаган яшел болынында җиңүчеләр туй иттеләр...

Алмыш ханның мең кеше сыйдырышлы өендә аш-су башкаларныкына караганда да күңеллерәк, шау-шулырак булды.

Алмыш хан, тун итәкләрен җыештырып, биек урынга утырды. Ханның сул ягына Айкын хатын утырды. Ире кебек, ул да озын буйлы, симез бер хатын иде. Аның өс-баш киемендә, кулларында чын ташлар җемелдәшә иде.

Бер казанны бүлеп бетергәч, икенче казан, икенче казан беткәч, өченче, дүртенче казан чыкты. Кунаклар тәмле азыкны мактый-мактый ашадылар. Өй эченә балык исе таралды — ашчылар ак балык ите тарата башладылар.

XV—XVI

Койтым бикәне болгар күзәтчеләре туктатты.

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны. Мин — Койтым бикә. Минем углым Тотыш — хан кулында.

---

[1] Чирү — гаскәр.

— Алайса, син Тотыш алыпның анасымыни?— диде алай башы, кызыксыну белдереп.— Менә ичмасам орышты. Күпме яшәп, шундый батырны күргәнем югые. Ярар, барыгыз... алай Тотышның анасы да булгач... Менә Кудаш сезне озатып куяр.

Алмыш хан, алтын-көмешле киемнәрен салмыйча, ике кулы белән биленә таянып, ятагында утырып тора иде. Койтым бикә үзе дә сизмәстән тетрәнеп китте: Тәңрем, нинди кансыз бу язмыш дигән нәрсә! Элекке яшь туердай таза, сылу Алмыш углан ботак-сатаклы карт имәнгә әйләнгән.

Күрән бинең өлкән хатыны, йола саклап, башындагы бүреген салды, тезләнде. Коры, нык бер тавыш белән:

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны Койтым бикә...— дип сүзгә башлады.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышып та, төшерә алмыйча аптырап утырган ханның йөзе кинәт ачылып китте.

— Койтым! — диде ул, яратып, ягымлы итеп.—Чынлап бу синме, Койтым?

— Бу — мин,— диде бикә, үзен үзе тынычландырырга тырышып.— Мин... Тотыш угланның анасы...

— Тотышның?

— Әйе. Син аны миңа кайтарып бир. Үлеме, тереме — кайтарып бир. Үтенечем шул. Мин шунсыз китмим!

— Китмә,— диде хан, тыныч кына.— Мин сине кумыйм. Кал янымда, хатыным булырсың. Углың белән кал. Би хатыны булуга караганда, хан хатыны булу яман түгел.

— Миңа углым кирәк. Тотыш кирәк!— диде бикә, күз яше сизелгән йомшаклык белән.

— Мин аны үлем тырнагыннан тартып алдым. Мин! Корыч-Тимернең кылычын мин тотып калдым. Син аны тапкансың, мин аны үлгәч терелттем. Шулай булгач, Тотыш алып... Тотыш арыслан синеке генә түгел, минеке дә! Ул миндә тотык[1] булып калачак. Ике елдан соң ул синең яныңа исән-сау килеш кайтыр. Аның урынына тотык итеп миңа Күрән би үзенең бүтән углын җибәрер. Югыйсә үзеңә тиешле каланны да менә шулай яу белән килеп алырга туры килә.

— Алайса, тагын бер үтенечемне тыңла,— диде бикә, аягына басып.— Углымны күрергә булмасмы?

---

[1] Тотык — берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен, дошман якларның берсе тарафыннан кулга алынган каршы як кешесе.

— Ник?— диде хан.— Аның янына имчеләр сине түгел, мине дә кертмәсләр. Кайгырма, миннән аңа кырын күз карашы да булмаячак.

— Бай бул, сау бул, Алмыш хан! Бай бул, сау бул, улым Тотыш!— диде Койтым бикә, җиңел сулап.

XVII

Чулман буена яу чыгар алдыннан, Алмыш хан, чит ил сатучыларын тоткарласа да, соңыннан, уйлана торгач, бу эшнең үзе өчен бик үк файдалы түгел икәнлеген аңламый булдыра алмады.

Алмыш хан тиз арада үзенең ялгышын төзәтергә булды. Ага-базарда җыелып яткан базарганнарга, сартларга төн ягына юл ачык икәнлеген белдерде. Шулай итеп, язгы ташуда ук килергә тиеш булган чит ил сатучылары, соңлап булса да, Акбүре җиренә дә килеп җиттеләр.

Кызыл Яр катауда ун көн буена зур базар булды. Базарга якын-тирәдәге авыллардан, урманнардан күп кешеләр килде. Җиңелү кайгысыннан нишләргә белмәгән акбүреләргә әйтерсең яңадан кот керде. Күрәсең, сату-алучылар килү куанычыннан, шулай ук хатынының сүзләренә күнеп, Күрән би Алмыш ханга бил бөгәргә килде, аңа мәңге турылыклы булырга дип ант эчте.

Өченче баб

I—IV

Тотыш шактый күп канын югалтты. Дүрт көн буена аның янына, шулай таң ату белән, Байтал имче килде. Дүрт көн буена Тотыш күзен дә ачып карый алмады. Бишенче көнне яралы җегет күзләрен ачты.

Бер-ике көннән Алмыш хан урдасы, Акбүре җиреннән кузгалып, кире көн ягына таба юл тотты.

Кичкә таба атлар, арбалар туктап калдылар. Тавышлар басыла төште. Әле анда, әле монда учаклар ягылды, кыздырылган ит, май исләре таралды.

Тотышның йокысы килмәде. Аның кайсыдыр җире авыртты, кайсыдыр җире сызланды. Аның күңелендә моңарчы үзен бик үк сиздермәгән бер кызыксыну уянды. Болгарлар аны каядыр алып баралар. «Нинди җир бу?»— диде ул үзенә үзе.

Тышта шылт иткән тавыш та ишетелми. Димәк, арба янында беркем юк.

 Яралы җегет идәнгә җайлап утырды да, ишек бавын чишмәкче булып, ярыктан кулын тышка сузды. Нәрсә булды соң әле бу? Әйе, аның кулы кеше кулына тиде. Җегет, барлык батырлыгын бергә җыеп:

— Кем бар анда?— диде.

Аның тавышы үзенә дә ишетелмәде.

— Тотыш... синме?— диде тыштагы ниндидер нәрсә, пышылдап. Бу, билгеле, имче дә түгел, сакчы да түгел иде. Ул ниндидер... кыз кеше булырга тиеш иде.

— Тотыш, мин сиңа ашарга китердем,— дип пышылдады ят кыз, бераз тынып торганнан соң. Ул арада тыштагы ят кеше ишек астыннан эчкә ниндидер авыр нәрсә куйды. Ул, яңадан капшанып, әлеге төргәкне табып алды, сүтте, андагы зур гына ит кисәген комсызланып ашарга кереште.

«Болай булгач, качам да качам инде!»— дип уйлады Тотыш, кыюланып.

Шулай да ул кача алмады. Үзе дә сизмәстән, ул ят, серле кыз турында уйлый башлады. Кем булыр ул? Килерме иртәгә, килмәсме?

Икенче көнне кыз бөтенләй килмәде. Кайгыдан Тотыш нәрсә уйларга да белмәде. Кыз «иртәгә» дә, «иртәгә» соңыннан да килмәде. Көндәгечә аның янына иртә-кич Байтал имче килде, ачтан үлмәслек кенә ашарга-эчәргә китерде.

Шулай итеп, көн артыннан көн үтте. Атларга атланган, арбаларга утырган Болгар иле, урман-суларны кичеп, үзенең төп җиренә таба кыймылдады. Акбүре җиреннән кузгалып китүләренә бер ай чамасы булды дигәндә, болгарларның мең кешелек иравылы[1] Ямгырчы би җиренә барып керде.

V—VII

Алмыш ханга буйсынган биләр арасында Ямгырчы би иң ышанычлыларыннан санала иде. Үз кеше булганга да Алмыш хан Чулман аша сал-күперне аның катавына якын җирдә салды. Ямгырчы би сал-күпергә тимәскә, саклап торырга сүз бирде.

---

[1] Иравыл — хәрәкәттәге армия алдыннан баручы гаскәри берләшмә. Авангард.

Болгарларның кайтуын түземсезлек белән көтеп торган Ямгырчы би, бер көтү сарык, кымыз, ачы бал алып, тиз арада хан янына килеп җитте. Алмыш хан Ямгырчы бинең тикмәгә генә килмәгәнлеген бик яхшы аңлады.

— Үзеңә тиешле телемне[1] алырга килдеңме? — диде ул, үзе беренче булып.— Күпме сорыйсың, турысын әйт!

— Турысы шул, ханым...— диде Ямгырчы би, утка ташланырга җыенган кеше сыман,— бир миңа кызың Аппакны!

Алмыш хан, корт чаккандай, кинәт урыныннан сикереп торды.

— Син... би, авызыңны үлчәп ач!— диде хан, кашларын җимереп.— Аппакка торырлык бернинди байлык юк. Алдан килешү буенча, мин сиңа телем бирергә тиешмен. Әйт: ни кирәк — колларммы? көтүләрме? тиреме? алтынмы? җирме? Ни кирәк?

— Аппактан башка миңа берни кирәкми,— диде Ямгырчы би, нык итеп.— Йә Аппакны бирәсең, йә мин синнән аерылам.

— Җитте! — диде Алмыш хан, аяк тибеп.— Аппак турында тыныңны чыгарма!

Күңеле кырылган бер төстә Ямгырчы би башын иде.

— Сау бул, ханым,— диде ул.— Мин киттем.

— Кит! — диде хан, кул селтәп.

Барысы да Ямгырчы би уйлаганча булып чыкты. Алмыш ханның чибәрлеге белән Болгар йортына атагы таралган гүзәл Аппакны үзенә бирмәячәген ул алдан ук белде. Аңа телем дә, Аппак та аз иде, аңа Алмыш ханның бөтен байлыгы — җиресуы, иле-көне кирәк иде. Ул берьюлы Алмыш ханны да, Хазар каганын да, булдыра алса — суарларны да, башка күршеләрен дә төп башына утыртмакчы булды.

Тик менә аның шунысы әчен пошырды: Чулманның теге ягында әле булса кара төтен күренми иде. Үзара килешү буенча, Болгар калага иң элек Килдеш би бәреп керергә, андагы кораллы ирләрне кырып салырга, шуннан соң күккә кара төтен үрләтергә тиеш иде.

Казаяклар, ашыгып, урман ягына юл тоттылар. Ямгырчы би китеп күп тә үтмәде, Чулманның аргы ягында ургылып күккә кара төтен күтәрелә башлады.

Куркыныч килүен белдереп, шундук быргылар чинарга тотынды. Шул чакны сал-күпердә бу якка таба чабып килүче

---

[1] Телем — бу урында күпер саклаган өчен түләү.

җайдак күренде. Алмыш хан янына килеп җитәр-җитмәс, ул, тамак ярып: «Яу килә, яу!» — дип кычкырып җибәрде.

Алмыш хан, олауларның кичүгә килеп җитүен көтеп тормастан, ир-атларга теге якка чыга башларга боерды. Дүрт мең кешелек чирү бары кич, караңгы төшкәндә генә чыгып бетте. Тәкин углан белән бер-ике меңлек гаскәр калды. Алмыш хан кебек, Тәкин углан да бу яктан куркыныч килер дип башына да китереп карамады. Ямгырчы бине нишләптер барысы да исләреннән чыгарып ташладылар.

Алмыш хан төнне сул якта кунды. Таң атар-атмас борын, торып, болгарлар ат менделәр, ярсып, оран салып[1], ханбалыкка[2] юнәлделәр.

VIII—X

Тотышның ярасы бөтенләй төзәлеп бетте. Тәкин углан атасының боерыгын белә иде. Шулай ук ул таза-сау җегетне имче карт карамагында гына калдыруның да бик үк яраган эш түгел икәнлеген аңлый иде. Тотыш өчен җирдә аерым өй кордылар. Тотыш җиргә аяк басты. Ишек төбендә ул ниндидер ят кеше белән очрашты. Матур кылыч борыны астында аның нечкә генә кара мыегы салынып тора иде.

— Мине сиңа җибәрделәр,— диде кол.— Тәкин углан җибәрде. Минем атым Торымтай, Алмыш ханның колы. Бүгеннән башлап мин синең колың.

— Каян син? Ничек бу көнгә төштең?

Алар озак кына сөйләшеп утырдылар. Тотыш, үзенең колы чыгып киткәч тә, озак кына учак янында уйланып утырды. Шулай утыра торгач, тышта аңа ниндидер кыштырдык ишетелгәндәй булды.

Ишек ачылып китте. Тотыш, исе китеп, аһылдап җибәрде. Аның каршысында, тулган айдай балкып, сокландыргыч гүзәл бер кыз басып тора иде.

— Мин сиңа... ашарга китердем... Тотыш,— диде ул, тотлыгып, сулуы кабып.

— Мин сине көттем,— диде җегет.— Нигә килмәдең?

— Җибәрмәделәр. Курыктым...— диде кыз.

— Кемнәр җибәрмәде соң?— диде Тотыш.

— Иям. Аппак...— диде кыз, пышылдап.

---

[1] Оран салу— каты кычкыру.

[2] Ханбалык — башкала.

Тотыш аптырап калды. Алмыш хан кызы аңа ашарга-эчәргә җибәргән! Ник? Яратамы, кызганамы? Димәк, бу кыз аның карасы, асравы, йомышчысы?

— Миңа хан кызыннан бернинди күчтәнәч кирәкми! — диде Тотыш, шактый тупас итеп.

— Ул сине ярата, Тотыш! — диде кыз.

— Мин аны яратмыйм! — диде Тотыш, усал итеп. Ул күбәгә белән комганны идәнгә орды. Ашамлык көлгә түгелде.

Кыз кулы белән битен каплап, чырыйлап кычкырып җибәрде. Кырт кына борылды да ишеккә ташланды.

XI—XIII

Тотыш бик соң исенә килде. Исенә килде дә шулай ук ишеккә ташланды, атылып тышка чыкты. Аңа йөрергә, каядыр барырга кирәк иде. Үзенең кая барып чыгасын бөтенләй белмәстән, ул караңгы төннең күзенә туры карап алга атлады.

Күп тә үтмәде, ул ниндидер агачлар арасына барып керде.

Туктале, котылды түгелме соң ул? Ул тагын артына борылып карады. Карады да бар көченә чабарга тотынды. Тизрәк, тизрәк! Таң атканчы, моннан ычкынырга кирәк!

Чулман! Бөек елга, туган елга! Менә килдем, менә таптым сине! Без яңадан бергә, изге елга!

Ниндидер ботак-сатакларга абынып, ул текә ярдан аска төште. Аяк астында төпсез, караңгы, куркыныч су барлыкка килде. Ник килде соң әле ул монда? Ул моннан качып китә алса, Алмыш хан аны эзләргә коралды ирләрен җибәрмәсмени? Акбүреләрне пыр туздырмасмыни? Шулай булгач, кемнәрнеңдер тотып алганын көтеп тормастан, яңадан тоткынлыгыңа әйләнеп кайтудан да яхшысы булмас, ахры. Ул инде борылып кирегә китмәкче дә булган иде... каяндыр аяк астыннан ниндидер кешеләр атылып чыкты. Чыктылар да чыбык-чабык арасында буталып калган ят җегетне эләктереп тә алдылар.

Үз өендә яланаяклы, яланбашлы Тотышны күреп, Ямгырчы би шаккатты.

— Әйе, Күрән би улгы... Тотыш...— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Минем киявем... буласы кеше, качкын, угры, бозык Тотыш! Син әле белмисеңдәдер, сөекле киявем, Алмыш хан синең йортыңны-иленне пыр туздырып ташлады ич! Ата-анаңны,

туганнарыңны, ырудашларыңны турап чүплеккә, Чулманга ыргытты.

— Ялган сөйлисең, би! — диде Тотыш.

— Ялган? Мин сиңа ишеткәнемне сөйлим: Алмыш хан Чулман буен яулап кайтып килә!

— Минем сугышасым килә, Алмыш ханнан үч аласым килә. Синнән башка кем корал бирер миңа, би?

— Минем дә, синең дә ягы бер — Алмыш хан. Аның сыртын сындырмыйча торып, миңа тынгы булмаячак. Мин сиңа корал бирсәм, йөз кешелек алай бирсәм, син нишләрсең, Тотыш углан?

— Болгарларга каршы уктай атылырмын, би! Бугазларын чәйнәрмен!

— Антмы?

— Ант! Ант! — диде Тотыш, кайнарланып.

— Мин бүген кояш чыгу белән яу башлыйм. Алмыш хан үзе теге якта. Тәкин угланны мин аны! Чулман буеннан талап алган байлыгын... бер тиенен калдырмыйча... Ул — безнең байлык. Моннан соң бөтен Ител-Чулман буена Ямгырчы би баш булачак. Тотыш углан... кияү! Безгә ничек тә аның кызы Аппакны кулга төшерергә кирәк. Аппак берүзе бөтен Болгар йортына тора.

Тотыш кинәт телсез-өнсез калды.

XIV—XVI

Казаяклар үзәк юл өстендәге каравылны кырын салдылар да, мыштым гына эш итәргә дигән боерык булуына да карамастан, коточкыч тавыш куптарып, йокылы өйләргә, олауларга, болындагы көтүләргә ташландылар. Канлы сугыш башланып китте. Үзәктәге бөҗра кысыла барган саен, болгарлар да ныграк каршылык күрсәтә башладылар.

Сугышның иң кызган бер чагында Тотышның күзенә бер таныш кеше чалынып калды. Тотыш, үзенең казаяклар ягында икәнлеген онытып:

— Торымтай! — дип кычкырып җибәрде.— Алмыш хан кызы Аппак кайда?

Торымтай уңдарак утырган бер өйгә төртеп күрсәтте.

Киез өй эчендә ул, ирләр киеме киеп, кулына кылыч тоткан бер кыз белән очрашты. Тотыш коралларын чак-чак кына төшереп җибәрмәде. Аның алдында... сөеклесе, аның гүзәле басып тора иде.

— Аппак кая?— диде ул, кызга туры карамаска тырышып.

— Аппак кирәкмени?— диде кыз, мыскыллы көлемсерәп.— Аппак кирәкми дигәнием түгелме соң? Аппактан җилләр исте!

Тыштагы шау-шу кечәя төште. Сакчы болгарларны туздырып, Аппак өенә казаяклар ябырылган иде. Тотыш алар арасында Ямгырчы бине күреп алды.

— Аппак булдымы?— дип кычкырды Ямгырчы би, тыны бетеп.

— Аппак юк,— диде Тотыш.

— Ялганлыйсың, юлбасар!

Ул кылычы белән Тотыш ягына селтәнеп җибәрде. Тотыш башын иеп калды. Кылыч аның алпагына кадалган каз каурыен кыеп төшерде.

— Би, үз каурыеңны үзең кистең! Минем сиңа антым юк! — диде Тотыш, агарынып.

Казаяклар, дәррәү кубып, яуга ташландылар.

— Җибәрмим! — дип кычкырды Тотыш, казаякларның юлына аркылы төшеп.

Алмыш ханның алыплары белән орышкандагы кебек, Тотышны изге бер үч-ачу тойгысы, саклык-уяулык тойгысы биләп алды.

Үзенә беренче булып якынаеп килгән ирнең сөңгесен ул, искәрмәстән бәреп, кулыннан төшерде. Туры ыргытылган сөңге, яртылаш күкрәгенә батып, аны шундук артка чөйлектерде. Тотышны уратып алган ярымалка кысыла башлады. Алар күп иде.

— Тотыш, бирешмә! Без икәү! — диде кыз, аны дәртләндереп.

Казаяклар төркеме артында кинәт ниндидер шартлау тавышы ишетелеп китте. Казаяклар, куркып, артларына борылдылар. Кемдер, тамак ярып:

— Артка төштеләр! — дип кычкырып җибәрде.

Ямгырчы би ирләре, бер-берсен этеп-төртеп, таптап-изеп, кайсы кая качыша башладылар. Тотыш, иясез бер атны эләктереп, качучылар артыннан куа китте. Казаяклар урман алдындагы ниндидер ерганакка юлыгып тоткарланып калгандай иттеләр. Бер яктан болгарлар килеп җитте, икенче яктан Тотыш белән Торымтай килеп басты. Ике арада каты сугыш башланды.

Менә шул чагында кемдер Тотышның башына күсәк белән тондырды.

XVII

Тотыш күзләрен ачып җибәргәндә, әйләнә-тирә ниндидер болганчык караңгылыкка төренгән иде. Димәк, ул тагын исән калган. Тик менә Ямгырчы белән артына гына җитеп булмады. Ул торып утырды, як-ягына каранды. Чыбылдыкның тартылып торган кырые янында ниндидер хатын-кыз карачкысы күренде. Елмаеп, сокланып, ул үзенең танышына, үзенең сөеклесенә карап тора башлады.

— Кил әле,— диде Тотыш.

Кыз күндәм генә урыныннан купты, сөрмәле күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, яралы җегеткә таба атлады.

Тотышның аңа: «Мин сине генә яратам!»— дип әйтәсе килде. Тел очына аның бөтенләй икенче сүзләр килде.

— Аппакка әйт... хан кызына... Мин аны яратмыйм! — диде ул, ашыгып, үртәлеп.

Ягымлы, юаш, күндәм кызны әйтерсең алдында алыштырып куйдылар. Күз ачып йомганчы, ул билендәге кәзлеген[1] тартып чыгарды.

— Менә мин ул Аппак! Мин! — диде.

— Син?! — диде Тотыш, шаккатып.

— Ник яратмыйсың, ник?! — диде кыз, янау катыш ялвару белән.— Мин шулай яратмаслыкмыни?

Тотыш ни дә булса әйтеп өлгергәнче, ул бөркәнчеген өстеннән салып ташлады. Аның килмәгән бер генә җире дә юк иде.

Тотыш инде чынлап та телдән калды. Күз алдын ялкын каплап алды.

— Син мине... алдадың...— диде ул, күпмедер тынып торганнан соң.

— Мин сине яратам! — диде кыз.

— Мин дә...— диде Тотыш.

XVIII

Болгар каланы хан килеп җиткәндә инде ут-ялкын чорнаган иде. Суарлар берничә урында койма эченә бәреп кергәннәр иде. Койма буйларында каты сугышлар бара иде.

Болгар ирләре тетрәнеп киттеләр. Боерык булганны да көтмәстән, сөрән салып, ут-ялкынга таба ыргылдылар. Суарлар

---

[1] Кәзлек — хатын-кыз хәнҗәре.

ашык-пошык чигенә башладылар. Иң беренче булып Килдеш би үзе табан ялтыратты.

Төшке сугыш бетте. Суарларның меңләгән ирләре мәңгегә күзләрен йомды.

Алмыш хан ханбалыкны аркылы-торкылы йөреп чыкты, янган, җимерелгән коймалар буенда булды. Кая гына бармасын, аңа пыскып-көйрәп яткан кара күмер, агач өемнәре, үлгән, янган кешеләр, көлгә-корымга буялган, шашынып, әрле-бирле чабышкан ирләр, хатыннар, балалар очрады.

Шунда аның күз алдына икенче төрле янгыннар килде. Әйе, әле кайчан гына ул үзе талап, яндырып йөрде. Инде менә аның үзен талап-яндырып киттеләр. Менә сиңа бөек Болгар! Болай булгач, болгарлар түгел — хазарлар. Хазар каганы җиңелмәс булып чыкты. Каган шымчылары күршеләрне туктаусыз котыртып тормасалар, болгарларга каршы туктаусыз корткычлык эшләмәсәләр, Килдеш бинең мондый эшкә йөрәге җитәр идемени? Димәк, тынгысыз кешеләрнең явызлыгыннан котылу өчен, иң элек Хазардан котылырга кирәк. Үзеңне, чыннан да, бай итеп, ирекле итеп тою өчен, каган белән ике арадагы җепләрне өзеп ташларга кирәк!

Алмыш ханның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Өченче көнне хан туган-тумачаларын яшерен киңәшкә җыйды.

XIX

Алмыш хан сүзгә башлады:

— Элеккечә ил тотып булмый. Талау, яндыру белән ерак китеп булмый. Көтү көр булсын өчен, терлекләр тынычлап утларга тиеш. Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк. Шуларны ничек булдырырга? Без янган ханбалыкны торгызырга тиешбез, без катауны беркемнең теше үтмәслек таш койма белән уратып алырга тиешбез.

— Кулыңда кылыч барында, дошманнардан куркып яшәү оят! — диештеләр кайберәүләр, шаулаша башлап.

Кашларын җыерып, йодрыкларын йомарлап, Алмыш хан яңадан урыныннан торды.

— Кулдагы кылычка гына да таянып яшәп булмый. Миңа кылычтан да, ук-җәядән дә, сөңгедән дә көчлерәк корал кирәк. Андый корал бар. Ул да булса — гарәпләр йоласы. Болгар тауга үрләргә теләсә, ислам динен тотарга тиеш.

— Әйтеп кара: ничек ирешерсең икән моңа?

— Мин, дин белгечләре — муллалар, мәзиннәр сорап, туры Багдадка, хәлифәнең үзенә илче җибәрәм.[1] Багдадка илчем итеп мин Тәкин угланны җибәрәм.

Дүртенче баб

I—X

Яңа урында Тотыш өчен хан урдасының читендә аерым өй кордылар. Аның янына, кечерәк өйгә Торымтай урнашты.

Тотыш белән Торымтай барган турыда елга сай иде. Алар су янына якынрак килделәр дә, тирә-яктагы үсмерләргә карамыйча, өсләрен чишенә башладылар.

Шул чакны аның колак төбендә генә:

— Әй син, килмешәк, кая тыкшынасың?! — дигән сүзләр ишетелеп китте.

Тотыш ялт кына артына борылып карады. Аннан берничә адым читтәрәк бер җегет басып тора иде. Бу теге Тотышны җиңгән Корыч-Тимер алып иде.

— Исеңдәме, син минем аяк астымда аунап яттың? Сине анда хан коткарып калды. Монда беркем коткармас — яхшы чакта үкчәңне күтәр! — диде Корыч-Тимер. Янап, күзләрен чекрәйтеп, ул Тотышка якын ук килде. Ул аны, күрәсең, суга төртеп җибәрмәкче булды.

Тотыш күңелендә, давыл булып, үч, ярсу, оят — барысы берьюлы калкып чыкты. Масайган Корыч-Тимер исенә килергә дә өлгермәде, Тотыш аның биленнән ике куллап кысып алды да «ә» дигәнче баш аркылы атып бәрде.

— Җәгез, кем тагын килмешәккә каршы килә?— диде Тотыш, усал елмаеп.

Аңа каршы чыгарга беркем дә батырчылык итмәде. Кемдер бары арттан гына таш ыргытты. Тотыш үзенә таш ыргытучыны эзләп тормады — күзенә эләккән беренче угланны тотып алды да аны да баш аркылы җиргә орды. Авызын ачып торган икенче бераүнең яңагына тондырды, өченчесенең корсагына төртеп алды. Ул арада Корыч-Тимер дә аягына басты. Басты да, ярсып, яңадан Тотышка таба килә башлады. Тотыш искәрмәстән аның эченә тибеп җибәрде — Алмыш ханның макталган алыбы гөрс итеп арты белән җиргә барып төште.

---

[1] Багдад шәһәре — мөселман диненең үзәге, хәлифә барлык мөселманнарның дин башлыгы саналган.

— Әй болгар куркаклары, белегез: бу — мин, Тотыш булырмын! — дип кычкырды Акбүре батыр, качып баручыларны мыскыллап.

— Юлбасар! Килмешәк! Сиңа монда барыбер көн булмас! — диделәр яшь әтәчләр, куак арасыннан йодрык янап.

Очынып, җиңеләеп, Тотыш суга ташланды, колач салып йөзеп китте.

Үзләре өенә бер йөз адым чамасы калгач, Торымтай барган җирендә туктап калды.

— Карале! — диде ул, каядыр алга күрсәтеп. Тотыш үз өе ягына карап тора башлады. Өйдән күккә, шәбәеп, төтен үрләп ята иде. Ул тизрәк өенә ашыкты.

Учак янында кемнедер күреп, ул чак-чак кына артына авып китмәде.

— Аппак ич!— диде кинәт Торымтай, кычкырып.— Минем күзем күрмәде, агып яткан су күрде...

Үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ул каядыр китеп барды.

— Син... Торымтайдан курыкмыйсыңдыр ич?— диде Тотыш кызга.— Әллә Торымтай синнән куркамы?

— Мин — гарәп динендәге кеше,— диде Аппак.— Гарәп дине буенча, ир кеше алдында хатын-кыз битен каплап йөрергә тиеш, ди. Көн дә мулла безне җыя да шундый нәрсәләр өйрәтә. Аннары гарәпчә укырга-язарга өйрәтә. Кызык түгел. Телләрен дә, язуларын да өйрәнәсем килми. Мин куркам. Мин Тәңредән куркам, ияләрдән куркам. Күңелемнән минем беркайчан да ата-баба йоласыннан баш тартканым юк.

— Ник син кешеләрдән генә түгел, көннән, кояштан куркасың? Мин тотык булган өченме?.. «Килмешәк» булган өченме?

— Юк, юк, Тотыш!— диде Аппак, куркып, аның муеныннан кочып.— Ни сөйлисең?! Ташка язмаганны!..

— Нәрсә, тагын «йола»мыни?— диде Тотыш, мыскыл итеп.

— Әйе, йола,— диде кыз.

— Минем кулларымны, аякларымны богаулап ташлый торган йолаларга төкерәм мин!

— Язык, язык! — диде кыз, дер-дер калтыранып.

Колакларын ике кулы белән томалап, ул ишеккә ташланды. Тотышны хан янына чакырдылар. Алмыш хан аңа кымыз бирде, аннары тыныч булырга тырышып сүзгә башлады.

— Тотыш углан,— диде,— Кызыл Яр катау янындагы орышта минем алыпларны үтереп, син атаңны-анаңны, ыруыңны якладың. Моның өчен сине яманлап булмый. Анда син

хаклы идең. Ләкин тормыш катлаулы. Тормышта... хаклы кеше түгел, көчле кеше хаклырак. Син, углан, үзең турында гына, үз катаның турында гына уйлыйсың. Шуннан башка барлык кеше, барлык ырулар синең өчен дошман. Шуңа күрә дә сез акбүреләр, суарлар, казаяклар бер-берегез белән сугышыпызгышып яши бирәсез. Таркаулыктан миңа да, сезгә дә файда юк. Шуны аңласаң, син мине дә аңларсың, минем ягым түгел, минем якчым булырсың. Син инде уйлыйсыңдыр: ни өчен Акбүре Алмыш ханга буйсынып яшәргә тиеш дип. Акбүре ирекле булырга тиеш дип. Сезнең уч төбедәй ирегегез ахыр чиктә сезнең өчен ирексезлек булып кайта. Минем кул астындагы ирек сезне талаудан, кан-яшьтән коткарачак. Син, Тотыш углан, менә шулар турында уйлап кара. Мин сиңа ат бирергә, үзеңнең коралларыңны кайтарырга боердым, Тотыш углан. Минем көтүдән үзең теләгән атны сайлап алырсың.

— Бай бул, Тәңре сиңа күп яшь бирсен, ханым! — диде куанычыннан нишләргә белмәгән җегет.

XVI

Юл буена Тотыш уйланып кайтты. Моңарчы ул бары үзе турында гына, үзенең язмышы турында гына уйланса, бүген ул башкалар турында уйланды. Чынлап торып уйлап карасаң, ник кирәк бу яулар-сугышлар? Акбүрене болгарлар килеп басты, болгарларны — суарлар. Алмыш хан белеп сөйли, үзара сугышлар булмасын өчен, чыннан да, бер йодрыкка тупланырга кирәк түгелме соң?!

Көне буена ул үзендә бер куанычлы җиңеллек тойды. Ул арада кояш та баеды. Ышкыйсы, тазартасы, төзәтәсе эшләре беткәч, Тотыш бушанып калгандай булды. Өенә керде дә, тезләрен кочаклап, кызу учак каршысына утырды. Тиздән йокларга ятты. Күзен йомып та өлгермәде, ишек тарткан тавышка ул, сикереп, урыныннан торды.

Ишекне ачып җибәргән иде... тимерле киемнәрен чылтыратып, ниндидер кораллы ир атылып килеп керде.

— Сиңа ни кирәк?— диде Тотыш, каушавын яшерергә тырышып.

— Син кирәк! — диде Аппак, көлә-көлә.— Кичер мине, Тотыш. Киен, әйдә, киттек.

— Кая?

— Кая булса да! Җәйге төн шундый матур! Коралларыңны ал, Тимеркуккә атлан,— диде кыз.

Бераздан алар, атларын әкрен генә атлатып, сөңгеләрен югары тотып, караңгылыкка кереп юк булдылар.

XVII

Бүген алар яктыра башлаганны сизмичәрәк калдылар. Таллык бетеп, тәбәнәк калкулыктан менеп килгәндә, алда, як-якта ниндидер атлылар күренде. Тотыш каршысына беренче булып килеп җиткән кораллы ир, битлеген күтәрмичә:

— Ым?[1] — дип кычкырды.

Тотыш аны тавышыннан танып алды. Каушау, аптырау кыргый бер ярсу белән алышынды.

Корыч-Тимер битлеген ачып җибәрде. Тотышка туры карап, шаркылдап көләргә тотынды: «Барыгыз, бар, ник тукталдыгыз?»

— Тотыш... беттек! — диде Аппак, пышылдап, алга узып.

Корыч-Тимер, җирне-күкне калтыратып:

— Уйнаш! — дип кычкырып җибәрде.— Тотыш — Аппак — уйнаш! — Атын борып, ул урда ягына чапты.

XVIII

Болгар йоласы буенча, кояш баеганнан алып кояш чыкканчыга тикле чит ир белән чит хатын-кыз бергә очрашса, уйнаш санала иде. Уйнаш өчен ирне дә, хатынны да — кем булуларына карамастан! — аяк-кулларын чабып, тураклап үтерәләр иде. Корыч-Тимер аларны үзенең әшнәләре белән ике көн күзәтеп йөрде.

Аппак Тотышка барысын да сөйләп, аңлатып бирде. Җегетнең йөзен кайгы-сагыш биләп алды. Менә ни өчен Аппак бары төнлә генә килгән икән аның янына! Хан кызы тотык белән бернинди бәйләнешкә кермәскә тиешләр. Ах, менә нинди кепе икән ул тотык!

— Тизрәк, тизрәк! — диде Аппак, Тотышны ашыктырып.— Мин әле ышанам. Ничек тә этине алданрак күрергә кирәк.

Алар ашыктылар. Үлемгә ашыгалар идеме алар, иреккәме — беркем дә белмәде.

XIX

Аппакның Тотыш белән бергәләп керергә теләгән ишеткәч, Алмыш хан, аңлап җитмәгәндәй:

— Минем каршыгамы?— диде.

---

[1] Ым — пароль.

— Әйе, ханым,— диде хан агасы.— Анда тагын Алып-Тархан углы Корыч-Тимер алып та килгән. Никтер кызган, бик ашыгыч, ди.

— Корыч-Тимер сүреләә төшсен. Әйт, керсен кызым,— диде хан. Алар икәүләп керделәр.

— Әти! — диде Аппак, ялвару белән.— Без сиңа зур йомыш белән кердек. Әти! Мин Тотышны яратам. Тотыш... мине... Без өйләнешергә булдык — ирек бир безгә!

— Син, кызым, үзеңнең кем икәнлегеңне онытып җибәргәнсең, ахрысы,— диде хан.

— Юк, әти,— диде Аппак, тынгысыз бер кабалану белән.— Тотыш мине үлемнән коткарды! Мине саклап, унлап казаякны үтерде.

— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы,— диде хан.— Мин кызымны тотыкка да, колга да, йолкышка да бирә алмыйм. Сау булыгыз, угланнар.

— Бар ышанычым синдә, әти! Безне бергә күрделәр. Корыч-Тимер... Тозак... Кызган мине, әти!

Алмыш ханның йөзен кара болыт каплап алды. Шул чакны кара болыт арасыннан якты кояш нурлары балкып чыкты.

— Тыңлагыз, сүзем шул,— диде ул, авыр гына сүзгә башлап,— Тотыш үзе, ата-анасы, ыруы гарәп диненә күчсә... тиешле калымын түләгәч... ике елдан соң өйләнешерсез. Ак юл сезгә, балалар.

Бишенче баб

I

Ике ел искән җилдәй үтте дә китте. Тотыш өчен бу ике ел бөтен бер тормыш булды. Алмыш хан аңа зур эшләр тапшырды. Тотыш углан ике мең кешелек чиру белән, көтмәгәндә, суарларны барып басты. Килдеш бинең үзен кулга төшерде. Башкортлардан ике ел түләнмәгән каланны көч бе-лән алып кайткач, йорт башы аны мукшыларга каршы җибәрде...

Ни булса да булды, ике ел узып китте. Алмыш хан аны бүген үз янына чакырып алды.

— Син ирекле, Тотыш углан,— диде ул.— Иленә кайт, мин әйткәннәрне үтә, калым китер. Шунда киявем булырсың... Алла боерса...

II—V

Тотыш юлга җыена башлады. Багдад ягыннан килеп, Болгарда төпләнеп калган Габид атлы тегүчегә ул туй өчен үзенә тун тектерергә биргән иде. Тотыш туры тегүче янына юнәлде.

— Өлгермәдем, Тотыш алып,— диде ул.— Кәтмәгәндә, олы кунаклар килеп төште — Фатих ибн Әхмәт!

Моның белән ул Фатих ибн Әхмәтнең бик зур кеше икәнлеген аңлатмакчы булды.

Тотыш, бүләкләр алып, туган ягына кайтып китәргә җыенып йөргән арада, Ага-базарга унике каек белән акбүреләр килеп төште. Акбүре каекларына Тотыш үзенең бүләкләрен, кием-салымнарын төятте. Шунда аны Алмыш ханның йомышчысы эзләп тапты. Хан янында ниндидер ят, чит кунаклар бар иде. Зур кунакларның берсе Башту углы Габдулла иде. Шушы көннәрдә генә ул түбәннән, Хазар йортының ханбалыгы Итил-Торадан килеп төшкән иде. Габдулланың әйтүенә караганда, Корыч-Тимер хазарларга барып чыккан. Корыч-Тимер Итил-Торага килеп җиткәндә, Тәкин углан әле Хазаранда булган. Шунда кышлап, ул быел яз Багдадка юл тотарга уйлаган. Корыч-Тимер боларны күргән дә каган кешеләренә җиткергән: Тәкин углан — сатучы түгел, Алмыш ханның хәлифәгә җибәрелгән яшерен илчесе, дигән. Каган кешеләре Тәкин угланны, Барыс угланны, аларның кешеләрен тотып алганнар.

Менә шуңа да күңелсез иде хан Тотыш белән саубуллашканда.

VI—IX

Имгәк аяк астында, дип белми әйтмәгәннәрдер, күрәсең, Күрән би үзенең үлемен аяк астында тапты. Манара башыннан төшеп килгәндә, аның аяк астындагы басма сынып китте. Авыр, авыру би «әх» дигәнче баш түбән аска мәтәлде.

Бине күмгәндә, ырудашлары чын күңелдән җыладылар. Күрән би үлгәч, аның туганы, ыруда иң атаклы кешеләрдән саналган Утташ кам, йола буенча, ыру башы булып калган иде.

Кайгы туе төштән соң башланды. Ашау-эчүнең, уен-көлкенең кызган чагында Койтым бикә, арып-алҗып, үз өенә кереп китте. Бусага янында аның каршысына кинәт бер кеше килеп басты.

— Бикәгә минем бер сүзем бар,— диде ул, телен көчкә әйләндереп.— Аулакта гына.

«Кем соң әле бу?» — дип уйлады Койтым бикә, тиз генә таный алмыйча. Туктале, Талут ич бу! Тотыш, чыбыркы белән сугып, күзен чыгарган Талут.

Талут, өйгә керү белән, бикә алдында тезләнде, сыңар күзеннән яшьләр коеп җыларга кереште.

— Бикә, кичер мине. Тәңре каршында языклы мин. Ирең-не... Күрән бине... мин үтердем, бикә,— диде.

— Ни өчен?! — диде бикә, пышылдап.

— Тотыш минем күземне чыгарды бер дә юкка. Күңелдә углыңа, сиңа, бикә, ачу саклап йөрдем. Шунда мине Утташ кам котыртты. Баскычның бер басмасын алыштырып куярга ул әйтте. Тагын шул: Утташ кам... ни... миңа Тотышны да... Мин баш тарттым.

— Мин сине тулысынча кичерәм, Талут! — диде бикә, дулкынланып.— Турысын сөйләвең өчен мин генә түгел, Тәңре дә ярлыкар сине, Талут.

Бикәнең авыр кайгыдан бастырылып ойый, тына барган йөрәге оясыннан атылып чыккан кош кебек ыргылып куйды. Аңа кичекмәстән берәрсен күрергә, сөйләшергә, ни дә булса эшләргә кирәк иде. Юкса ул соңга калачак! Кем белән сөйләшергә? Котан, Акбога... Аның үги угыллары.

Исерешеп беткән, баш-аяк килгән кешеләр арасында Котанны ул бик тиз тапты. Үзе артыннан барырга кушты.

Койтым бикә елмайды, учактагы утка яны беләнрәк торган Котанның күзләренә туры карады да:

— Мин сиңа ошыйммы, углым. Ошасам, шул: синнән башка мин беркемгә кияүгә чыкмаячакмын! — диде.— Тик син шуны аңларга тиешсең. Мин өлкән хатын гына булмаячакмын. Ыру башы булачакмын! Шуңа килешсәң, иртәгәдән мин — синең хатының!

Котан үзенең зур, көчле кулына бикәнең ак кулын алып кысты да, чын күңелдән соклану белән:

— Синнән дә башлырак, кыюрак кеше калмады ыруда, анам! Тулысынча мин сиңа буйсынам. Ант! — диде.

Шул чакны кемнеңдер бәрелә-сугыла өйалдына килеп кергәне ишетелде.

Койтым бикә ишекне ачып җибәргән иде, каршысында Утташ кам урынына Тотышны күреп, артына авып китә язды.

— Углым, Тотыш! — диде ул, кочагын җәеп.

X

Җыен үзенең соңгы сүзен әйтте: ыру башы Күрән бине үтергән өчен, Утташ камны Тәңре катына озаттылар. Талутны Койтым бикә җыенда яклап калды. Койтым бикә җиңеп чыкты. Җыен аны ыру башы итеп куйды. Билекне[1] ыру башы үзенең улы Тотышка бирде.

Берничә көннән Тотыш анасына үзенең эч серләрен ачты. Койтым бикә, елмаеп, улына озак кына карап утырды.

Аның улы Тотыш Тәңкәсен оныткан. Ул әнә хан кызын ярата! Нәрсә бу — язмыш шуклыгымы, әллә соң Болгар ханының бик еракка ташланган җәтмәсеме? Ун мең тиен калым түләргә, бөтен ыруың белән гарәп диненә күчәргә... Бу аз түгел. Хан кызы Аппакка торырлык бүләк бу. Ханның, чыннан да, үз уйлары бардыр. Акбүрене үз кулына алса, бөтен Чулман буе аныкы булачак. Биарны төн ягыннан диңгездән килгән явыз юлбасарлар талаган. Биар тузган, юкка чыккан.

Алмыш ханга... аның белән туганлашуга? Була торган эшме бу? Барысы өчен ул аңардан үч алырга тиеш түгелмени?

Ул монда Акбүредә бикә булып, баш булып яши. Шулай булгач, ул инде үзеннән бигрәк ил-көн турында, аның бүгенгесе, иртәгесе турында кайгыртырга тиеш түгелмени?

Акбүре яшәргә тиеш. Алмыш хан белән туганлашу ул — мәңге иминлек дигән сүз. Акбүре җирендә беркайчан да олы яу, сугыш булмаячак дигән сүз.

— Мин, улым, синең бер генә теләгеңә дә каршы килмәячәкмен,— диде бикә, озак кына сүзсез утырганнан соң.— Син инде үзең би. Үз башың белән уйлап кара: бүгеннән тотып без ата-баба йоласыннан баш тартсак, ыру безгә ни әйтер? Кулдан тотарлар да артка тибәрләр.

— Нишләргә соң, алайса?— диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Ашыкмаска кирәк, улым,— диде ана кеше.— Көтәргә, ыруны тулысынча үз кулыбызга алырга. Ике айдан түгел, дүртбиш айдан...

XI

Җылы, изге бер таңда Тотыш бинең төрле төсләргә буялган унике каегы Кызыл Яр катау тамгасыннан кузгалып китте. Алар күп кенә авылларны, катауларны узып киттеләр.

---

[1] Билек — би дәрәҗәсе.

Шуранга Чулманның сул як яры буйлап китәргә булдылар. Күзгә төртсәң күренмәслек кара төндә тавыш-тынсыз гына яр читеннән йөзеп барганда, су өстендә әле анда, әле монда утлар кабынып китте. Үзенең чолганышта калуын күреп, Тотыш бинең эче жу итеп китте.

Төн бөркәнчеге астыннан сиздермичә генә утсыз каек килеп чыкты. Аягүрә баскан Ямгырчы бинең куркыныч карачкысы, караңгыдан чыгып, акбүреләрнең күз алдында ук күренеп китте.

— Нинди эш бу? Оят кирәк азрак! Юк, юк, кунак итми җибәрмим,— диде Ямгырчы би.

XII

Ямгырчы би кунакларның барысын да аерым-аерым өйләргә урнаштырды. Акбүреләр төш җиткәнче йокладылар.

Тотыш би кисәк кенә уянды. Күзләрен ачып җибәргән иде, үзенең аяк очында елмаеп утырган Тәңкәне күреп тынсыз калды.

— Исәнме, Тотыш,— диде Тәңкә, балкып.— Мин сине көттем. Ике ел буе көттем. Таң аттымы, күзем Чулманда булды.

Тотыш нидер әйтмәкче булды. Теле әйтерсең аңкавына ябышып калды. Тимер кебек авыр кулын, көчкә күтәреп, Тәңкәнең биленә салды. Күңелендә аның, ахрысы, кызгану тойгысы баш калкытты. Ул аны, билгеле, яратмый иде. Шулай да ул аны җиңел генә читкә дә сыпырып ташлый алмый иде, ахрысы. Ул аның яшьлеге иде. Шул үткәннең бер кисәге иде.

Ничек соң аның күңелен кырмыйча гына аңа шул турыда әйтеп бирергә икән?

— Мин Алмыш ханга калан илтә барам,— диде ул, әкрен генә сүзгә башлап.

Яшь хатынның көләч йөзе сүрелеп калды, уттай кайнарлыгы өреп сүндергәндәй юкка чыкты. Тәңкә кинәт өстендәге ябынгычын атып бәрде. Читекләрен киде.

— Мин барысын да беләм! — диде ул, коры, усал итеп.— Мин сине ике ел көттем. Суар Килдеш бинең кече углыннан баш тарттым, угыз ябгуыннан[1] баш тарттым. Син икейөзле! Балыкчы куышында кайгылы төннәреңне уртаклашканда Тәңкә кирәгие, инде би булгач, Алмыш хан кызы Аппак кирәк булган!

Башын югары тотып, ул өйдән чыгып китте.

---

[1] Ябгу — башлык.

Кичкә Ямгырчы би кунакларга аш-су ясады. Төн урталары якынлашыр алдыннан, ашап-эчеп, күңел ачып туйгач, би үзенең кунакларын мунча керергә алып китте.

Мунчадан кайтуга, түрдә елмаеп утырган Тәңкәне күреп, Тотыш бераз гына аптырап калды.

— Ник килдең?— диде Тотыш, ачуланган сыман итенеп.

— Сөйләшер өчен,— диде Тәңкә.

Күп тә үтмәде, өйгә өлкән яшьтәге бер хатын килеп керде. Кулына ул яшь бала тоткан иде.

Тотыш аптырауның соңгы чигенә җиткән иде. Имеш, аның углы бар. Тотыш белән беренче углы.

— Без сине икәүләп көттек, әттә! — диде Тәңкә, юаш кына, углы булып.— Атым минем — Күке!

Тотыш, баланың берәр җирен имгәтүдән куркып, иплән кенә аны кулына алды, тезенә бастырды. Аның нәни көчен тоеп, аның йомшак тәпиләрен, кулларын тоеп, Тотыш көлеп җибәрде.

— Атаң ич,— дигән булды Тәңкә, углына эндәшеп.— Ул әнннәне оныткан, син дә аны оныттыңмы әллә?

— Мин «әннә»не онытмадым,— диде Тотыш.— Әннәсе дә, углы да... үземнеке!

— Тотыш?! — диде Тәңкә, аның күзләренә карап, аның чынмы, юриме әйткәнен белергә тырышып.

— Әйе,— диде Тотыш.— Сүзем сүз: сине дә, углымны да беркайчан ташламам!

Шулай итеп, бер яшьлек тә берничә айлык Күке беркемгә дә баш бирмәгән кырыс атасын аяк астына салды да куйды. Тотыш белән Болгарга Аппак янына ашкынган какшамас күңелендә нидер кинәт кителеп төшкәндәй булды.

Дүртенче көнне аның өенә — Тәңкә югында — Майчан аксакал белән субашы Котан килеп керде.

— Тотыш би, углым,— диде Майчан аксакал.— Безгә нидер эшләргә кирәк.

— Без менә үзара киңәштек тә сиңа әйтмәкче булдык,— диде үги ата.— Моннан ары икеле-микеле яту ярамас безгә. Ямгырчы бигә кода булып керик тә, калымны түлик тә, кайтыйк та китик! Алмыш ханга никтер аяк тартмый...

— Үземчә эшләрмен! — диде Тотыш. — Иң элек Аппакны алып кайтам, Тәңкә белән углымны — соңыннан.

Шул ук сүзләрне ул Тәңкәгә дә әйтте.

— Син әле дә онытмадыңмыни аны?— диде Тәңкә, арты белән борылып.

— Көн дә җир өстенә чыга торган кояшны онытып буламы?— диде Тотыш.

— Ул, алайса, синең өчен кояш?— диде Тәңкә, никтер тыныч кына.— Мин кем?

— Син... син — ай!

— Минем ай буласым килми,— диде Тәңкә, шул ук салкын бер төшенкелек белән.

— Мине ыру җибәрде. Мин ыруга, анама каршы килә алмыйм,— диде Тотыш.

Тәңкә кырт кына читкә борылды да, яшьле күзләрен күрсәтмәскә тырышып, ашыгып-кабаланып, өйдән үк чыгып китте. Шул китүдән ул бүтән килмәде.

Икенче көнне кич, караңгы төшкәч, аны Ямгырчы би янына чакырдылар.

XVI—XVII

— Ха-ха! — дип кычкырды Ямгырчы, Тотышны күрү белән.— Бик сагынып көттем мин сине, ике ел буена көттем шушы очрашуны. Калым белән, байлык белән төшүеңне көттем. Инде менә монысында эләктереп алдым. Шулай да әле утлы табада кыздырып ашамадым. Кызымның сүзен тыңладым. Инде түземлегем төкәнде. Кызым миңа барысын да сөйләде. Ха-ха! Тотыш алып! Телим икән кыздырып ашыйм, телим икән итеңне каклап куям. Син әллә чынлап та үзеңне Алмыш ханга җибәрерләр дип уйлыйсыңмы? Казаякларны чебеш урынына кырганыңны оныткандыр дип уйлыйсыңмы?

Ямгырчы би авызыннан утлар чәчеп тузынганда, Тотыш ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышты. Ямгырчы бинең мыскыллы янаулары соңгы чиккә җиткәч, Тотыш түзмәде, кылычын суырып чыгарды да...

Тотыш аның шул соңгы «ха-ха»сын гына ишетте. Аяк астындагы палас кинәт убылып китте. Тотыш каядыр аска, караңгыга ычкынды. Кинәт ачылып киткән баз капкачы шундук кире ябылды.

Кызып китеп, атасына әләкләгәндә Тәңкә аны аз гына да кызганмаган иде. Инде аның юклыгын күргәч, ул куркудан шашар чиккә җитте. Ул үзенең ышанычлы кешеләрен эзләп тапты. Алар аңа барысын да төкми-чәчми сөйләп бирделәр.

Кинәт аның йөрәге бөтенләй икенче төрле тибә башлады. Тирән баз ишегенең ачкычы атасының тимерле тартмасында саклана иде. Ул, башта өенә кайтып, үзенең барлык алтын-көмешләрен янчыгына тутырды да тиз атасы өенә килде. Берни әйтмичә, ул тышкы ишек төбендәге сакчыга бер уч көмеш акчалар бирде.

— Синең өчен берни кызганыч түгел, кызым,— диде сакчы, тыныч кына.— Син монда торып тор. Мин тиз килермен.

Күпмедер вакыттан соң караңгыдан ике карачкы килеп чыкты. Аларның берсе — әлеге өлкән яшьләрдәге ишек сакчысы, икенчесе Торымтай иде.

XVIII

Торымтай аны иңбашына күтәрде. Алар караңгы, тар баскычтан өскә үрмәли башладылар. Тышта инде баздагы кебек үк караңгы түгел иде. Торымтай иплəп кенә Тотышны аягына бастырды.

— Ашыгырга кирәк! — диде Тәңкә.— Урдада калган кешеләрегезне коткарырга да коралларыгызны алырга кирәк.

Тотышны яр буенда калдырып, Торымтай берничә ир белән тиз генә җир тишегенә таба йөгерде. Күп тә үтмәде, ташлы тар сукмактан бер-бер артлы тезелеп төшеп килгән кешеләр — акбүреләр күренде.

Каеклар бер-бер артлы китә башладылар. Яр буенда акбүреләрнең ике-өч каегы гына торып калды. Тотыш би исә Торымтай белән киткән ирләрне, аңардан да бигрәк Тәңкәне көтте. Тәңкә аңа таба килә башлады. Анда әлерәк кенә күзгә бәрелеп торган ашыгу-кабалану да, бизгәк тоткандагы сыман ялкынланып яну да юк иде. Андагы бу салкынлык, андагы бу ныклык Тотышны өркетеп җибәрде. Ул, аның күзләренә туры карый алмыйча, башын түбән иде.

Тотыш, ике кулын күтәреп, иплəп кенә аның беләкләреннән тотып алмакчы булды.

— Юк! — диде Тәңкә, кулларын тартып алып.— Бар, кит. Син иреклe.

Тотыш би авыр гына көрсенеп куйды.

— Мин килермен. Көт,— диде ул, иплəп кенә.— Углымны сакла.

— Килмә,— диде Тәңкә.— Сиңа ыруында мин авыр йөк булачакмын. Мине оныт. Бәхетле бул.

— Ачуланма миңа. Бай бул, сау бул,— диде Тотыш би.

— Җитте! Кит! Кит! — дип кычкырды кинәт Тәңкә, йөрәк түреннән чыккан бер ачыну белән. Шул ук мәлдә ул кәзлек тартып чыгарды. Ул, кәзлек сабын Тотышка сузып:

— Соңгы үтенечем: када миңа, Тотыш! — диде.

Тотышның үзеннән-үзе сузылган кулы кире тартылды. Кәзлек төшеп китте.

Ышану буенча, очлы тимерне кулдан төшереп җибәрү яманга юрала иде. Тәңкә кәзлеген алып тормады, коты алынып, читкә сикерде, йөгерә башлады.

— Тотыш, тизрәк, тизрәк! — дип кычкырды Торымтай каектан.

XIX

«Шушы микәнни инде аерылышу?» — дип уйлады Тотыш, авыр, кыен бер тойгы кичереп. Ул — Тәңкә җиңел генә, кыр кәҗәсе кебек кенә йөгергәләп менеп киткән текә яр башына шактый озак карап барды.

Би утырган каек алданрак кузгалган каекларны куып җитәргә тиеш иде.

Шулай ашыгып, кызулап барганда, ишкәкчеләр ярда ниндидер нәрсә күреп алдылар.

Туктале, кем соң бу? Тәңкә... түгелме соң?

— То-ты-ы-ыш! — дип кычкырды шул чакны күк читендә басып торган кеше.

Тотыш аягына басты, ике кулын авызына куеп:

— Тәңкә-әәә! — дип кычкырды.

Кешеләр генә түгел, киң Чулман да, исе китеп, тып-тын калды. Каралҗым яр буйлары, биек нарат лар, су өстендә очкан акчарлаклар, керәшәләр — барысы да, пошынып, борчылып, упкын кырыена барып баскан тынгысыз йөрәкне күзәттеләр. Ник баскан ул анда куркыныч таш өстенә?

Соңгы баб

I—III

Ямгырчы бигә Алмыш ханнан тартык килеп төште. Тартык Ямгырчы бигә ханнан кичекмичә бөтен ыруы белән Өчкүл янына килеп җитәргә дигән боерыгын тапшырды.

— Ни булды? — диде би, сагая калып.

— Болгарга җырактан, Багдадтан илчеләр килә! — диде тартык, күтәренкелек белән. — Барлык мөселманнарның башы

әл-Моктадир үзенең ышанычлы кешеләрен җибәргән. Ханга буйсынган барлык ил-көн, барлык ырулар, ислам диненә күчкәнлекләрен танып, хәлифә илчесе алдында ант бирәчәкләр.

Алмыш хан урдасына башка яклардан да төркем-төркем булып кешеләр килделәр. Менә, кешеләрне тын калырга өндәп, быргылар кычкырды. Хәлифә илчесе Ибн Фадлан бөтәрләнгән битекне алды да укырга җыенды. Башту углы Габдулла шундук аның сүзләрен болгар теленә әйләндереп барды.

Хәлифә битеген укып бетергәч, бөтен киң болынны тутырган кешеләр, җирне-күкне дер селкетеп, бер авыздан: «Алла!» — дип кычкырдылар.

Алмыш хан зур авыр йодрыгын йомарлады да кулын күтәрде:

— Болгарлар! Болгар җиренең барлык иле-көне, ырулары! — дип кычкырды Алмыш хан, көчле, күтәренке бер тавыш белән.— Моннан соң безнең барыбызның да Тәңребез бер генә. Ул да булса — Алла! Аллага табынган, аны бер дип белгән барлык мөселманнар тигез! Безне изге хәлифә үзе таный. Бүгеннән башлап мин, Алмыш хан, үземнең Хазар каганына бәйсез икәнлегемне белдерәм. Бүгеннән башлап Болгар йорты җирдә үзенә ирек даулаячак, үз көнен үзе күрәчәк, үз язмышын үзе сайлаячак. Күктә кояш сүнми торып, Болгар йорты сүнмәячәк.

IV

Койтым бикә Шуран катауга туктады. Ямгырчы би белән аның арасында зур гына сөйләшү булды. Койтым бикә Тотыштан туган Күкене үзенә биреп җибәрүне сорады. Тотыш инде юк, диде, аның кайдалыгын беркем белми, диде. Күке минем бердәнбер юанычым, диде. Ямгырчы би ике арада мондый сөйләшү буласын, күрәсең, алдан ук көтеп торган иде.

— Күкенең анасы бар,— диде ул.— Күке сиңа юаныч булган кебек, анасына да юаныч.

— Чакырт кызыңны! — диде Койтым бикә.

Койтым бикә, киленен кызганып, аңа углының кайда ничек югалуын әйтмәде. Ул аңа: Тотыш Ител аръягында юлбасарлар белән сугышта үлгән, ахрысы, дип ялганлады.

— Нишлисең, бирәсеңме балаңны?— диде ата кеше үзенең кызына.

— Мин углымны беркемгә бирмим,— диде Тәңкә, каны качкан иреннәрен чәйнәп.— Анам каршы килмәсә, мин аның белән китәрием... углымны алып.

— Мин синнән шуны гына көттем дә, кызым! — диде Койтым бикә, елмаеп, Тәңкәне кочагына алып.

— Минем тагын бер кешем бар,— диде Тәңкә, оялып кына,— Торымтайны да... каршы килмәссезме, анам?

1969 ел, Казан

«Итил суы ака торур» романын өйрәнү юллары

Проблема. Без «Роман-хроника», «Истәлекләр», «Тарихи роман» дип аталган берничә әсәр өйрәндек. Андый әсәрләргә анализны нәрсәдән башларга, ничек таркатырга һәм гомумиләштерергә кирәклеген беләбез.

Ләкин без өйрәнгән ул әсәрләр күп дигәндә йөз ел элек булып үткән вакыйгаларны сурәтлиләр. Нурихан Фәттах язган чорны исә автор үзе дә күрмәгән (мәсәлән, Г. Бәширов, И. Салахов үзләренең башларыннан кичкәннәрен язганнар), ул чор вакыйгаларын ачыклап килүче истәлекләр, документлар да (М. Галәү язган чордагы кебек) юк диярлек.

Романның бу үзенчәлеге анализ вакытында өстәмә бәя бирүне сорый. Ул бәя ничек табыла ала?

Әдәби әсәрен тарихның иң ерактагы вакыйгаларына багышласа да, әдип барыбер үзе яшәгән чор вакыйгаларын күздә тота. Романның бүгенге көн өчен дә актуаль булуын ничек табарга?

Бу сорауларга җавапны анализ гына бирә ала.

Романның сюжеты. Зур күләмле әсәрләрне дәреслекләргә кыскартып кына сыйдырырга мөмкин. Бу юлы да без, гадәттәгечә, әсәрнең төп сюжет сызыкларын, төзелешен, символларын, метафора-вакыйгаларын саклап калырга тырыштык.

«Итил суы ака торур» романында ике сюжет сызыгы бар. Аларның берсе дәүләт төзү вакыйгаларын, икенчесе әсәрнең төп герое булган Тотыш язмышын төзүче вакыйгаларны үзара бәйли. Сюжет сызыклары әледән-әле үзара кисешеп торалар, бер-берсенә нык тәэсир итәләр. Берсендәге вакыйга икенчесендәге башка бер вакыйганың сәбәбе була. Ләкин анализ вакытында без аларны, аерып, берәм-берәм өйрәнергә тиеш булабыз.

Дәреслектә дәүләт төзелешенә багышланган вакыйгалар, нигездә, сакланды. Көчле, иректе дәүләт төзү өчен көрәш романда шул эшне башлап йөрүче ханнар, биләрнең эчке каршылыклары белән бергә кушыла. Кызганычка каршы, оста

калəм иясе тарафыннан язылган бу кичерешлəрнең бер өлеше дəреслеккə кермəде.

Тотыш язмышын күрсəткəн сюжет сызыгында да герой кичерешлəре тулысынча дəреслеккə керə алмады. Тотышның Ямгырчы базыннан котылганнан соң күргəннəре турында да əсəрнең тулы вариантын укыгач кына белə аласыз.

Романның төзелеше. Роман жанрының иң гомуми төзелеше төп геройның тирə-юнь белəн конфликтыннан гыйбарəт булуын искə төшерик.

Төп геройның Тотыш булуын, аңа əсəрдəге ике сюжет сызыгының берсе багышлануыннан белəбез. Конфликтның мəнфəгатьлəр көрəше булуын искə төшерсəк, Тотышның кемнəр белəн һəм ни өчен конфликтка керүен ачыклау җиңелəя төшə. Хəзер конфликтларны барлыйк.

1. Көчле, дəртле, үз гамəллəренə, кылган эшлəренə җавап бирү дəрəҗəсенə күтəрелеп җитмəгəн яшь Тотышның үзен күрсəтəсе килə. Үзенең көчен, җитезлеген ул фəкать сугышта гына күрсəтə ала. Шуңа күрə егет ил агаларының килешеп берлəшү сəясəтенə каршы чыга.

2. Тотыш — үзенең табигате белəн ирек сөюче шəхес. Аның ирекка омтылышына йолалар, законнар каршы төшə.

3. Тотыш башкалардан үзенең көче, чибəрлеге белəн аерылып тора. Тирə-юнь үзеннəн өстен кешегə бервакытта да битараф булмый. Ул аңа йə табына, йə аны юкка чыгарырга тырыша. Тотышның горурлыгы үзе турында гына уйлау һəм аның əдəпсезлеге итеп кабул ителə. Үзендə фикер, телəк, сайлау ирекен саклап калу өчен, Тотыш гомере буена көрəшергə тиеш. Тотыш нинди генə көчле булмасын, йолаларны да, тирə-юньне дə, ханнар сəясəтен дə берьялгызы гына җиңə алмый. Шуңа күрə ул үлəргə тиеш.

Романның тарихи чынлыгы. Сугышлар, урыннан урынга күчеп йөрүлəр, янгыннар һəм, ниһаять, дəүлəтчелекне югалту нəтиҗəсез калмаган — борынгы болгарлар турында рəсми кəгазьлəр, фəнни хезмəтлəр, истəлеклəр, матур əдəбият əсəрлəре дə сакланмаган. Шулай булгач, əдип ул заманны ничек дөрес итеп күз алдына китерə ала соң?

Фəн өйрəтүенчə, тарихи вакыйгалар бер үк халыкның үзендə дə, башка халык язмышында да кабатланалар. Тарих аларны коллык җəмгыяте, крепостнойлык мөнəсəбəтлəре аша үткəрə. Җəмгыятьнең нииндиендə генə яшəсəлəр дə, халыклар үз дəүлəтлəрен, ə аңа кадəр ыруларын ныгытырга тырышалар.

Шулай иткәндә генә дөньяда ирекле кешеләр булып яши алуларын яхшы беләләр.

Ыруларны һәм дәүләтләрне берләшеп, уртак тел табып та, башка халыкларны яулап, алар исәбенә дә ныгытырга мөмкин. Бер-берсенә капма-каршы булган ике теләк, власть өчен көрәш рәвешен алып, тарихның буеннан-буена сузыла.

Тарихның шул рәвешле кабатлануы язмышлары билгесез булган халыкларның язмышын өйрәнүгә ярдәм итә.

Нурихан Фәттах шулай иткән дә: ул үзенең хыялын шундый фәнни нәтиҗәләргә буйсындырган. Ә фәнни нәтиҗәләре — тарихта армый-талмый эзләнү җимеше.

Романның тарихи чынлыгы авторның үзе тапкан фәнни нәтиҗәләренә нигезләнсә, вакыйгаларда катнашкан персонажларның чынлыгы аларның кичерешләрен дәлилләү дәрәҗәсенә бәйле.

Тарихның ерак чоры турында ни язсаң да ярый, үткән заман әдипләрне дә, тарихчыларны да җавапка тартмый. Шулай булса да Нурихан Фәттах борынгы болгарларның — безнең бабаларыбызның чиксез батырлыкларын күрсәтү кебек отышлы вакыйгалар язу белән мавыкмаган. Киресенчә, аксакаллар гына уйлап таба торган нәтиҗәгә килгән. Батырлык көчтә дә, гайрәттә дә, куркусызлыкта да түгел, сабырлыкта, ди. Зирәклекнең бер нәтиҗәсе буларак сабырлык борынгы бабайларның иң күркәм сыйфатлары итеп сурәтләнә.

Романның исеме. «Ител суы ака торур» исеменең мәгънәләрен роман эчендәге бәйләнешләрдән табабыз.

Эпиграф белән бәйләнеше. Роман исеме борынгы җырның беренче юлы. Бу җыр эпиграф булып килә. Шуңа күрә исемгә җырның тулы эчтәлеге күчә. Хәзерге тел белән әйтсәк, аның эчтәлеге мондый: Идел су ага да ага, кыя төбенә кага да кага. Башкача әйтсәк, Идел ярларына сыеша алмый, ирекә омтыла. Ирекә чыга, җәелә һәм, шулай итеп, тереклек өчен уңайлы шартлар тудыра.

Метафора вазифасын үтәүче образның мәгънәләре күптөрле. Без шуларның икесен әйтеп үтик. Автор үзе борынгы дип әйткән җырда Иделнең заман агышын күрсәтүче вакыт мәгънәсе алуын күрәбез (ака торур). Идел ниндидер бик куәтле ил дә (ярларына бәрә, киңәя, тереклеккә уңай шартлар тудыра).

Эпиграфтагы беренче җыр борынгы заманныкы дип әйтелсә, икенчесен Нурихан Фәттах хәзерге заманныкы ди. Икенче

җырның мәгънәсен, димәк, хәзерге заман кешесен күз алдында тотып эзләргә кирәк.

Роман исеменең эчтәлеге, эпиграфтан тыш, әсәр эчендәге вакыйгалар бәйләнешендә тулыландырыла. Роман яз җитүен Идел агышы аша сурәтләү белән башлана, һәм монда Идел заман агышы булып килә.

Идел агышы әсәрнең барлык бабларында берничә мәртәбә кабатлана, һәм һәр кабатлануда аңа яңа эчтәлек өстәлә бара. Алтынчы бабның IX бүлегендә, мәсәлән: «Анда (Иделдә), төрек ирләрендәге сыман, сокландыргыч батырлык та, тыелгысыз кыргыйлык та, төрек кызларындагы сыман күреп туймаслык күркәмлек тә, тыйнак юашлык та бар иде».

Иделне башка ил сәүдәгәре шулай күрә.

Алтынчы бабның беренче бүлегендә Идел Тотыш би күзе белән бәяләнә: «Олуг Ител! — диде Тотыш би, туган җиренең бөек суына эндәшеп.— Исән-имин илтеп тапшыр мине сөйгәнемә! Юлымда ак җәймә бул, изге Ител! Мин, Тотыш би, синең биләмәңә кердем, синең тигез юлыңнан барам. Ачуланма миңа, усалланма, каекларымны каплама, кешеләремне суырма. Менә сиңа калай итеп көмеш йөзегемне бирәм, уналты бөртек көмеш акча бирәм, гүзәл Ител!»

Шактый вакыт үткәч, Тотыш тагын Идел белән сөйләшә:

«Әйтче, Ител, күрдеңме син минем анамны, күрдеңме син минем Тәңкәмне? Күрдеңме син минем каным нәни углымны? Уйлыйлармы алар мине, көтәләрме алар мине, туганым Ител?

Ител ага да ага... Алар монда икәү. Ителнең яртысы — Чулман. Алар кавышканнар, алар табышканнар. Башкаларда аларның эше юк...

Ител ага да ага... Әле кайчан гына аксыл-яшькелт иде, инде әнә кара төскә керде. Елкылдап, тере кебек кыймылдап, ыңгырашып ага да ага. Кайчаннан бирле агасың син шулай, Ител? Моннан йөз ел элек, мең ел элек әлегечә туктамыйча актыңмы син? Күптән, бик күптәннән синең яр буенда әлегедәй берәр җегет утырдымы шулай сагышланып?»

Романдагы Идел турындагы бу сурәтләр әсәр исеменә нинди эчтәлек өсти? Романдагы сурәтләр һәм вакыйгалар бәйләнешендә алган яңа эчтәлекләре белән «Ител суы ака торур» образы әсәр эчтәлеген аңларга ничек ярдәм итә? Ул кадәресен һәркем үзенчә сөйли ала.

Романның актуальлеге. Актуальлеге дип әсәрнең хәзерге заман куйган сорауларга җавап бирә алуына әйтәләр. Актуальлек борынгы заман вакыйгаларының бүгенге көн вакыйгаларына охшавы түгел, ул — вакыйгаларның бүгенге көнне күздә тотып язылуында.

Икенче эпиграфында әдип: «Кызганам моңлы баланы, Үзем моңлы булганга»,— ди. «Бала» — Тотышмы, әллә бөек Болгар дәүләтенең бүгенге кызганыч хәлеме?

Тотыш булса, ни өчен соң әле әдип аны кызганырга мөмкин? Бәлки, әдип үзе дә, борынгы батыр кебек, башкаларга охшамавы аркасында кимлек-хурлык күргәнгәдер?

Нурихан Фәттахны милләтнең 70 нче еллардагы хәле моңландыра дип әйтергә хакыбыз бармы?

Габдулла Тукайның «Шүрәле»сен искә төшерик. Поэмасында шагыйрь, бөек Болгар дәүләтенең куәтен, кешеләренең батырлыгын, дәүләтнең мөстәкыйльлеген күз алдына китереп, шул заманны үзе яшәгән чордагы милләт белән чагыштыра һәм:

> Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе:
> Аh! — дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе,—

дип уфтана. Романда Габдулла Тукай сүзләре юк. Әмма әсәрнең сюжеты, вакыйгалары, эпиграфлары бәйләнешләре «Аh! — дисең, без ничек болай соң?» соравын кабатлыйлар.

Биремнәр һәм сораулар

1. Тотыш, тоткынлыктан Тәңкә ярдәмендә котылгач, Болгарга исән-имин килеп җитә. Анда Аппакның Хазар каганына (ханына) кияүгә бирелүен белә. (Китабыгызда бу вакыйгалар юк.)

Тотыш холкын хәзер яхшы беләбез. Әгәр дә сез үзегез китап авторы булсагыз, Аппакның Хазар дәүләтенә китүен белгән Тотышны ни эшләтер идегез? Аның Болгар ханына мөнәсәбәтен, үзе белән Болгарга килгән ырудашларына мөнәсәбәтен (алар арасында Тотыш урынына би булырга теләүче Котан да бар) ничек язар идегез? Кайларга җибәреп, кайлардан кайтарыр идегез?

Сюжетны шул рәвешле дәвам итеп, киңәйтелгән план языгыз. Планның һәр бүлегендә бер вакыйга булырга тиеш.

2. Сюжет сызыклары турында аерым-аерым сөйләгез. Аларның кисешкән урыннарын күрсәтегез. Романда ике сюжет сызыгының нигә кирәклеген аңлатыгыз.

3. Сабырлык — батырлык белән тиңләшерлек сыйфат. Дәүләт башында торучылар өчен сабырлык хәтта батырлыклардан да өстен, дидек. Ни өчен шулай?

4. Алтынчы бабның IX бүлегендә Нурихан Фәттах: «Болгарда тормыш талгын гына, ашыкмыйча гына ага иде»,— дип яза. Бу җөмләнең эчтәлеген ачыгыз.

5. «Ител суы ака торур» исеменең төрле бәйләнешләргә кереп алган эчтәлеген барлап чыгыгыз.

6. Романның актуальлеге турында, дәреслектә әйтелгәннән тыш, тагын нәрсә әйтә аласыз?

7. Эпиграфтагы икенче җырга автор хәзерге заман халык җыры дип куйган. Шулай булгач, ни өчен анда «Ага сулар Болгарга» кебек юллар бар?

8. Тәңкә образына бәя бирегез.

9. Тәңкәнең әтисе Ямгырчы образына бәя бирегез.

10. Тотышның әнисе Койтым бикәгә бәя бирегез.

Гариф Ахунов
(1925—2000)

Гарифҗан Ахун улы Ахунов 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында туа. Җидееллык мәктәпне Казанбаш авылында тәмамлый. Сугыш елларында гади колхозчы, аннары, бик яшь булуына карамастан, кырчылык бригадасы бригадиры, клуб мөдире була. Тиз арада буяучы һөнәрен өйрәнеп ала һәм ике ел буена буяучы булып эшли.

1947 елда Арча педагогия училищесын тәмамлый. Аннары Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. «Галләм сорау ала» исемле беренче хикәясен диплом алган елда бастыра.

Шуннан соң Гариф Ахунов ару-талуны белми яза да яза. Бер-бер артлы роман-повестьлар, пьесалар, хикәяләр, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре бастырып кына тора.

Төрле жанрлы, күп санлы әсәрләрен язган арада, ул «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналының җаваплы секретаре булып тора. Әлмәттә Язучылар берлеге бүлекчәсен оештырып, аны җитәкли. Тиздән Гариф Ахуновны Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп сайлыйлар. Шул елларны ул РСФСРның Югары Советы депутаты вазифасын да башкара.

Гариф Ахунов, нинди генә дәрәҗәле урыннарда эшләсә дә, холкын үзгәртмәде. Һәр эшкә җиң сызганып тотынды, элеккечә ачык йөзле, кешеләр белән бик җиңел таныша, ярдәмчел булып калды.

Буяучы һөнәренә һәвәслеген әйткән идек, шуның өстенә ул әле менә дигән рәссам һәм телнең милли нечкәлекләрен, ритмикасын, интонациясен бик яхшы тоя торган тәрҗемәче дә.

60 нчы еллардан соң иҗат иткән әдипләр арасында ул, мөгаен, иң күп иҗат иткән язучыдыр. Аның «Хәзинә» исемле

күләмле, киң колачлы романы Татарстан нефтьчеләре турындагы иң җитди әсәр дип бәяләнде. Бу әсәр сюжетына нигезләнеп, нәфис фильм да эшләнде.

Гариф Ахуновның «Ардуан батыр», «Чикләвек төше» повестьлары, «Идел кызы» романы татар әдәбияты тарихына соңгы елларда иҗат ителгән күренекле әсәрләр белән бергә керделәр.

Дәреслектә «Идел кызы» романының беренче китабы белән танышырсыз. Ә әдипнең башка әсәрләрен үзегез укып белерсез дип ышанып калабыз.

ИДЕЛ КЫЗЫ

(Роман)

БЕРЕНЧЕ КИТАП

Беренче башлам

I

Бу төнне Габбас мулла йокы күрмәде.

Тышта буран үкерә. Инде өченче көн туктаусыз котырынган җил-буранның, әле йорт нигезенә үк килеп җитеп, ач бүреләр көтүе сыман, куркыныч авазлар белән улавы, әле бөтенләй ерагаеп, кайлардандыр әйләнеп кайтуы бозлы тәрәзә пыяласына, урам караңгылыгына төбәлеп утырган Габбас мулланың җанын тетрәтә иде. Буран тавышы тынып торган арада, ул, колагын шыңкайтып, зиһенен җыеп, икенче бер тавышны, инде кайчаннан бирле зарыгып көткән сабый бала тавышын ишетергә тели...

Аскы өйдә Шәмсениса абыстай балага авырый.

Тик һаман сөенче алырга килүче юк иде әле.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн, адәм баласы адашып үләрдәй ачы суык буран әллә ниткән куркыныч хәлләр вәгъдә итә төсле. Әгәр Шәмсениса баласын таба алмаса, аны Салагышка фельдшерга алып барырга туры килсә? Юлдаш юк Габбас муллага. Ат караучы Бөкре Гафият (кара инде, юньсез!) нәкъ менә шул көнне кичтән, сәрхушлык өянәге кузгалып, каядыр китеп олакты! Ничәмә-ничә кат куңеленә беркетте Габбас: эчүдән айныган көннең иртәгесен үк куып чыгарам, диде. Булдыра алмый. Гафият кебек ат җанлы кешене көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың.

Һай шул сәрхушлыгы булмаса!

Авыл көтүчесенең хатыны Бибисара күз яше белән елап килде:

— Биздерәсеңме, хәзрәт, шул бөкреңне бездән. Иремне эштән чыгара бит инде. Ай саен чиреге белән көмешкә эчәләр...

Бөкре Гафиятне Габбас мулла бик хәтәр тиргәп ташлады. Гафият исә мулланың вәгазен башын ия төшеп, үкенгән сыман, юаш кына тыңлап торды, аннары әйтте:

— Менә син, Габбас, бер ел элек кенә хәерче Җамалетдинның ундүртенче баласы иең. Кем сине мулла итте? Алыпсатар Габделхәлим. Кырык яшьлек тол абыстайга ир кирәк булды — вәт сине өйләндерделәр...

Эчү өянәге кузгалмаган булса, Гафият бүген аның янында булыр иде... Юк бит, юк, юньсез!

Гафиятнең сүзләре, янә дә исенә төшеп, йөрәгенә үткен хәнҗәр булып кадалды.

Язмышың шулай булгач, нихәл итмәк кирәк. Мулла булам дип ашкынып тора идемени Габбас? Иж-Буби мәдрәсәсендә укып чыккач, ул бит Зартугайда калам дип тә черәшмәде. Казакъ даласына мөгаллимлеккә китеп барды. Барган җирендә яраттылар аны, өрмәгән җиргә утыртмадылар. Алар аны гомер бакый үзләрендә калдырырга, өйләндереп, йортлы-җирле итәргә дә ризалар иде. Бу фани дөньяда сагыш дигән тойгы да бар бит әле. Туган-үскән якларын үләр чиккә җитеп сагыну аны, казакъ иле белән саубуллашып, янә үзе укып чыккан Иш-Бубига кайтып төшәргә мәҗбүр итте.

Нияте халыкка аң-белем таратып, дөньяга мәгърифәт нуры сибеп яшәү иде.

Ләкин син уйлаган белән генә түгел икән шул. Дөньяда Габделхәлим абзаң бар әле. Ул әнә синең алгы көнеңне матурлык итеп күрергә тели. Зартугайның икенче мәхәллә мулласы Гыйматдин вафат булган. Хәзрәтнең кырык ике яшьлек хатыны Шәмсениса абыстай тол калган. Үзе тулып пешкән, чибәр, үзе укымышлы, үзе череп чыккан бай, җитмәсә, балачагасы да юк икән. Гыйматдин мәрхүмнән кара туры айгыр, ике бия, абзар тулы мал-туар, төлке толып, чарлаклап салынган алты почмаклы йорт торып кала.

— Менә синең, менла кем Габбас, рәхәткә тиешер көннәрең! — диде кызыл малчы Габделхәлим абзый.— Сасы мажик балалары белән мәдрәсәдә тынчып ятканчы, Гыйматдин хаҗиның варисы итәм мин сине. Түбән мәхәлләгә мулла итеп куйдырам!

Габбас, буран тавышы ерагайган арада, аскы өйдән килгән тавышларга колак салгалап торды.

Габбасның үлеп тә шул яшь тавышны, дөнья ярып кычкырган бала тавышын ишетәсе килә. Шул бала дөньяга килсә, ул Шәмсенисаны ярата башлар кебек тоя иде.

Шәмсениса остабикә буйга узгач, Габбас аңа йорт эшен дә эшләтмәскә тырышты. Каралты-кураны, мал-туарны Гафият карады. Атларга башакны Габбас үзе болгатып бирде, сыер абзарын үзе җыештырды, тумыштан крестьян баласы булгангадыр, бу эшләр аңа бер дә авыр тоелмый иде.

Ат караучы итеп Бөкре Гафиятне алган икән, ул аны эш эшли алмаганнан яки эшләргә гарьләнгәннән түгел. Сөләйман хәзрәт алдында абруен төшерергә теләмәгәннән генә алган иде. Мулла булсаң мулла бул — хезмәтчеләрең янында булсын!

Габбасның канына тоз салган, бертуктаусыз каныккан кеше әнә шул Югары мәхәллә мулласы Сөләйман иде инде. Гыйматдин хаҗиның сәфәрдә үлеп калганын ишеткән сәгатьтән башлап, Сөләйман хәзрәт мәрхүмнең барлык мал-мөлкәтен күңеленнән үзенеке янына кушып куйган, казакъ ягыннан кайткан йолкыш бер мөгаллим ул хәзинәгә нәфесен сузар дип, башына да китермәгән иде. Ул аны указлы мулла иттермәде.

Чолан ишеген көч-хәл белән бикләп, югарыгы катка менеп барганда, болдырдан ашыгып төшүче берәүгә килеп бәрелде.

Караңгыда хатын-кыз тавышы:

— Хәзрәт... син түгелме?— дип каушап дәште.

— Көмеш түтәй, синме? Шәмсениса бәбәйләдеме әллә?

— Кыз бала тапты.

Габбас мулла, утызлы лампаны кабызып, аны өстәл турысына төшерде дә өстәл янына утырды.

Каурый каләмне кара савытына манды, вәкарь белән ашыкмый гына яза башлады: «1901 сәнә, 17 гыйнуар, җомга көн, иртәнге сәгать алты. Кызым Нурия туды. Гасыр башында. Бәхетең белән, төкле аягың белән, балам!»

Аннары ул башын өстәлгә салып, тавышсыз гына, мул яшь түгеп елап җибәрде.

II—V

Нурия, тәпи басып йөри башлаганнан алып, курчак яратты. Урамга чыкмый диярлек, көннәр, атналар, айлар буе тәрәзә каршысында курчаклары белән уйный. Офык читенә аккош

мамыгыдай ак болытлар карап торган бер көнне әтисе белән әнисе Нурияне тегермән буасы янына алып төшәргә булдылар. Алар артыннан сүзсез генә ияреп йөргән Шәмсениса абыстай, тизрәк өйгә кайтырга ашыктыра башлагач, Габбас мулла, юаш кына итеп:

— Йөрик әле бераз. Сәйранга чыккан юк бит,— дип куйды. Өчәү бергә кичке бакча юлыннан бик озак йөрделәр. Габбас мулланың күңеле әйтеп бетергесез моңсу иде. Аның кулыннан бәләкәй кулы белән тотып барган боек күңелле Нурия дә, сәгатьләр буе сүзсез йөргән Шәмсениса абыстай да аның гаиләсе түгелдер, болар таң алдыннан керә торган рәхәт һәм җиңелчә бер төш кенәдер кебек тоела иде.

Габбас муллага нидер җитми, алсу офыктагы каралҗым наратлар да, еракта тоташ стена булып күренгән Бояр урманы да әллә кайларда, күгелҗем томаннар аръягында калган балачакның серләрен саклаучы, сагышларын көчәйтүче җанга газиз нәрсәләр булып тоелалар. Мәңге кайтмас яшь гомер җанда үксеп елый иде.

Кичен кояш баегач, Габделхәлим абзый арбадан җиңел генә сикереп төште, дилбегәне Гафият кулына ыргытты.

— Саумы, Гафият! Мулла өйдәме?

Гафият кырынмаган ияген сыпырып куйды:

— Яшь мулла кәефсез. Син китергән куян үлде. Бәләкәй мәхдүмә көйсезләнә,— диде.

Габделхәлим абзый, юл кәҗәненең чабуларын җилфердәтеп, күн итекле аяклары белән каты-каты басып, болдырга таба китте.

Габбас мулла ике куллап килеп күреште.

— Дөньялар үзгәрә, Габбас,— диде Габделхәлим абзый, чәйнектән беренче чынаякны агызганда.— Хөррият заманнары килә. Пайтәхеттә, Мәскәүдә чуалышлар бара. Казан унирситетында ыстудиннәр гауга куптара... Беләсеңме нәрсә... Таминдар бай Тураев белән сөйләштем. Зартугайга мәптек-шкула салып бирергә ризалыгын белдерде. Әмма да ләкин, ди, ул мәптек-шкулада укыту рәтен белә торган учитель вә һәм дә мөгаллимнәре булса гына салдырам, ди.

Габбас, алсуланган ирене белән мыек очын чәйнәштереп, беркавым дәшми утырды.

— Андый мәктәпне Таминдар бай, акыллы булса, былтыр ук, өченче елны ук салдыра башларга тиеш иде. Илгә эшмәкәрләр кирәк. Хөррият заманасы килә, татарның да күзе ачылырга

тиештер бит инде. Имеш, мөгаллим булмаса, Таминдар бай мәктәп салдырмый. Салдырмаса, үзенә начар, ул тотасы пароходларны, ул ачасы заводларны кем эшләтер? Сөләйман хәзрәт тал чыбыгы ашаткан мокыт шәкертләрме?

V

Атлар нәкъ җидәү иде.

Иң алда Таминдар байның тимер күк алашасы күкрәк киереп басып тора. Аның белән янәшә Бүре Бадулның Алмачуары, аннары кара туры, аннары Акбүз ат, җирән ат, иң азакка Солтанның сары биясен китереп бастырдылар.

Команда бирүне Шәрифҗанга тапшырдылар.

— Бер, ике, өч!

Солтан абайламый калды, атлар барысы берьюлы чыгып чапты. Атларның алтысы да аңардан алдарак чаба. Мөгыйн атланган күк алаша аларны ярты чакрым чамасы калдырган иде.

Солтанның тешләре кысылып килде. Унбер яшькә җитеп, аның әле беркайчан да мондый гарьлекле хисне кичергәне юк иде.

— Сары бия, җаным, әйдә, куала-куала!

Сары бия башта Бадуллар атын узды, аннары кара туры артта калды. Урман буен борылуга ике тында Таминдар байның күк алашасын куып җитте. Моны сизгән Мөгыйн, Солтанга таба борылып:

— Узып кына кара! — дип кычкыра иде.

Ул басу юлыннан янәшә чапкан сары биянең үзе белән тигезләнгәнен генә көтеп алды да, селтәнеп торып, атның башына камчы белән китереп сукты. Ат башы шундук күздән югалды.

Солтан чак кына егылып төшми калды.

Мөгыйннең аты хәлдән тайган иде инде, әмма чабышчы үзе бик уяу, камчысы баш очында яшен урынына айкала иде. Солтан аты тигезләшә башлауга, Мөгыйн янә дә ат өстендә калкына төште, ат башына сугарга әзер тотып, камчысын күтәрде. Солтанның йөрәге атылып чыгардай булып ярсына иде. Мөгыйн камчысы һаваны ярды — аның белән янәшә үк Солтан камчысы, чыжылдап торып, Мөгыйннең битенә килеп төште. Солтан аның ачыргаланып кычкырганын, ат өстеннән капчыктай авып төшкәнен генә абайлап өлгерде — сары бия сузылып йөзеп китте, бер тында Солтанны басу капкасы төбенә китереп

җиткерде. Туктап-нитеп тормыйча, мәчет ягына — үзләренең йортына чапты.

Чолан ишегеннән, киез эшләпәсен кия-кия, әтисе Садыйк ашыгып чыкты.

— Әти! Чабышка бардык! Беренче килдем! — дип әле һаман бәйге исереклегеннән айнып җитә алмастан кычкырып җибәрде Солтан.

VI

Көн артыннан көн үтә, ел артыннан ел.

Нурия әтисеннән укый-язарга өйрәнде. Әтисе аны, күкрәгенә кысып, аркасыннан сыйпый. Нурия инде зур — ун яшендә, аркасыннан сыйпаганга ояла.

Мең тугыз йөз унынчы елның декабрь урталары. Габбас мулла йортыннан кара туры айгыр җигелгән артлы чанада, Салагышка тәрәп, төлке толыплы Габбас мулла утыра; аңа каршы мамык юрган эченнән алсу бите генә күренеп калган Нурия бара.

Юлда Саклау урманы аша уздылар. Әтисе атны куаламады, җай гына алып барды. Чуртанкүл болыннары башланды. Алар Салагышка килеп керделәр.

Салам, печән калдыкларыннан чуарланган һәм кар белән укмашып каткан базар мәйданнан узгач, урыс капка түбәсенә «Салаушское русско-земское училище» дип кара калайга ак буяу белән язган бер катлы зур агач йорт янында Габбас мулла атын туктатты.

— Йә, балам, Аллага тапшырып төшик. Син укыйсы мәктәп шушы була,— диде.

Шул мәлне мәчеттән кайтып килгән мескен бүрекле ике карт болар янына килеп туктадылар.

Аларның берсе, ярым йомык күзен кул аркасы белән ышкый-ышкый:

— И йөзең кара, бәдбәхет! — дип, чыелдык тавыш белән кычкырып җибәрде.— Иманыңны урыска саткан нәмәстәкәй, газиз балаңны зар елатып, үз кулың белән көферлеккә илтеп тыкмакчы буласың!

Нурия Салагышта ике кыш укыды.

Шул вакыт эчендә Нурия үзе дә, әтисе дә шактый ук үзгәрделәр.

Әтисе аны шимбә көннәрендә кичен ат белән килеп ала, дүшәмбе көнне иртән яңадан ат белән китереп куя иде. Бер сүз

дәшми кайта, йә булмаса әкрен генә җыру җырлый. Сүзсез генә моңлана. Әллә кайгысы бар инде аның.

Өйдәге тормыш та әллә ничек көйсезләнеп китте. Әтисе белән әнисе элекке төсле тату гына сөйләшеп йөрмиләр, чамадан тыш кычкырып сөйләшәләр. Барысы да шул Хәнифә түтәй килгәч булды. Көмеш бар чагында бер дә алай түгел иде...

Нурия, йөрәге дөпелдәп типкән хәлдә, әтисенең кемгәдер өйләнәчәген аңлап алды. Кемгәдер дигәне Хәнифә түтәйдер әле! Юк, моның булуы мөмкин түгел! Була калса, ул Хәнифә түтәйгә әйләнеп тә карамас.

Дөньялар бик кинәт үзгәреп китте.

Әтисе Нурияне, Салагыш мәктәбеннән алып кайтып, Зартугайдан унсигез чакрым ераклыктагы Пәнҗәр авылына илтеп бирде.

Пәнҗәрдә Габбас мулланың танышы Митрәй дәдә бар икән. Нурия шуларга урнашты.

VII

«Яз килде, кояш яз алып килде!» — диләр кешеләр.

Зартугай малайларын алдый алмассың: язны кояш та, җилләр дә алып килми, язны тегермәнче Чишмәбай алып килә.

— Зартугайлар, торыгыз! Яз башлыйбыз, яз ясыйбыз!

Шыгырдап, капкалар ачыла. Озын саплы багор, балта-көрәк, тимер лом тоткан агайлар, быдыр-быдыр сөйләшеп, тыкрыкларга җыела башлаган. Солтан фонарь утын болгаган Чишмәбайның әзмәвердәй олы гәүдәсен күреп калды.

Халык Чишмәбай артыннан тегермән буасы ягына юнәлде. Чишмәбай авылның гүәрдин егетләрен сайлап, елга ярына тезеп чыкты. Субайларны боздан сакларга ун егетне сайлап алып, Шаукымлы Шәяхмәтне аларга башлык булуын сорады. Боз ватып торучылар аерым әртилгә оештылар.

Эшче-гаскәр һөҗүмгә күчте: боз ватты, субайларны боздан аралады.

Иш суы, дулап-гүләп, арыклары ачылган капкага ташланды.

Яз башлау йоласының иң матур өлеше җитте. Ел саен кабатлана торган гадәт буенча, яшь-җилкенчәк, буаның түбән ягына чыгып, боз кантарларына салам көлтәләре куеп, ут ягып җибәрә башладылар.

Нуриянең дә җанында ялкын дөрли, аның да шул ялкынны ут итеп язгы ташкын сулары белән агызып җибәрәсе килә иде.

Аның беренче җибәргән уты Солтанга барып җитә алмады. Ләкин аның үз утын яр буенда гына яндырып калдырасы килми, Иш суының урта бер җиреннән җибәрәсе килә.

Нурия, кулына салам көлтәсе тотып, үсмер егетләрдән уздырырга теләп, бер урында бөялеп торган бозлар өстенә кереп китте.

Корсакларын таякларына терәп, гайрәт орып торучы картлар аны күреп алдылар да куркышып кычкырып җибәрделәр:

— Карагыз әле, кара, харап була бит!

Ләкин Нурия үзенә дәшкән тавышларны ишетми, кулына тоткан салам көлтәсен селти-селти, тар басмадан чыккан кеше кебек, әле бер, әле икенче якка авышып, боздан бозга кучә, эчкәрәк керә бара иде. Аңа таба бик дәү боз кантары кузгалды. Хәвефне Нурия үзе дә сизеп алды. Каушады. Кире борылырга итә башлады. Ләкин кире борылырга юл калмаган иде инде.

Түбән очның ике егете, Чишмәбай Каюмга ияреп, боз өстенә сикерделәр.

Алар янына Шаукымлы Шәяхмәт тә сикереп менде. Унөч яшьлек үсмер кызны бик җиңел үткәреп җибәргән боз күпере дүрт ир-атны берьюлы күтәрә алмады. Өстәвенә бу саксыз хәрәкәт бөялеп торган бозларның тынычлыгын алды.

Нурия чырылдап кычкырып җибәрде.

Нурия тавышы Солтанның җанын айкап алды. Аны-моны уйлап торырга вакыт юк иде, ул, кулына багор тотып, аерым-аерым аккан бозлар аша сикерә-сикерә, Нуриягә таба китте. Сикереп булырдай җирдә сикерде, сикереп булмастай җирдә боз кантарын багоры белән үзенә тартып китерде. Ничек итсә итте, теге ярга Нурия агып барган боздан алдарак барып җитте.

Боз яр читеннән бер метрлар ары йөзеп бара иде.

Солтан, багорын сузып: «Ябыш!» — дип кычкырды.

Нурия ябышты.

Солтан Нурияне бозы-ние белән яр буена тартып китерде.

— Сикер! — диде Солтан.

Нурия сикерде һәм, шапылдап, яр буендагы суга килеп төште. Солтан аны шундук яр читенә тартып чыгарды. Нурия, дер-дер калтыравыннан, халык арасында лачма су булып басып торуыннан уңайсызланып, өйләренә таба йөгерде.

VIII

Әтисе бер дә бер көнне Солтанга әйтеп куя:

— Йокларга иртәрәк ятарга кирәк, малай! Иртәгә таң белән кырга чыгасы.

Солтан кырга чыгуның нәрсә икәнен белә. Авыл малае хафасыз тормыш өчен яратылмаган. Ун яшеңнән сине тырма артыннан йөгертә башлыйлар, унике яшеңдә, җирнең хуҗасы итеп, сука башы тоттыралар. Тукта, сары бия кая китте соң әле?

Солтан болытлар өстеннән япа-ялгыз оча. Болытлар артыннан аккош килеп чыкты. Кеше төсле сөйләшә белә, имеш.

— Солтан, син мине эзләп очасыңмы?

Солтан аның канатыннан тотып ала, караса... аккош дигәне аккош түгел, Нурия-Нәркәй... Чабата аңа шундый килешә, ул юкка гына читек-кәвеш киеп йөри икән.

Астан әтисе кычкыра:

— Солтан, тор, малай, тор. Йоклап ятар чак түгел.— Әтисе аның өстеннән чикмәнне тартып ала. Солтан күзләрен уып торып утыра.

«Әни кабартма пешерә. Чәчүгә чыгабыз икән»,— дип уйлый Солтан.

Бер чирек сәгатьтән басуга килеп җиттеләр. Басу өсте атлар, кешеләр белән тулы иде инде.

Солтанның, Сабан туе көрәшчесе кебек, колач җәеп, ике куллап, сабан сабына тотынуы, аннары алга иелә төшеп җай гына атлап китүе, аның артыннан җемелдәп кара буразна сызылып калуы аның өчен дөньядагы барлык куанычлардан да куанычлырак иде.

Кояш, шактый югары күтәрелеп, баш өстендә кыздыра башлады. Әбәткә туктарга булдылар.

Таганнан корымлы чиләк белән чәйне алып килгәндә, озын буе белән сузылып, Шәяхмәт килеп җитте.

Бертуган энесе булса да, Садыйк абзый Шәяхмәтне бик үк өнәп бетерми. Җиргә берекмәгән кеше Шәяхмәт. Беренче кар төшү белән, Таминдар бай Тураевтан әҗәткә акча алып, әртил җыя, шул әртиле белән кышның кыш буе Тугыз буй урманнарында дилянке кистереп ята. Җәй буена Чаллы белән Чистайга сал куа.

Абыйсы аны башта сагынып каршы ала, берәр кружка төшереп алгач, малны табып та тота белмәгәне өчен тирги.

Шәяхмәт чибәр кара мыекны бармак белән сыпыра-сыпыра елмая:

— Гомерең малга кызыгып үтте синең, абый. Нәрсә ул дөнья малы? Дуңгыз каны бит ул. Баеган саен байыйсы килә. Үтереш, суеш, талаш! Тфү! Шул да булдымы тормыш? Идел дәрьяларын гизеп, башымны салларга салып йөрүемә ни җиткән? Кил әле,

әнем Солтан! — Солтан уңайсызланып кына килде. Шәяхмәт абыйсы аны, җилкәсеннән кочып, үз янына утыртты.— Менә кем бәхетле дөньяда! Минем шундый тавышым булсамы? Дөнья малы нәрсә ул.

Садыйк абзый беренче булып аңына килә:

— Ярар, туганнар, булмаса, кузгалыйк.

Шәяхмәт тә күтәрелә, абыйсының каршысына ук баса, ашыгып, инәлеп диярлек сөйли башлый:

— Абый җаным... Тыңлале сүземне. Бир син миңа бер генә җәйгә Солтанны. Мин бит аны ач итмим, ялангач итмим, мин бит аңа дөнья күрсәтәм.

— Беләм мин синең ничек дөнья күрсәткәнеңне. Юк, туганкаем, үзең зимагурлыкта йөргәнең дә бик җиткән.

— Ә мин сиңа йортлык бүрәнә бирсәм?

Садыйк абзый кинәт икеләнә башлый:

— Кайчан бирәсең?— ди ул, ниһаять.

— Хет иртәгә.

Кирәк кирәкне ега. Садыйк абзый, тешен кысып, дөньясын каргап, аның белән килешә.

IX

Шәмсениса абыстай, көнчелектән янган йөрәген баса алмыйча, кызы Нурия алдында ачы күз яшьләрен түксә дә, Габбас мулланың асрау кыз Хәнифәгә өйләнүе аның фатихасыннан башка эшләнмәде.

Шәмсениса абыстай илле биш яшен тутырганда, Габбас муллага нибары утыз биш кенә яшь иде әле.

Мулланың иртәме-соңмы яшь хатынга өйләнәчәген Шәмсениса белә иде. Берәр әрәмтамакка өйләнеп куйса — ни хәлләр итәрсең. Ул чагында бит йортның хуҗабикәсе Шәмсениса түгел, әнә шул әрәмтамак булачак.

Шәмсениса карчык, күңел түрендә кабынган көнчелек утын басып, асрау кызны хәреф танырга, язу язарга, хисапларга өйрәтә башлады. Яшь абыстай мулла йортына кызыллык китерерлек булмасын!

Иң кыены Хәнифәнең үзен күндерү иде.

Тәмле тел дигәндә Шәмсениса абыстайны өйрәтеп торасы юк, тәмле теле белән Хәнифәне иренә кияүгә чыгарга күндереп бетерә алды.

Иң соңгы чара Рамазан картны — Хәнифәнең әтисен күндерү иде. Гафият аны, кара туры айгыр белән тарантаска

утыртып, Рамазан картларның җил капкасы төбенә китерде.

Рамазан карт кунакны каршы алырга үзе чыкты. Шәмсениса абыстай бер генә мәлгә аяк киеменнән атлап китәргә шикләнеп торды.

Рамазан карт беренче булып аңына килде:

— Абыстайның астына киез җәй,— диде.

Мотаһара түти урындык киезе алып килеп, сәке буена җәйде.

Өчәүләп, авыз эченнән дога укып, битләрен сыпырдылар.

— Озак торырга килмәдем мин,— диде Шәмсениса абыстай.— Мин, Рамазан абзый, синең белән киңәш-табыш итәргә дип килгәнием. Кызыңа хәзрәтнең күзе төште. Аллага тапшырып, башлы-күзле итикме, әллә аты-чабы чыкканчы бездән алып китәсезме?

Рамазан карт аны: «Җитте сиңа!» — дип кырт кисте.

— Картайдым, Рамазан абзый. Мал-мөлкәтемне ышанычлы кулларга калдыралсам ие дип, көн дә саен Тәңрегә ялварам. Варисыбыз юк. Хәнифә Габбас хәзрәткә ир бала да табып бирсә, үз балам кебек кадерләп кенә үстерерием.

Рамазан картның каушавы чал төк баскан битенә үк чыккан иде. Кулына алган акчаларын кая куярга белмичә әвәләргә тотынды.

Җәйге эшләр башланырга торганлыктан, никах мәҗлесен озакка сузмадылар.

X—XII

Көн болытлы, тынып җиткән елга өсте шадралана башлаган, каршыдан җил исә. Садыйк абзый, чикмән җиңенә кулын тыгып, яр читендә таптана.

Унөч яшькә җитеп, әле беркайчан да башыннан сыйпамаган, ягымлы сүзләр әйтә белмәгән кырыс табигатьле әтисе Солтанга бу минутларда никтер үтә дә якын, хәтта ки кызганыч та кебек тоелып китә.

Саллар әкрен генә, хәтта күзгә күренмәс дәрәҗәдә әкренлек белән кузгала. Яр буена җыела башлаган халык, кулларын каш өстенә куеп, Шаукымлы Шәяхмәтнең куәтле-гайрәтле егетләрен сүзсез генә озатып калалар...

Кама дәрьясы урам озынлыгы салны үзенеке итеп өлгергәнче, Шаукымлы Шәяхмәт егетләренә беләк-күкрәкләренең

көч-куәтен шактый күп җигәргә туры килде. Ара-тирә Шәяхмәт абыйсының калын көчле тавыш белән команда биргәне ишетелеп кала:

— Уңгарак ал! Койрыкны тигезлә!

Команда тавышы, су чупылдаулары белән кушылып, күңелдә янә Зартугайны тергезә. Аларның да быел яңа өйләре булачак бит әле. Яңа өйдә тора башлагач, Айдар Садыйкларына Нурия-Нөркәйнең әти-әниләре дә кырын карамастыр бит инде... Ә нигә соң дөньяда берәүләр интекми-нитми генә рәхәт яши, икенче берәүләр гомер буе интегеп тә рәхәт яши алмый?

1913 елның көзендә Шәяхмәт абыйсы Солтанны, Алабугага китереп, Земское училищега укырга урнаштырды. Тормыш тора-бара үз дигәнен итте, әкренләп Солтанның юашлыгын куып чыгарды. Җирән чәчле, дәү йодрыклы Мәрдәннәр, тиктормас Зарифлар, моңсу күзле Шәрифҗаннар белән дуслашу аңа ялгыз түгеллеген, бу дөньяда иптәшләре барлыгын аңлатты. Ул туп сугарга, тәрәзә ватса качарга, купец малайлары сугышырга тотынса, аларга «сдача» бирергә өйрәнде.

Кичен өйгә биргән шигырьләрне ятлап утырган чакта, аның күз алдына томыраеп торган зур кара күзле аңа бик якын да, буй җитмәс ерак та булган кыз килеп баса иде. Баса да аны шигырь ятлаудан туктата.

Беркөнне алар укудан бергә кайттылар.

— Син кайда торасың?— диде Нурия, училище капкасыннан чыккач.

— Казанский урамда, ә син?

— Мин дә шунда торам бит...

...Кич. Караңгы төшеп килә.

Солтан белән Нурия Ерзовка бистәсеннән кайталар.

Урам уртасына җигүле атлар килеп өялгән, коймаларга орына-орына, урам тутырып, халык ташкыны килә. Халык күмәк ташкын булып пристаньга таба кузгалды.

Пристаньга таба агылган халык төркеме өстеннән, урамнарны иңләп, елау-сыкрау авазларын бергә туплап, рәхимсез бер сүз калка:

— Сугыш!

Икенче башлам

I—III

Зур тормышка чыгу, аң-белемле булу, затлы пинжәк киеп, шәһәр малае булып йөрүләр бөтендөнья сугышының аяусыз корабына бәрелеп челпәрәмә килде.

Солтан Алабуганың Земское училище укучысыннан янә авыл малаена әйләнеп калды.

Ике ел эчендә күзгә күренеп күтәрелгән Таминдар Тураев Иж буена алты ташлы тегермән салдырды. Зартугайның урта бер җирендә, әйләнә-тирәгә ерактан ук күренерлек булып, кызыл кирпечтән һәм нарат бүрәнәдән ике катлы бина калкып чыкты. Бу бина яңача укыту өчен салынган мәдрәсә хезмәтен дә, бер үк вакытта школа-мәктәп хезмәтен дә үти башлады.

Уналтынчы елның язы авыл халкына яңа бер мәшәкать өстәде. Дөбер-шатыр килеп, ярсып-дулап, бозлар агып бетүгә, Кама суы күзгә күренеп арта башлады. Кама суы Иж елгасына бәреп керде, югарыга таба күтәрелә башлады. Халыкның котын алып, урамнарны, ишегалларын су басты.

Апрельнең унберендә Садыйк картларга Нәбкәй староста белән Салагышның Кысык Минҗаны килеп чыктылар. Аларны зур кара көймә белән десятник Дөмеки китерә килде.

— Сезгә миннән ни кирәк соң?— диде Садыйк карт, шикләнеп.

Нәбкәй староста урыныннан торды:

— Бу араларда сиңа читтән берәү дә килмәдеме?

— Ул ниткән сүз? Кем миңа читтән килергә тиешле? Сезгә кем кирәк?

— Безгә кирәк кеше бер генә: синең энең Шәяхмәт,— диде Нәбкәй староста. Садыйк карт җилкәсен җыерды, башын кырын салды:

— Ә нигә әле сез Шәяхмәтне минем өйдән эзлисез? Аның бит үз өе бар. Аннары килеп, сез бит аның сугышка киткәнен үз күзегез белән күрдегез.

— Киткәнен күрдек, Садыйк абзый, ә менә кайтканын күрә алмадык,— диде Дөмеки, сүзгә кушылып.

— Кайтканы юк бит аның!

— Кайткан ул. Синдә качып ята. Син аны безгә әйтергә теләмисең,— диде Нәбкәй староста.

Лапасны, чоланны, ат һәм сыер абзарларын — берсен-бер калдырмый актарып бетерсәләр дә, Шәяхмәт Айдаров табылмады.

Садыйк картка киенергә боердылар, ашарына ризык алдырып, көймәгә алып чыгып утырттылар.

IV

Әтисен Салагыштан кичә генә кайтардылар. Аның күңеле төшенке, эшкә кулы бармый.

Урамнан кемдер ачы тавыш белән кычкырып узды:

— Каравыл өенә җыенга! Каравыл өенә җыенга!

Каравыл өе янындагы баганага иске чуен кисәге элгәннәр, шул турыга иске бер өстәл куйганнар иде. Өстәл янына Зартугайның эреле-ваклы түрәләре җыелды.

Нәбкәй староста, түшенә таккан калаен рәтләп куйгач, кулына тоткан чүкеч кисәгенә китереп сукты:

— Җәмәгать! Авылыбызның Айдар Шәяхмәте сугышта сугышырга теләмичә дизилтир булган. Менә күрегез: казна кәгазе алдык. Бу кәгазьдә әйтелгән, сугышта сугышмаган кәнитилни кешеләрнең йорт-җирен, иманасын сатарга яки мәхәллә исәбенә алырга диелгән.

Шәяхмәт Айдаров йортына Таминдар бай хуҗа булды. Солтан бу көнне җанын айкаган уй-сорауларга җавап бирерлек түгел иде. Ул Габбас мулланың Шәяхмәт абыйсын яклап бер генә сүз дә әйтмәвенә, халыкның да ризасызлык белдермичә, сарык көтүедәй өелешеп торуына кәефе китеп, үзалдына ярсынып, өйләренә кайтты.

...Йорт сату вакыйгасын Габбас мулла үзенчә кичерде. «Айдар Шәяхмәтенә ни җитмәгән? Сугыштан качкан. Качып, кая бара? Җир казып, җир астына керәме? Әллә качкын булып урманда ятаргамы исәбе? Гомер буе ничек җир астында ятмак кирәк? Ул бит үзеңне терелэтә күмеп кую, якты дөньядан үз телэгең белән исән чакта ук ваз кичү дигән сүз. Ярабби, әллә мин аңламаган икенче бер хикмәте бармы соң бу дөньяның?»

Шәмсениса абыстай бүгенге хәлләрдән үзенчә бик төгәл нәтиҗә ясады: «Нурияне Айдар Садыйкларына керүдән тыям. Патша дошманы булган нәсел белән аралашу җүннелеккә түгел».

Өченче башлам

I

1917 ел.

Россия давыл кузгаткан диңгез төсле шаулый.

Тирә-як авыллардан көн саен ишетелеп торган шомлы хәбәрләрнең күпмесе чын, күпмесе уйдырма булгандыр, әмма Солтанның үз күзе белән күргәне моңарчы булмаган өр-яңа заманның килеп җитүен аермачык әйтеп тора иде. Таминдар Тураев мәктәбендә, зур сыйныфлар укый торган бүлмәдә, Микулай патша сурәте бар иде. Малайлар бер дә бер көнне шул сурәтне стенадан алып, кадак белән күзен тиштеләр, аннары өстенә менеп сикерделәр. Беркемгә берни булмады.

Шуннан соң вакыйгалар акыл иярмәс тизлек белән алмашынып тора башладылар.

Зартугайга Шәяхмәт Айдаров кайтып төште. Бер дистәгә якын җайдак ияртеп, кайчандыр үз йорты булган җиргә — Габделхәлим сәүдәгәр кибете алдына килеп туктады. Габделхәлим бай кибетенең ишеген каерып ачып җибәрде.

— Сәлам бирдек, купец әфәнделәр! — Буынтыклы зур кара кулын кылыч сабына китереп куйды.

Габделхәлим сәүдәгәрнең йөзе мәет кебек агарды.

— Калтыранма, Габделхәлим абзый! Гаепсезгә тырнак белән дә чиертмибез. Менә нәрсә, Габделхәлим абзый, Таминдар Тураевка әйт, Шәяхмәт Айдаров кайтты, диген, кибетләрен иртәгә үк берсен-бер калдырмый ярлылар комитетына тапшырсын. Аңладыңмы?

— Ишеттем, энем Шәяхмәт.

— Кисәтеп куям: өләшсә, үзенә үпкәләсен. Бүре базына алып чыгып, җанын җәһәннәмгә олактырырмын!

Солтан аны нибарысы ике тапкыр күреп калды. Абыйсы башта Солтанны җилкәсеннән кочаклап, муенын авырттырганчы кысты.

— Сугышчы! Настоящий сугышчы! Менә кемнәр кирәк миңа! Болар белән мин буржуйларга каршы сугышып карар идем.

Солтан каушаган. Яшерми әйтсәң, аның да абыйсыныкы төсле күн куртка киеп, янтыкка кара наган тагып, авыл буйлап гайрәт орып йөрисе килә. Менә ул чагында ачуны китергән кешеләр белән сөйләшеп карар иде ул.

Садыйк карт бик төрпә генә сүз башлады:

— Тагын муллаларны, байларны талап йөрдеңме? Нишләп каныгасың син аларга? Ил ачтан үлгәндә, ярман сугышы вакытында алар бит әҗәткә биреп тордылар.

Шәяхмәт аның сүзен елмая биреп тыңлады. Түзмәде, җан түреннән чыккан тавыш белән әйтте:

— Синең бәддогаңнан, абый, әгәр беләсең килсә, минем бер кылым да селкенми. Син мине имансызлыкта гаеплисең. Минем иманым бер генә: хезмәт иясе халкының җелеген суырган аждаһаларны Җир йөзеннән себереп түкми торып, мин көрәштән туктамыйм.

II

Зартугайда, Салагышта, Кама буеның башка авылларында Габбас муллага бигүк аңлашылып җитмәгән хәлләр, үзгәрешләр көн саен диярлек булып тора. Габбас мулла Зартугайга бик озак килә торган гәзитләрне зарыгып көтеп ала: алардан дөнья хәлләрен укый, дөньяга Мулланур Вахитов дигән чая егетнең чыгуын, аның юксыллар, кимсетелгәннәр ягын якларга керешүен, сугышка каршы чыгуын белә.

Шундый шомнар эчендә яз үтә, җәй үтә. Авылларда ике көннең берендә митингы, җыелалар да акырыналар, җыелалар да акырыналар; сугышка халыкны яңадан кузгата башлыйлар.

Көзгә таба, Габбасның җанына борчу салып, яучылар килә башлады. Нурияне димлиләр. Әти кешенең кәефе кырылды. Кияүләп-туйлап ята торган заманмы? Иртән торуга авылда ни буласын беркем белми. Нуриянең үзенең дә уенда ул түгел. Иртән торса, кичкә керсә — күзе Садыйклар тәрәзәсендә. Анда ни калган? Садыйк малае Солтанга күңеле төште микән? Имансыз нәсел бит алар, денсезләр. Кара инде ул Шәяхмәтне — денсезнең дә денсезе. Күзе-башы аларган. Кемнәрне генә таламады, кемнәрне генә оясыннан тузгытмады.

Габбас мулланың күңеле тыныч түгел иде быел. Юк, мине дә башкалар белән рәттән авыл ярлылары талар, атымны-сыерымны алып китәрләр дип куркудан түгел. Мал-мөлкәткә ул беркайчан да җанын фида кылмады. Габбас мулла өчен иң газиз нәрсә — җан тынычлыгы. Быел әнә шул җан тынычлыгы югалды аның.

Патша төшерелде. Инанган, табынган, Алла кебек күргән патша төшерелде. Җир-суларны, мал-мөлкәтне дин әһелләре халыкка вәгазь сөйләгәндә изге дип, хосусый милеккә бирәү-

нең дә кагылырга хакы юк дип өйрәтеп килделәр. Ул иман юкка чыгарылды — Айдар Шәяхмәте беренче башлап хосусый милеккә кул сузды. Аннары барысы да кул суза башладылар.

Нәрсә бу? Шәяхмәтнең теге елларны йорт-җирен тузгыткан өчен байлардан үч алуымы, әллә булмаса, ул аны шулай булырга тиешле дип ышанып, законлаштырып ук эшлиме?

Шәмсениса көн саен иртә баштан алтын-көмешләрен барлый, көмеш тәңкәләрне, асылташлы беләзекләрне Хәнифәнең чәч толымына гына тыгып калмый, чәч эчләренә дә, толым асларына да тагарга, күлмәк эченнән алтын укалы күкрәкчәләрне кат-кат кидертергә тырыша. Адәм баласы акылын җуйса җуя икән. Ярабби, чәч толымындагы, күлмәк астындагы хәзинә белән күпме яшәп була? Монда бит дөньяның асты өскә килә, илдән бәрәкәт оча, динне, шәригатьне танымыйлар. Мең ел буена килгән Мөхәммәт өммәте юкка чыгамыни?

Вакыт-вакыт Габбас мулла тол абыстай Шәмсенисага йортка кергәненә үкенә башлый. Әгәр ул моннан егерме ел элек аңар йортка кермәгән булса, мәдрәсәдә балалар укытып, яки алар нәселендәге крестьянлык гадәте буенча, җир сөреп, чәчү чәчеп, игеп яшәгән булса? Болай да бит инде ул шул эшләрнең күбесен үз кулы белән эшләде. Кунакка кем йөрде? Шәмсениса. Өйдәге барлык кара эшне кем эшләде? Хәнифә. Димәк, шулай булгачыннан, ул хатын алмаган, асрау алган булып чыга түгелме? Ә бит хәзер әнә асрау тоткан өчен яхшы булмас, диләр. Асрау тотканнарга елын елга исәпләп түләттерергә кирәк булыр, диләр. Хәнифәнең ул эшкә барып җитәрлек аңы юк, ләкин бит аның күңеленә коткы салмаслар дип кем әйтә ала? Ат карауч Гафиятне ал. Анысы бит — турыдан-туры хезмәтче. Нигә әле ул соңгы көннәрдә сүз тыңламый торган, әрепләшүчән булып китте? Синең авыл каршысына басып, җавап бирер көннәрең җитмәс микән, Габбас?

Шундый уйлар белән вәсвәсә килеп йөргән бермәлне, октябрь башларында, Габбас мулла йортына тагын яучылар килеп төште. Яучыларның берсе кендекче Сафура булып чыкты. Сафура-җаһил йоласын китереп, озаклап дога кылды.

— Егетегез кем соң?— диде Шәмсениса абыстай.

— Без, Шәмсениса абыстай, Габбас белән синең йортыңа Таиндар бай улы Һашимнан илче булып килдек.

Шул мәлне әллә каян Габбас пәйда булды, яучыларның да, Шәмсенисаның да авызын ачтырмаслык итеп өзеп әйтте:

— Кызыбыз яшь, ике елдан килерсез!

Шәмсениса абыстай ирен төне буе тиргәп чыкты. Күз яше белән каргады.

Петроградта «Аврора» туплары атып, бөтен илдә Совет власте урнашканчы, Габбас муллага бүтән ячучы килмәде.

Давыллы унсигезенче елны илдә гражданнар сугышы куп-кач, мал-мөлкәтен югалтканнар, качкан ояларыннан чыгып, комиссарларны, укытучыларны суеп йөри башлагач, бердәнбер кызы Нурия өчен курку Габбас мулланың җанын тагын бер мәртәбә тимер кыршау белән кысып алды.

III

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы август төнендә Садыйк карт, ярсып өргән эт тавышына уянып, карчыгы Мәүдүдәгә дәште:

— Капкада кеше бар. Солтанны уят, мин чыга торам.

— Әти, ач, бу мин,— диде карлыккан басынкы тавыш.

Капка ачуга каршысына картузлы, мылтыклы кеше кереп баскач, Садыйк карт имәнеп китте, ләкин, олы улын танып, аңа юл бирде.

Өчәүләп өйгә керделәр.

Әни кеше мәш килеп йөри башлады, лампа кабызырга шыр-пы тапмый интегеп бетте, аннары улы янына килеп, аның төнлә кайтып, туңган зур кытыршы кулын ике куллап тотып исәнләште, сагышлы тавыш белән әйтте:

— Син... исән икән. Дөньяда ни булганны да белер хәл юк. Синең өчен кайгыруларым...

Аны тынычландырып йокларга яткыздылар. Мөхәммәтша шуннан соң гына, әтисе белән Солтанны каршысына утыртып, үз хәлләрен сөйләп бирде.

— Ижауда фетнә. Кичә башланды. Акгвардияче офицерлар Советка каршы теш ыржайтып яткан фронтовикларны коралландырганнар, коммунистларны, совет оешмасы башлыкларын асалар, кисәләр, суялар.

— Безгә дә килеп җитәрме икән ул?— диде Садыйк карт, күкрәген ышкып.

— Килеп җитүе көн кебек ачык. Әти, син урамга бик чыгып йөрмә.

Мөхәммәтша абыйсы фетнәне кайтып сөйләгәннән соң өйдә бер генә кич кунды да янә китеп барды.

Акларның якынлашуын башта Зартугай аркылы узган әсир гвардиячеләр колоннасы сиздерде.

Алабуга белән Пәнҗәр арасындагы карагайлы кара урманнарда партиянең өяз комитеты оештырган партизан отрядлары хәрәкәт итә. Шундый отрядларның берсе белән элекке фронтовик, большевик Имам Каһарманов җитәкчелек итә.

Каһарманов отрядына көннәрдән бер көнне Зартугайның Бүре Бадул килеп эләкте. Бадулның нинди бүре икәнен белгәнгә күрә, аңардан Каһарманов үзе сорау алды:

— Дошман турында нинди хәбәр беләсең?

Бадул өстеннән үлем йөге алып ташлагандай селкенеп куйды.

— Сезнең күршедәге кардон йортына Таминдар Тураев бандасы пулемет урнаштырды.

— Кайчан урнаштырды?— Каһарманов сакал-мыексыз иягән кысып тотты:— Мурзин, Костров! Тикшерергә.

Отряд кардоннан ике пулемет, өч дистә граната, бер йөзгә якын мылтык алып кайтты. Төнге кунакларны каршы алырга засада кордылар. Килүчеләр алтау. Аларның икесе шундук һәлак булды, өчесенең авызына чүпрәк тыгып, арбага бәйләп салдылар. Алтынчысы алтатардан уңлы-суллы атарга тотынды. Ул бары тик Бүре Бадулның җилкәсен генә пуля белән сыдырттырып ала алды.

Җан ачуы чыккан Бадул офицерга ташланды. Ярсыз тимер кебек авыр уң кулы белән тегенең авызына китереп сукты.

Акларга сатылган Галләмовның яшисе килә иде. Ул партизаннарга ике зур белешмә бирде. Икенчесе — Таминдар Тураевның, регуляр гаскәрләр ярдәме белән, Камага үлем баржалары куеп чыгуы иде.

— Кызыл командирлар бармы баржада?

— Бар. Бер зур командир барлыгын әйтә алам. Шәяхмәт Айдаров.

— Айдаров?! — Командир урыныннан торды:— Баржаны кайчан батырырга фәрман бирелде?

— Тагын бер атнадан.

Барлык якны чамалап, исәпләп-барлап чыкканнан соң, баржага утыз кешелек отряд, шуның янына ун җайдак, пулемет куелган тачанка җибәрергә булдылар.

Отряд юлга чыкты. Атлылар, аны-моны карамыйча, яр буена атылып килеп чыкканда, буксир үлем баржасын тагып алган — юлга чыгу өчен кузгалып маташа иде.

Мурзин команда бирде, партизаннар, ур-ра кычкырып, аска ташландылар.

Алар баржага бәреп кергәндә, буксир инде кычкыртудан туктаган, дөрләп яна иде. Партизаннар трюмны ачтылар, үлемгә хөкем ителгәннәрне өскә чыгара башладылар.

Кыйналудан, газаплаулардан үзен үзе тота алмас хәлгә килгән Айдаровны ике партизан җилкәләренә салып алып чыктылар.

VII

Зартугай урамнарыннан көн саен арыган, өшәнгән атлылар уза. Акларның җиңелү белмәс бөек армиясе Кама үзәннәреннән Башкортстанга таба чигенә.

Габбас мулла йортына, ак күбеккә баткан атын камчылап, Кысык Минҗан йөгереп керде.

— Син нишләп гамьсез ятасың, Габбас? Әллә бер сине башыңнан сыйпарлар дип беләсеңме? Байбәтчәнең, мулла-мултагайның берсен-бер калдырмый суеп киләләр ди бәлшәвикләр.

Габбас мулла, гүя сакалы белән киңәш-табыш иткәндәй, беркавым дәшми торды.

— Син мине кыстама, кем, Минҗан. Җигеп чыгарга арбам да әзер түгел, биям дә колыннарга тора.

— Үкенерсең, хәзрәт, соң булыр.

— Үкенерсең дип... Ник үкеним икән мин? Сәвиткә каршы гамәл кылганым юк, авыл кешеләрен сатмадым.

— Кем саткан?— диде Минҗан, исән күзен акайтып.

— Башыңны җүләргә салма, Минҗан абзый. Шәрифҗан мөгаллим вафаты синең вөҗданыңда.

— Анысы инде, үткәнне казымыйк, хәзрәт. Барыбыз да — дөнья коллары. Муеныңа алтатар терәп әмер иткәч, аңкитми хәлең юк.

— Ярар, сөйләштек. Син алып киткәнсең икән, җавабын үзең бирәсе. Ул беткән башларга ияреп, ирекле баштан Себер китәр хәлем юк. Үлсәм дә, калсам да шушы Зартугайда. Тәкъдирдә ни язган, шул булыр.

Кысык Минҗан, башын капкага бәрә язып, мулла йортыннан чыгып китте.

Акларның актык гаскәрләре авылдан уза. Таланасы әйбер таланып беткән.

Солтаннарга, бер төркем солдат ияртеп, нык гәүдәле фельдфебель килеп керде.

— Лошади есть?— диде, кулын кобурына куеп. Сарык абзарыннан салам белән каплап куйган җирдән сары бияне җитәкләп алып чыктылар.

Атның тезгенен ычкындырмый азапланган Садыйк картны читкә селтәп аттылар.

— Улыңмы? Илтә барыр. Алмашка ат бирербез,— диде фельдфебель.

Фельдфебель белән аның денщигын утыртып, Солтан Салагыш юлыннан чигенеп баручы олауларга килеп кушылды. Күңелендә аның хәзер бер генә уй: Азин гаскәренә кушылып, үтерүчеләрдән Шәрифҗанның үчен алу иде. Ләкин хәзергә качып китү өчен бер генә дә җай юк.

Чигенүче гаскәр, күрәсең, Пәнҗәрдән пароход белән китәргә исәп тота: авылның ындыр артлары, басу юллары олаулар белән тулган. Фельдфебель каядыр китеп югалды. Солтан, җирдән чәчелгән печәннәрне җыеп, сары биясен ашатты. Күршедәге олауларга күз төшергәләп алды. Җирән сакаллы ике рус, Солтан ишетмәсен дип бугай, сак кына сөйләшәләр иде. Ләкин Солтанның сизгер колагы сизеп алды: болар качып китәргә җыеналар.

Атларын борып, урам якка таба китә башлаулары булды, Солтан да алар артыннан иярде. Атлар өстеннән ак күбек оча башлаганчы чаптылар. Солтан Саранбайлар авылына элдертте. Авылга керер алдыннан, кечерәк бер сазлыкны узарга кирәк иде. Солтан шул хакта кайгырып кайта иде, җир астыннан чыккандай, аның каршысына берьюлы ике атлы килеп туктады. Берсенең аты кечкенә, ишәк чаклы гына иде.

Солтан белән бәхәсләшеп тормадылар. Тәбәнәк аттагысы ялт кына җиргә сикерде дә йөгән тезгенен Солтанга тоттырды, үзе биягә атланды.

— Кемнәр соң сез: акларммы, кызылларммы?

— Давай, егет, җик тә тай,— диде бәләкәй ат калдырган сугышчы.— Ату монысын алып китәргә дә күп сорамабыз.

Солтан, күзенә яшь килүдән уңайсызланып, тиз генә сиртмәгә менеп утырды. Караса, ат дигәне тәртәнең яртысына гына җиткән, хет тагын шундый бер бәләкәй ат ялгап җик. Кәҗә бит бу, чын кәҗә!

Дүртенче башлам

I

1919 елның көзендә, заманалар бераз гына булса да тынычланып, Кама буенда мылтык тавышлары тынгач, Габбас мулла, ат җигеп, Нурияне янә дә Алабугага китерде. Алабуга — алар авылына иң якын кала. Габбасның туганнан туган сеңлесе Зәйтүнә анда балалар укыта, тутасы ягыннан кардәш тиешле Наҗия Уразаева, буй җиткән кыз, урта мәктәп итеп җиһазланган зур кирпеч йортта укып йөри. Нурия шулар янында, әвәләнеп, кыш чыгар дип фикер йөртелде.

Кунакларны Зәйтүнә каршылады. Шомырт кара ике толым чәче көзге пальто өстеннән салынып торган Нуриянең алсу капкан битләреннән сөеп:

— Йа Алла, кемнәр бәхетенә шулай тулып пештең син?! — диде.— Укырга дип килдеңме? Бик әйбәт, бик яхшы, үз янымда яшәрсең, Наҗия белән бергәләп укырсыз...

— Наҗия апам кайда соң? — диде Нурия.

— Кайтыр, иркәм, Наҗия дә кайтыр. Аларны урман кисәргә җибәрделәр бер атнага. Югары сыйныфта укучылар утынны үзләренә үзләре әзерли.

Саргылт битен җыерчык һәм борчу баскан озын сарафанлы бер хатын утын күтәреп керде.

— Йорт хуҗабыз, Серафима Ниловна,— диде Зәйтүнә, ул чыгып киткәч.— Ире кызыл командир булган. Дошманнар үтергәннәр. Мичне көн саен үзе кереп яга, бичара.

Сүзсез генә аерылдылар. Әтисе өстен киенеп, ишектән бөкрәя төшеп чыгып китте. Нурия, үзен гаять бәхетсез сизеп, әтисе кебек, урындык читенә чүмәште, башын иде; әллә нишләп йөрәк сыкрый, кешегә күрсәтмичә генә үксеп елыйсы килә.

Зәйтүнә апасы урын җәйде, сеңлесенең башыннан сыйпап йокларга яткызды.

Озак йоклагандырмы, юкмы — берзаманны каты итеп тертләнгә уянды. Өстәлдә сары ут яна, каршысында кыска итеп чәчен кистергән, өстенә кофта-юбка, аягына күн итек кигән бер кыз басып тора. Почык борынлы, мыскылчан чырайлы бу кызның тавышы тәмәке тартудан карлыккан ирләр тавышы кебек тупас иде.

— Тор, буржуй кызы, киерелеп ятма, мин сиңа бер кызык күрсәтәм! Без Наҗия Уразаева булырбыз!

— Синмени ул Нәҗия апам? Әле бит сине Зәйтүнә апа бер атнага китте дигән иде.

— Ә мин үземә тигән өлешне дүрт көндә кисеп бетердем.

Нәҗия, мич капкачын ачып, шунда чүгәләде, гәзит кәгазе ертып, тәмәке төрде. Ике борын тишегеннән паровоздан чыккан төсле ак төтен агылып чыкты.

— Әйдә, Зәйтүнә апа югында берәр чокыр эчеп алабыз.

— Кит, җүләр! — диде Нурия, коты алынып.

Нәҗия калай кружкага аксыл-яшькелт сыекча салды, башын артка ташлап эчеп җибәрде. Бик кинәт исереп китте, Нурияне килеп кочаклады:

— Ә син беләсеңме, буржуй кызы, замана хәзер пыралитарьятныкы! Хәзер мин үземә үзем баш. Телим — тәмәке тартам, телим — эчәм. Мине беркем берни эшләтә алмый. Ха-ха-ха! Әйдә, тансавайт итәбез.

Ул Нурияне ду китереп әйләндерә башлады.

Шул көннән башлап бу йортта Нурия өчен көтелмәгән шаушулы, өермәле тормыш башланды.

II

Әнә шулай бергә яшәп ятканда, Нуриянең тормышында көтелмәгән бер хәл булды. Күрше фатирда стена аша гына музыка уйнап җибәрделәр. Бу язгы саф авазларның, тымызык тамчыларның, җылы кояш нурларының нинди уен коралыннан чыгуын ул берничек тә аңлый алмады. Аңлыйсы килү, белергә теләү тәкатьсез рәвештә аның күңелен алгысыта иде.

— Апа җаным, бер генә минутка мине күршеләргә алып кер әле,— диде ул Нәҗиягә.

— Ярамый! — диде Нәҗия. Нык итеп, өзеп әйтте.

Киләсе ял көнендә Зәйтүнә апасы Нурияне Ибраһим Баяновларга алып барырга вәгъдә итте. Баянов «Буби» мәдрәсәсендә чакта Габбас мулладан сабак укыган икән.

Чал кашлы, пенснелы Ибраһим абый ошады аңа. Зәйтүнә апасы Нуриянең Баяновны үз итеп өлгерүен сизде, шуңа күрә әйтер сүзен тартынып-нитеп тормыйча әйтте:

— Сеңлебезнең бер һөнәре артырга тора бит әле, Ибраһим абзый, Нурия музыкага һәвәс булып чыкты бит. Менә сез, тәҗрибәле укытучы, ничек карыйсыз бу эшкә?

Әйбәт карый икән укытучы — яратып баш какты, тиздән яшьләр өчен нардомда бальный танец кичәләре оештырылачагын, теләгән кешенең язылa алачагын белдерде.

Танцы өчен бик килешле дип таптылар Нуриянең гәүдәсен. Музыкаль слухына да яхшы бәя бирделәр.

Тормыш үзенекен итте: Нурия, усаллашып, рояль уйнарга, дәресрәге, ул кышны көй чыгарырга, теләсә кайсы егетнең күзен ут яндырырлык итеп танцыга өйрәнде.

Нурия өчен Нәҗия гомумән дә акыл ирешмәслек бер могҗиза иде. Әле күптәнмени, ул бит аның канатлы ал алъяпкычын ябып, ап-ак йон оекбаш белән тугызлыдан үргән чабата киеп йөргән чакларын белә, ул аның юашның да юашы чакларын күрә иде. Хәзер кара: Нәҗия теләсә кайсы малай белән сугыша ала, теләсә кайсы укытучы белән бәхәсләшә ала, ни генә эшләмәсен — һәрвакыт өстен чыга. Мәктәптә иң зур эшләрне ул башлап йөри. Нурия һәм башка кызлар өстеннән ул атаманлык итә. Нәҗия зарланып йөрүчеләрне, «пыралитарьятның» явыз дошманы дип санап, эт урынына сүгә, кайчагында яңакларына менеп төшәргә дә күп сорамый иде.

Менә шушы батыр кыз, берәүгә бер сүз әйтмичә, Алабугадан китеп барды.

Моңа бик сәерсенделәр. Сәбәбен эзләделәр, таба алмадылар.

III

Зәйтүнә мөгаллимә үзе алып барган дәресләрдә шаулап утырганнарын хәтерләми. Ә менә бүген малайлар белән кызлар һичбер рөхсәтсез тәрәзәгә ташландылар. Мөгаллимә сыйныф хәтле сыйныфны берьюлы кузгата алырлык вакыйга булганны карар өчен тәрәзә буена килде.

Килде һәм, урамдагы тамашага хәйран калып, авызын ачты да ябарга онытты. Тәрәзә каршысында ук бик күп булып атлы арбалар туктаган, арбаларның әле берсеннән, әле икенчесеннән йә көрәк сакаллы поп төшә яки чалма-чапанлы мулла язгы көпшәк кар өстенә коела иде.

Карый торгач, Зәйтүнә мөгаллимә дин башлыкларын үзенә буйсындырган кешенең кем икәнен дә күреп алды. Бу — Нәҗия атаман иде. Аның өстендә яшькелт бушлат, бушлатны ул яссы каеш белән буып куйган, каешка кара кобуралы наган таккан.

Барлык мулла-мәзинне, барлык попны-дьяконны арбаларыннан төшергәч, мәктәп тәрәзәсе буена тезеп куйды.

— Хи-р-р-но! — дип кычкырып үрә катырды, бер-ике, бер-икегә санатты, ике рәт итеп тезде дә мәктәп тирәли бер өч

мәртәбә чаптырып әйләндерде, шуннан соң гына олауларына утырырга рөхсәт биреп, урман ягына таба алып китте.

Әнә шул көннән соң мәктәп укучылары арасында Нәҗия Уразаеваның милиция эшенә кергәнлеге, укучылар салкында туңып утырмасын өчен, Алабуга өязендәге поплардан һәм муллалардан унҗиде кешене җыеп алып килеп, урман кистереп ятуы турындагы хәбәр таралды.

Нурия күңелендә Нәҗиягә карата ямьсез бер төен урнашты. Нәҗия аның әтисен башкалар белән бергә көн саен, балалар сабакка җыелган чакны туры китереп, мәктәп тирәли йөгертеп кенә калмый, башка руханилар белән бергә салкын баракта асрый, кызы янына күрешергә дә җибәрми, үзе дә хәзер элекке фатирына кайтып күренми иде.

Габбас мулла бары ун көннән соң гына кызы белән күрешә алды. Ул, бәләкәйдән үк урман эшендә эшләп үскән булса да, бу юлы урман эшенең авырлыгыннан зарлана башлады.

— Бигрәк кансыз кеше булып чыкты бу Нәҗия! Сулыш алырга да ирек бирми. Көне буе урман кискәнеңә дә түзәр иең, бихисап сүгенә. Муллаларны мыскыл итеп тәмәке тарта. Совет динне мыскыл итәргә кушмый! Декретны укып карагыз. Сезнең кеше җанында тукынырга, дин әһелләрен мыскылларга берегезнең дә хакыгыз юк! Юк! Без монда урман кисеп йөрибез икән, балалар суыкта утырмасынга кисәбез.

Бу юлы инде Зәйтүнә мөгаллимә дә тыныч кына кала алмады:

— Ә теге заманнарда халыкны ничек мыскыл иттеләр? Авызыгызга май каптыгыз. Ник син ул чагында хакыйкать эзләмәдең, ә? Бүген сезгә Нәҗия кычкырган, сезнең инде шуңар үләр чикләргә җитеп ачуыгыз килә, ай-һай-һай, бар икән кадерле җаннар! Ә бит синең өстеңдә әйбәт тун, абзыкаем, башыңда җылы бүрек. Син өеңнән алып килгән туклыклы ризык ашыйсың. Ә безгә ясмык кушкан чи арыш ипие, солы боткасы! Синең кызың ул ашны ашамый.

Габбас мулла каршы сүз әйтмәде.

Тагын ике атнадан урман кисү буенча үз өлешенә тигәнне бетереп, ул Зартугайга кайтып китте. Дүрт-биш чакрым кайту белән үк, аның аяклары йөрмәс булды. Муллалар, Саранбайлардан ат яллап, аны мең иншалла белән өенә кайтарып җиткезделәр. Шул көннән башлап Габбас мулла сеңлесе Зәйтүнәгә дә, башкисәр Нәҗиягә дә, аның хурлыгына шаһит булган кызы Нуриягә дә күңелендә рәнҗеш саклап калды.

IV

Габбас мулла өендә Нурияне шаулап каршы алмадылар. Габбас мулла үзе, үлгәннәргә ясин чыгарга дип, Хәнифә түти, әтисе белән сеңлесенең җеназасын күреп калырга дип, югары очка киткәннәр.

Шәмсениса абыстай аны чәй куеп эчертте, үзенең бу елда бик тә картайганын, шушы корылыкның, ачлыкның бик тәңкәгә тигәнен сөйләп китте.

— Җылап керә күрше-колан. Бер умачлык он сорап та, ашка салырлык бер бәрәңге сорап та керәләр. Бирмәсәң — ачтан шешенгән кешеләрнең йөрәк бәгъреңә төшәрлек итеп карауларын күрү әҗәл белән бер.

V

Бер ай эчендә Нурия эч пошудан ябыгып, олыгаеп киткәндәй булды. Аның мәңгегә дип яраткан кешесе әллә кайларда йөри, аның өенә кайтканы да юк, кайда икәнен хәбәр иткәне дә юк. Монда сагыштан саргаеп ятканчы, Нурия Казанга китәргә ният кылды.

Салагышка Казаннан укытучы булып кайткан Мәрхәбә, аны өйләренә шыпырт кына чакырып, бер хат тапшырды. Хат аңардан иде: исән икән бит аның Солтаны!

Ул көннең көн буе Солтанга хат язды. Хисләрен әйтеп бирә алырдай сүз табудан гаҗиз калгач, ул бүген үк Казанга чыгып китү, Солтанның Казан урамнарыннан атлап баруын күз кыры белән генә булса да күрү хакында хыяллана башлады.

Кешеләргә сөенеч китерүдән ямь таба торган Мәрхәбә тагын килеп җитә, өр-яңа хәбәр әйтә: аның әтисе Ибраһим Баянов Алабугадан кайткан. Аны Казанга Җир эшләре халык комиссарының урынбасары итеп алалар. Нурия Мәрхәбәләргә бүген кичкырын кереп чыгарга булды.

Ибраһим Баянов буй-буй сызыклы ак күлмәгенең сәдәпләрен каптыра-каптыра килеп җитте. Нурия, батырлыгын җыеп, бер әйтүдә пулеметтан сиптергән төсле сүзен сибеп ташлады.

— Мин быел Казанга укырга бармакчы булган идем. Сезнең дә Казанга барасыгыз бар икән дип ишеттем.

— Бәрәкалла! Сез ике елда бик үскәнсез,— дип, Баянов Нурияне бик оялтты.— Без, әлбәттә, сезне алып барырбыз. Мин бит әле үзем генә түгел. Казаннан кайткан энем Габидулла белән аның хатыны Нурҗиһан Алабугада калдылар. Бергәбергә оешып, Казанга сәфәр кылырбыз.

— Ибраһим абый, минем белән бергә Кәшифә дә барсын әле.

Баянов чал кергән кашларын тагын бер мәртәбә түбән төшереп алды:

— Ярар. Барсын. Алырбыз.

Нурия белән Кәшифә, Казанга җитеп, Нурҗиһан йортына кергәч, ишек төбеннән узмыйча, хуҗаларны аптыратып бетерделәр.

Өлкә комитетында аларга фармшкола, пединститут, университет янындагы рабфакка тәкъдим иттеләр. Ибраһим абзый кызларны рабфакка күндерде.

Кешеләрдән сорасаң, менә алга таба, менә сулга таба, менә артка таба дип өйрәтеп җибәрәләр. Казан каласына беренче мәртәбә аяк баскан кешегә «алга таба» ни дә, «артка таба» ни — каян беләсең аны!

Әйләнчек сарык кебек әйләнеп йөри торгач, биек бер коймa буйлап Воскресенский урамына менә башладылар. Инде шактый арыдылар, табасы килә рабфакны.

Кемдер Нуриянең битен каплап алды, кыз чырыйлап кычкырып җибәрде. Күзен ачса... каршысында, авызын колагына хәтле җәеп, Солтан басып тора. Ул нинди үскән, тазарган! Сары каеш, гимнастерка, галифе чалбар, күн итек нинди килешә аңа!

Солтанның җанын кайнар бер дулкын яндырып алды. Ул кызларның икесе белән дә ике куллап күреште дә, күңел түреннән чыккан рәхәт бер калын тавыш белән:

— И сагындым да соң үзегезне! — диде.

Нурия мөлдерәмә тулы хисләрен түгеп җибәрүдән курыккандай телсез калды. Аның өчен Зартугай хәлләрен Кәшифә сөйләп бирде.

Солтан аларны университет ишегалдына кертеп, рабфак канцеляриясенә кадәр озатып куйды, икесен бергә кочаклап саубуллашты, аннары солдатларча кырт борылып, таза нык адымнар белән китеп барды.

— Нәрсә син әвене янган адәм кебек торасың? — диде Кәшифә.

Кәшифә әкрен генә көлде дә:

— Яратуы чын булса, үзе эзләп тапсын! Кызлар горур булырга тиеш!— диде.

Алар гаризаларын, командировка кәгазьләрен канцеляриягә кертеп бирделәр, кичен рус теле белән арифметикадан имтихан тапшырдылар.

VI

Нурия Казанда музыка техникумы барлыгын белеп алды. Композитор Солтан Габәши тәкъдиме белән, Нурияне кабул иттеләр.

Кабан күленең уң ярында борынгы кирпеч йорт тора. Менә шунда Идел буе авылларыннан һәм шәһәр бистәләреннән белемгә сусаган татар-чуваш-мукшы балаларын китереп тутырдылар. «Шәрык академиясе рабфагы» дигән яңгыравыклы зур исем биреп, ач-ялангач халыкны ил белән идарә итү өчен тизләтелгән ысуллар белән укытырга керештеләр.

Солтан Айдаров та шушы казанга килеп эләкте.

Ачлык-ялангачлыкта, суык биналарда яшәгән рабфакчылар көн саен күңел юаткыч шаярулар уйлап табалар. Йокысы каты булган берәр егетне, караваты-ние белән күтәреп, коридорга чыгаралар. Колчак Хәсән белән Имам Каһарманов Сәйфелмөлекне өстәл өстенә менгереп бастырганнар да чалбарын тарталар. Сәйфелмөлек, авыл гыйбаты, шәһәрчә булам дип, чалбарыннан галифе әмәлләгән — күпереп торсынга салам тутырган икән.

Көндезләрен дөнья революциясе, Совет властеның бурычлары турында ач карынга лекция тыңлап кайталар; лекциядән соң, бүлмә-бүлмә җыелып, паек алырга казна келәтенә йөгерәләр. Паек дигәннәре — атнасына бербөтен ипи.

Нурия музыка техникумында бер генә ел укып калды. Аның музыка мәктәбеннән китүенә Нух Галләм дә сәбәпче булды. Рабфакта үткәрелгән зур бер җыелышта ул Нурия Уразаевага ташланды.

— Беләсезме, иптәшләр, безнең арабызда пролетариат идеологиясенә каршы кешеләр бар. Мәсәлән, Нурия Уразаева, сыйнфый аңын күтәрәсе урында, буржуаз идеологиясенә бирелеп, музыка мәктәбендә укып йөри.

Җыелышта Нурия Уразаеваны рабфактан чыгару турында карар кабул ителмәде. Ә ике көннән, приказлар тактасы янына җыелган халыкны күреп, Нурия, эченнән ут йотып, шунда барды. Аның рабфактан куылуы турында приказ чыккан, приказда Н. Г. Уразаеваның мулла кызы булуы, эшче-крестьян балалары укыган җирдә укырга тиеш түгеллеге, рабфакчы кызның нәсел-нәсәбен яшереп йөрүе бик усал сүзләр белән әйтелгән иде.

Нурия коридорда җыелган егетләр-кызлар алдында ук күз яше белән елап җибәрде.

Иң авыр минутларда аңа Солтан кирәк, ярдәм итсә, бары ул гына ярдәм итә алачак иде. Бәхетсезгә вакытсыз, дигәндәй, Солтан өйдә юк иде. Тик Имам Каһарманов кына ишеклетүрле йөренеп тора иде. Каһарманов — кырык яшьләрендәге кеше Нурияне бүлми-нитми тыңлады. Тыңлап бетергәч:

— Озакламый Солтан кайтыр, ул тимер юл стансасына вагон бушатырга киткәние, кайтып җитүе белән, синең яныңа йөгертермен, яме,— диде.

Нурия Нурҗиһан җиңгиләрнең өенә барып карарга булды. Габидулла абзыйдан киңәш сорармын дип өметләнде.

Габидулла абзый Нуриянең ник килгәнен ике сүз белән сорашты. Йөзен болыт басты.

— Да, сеңлем, эшең хөрти. Бик хөрти! Ярый, үскәнем, торактан китәргә ашыкма. Мин иртәгә иртүк наркомзем белән үзем сөйләшермен.

Бер көн узды — Нурия Уразаеваны рабфак җитәкчеләре чакырмый. Тагын бер көн узды — чакыручы юк. Солтан да күзгә-башка күренми. Урамнан атлы олаулар дөбердәп уза, дагалы тояк тавышлары ишетеп, Нурия шул тавышларны тыңлап, озак кына уйланып ята.

Иртәгесен иртүк, Нурияләр чәй эчеп утырганда, алар бүлмәсенә атылып-бәрелеп Солтан килеп керде һәм Нурияне җилтерәтеп алып чыгып китте.

Воскресенский урамыннан бара торгач, кечерәк бер йортның коридорына барып керделәр. Караңгыда, кармаланып, ишекне таптылар.

Армиядән кайтканнан бирле обмоткалы солдат ботинкасын салмый торган, мыеклы, күзлекле, илле яшьләрендәге бер кеше алар каршысына килеп басты.

— Иптәш Виннер сез буласызмы?

— Мин булсам ни диярсез?

Солтан тулы кызылармеец формасыннан иде, үкчәне үкчәгә китереп бәрде дә кулны чигә турысына күтәреп честь бирде.

— Мин ТатЦИКтан килдем. Председатель заданиесе белән. Менә сезгә язу, менә сезгә тере кеше, нәтиҗәсен белергә нуль-нуль унсигез сәгатьтә керермен.

Каушый төшеп, күзлеген рәтли башлаган Виннерның кулына пакет тоттырды.

Нурия кергәч, Виннер:

— Сезнең эшне бик җентекләп, игътибар белән өйрәнүне таләп итә ТатЦИК. Йә, сөйләгез, әтиегез кем, хәзер кайда яши?

Нурия этисенең крестьян гаиләсендә туып үскән бала булуын, балалар укытуын, эшли-эшли, бармаклары бирчәеп бетүен сөйләде.

— Ә синең үзеңнең, рабфакны бетергәч, нинди ниятләрең бар, Уразаева? — диде Виннер.

— Институтта укыр идем.

— Ярый, бар, кайт та дәресләреңә тотын. Калган дәресләреңне укып җиткер, мөдир белән үзем сөйләшермен.

Нурия кая басканын белми чыгып йөгерде.

Ул кичнең кич буе Солтан белән урамда йөрде, кино карады, саубуллашыр алдыннан Солтанның үткенлеген мактады:

— Ай-яй, булдыклы егет булып чыктың син, малай. Мине бүтән чыгармаслар инде рабфактан.

— Чыгарсалар да аптырама: үземә кияүгә чыгарсың, гражданнар сугышы солдаты, ярлы кеше хатынына рабфакта укырга рөхсәт итәрләр.

Солтан бу минутларда моны уйнап әйтсә дә, Нуриягә өйләнү, аның белән матур гаилә кору аның соңгы көннәрдә күңеленә кереп утырган зур бер хыялы иде. Нуриянең рабфактан чыгарылуын белгәч тә, ул — Үзәк Башкарма Комитеты председателенә йөгерде. Үзенең барлык документларын күрсәтте һәм Нурия Уразаеваны үзенең булачак хатыны итеп тәкъдим итте.

Йөри торгач, алар Кабанның биегрәк ярына, карт бер өянке төбенә килеп чыктылар. Тоныкына булып шәүләләнгән Кабан күле өстеннән, аркылыга кисеп, сукмак узган, кешеләр, яр буйларыннан әйләнеп йөрмичә, үзләренә сукмакны боз өстеннән салганнар. Һәркемнең үз сукмагы булырга тиеш. Тармы ул, киңме, кәкреме ул, турымы — үз сукмагы.

Солтан да үз сукмагын салыр, ә менә шул сукмактан аның белән кулга-кул тотынып кем барыр?

— Кемне уйлыйсың, Солтан?

— Сине.

— Китче, чынмы?

— Яратам мин сине. Синсез яши алмыйм. Безгә өйләнергә кирәк. Син мине тилмертмә, Нөркәй.

Алар айсыз төндә Кабан күле ярының йөзьяшәр өянкесе төбендә, гомер буе бер-берсен яратырга, гомер буе бер-берсенә турылыклы булырга вәгъдәләр биреп, беренче кат үбештеләр.

IX

Рабфакчыларның эшкә билгеләнер вакытлары җитте. Нурия сабырсызлык белән үз фамилиясен көтте.

— Уразаева Нурия Габбасовна,— диде Виннер.

Нурия урыныннан торып басты:

— Мин... укуымны дәвам итәр идем. Бакчачы... агроном булырга.

Виннер Уразаева фамилиясе турысына «Сельхоз институт» дип язып куйды.

Учком рәисе Охливанкин, озынча битле чуваш егете:

— Бездә Уразаева өстеннән ике гариза бар. Иптәш Галләмов белән иптәш Хамматов аны югары уку йортына җибәрү зарарлы булыр дип исәплиләр,— диде.

Рабфакчылар арасыннан фәкыйрь генә киенгән, сөякчел зур гәүдәле Хамматов күтәрелде.

— Гаризаның берсен мин яздым,— диде,— Уразаева барыбер Совет иле кешесе булмас. Ул Алабугада укыды, ләкин эшче-крестьян балаларын укытырга китмәде. Бүгенге көнгә тикле комсомол түгел. Ни өчен? Җәй саен авылга Габбас мулла йортына кайта, ни өчен ул шушы көнгә тикле әтисеннән ваз кичмәгән?

Нух Галләм урыныннан торды.

— Завуч иптәш, теге чакта Уразаеваны сез яклап калдыгыз. Сез аны, бәлки, хәзер дә совет вузына сөйрәп кертмәкче буласыздыр, ләкин ул эшегез барып чыкмас. Белеп торыгыз: мин Мәскәүгә чаклы барып җитәрмен.

Беренче булып учком рәисе Охливанкин сүз алды:

— Мин Хамматов белән Галләмов гаризаларын дөрес дип тапмыйм. Уразаеваны югары мәктәптә белем алырга лаеклы дип саныйбыз. Мин моны барлык рабфакчылар исеменнән әйтәм.

— Тагын сөйләүчеләр бармы?

Нурия ни күзе белән күрсен, Кәшифә күтәрелде. Учына бер йөткереп алгач әйтте:

— Мин Хамматов хакында бер сүз дә әйтә алмыйм. Галләмовның гадел түгеллеген әйтә алам... Ул — эшәке, бозык кеше. Карьерист. Галләмов Уразаева артыннан ухаживать итте. Уразаева аның ухаживаниесен кире какты.

Зал бик кинәт шауларга, көләргә, бәхәсләшергә тотынды.

Нурия үзен кая билгеләүләрен дә ачыкламады — аның күңеле ташып тулган иде. Бергә укыган иптәшләре аны яклап

чыктылар. Гаделсезлеккә юл куелмады. Шуннан да зуррак бәхет аның өчен юк.

Тагын ике көннән Кәшифә рабфак бетерүчеләргә командировкалар әзерли башлауларын ишетеп кайтты.

— Беләсеңме, Нуриякәем, мин икеләнә башладым әле,— диде ул, кайтып керешкә.— Без ялгышмадык микән? Кешеләр әйтә, агроном булу хатын-кыз эше түгел, диләр.

Икәүләп баш ваттылар. Агроном булыргамы, әллә врачмы? Врачлыкка укырга булдылар.

Икәүләп рабфакка чаптылар. Анда командировкаларны җибәреп өлгермәгәннәр иде әле. Секретарь карт командировканы алар теләгән вузга язып бирде.

Бишенче башлам

I

Өйләнү Солтанга шактый ук зур мәшәкать алып килде.

Садыйк карт алагаемга бер күтәрелеп бәрелде:

— Шәмсениса остабикә кызынамы? Аллам сакласын! Муллаларның ач күзен туйдырырлык туй бүләге каян аласың? Мәхдүмәне көйләп торырлык сабырлык каян килсен?

— Ул бит мәхдүмә[1] түгел инде, әти. Ул бит Габбас мулладан баш тартты,— диде Солтан, чәйле тәлинкәсен өстәлгә куеп.

Садыйк карт та чәй эчүдән туктады, иелә төшеп тезеп китте:

— Менә шунысы начар да аның! Җүнле кеше газиз атасыннан баш тартамы? Кая яраган бу? Кайчан булган эш? Сәвит шулай өйрәтәмени? Бүген атасыннан, иртәгә иреннән, аннары... дененнән? Юк, Солтан, мәхдүмә дип авызыңны да ачма, мулла кызына өйләнергә рөхсәт юк.

Солтан, сүзне беткәнгә санап, урыныннан торды.

— Ярый, әти, синең рөхсәттән башка гына өйләнербез! — Чөйдән күн тужуркасын алып киде, саубуллашмый гына чыгып китте.

Авыл урамын ике мәртәбә урап килгәч, ул, ниһаять, Габбас муллаларга керергә батырчылык итте.

Габбас мулла Солтан белән корырак исәнләште.

— Габбас абзый, төп сүзгә күчик. Мин сездән Нурияне сорарга килдем. Бергә укыдык, икебез дә Казанда, бергә яшәргә рөхсәт итегез.

---

[1] Мәхдүмә — *бу урында:* мулла кызы.

«Кая бара бу дөнья?— дип уйлый иде Габбас мулла.— Минем кызымны сорап килер йолкышмы бу? Кучер булып йөргәненә әле кайчан гына бит. Инде менә хәзер мин бердәнбер кызымны Садыйкның иманы качкан бер малаена бирергә тиеш. Садыйклар нәселе белән нәселемне кушарга тиеш. Кая бара бу дөнья?»

...Алар август аеның кояшлы бер көнендә Казанның үзәк ЗАГСына барып язылдылар. Габбас мулла кызы бүген иске тормыш киртәләрен атлап чыкты. Бүгенгесе шушы кояшлы көн кебек ачык: ирекле тормыш аны яңа юлдан алып китте.

Солтанның кулына тотынып, таудан күтәрелә Нурия.

Алар тау башына менеп җиткәч, Нурия үзе сүз башлады:

— Солтан, минем сиңа бик кирәкле сүз әйтәсем бар... Әтидән хат алдым мин. Менә шушында, шушы тау түбәсендә, безнең икебез... бер җан, бер тән булып яшисе сәгатьләребез сукканда, мин сиңа... ул хатны укып күрсәтергә тиеш. Укыйммы?

— Укы, Нөркәй.

Нурия кофтасы эченә кулын тыгып, дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

Солтан аның йөзе агара баруын, иреннәре дерелдәшүен күрде.

«Кызым, күз нурым, балам. Мин сиңа, бәлкем, бүтән хат язмам да. Син, сабырлыгыңны җыеп, минем бу хатымны укып бетер, яме.

Бәлки инде, мин соңга да калганмындыр, сез Садыйк абзый малае белән башлы-күзле булып яши дә башлагансыздыр. Тик син аны бер генә кешегә дә күрсәтмә, үзең генә бел, яме? Моны әйтүемнең сәбәбе шулдыр: минем бик күп нәрсәдән күңелем кайтты, бизде, иманым какшады инде. Синнән, бердәнберебездән дә, күңелем бизмәгәе дип ут йотып йөрим.

Хат язуымның хикмәте менә нәрсә: безнең халыкта моңарчы балалар ата-ана сүзеннән чыкмый торганые. Син чыктың. Минем дә, әниеңнең дә фатихасын алмый торып тормыш корырга ашыктың. Садыйк малае Солтанга сүз әйтмим, шул ук вакытта мин аның белән җан ачып сөйләшә дә алмыйм. Айдарныкыларны беләм мин: нәселләре белән гаййәр[1] халык. Алар нәселендәге төп сыйфат — баш бирмәү. Үлгәндә дә, кабергә кергәндә дә. Аларга йә табынырга, аларны йә җиңәргә генә була. Боларны сиңа Солтаннан гайрәтең чиксен дип

---

[1] Гаййәр — батыр.

әйтмим. Кызың кемне сайласа — киявең шул булыр. Тик безне онытмасаң икән. Мин крестьян баласы. Бәхетне күктән көтмәдем, халыкны рәнҗетмәдем, байларга койрык болгамадым. Мин дөньяда үзем аңлаганча, туры яшәдем.

Сиңа, бердәнберебезгә, тормышыңны башлап җибәрер алдыннан, шуларны әйтүне бурычым дип санадым. Сау бул, балам. Әтиең Габбас Уразаев дип беләсең».

Хатны укып бетергәч, икесе дә сүзсез калдылар. Солтан кузгалды, китә башлады. Үпкәләгәне чыраена чыккан иде.

— Хат яз,— диде.— Җылырак итеп яз. Рәнҗеп утырмасын картлач...

Нурия аңа беренче мәртәбә, ире итеп, авыр минутларының таянычы итеп карады. Таянычың бар икәнне сизү рәхәт иде.

II—VI

Шулай көн артыннан көн узып, университет аудиторияләрендә өши-өши укып йөреп, Кәшифә белән бергә беренче имтиханнарны тапшырдылар. Бу әле анатомиядән беренче бүлекләр генә иде: сөякләр, итләр, сеңерләр бүлеге. Суык кыш узып, май кояшы җылыта башлагач, Нурия, бала анасы булырга җыенганын белеп, бик хәтәр куркуга төште. Булачак яшь ананың күңеленә мин барыбер баладан үләм дигән бер уй кереп утырды. Япь-яшь көе табутта ятачагын, иптәшләре аны кызганачакларын күз алдына китереп, Солтан югында, рәхәтләнеп бер елады; аннары күңеле бушагач, үләр алдыннан ике төрле җитди эш эшләүне кирәк тапты. Иң әүвәл деканнары профессор Воробьевтан бер ел укымый торырга академик ял алды. Ул хәзер берәүгә дә күренеп йөрмәячәк. Икенче җитди эше бала табу йортын сайлауга бәйле иде. Нурия Кремль буе урамындагы беренче бала табу йортын сайлап алды...

Акыл ирешә алмас озак, мәңгелек булып тоелган газаплы гомер узды. Кыз бала дөньяга аваз салды.

Нурия дөньяга өр-яңа кеше китерүенә ниһләргә белми сөенгән, шул ук вакытта ире Солтанның — әй мөртәт! — хатыны бала табар чакта гына командировкага китеп баруына рәнҗеп, аермачык газаплар эчендә яна, гасабиләнеп, иренең кайтып җиткәнен көтә.

Әгерҗедән кайтып җитү өчен, нибары ике-өч көн вакыт кирәк иде югыйсә. Солтан өч көннән, биш көннән соң да күренмәде. Нурия баласы белән өйгә кайтып бер көн торганнан соң гына кайтып җитте.

Балага җиде ай тулганда, этисе Солтанны тагын Әгерҗе төбәгенә, бу юлы инде ел буе торып яшәргә җибәрделәр.

Эльмира, ун ай тулып, теле ачыла башлаган чакта бик кинәт авырып китте. Врачлар балада менингит икәнен ачыкладылар. Баланың авырып китүен әйтеп, Солтанга ашыгыч хат яздылар. Бу юлы хат көттереп килмәде. Лэкин эти кеше тиз генә кайта алмавын әйткән, «тормыш булгач, бала авырмый тормас инде», дигәнрәк юату сүзләре язып җибәргән иде.

Нуриянең иренә коточкыч хәтере калды. Ул аңар бүтән хат язып тормады.

Тагын бер айдан бала үлде. Телеграмма бирсәләр дә, Солтан кызын күмәргә кайтмады. Хәтта хәбәр дә язмады. Баласы үлеп киткәч тә, күмәргә дә кайтмавы — бала хәсрәтеннән саргаеп калган яшь ананы өнсез итте. Әйткән иде аны әнисе, чыкма Садыйкныкыларга, аларда иман юк дигән иде, тәки дөрескә чыкты.

Үләр чиккә җитеп рәнҗегән Нурия хатны вак кисәкләргә ертып ташлады.

Авыру әнисе янына Зартугайга кайткан Кәшифә туганүскән якларыннан көтелмәгән хәбәрләр алып килде.

— И-и малакаем,— диде ул, Нурия каршына утырып.— Солтанны икәүләп эт итеп тиргибез. Бактың исә аның хәле синнән-миннән дә хөртирәк икән. Авылда җир бүлеп йөргән чакта крестьяннар аңа сәнәк белән кадаганнар. Ике атна Әгерҗе больницасында ятып чыккан, синең хәлең авыраер дип кенә әйтмәгән.

— Кайчаннар кайтыр икән? Уф! Уйласам, йөрәкләрем жу итеп китә, явыз адәмнәр аның башына җитмәсләр микән, Кәшифәкәем? Ярасы төзәлгәнме? Әллә үзем Әгерҗегә китеп барыйм микән?

Кәшифә кайтырга җыенып, юка шәлен иңенә сала башлаган иде, ишек шакыган тавышка тукталып калды.

— Керегез! — диде Нурия.

Ишек төбендә кулына кара чемодан тоткан, күн курткалы Солтан пәйда булды.

VII

Никадәр генә очсыз-кырыйсыз булып тоелмасын — студентлык еллары да бер узып китә.

Нурия Габбас кызы Уразаева медицина институтын тәмамлап чыккан чакта, Солтан Айдаровны Казан Җир төзү

техникумының директоры итеп күтәрделәр. Сөенергә ашыкма. Нурия Уразаева Казанда ничәмә ел укыган дәвердә гел Казанда булып килгән Җир төзү техникумын Казаннан җиде чакрым ары — Авыл хуҗалыгы институтының фермасы янына күчереп куймасыннармы! Солтан Айдаровка нәкъ шунда, техникум урнашкан төбәктә ике бүлмәле өр-яңа фатир да биреп куйдылар. Ничәмә еллар гомер кичергән сигез метрлы уңайсыз фатирдан барлы-юклы нәрсәләрне олаучы абзый арбасының төбенә сал да өр-яңа урынга күчеп кит!

Алай тиз генә күчеп китеп булмый икән шул. Атаклы профессор Милославскийның, Казанның гистологлар[1] мәктәбен җитәкләп барган кешенең, күңеленә Уразаева ошар да, ул аны үзенең ассистенты итәргә ният кылыр дип кем уйлаган?!

Казанда машиналар бик аз, трамвай техникум фермалары янына кадәр бармый, ә Уразаева дигән аспиранткага көн саен институтка килергә кирәк.

Менә шунда гына Нурия кияү буласы кешесен дөрес сайлаганын белеп алды. Солтан аны ферма янына күчеп килергә кыстамады, Нурия баш-күз алганчы дип, Солтан янына Шәмсениса абыстай вакытлыча күченеп килде, һәм ул яраткан киявен бик зур тырышлык белән карап-багып тора башлады.

Профессор Милославский беркөнне аны үзенең иште ассистентларыннан берсе, озын буйлы, ак халатлы кеше янына алып килде дә:

— Нурусся, сине медицинада галим итәчәк кеше менә шушы булыр. Син аны Николай Григорьевич дип олылап дәшсәң, аның, дәшкән саен, күңеле булыр,— диде.

Иртән сигездә башланган эш төнге сәгать уннарда гына бетә. Нурия көндезләрен лаборатория техникасын үзләштерә, чит телләрне өйрәнә. Аннары тәрҗемәгә утыра. Нәкъ менә Нурия аспирантурага кергән елны институтларда татарча дәреслекләр булдыру бурычы куелган иде.

Александр Николаевич лабораториягә килеп керде. Тавышны шыгырдатып, сүз башлады:

— Балакайларым, Николай Григорьевич, Нурусся, минем сезгә әйтер сүзем бар. Кафедраларга татарча дәреслекләр кирәк. Нурусся гистология дәреслеген тәрҗемә итәргә тиеш, ә син, Николай Григорьевич, моңа шартлар тудырырга тиеш.

---

[1] Гистолог — кеше һәм хайван организмы тукымаларының төзелешен өйрәнүче.

Уразаева тәрҗемәне тизләтүнең яңа бер чарасын да эзләп тапты. Шул көннәрдә генә Алабугадан Казанга кайтып урнашкан Зәйтүнә Уразаеваны — мөгаллимә апасын ярдәмгә чакырды. Зәйтүнә апасының исә тел-әдәбият кануннарын өйрәнеп торасы юк, ул аларны биш бармагы кебек белә иде.

Алтынчы башлам

I

Шәмсениса абыстай никтер үтә дә ачылып үз итеп җибәрде бит әле Хәнифәне.

— Менә сиңа өч тәңкә көмеш, күчтәнәч алырсың, мампасимазар, йә Шәфикага курчак,— диде, аннары шыпыртрак тавышка күчеп, ачыклабрак әйтте: — Без бүген Габделхәлим абзыйларга барабыз, сырхаулап тора икән, килсеннәр дип әйттергән, без югында берүк өйдән чыгып йөри күрмә, явыз күздән Алла сакласын, йә әйберләрне урлап чыгарлар, йә үч итеп ут төртерләр. Без ике көннән артыгын тормабыз, урак өсте җитә...

Габбас мулла тарантаска кара айгырны җикте, яшел печән салды; хәзрәт белән абыстай, мамык ястыкка аркаларын терәп, икәү бергә кунакка китеп бардылар.

Хәнифә аларны капка ачып, капка ябып озатып калды.

Хәнифә дөнья тигезсезлеге турында озаклап уйлый белә торган җиңгә түгел иде. Рамазан картның ишле гаиләсендә ул соң дәрәҗәдә фәкыйрь иде. Беренче аңар күз аткан кеше Габбас мулла булды, беренче мәртәбә аңа бала итәкле ал сатин күлмәк, репс камзул, чәмчәле читек, башына ефәк шәл бөркәндергән кеше Шәмсениса абыстай булды. Шушы икедән бүтән кешене ул күрмәде дә, белмәде дә, биек коймалар, урыс капкалар эчендә бикләнеп калды.

Габбас мулла белән Шәмсениса абыстай кунакка китеп баргач, ул сабыен, бәби арбасына салып, ишегалдында тирбәтеп йөрде. Коба сыерның сөтен савып кайнатырга куйды, казан төбенә утырган касмагын бака кабырчыгы белән кырып, казанны юды, тик шуннан соң гына йокларга әзерләнә башлады. Ләкин — ни хикмәт бу? — утны сүндерүгә, аның күңеленә шом төште, ул ялгызлыктан курка башлады.

Шикләнү-шөбһәләнүләрен җиңә алмагач, ул күрше карчыгы Кафия әбине аулак өйгә иптәшкә алып чыкты. Гадәт буенча

авыл хәлләрен сөйләштеләр, күбрәк Кафия әби сөйләде. Хәнифә аның сагышлы әкрен тавышыннан изрәп йоклап китте.

Ул кемнеңдер тамак ертып кычкырган тавышларына сискәнеп уянды: урамда тәрәзә артында кызыл шәүләләр биешә, кычкырган шомлы тавышлар отыры көчәя бара иде:

— Пожар! Пожар! Янабыз!

Хәнифә, җан ачысы белән кычкырып, кызы Шәфикага ташланды, аны күкрәгенә кыскан көе, бер кат эчке күлмәктән ишегалдына чыгып китте. Кафия карчык, алдына-артына карамый, өйләренә элдертте.

Таң атып килгәндә, янгынны туктаттылар. Төнге пожар җиде йорттан кара баганалар һәм тырпаеп торган морҗалар гына калдырып сүнде.

Көн яктырганда, Габбас муллалар кунактан кайтып төште. Шәмсениса абыстай, йорт урынына көл өемен күрүгә, кычкыра да алмыйча, тораташ катты. Габбас мулла тарантастан төште, кара күмер булып калган йорт урынын бер әйләнеп чыкты, бик мескен хәлдә бөгәрләнеп яткан комган калдыгын читек башы белән әйләндереп карагач, үзләре янына җыела башлаган халыктан:

— Хәнифә кайда? Балам исәнме? — дип сорады.

Хәнифә аларны, баласын күтәргән килеш, капка төбендә каршылады. Алар хәзер өчесе дә бертигез: Шәмсениса абыстайны Хәнифәдән аерып торган мал-мөлкәт төтен булып күккә очкан иде.

Тагын бер атнадан Шәмсениса абыстай Казан каласына, кызы Нурия янына китеп барды, аннан ул хат та язмады, хәбәрхәтерен дә ирештермәде.

II

Уттан зыян күргән кешеләргә йорт салыр өчен авыл Советы урманнан диләнке бүлеп бирде. Тик Габбас Уразаевка гына, мулла булганы өчен, диләнке эләкмәде. Моңа ул бик гарьләнде, ник дисәң, авылның диндар картлары аны, кызын Пәнҗәрдә рус мәктәбендә укытканы өчен, көфер дип, кызыл мулла дип күзен ачырмасалар, инде менә бәлагә тарыгач, авыл Советы башлыклары да аның хәленә кермәде, аны буржуй сыйныфына яздылар.

Йортсыз калган Габбас муллага ярдәм итәргә ашкынып торучылар бигүк күренми, берничә кеше генә, авыл йоклагач, Габбас мулла яшь хатыны белән яшәгән келәткә килеп

садакаларын биреп китәләр иде. Күбрәк Габбас белән Хәнифә икесе эшләделәр. Йорт урынын атна буе көлдән, күмердән әрчеделәр; бәхетләренә ак келәтнең бер стенасы гына күмерләнеп калган, түбәсе дә, өч стенасы да исән иде.

Көтелмәгәндә килгән бәла-каза аларны бик тиз туганлаштырды.

Ниһаять, йортның үзен кайгыртыр көн дә җитте.

Габбас мулла ак келәттә сакланып калган төлке тунны, коба сыерын сатты. Ул гына да җитми иде, җаны сыкрап булса да, кара айгырны сатты.

Осталар аңа ике көннән йорт салырга керештеләр. Йортны элекке кебек үк дәү, бизәкле булмаса да, Имам Каһармановка һәм имансыз Нәҗиягә үч итеп, ике катлы, болдырлы итеп салдырды. Биек урыс капка койдырды, өй түре койманың өч торыгын челтәрле рәшәткә белән бизәтте. Муллалыгын бөтенләй диярлек ташлап, башкалар кебек, сука сукалап, тырма тырмалап, чәчү чәчеп, яңа нигездә яңача көн күрә башлады.

III—IV

Дүрт кеше Совет йортына җыелдылар. Кызыл гвардияче Кадыйр Гонцов, партячейка секретаре Имам Каһарманов, Совет башлыгы Мәрдән Мурзин һәм җир белгече Солтан Айдаров.

— Иптәшләр, бүгенгесе көнне безнең алга миравай революция китереп куйган бурыч бер генә: Габбас Уразаевны раскулачивать итү.— Каһарманов, зур авызы белән бергә аска төшеп киткән ияген ябып, күз йөртеп чыкты:— Кстати, волкомның Шәяхмәт Айдаров безгә җир бүлү өчен наркомземнан иптәш чакыртты. Айдаров иптәш Габбас Уразаевны раскулачивать итүдә катнашырга теләк белдерде.

Алар бүтән сөйләшмәделәр. Каһарманов озын чандыр гәүдәсе белән алдан атлады. Мулла йортының буяулы сары капкасыннан керделәр.

Култык астына папка кыстырган Мәрдән алга килеп чыкты.

— Иптәшләр, минем арттан! — Зур-зур атлап, йортның болдырына менде, ишекне ачам дигәндә, каршыларына килеп чыккан Габбас муллага юлыкты.

Әллә берәр җиргә барырга җыенган, әллә көтелмәгән кунакларның киләсен сизенеп, юри әзерләнеп торган — мулла парадный формада чыккан иде. Башында — ап-ак бохар чалма,

өстендә парчалы яшел атлас казаки, атлас чалбар күренә, аякта сафиян читек.

— Хәбәрне әйт! — Каһарманов авыл Советы башлыгына борылды. Мурзин алга чыкты, папкадан кәгазь чыгарды.

— Гражданин Уразаев, сез авылда дин агуы таратучы дошман илимент буларак, раскулачиваниегә эләгәсез,— диде.

Чакырылмаган кунаклар болдырга килделәр.

Габбас мулла, тик шунда гына Солтанны танып:

— Кияү! — дип кычкырып җибәрде.— Минем ни гаебем бар? Күзләрен наданлык баскан кешеләр ябырылсын да ди, соң бит син... соң бит укымышлы кеше ләбаса!

— Бу мин чыгарган закон түгел,— дип, Айдаров йомшаграк тавыш белән сөйләнә башлаган иде, Каһарманов, Солтанга сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмичә, барысын берьюлы өйгә алып кереп китте.

Сыер дуласа — аттан яман. Хәнифә күзенә ак-кара күренмәс дәрәҗәгә җитеп ярсыган иде.

Почмак яктан бәләкәй чемодан алып чыгып килгән Мәрдәнгә очып кунды:

— Кая алып барасың минем кызымның әйберләрен? Атаң малы дип белдеңме әллә аны, хәерче! Җыен жулик, йорт басучы. Талаучылар! Менә бусы... — Солтан Айдаровка бармагы белән төртә-төртә өстенә килә башлады: — Менә бусы — кабер якасына җиткән Садыйк картны үтерергә тотынды. Иман юк, оят юк! Денсезләр! Ата хәтле атага кул күтәр, имеш. Җирен калхузга талап алды. Садыйк абзый зимнәмир чокырына төшеп яткан. Җирен бирмәс өчен. Ә бу пугачтан атам дип куркыта, ди, тәмуг кисәве! Чыгыгыз минем йортымнан!

Каһарманов Салагыштан атлы ике милиционер чакыртты. Бар булган әйберләрнең бөртеген дә калдырмый алып чыкты.

Кичкә таба мулла йортын сүтәргә керештеләр. Мал-мөлкәтне каралты-кураны торг белән саттылар.

Зартугай халкы йокыга талгач, түбән очның Пәдеш белән Дәүли карт, хәрабә хәленә әйләндерелгән мулла нигезенә килеп, мунча тәрәзәсен чиерттеләр.

— Без әле бу, хәзрәт. Казаныңны китердек.

Габбас мулланың тавышы калтырап китте:

— Каһармановлар белсә...

— Белсеннәр. Без бит аны урлап алмадык. Үз акчабызга сатып алдык.

Габбас мулла авыз ачып бер сүз дә әйтә алмады — күңеле тулган иде.

Тагын бер атнадан Хәнифә аның бердәнбер исән калган күлмәк-ыштанын юып бирде, төенчек белән юлга азык әзерләп, Казанга озатып җибәрде.

Пожардан соң мең бәла белән җиткергән соңгы йортын тартып алып, үзен мунчада яшәргә калдырулары, киңәш сорап калага баргач, Нуриянең аны караңгы чырай белән каршы алып, бүтән килеп йөрмәвен үтенүе Габбас мулланы тетрәтеп җибәрде. Шул минуттан башлап аның өчен дөньяда яшәүнең кызыгы бетте...

Аның шәкертләре хәзер кайда гына юк. Күбесе дөнья өчен дә кирәкле кешеләр булып чыктылар. Казан каласына китеп, зур урыннарга кереп утырдылар. Алар халыкка азатлык бирдек дип күкрәк кагалар, алар мулла-мунтагай, кулак-куштан дип кычкыралар. Алар Габбас мулла кебекләр өстенә дә кемнәрнедер өстереп җибәрәләр. Әнә бит аны, йортсыз-җирсез калган байгышны, Бөкре Гафият хәл белешергә килгән булып мыскыллап китте:

— Нихәл, мулла абзый, тимер караватка сузылып, чарлаклы өйдә гәҗит укуы рәхәтрәк иеме, мунча ләукәсендә сузылып ятып укуы рәхәтрәкме?

Карале хикмәти хода, Габбасның моңарчы күңелен нык итеп тоткан нәрсә икәү булган икән: берсе — кызы Нуриягә булган ышаныч, икенчесе — авыл халкының ихтирамын тою.

Хәзер боларның берсе дә юк. Кызы Нурия аны күңеленнән сызып ташлады. Аңа ата түгел, аңа үз җаны кадерле.

Габбас мулла бик озак вәсвәсәләнеп ятты. Ята торгач, тагын йокыга куергандай булып, берсеннән-берсе ямьсез төшләр күреп саташа башлады.

Көн-ай җәелгәнне Габбас мулла көч-хәл белән күтәп алды. Озаклап юынды. Пакь күлмәк-ыштан сорап алып киде. Ак кулларын чыгарып, чайрап йоклаган Шәфикасы өстенә иелде, үбәргә курыкты, сакалы тиюдән баланың сискәнеп уянуы мөмкин иде, кулын күкрәгенә кушырып, бер тын карап торды, борын канатын ачыттырып, бер тамчы яше төште дә сакалы эчендә югалды.

Габбас мулла ашыгып, кабаланып урамга чыкты. Шул чыгудан ул өйгә әйләнеп кайтмады.

Хәнифә аны өйлә җиткәнче сабыр гына көтте. Төшке ашка кайтмагач, таныш-белешләрдән, күршеләрдән сораштырды:

юк. Инде бер дә карар урын калмагач, әллә Ходаем, үлгән балалары рухына Коръән чыгарга киттеме икән дип, зиратка барды.

Чыннан да, хәзрәт шунда, буралып салынган чардуган буендагы карт каенга маңгаен терәп басып тора иде.

Тагын бераздан Зартугай урамнарында өйдән өйгә шомлы хәбәр таралды:

— Габбас мулла асылынып үлгән. Зират каенына!

VI

Габбас мулланың авыл Советы бинасы итеп тау башына күчереп салдырылган ике катлы йортында Нәҗия Уразаева шаһитлардан сорау алды.

Нәҗия Уразаева Хәнифәнең моңлы бер сагыш белән истәлекләр дөньясына кереп китүен, бүлдерми-нитми, озак кына тыңлап утырды. Хәнифәнең, мулла йортында асрау хәлендә яшәгән яшь кенә хатынның, җәбер-золым турында бер генә сүз дә әйтмәве, бар булган хәлне шулай булырга тиеш кебек кабул итүе аны уйга калдырды.

Габбас мулланың күршеләреннән берничә кешене — шаһитларны чакырып сорау алды. Арадан берсе дә мәрхүмне яманламады, аңар тел тидермәде. Тырыш ие, укымышлы ие, халыкны таламады, садаканы да бирсәң алды, бирмәсәң сорамады, ярлыябагайның хәленә керә торган кеше ие... диделәр. Кызгандылар.

Габбас мулланы зиратка күмеп кайтканның икенче көнендә участок милиционеры Уразаеваны Салагыш волостеның милиция башлыгы үзенә чакырып алды:

— Зартугайда тәртипсезлек! Ярдәмгә ике милиционер алып, атларга атланып, хәзер үк шунда китегез.

Нәҗия Уразаева, тузан туздырып, авылга килеп кергәндә, Зартугай купкан, урам тулы халык мәчет ягына таба агыла иде.

Участковый халыкны аралап, мәчет янына килеп җитте: өстә — билләрен дилбегә белән бәйләгән ике кеше, кулларына пычкы тотып, мәчетнең манарасын кисәргә җыеналар иде.

Уразаева өзәңгеләренә басып күтәрелде дә:

— Хәзер үк түбәнгә төшегез! — дип боерды.

Мәчет түбәсендәгеләрнең берсе Кадыйр Гонцов:

— Безгә Сәвит башлыгы үзе кушты. Искелек калдыгының көлен күккә очырмый төшмибез! — дип кычкырды.

Халык тагын ду килде.

— Кисеп кенә карасыннар! Самасут ясыйбыз!

— Диннән көләргә берәүнең дә хакы юк.

— Тавыш! — дип, тамагы карлыкканчы кычкырды участковый Уразаева.— Соңгы тапкыр кисәтәм: төшегез! Боерыкка каршы килү — контрлык дип исәпләнәчәк!

Түбәдәгеләрнең икесе төшү ягына кузгалдылар. Кадыйр кузгалмады.

— Революция исеменнән боерык бирәм: мылтыкларны на взво-оод! Тыңла минем команданы: огонь!!!

Берьюлы ике мылтык атылды һәм Кадыйр Гонцов, көлтә кебек авып, җиргә тәгәрәп төште. Халык аһ итте. Ул исән, тик аягын гына имгәткән иде.

Тагын бер атнадан Наҗия Уразаеваны волкомга чакырып алып аңлатма бирүен таләп иттеләр. Аларга Зартугай коммунистлары Кадыйр Гонцов белән Мәрдән Мурзиннан жалоба килгән иде.

Наҗия Уразаева аңлатманы язмача бирде.

«Мәчет манарасын кисәргә менүчеләр хәвефсезлек кагыйдәләрен бозганнар. Киселгән манараның авып төшеп, мәчет янына җыелган халыкны имгәтүе мөмкин иде. Кадыйр Гонцов партиягә гражданнар сугышы вакытында кереп калган, революциягә бернинди файда китермәгән. Сыйнфыйлык ягы: люмпен, аерым бер һөнәре юк; авыл халкы телендә йөргән исеме: ата зимагур. Атарга команда бирдем. Шуның белән чуалыш бетте. Зартугай халкы тынычланды. Социализм строена ышаныч халыкта сакланып калды. Кирәге чыкса, социализм ныгыгач, мәчет манарасын трактор белән тарттырып аударырбыз».

Беренче китап тәмам.

Әгерҗе — Әлмәт — Казан,
1962—1976 еллар

Романга анализ ясау юллары

Теория. Без быел да татар әдәбиятының тарихын, шул тарихның бер чорын өйрәнәбез. Без танышкан һәр әсәр шул тарихның бер кисәге, ягъни аны төзүче өлеше икәнлеген истән чыгармыйк.

Әдәбият тарихын аның өлешләренә — аерым әсәрләргә тулы анализ ясап өйрәнү юлы, билгеле, иң әйбәт юл булыр иде. Ләкин язучылар күп, әсәрләр тагын да күбрәк. Без ул тарихны нибары өч китапка сыйдырырга тиеш булабыз. Ничек сыйдырабыз?

Әдәбият тарихы ул — әдәбиятның нинди дер сыйфатларының дәвамлылыгы һәм яңаруы дигән сүз. Тарих әдәбиятның барлык сыйфатларын да түгел, бәлки кайбер, әмма бик мөһим сыйфатларының кабатлануын гына искә ала. Дөрес, ул очраклы күренешләрне дә, туа-югала торган сыйфатларны да кире какмый, аларны тарихи үсешнең гомуми агымында бар дип исәпли, үзенең гомумилеге эченә сыйдыра, әмма махсус атамый. Мондый өйрәнү алымын «истә тоту» алымы дип атыйк.

Кайсы гына әсәргә анализ ясасак та, ике нәрсәне һәрвакыт күз алдында тотарга тиешбез: 1) Әдәбият тарихының үзәк юлын; 2) Ул юлларга килеп кушылучы сукмакларны.

Катлаулы романнарны чор темасына бәйләп өйрәнә алабыз. Шулай итсәк, эшне җиңеләйтәбез.

Чорга хас үзенчәлекләрне белгән кеше өйрәнелә торган әсәрдә дә бу үзенчәлекләрнең төп сыйфатлары бар, дип уйлый. Өйрәнүне шул сыйфатларны эзләүдән башлый. Мәсәлән, без өйрәнә торган чорның төп сыйфаты хакыйкать эзләү белән бәйле. Димәк, анализны да шул темага бәйле рәвештә ясыйбыз.

Проблема. Теориядән чыгып, Гариф Ахунов романында төп тема хакыйкать темасы булырга тиеш дип фараз итәбез. Хакыйкатьне һәркем үзенчә күрә, шуңа күрә бу әсәрдә дә теманың яңача ачылуын табарга тырышабыз. Димәк, безне кызыксындырган сораулар мондый булырга тиеш:

1. Гариф Ахунов өчен ялган һәм хакыйкать нәрсәдән гыйбарәт?

2. Әдип хакыйкать темасын персонажлары язмышы белән ни дәрәҗәдә бәйли алган?

3. Романга анализ ясаганда, хакыйкать темасын өч заманда карый алабыз: а) хакыйкать белән ялганга персонажлар бәясе; ә) роман язылган елларда бу темага автор карашы; б) хакыйкать — ялган темасы күп еллар дәвамында иң актуаль гына түгел, иң хәтәр тема да була. Дөреслекне әйткән өчен әле бу әсәр язылган елларда да авторның башыннан сыйпамыйлар иде. Шуңа күрә романга бүгенге күзлектән чыгып бәя бирәбез һәм үзебезгә үзебез мондый сорау куябыз: Гариф Ахунов хакыйкатьне ни дәрәҗәдә кыю итеп әйтә алган?

Романның сюжеты. Күләмле романнарда берничә сюжет сызыгы булу мөмкинлеген без инде яхшы беләбез. Анализга керешкәнче, сюжет сызыкларын берләштереп күз алдына китерик. Сюжет сызыклары әсәрнең буеннан-буена сузылган

һәм күпмедер дәрәҗәдә вакыйга буларак тәмамланган булырга тиеш.

1 нче бирем. Тәмамланган сюжет сызыкларын табыгыз.

2 нче бирем. Сез «Идел кызы» романының беренче китабы белән генә таныштыгыз. Романның дәвамы да бар. Башка китапларында сюжет сызыкларының кайсысы һәм ничек дәвам итәргә мөмкин?

Романның төзелеше. Төзелешне роман жанрының үзенчәлегеннән таба идек. Шул юл белән китик: төп геройның тирәлек белән конфликтын өйрәник.

3 нче бирем. Романның төп героен табыгыз һәм аның ни өчен төп герой булуын исбат итегез.

4 нче бирем. Төп герой конфликтка кергән тирәлекне ачыклагыз. Аларның кемнәр һәм нинди социаль төркемнәр булуын әйтегез.

5 нче бирем. Романдагы төп конфликтның нигезен, ягъни төп герой һәм тирәлек мәнфәгатьләрен әйтегез. Герой һәм тирәлек мәнфәгатьләре ни өчен конфликтка керәләр, аңлатыгыз.

Романдагы вакыйгаларның чынлыгы. Нурихан Фәттахның «Ител суы ака торур» романы тарихи дип аталса да, тарихы билгесез заманга багышланган, дидек. «Идел кызы» тарихи роман дип аталмый, әмма һәркемгә мәгълүм еллардагы вакыйгалар турында сөйли. Шуңа күрә Нурихан Фәттах романындагы чынлыкны тарихи үсештәге охшаш вакыйгаларда, илләрнең охшаш язмышларында, авторның интуициясендә һәм романның актуальлегендә, дигән идек.

6 нчы бирем. Билгеле вакыйгалар турында язылганга «Идел кызы» романы тормышка тәңгәл килерлек хәлдә тормышчан булырга тиеш иде. Шулаймы?

Романның актуальлеге. Роман язылган заманнан соң илдә зур үзгәрешләр булды. Солтан белән Нурия табынган идеология халыкка зарарлы дип табылды. Коммунизм идеалы капитализм идеалына алышынды. Персонажлар эзләп-эзләп тә җавапларын таба алмаган сораулар хәзер безгә көн кебек ачык, аларга хәзер түбән сыйныф балалары да җавап бирә алалар.

Бездә әле шәфкатьлелек сыйфаты азмы-күпме сакланып калган. Кеше хәленә керә беләбез, кайгылы кешене кызганабыз, бәхетле кешенең шатлыгын уртаклаша алабыз. Хәсрәт кичерүче кеше әсәр персонажы дип тормыйбыз, ул хәтта алдагы гасырда яшәсә дә аның хәленә керәбез. Бары тик автор аның

хисләрен ышандырырлык итеп нигезләсен һәм сурәтләсен генә.

Без әдәби әсәрләрнең потенциаль эчтәлеге барлыгын да беләбез. Анда язылган вакыйгалар шәүләсен бүгенге көн вакыйгаларына төшерә алабыз.

7 нче бирем.

«Идел кызы» әсәренең бүгенге көндә әһәмияте нәрсәдән гыйбарәт?

Йомгак

Әсәрләрен үткән заман вакыйгаларын тасвирлауга багышлаган өч әдип иҗатын өйрәндек. Тарихи темага иҗат итүче әдипләр, билгеле, өчәү генә түгел. Алар язган әсәрләр тарихның төрле чоры турында сөйлиләр, ул роман, повестьларның сюжетлары да, персонажлары да, стильләре дә төрле. Әмма бу әсәрләрнең бик мөһим уртак яклары бар — аларның һәммәсе татар халкы тарихындагы хакыйкатькә багышланганнар. Бар да тарихи вакыйгалар турында сөйлиләр, әмма яңа заман тормышын күз алдында тоталар.

Татар халкы элек тә, хәзер дә өмет белән яши. Өметенең тормышка ашмаячагын да белә, шулай булса да өметен югалтмый, тормышның иң авыр вакытларында бәхет киләренә ышана,— ди Гомәр ага Бәширов «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә.

Борынгы Болгар иленең башлыклары сугышка каршы булды. Татар милләтен күпме генә измәсеннәр, татар халкы барыбер үзенең милли хисен, милли җырын, горурлыгын саклап кала алды, ди Нурихан Фәттах «Итил суы ака торур» романында.

Бездә кеше үз хакыйкатен һәм горурлыгын фәкать үлеме белән генә күрсәтә алды,— дип яза Гариф Ахунов «Идел кызы» романында.

Хакыйкатькә һәр әдип үзенчә бәя бирә. Әмма бар да Тукай куйган сорауны куя:

«Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аh! — дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе...»

Әмирхан Еники
(1909—2000)

Әмирхан Еники 1909 елның 2 мартында хәзерге Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында туа. Төрле мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә белем алганнан соң, 1925 елда Казанга килә. Бер ел рабфакта укый, аннары Хезмәтне фәнни оештыру институтын тәмамлый. Беренче хикәяләрен шушы елларда Казанда яза башлый. Утызынчы еллар якынлаша. Илдә репрессия көчәйгәннән-көчәя бара. Татарстанда ул аеруча куәтле була. Кулына каләм алып әсәр язучыларга да, башын күтәреп үз фикерен әйтергә базган кешеләргә дә НКВД күзе бик тиз төшә. Яшь булуына карамастан, бәлки нәкъ менә яшь булганга күрәдер, Әмирхан Еники исән-имин чакта туган яклардан чыгып китү ягын карый. Бакуга барып төрле эшләрдә эшләп йөри. Бөек Ватан сугышы алдыннан Үзбәкстанга барып чыга һәм анда мөгаллим була.

Сугыш елларын әдип фронтта үткәрә. Монда аның иҗат активлыгы бермә-бер арта. «Бала», «Ана һәм кыз», безгә таныш «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге» исемле хикәяләрен ул сугыш елларында бик авыр шартларда яза.

Сугыштан кайткач, Әмирхан Еники Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар бүлеге мөдире вазифасын башкара. Аннары иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Әдипнең ике күркәм сыйфаты беренче хикәяләрендә үк күренә. Беренчедән, ул үзен сюжет төзү остасы итеп таныта. Аның әсәрләре Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов иҗатын искә төшерәләр. Һәр сюжеты тәмамланган. Әсәрләренең төзе-

лешенә җайлашып торалар. Һәр әсәрдә метафора-вакыйга, иң кирәк урыннарда кабатланулар. Язучы — укучы әңгәмәсе өчен кирәк булган бу алымнар Әмирхан Еники әсәрләрен күпмәгънәле итәләр, бәйләнешләр байлыгы төрле заманнар өчен актуаль булырлык эчтәлек тудыра алалар.

Беренче хикәяләрендә үк Әмирхан Еники үз стиле белән яза ала торган әдип булуын күрсәтте.

Аңа әсәрдәге вакыйгалардан бигрәк шул вакыйгалар тудырган кичерешләр кадерлерәк. Персонажларның уйларын, кичерешләрен тасвирлауда Ә. Еникигә тиңдәш әдип юк икәнлеге мәгълүм булды. Аның чәчмә әсәрләре шигырь кебек укыла, һәр басымы үз урынында, һәр иҗеге санаулы.

Илленче-алтмышынчы елларда Әмирхан Еники бер-бер артлы «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә» повестьларын бастырып чыгара. «Шаяру», «Туган туфрак», «Әйтелмәгән васыять» кебек татар әдәбиятының иң күркәм әсәрләреннән булган хикәяләрен иҗат итә. Бу әсәрләре белән автор үзенең тагын бер гүзәл сыйфатын ача: ул аз гына да җайлаша белми торган хакыйкатьне ярып салучы курку белмәс әдип икән.

Илленче елларда ул идеологиянең көчле, дәһшәтле агымына каршы берьялгызы йөзеп баручы әдип иде дисәк һич ялгышмабыз. Бу елларда Әмирхан Еники әсәрләреннән ялгыш фикер эзләү, аны тормышны аңламауда гаепләү күпчелек тәнкыйтьчеләр өчен изге бер эшкә әйләнде. Әдипнең повесть һәм хикәяләре бик соңга калып, гаять зур авырлык белән генә дөнья күрде. Чыккан берсе тәнкыйть утына эләкте. Ләкин Әмирхан Еники каршы сүз әйтмәде, берәү белән дә конфликтка кермәде, алдагысыннан да «усалрак» әсәрен язып бастыра торды. Тәнкыйтьнең ниндиенә генә эләксә дә, ул туры юлыннан читкә чыкмады.

Әмирхан Еники күп еллар буена шундый сабырлыгын югалтмый торган курку белмәс, хакыйкатьтән аз гына да тайпылмас көрәшче булды. Ләкин аның сабырлыгы астында нинди утлы өермәләр, үпкәләр, рәнҗүләр дулаганын ул инде үзе генә белгән.

Күп кенә әдипләр үткән тормышлары турында зур-зур әсәрләр язып чыктылар. Әмирхан Еники үз иҗатының буеннан-буена сузылган идеология белән конфликтын беренчеләрдән булып язып чыгарга хаклы иде. Әдип бу хакта соңгы елларда гына язды.

ТУГАН ТУФРАК

(Хикәя)

I

Клараның бабасы, мәрхүм, аңа еш кына: «Клара бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туган туфрагы бит ул!» — дип әйтә торган иде. Клара, ни әйтергә белмичә, уңайсызланып кала торган иде. Әллә кайдагы ул «туган туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде. Гомумән, Клара, чын шәһәр кызы булганлыктан, авыл җирен өнәп бетерми иде. Нәрсә ул авыл? Азрак күрергә туры килде аңа мактаулы авыл җирен. Салкын, пычрак көзләрдә барып, бәрәңге казып йөрде. Чыланды, күшекте, тыгыз өйләрдә тараканнардан җирәнә-җирәнә кунып ятты, өсбашы тузып, үзе керләнеп бетте. Бернинди кызык та, матурлык та тапмады ул анда.

Ничек кенә булмасын, бабасының «туган туфрак» дигәнен Клара ихтыярсыздан элек үзе барып йөргән шул Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләре белән бертөслерәк итеп күрә иде.

Ә бабасы үзенең Каракошын, шунда үткәргән гомерен еш кына сагынып исенә төшерә торган иде. Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен— барысын да кызык итеп, тәмле итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде. Клара, карт кешенең хәтере өчен генә аны тыңлаштырса да, барыбер үзенчә уйлый иде. «Боже мой,— ди иде ул эченнән генә,— хәзерге авылның коты юк, ә иске авыл нинди булгандыр инде ул?..» Аның укып белүе буенча, иске авылның бер кызыгы да булмаган. Иске авылда бары хәерчелек, караңгылык, наданлык, вәхшилек кенә булган. Байлар ярлыларны изгәннәр, крестьяннар гел ач утырганнар. Йә, моның нәрсәсен сагынасың? Дөрес, аның бабасы, сөйләвенә караганда, таза гына тормышлы булган (Клара исәбенчә, середняк булырга тиеш), аты булган, сыеры булган, иген иккән. Әмма шулай да хәзерге вакытта иске авылны сагынып утыру һич килешә торган эш түгел инде. Политик артталык, наданлык бу... Кайчакта Клара, артык түзә алмыйча, бабасының сүзен бүлә иде: «Куй инде, бабакай, мактама инде син иске авылны. Йә, сезнең шул Каракошыгызда элек мәктәп булганмы, клуб, радио, электр булганмы?»

Юк, аларның берсе дә булмаган. Хәер, мәчет катында кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган. Хәтта бабасы малай чагында керосин лампасы да булмаган. Чыра яндырганнар.

Әмма шуңа да карамастан бабасы үзенең Каракошын һаман сагына иде.

Ә менә Клараның әтисе, шул авылда туып үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. Әтисе аның алдынгы кеше шул, капитализм чорындагы авылны сагынып, мактап сөйләүнең килешмәгәнлеген бик яхшы белә ул.

Инде менә үткән көз Клараның бабасы каты авырудан соң үлеп тә китте. Сиксән елдан артык дәвам иткән гомер өзелде. Барысын да — сагыну-юксынуларын да, җыр-экиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте.

Хәзер инде гаиләдә Каракошны телгә алучы да юк, «туган туфрак» дигән сүз үзе үк бөтенләй онытылырга тиеш иде. Ләкин, ни гаҗәптер, Клара, бабасы үлгәннән соң, аның әйткән сүзләрен исенә төшергәли башлады.

Ахырда, эчке бер тынычсызлану белән уйланып йөри торгач, Кларада бабасының туган авылын кайтып күрү теләге туды. Ничектер менә, бабасы алдында бурычлы кебек ул, әгәр аның васыятен үтәмәсә, җаны бервакытта да тынычланмас шикелле... Бер елдан ул институтны бетерергә тиеш, аннары инде үзең теләгән җиргә барып йөрүләр авыр булачак.

Клара әнә шулай уйлады һәм, җәйге каникул вакытында тиз генә җыенып, ерак Каракошка китеп тә барды.

II

Клара Каракошның үзенә түгел, ә Каракоштан күчеп утырган Зиреклебаш авылына кайтырга тиеш иде. Чөнки аларның кайтып төшәрлек бердәнбер якын кардәшләре Зиреклебашта тора иде.

Хәмдия җиңгәчәсе Зиреклебашта Рәхмәй атлы уртанчы улы белән тора. Рәхмәй инде Кларага тудык абый була. Аның күз төбәп кайткан якыннары әнә шулар иде.

Поезд ике генә минут торды да китеп тә барды. Шул арада аның каршысына соры плащ, кара кепка кигән, чыбыркы тоткан кечерәк буйлы чандыр бер егет килеп басты.

Клара кыюсыз гына сорады:

— Сез... Рәхмәй абый буласызмы?

— Нәкъ үзе, нәкъ үзе! — диде Рәхмәй абыйсы һәм, чыбыркысын култык астына кыстырып, ике кулын күрешергә сузды.

Ат янына киттеләр. Биле сыгылыбрак торган тарантаска яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар палас бөкләп салганнар. Рәхмәй абыйсы ике куллап паласны суккалап алды.

— Әйдә, утыр, сеңлем! Менә аласыңмы?

Ул гүя күтәреп утыртмакчы да иде, ләкин Клара үзе җиңел генә менеп утырды.

Йомры гына туры ат кырын-кырын борылды да, юлга төшеп, вак адымнар белән юыртып китте. Кларaның гомерендә беренче мәртәбә диярлек ямь-яшел сусыл печән салган тарантаска утырып, атта баруы иде. Бик рәхәт булып тоелды аңа бу нәрсә. Җир якын, үләннәр якын, аттан тир һәм каеш исе килә, юк, бу этисен йөрткән «Волга»дан поэтичныйрак иде.

Рәхмәй абыйсы, артына борылып, аңа бөтен күзе белән дигәндәй елмаеп карады.

— Һәй, Клара, Клара! Син икәнсең инде ул Клара, ә? Бик якын туганнар бит без, уйласаң, Клара аккошым! Беләсеңме шуны?

— Беләм. Бабакайның братының улы буласыз бит сез! Шулай бит?

— Син миңа пләмәш буласың, канатым! Ә күрешкәнебез юк, вәт тамаша! Бик ерак киттегез шул, ерак киттегез!..

Клара ихтыярсыздан пошынып уйлады: менә беренче күрешүдән үк аңа туганлык хисен ничек сөенеп һәм юмартланып күрсәтәләр. Ә ул хәзергәчә мондый хисне үзендә сизмичә килде. Ниндидер Рәхмәй атлы «тудык абый» аның өчен әллә бар, әллә юк иде.

Җиде чакрымдагы Зиреклебашка караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч кайтып җиттеләр. Кечкенә өй эче бермәлгә балачага һәм хатын-кызлар белән тулып китте. Күрше-тирәдән керүчеләр дә бар иде, ахрысы. Тик Клара үз тирәсендә бертуктаусыз бөтерелеп, шатлык-иркәләү сүзләре чәчкән какча гәүдәле хатынның кем икәнен бусагадан атлау белән үк танып алды: — Хәмдия җиңгәчәсе иде. Гаҗәп җиңел сөякле, куштан һәм татлы телле булып күренде ул Кларага.

Аны чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар, юынганда кулына комганнан җылы су салып тордылар, астына йомшак көрпә салып түргә утырттылар, бик тәмле токмач белән сыйладылар.

...Күпмедер утыргач, аны өйалдындагы махсус юып җыештырылган ак чоланга кертеп, озынча түшәк җәйгән агач караватка яткырдылар.

Ә иртәгәсен аны күз кабакларын кытыклаган ниндидер җылы яктылык, борынына кергән ниндидер тәмле хуш ис йокысыннан уятты. Күзләрен ачкач, ул шактый биектә салам кыекны күрде: чоланның такта түшәме юк, имеш, ә кояш нурлары аның күзенә ике кыек арасындагы такта ярыкларыннан төшә икән. Югарыдагы аркылы киртәгә, икешәр-икешәр бәйләп, быелгы каен себеркеләрен элгәннәр, ә бүрәнә стенага мәтрүшкә бәйләмнәре асып куйганнар. Борынны кытыклаган бу гаҗәеп хуш ис шулардан тарала икән.

Клара, күзен ачкач, тагын «ак» чоланның шүрлегендә һәм чөйләрендә аңа исемнәре дә билгеле булмаган әйберләрне — йон кабасын, тәрәш таракны, каен тузыннан теккән кечкенә тубалны, кипкән шомырт белән тулы агач шаваны күрде. Бу әкәмәт нәрсәләр аны бик борынгы бер заманга кайтаргандай итте.

Клара, ниһаять, торып, киң билбаулы ефәк халатын гына киеп чоланга чыкты. Ишеккә баруга, чыбык-чабык күтәреп килгән җиңгәчәсе очрады.

— Ә, Иркә туташ, тордыңмы, якты күзем? — диде ул, җыр әйткәндәй көйләбрәк.— Хәзер, хәзер сөлге белән комган чыгарам, чирәмдә генә юынырсың!

Клара аптырый калды: «Нигә Иркә туташ? Әллә аның чын исемен яратмаганнармы? Әллә озак йоклаган өчен көлеп әйтәләрме? Ләкин соңыннан төшенеп алды: юк, көлеп түгел икән, ә чын ихластан аны кадерләп, сөеп дәшү икән ул... Иркә туташ! Нинди матур, нинди ягымлы! Карагызчы, авыл кешесе дә шулай әйтә белер икән?!

Ишегалдына чыккач, Клара хәйран булып, тукталып калды: йортның киртәсеннән кул сузымы җирдә генә иген кыры башланып китә. Очы-кырые күренмәгән бу күкрәп үскән иген шулкадәр якын, хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә.

Киртә буенда гына казыкка бәйләгән бер яшь сарык кетеркетер чәчәкле үлән кимереп йөри... «Ах, душечка, ах, җаным! — диде Клара, тәмам нечкәреп.— Килче, килче миңа, матурым!..» Сарык, башын текә генә күтәреп, авызындагы үләнен чәйнәүдән туктап, аптырау-курку тулы күзләрен Кларага төбәде. Юк, бу төпсез, хәйләсез, бары җан калтыравын гына чагылдыра алган якты күзләргә озак карап торуы мөмкин түгел иде.

Клара юынган арада, ашыга-ашыга, Рәхмәй абыйсының хатыны кайтып керде. Бу яшь җиңгәчәй — Мөнирә җиңгәчәй

була инде. Таза гына, сылу гына гәүдәле, үзеннән-үзе елмаерга торган сөйкемле чырайлы, матур кара кашлы, кара күзле яшь хатын иде ул... Фермада сыер сава икән, әле шуннан ашыгып кайтуы.

Шул арада болар янына урамнан ике яшь кенә бала тупылдашып йөгереп килде. Зуррагы, биш-алты яшьләрендәгесе — малай, ә кечкенәсе — өч-дүрт яшьлек кызчык иде. Алар шактый әрсез-чая булып чыктылар. Авыл балалары димәссең. Шунда ук апаларына сарылып такылдый да башладылар.

— Менә сез нинди икәнсез! Матур икәнсез, акыллы икәнсез! Йә, синең исемең ничек?

— Алмас! — диде малай, авыз тутырып, батыр гына.

— Ә синеке, күбәләгем?

Кызчык башын кырын салды һәм акрын гына:

— Алсу! — диде.

Барысы да җыйнаулашып өйгә керделәр. Карт җиңгәчәсе Клараны өтәләнеп каршылады.

— Әйдә, Иркә туташ, әйдә, күз нурым! Карының да бик ачыккандыр инде синең, уятырга җәлләдек, юлдан соң туйганчы бер йокласын, дидек.

— Хәзер, Хәмдия җиңгәчәй, чәчемне генә тарап алыйм. Клара көзге каршына басып, кыска коңгырт чәчләрен, бер кулы белән тузгыткалап, тарарга кереште. Бу минутта нигәдер барысы да, эшләреннән калып, Кларага карап тордылар. Клара аларның үзенә, үзенең нечкә, зифа буена, затлы матур киемнәренә, гомумән, шәһәр зәвыгын аңкытып торган чибәр туташ булуына сокланып карауларын сизде. Бу аңарда горурлык һәм өстенлек тойгысы уятты. Әмма шул ук вакытта үзе белән алар арасында никадәр тирән аерма барлыгын, үзе яшәгән җиңел, гамьсез тормышның аларда юклыгын, хезмәтнең әле нәрсә икәнен белмәстән, үзенең алар күрмәгән ганимәтләр белән файдалануын, ләкин аларның, шушы аерманы сизгән хәлдә дә, аны әнә ничек якын туган итүләрен ул эчке бер уңайсызлану белән хис итмичә кала алмады.

...Ул чәчен тарап бетерүгә, барысы да тагын хәрәкәткә килделәр, тагын түргә узып утырырга кыстый башладылар. Ләкин Клара, кереп утырганчы, иң элек стена буенда торган чемоданын алып урындыкка куйды да, ачып, бүләкләрен чыгара башлады. Карт җиңгәчәсенә ул яшел сатин күлмәклек белән ак батист яулык бирде, яшь җиңгәсенә бик матур ефәк күлмәклек бирде, Рәхмәй абыйсына дип китергән ике якалы күлмәкне

дә галстугы белән бергә чыгарып сузды, балаларның берсенә — малайга — чиккән үзбәк түбәтәе кидерде, ә кызчыкка бик матур кызыл туфлиләр тоттырды. Аннары ул күчтәнәчләрен чыгарып өстәлгә салды. Барысы да искиткеч куандылар. Карт җиңгәчәсе, кәнәфигә утырып, озын итеп дога кылды.

— Бик тә зурладың, бик тә сөендердең безне, Иркә туташ! — диде карт җиңгәчәсе.— Рабби Ходам, әти-әнисенә озын гомерләр бирсен, сезгә бакый рәхәт бәхетләр насыйп итсен! Амин!

Клара күңеле тулудан бер сүз әйтмәде, яшьләремне тыя алмам дип курыкты ул...

Чәйдән соң Клара, чоланга кереп, өстен алыштырып чыкты.

...Инде авылны күрергә кирәк. Яшь җиңгәчәсе ашыгып фермасына китте, карт җиңгәчәсе өй эшләренә тотынды, Кларага иптәшкә Алмас белән Алсу калды.

Авылның утырган җире гаҗәп матур иде, монда кечкенә авыллар тирәсендә генә очрый торган ниндидер үзенә бер ямьлелек бар иде. Каршыдагы өйләр артыннан ук яшь урман башлана. Урамның түбән очы яшел чирәмлеккә барып чыга һәм шуннан ерак түгел, ялгызы гына утырган мәһабәт биек тау күренеп тора. Ә бире очта, менә киртәләр яныннан ук, иген кыры башланып китә. Ничектер барысы да — урманы да, тавы да, кыры да —кул сузымы гына җирдә. Һәм атлап чыгу белән, үзеңне табигать кочагында күрәсең! Кларага аеруча менә шушы якынлык сокландырды да. Ялан күрер өчен машинага утырып әллә кая чабасы юк икән монда...

Каршыдагы йортның киртәсе буеннан үтеп, бер йөз-йөз илле адым китүгә, алар урманга барып та җиттеләр.

Нәкъ урман авызында аларга юкә бәйләме күтәреп чыгып килүче бер бабай очрады. Бабай базык кына гәүдәле, түгәрәк йөзле, мыексыз, ап-ак сакаллы иде. Ул тукталып Кларага дәште:

— Исәнме, кызым? Безнең мондагы кызларга бер охшамагансың, кайдан син үзең?

— Мин шәһәрдән, бабай! Казаннан.

Бабай бәйләмен җиргә куйды.

— Казанна-ан? Бик ерактан килгән кунак икәнсең, алай! — Ул бераз башын селкеп торды.— Кемгә кайттың соң син, рәхмәт төшкере?

— Менә Рәхмәй абыйларга,— диде Клара.

— Ә Рәхмәйләргә... Ябалак Хәмматшаның Рәхмәенә була инде, алайса!

— Соң син үзең, канатым, кем кызы буласың?

— Бабай, сез аны белмәссез. Әтием минем авылдан бик күптән киткән. Бәлкем, әтиемнең әтисен, минем бабамны беләсездер? Мөхәммәтҗан. Каракошта торган ул.

— Мөхәммәтҗан! Тукта, тукта, Хәммәтшаның бертуган агасы Мөхәммәтҗанмы? Ә-ә, әнә ничек икән! Һә, чулак Мөхәммәтҗанны белмәскә соң, безнең кодабыз бит ул, чулак Мөхәммәтҗан! Минем анайның бертуган энесенең, Әптел дәдәйнең уртанчы кызын синең әбиең Гайшә тутай белән тудык бәлеш Усман малаена биргәннәр иде. Бабаң белән әбиең дә кодалар булып килгәннәр иде. Әмма егет тә кеше иде яшь чагында бабаң! Бөеренә таянып, бер җырлап җибәрсә, кунакларның һушын ала иде. Исән-сау гынамы соң әле Хәммәтҗан кода, рәхмәт төшкере!

— Юк, бабай, үлде инде ул! Былтыр көз...

— Үлде? Иһи-һи...

Бабай, чүгәләп, җитди-моңсу кыяфәт белән дога укырга кереште.

Бабай бәйләмен алырга дип иелде һәм шул чакта, Кларага сыенып торган Алсуны күреп, аның башыннан сыйпады.

— Юлыгызны бүлдем, барыгыз инде, үскәннәрем.

Бу очрашу бик дулкынландырды Кларины. Аерылып киткәч тә һаман: «Нинди ягымлы кешеләр, нинди яхшы күңелле кешеләр!» — дип уйланды ул. Моңарчы бер җирдә дә әле аның мондагы кебек йомшак мөгамәлә, якты чырай күргәне, мондагы кебек шигъри тәмле итеп сөйләүне ишеткәне юк иде. Гаҗәп иде бу! Тормышны бик мәкерле нәрсә дип әйтәләр бит! Бер төчесен, бер әчесен каптыра, диләр. Әмма шулай да кешеләргә изгелек хас булырга тиеш. Бик борыннан аларның йөрәкләренә салынган орлык булырга тиеш бу... Инде тормышлар яхшыра һәм бәхетләр тигезләнә барган саен, ул орлыклар тулысынча шытып, барлык кешеләрнең дә үзара мөнәсәбәтләре менә шулай якты, җылы булып китмәсмени?

Кларaның дулкынланган күңеленнән ихтыярсыз әнә шундый уйлар кичеп үтте. Аңа рәхәт иде, гүя бабай аны «туган туфракның» саф суына манып алды, ул рухи баеп, пакьләнеп киткәндәй булды.

Урманга керделәр. Монда торганы яфраклы агач иде: каен, юкә, усак, чаган, карама, әлмә — танып бетермәссең, ләкин бер генә дә ылыслы агач юк. Шуңамыдыр, урман эче ничектер нурлы иде, әледән-әле хисапсыз чәчәкләр белән чуарланган кечкенә

аланчыклар ачыла гына тора иде. Бу күренештән Клараның башы әйләнеп, кайсы аланчыкта тукталырга, кайсы чәчәккә үрелергә белмичә, ул әле уңга, әле сулга кереп китә, аннары тагы иске урынына килеп чыга иде... Ул тик балаларны югалтудан курыкты. Алмас урман җәнлеге шикелле, каядыр китә дә югала иде. Әллә кайдан гына килеп чыга да: «Әйдә, апам!» — дип, йә җиләк тулы берәр уйдыклыкка, йә оясы белән утырган бөрлегәнлеккә ияртеп алып китә иде. Ахырда урманны шактый айкап йөргәннән соң, бер дә күрмәгәндәй зур кочак чәчәк җыеп кайтырга чыктылар.

Аш сосар алдыннан гына аларга кара күн фуражка кигән таза, бер яшь кеше килеп керде. Берсекөнгә авылның бөтен картын-яшен печәнгә чыгарабыз, ди.

Җиңгәчәсе егетнең бөтен әйткәннәрен хуплап торды, тик ахырдан гына:

— Һәй, Хәсәнкәем, әйткәнеңне дә көтмәс идем,— диде,— кунагым бар бит!

Егет елтыр кара күзләре белән Кларага туры гына карап алды да көлемсерәп:

— Кунак кызга да тырманың җиңелен әзерләп куярбыз,— диде.

«Вот какой нахал!» — диде Клара эченнән, гадәтенчә бик ачуы килгәндәй итеп.

Шуннан соң ул егетнең тыныч кына болай дип әйтүен ишетте:

— Хәдияттәй, мин сине артык кыстамыйм, кунакны ялгыз калдырып булмый, канешно, аны гына беләбез... Үз җаеңа карарсың тагы, эш синнән качмас... Ярый, мин киттем. Хушыгыз, туташ!

Ниһаять, бар да ашка җыелдылар. Табын яңы гел сүз белән узды. Менә хәзер генә ул туганнары белән якыннан танышты. Рәхмәй абыйсы гади колхозчы икән, ләкин болай селкенеп йөрүдән туйдым, ди, берәр комбайнга басарга исәпләп торам, ди.

Мөнирә җиңгәчәсе, әйткәнебезчә, фермада сыер сава.

Клара аларның көнкүреш хәлләре белән дә читләтеп кенә булса да кызыксынды.

Карт җиңгәчәсе ике сүзнең берендә, «Аллага шөкер» дип тора. Ипи кайгысы китте, ди, түбәбездән су үтми, ди, мал-туарыбыз бар, ди, аяк-кулыбыз сау, ди.

Гомумән, ул бик азга да шөкер итәргә өйрәнгән, ахрысы.

Әлбәттә, Клараның үзеннән дә күп нәрсәләр турында сораштылар. Аның бу кешеләр алдында мактанасы, шәп, рәхәт торулары белән ялтырап күренәсе килми иде.

Сүз ахырында иртәгә Каракошка барып кайтырга булдылар. Җае да чыгып тора икән — Рәхмәй абыйсы, бригадир кушуы буенча, шунда барырга тиеш.

III

Икенче көнне иртәнге чәйдән соң Рәхмәй абыйсы, әлеге биле сыгылыбрак торган тарантаска Алмас белән Алсуны утыртып, шул ук бәләкәй атта кызу гына ишегалдына юырттырып килеп керде. Балаларны төшереп, печән өстенә чуар палас чыгарып җәйделәр, ике мендәр салдылар.

Иң элек Хәмдия җиңгәчәсе — кызыл эчле тирән галошлардан һәм эре чәчәкле шәльяулыктан, туйга баручы кодача төсле, бисмилласын әйтеп, иплэп кенә тарантаска менеп утырды. Аның янына чажлап торган ефәк плащтан, кауырый кадаган бик килешле эшләпәдән Клара менеп урнашты.

Кузгалып киттеләр. Балалар әниләре янында елашып калдылар.

...Авыл урамының түбән очыннан барып чыккач, сулга борылып, тау итәгеннән киттеләр. Ялгыз утырган тау шактый биек һәм мәһабәт иде. Таулар Кларада һәрвакыт ихтыярсыз соклану уяталар. Гүя алар, дөньядан югары күтәрелеп, түбәндәге тормышка бәйсез бер горурлык белән тын гына карап торалар. Алар бик күп хәлләрне күреп беләләр һәм эчләренә җыеп баралар төсле... Нинди генә тауны күрмәсен, Клараның шуңа менәсе, шуның түбәсеннән дөнья өстенә карап торасы килә иде.

— Бу безнең Чабыл тавыбыз,— диде җиңгәчәсе.

Моны ишетүгә, Клараның исенә бабасы кылт итеп төште. Мәрхүм бабасы еш кына: «Чабылтау, Чабылтау»,— дип сөйләнә иде. Шушы икән инде ул Чабылтау! Бабасы малай чагыннан ук бу тау тирәсендә күп йөргән булырга тиеш. Шунда аларның җирләре, шунда печәнлекләре булган шикелле... Клара бу хакта сорагач, җиңгәчәсе:

— Әйе, аккошым, каенатамнарның Корысазлык дигән печәнлекләре шушында иде шул,— диде.

Юл, Чабылтауны әйләнеп, көньякка табан борылгач, Клара алдында гаҗәеп күренешләр ачылды. Бу ялгыз тау үзе дә гаять зур биеклек өстендә утыра икән. Рәхмәй абыйсы юл буенча диярлек күрсәтеп бара: «Ә-онә теге Өзектау инде! Шуннан уңга

таба китсәң, безнең Зирекле буена барып чыгасың. Әнә нәкъ каршыбызда Әркәсле яланы... Сулга карасаң, әнә анда Имәнлек башланып китә... Бабакаеңнан ишеткәнең дә бардыр әле».

Әйе, дөрес, Клара боларның барысын да бабасыннан ишеткәне бар иде. Шуңа күрәдер инде хәзер аңа бу кырлар, бу таулар, бу урманнар электән үк таныш булып тоела иде. Хәтта берара аның күңеленнән: «Тукта, мин үз күзләрем белән дә боларны кайчандыр бер күрдем түгелме соң?» — дигән гаҗәеп сәер, шул ук вакытта ничектер бик якты, ләззәтле сизенү кичеп үтте. Бик ышанасы килде шуның чын булуына! Ләкин... юк, күргәне юк, әлбәттә. Әмма шушы ачык сизенү тәэсиреннән ул ихтыярсыз авыз эченнән генә берничә мәртәбә: «Туган туфрак, туган туфрак!» — дип кабатлап куйды.

Ике тау арасындагы текә юлдан атны тыя-тыя гына түбән төштеләр һәм, чуерташлар өстеннән сырланып аккан инешне кичеп, бер тыкрыктан авылның зур урамына барып керделәр... Менә сиңа Каракош!

Тәҗрибәле күз бу авылның кайчандыр бик зур булуын һәм бик тыгыз утырганлыгын чамалар иде. Төп урамның бер очыннан икенче очын күреп булырлык түгел... Тагын янәшә сузылган һәм аркылы кисеп узган урамнар да бар. Кыскасы, искечә әйткәндә, элек бу өч-дүрт мәхәлләле бер авыл булган булырга тиеш. Хәзер исә, өстеннән давыл узгандай, ул бик сирәкләнеп, тузып калган иде. Каракош башыннан күп хәлләр кичкән булырга тиеш.

Ләкин Клара боларның барысыннан да хәбәрсез иде, билгеле.

Авыл уртасына җитәрәк алар урамга буй салынган, такта белән япкан таза гына йортның капкасына килеп туктадылар. Бу — Кларага әллә кайсы яктан, әллә ничек кенә кардәш тиешле Сәйфетдин абзыйның йорты иде. Капканы өстенә ак күлмәк, башына кара кәләпүш кигән кәкрерәк аяклы хуҗа үзе ачты. Өйдән шәһәрчә диярлек киенгән, кечкенә буйлы, йөзгә бик сөйкемле яшь хатын һәм буйга-сынга таза гына егет ашыгып чыктылар. Болар Сәйфетдин абзыйның улы белән килене иде...

Хәмдия җиңгәчәсе Кларaны терсәгеннән этәребрәк:

— Менә Иркә туташны сезгә күрсәтергә алып килдем,— диде.— Хәмматҗан дәдәбезнең внукасы була инде. Каладан кайтты.

Барысы да аның белән бик куанышып күрештеләр. Аеруча Кларaны күрүенә яшь килен бик шат иде шикелле — ничектер

беренче караштан ук ул аңа, үз тиңен очраткандай, бик җылы, бик якын итеп карады. Аннары кунакларны өйнең түр ягына алып керделәр. Өй эче тәмам шәһәрчә дип әйтерлек иде. Чебеннең әсәре дә юк, үзе чиста, үзе рәхәт, салкынча... Күренеп тора, шәһәр тәртибен алып килгән кешенең кулы хуҗа монда...

Яшь килен, биленә кечкенә алъяпкыч буып, аш-чәй хәстәренә кереште. Ире дә аңа, кушмастан, булыша башлады.

Хуҗа бер чыккан арада, Клара җиңгәчәсеннән акрын гына: «Бабакайлар йорты еракмы, кайчан барабыз?» — дип сорап куйды. «Ерак түгел»,— диде җиңгәчәсе; шуннан Клара бик үтенгәч, алар чәйгә хәтле барып килергә булдылар.

Урамга чыккач, җиңгәчәсе Кларaны югары очка таба алып китте һәм бераз баргач та ике йорт арасындагы иркен генә бер буш урын каршында тукталды.

— Менә шушы була инде бабаңнарның утырган җирләре, Иркә туташ! — диде ул, кабер өстенә килгәндәй тавышын акрынайтып.

Клара, берни аңламыйча, әүвәл алга, аннан тирә-ягына каранды. Нәрсә соң бу?.. Урамнан алып, инешкә төшеп җиткәнче алабута, кычыткан, әрекмән басып бетергән буш җир җәелеп ята. Ник бер агач, ник бер таш, ник бер каккан казык күренсен! Бу урында кайчан да булса кемнәрнеңдер йорт-җир белән дөнья көтеп яшәүләрен күз алдына китерүе дә бик читен иде. Җиңгәчәсе, аның хәлен аңлап булса кирәк, җиңелчә көрсенеп әйтеп куйды:

— Бетте шул инде, нигез дип әйтерлеге калмады...

— Ә кая булды соң мондагы йорт, бабакайдан калган йорт? — диде Клара, нигәдер бераз сабырсызланып.

— Соң белмисеңмени, бабаң бит, сезнең янга киткәндә, йортын сакау Хисамига сатып китте! Хисами, сугыш беткәч тә, сафхузга күчеп китте. Йортын да шунда күчерде...

Клара алабута, кычыткан баскан буш җиргә карап тора башлады. Шушы икән инде... «нигез»!.. Бернинди кызгану-фәлән кебек нәрсә хис итмәде Клара үзендә, тик алдануы өчен кәефе генә азрак кырылды... Бер генә дә күрер нәрсә калмаган ич! Билгесез, ят бер урын икән бу аның өчен... Әгәр бабасы үзе бу ташландык урынны кайтып күрсә, нишләр иде икән? Түзмәс иде, елар иде, һичшиксез елар иде... Туган җирем, гомер иткән җирем дип, шәһәрнең дүрт стенасы эчендә гел сагынып утырды бит!

— Җиңгәчәй, син бу йортны беләсеңдер инде?

— Һи, белмичә соң? Мин бит шушы йортка килен булып төштем. Минем Хәмматшам бабаеңнан аерылып чыкмаган иде әле... Туебыз бик тә күңелле, бик тә шәп узды... Вәлиулла абзый, мәрхүм, туй капкадан килеп керүгә, мылтыктан атып җибәрде. Ул халык, мин сиңа әйтим, ул бала-чага!.. Мине җитәкләп ак киез өстеннән генә өйгә алып керделәр... Һи, сөйләсәң, Иркә туташ, исең-акылың китәр. Үтте инде... үтте. Аллага шөкер, менә хәзер үзем дә киленле булдым. Тик Хәмматшам гына күрмәде.

Алар, акрын гына кузгалып, Сәйфетдин абзыйларга кайтып киттеләр.

Чәйне озаклап, тәмләп эчтеләр. Сәйфетдин абзасы белән җиңгәчәсе сөйләшеп рәхәтләнделәр генә. Әллә кайчангы хәлләрне искә төшереп, әллә кемнәрне телгә алып бетерделәр. Кем белән ни булган, кем кая киткән, ул анда ничек тора, кемнең баласы кайсы шәһәрдә кем булып эшли, кемнең улыннан яки кызыннан күпме акча килгән, ә кем бер тиен дә җибәрми — барысын санап чыктылар. Клара бернәсәгә гаҗәпләнде: Каракоштан доньяга сибелгән кешеләр гаять күп икән... Ерак Көнчыгыш, Себер, Урта Азия, Урал, Мәскәү, Ленинград, Киев, Баку — кая гына барып чыкмаганнар алар! Тагын шунысы кызык: кайда гына булмасыннар, ниндидер нечкә җепләр аларны Каракош белән һаман бәйли икән әле.

Чәйдән соң яшьләр авыл буйлап бер йөреп кайтырга дип чыгып киттеләр.

Сания үзе дә, аның ире Зиннур да Клара өчен бик кулай кешеләр булып чыктылар. Алар Кларачы урам уртасыннан түбән очка таба алып киттеләр. Авылның хәл-әхвәлен аз-маз сөйләп бардылар.

Кларага колхозның былтыр гына салынып беткән яңа идарәсе белән гаражын күрсәттеләр. Клара: «Ә клубыгыз бармы?» — дип сорагач, Сания аңа бер генә сүз белән җавап бирде: «Булачак!»

Кларага идарә каршында торган мәчетне дә күрсәттеләр. Клара гаҗәпләнеп калды: мәчетнең тәбәнәк кенә манарасы белән кәкрәйгән ае да бар, имеш! Ничек сакланган ул! Ләкин бик тә искергән, тузган инде. Мәчет Кларада ятсыну һәм шомлануга охшаган ниндидер бер авыр хис уятты. Ә бабасы аның мәчет катындагы мәдрәсәдә укып йөрүен сөйли торган иде. Анысы хәзер юк, күрәсең.

Мактаулы Каракош! Клара үзенчә бик кызыксынып, сынап карый аңа. Монда беренче күзгә ташланган нәрсә — авылга каршы яклап тезелеп киткән таулар иде. Бабасы: «Каракош-кайның таулары киртләч-киртләч, киртләчләре бетә кар киткәч»,— дип җырлый торган иде. Чынлап та, бу ак маңгайлы текә тауларны вак ерганаклар агып һәм кәҗәләр таптап, аркылыга-буйга сырлап бетергәннәр икән. Таулар Кларага ни өчендер тәбәнәк һәм боек күренделәр.

Авыл үзе бик чуар. Өйләренең искергән-тузганнары да күп, ишелергә торганнары да бар, нигезен яки түбәсе яңартып җибәргәннәре дә шактый гына, өр-яңадан салынганнары да очрый... Әгәр Клара урынында берәр дөнья күргән олы кеше булса, ул бу өйләргә карап авылның үткән тарихын да, бүгенге хәлен дә китаптан укыган шикелле укыр иде.

Авылдан тип-тигез тугайлыкка барып чыктылар. Алда — буа, буада — иске тегермән, тегермәннән ары ферма каралтылары күренә. Ямь-яшел тугайда кәтү-кәтү ап-ак казлар утыралар.

Яшьләр авыл артына, чирәмлеккә күтәрелеп, шуннан ашыкмыйча гына кайтырга чыктылар.

Монда җире дә, һавасы да бүтәнчәрәк икән — ничектер дала исе аңкый. Бәрчекләнеп торган кара туфрак, эсседә кипкән сирәк үлән һәм ефәк чуклы кылганна... Кылганнар... Гел бер якка таба селкенеп торалар икән бу... кылганнар. Казан тирәсендә юк бит алар!

Сания, иелеп, җиргә учлам-учлам ябышып үскән вак кына зәңгәр чәчәкле бер үләнне йолкып алды да Кларага:

— Мәгез әле, иснәп карагыз! — дип сузды.

Клара үләнне алып борынына китерде һәм хәйран калды: үлән искиткеч хуш исле иде.

— Нәрсә бу?

— Ислемай үләне! Клара аны тирән итеп, кат-кат иснәде һәм бермәлгә исереп киткәндәй булды. Чиксез дала аның күз алдына килде. Бабасының яшь малай чагын, шушы ислемай үләннәре җыя-җыя йөгереп йөргән чакларын ап-ачык күргәндәй булды... Кинәт шулкадәр ерак үткәнгә кайта алу әллә ничек шомлы да, әйтеп бетергесез татлы да булып тоелды аңа... Айнырга теләп ул башын кат-кат чайкап куйды.

Сания тагын ак әремне дә уып иснәтте. Монысыннан да дала эссесе, дала исе аңкып тора иде. Клара ихтыярсыздан: «Әтием бу исләрне ничек оныта алды икән?»— дип уйлап куйды.

Ә менә бабасы онытмаган иде, сагына иде. Әгәр ул исән булса, Клара бу үләннәрне алып кайтып аңа иснәткән булыр иде.

Кайткач, тагын чәй эчтеләр, бик тәмле аш ашадылар. Ниһаять, көн сүрелгәч, Сания белән Зиннурны берсекөнгә Зиреклебашка кунакка чакырып, юлга чыктылар.

Авылны чыкмас борын Рәхмәй абыйсы атын беразга гына кибет алдында туктатты. Җиңгәчәсе кибеттән чикләвек, йөзем, кипкән өрек кебек нәрсәләр алды. Клара барысы өчен түләп тә өлгерде. Шуннан соң Клара Рәхмәй абзасына, көчләп дигәндәй, илле сумлык акча бирде. Рәхмәй, үзеннән дә өстәп, ике шешә акны, бер шешә кызылны алды. Шуларны кучер астындагы печәнгә әйбәтләп яшергәч, утырышып, авылдан чыгып киттеләр.

Тау итәгенә җиткәч, барысы да җанландылар. Җиңгәсе калкынып:

— Машалла, кайтып җитәбез түгелме соң? — диде.— Һи, көтү дә кайтып бара икән ләбаса!

Шул чакта Клара бик сәер бернәрсә күрде: җирдән, кәҗәсарыклар арасында, әллә нихәтле сыерчыклар кайтып килә. Нәкъ менә көтүгә чыккан йорт кошлары шикелле очмыйча, җәяүләп, йөгерә-йөгерә кайтып киләләр. Бу гаҗәп сәер, кызыклы күренештән кәефе килгән Клара кычкырып җибәрде:

— Җиңгәчәй, карале, көтүдә сыерчыклар!

— Ә, ие шул! Бала очыргач, көтүдән калмыйлар инде алар. Мал тирәсендә аларга азык табыла. Мал белән бит чебен дә, корт та ияреп йөри... Шуларны чүплиләр бу Алла кошлары!

«Удивительно!» — дип уйлап алды Клара эченнән. Аңа ничектер берьюлы күңелле, рәхәт булып китте.

Рәхмәй абыйсы, артына каерылып, кояш баешына карап алды.

— Иртәгә дә аяз булмакчы икән,— диде ул, башын кагып.— Бик әйбәт. Печәнчеләргә мач килә.

Клара, кинәт җанланып:

— Җиңгәчәй, минем дә печәнгә барасым килә,— диде.— Миңа барырга ярыймы?

— Ник ярамасын! Ярый, бик ярый, аккошым! Үзем алып барырмын,— диде җиңгәчәсе, ничектер Клараның бу теләген шунда ук куәтләп.

— Барабыз, җиңгәчәй, барабыз! — диде Клара, чын-чыннан рухланып, һәм аны кинәт ниндидер бер канатлану, җилкенү биләп алды. Һич уйламаганда, аның менә хәзер үк әнә шул

Чабылтауга менәсе, шуннан дөнья өстенә бер карыйсы килде. Ул атны туктатырга кушты: «Мин тауга менәм!» — диде. Җиңгәчәсенең аптырап: «Һай, Иркә туташ, каян уйладың әле, кояш та баеп бара, ялгыз куркырсың ич!» — диюенә карамастан, ул тарантастан төште дә ашыга-ашыга тауга таба китте.

Тауны мену читтән караганда гына ансат булып күренә икән ул. Тау, менә башлагач, шактый биек булып чыкты, аннары, югарырак күтәрелгән саен, ул текәрәккә әйләнә барды. Кларaның әледән-әле аягы тая башлады, хәтта ара-тирә артка таба шуып та киткәләде. Ләкин һичнигә карамыйча, үлән төпләренә аягын ныграк терәп, тазарак үскән сабакларга тотынып, иелә-бөгелә һаман күтәрелде. Ахырда, азаплана торгач, Чабыл башына менеп җитте...

Тау түбәсе — ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора. Монда сәер бер тынлык хөкем сөрә. Әллә нинди генә шунда, түбәндәге тормыштан аерылу хисен уяткан, бушлык халәтенә якын бер тынлык иде бу... Бу тынлыкта бары җилнең акрын гына исүе ишетелеп тора кебек.

Клара түбә уртасынарак атлады. Кояш баеп өлгергән иде инде... Ләкин бөтен әтраф бик якты иде әле, шунлыктан иң ерак офыклар да ачык күренә иде. Клара тантаналы бер киеренкелек кичергән хәлдә тирә-як дөньяны карарга кереште. Никадәр ерак җирләр ачылган иде аның күз алдында! Бик-бик еракта күгелҗем томанга өртелгән ялгыз таулар күренә, чиксез киңлекләргә сибелеп, әле тегендә, әле монда җиргә ябышып яткан авыллар күренә, җептәй сузылган юлларны да бик ачык аерып була. Хәтта юлларның теге яки бу төшендә, бөтерелеп сузылган тузанга карап, машиналар чабуын да шәйләп була иде.

Клара озак кына Каракошны эзләде. Кайда ул? Нигә күренми? Ниһаять, түбәндәге ике тау арасыннан ниндидер бер авылның читен күреп алды. Ул ерак та түгел иде. Клара чамалап карады: хәзер генә алар кайткан юл нәкъ менә шул ике тау арасыннан килеп чыга икән. Димәк, Каракош шунда. Каракошның бер генә читен күрү дә Клара өчен күңелле булып китте, ничектер менә авылдан аңа җанлы җеп сузылган кебек булды. Каракош аңа да якын икән ләбаса!

Аннары тирә-якка күз йөртеп, акрын гына артына борылды. Кинәт аның күзенә нидер көзгедәй уйнаклап-чагылып китте. Арбага ике яклап тезелешеп утырган егетләрнең бастырып тоткан чалгылары ара-тирә әнә шулай чагылып-чагылып киткәли

икән!.. Печән чабучылар кайтып баралар. Арттагы атларга, тырмаларын югары күтәреп, хатын-кызлар тәялгән... Бу күренеш Кларадны аеруча сөендереп җибәрде. Иртәгә бит ул үзе дә печәнгә чыгачак. Менә шулай, үзе кебек кызлар белән бергә, аякларын салындырып арбага утырган килеш, тырмасын күтәреп болынга барыр, болыннан кайтыр!.. Теге кем, Хәсән дигәннәре: «Кунак кызга тырманың җиңелен әзерләп куярбыз!» — диде бит... Мут күз! Шәһәр кызының кулларын үзенчә кызгана торгандыр инде. Тукта, күрсәтер әле ул аңа үзенең кулларын!

...Менә Зиреклебаш. Карасана, яп-якында гына икән ул. Бөтен өйләре, каралтылары, ишегаллары, көтүдән таралган маллары, кечке эшләрен бетереп йөрүче кешеләре белән, уч төбендәге шикелле, ап-ачык күренеп тора. Әнә иң кырыйда Рәхмәй абыйларының өе. Әнә капка төбендә моннан бармактай гына күренгән Алмас белән Алсу тауга карап торалар бугай. Исләре китеп Клара апаларын күзәтә торгандыр инде алар. Уңган җиңгәчәсе кай арада кайтып, учагын ягып та өлгергән — морҗаларыннан аксыл төтен акрын гына һавага күтәрелә... Кунакчыл өйнең сый-хөрмәт төтене бу... Юк, алай гына да түгел, туган туфрак төтене бу... Бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир! Һәм Клара, үз гомерендә беренче тапкыр моның буш сүз генә булмавын аңлап, шуңа исктикеч сөенде. Беренче тапкыр, бик табигый рәвештә, туган җиренә, туган халкына, телдән генә сөйләнә торган түгел, ә кан тамырында йөри торган чын якынлык-мәхәббәт хис итте ул... һәм бөтен хисләрдән дә изгерәк, көчлерәк бу хис аның яшь йөрәген әйтеп бетергесез куанычлы бәхет белән тутырды.

Ул башыннан эшләпәсен алып, йөзен кичке тау җиленә куеп, күзләрен дым каплаганчы чиксез киңлекләргә карап торды. Аерыласы килми иде аның бу тын биеклектән, бу яңа, тансык хисләр дулкыныннан...

1959 ел

Хикәянең эчтәлеге

«Туган туфрак» хикәясенең сюжеты бик гади кебек. Клара исемле шәһәр кызы бабасының үләр алдыннан әйткән васыятен үти: туган туфракны күреп кайтырга дип авылга кайта. Башта бер авылда, аннан соң икенчесендә булып, андагы кешеләр белән таныша, табигатьне күреп соклана.

Бу вакыйгалар, әлбәттә, хикәянең чын сюжеты түгел. Әсәрнең сюжеты — Кларaның эчке дөньясында, андагы хисләрнең хәрәкәтендә. Ә авылда күргән-белгәннәр — шул хәрәкәтне куәтләп торучы шартлар, дәлилләр генә.

Кичерешләр сюжеты Кларaның бабасы сүзләренә көлебрәк караудан башлана. Клара бабасының туган туфрак, нигез турында сөйләгәннәрен бөтенләй диярлек аңламый. Ул Туган ил төшенчәсен, Туган ил өчен үлүнең бәхет булуын яхшы белә. Аның бу инануы бәхәссез хакыйкать бит. Шулай булгач, бабасының хисләр, сагыну турында сөйләүләре аның өчен авыл кешесенең наданлыгы, артталыгы гына. Кларaны шушы яшенә кадәр мәктәптә дә, югары уку йортында да иске авыл ул, изелгән ярлы-хәерчеләр авылы дип өйрәткәннәр.

Авыл белән якыннанрак танышкан саен, Кларaның күңелендә үзенә таныш булмаган татлы хис күбрәк урын ала бара. Ул беренче мәртәбә моңа кадәр инанып яшәгән хакыйкатькә ышанмый башлый. Элеккеге авыл гел начар гына булмаган икән, анда да, ул вакытта да кешеләр җитешле дә, бәхетле дә булганнар. Макталган хәзерге заман авылы исә артык матур да, җитеш тә түгел.

Авыл белән якыннан танышу, Кларaның дөньяга карашын үзгәртә. Үз хакыйкатен табарга ярдәм итә. Сюжетның беренче вакыйгасы шундый үзгәреш белән тәгалләнә.

Туган як, туган туфрак, нигез сүзләре тора-бара хис белән тулыланалар. Яшь кыз күңелендә моңарчы күрмәгән яңа дөнья барлыкка килә. Бу дөньяны туган якка мәхәббәт хисе тудыра. Күңелендәге үзгәреш Кларaны рухи яктан баета, кеше итә, бәхетле итә.

Хикәянең сюжеты, шул рәвешле, Кларaның уй һәм хисләре үзгәрүеннән гыйбарәт.

Хикәянең сюжеты әледән-әле төрле кабатлаулар, каршылыклы күренешләр белән салмак агышыннан тукталып-тукталып кала. Әсәрнең буеннан-буена чәчеп чыккан кабатлаулары һәм каршылыклары белән Әмирхан Еники укучысын туктап-туктап уйланырга, әсәренең башында сөйләгән вакыйгаларына әйләнеп кайтырга өнди.

Кабатлауларның иң күбесе — тау.

Әсәрдә таулар күп һәм төрле-төрле. Тауны әдип итәгеннән торып та тасвирлый, икенче бер тау башыннан карап та сурәтли. Аның турында үзе дә сөйли, Клaрадан да сөйләтә. Тауларның иң гомуми һәм мөһим сыйфаты — биек булу.

Таудан тау биек, тау үзәннән дә, елгалардан, урманнардан да биек. Клара иң биек тауның башына менеп бөтен дөньяны берьюлы күрергә тели. Аның бу теләге турында да Әмирхан Еники кат-кат яза. Әсәр ахырында теләгенә ирештерә дә. Клара бабасы сагынып сөйләгән Чабыл тавына менә. Шул югарылыктан торып туган туфрагына бөтенләй башка күз белән карый. Моннан торып ул бабасы туган авылны гына түгел, бабасы йөргән урманнарны да, юлларны да, авылларны да берьюлы күрә. Шул яңа дөнья белән үзенең якынлыгын сизә һәм шуңа чиксез шатлана. Клара, шул рәвешле, рухи яктан күтәрелә. Дөньяны танып белүендә яңа биеклеккә менә.

Укучы тора-бара тауның символ булуын белеп ала. Шул вазифасы белән символ-тау туган туфрак эчтәлегенә ачыклык кертә: кешеләрдә туган туфрак хисе уяну дөньяга караш киңәю ул, ди.

Тау кешене җирдән югары күтәрә, аннан ераклаштыра. Ләкин тау башына менеп җирдән ераклашканчы Кларaны Әмирхан Еники җиргә якынайта. Бу якынаю Рәхмәй абзасының тарантасына утыргач башлана. Шул мизгелдән башлап ул авыл кешеләре һәм авылның гүзәл табигате белән якыная. Җирдә эшләүче кешеләрнең көнкүреше белән таныша. Тарантас аны җиргә төшерсә, тау биеклеккә менгерә. Клара җиргә якынайганнан соң гына биеклеккә менә ала. Икенче төрле әйткәндә, туган ягын якыннан белгәч кенә дөньяга башка биеклектән торып карый. Тарантас образы, шулай итеп, туган туфрак эчтәлегенә үз өлешен кертә: яратыр өчен башта белергә кирәклеген кисәтә.

Туган туфрак эчтәлеген әдип чәчәкләр аша да тулыландыра. Кипкән ак башлы кылган белән яшел, исле, зәңгәр чәчәкле үләнне янәшә куя. Укучы игътибарын кылганга җәлеп итәр өчен салмак кына сөйләп килгән җиреннән интонациясен үзгәртә: «Эсседән кипкән сирәк үлән һәм ефәк чуклы кылганнар... Кылганнар... Гел бер якка таба селкенеп торалар икән бу... кылганнар. Казан тирәсендә юк бит алар»,— ди.

Игътибар итик: әдип җөмләләрен кабатланулар белән дә, күп нокталар белән дә бүлгәли. Кылганга башка мәгънә бирүен шулай белдерә.

Әдип сүзен тыңлыйбыз һәм, тукталып, кылганның бәйләнешләрен эзлибез. Кылган шәһәр тирәләреннән киткән. Ул булган җирдә дала исе килә. Аның янында үскән чәчәкләрдән дә дала исе килә. Әмирхан Еники бу сүзгә дә игътибар итүне

сорый һәм аны да кат-кат кабатлый. Кылт итеп Хәсән Туфанның «Узып барышлый» исемле шигыре искә төшә. Без әдипләрнең барлык әсәрләрен дә белеп бетерә алмыйбыз, билгеле. Әмма «Узып барышлый» шигырен үзен укымышлы, мәдәниятле дип исәпләгән кеше белергә тиеш. Әмирхан Еники дә шулай дип уйлый. Ә Хәсән Туфан, искә төшерик, болай яза:

Дала, дала!
Туган җир дә түгел,
Торган җир дә түгел син минем.
Тезләндем мин изге туфрагыңа,
Нишләттең соң мине син бүген?

Нәрсә соң бу?
Өч-дүрт мең ел элек
Далаларда гомер кичергән
Бабайларның хәтерләре әллә
Уянамы минем хисемдә?..

Дала бит ул — безнең борынгы бабайларның гомер кичергән урыны. Дала исе — хәтер. Чал кылганнар ни өчен гел бер якка селкенеп ишарә ясыйлар? Тарихка таба бөгелмиләрме? Туган туфракның тарих белән бәйләнешен күрсәтеп тормыйлармы?

Туган туфрак тарихи хәтер белән бәйле һәм ул хәтер буыннан-буынга күчеп яңара тора. Туган туфракның изгелеге шуннан гыйбарәт.

Чәчәк-символлар өстәгән эчтәлек әдип өчен аеруча мөһим, шуңа күрә ул аны башка вакыйгада тагын бер тапкыр кабатлый.

Клара бабасы туып үскән йорт янына бара. Ул урында алабуталар гына үсеп утыра. Туган туфрак юк, нигез юк. Әмма алар Клара өчен генә юк, вакытлыча гына юк. Менә хәзер Хәмдия әбисе шул җиргә онытылып карап торыр да матур яшьлегенең иң гүзәл көнен күз алдына китерер: шушы нигезгә беренче тапкыр килен булып аяк атлавы турында сөйләр. Бик аз гына вакыт эчендә Хәмдия карчык яшьлегенә, бәхетенә әйләнеп кайтыр. Аның бу бәхете, үзе бер дөнья булып саклаган хәтере әлеге нигез белән бәйле. Шул рәвешле, юк нигез, юк йорт кинәт кенә бар була. Тирән мәгънә ала. Тарих булып хәтердә яшәгән вакыйгаларга әверелә. Бу вакыйгалар өзлексез җанланып, кешене яшәтеп, рухландырып, юатып торалар. Хәмдия өчен туган туфрак бәхетле көннәре белән бәйле кешеләрнең — туганнарының истәлеге. Аларга булган хөрмәтенең, мәхәббәтенең

яшь буыннарга да көчүе. Хәмдия җиңгәчәйнең Кларааны үз итеп, шатланып каршылавы һәм кулыннан килгән кадәр кунак итүе — әдәплелек билгесе генә түгел, туган туфрак хисенең табигый чагылышы да.

Бер Хәмдия генә түгел, Клараның хәтта бик ерак туганнары да аның кайтуына ихлас күңелдән шатланалар. Ләкин күп тә үтмәс Клара да якыннарын шулай матур итеп, ихлас күңеленнән каршы алыр. Клара да, авыл кешеләре кебек үк, кемнеңдер (хәтта туганы булмаса да) кайгысын уртаклашачак, ә кемнеңдер кызганыч язмышы өчен көенәчәк.

Клара, биеклеккә күтәрелгәч, үзендә мондагы табигатькә, кешеләргә якынлык хисе тууын сизеп сөенә. Ә без, Әмирхан Еникинең «Туган туфрак» әсәре белән танышып чыккач, туган туфрак хисе ул кешенең яшәеше, чынлыгы, изгелеге икән дигән нәтиҗәгә киләбез.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Хикәянең эчтәлеге» бүлеген өлешләргә аерыгыз. 1 нче, 2 нче, 3 нче дип һәр өлештәге темага исем бирегез. Шуннан соң бу бүлекнең планын төзегез.

2. Шул план нигезендә, үзегезгә истә калдырырга уңайлы итеп, конспект языгыз.

3. «Хикәянең эчтәлеге» бүлегендә анализ алымнары күрсәтелмәгән диярлек. Шулай да бу бүлек — әсәргә анализ. Сезгә билгеле тәртип буенча анализның барлык алымнарын кулланып язылган.

«Хикәянең эчтәлеге» бүлегеннән анализ алымнарын гына сайлап языгыз.

4. Хикәя сюжетының (кичерешләр агымының) үзгәргән урыннарын күрсәтегез. Ничек үзгәрүен аңлатыгыз.

5. Клараның дөньяга карашы нинди сәбәпләр аркасында үзгәрә? Бүлектә язганнарга үз күзәтүләрегезне өстәгез.

6. Кларада туган туфрак хисен тудыручы вакыйгаларны санап чыгыгыз.

7. Тау символы рухи биеклекне аңлатып килә, дидек. Әсәрдә бу хакта әйтелә. Шул урынны табыгыз.

8. Тауның биеклек кенә түгел, башка сыйфатлары да бар бит. Әсәрдә күрсәтелгән тауның башка яклары эчтәлеккә ниләр өсти ала?

9. Бүлектә чәчәкләрнең мәгънәләре турында да бик аз әйтелгән. Бу урынны тагын бер кат укып чыгыгыз, чәчәкләр тагын нинди мәгънәләр бирә алалар?

10. Автор Клараның җиргә якынлыгы турында әйтә. Шул урынарны табып укыгыз. Ләкин якынлык сүзен әдип башка мәгънәләрдә дә берничә урында кабатлый. Димәк, бу сүзгә тирән мәгънә сала. Нинди мәгънәләр салырга мөмкин?

ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

Баязит Бикбайга

I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр. Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәрне» җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнгәме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Менә бүген дә гел туңып тора, аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк»,— ди ул, үз-үзенә иренеп кенә, һәм авылга таба борыла.

Бәпкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе, диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән?

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Аның хәзер бер генә эше бар — ул ялан таптарга ярата. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләнче бригаданың да тегәнче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр.

Карт әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

— Нихәл, арумы, Миңлебай агай? — диде.

— Каян кайтып киләсең болай? — диде карт.

— Менә кизәк җыярга чыккан идем.

— Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

— Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора,— диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

— Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек,—диде карт.— Ярый, кортка, юлыңда бул! — Һәм карт, озын аякларын сыга биреп китеп барды.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда ашсуы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗалы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплән кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-савытын юу, аннары әзер казанда үзенә берике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Ләкин карчык сизә: пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана. Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрен алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишегалдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

— Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә бөгәрләнеп ятты. Ятып күзләрен йомуга, ул салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте. Күпмедер вакыттан соң бераз җылынган кебек булды. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме дип сорады. Әбинең

җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән иреннәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте.

Карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар. Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларына, кызларына хәбәр итикме, дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, шушында гомере буе яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята — йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр — шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта. Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына, гадәттә, бик кыска вакытка гына кайталар.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча тордылар. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыккан, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян — хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур

кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач...

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле... Менә зур улы Суфиян. Беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар — аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, нindидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читтән аша гына карап кала иде.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде — кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр. Оныгының күңелен табар өчен, Акъәби әледән-әле аңа башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни аңламыйча, «бабушкасына» бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

— А, да-да, точно! — дип баш кагып куя иде.

Менә шулай Акъәби ялгыз башы улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, исән-имин генә яшәп килде. Әмма быел урынга ук ятарга мәҗбүр булды. Күршеләре карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар. Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, мотоциклын пырылдатып, Акъәби капкасы төбенә килеп туктады.

— Саумы, Акъәби? — диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп.— Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

Сәетгали карчыкның суырылып, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды:

— Әллә, мин әйтәм,— диде бригадир, сак кына,— калага хәбәр итикме? Суфиян агай йә булмаса Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

— Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр,— диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.— Рәхмәт керүеңә, Сәетгали улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар.

Ә берничә көннән соң өр-яңа «Волга» машинасы Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Кызының: «Әсәем!» — дип дәшүен ишеткәч, Акъәби сискәнеп күзләрен ачты.

— Кызым, Гөлбикә! — диде ул, өзелеп.

Кызы шунда ук килеп аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар, тотынышып, икесе дә елап җибәрделәр.

Карчыкның кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде.

— Әсәем,— диде кызы, әнисенә үрелеп.— Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

— Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык авыр сулап кына куйды. Тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, Ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына — карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар каладан кайткан кадерле

кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен шулай әдәп саклап көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Йөзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул — кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә, ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар, иплән кенә утырттылар. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде:

— Акъәби, җаным, хуш, сау бул инде!

— Акъәби, бәгырем, терелеп кайта күр!

— Хуш, безне онытма, без көтәбез сине! — диделәр аңа. Ә таякка таянган бер карчык:

— Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен! — диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Машина шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби, кинәт урыныннан кузгалып:

— Һай, кәфенлегемне оныткамын лабаса! — диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм чыраен сытып:

— Куйсана, әсәй! — диде, үпкә катыш рәнҗү белән.— Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

II

Менә Акъәби ялгызы кечкенә генә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тоныклына ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята.

Карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп киттеләр. Чукечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә

чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тартынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли.

Әнисе янына күрешә килгәч тә, ул карлыкканрак тавышы белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

— Һай, әсәй, әсәй, әсәем! — диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып.— Ну, ничего, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип... Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

— Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап күреште. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк — карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде.

Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде — барыбер аның токымы, аның каны! Ах бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы — Татьяна, Светлана, Рита белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, бабушка!» — дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен караватр янындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык.

Ә Акъәби үз нәүбәтендә бу җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Карчык тирән

генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке! Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп керде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән. Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты... Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» — диде. Шуннан соң барысы да залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торуда мәгънә юк. Хәер, үзенә әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Акъәби калага килеп урынга яту белән Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар. Ләкин шулай да язарга ашыкмадылар.

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылары өчен бу бик читен хәл: алар үз-үзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, җан җылысымы, борчылып торумы кимеде кебек.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый. Тик ул көне буе ялгыз ятудан туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Бигрәк тә кызының ике баласын — алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Гүзәле, кыз бала булганга, ахры, авыру әбисеннән бер дә

ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» — дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «Әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр. Кунакларның күбесе читтәге бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу — тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!» — дип, ике куллап күрешә, аннары урындык алып, караватт кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның әчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъәби, Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә.— Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем — Акбикә,— ди карчык, бу көтелмәгән сораууга бераз пошынып.— Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

— Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул.

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! — дип әйтәсе килеп тора.

Шагыйрь, кызыксынып, һәм карчыктан иплән кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына... Карчык сөйләп беткәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

— Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

— Килешмичә нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки, борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса, сагынып идем,— ди карчык, уйланып кына.— Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — барысы да онытылмаска тиеш, минемчә...

«Сәер кеше,— дип уйлана карчык,— ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә ниндидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» — һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, ихластан кызганып кала торган иде.

...Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Башта ул, чынлап та, Юлкотлысын сагынып йөдәде. Бөтенесе: яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, маллары — бер генә минутка да исеннән чыкмый...

Карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар — җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул — гомере буена башыннан

яулыгын салмаган мөселман карчыгы — Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән, гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде.

Кызы бер кичне аның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

— Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар,— диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән.— Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне...

— Әсәем, бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә,— диде кызы, кат-кат башын селкеп.— Хәлең юк, тавышың бетә, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

— Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул...

Кызы урыныннан ук торды — ул гадәтенчә каядыр ашыга иде.

— Ярый хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде. Әмма аның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Балалар белән аның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары аның бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Ләкин шулай да аның балаларына үпкәлисе, рәнҗисе килми.

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар — шуларның барысы да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзаркурасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең ак ука тоткан, якут

каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән әдрәс[1] астарлы кашмау[2] белән чәчкабын[3] Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде.

Билгеле, кызы — кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка яшәп килде. Ул менә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Ходаем, туган илкәйгә юл? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил — туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларның сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минжиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә: «Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез «Аслы күл» әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы «Аслы күл» Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендыру өчен, атагыз сезне арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә «Аслы күл»нең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» әкиятен

---

[1] Әдрәс — ярым ефәк чуар тукыма.
[2] Кашмау — кием.
[3] Чәчкаб — баш киеме.

ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере, диләр, каеннар бәреп торган чишмәне Сусылуның озын, кара толымнарыннан саркып чыккан су, диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең «Аслы күл» яклары! Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз...

Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны бетергәч, калага китәбез дидегез,— каршы тормадык. Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез. Бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз?

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыругтан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббергә бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит — халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә. Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени?

Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде — сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы? Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һәй,

әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле»,— диделәр, гел тыйдылар һәм аны юатыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр — торса, тагын бер атна-ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тудырды.

Кияве белән кызының фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә, бик авыр, бик күңелсез булачак. Нишлисең инде, үләргә булгач, кайда да барыбер... Аның каравы балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар.

Бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште.

— Што сез,— диде кычкырып,— кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

— Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзеңә аласың... Сиңа да ана бит ул!

Бу сүзләрдән соң Суфиян шактый аптыраугa төшеп, җилкәсен кашырга тотынды. Һәм бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй җаным,—диделәр алар аңа иплән кенә,— докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның сәбәбен сизгәндерме-юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым җитте, аңлагыз шуны!» — диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар һәм больницага илтеп салдылар.

...Өч тәүлек үтүгә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй киткән дә барган.

Иртән-иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җеназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Суфиян — әсәен озату шәрәфенә, бөтен орден-медальләрен өряңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник — кабер кырыенда таш сыңдай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

...Күмеп бетергәч тә, борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды.

— Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек,— диде ул, салмак кына.— Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?.. Күрә белдекме

без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян, кычкырып, аның сүзен бүлде:

— Син ни сөйлисең, ә? Ташла, кирәкми...

— Безобразие бу! — диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда: кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз дип, борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук карчыкның колхоз машинасына салып җибәргән иске яшел сандыгы да килеп төшә. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта берберсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), кашмавы, чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында ук үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук

аталарының камчат бүреге дә килеп чыкты. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле камчысы иде.

— Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бу! — дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

— Да-а, менә бу ичмасам реликвия! — диде кияве дә, сокланып.— Тик кем саклар аны?

— Ә аның хуҗасы бар,— диде Суфиян катгый рәвештә һәм улы Геннадийга борылып әйтте: — Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхмәтовлар кулында йөргән камчы бу!..

...Инде калган әйберләрне нишләтү мәсьәләсе кузгалды. Кияүләренең башына шәп бер идея килде. Ул болай диде:

— Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит... Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә, киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр.

Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен кием-салымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп саф көмештән эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Куышакуыша йөгергән кылганнар арасыннан озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә.

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

— Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми — ул бит аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән

иде. «Балалар акылы керә башлаган ахрысы бу картка»,— дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

— Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

— Алдама,— ди ул, таягының башын селкеп.— Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөзьяшәр Миңлебай карт!

1965 ел

Хикәянең темасы

Акъәби һәм аның авылдашларының рухи дөньясы белән без Әмирхан Еникинең «Туган туфрак» хикәясендә таныштык. Андагы персонажларның исемнәре, яшьләре башка иде, әмма Хәмдияләр һәм аның авылдашлары да изге хисләрне саклап торучылар, алар да кешене шул хисләр генә кеше итә дигән уй белән яшиләр. «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә Әмирхан Еники Акъәбинең фаҗигасен язса да, аны барыбер Хәмдиягә охшатып тасвирлый.

«Туган туфрак» хикәясендә Клараның ата-аналары турында йөгереп кенә, алар авылларына кайтмыйлар дип кенә әйтеп үтелгән иде. Бу әсәрендә әдип төп игътибарны Клараның әти-әниләре кебек кешеләргә юнәлдерә.

Нинди кешеләр соң алар — Клараның әти-әниләре һәм Акъәбинең балалары?

Иң җиңел җавап мондый: алар әниләренең васыятен тыңламыйлар, үтенечен үтәмиләр. Туган туфрактан аерылган кешеләр.

Бу җавапта туган туфрак хисен югалткан кешеләр, хәтта әниләрен дә санга сукмый башлыйлар икән дигән фикер ята. Ләкин бу фикер безне канәгатьләндерә алмый.

Акъәбинең уллары, кызлары, киленнәре, кияүләре һәм оныклары — һәммәсе дә үзләрен ата-аналары алдында җаваплы итеп күрсәтергә тырышалар. Алар әниләренең хәле авырайганын белү белән тиз генә аны кайтып алалар. Ананы иң яхшы табибларга күрсәтәләр. Тәрбиялиләр.

Акъәбинең балалары — әдәпле кешеләр. Алар әниләренә бер генә авыр сүз дә әйтмиләр. Хәлен белеп кенә торалар, юаталар, авыруын әйтеп борчымыйлар.

Ә менә хикәянең исеме — «Әйтелмәгән васыять». Әйтелмәгән, чөнки Акъәби үзенең васыятен күпме генә әйтергә омтылмасын, аны берәү дә тыңламый. Тыңламыйлар, шулай да үзләре кыенсыналар. Кәфенлеген кайтып алмыйлар, ләкин әбинең сандыгыннан ап-ак кәфенлек килеп чыккач, бер-берсенең күзенә туры карарга да оялалар. Әбине, өйдә үлүеннән куркып, хастаханәгә озаталар. Озаткач, тагын оялгандай итәләр.

Менә шундый каршылыклы кешеләр әбинең балалары. Ни өчен шундыйлар?

Вакыйгаларны искә төшерик: авылдан кузгалып киткәч, кәфенлекне кире кайтып алмыйлар — борылып кайтып мәшәкатьләнәселәре килми. Васыятьне тыңлап тормыйлар, юк-бар нәрсәгә вакыт әрәм итәбез, дип уйлыйлар. Акъәбине, өйдә калдырыгыз дип ялваруына да карамастан, хастаханәгә салалар,— өйдә үлсә, мәшәкате күп булыр дип куркалар.

Әбине өйгә алып кайту да мәшәкать мәшәкатен, әмма бу мәшәкатькә алар бурыч үтәү өчен генә риза булалар.

Моны Акъәби үзе дә абайлап ала. Әбинең фаҗигасе үләсен белүдә түгел, үлемне ул олыгайгач һәр кешегә килә торган гадәти бер вакыйга итеп кенә кабул итә. Ул балаларының хиссез, рухсыз, хәтерсез чит кешеләргә әйләнүләрен күреп кара хәсрәткә бата. Елмаюларында җылылык, хәсрәтләрендә тойгы, мәхәббәт сүзләрендә хис юклыгын күреп телсез кала.

Әмма әдип Акъәби күрмәгәнне дә күрә.

Суфияннар, Гөлбикәләр күктән төшкән кешеләр түгел. Кайчандыр алар шул ук Акъәби тәрбиясендә үскәннәр. Аларның да учагында Акъәби кабызып җибәргән мәхәббәт күмере калган иде. Әниләренең ялварган күзләренә караганда бу күмерләр пыскып-пыскып куя. Балалары әниләрен алдаганнары өчен дә оялалар, шул оятларын басар өчен, бер-берсенә авыр сүзләр әйтәләр.

Туган туфрак хисе Суфияннарның инде катып өлгергән бәгырьләрен җиңә алмый. Ул бит вакытлыча, әниләренең үлеме алдыннан гына үзенең барлыгын белдереп куйган иде. Аның Суфияннарны гомерләре буена үкенечтә яшәтерлек һәм чын мәгънәсендә бәхетле итәрлек көче юк.

Тынычлыкта, үз җаең белән генә, заманга ярашып яшәү өчен Суфияннарга, Гөлбикәләргә тизрәк туган туфрак хисеннән

арынырга кирәк. Чөнки ул аларга хәзер борчу гына тудыра. Хәтердәге бөтен җылы хисләрне, туган як белән бәйле булган барлык нәрсәләрне юк итәргә, каядыр тапшырып күздән югалтырга кирәк.

Шул рәвешле, милләтне — милләт, авылдашларны — авылдаш, гаиләне — гаилә, ә кешеләрне кеше иткән туган туфрак хисе заман өчен яраксыз, искергән бер гадәткә әйләнә. Ул яңа тормыш таләбе белән югалырга, онытылырга, сүнәргә тиеш була.

Олыларга, якыннарга, туган якка хөрмәт, мәхәббәт уты сүнүгә кем гаепле? Кларaның әти-әнисеме? Суфиянмы? Гөлбикәме, аның иреме?

«Безнең яшәү рәвешебез»,— дип җавап бирә Әмирхан Еники бу сорауга. Кызганычка каршы, тормышта заман агымына ияреп, ваемсыз гына йөзүдән дә җиңел эш юк. Һәм шулай йөзүчеләр көннән-көн арта бара. Кешеләр күңелендә балачактан ук салынган туган туфрак хисләре көннән-көн сүнә.

Заман шаукымына ияреп, Акъәби балалары да үзләрен тормыш агымы иркенә куйганнар.

Ләкин бу агымга каршы йөзәргә дә була бит әле. Алай итү мәшәкатьлерәк, ә хикәя язылган елларда хәтәр дә иде. Алай да Акъәбиләр, Миңлебай бабайлар, әбинең күршесе Гарифә кебек авыл кешеләре күңелләрендәге изге байлыкны төкмичәчми саклап кала алганнар бит. Шәһәрдә Шагыйрь кебек һәм, ниһаять, автор Әмирхан Еники кебек кешеләр югала барган матурлыкны торгызырга теләп җан атып йөриләр бит!

Туган туфрак темасына Әмирхан Еники әледән-әле әйләнеп кайта. Аны әле бер яктан, әле икенче яктан ача. Шуларны гомумиләштереп әйтсәк, әхлак — туган туфрак хисен саклап калудан гыйбарәт, үзенең изге нигезеннән аерылган әхлак буш сүз генә дигән нәтиҗәгә киләбез.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Хикәянең темасы» бүлегеп инша дип фараз итегез. Иншаның планын төзегез.

2. Бу бүлектә дәреслек авторы фәнни коры стильгә үз хисен дә кушып җибәрә. Шул урынны табыгыз.

3. Дәфтәрләрегезгә бүлекнең конспектын языгыз. Моның өчен үзегез төзегән планнан файдаланыгыз. Конспект фәнни стиль белән генә языла. Алдагы дәрестә өй эшен конспектыгыздан файдаланып сөйли алачаксыз.

4. «Хикәянең темасы» бүлегендә тема бер яктан гына ачылды. Әсәрнең эчтәлеген табу өчен, хикәя эчендәге һәм тышындагы бәйләнешләрнең мәгънәләрен белү кирәк. Шулай иткәндә, төп тема башка яклары белән дә ачылачак.

Хикәягә анализ ясагыз.

Нәтиҗә

Без төрле сыйныфларда Әмирхан Еникинең дүрт әсәрен өйрәндек. Һәр әсәрен өлешләргә бүлдек, андагы метафора-вакыйгаларны, символларны таптык, кабатланган урыннарның ни өчен кабатлануын ачыкладык, исемнәреннән мәгънәләр эзләдек. Икенче төрле әйткәндә, бербөтен әсәрне кабат җыеп куяр өчен таркаттык.

Ләкин үз чиратында һәр әсәр — язучы иҗатының бер өлеше бит. Без, бер әсәрне бөтен бер күренеш итеп өйрәнгән кебек, язучы иҗатын да бөтен күренеш итеп күзаллый алабыз. Моның өчен аерым әсәрләр арасындагы бәйләнешләрне табарга, әсәрләрнең охшаш якларын күреп алырга һәм шул нигездә берләштерергә, ягъни гомумиләштерергә кирәк.

Әмирхан Еники без өйрәнгән әсәрләренең барысында да гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр турында яза. «Матурлык» хикәясендә, мәсәлән, әти-әнисенең балаларына, балаларының әти-әнисенә мәхәббәтен табигатьтә була ала торган иң гүзәл матурлык дип бәяли. «Бер генә сәгатькә» хикәясендә кешеләрнең гаиләдән аерылуы иң зур фаҗига булуын күрсәтә. Ә «Туган туфрак» белән «Әйтелмәгән васыять» әсәрләрендә туганнарның, авылдашларның бер-берсенә якынлыгын, мәхәббәтен, кешене кеше итә торган, аңа бәхет биргән иң изге, иң тотрыклы хис дип бәяли. Бу хискә ул туган туфрак хисе дип исем бирә.

Милләт үзенең рухи нигезен югалтып таркала. Аны ничек саклап калырга?

Әмирхан Еники һәр әсәрендә диярлек шул сорауга җавап эзли, шул сорауны куеп кешеләрдә борчу уятмакчы була. Шуңа күрә милләтнең рухи нигезен саклап калу проблемасы әдип иҗатында күтәрелгән төп проблема дип нәтиҗә ясыйбыз.

Әмирхан Еники милләтне саклап калу проблемасын бу хакта авыз да ачарга ярамаган елларда күтәрә. Бу елларда милләтләрнең бергә кушылып, телләрен, гореф-гадәтләрен югалтырга тиешлеге бәхәссез хакыйкать дип санала иде. Кызганычка каршы, бу «хакыйкать»не татарның үз зыялылары да халыкка ышандырырга тырыштылар.

Әмирхан Еники берьялгызы менә шул көчле, хәтәр хакыйкатькә каршы чыгарга курыкмады. Үз хакыйкатен ул хикәяләре, повестьлары, романнары аша укучысына сабыр гына аңлатты.

Әмирхан Еники әсәрләренең барысында да метафоралар, символлар, мәгънә тудыручы кабатланулар, үз-үзенә каршы килүче күренешләр күп. Алар һәрберсе үзара мәгънә җепләре белән бәйләнгәннәр. Әсәрләрне укыганда без шуларны эзләп табабыз, авторның ни әйтергә теләгәнен белү өчен әле әсәрнең исеменә, әле алдагы вакыйгаларга, әле метафораларга әйләнеп кайтабыз. Без инде мондый әсәрләрнең диалогка корылган булуын беләбез. Диалог дигәндә автор белән укучы аңлашуын күз алдында тоталар.

Диалог алымнары күбрәк булган саен, әсәрдәге эчтәлек арта бара. Потенциаль эчтәлекне дә фәкать әсәр эчендәге бәйләнешләр муллыгы гына бирә ала.

Диалог алымнарының байлыгы Әмирхан Еникинең стиль үзенчәлеге дип санала ала.

Аяз Гыйләҗев
(1928—2002)

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Бала чагы Зәй районының Югары Баграж авылында үтә. Монда ул унынчы сыйныфка кадәр укый һәм яңадан туган ягы Сарманга кайтып китә.

Сугышның соңгы (1945) елы... Өлгергәнлек аттестаты алу белән югары уку йортына калага китәргә мөмкинлек юк. Аяз колхозда эшләп ала. Кеше белән җиңел аралашучан тынгысыз бу егетне комсомол комитетында бик тиз күреп алалар һәм Зәй районына чакыралар. Монда ул комсомол комитетының бүлек мөдире булып эшли.

Ул, мәктәпне тәмамлап өч ел үткәч кенә, үзе теләгән югары уку йортына — Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтихан тота. Әмма монда ул нибары ике ел гына укып кала. Илдә репрессия дулкынының кабат көчәеп китүе, язучылык эшенә җиң сызганып тотынган яшь егетнең язмышын да хәл итә. Юлбашчыларга тел тидергәне өчен кулга алынуын ул төрмәгә утыргач кына белә. Казакъстанның кырыс табигатьле далаларында урнашкан төрмәләрдә, карцерларда утырып чыкканнан соң, ул ташчы, бетончы булып, аннары бригадир, десятник хезмәтендә биш елын үткәрә.

Аннары Казанга кайтып, «Чаян», «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында эшли. Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый һәм иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Аяз Гыйләҗев студент чагында ук хикәяләр язып бастыра. Ә инде «Дүртәү» дип исемләнгән күләмле әсәреннән соң, бер-бер артлы «Өч аршын җир» (1962), «Зәй энҗеләре» (1963),

«Урталыкта» (1969), «Урамнар артында яшел болын» (1969), «Язгы кәрваннар» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973), «Мең чакрым юл» (1977—1978), «Җомга көн, кич белән» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1979—1980) исемле повесть һәм романнар иҗат итә. Ә «Балта кем кулында?», «Йәгез, бер дога» романнарын соңгы ике елда тәмамлый.

Аяз Гыйләҗев — танылган драматург та. Аның сәхнәдә уйналган пьесаларын санап чыгу гына да ярты бит урын алыр иде. «Җиз кыңгырау», «Киек Каз Юлы», «Көзге ачы җилләрдә», «Җиргә тапшырылган серләр», «Әңгер-меңгер», «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз», «Хушыгыз, тургайлар», «Кара күзле кызлар», «Шомырт чәчәк атканда», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы кош», «Яланаяклы кыз» — Аяз Гыйләҗев язган пьесаларның бер өлеше генә.

Аяз Гыйләҗев тә — Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах кебек, тормышның иң яман чакларында да үз йөзен югалтмаган, һәркем күреп тә, әйтергә базмаган хакыйкатьне теләсә нинди юл белән укучысына ирештереп килгән кыю әдип.

ҖОМГА КӨН, КИЧ БЕЛӘН

I

Өстән, тауның иң биек ноктасыннан карасаң, Ташлыяр елгасын кодрәт белән сызып куйганнар диярсең: нәкъ көнчыгыштан ага да ага, Аксыргак авылына җитәрәк, икеләнеп кала; боргалана башлый, алай гынамы сиңа, ындыр артларына сырышып, куе-кучкылланып үскән таллар арасына кергәч, бераз күздән югалып та тора. Авылның түбән очына җиткәндә, Аксыргакның таудан бәреп чыккан биш чишмәсен дә үзенә алып, тагын ачыла Ташлыяр. Түбән очта ишәеп ачыла, аннан кинәт тарая, ярлары текәләнә, агымы шәбәя, ярга бассаң, аккан тавышы ишетелә башлый.

Соңгы елларда Зәйдә ГРЭС салдылар — ул тирә-як авыллардан байтак чуар йөрәкләрне җыйды. Аксыргактан да бик күпләрне үзенә суырып алды, авыл уртасындагы дәрәҗәле урыннарда да буш ихаталар ешайды...

Яткын җирләрне үзләштерү шаукымы тар җирле Татарстан авылларыннан узган иде. Шуңа күрә аръяктагы бу урынга кызыгучы да, күз салучы да табылмады: җир мөгаен генә

шактый еллар шулай буш килеш ятар да иде, колхозга яңа председатель килде.

Җиһангир Сәфәргалин, читтән килгән булса да, эшне чын хуҗаларча башлады. Иң әүвәл урам-тыкрыкларны рәткә китерде, тракторларның эресен-вагын ел әйләнәсендә урамга керүдән тыйды. Бик күп җирләргә агач утыртылды. Аксыргак тарихында беренче буларак, Ташлыяр аша тимер култыксалы күпер койдырды.

Алдагы елда Сәфәргалин зират коймасының баганаларын бетон белән алмаштырды, урам чатларына лампочкалар элдертте.

Иң соңгы мактаулы эше шул булды: Түбән очта, Ташлыяр кинәт кенә тарайган урында елганы будыртты. «Киленнәргә кер чайкарлык, ә кайберәүләргә арык шавын тыңларлык булсын!» — диде.

Каз тавышы, бәләк тавышы яңгыраганда арыкның акрын гына тавышлана башлавын ишетмәделәр дә әле. Арык шавының кемгәдер, кайчандыр хаҗәт буласын, әлбәттә, берәү дә уйлап карамады.

Болар белән генә тынмады Сәфәргалин, буа аръягында буш урындагы өй-баз чокырларын бульдозер белән тигезләтте; койма белән әйләндереп алып, бөтен кишәрлеккә каен аралаш яшь чыршы күчереп утырттырды. Бакча уртасында шәһәрдән килгән осталар гади генә дүртпочмаклы мәрмәр һәйкәл койдылар. Һәйкәлгә дә гап-гади сүзләр язылды: «Сугышта һәлак булган авылдашлар! Без сезне онытмадык!»

Аннан һәлак булганнарның исемнәре рәт-рәт тезелде.

Бусына да кул куйдылар аксыргаклылар.

Җиһангир Сәфәргалин кырык дүртенче яшенә чыккач, язгы кыр эшләре төгәлләнеп, Сабан туена нәкъ бер атна калды дигәндә кинәт вафат булды. «Йөрәк!» диделәр врачлар...

Аксыргаклылар «аһ!» иттеләр. Әтисе Җиһангирны монда калдырырга ризалык бирмәде. «Сәфәргалиннарның Тегәрҗеп авылында үз кадерле почмаклары бар, әби-бабалары шунда күмелгән. Вакытсыз китеп барган улымны да шунда күмәргә телим»,— диде.

Һәйкәл алдында матәм митингысында кайгылы-тантаналы сүзләр әйтелде, антлар бирелде; музыкантлар кайгы көйләрен туктаусыз уйнап тордылар.

II

Буа тавышын шул чагында беренче тапкыр аермачык ишетте Бибинур карчык. Шул минуттан ул үзенең кылган гамәлләренең сәбәп-нигезен аңламас хәлгә килде: Тегәрҗеп авылына карап Җиһангир Сәфәргалинны соңгы юлына алып чыккан машинада, мәрхүмнең аяк очында, йомылып кына, орчык башы хәтле бәләкәй карчыкның бөршәеп утыруын берәү дә күрмәде, берәү дә аннан: «Кая барасың син, әй кортка! Анда сиңа ни калган?» — дип гаҗәпләнеп сорамады.

Нигә Тегәрҗеп авылына кадәр үк озатырга ниятләде аны Бибинур?

Нигә утырды ул машинага?

Машиналар аның хатирәсе булган таш күперне тавышсыз гына уздылар. Урманга кергәнче ул башын күтәреп тә карамады.

Зират капкасы төбендә аларны кара болыт булып Җиһангирның авылдашлары каршылады. Кемнәрдер көчле куллары белән табутны күтәреп алды, халык савылып, мәһабәт тынлык саклап, эчкә керә башлады. Бибинур карчык, хатын-кыз буларак, әдәп саклап койманың бу ягында калды.

«Тар каберләрең киң булсын,— дип теләк теләде карчык,— исемең кешеләрнең якты күңелләреннән мәңге онытылмасын. Кыямәт газапларын татыма, оҗмахлы бул! Чөнки син кешеләргә бары тик матурлык, азатлык кына теләдең».

Ятим, япа-ялгыз, кем өчен еласын, байтактан күзеннән яшь чыкканы юк иде, бүген күз төпләре рәхәт кычытып дымланды, ул коймага маңгаен терәп елый башлады, үкси-үкси җиргә чүкте. «Хуш, Җиһангир балам, хуш, асыл затым, хуш, нә-нәм!» — дип, байтак үрсәләнде Бибинур.

Ул исенә килеп зират тирәли урап чыкканда, мәетне күйганнар, халык таралышкан иде инде.

Аның аягы атламас булды, ул койма кырыендагы җылы җиргә утырды. Тик нигә аны берәү дә күрмәде соң?

Шактый вакыт узды бугай. Җир өстендә мыштым гына кичке дым йөгерде, тургай тавышлары тынды. Авыл ягыннан сискәндергеч аяк тавышлары ишетелгәч кенә дерт итеп калкынды, сүзсез караңгылыкка текәлде.

Килүче Вәли карт иде.

— Күргән кешегә дә охшатам. Ә-ә— дип сузды карт.— Машинада күрдем мин сине. Нишләп кайтып китмәдең соң, алайса?

— Белмим,— диде Бибинур, аптырап.— Машиналар киткән иде инде, зиһенем таралды.

— Син кем белән торасың соң? — дип кызыксынды карт.

— Бер башым,— дип, авыр гына көрсенде карчык.

Вәли: «Балаларың кайда?» дип сорарга да теләгән иде, ниятеннән кайтып өлгерде:

— Алайса, куна калсаң да, сүз әйтүче юк икән. Чәй эчмичә барыбер җибәрмим.

Чәй эчәсе килә иде Бибинурның. Бусына ул тиз ризалашты.

Алты почмаклы өй янына тиз үк кайтып туктадылар.

Җиһангирның анасы, күз төпләре караеп күгәргән карчык, картының күз карашын аңлап, сүзсез генә табын әзерләргә керешге. Җиз самовар өстенә ак тастымал капланган булса да, Бибинур таныды, Тула самовары! Кайчандыр аларның да шундый самовары бар иде... «Тульский оружейный завод. 1926 год» дип язылган... Самоварны күргәч, аның хәле бетеп китте.

Ашау-эчү тәмамлангач, сәкедән ашъяулык киткәч кенә әңгәмәгә керештеләр.

Хуҗалар Бибинурны артык кыстамадылар. Вәли карт аны авыл очына хәтле озата килде.

— Улымны олылаганың өчен рәхмәт.

— Әйбәт кеше иде бит.

Бибинур, карттан аерылгач ук, адымнарын кызулатты.

III

Курка-шүрли барса да, җиде чакрым йөргән аякка арамыни, Бибинур таң яралганда авылга кайтып керде.

Ялгыз карчыкның йокысы күбәләк гомере генә, ятты да торды да. Ике тапкыр кибет тирәсен урап килде. Ачмый гына бит Әсмабикә уңмаган.

«Яңа эчке күлмәк белән яңа ыштан алырга кирәк»,— дип уйлады ул.

Бар иде аның, түшәм матчасына кыстырып куйган шыгырдап торган унтугыз тәңкәсе бар иде. Соңгы айның пенсиясе. Егерме тәңкә иде алганда, авызы явыз, тәмлегә кызыкты, бер тәңкәлек кәгазьле кәнфит алып кайтып суырып бетерде.

Галикәйнең дә егерме тәңкә генә пенсиясе! Акча турында алар икәү очрашканда гына сүз алышалар.

— Әй Бибинур, зарланма. Акча кешене боза,— ди Галикәй, ике җирдән сынык тешле авызын ерып.

Галикәйгә авыз ерса да була, улы-килене янында, үзе дә тик ятмый, сунарга, балыкка йөри. Иясез этләрне ата, тиресен дә үзе или, бүрек тегеп җибәрә.

Гомумән, аларның эч серләре сыя. Җайлап сорасаң, Галикәй, килеп, идән тактасын алыштырып та куяр иде, акча да сорамас иде, тик беркемгә дә ялынып барырга яратмый Бибинур.

Ул унтугыз тәңкәне матчага кыстырган җиреннән алып, учына кысты һәм тагын кибеткә йөгерде. Арзанлы гына ситсы алып бер-ике ыштан тегеп җибәргәндә дә ярар иде дә, җөй машинасы да байтактан юк инде Бибинурның... Самовар белән бер елны бетте.

Кибеттә ике-өч хатын бар иде. Икесе түзәрлек, сүз-йомыш сыя торган хатыннар, өченчесе Бибинурның игез сыңары Зөһрәбану иде...

Бер дә күрәсе килми иде Бибинурның үз сыңарын! Җәнҗал башлаучы Зөһрәбануга ашыгып кына карап алды да аның күзе шүрлектә төргәге белән яткан кызыл комачка төште.

Шушы төргәктән алынган бит инде Җиһангирның табутын чорнаган кызыл комач!

Эчке күлмәкләр эленгән баганага күзе дә төшмәде хәзер Бибинурның.

Нишлисең, кибеткә йөргәли Бибинур... Әйтергә кирәк, еш йөри, ялгыз карчык тагын кая барсын да нинди юаныч тапсын?

Гадәттә, ул кибеткә басынкы гына килеп керә. Әсмабикә белән бер-ике сүз алыша. Соңгы яңалыкларын сөйләп биргәч, игътибар белән тыңлап тора, үзе дә нидер ишетә. Кибеткә бер йомышсыз, сүз сөйләр өчен генә йөреп булмый. Абруеңны төшермәс өчен бик хаҗәт йомыш та эзләп табарга кирәк әле!

Ниләр генә кыланмый Бибинур мондый чакларда!

«Чәй кайттымы?» — дип сорый, озак итеп, җентекләп күлмәклек сайлый. Кулы арыганчы, озак итеп тотып торганнан соң, Әсмабикәгә кире кайтара. «Әйбәтен әйбәт тә, мондый кадерле малны кем генә ала дисең хәзер?»

Ситсыларны, хуҗалык кирәк-яракларын, киштәдәге йөз төрле вак-төяк әйберләрне, һәммәсен аерым-аерым, биш-ун мәртәбә күздән кичергәннән соң, ул, кибеткә кергән саен, бер кап шырпы сатып ала. Хуҗалыкта утсыз яшәп булмый, мич арасында шырпы корыда череми дә, дымланмый да.

Күлмәгенең ямаулы, тирән кесәсендә аның һәрчак шырпысы булыр, шылтырап йөдәтмәсен өчен, ул икешәр капны берьюлы кулъяулыгы белән төйнәп йөртә, урамда очраганнарга кайчагында бер кабын сүтеп бүләк тә итә. «Миннән күрсеннәр, әйдә, яхшылыкны» дип уйлый ул канәгатьлек белән.

* * *

Бүген ул ишек төбендә икеләнеп тормады: нияте нык, фикере нигезле иде. Кулында йомарланган унтугыз тәңкә! Бик зур акча бит ул аңлаган кешегә! Аңа күпме шикәр, ярма, сыек май алырга була!.. Шикәр сипкән дөге бәлешен үлеп ярата Бибинур, бер башы гына булгач, бәлешне сандугач оясы хәтле итеп кенә пешерә. Ризыкның бөртеген дә әрәм итми, сөяк-санагын, калдык-постыгын ташларга жәлләп моннан ике ел элек, көзлектә, адашкан бер этне ияләштергән иде. Карабай иде исеме. Койрыгын селкеп, Бибинур әбисенең күзенә генә карап, сыйланып кыш чыкты да, салкыннар шиңеп, яз кергәч, каядыр китеп югалды.

— Әсмабикә, Әсмабикә дим!

Зөһрәбану да, кибетче дә аның шырпы сораячагын әллә кайчаннан белеп торалар.

— Әсмабикә дим, Сабан туе җитеп килә, мин һаман иске яулыгым белән йөрим. Син миңа менә шушы кызыл комачтан бер яулыклык кына кисеп бир.

Әсмабикә бик гаҗәпсенеп, тәэсирләнеп карчыкка яулыклык комач үлчәде. Бибинур карчык яулыкны ике кулы белән күкрәгенә кысып ишеккә җиткәндә, ул аны дәшеп туктатты:

— Бибинур әби! Әллә минем янга эшкә керәсеңме? Җыештыручы Камәр апа кулбашларым бик сызлый дип зарлана...

— Юк,— дип кистерде Бибинур карчык.— Эшкә керергә балалар кушмый.

— Балалар?! — Әсмабикәнең җәя төсле нәзек кашлары маңгаена сикерде.— Шулар кушмыймы? Ә алар синең ни рәвешле тереклек итеп ятканыңны беләме? Синең интеккәнне күрәме алар?

— Юк, Әсмабикә, үгетләмә. Балалар ишетеп алса яхшы түгел. Аларны рәнҗетәсем килми.

Бибинур шулай диде дә тиз-тиз атлап чыгып китте.

IV

Тыкрыктан менеп килүче Галикәй күзенә чалынгач, туктап аны көтә башлады. Бибинурның бу юлы аны күрәсе килә иде...

Ул кибеттән буш кул белән чыкмады бүген, кеше рәтеннән яшәп ята, Сабан туе алды икәнен онытмый, кулында өр-яңа комач яулык!..

— Бибинур,— диде Галикәй, мыек чылгыйларын йолыккалап.— Сине күрәсем килә иде! Сәгатем рәтләп йөрми дигән идең түгелме?

— Әйдә, ахирәт, гамәлен чутлый торган нәрсә түгел әле. Алга китсә ни дә, артка калса ни!

— Бибинур! — Галикәйнең тавышы бик сәер, нечкәреп яңгырады.— Кичкырын өең янынннан уздым, утың күренмәде.

— Мин өйдә түгел идем, Галикәй.

— Кичә кереп чыкмакчы идем. Син дә ялгыз, мин дә шулай диярлек. Әнә япь-яшьләр дә егылып үлә дим... Әллә бар гомер, әллә юк гомер дигәндәй, һәй, үзең дә беләсең инде! Сиңа күчеп килимме, Бибинур?

— Өйдәш булыпмы? Нигә миңа өйдәш?

— Өйдәш димим лә! — Галикәйнең кәефе кырылды.— Бөтенләйгә дим, синең янга!

— Әй Галикәй, Галикәй! — Авызы чак кына ерыла башлаган Бибинур кинәт җитдиләнде,— ә балалар? Алар ни әйтер?!

— Каф тау артына әнкәләреннән качкан балаларны оныт син, бөтенләй күңелеңнән чыгарып ташла! Юк синең балаларың!

— Нигә булмасын, бар.

Галикәйнең ачуы чын-чынлап кабарды, ул, буш брезент капчыгын селки-селки, урам уртасыннан кайтып та китте. Бара-бара да, очраган бер кешегә: «Юк дим мин аңа, балалары юк аның!» — дип кабатлый.

Нияте нык иде Галикәйнең: бер атуда ике куянны алмакчы була иде, тик һич тә җае чыкмый, Бибинурга үтемле итеп сүз кушарга базмыйча йөри иде. Бибинур, җил-җил атлап, Түбән очка төшеп китте.

Галикәйнең сүзе ошамады түгел аңа, киресенчә, бик ошады. Бик абруйлы кешесе авылның, чип-чиста, әйбәт карт. Ә карчыклар берсе дә Галикәйдән баш тартмаслар иде.

V

Бүген дүшәмбе. Сабан туена төгәл бер атна бар. Рәсәйнең бөтен почмакларына авылның иң сөенечле бәйрәменә чакырып телеграммалар инде киткән, кемнәрдер ашыгыч юлда, Бибинур гына беркемне дә көтми, ул кайтканнарның уртак шатлыгы белән, авыл сөенече белән юанып яшәячәк.

Шуңа күрә бәйрәмендә дә ул, бүгенгедән бигрәк, үткәннәре турында уйлый... Чын дөресен генә әйткәндә, үткән гомерендә дә бәйрәмнәрне аз күрде Бибинур, бик аз; тик аз күрдем дип авыз ачып зарланмады, шөкрана кылырлык, сөенерлек сәбәпләр тапты, көр күңел белән яшәде...

Бер гаиләдә биш кыз! Ата белән ана тилмереп малай көткәндә семьяга тагын кызлар — игезәкләр өстәлде... Зөһрәбану белән алар бик тату яшәделәр, бергә уйнадылар, башны башка куеп агач сандык өстендә бергә йокладылар. Тора-бара апалары кияүгә чыга башладылар.

Кызлары матур иде Гыйльфанның! Аерата төпчек кызлар — игезәкләр сылу булып үсте. Әллә төпчекләрнең бәхетен апалары ияртеп киттеме, унҗидене дә тутырдылар сылу Бибинур белән гүзәл Зөһрәбану, унсигез дә, егермегә дә җиттеләр, кызлы йорт капкасына берәү дә ат бәйләмәде.

Авылда комсомол ячейкалары төзелеп, колхозлар калкып чыгып, замана да, кешеләр дә, мөнәсәбәтләр дә тамырдан үзгәрә башлаган чак иде...

Берзаман, районда беренче буларак, алар балалар бакчасы ачтылар, кемнән киткән исем булгандыр, аны «Плащадка» дип атап йөртә башладылар.

Колхозның беренче рәисе Сабирҗан солдат беркөнне кәнсәләргә Бибинурны чакырып кертте.

— Кызым,— диде ул, Бибинурның аркасыннан сөеп.— Укуязуың бар, булганлыгың бар, беләбез, тот та кер син шул «Плащадка» балаларын карарга. Мәктәп директорының хатыны Хәнифә апаң мөдир булыр, син аш-су пешерерсең, кер юарсың, идән-сайгагын карарсың. Һәйбәт кенә эш хакы да куярбыз, ризамы?

— Ә Зөһрәбану? — диде Бибинур, куанганын белдермәскә тырышып.

— Зөһрәбану дисеңме? Кем аркасында кияүгә чыкмаганыңны беләсеңме соң син? Зөһрәбануны Зәһәрбану дип йөртәләр авылда. Безнең авылда пычак телле хатыннарны өнәмиләр, татарга аңа хатын юаш булсын.

Хәнифә кул астында Бибинур «Плащадка»да эшли башлады. Эшли башлавын әти-әниләре бик яраттылар. «Кызның бәхете бар икән!» — диделәр күршеләр. Зөһрәбану гына Бибинурның күркәм эшкә урнашуын ятратмады, Хәнифәдән өйрәнеп кайткан сүзләрен өйдә сөйләвенә җене чыкты. Сыңарының йорт эшенә, аш-суга остаруын күреп, көнләшүеннән шартлар дәрәҗәгә җитте.

Сыңар күз Сабирҗан солдатның сүзе рас килә инде әллә. Сабан туе кичендә, Бибинурларга өч йорт аркылы гына яшәп яткан аксыл юка чәчле, бик киң чыгынкы маңгайлы Мирзаһит аны кичке уеннан озата кайтты. Әткәсе хәстәрләгән эскәмиядә алар Сабан туе таңын каршыладылар. Мирзаһит бер генә түгел, күп тапкырлар килде. Аулак өйләрнең берсендә, «Авыллы» уйнаганда Мирзаһит Бибинурны караңгы өйалдына чакырып чыгарды, бит очыннан чут итеп үпте. Калай савытта кершән, кәгазь савытта пудра бүләк итте. Җавап итеп, Бибинур «М. Ш.» хәрефләре бүген иртән генә өстәлгән кульяулыгы бирде.

Кыр эшләре тәмамланып килә диярлек, хәзер Мирзаһитның тел төбендә өйләнү, туй ясау булса, Бибинурның да күңелендә шул уй иде.

Гыйльфан агай өендә «туй» дигән сүз яңгырауга, Зөһрәбану агач сандык өстенә капланып, кичкә кадәр үкседе...

Бибинур белән аралары көннән-көн кискенләште.

Мәктәптә укулар башланды. «Плащадка»да йөргән олырак балалар, киндер букчаларына каләм-дәфтәр тыгып, беренче сыйныфка киттеләр. Мәктәп биналарын аксыргаклылар куылган кулакларның йортларын сүтеп күчереп салганнар иде. Бу эшне Совет рәисе Габдуллаҗан Абдуллин дигән авылның иң актив кешесе башлап йөргән иде. Бу кеше берсеннән-берсе вак өч баласы, олы авызлы, ямьсез генә хатыны Гайшә белән уртача гына тереклек итеп яшә иде. Шул көннәрдә Аксыргак авылын гына түгел, бөтен тирә-якны тетрәткән канлы вакыйга булып алды.

Күзге явымлы, күзгә төртсәң күренмәслек караңгы кич иңә. Гайшә, иренең иске шинелен, бүреген киеп ишегалдына чыга. Лапас авызына барып җитүе була, кемдер аның арт чүмеченә тимер кендек белән китереп суга... Хатын аһылдап кычкырып җибәрүгә, оручылардан берсе: «Ул түгел! Ул түгел!» — дип акырып куя...

Габдуллаҗан балта күтәреп атылып чыкканда, Гайшә җан биргән була инде...

Төпчекләре Нәҗипне моңарчы «Плащадка»га Гайшә алып килә иде. Гайшәне җирләгәннең икенче көнендә баланы бакчага Габдуллаҗан үзе озата төште. Бибинур вакытсыз тол калган ир каршысына чыкты.

— Менә китердем,— диде ир, сабыр гына.

— Олылары ничек, Габдуллаҗан абый?

— Өйдә инде. Җылашып калдылар. Алары аңлый...

— Аларын да алып төшәрләр, Габдуллаҗан абый.

— Олыларын ничек тә карармын инде, төпчеген нишләтергә? Бакча барында әйбәт иде дә, тиздән «Плащадка»ны ябабыз бит.

Бәләкәй улын күкрәгенә кысып-кысып сөйгән Бибинурдан бик озак күзен алалмыйча торды Габдуллаҗан. Аларның күз карашлары очраштылар.

Бибинур ул көнне кичен Мирзаһит белән күрешергә тиеш иде, бармады. Егет ике-өч тапкыр аларның өй турыннан узып китте, өченчесендә бер генә җыр җырлады:

> Бүген төнлә төшләремдә:
> Карасу, кара урман.
> Шул карасу, кара урман
> Без аерылышырга булган.

Нигә алай дип җырлады Мирзаһит, үзе дә аңламады...

Ә Бибинурның күз алдыннан бөгәрләнеп, кайракланып беткән утыртма якалы сатин күлмәк кигән, ябык, бер тәүлектә бетәшеп каткан Габдуллаҗан китмәде; мәет чыккан өйдә тәгәрәшеп калган өч сабый турында кайта-кайта уйлады ул...

Икенче көнне таң белән ул Габдуллаҗаннарга китте.

Аягына олтанлы көрән итек кигән, авызына сасы махра капкан Габдуллаҗан, корымга, көлгә батып, мичкә чуен белән бәрәңге куеп маташа иде. Уянып өлгергән олы кызы һәм уртанчы малае пычрак идәнгә түшләре белән ятып чиртеш уйныйлар. Нәҗип җиңе умырылып чыккан иске тун ябынып сәкедә йоклап ята. Сабыйның тун итәгеннән каерылып чыккан нәзек ботын күреп ул елап җибәрә язды...

— Нәҗипне бакчага үзем алып барам, шуңа кердем,— диде ул аптырап карап торган Габдуллаҗанга.— Өйдә балалар, ә син махра төтәтәсең, Габдуллаҗан абый.

Малайны, уятып, кабыл-кобыл киендерделәр. Бибинур йортның шактый каралмаган икәнен, әйбер-кара, ризыкларның тарау, кадерсез ятуын сизеп алды.

Габдуллаҗаннардагы тәртипсезлек Бибинурга бик авыр тәэсир итте.

Атнага якын шулай барды. Бибинур иртән Нәҗипне кереп ала, малайны «Плашадка»дан алырга этисе килә.

Кич белән, соң гына Бибинур Зәкиләргә аулак өйгә барды, шунда алар Мирзаһит белән очраштылар. «Авыллы» уйнаганда Мирзаһит гадәтенчә кызны өйалдына, аулакка дәшеп чыгарды.

— Нихәлләрең бар, Бибинур? — дип сорады.

— Нихәл дип, «Плащадка»ны ябалар. Менә әйберләрне барлап әзерлибез. Һич вакыт юк.

— Тизрәк япсыннар иде,— дип куйды Мирзаһит гади генә.— Яратмыйм мин бала-чага чыр-чуын. Җылыйлар алар, акыралар.

— Ә үз балаңны яратырсыңмы син, Мирзаһит? — Кыз кыюсыз гына егеткә таба тартылып алды.

— Каян беләсең аны. Ул турыда уйлаган юк. Баласыз да яшәп булмыймыни?

Бибинур кайта-кайта, кат-кат егетнең һәр әйткән сүзен хәтер иләге аша үткәрде, уйлады, мыштым гына, мендәр почмагын тешләп, балавыз сыгып та алды. Егетнең сүзләре аны сагайткан да, сискәндергән дә иде.

Иртәгә «Плащадка» ябыласы дигән көнне Габдуллаҗан Нәҗипне алырга килмәде. Караңгылык куерып беткәч, Бибинур малайны күтәрде дә югары очка менеп китте. Габдуллаҗанның җиргә үк салынган иске капкасын иңе белән этеп ачып ишегалдына керде, өйгә үк үтте.

Үксезлекләре йөзенә үк чыккан кыз белән малай катып үләрлек салкын өйдә иске бишмәтләренә төренеп катык ашыйлар иде. Абзарда сыер мөгри, сарыклар кычкырыша иде.

Бибинур юынтык суны малларга чыгарып утыртты, печән ыргытты, көянтә-чиләк асып инешкә төшеп менде. Мичкә ягып җибәрде, идәнне юып чыгарды. Чәй куеп балаларны эчертте, йокларга яткырды.

Габдуллаҗан районнан соң гына кайтты. Бибинурны күргәч, ул куркып китте.

— Балаларга бер-бер хәл бармы әллә?

— Юк, юк,— дип ашыгып күтәрелде кыз.— Чишен, Габдуллаҗан абый. Бәй, син манма су булгансың ич!

— Тоташ яңгыр астында кайттык. Ат тарта алмый, мескен. Җәяүләдек.

Өйнең эче генә түгел, төсе, исе дә үзгәргән иде. Өстәлдә ак тастымал белән төрелгән бәрәңге тора, чәй чынаяклары ялт иткән.

Габдуллаҗан, мич арасына кереп, коры чалбар киде, ишек катындагы урындыкка утырды.

— Соңга калмыйсыңмы, Бибинур? Кайтырга курыкмассыңмы?

— Менә ни уйладым әле мин, Габдуллаҗан абый. Әгәр син каршы килмәсәң, мин бөтенләйгә монда калам... Балалар ятим бит. Нәҗипне бик яраттым.

— Ныклап уйладыңмы син, Бибинур?

— Ныклап, Габдуллаҗан абый. Балаларыңны күрсәм, йөрәгем әрни.

Икенче көн, балалар уянуга, кайнар бәрәңге, буын атып, өстәлдә утыра иде, чынаякларга хуш исле сөт салынган, юка, тигез телемнәр белән ипи дә киселгән иде. Балалар өстәлнең бер ягына тезелештеләр.

— Менә, балалар, сезгә яңа әнкәй. Бибинур апагызны моннан соң әнкәй дип йөртә башларсыз, яме.

Нәҗипнең артык исе китмәде, ыштансыз малай дәү генә агач кашык белән каерып алды да бәрәңгене авызына капты.

— Әйем, тәмсез! — дип акырды.

Кыз да бәрәңгене татып карады, йөзен бозып:

— Тоз гына! — дип кире түкерде.

Бибинур да кабып карады, чыннан да, бәрәңге шыр тоз иде... Ул арада чалгы пәке белән кырынып чистарынган Габдуллаҗан да өстәл янына килеп утырды.

— Каяле, кая. Без дә авыз итеп карыйк.— Ул бәрәңгене мул итеп алды да капты, авыз, күз тирәсендәге җыерчыклар нур белән тулды.— Булган бу! Тәмле пешерәсең икән бәрәңгене, Бибинур. Дөрес, бер хатасы бар, тозы азрак.

Һәм ул агач савыттан учына байтак тоз салды да агач бадьянга тутырган бәрәңге яркалары өстенә сибеп җибәрде, рәхәтләнеп ашарга тотынды. Бибинурның итәгенә күз яше тамды, ул да кыяр-кыймас кына бадьянга үрелде... Балалар да этиләре артыннан ашарга тотындылар.

Бәләкәй Нәҗипне күтәреп соңгы тапкыр «Плацадка»га җитеп килгәндә, аңа очраган беренче кеше Мирзаһит булды.

— Бибинур, дөресме? — диде ул, килеп җитәрәк.

— Дөрес, Мирзаһит.

— Ә мин? — Егет бик нык җәберсенгән иде.— Миңа биргән вәгъдәң кайда?

— Вәгъдә үк бирешмәдек, Мирзаһит, ялгышма. Мәгәр өметем синдә иде. Син әйбәт егет, бер авыр сүз әйтмәдең. Синнән дә әйбәтне табачагым юк иде, Мирзаһит... Хәзер дә авыр сүз әйтеп ямьсезләнмә... Син үзеңә тиңне табарсың, иеме?

Һай, гомерләр! Күк гөмбәзен иңләп аккан ак болытлар кебек эределәр дә беттеләр. Ак керфекле басынкы егет Мирзаһит Днепрны кичкәндә Герой исемен алды. Чехословакия тауларында җан биреп, мәңгегә шунда ятып калды. Нәҗипне күкрәгенә кыскан кызга «әйбәт яшә!» дип әйтеп калган иде, моннан ары да хәлен белешеп, ярдәмләшеп торды.

Үги ананы бер чакта да яратмаганнар икән шул. Үги ана турында күпме әкиятләр, бәетләр тумаган! Үги ана — ялмавыз. Үги ана — аждаһа. Бибинурның үзенә өч үги. Тик аның явыз үги әни буласы килми. Габдуллаҗанга бик нык зарланды.

— Син — ата, балаларга ныгытып аңлат. Һаман-һаман чит итсәләр, миңа бик кыен. Тудырган да ана, үстергән дә ана! Шуны яшьтән үк белсеннәр.

Ире ни чарасын тапкандыр, балаларын ничек үгетләгәндер, Хәтимә беркөнне мәктәптән кайтты да озак кына аңа карап торгач:

— Әнкәй,— диде.

Авыз эчендә әвәләбрәк әйтте, «әнкәй» дигәне «әнки» кебегрәк яңгырады, Бибинур барыбер шат иде, нәниләр дә апаларыннан күрмәкче шул көннән аны «әнки» дип йөртә башладылар.

Тора-бара балалар яшь әниләрен яраттылар, бишәүләп тату гына тора башладылар, бер генә як һаман китек кала бирде: Бибинурның бәбие юк иде.

Бәбәй алып кайтырга өлгермәде Бибинур, кырык беренче ел килеп җитте.

Габдуллаҗанны да, Мирзаһитны да берьюлы алдылар.

Һай, ул көннәр! Һай, ул гомерләр!

* * *

Почта машинасы тирәсендә ул көнне бик озак маташтылар. Газета-журналларны, хатларны, иң актыктан посылкаларны бушаттылар. «Галим абыйларга ике посылка!» «Хәмәтләргә ничә җирдән хат!» дигән сүзләр туктаусыз шаулаган буа тавышын басып бакчада бик озак яңгырап торды.

Бибинур карчык та көтте. Бер кайтырга тиеш бит инде алар! Җаннары булса, аналары янына Сабан туена бер кайтырга тиешләр!

Почта кызлары гөр-гөр килеп сөйләшәләр, алар Бибинур карчыкның ни көткәнен бик яхшы аңлыйлар.

Ә буа шаулый! Шаулый! Җиһангир Сәфәргалинны озаткандагы кебек үк моңсу шаулый... Әллә кайларга чакырып шаулый буа. Хәер, әҗәл көтеп кенә яшәгән карчыкны кая чакырсын ди ул тагын? Шуңа ямансудыр аның тавышы, шуңа моңлыдыр...

Исәнгерәп тагын күпме утырган булыр иде Бибинур, буа буйлап каз куып килүче Зөһрәбануны абайлады, урыныннан купты, тиз-тиз авыл урамына элдертте. Авылның ике очында икәү тигез картайсалар да, алар бер-берсенә йөрешмәделәр. Габдуллаҗанның кара кәгазе килгән көнне «Минем каргышым төште!» дигән Зөһрәбану.

Моннан соң ничек кермәк кирәк тә йорт арасында ничек очрашмак кирәк.

VII

Монда төп гаепле итеп Бибинур үзен саный иде. Әгәр Габдуллаҗанга ябышып чыкмаса... Зөһрәбану аны алай каһәрләмәс иде...

Кырык икенең февралендә аны ат карарга куйдылар.

Сиксән ике ат бар иде ул килгәндә. Ул — өлкән ат караучы. Март урталарында атларга азык бик кыйтыланды. Бибинур куна-төнә диярлек абзарда ятты, кышын үзләре түккән тиресне тырма белән тарап, салам-соламны бөртекләп җыеп ашаттылар.

Балалар, акрынлап, исәя башладылар, уртанчы малай да вак-төяккә ярый, йомыш-юлга чаба, кышын ишегалдын кардан чистарта; Нәҗип тә кул арасына керә, утынлыктан йомычка алып керә, иске таска көл тутырып бакчага чыгара. Хәтимә көтү каршыларга бара, энекәшләрен карый, мунчага су ташый. Менә сугыш тәмамланыр, алар Габдуллаҗан белән утырып бик күп акыллы китаплар укырлар, газеталарга язылырлар, бергәбергә хак юлдан тайпылмаслар. Балаларны да белемле итәргә кирәк. Иң мөһиме, Габдуллаҗан гына исән булсын.

Атның озын ялы, Бибинурның куе чәчләре җилдә уйный, кырлар өстендәге тоташ хуш истә тирбәнеп күбәләкләр оча.

Авылга кайтып кереп, аръяктагы өч өйне узганнар гына иде, күпер өстендә айгыр башын артка чөеп кешнәп җибәрде. Айгыр

тавышынамы, ике кеше аңа каршы килә башлады. Ул нидер сизенеп тезгенне беләзегенә урады.

— Кайда югалдың син болай, Бибинур?

— Нәрсә бар?— Аның теле көрмәкләнде. «Балалар! Тышкы яктан бикләп киткән кеше кичкә кадәр йөрдем. Сантый! Исәр!»

— Габдуллаҗанның хәбәре килде.

— Ранныймы?

— Түгел шул, үлгән. Балаларың бик җылаша, Бибинур.

Ул айгырга очып менде дә чабата үкчәләре белән ике янтыгын да төя башлады: «На, на, на!»

«Балакайларым, балакайларым! — дип пышылдады аның канлы иреннәре.— Сабыйларым, ятимнәрем минем! Әткәгез исеме белән ант итәм, гомерем булса, берегезне дә ташламам! Һәммәгезне кеше иткәнче карармын!»

VIII

Кичә утырган урынмы бу? Монда кичә бик рәхәт булган иде. Малайлар Бибинур килеп утыргач нигәдер шикләнделәр, тавышлары тынды. Уйнагыз, малайлар, шаулагыз, гөрләгез!..

Малайлар белән мавыгып, ул янына ук килеп баскан Галикәйне дә абайламыйча калган.

— Кая барырга чыктың болай? Бибинур сорамыйча түзә алмады.

— Тигез картай икән аны, Бибинур! — Галикәй Бибинур янына килеп утырды.— Башка берәүгә әйтмәс идем, Бибинур... Син үзең дә читенлекнең ни икәнен белә торган кеше. Балалар янында тәмле ашап та булмый, Бибинур. Авыз да олы, чапылдый торгандыр инде... Нигә шуны утырган саен телгә алыргадыр инде: «Шапылдатма, эти»,— ди малай. «Тынычрак аша, эти»,— ди килен... рәхәтләнеп тәлинкә ялаган юк...

Ярдәм итәргә кирәк Галикәйгә дип уйлады Бибинур... Әллә?.. Туп-туры өйгә алып кайтыргамы? Икесенә дә рәхәт, кулай булыр иде. Рәхәт тоткынлыктан мәшәкатьле иреккә чыгарырга кирәк аны!

Әгәр Зөһрәбану белән кавышсалар?!

Зөһрәбануны да ялгызлыктан коткарганда ярыйдыр ла?..

— Син, бар, бик әйбәтләп өс-башыңны алыштыр. Мыегыңны төзәт. Мин Зөһрәбану янына керә торам.

— Сугышып бетмәссезме?

— Бетмәбез, курыкма. Татулашырга уйлыйм. Менә син уйлап, әзерләнеп төш.

— Ни уйларга кушасың инде син минем буш башка?
— Зөһрәбану янына күчәсең.
— Ну көлдердең, Бибинур, валлаһи!
— Ә син көлмә. Син дә ялгыз, ул да ялгыз. Гомере буе кемнедер көтеп яшәде ул. Гомеренең ахырына бару куркыныч аңа хәзер.
— Ә син ялгыз түгелме? Гомер актыгына бару сиңа куркыныч түгелме?
— Минем балаларым бар,— диде Бибинур, тыйнак кына.— Мин алар белән яшим.
Галикәй сүгенгәнен сизми дә калды:
— Соң ул шиңгән кишерләрне бала дип кем әйтер?!
— Балалар түгел, заман үзгәрде. Алар башкача яши. Мин алар булганга куана алам. Миңа күп кирәкми, шул да җиткән.
Тәндә көч-куәт барында Зөһрәбану белән араны рәтләп куясы иде. Бу эшне калдырырга ярамый. Теге дөньяда да каргыш ишетеп ятармы Бибинур?
Ул барып кергәндә Зөһрәбану, җиргә чүгәләп, ярык тагарагында тавыкларга көрпә болгата иде.
— Исәнме, Зөһрәбану. Тавык шактый мул асрыйсың икән.
— Җан көекләре инде. Юньләп күкәй салганнары да юк. Ашарга дисәң, убыр кебек умыралар.
— Кош-корт ашый инде,— диде Бибинур, битараф кына.— Әйдә, өйгә керик, Зөһрәбану. Аннан өс-башыңны алыштыр идең. Сабан туе алды, берәрсе килеп керер җә.
— Керик соң,— диде Зөһрәбану, теләр-теләмәс кенә.
— Уйладым-уйладым да кереп чыгарга булдым әле,— диде Бибинур, алъяпкычка төйнәгән күчтәнәчләрен капшап.
— Нигә кермәскә? — диде чыра телә башлаган җиреннән калкып Зөһрәбану. Ул ашыга-ашыга самоварына су тутырды, ут кабызды. Шул арада өс-башын да карап өлгерде.
Ишегалдында аяк тавышы ишетелде. Аны-моны ачыкларга өлгергәнче ишек ачылды, иң әүвәл Галикәйнең гадәттән текәрәк өскә караган мыек чылгыйлары, аннан тукмак борыны, вак бәлеш хәтле авызы, аннан соң гына үзе күренде.
— Исән-сау гына торасыңмы, Зөһрәбану! — диде Галикәй.— Бәй, Бибинур да монда икән ич!
«Риза! Риза булмаса алай тиз төшмәс иде!» — дип сөенеп уйлады Бибинур.
Өчесе өч җиргә утырып өч уй уйладылар.

«Тәртә арасына кергәч, чыгымчы ат та юашлана!» Бу — Галикәй.

«Ходаем, юкка гына йөрми болар. Тикмәгә генә кермәгән!» Бусы — Зөһрәбану.

Галикәй чалбар кесәсеннән күз явын алырлык елкылдап торган юка яулык тартып чыгарды.

— Сиңа, Зөһрәбану. Сабан туе бүләге.

— Матур,— диде эчкерсез сокланып Бибинур.

Зөһрәбану елап җибәрде.

— Без сиңа бер олы киңәш белән килдек бит, Зөһрәбану,— диде, ниһаять, Бибинур. Галикәй шикәрен вакламыйча гына йотып җибәрде, ашыгып чынаягын каплады.

— Нинди киңәш икән ул? — дигән булды яулык читен тешләп Зөһрәбану.

— Һәммәбезнең үзенә күрә тормышы бар дигәндәй, син яшәп ятасың, мин дә шулай алга барам... Менә Галикәйнең генә тормыш көйләнеп бетмәгән. Өйдә тынычлык юк аңа. Яшьләр арасына сыеп бетми.

Зөһрәбану ике кулы белән дә тезләренә суккалап:

— Мондый эштә миннән нинди киңәш кирәк соң сезгә? Минем баш бик юка, ишеткәнем дә әләгеп тормый хәзер,— диде дә Бибинурга карады.

— Әллә, мин әйтәм,— дип башлаган иде, Галикәй аны бүлдерде:

— Тукта әле, Бибинур, үзем әйтеп карыйм. Син ялгыз, Зөһрәбану, ялгызлыкны беләбез. Әллә соң бергә-бергә тора башлыйбызмы?

— Галикәйне беләсең, җайсыз кеше түгел. Аракы белән дуслыгы чамалы. Таза, сәламәт — бер-берегезгә юаныч, озак елларга терәк булырсыз.

— Нигә үзең чыкмыйсың, алайса? Аңа?

— Миңа сүз кушканы юк! Аннары минем, беләсең ич, балалар! Балалар ни әйтер.

— Хәзер аш салам, чырлый тавыгым бар, шуны суям.

— Суябыз аны, Зөһрәбану,— диде Галикәй, ике җиңен тиз-тиз сызганып.

— Миңа китсәм дә ярыйдыр, шәт. Рәхмәт үзеңә, Зөһрәбану. Сүземне җиргә екмадың, монысы өчен мең рәхмәт.

Сәкегә менеп ятканда үз өстеннән бик олы бурыч төшкәнен, сыңары белән арасы яхшыруын аңлады. «Дөньялыкта эшем калмады»,— дип тынычланып кабатлады ул бераздан.

IX

Әле пенсиягә чыгуны да картлык дип санамады Бибинур, кирәк чакта вак-төяк эшкә йөрде, чүгендер утады, бәрәңге чүпләште.

Җәйгә кергәч, аны бөтенләй танып булмый, бөтенләй үзгәрә иде Бибинур! Һәр тәрәзне киң ачып өйне хуш ис белән тутыра иде. Көзге моңсу айларда да ул тулаем бәхетле иде: сары яфраклар коелып тирбәлә-тирбәлә Ташлыяр елгасының вак-вак купшы дулкыннарында әллә кайларга агып киткәнне сүзсез-өнсез, сөенеченнән онытылып күзәтә иде Бибинур.

Кышның үз гүзәллеге! Яңа яуган ак мамыкка аякны иркәләп торган киез итек белән шыгыр-шыгыр басып бәкегә суга төшүләр нинди олы бәхет иде! Үзеңне чиксез галәм белән бер итеп сизәсең. Син җиргә мәңгегә килгән кебек!

Елларның, айларның гына түгел, атналарның, көннәрнең тууын белеп, тоеп яшәмәдеме ул?

Һәм көннәрдән бер көнне бөтенесе үзгәрде. Дөнья белән бәйләнеш өзелде. Табигать белән уртаклык тукталды. Һәм Бибинур: «Әһә, миңа да картлык килеп җитте»,— дип нәтиҗә ясады.

Ике көн хатирәләр тозагыннан ычкына алмыйча мич башында боргаланып ятты. Өченче көнне торды, кочагы белән каен утыны алып керде, мич гөмбәзенә кадәр тутырып якты.

Өенә җылы төшеп, ашап-эчкәч кар бик тирән ятканчы дип, зиратка Гайшә кабере янына китте. Зиратка Бибинурны Гайшәнең фаҗигале үлеме генә түгел, бурычы, җаваплылык та йөртә. Бибинур алып калды ич Гайшәнең өч баласын! Балалар турында ул Гайшә белән генә сөйләшә.

— Гайшә! Миңа да бу дөньяны кичеп сезнең янга килергә вакыт җитте бугай... Синең алда да гаебем бардыр. Кешеләр сөйли балалар мине ташлады дип, аларны гаеплиләр... Кем уйлаган дөньялар болайга әйләнеп китәр дип... Гайшә, бик дөрес уйлап ятасың, сирәк-мирәк хат язгаласалар, икебезнең йөзебез ил алдында ак булыр иде. Аннары, нәнекәчләрем, берәр генә мәртәбә, ике-өч елга бер генә тапкыр Аксыргакның Сабан туена кайтсалар ни әйтер идек кана? Синең катыңа җыйнаулашып, балалар белән бергәләшеп килә алсак, ни сөенеч булыр иде. Баланың баласы — балдан татлы, диләр. Шулайдыр. Балаларның балаларын күрү насыйп булмады. Барын эшләдем мин, Гайшә, тынмадым: тау-тау иген үстердем, көтү-көтү колын тәрбияләдем, бары да булды, җаным, үземә язганнан канәгать,

мәгәр бик олы бер үкенечем калды: бала сөеп туймадым. Балаларның балаларын күрмәдек без синең белән!..

Йә, хуш. Аякка таракан керә башлады. Озакламый мин дә сезнең катыгызга мәңгелеккә килермен!

Ул яңа сукмактан туп-туры зират капкасына бара башлый. Олы юлга чыккач, аны машина куып узды, тик ул күтәрелеп тә карамады. Кыр өстенә рәхәт тынлык хуҗа, кыш көне генә була торган гаҗәеп киңлектә, бушлыкта күз чагыла торган матурлык иде, тик боларның берсе дә Бибинурны әсәрләндермәде, ул үзен бу дөньядан киткән итеп санады.

«И гомерләр! И гомерләр!»

Язы да җитте. Яз җиткәнне тоймады аның җаны, ташу карарга төшмәде. Әҗәлен көтте.

Җәй җитте. Әҗәл һаман көттерде.

Җәй башының иң матур көннәренең берсендә аның җиргә чүгә башлаган йорт-кураларын карарга яңа председатель Җиһангир Сәфәргалин килеп керде. Аның аз гына бөдрәләнеп торган кызыл чәче туктаусыз агылып торган нурлар арасында бөтенләй кызыл комач кебек булып күренде.

X

— Исәнме, әбекәй,— диде Җиһангир.

— Исәнме, улым,— диде Бибинур кинәт һәм гаҗәпләнеп куйды. «Улым» дип бик күптәннән әйткәне юк иде инде аның!

— Ни хәлләрдә яшәп ятасың?

— Бик әйбәт яшим,— диде теге. Ни дисен, беренче күргән кешегә «Үлем килгәнне көтеп ятам» дисенме?!

Хәзер аны өйгә чакырырга кирәк иде. Мондый сөйкемле председательне ничек кире борып чыгарасың?..

Тик бу председатель өйгә керергә дә, ярым чүгәләгән өйгә бәйләнергә дә ашыкмады, кулы белән баскычка күрсәтеп:

— Вакытыгыз булса, утырып торыйк шушында,— диде.

— Мондый ишегаллары хәзер юк,— диде ул бераздан.

— Нинди? — дип сорады шикләнеп карчык.

— Матур... Ямь-яшел. Хуш исле. Малай чакта безнең ишегалды да шундый була иде. Әй ауный идек шунда. Мәтәлчек ата идек! Качышлы уйный идек.

— Хәзер балалар качышлы уйнамыйлар,— диде Бибинур, таркау гына.

— Мин дә шаккатам аңа! Качышлы уйнамыйлар, тычкан салыш бетте, күз бәйләш тә онытылды... Нигә икән, белмисезме?

Бибинурның фикере чуалып калды: тукта әле, нәрсәгә аңа «Качышлы» уены?

— Авылларның үз төсен сакларга кирәк! Менә нәрсә борчый мине! Авыл бит ул — сандугачлар оясы. Шагыйрьләр авылда гына туа.

«Акыллы председатель килде дип сөйләгәннәр иде, бик җильяк, җиңелрәк нәмәрсә икән!» — дип сызланды Бибинурның күңеле.

— Әйдә, өйгә кер. Чәй куям,— диде Бибинур, тәмам аптырап.

Җиһангир баш чайкады:

— Рәхмәт, әби. Монда да бик күңелле ич. Песи борчагын бик ярата идем мин!.. Кабыгыннан әрчи-әрчи аяк бөкләп ишегалды уртасында утырганым әле дә хәтеремдә.— Әби,— дип, утырган урыныннан калкынды Җиһангир.— Нигә җыелышларга төшмисез? Мин өлкәннәрне киңәшкә чакыргалыйм. Сезне элек бик актив булган, диләр. Хәзер ник үзгәрдегез?

— Картаелды инде,— диде Бибинур, шүрләп кенә.

— Картаймагыз. Безнең алдагы планнар бик кызыклы, бик матур. Бакча ясарга уйлыйбыз. Ташлыярны буып куярга да исәп. Идарәгә төшеп йөрегез, туп-туры үземә керегез. Бергәләп уйлашыйк.

Председательнең аяк астында калып җиргә ауган бәпкә үләннәре күптән калкынды инде. Бибинур гына нишләргә белмичә аптырап, болдырда бик озак утырды.

Кич белән аны идарәгә чакыртып җитмеш биш тәңкә акча бирделәр. «Ветераннарның һәммәсенә өлеш чыгардык»,— диде бухгалтер.

Юк, җитмеш биш сум акча бирдергәне өчен түгел, керәп чыкканы өчен дә түгел (гәрчә болары өчен дә Бибинур чын күңеленнән Җиһангирга кат-кат рәхмәт укыды!), әллә нәрсә өчен һәм әллә ничек кенә Бибинурның күңеле күтәрелде... Бибинур карчыкның күңел серен сезгә генә сөйлим, хөрмәтле укучылар!

Шул иртәдән, шушы сәер сөйләшүдән Бибинурның тормышы кинәт үзгәрде. Иң башта Бибинур күгәреп тоныкланган көзгесен чолан почмагына чыгарып атты да, ике тәрәзә арасына, түргә, бәләкәй булса да, көмеш кебек ап-ак көзге кайтарып элде. Эчке рамнарын алып, тәрәзә пыялаларын ышкый-ышкый юды... Районга барып ак буяу алып кайтты, рамнарын шаплап буяды. Тәрәзә пәрдәләрен кайнатып юды, үтүкләп элде...

Зәкия карчык Бибинур ихатасыннан күзен алмый иде бу арада. Күршесе аны тәмам хәйран калдырды: йөгерә-йөгерә суга төшеп китә, өй эченнән әле балта, әле чүкеч тавышы килә. Бибинурны чын күңеленнән кызганып уфылдады: «Ходай хәерле итсен, карчыкның зиһене тарала башлады... Әҗәле җитәдер, мөгаен!»

Шул көннән Бибинур бер киноны, бер театрны калдырмый башлады, җыелышларда иң алдынгы рәткә барып утырды. Бакча утыртканда башыннан ахырына кадәр кайнашты. Күпер сукканда да, бакча утыртканда да, буа ясаганда да ул бары тик Җиһангир Сәфәргалинны күрер өчен генә барып йөрде...

Ничек итеп атарга инде бу мөнәсәбәтне?

Мәхәббәт дисәң ышанмаслар. Гыйшык дисәң шикләнерләр.

Ничек кенә атасаң да, Бибинур карчык Җиһангирны күрмичә, аның калын тавышын ишетмичә бер генә көн дә яши алмый иде.

Дөресен әйткәндә, Бибинур карчыкның сизгер мәхәббәтле йөрәге берәүгә дә гашыйк булмыйча калган иде бит! Мирзаһитны ул егет хөрмәт иткәнгә генә якын күрде. Габдуллаҗанны да яратырга өлгермәде. Дөрес, иренә күнекте, уртак язмышлары берләштергәч, ул аны чит итә алмады, бар булганынча сөйде, иркәләде. Бибинурга исә Ходай ярата белә торган йөрәк биргән иде. Кемне дә булса яраттымы ул моңарчы?

Хәзер уйлап-уйлап карый да, башын чайкый, юк, яратмады. Балаларын сөйде, ә нәтиҗә? Бәлки, әнә шул күңелсез нәтиҗә аның җанын эзләргә мәҗбүр иткәндер дә, әгәр ул бетмәс мәхәббәтен балаларыннан оныкларына күчерсә, бу хәлләр бөтенләй булмый да калыр иде, кем белсен.

Йөрәк яратудан туймый икән! Мәхәббәткә лаек йөрәк һаман яши, тибә, эзләнә икән... Җиһангирның урамнан үтеп киткәнен күреп калса, Бибинурга бәйрәм! Җиһангир җыелышта чыгыш ясаса, аның өчен шатлык! Ул утырткан бакча — аның өчен җәннәт бакчасы.

Аксыргак авылы аның өчен хәзер изге урын — чөнки аның һәр карышында Җиһангирның аяк эзләре бар...

Ташлыяр елгасы — Бибинур өчен сер дөньясы!

Әйе, ул — кеше. Беренче сандугачлар, яшел уҗым кылычлары, язгы күкрәүләр, салават күпере, һәммәсе кирәк хәзер Бибинурга! Мәхәббәт кагылган йөрәкнең күләме чиксез! Аңа ай-йолдызлары белән бөтен Галәм кереп урнаша ала. Мәхәббәтле йөрәк юмарт, гадел, бәхетле.

«Ярабби, мин тилене кичер! Рәнҗемә миңа! Тик нигә бу хисләрне картлыгымда татырга боердың!» — дип, кичке караңгыда ул мендәренә капланып Ходаена ялвара!

Хәзер ул яшәреп китте, адымы үзгәрде.

Нигә гаиләсен алып килми Җиһангир? Бар диләр, хатыны да, улы да бар, диләр... Хатыны да килми, килмәячәк тә, диләр...

Шундый ирнең кадерен белмәгән ахмак хатыннар да булыр икән! Ире бар килеш ничек ялгыз яшәргә ризалаша ул? Ялгызлыкның тәмуг газабына тиң икәнен белми микәнни ул?

Төшенә дә сөенечләр генә керде. Ак казлар өере, каңгылдашып, ак күпер аша чыкты... Кайдадыр ак, сары әләмнәр җилфердәде... Болын өстен ап-ак энҗе чәчәкләр каплаган иде...

Йоклаганда да аның йөзеннән, йомык күзләреннән нур ага иде.

Зәкия карчык та әллә ничә кат укынып аның тәрәзәләренә карады: әллә таң да ата инде?..

Аны йокысыннан да Зәкия карчык уятты:

— Карчык, карчык! Ишетәсеңме, председателебез Җиһангир Сәфәргалин дөнья куйган!..

XI

Бүген җомга көн. Бүген ул тып-тыныч. Ниһаять, үзенә язганны башкарды, дөньядагы барлык бурычын үтәде.

Бүген монда рәхәт. Бакча әлегә тып-тын. Буа гына шаулый. Бүген ул тагын аның тавышын тыңлый. Беркөн генә ул буа тавышын бөтенләй ишетми торды. Гаҗәп, чыннан да! Буада кер юды үзе, арык тавышын ишетмәде. Бүген аермачык ишетә. Авылда яңгыраган көр әтәч тавышларын да ишетә, көтүгә куылмаган бүлтерек бәрәннәр бәәлдәве дә аңа килеп ирешә. Ләкин Бибинур башка тавышларны шунда ук оныта бара.

Их, Җиһангир да исән булса! Юк, буасы гына шаулый, каядыр өндәп, әллә нинди сихерле өннәр чыгарып шаулый буа!

Их, менә шулай йокымсырап утырганда гына тирбәлә-тирбәлә мәңгелек елгасына кушылып китеп агасы иде! Агасы да, агасы иде... Оеп, тынычланып йокымсырады Бибинур. Кемдер аның исемен атап та дәшкәч, чәчрәп уянды.

Ачык тәрәзәдән үрелеп, Миңлегөл кул болгады.

— Килче монда, Бибинур әби!

Бик озак узды ул бакча эскәмиясе белән почта арасын, бик авыр атлап.

Миңлегөл ишек катына чыгып ук аны көтеп тора иде.

Миңлегөл чак кына сабыр итеп торды.

— Синең көн туды исә почта янына төшеп утырганыңны күреп барыбызның да йөрәге әрни, Бибинур әби. Балаларыңнан хәбәр көтәсең син, әйеме? Ә алардан бер хәбәр дә юк. Без, авыл комсомоллары, аларга хат язып карадык. «Әнкәгез бик тилмерә, ялгызлык яман нәрсә, ник аны оныттыгыз?» — дип сорадык.

Карчыкның керфекләре яшькә чыланды.

— Балаларга кагылмаска иде!

— Сине генә түгел, бөтен авылны рәнҗетте ич алар! Мин синең балаларыңның шул яманлыгы хакында газетага язган идем, редакциягә.

— Редакциягә?

— Өчесе дә әйбәт урында эшлиләр, әнкәләренә кулъяулык та сатып алып биргәннәре юк, дидем. Эшләгән җирләрендә әнкәләренең соңгы самоварына тиклем талап алып киткәннәрен ишеткәннәре юктыр! Фельетон басылып чыккач сикерешерләр, эссе табага басарлар әле!

Тарта Бибинурның керфеге, үтереп тарта.

— Кирәкмәс иде, хата кылгансың,— дип кабатлады ул, тәмам хәле китеп.

— Әле генә Казаннан шалтыраттылар. Иртәгә редакциядән корреспондент килеп җитәчәк.

Карчык балалары өстенә куркынычлы бер хәл туып килгәнен аңлады һәм каушап, куркып китте.

Бөтен дөнья үзгәрде.

Бая гына йокымсыраган урын каты һәм кытыршы иде. Кая борылса да, күз кабакларын чәнчеп кояш төшкән кебек иде.

Байтак изалангач кына аңлашылды: «Буа шавы комачаулый ич!»

Үткәннәр җыр булып тезелеп акканда буа тавышы аңа тугры юлдаш иде. Миңлегөл чытлык белән сөйләшкәннән соң, буа тавышы аның уйларын өзгәли, ботарлый һәм туктата икән! Димәк, монда озак утырырга ярамый. Иртәгесе көнгә аның уе ачык һәм әзер булырга тиеш.

Ул, ашыга-ашыга, өенә кайтты, нигәдер капка бигеп элде. Түргә узды, өстәл янына утырды, терсәген өстәлгә, кайнар яңагын учына куйды. Ай тиле кыз Миңлегөл! Җиһангир абый кушты дигән була, булмас, ошамаганны кушмагандыр. Хәзер бит эте-бете гәҗит укый. Габдуллаҗан белән Гайшә ни уйлап

яталар? Исән башың белән шул кара хаксызлыкны кылырга рөхсәт бирдеңме дип, каберләрендә борылып ятарлар.

Әгәр дә мәгәр... Тукта! Чү! Өе таза булса, җиһазлардан вак-төяк нәрсәләр юнәтә алса, гәҗит кешесен ничек тә көйләп озатыр иде. «Шөкер, балалар язгалап тора, акча да салгалыйлар, һичнәмәгә мохтаҗлыгым юк!» дияр иде. Инде хатларны күрсәтүне сораган тәкъдирдә, бар ич алар, әнә матчага кыстырган җирдә торалар.

Хәзер мең кат кайгыртып язсаң да, балаларның мәхәббәтен яулап алырың юк. Көчләп сорап алган мәхәббәт нигә кирәк аңа?

Кинәт ул буа тавышын ишеткән кук булды: шаулый бит ул, шаулый! Чакыра. Чакырганын бер Бибинур ишетәдер Аксыргакта!

Килүчене туктатып булмый, сүз дә юк. Киләчәк ул, киләчәк тә туп-туры Бибинурның йортын эзләп табып түренә үк узачак. Чәй куяр иде — самовары юк, «балаларым ярдәмнән ташламый!» дияр иде — өй эче шып-шыр...

Килер, язар, хәзер аны берничек тә тыя торган түгел. Их, Миңлегөл, башсыз!.. Нишләргә? Әгәр түрдә самовар балкып утырса... «Зингер» машинасы күренсә... Тегендә-монда төрле-төрле чүпрәк, эленкеләр өй эчен бизәп торса... Ул чагында аяк терәп сөйләшә алыр иде Бибинур!.. Кыскасы, самоварын да, җөй машинасын да табарга, вакытлыча гына юнәтергә кирәк!.. Башка чара калмаган...

Аксыргакта бармы икән ул борынгы Тула самовары? Тик моңарчы йомышка йөрешмәгән кешедән ничек сорап торасың? Кунак өстенә кунак кайтканда, кем сиңа самоварын биреп торсын!

Бибинур нәкъ үзләренеке төсле самовар белән җөй машинасын шушы арада гына күрде... Әһә, Җиһангирны соңгы юлга озата баргач, аларда, әтиләрендә, кызыл сакаллы Вәли картларда күрде.

Аларда сакланган әнә, Бибинур гына саклый алмады. Күзләренә ни күренсә, шуны йомарладылар. «Иске әйберләр модада!» имеш.

Бибинур бер акылга килде: «Әйе, мин аларга серне ача да алам, әйбер-караларын бер көнгә сорап тора да алам».

Бибинур сабыр гына, барын уйлап, Тегәрҗеп авылына барырга әзерләнә башлады. Өй эче кинәт караңгыланды. Әнә теге, көнбатыштагы ертык итәкле елгыр болытлар җир сугарырга җыеналар түгелме!

Яңгыр түгел, таш яуса да барырга кирәк Бибинурга, самовар, җөй машинасы ише олырак әйберләрне дә алып кайтырга кирәк, башка вак-төяге дә артмас.

Кемнәрдер аңа сәлам биреп узды, кемнәрдер тәрәз ачып бәйрәм белән котладылар, әмма ул тукталып тормады, сәламга каршы сәлам бирде, чакыручыларга рәхмәт укыды.

Буа өсли чыкканда уйлары төзек түгел иде, максаты гына ачык иде: тизрәк барып җитәргә дә, эшне эш итәргә!..

Аннан тауга менә башлады, бәй, монда яңгыр нык ук сыптырып узган икән. Урманга якынайган саен, һава сафланды, сулыш җиңеләйде, әмма аның күңеленнән шом китмәде. Бүген юлның аулаклыгы, бушлыгы гел искә төшеп, җанны талап тора иде.

Урманга җитәрәк юл бөтенләй изрәде, аның таягы тирәнрәк бата башлады.

Урман аны салкынча дымлы әңгере, чык асылынган яфраклары һәм шикләндергеч шомы белән каршы алды.

Кайдадыр якындарак кына, җанны өшетеп, эт өрде. Теге юлы, Җиһангирны җирләп төнен ялгыз кайтканда да эт тавышы колакка чагылган иде түгелме? Теге чакта, төнлә кайтса да, ул кадәрле шигәймәгән иде, хәзер нинди эт йөрер икән монда дип, куркынып уйлады. Бу тирәдә лесник-мазарлар тормый. Якында гына башка авыл да юк. Бүре уласа икән, төлке чинаса икән, ә монда эт өрә!

Яңгыр сибәли башлады. Чама белән елгага җитәргә тиеш иде кебек, әмма юлның күренгән кадәресе алда тып-тын һәм аулак иде. Елгага җиткәнен ярдан төшә башлагач кына аңлады, таеп, лып итеп, артына утырды. Атлаган саен куакларга ябышты, елганың үзенә барып җитте. Су шактый салкын иде, ул талпынып теге як ярга чыгуга, бер-ике-өч тапкыр нык кына төчкерде. Яр өстендә, бик якында гына алама тавыш белән, татлы, серле тынлыкны ерткалап, эт өрә башлады.

Яр өстенә менеп җитәм дигәндә генә, коты чыгып туктап калды... Юлны урталайга ярып, нәкъ аның каршысына, сузылып кына эт өере чабып килә иде. Ул кулларын бутап чәрелдәп кычкырып җибәрде һәм, артына утырып, әле генә интегеп менгән үрдән аска шуып төште, елганың үзе килгән ярына ташланды. Этләр ярны иңләп аска төштеләр дә, чокырны тутырып аккан су янына җиткәч, беразга тыелдылар. Иң алдан чапкан йөнтәс койрыклы алама эт кенә баягы кебек карлыккан аваз салып өреп җибәрде. Шушы тукталыш Бибинурны

коткарды, ул әлсерәп яр өстенә үрмәләде һәм беренче очраган дәү чыршы кәүсәсенә килеп сыенды. Этләр тавышсыз-тынсыз гына нидер көтәләр иде. Менә алар астарак, елганың таррак урынын эзләп таптылар, берәм-берәм бу якка сикереп чыккач, ярга менә башладылар. Өметсезлектән нишләргә белмәгән карчык як-ягына каранып торды да кулындагы нәзек таякны этләргә таба атып бәргәч, чыршының җиргә үк төшеп торган үткен ботакларына ябышып агачка менә башлады... Этләр абалап өрә-өрә чыршыны камап алдылар, иң алдан чапкан чуар эт, Бибинурның үкчәсен эләктереп тә алды. Башмаклар кайдадыр үлән арасында төшеп калган иде...

Җиде-сигез эт чыршы тирәли чаба-чаба тешләрен ыржайтып, ырлап өрәләр иде. Карчык югарырак үрмәләде, ике кулы белән чытырдатып агачны кочаклады.

Ул үз хәленең үтә яман, үтә мөшкел икәнлеген күңел төбе белән төшенсә дә, әле бар бәлане, аның зурлыгын күз алдына да китереп бетерә алмады. Былтыр көз Галикәй ачынып сөйләгән бер вакыйга шул чакта гына аның хәтеренә төште.

«Беркөн таудан төшеп киләм. Тамагым кипкәч Бики ягына чишмәгә сугылдым. Су эчәргә генә иелгән идем, яныма өч эт килеп чыкмасмы? Таларга җыеналар, бугазга сикерәләр явызлар! Әле дә ярый күсәк тоткан идем. Тоттым да як-якка селтим генә шуны! Китмиләр. Мылтык барын белә шул алар, кеше янында сабак алып иясез калып кыргыйланган этләр! Алар кешене бер дә яратмый. Тырышып-тырышып бүреләрне кырып бетердек, ә табигатьтә бүре бик тә кирәк икән! Бүре табигатькә хуҗа булганда эш бөтенләй башка икән! Көчле хуҗа юк җирдә әшәке алама этләр хуҗалыкта властьны эләктерә, алар баш була. Кала хулиганнары төсле оешып алалар да, бер чакта да ялгыз йөрмиләр, өер булалар, башлык та табыла. Өч этнең берсе бияләй хәтле генә, иң нык ярсып шунысы ябыша. Бүре үз хуҗалыгын этләргә бирер торамы?»

Шулай дип сөйләгән иде Галикәй. Чын булган икән сүзе. Мөгаен, шул явызлар йөри чыршы тирәли!..

Бибинур, чыннан да, ике-өч елдан бирле урман юлларында юлбасарлык кылып йөрүче әшәке этләр өеренә тап булган иде бүген. Өер башы тәбәнәк кенә, әмма үтә чыккан хәйләкәр, сак һәм оста эш йөртеп, аучыларны да байтак тапкырлар карама көленә утыртып өерне һәлакәттән коткарып килүче кара бер эт иде. Яхшылабрак карагач Бибинур өер башын таныды, әйе,

бу ул иде, моннан ике ел элек, кышкы суыкларда саламга төреп, тамагына җылы аш ашатып, соңгы ризыкларын бүлешкән аның эте Карабай иде. Бала табарга чыгып югалды да шуннан кайтмады. Өердә аңа охшаган тагын ике эт бар иде, әллә шул явызның балаларымы, дип уйлады ул.

Бибинур мөмкин кадәр ягымлы, тәмле телле булырга тырышып эткә эндәште.

— Карабай, Карабай, нишлисең? Мин синең Бибинур нәнәң булам ич!

Карабай тавышны таныды, кайчандыр булган кушаматын ишетеп, чак кына тынып торды да сырт йонын кабартты. Шуны күзәтеп торган куштан чуар эт, Бибинурның үкчәсен эләктерергә омтылып, кат-кат өскә сикерде.

Яхшылык белән кешене генә түгел, җан ияләрен дә үзгәртеп була дип ышанган бичара Бибинур аны-моны абайламыйча һаман явызны юмаларга, иркәләргә маташты.

Этләр аның ягымлы эндәшенә дәррәү ырылдап җавап бирделәр.

Ул аптырап, аңгыраеп байтак утырды. Караңгылык тәмам куерды, яңгыр килә-китә сибәләп торды, этләр чыршы астындагы коры урыннарны сайлап сузылышып яттылар. Карабай гына уяу иде.

— Мин сезнеме? Мин сезнеме хәзер? Утлы табага бастырмасаммы? — дип, яман кычкырып җибәрде тәкате калмаган Бибинур.

Ул күлмәк кесәсенә тыгылды, шөкер, шырпысы бу юлы да янында икән, бер генә түгел, ике кап. Ул үрелә-үрелә ботаксатак сындыра башлады, сындырган берен тезе белән корсагына кысты. Этләр ботак сынган тавышка сискәнеп уяндылар. Бибинур өч шырпыны бергә тотып кабына сызып җибәрде. Ботакларга тоташ ут күчкәнен күреп Бибинурның эченә өмет җылысы йөгерде. Ут юанрак ботакларга да еленгәч, Бибинур селтәнеп себеркене этләр өстенә сибеп җибәрде. Этләр уттан куркып артка чигенделәр. Ул икенче бәйләмне әзерләгән арада бая җиргә чәчелгән чыбыклар янып бетте, алар төшкән урыннарда ылыс төтәде, борынга тәмле ис урладе.

Коры, сагызлы ботакларны елгыр ут ялмап кына алды. Ул көлтәне өскәрәк күтәрде, этләр өеренә сибеп җибәрде. Чыбыклар бөтен җирдә чытыр-чытыр яна башладылар, чыршы тирәсен сыек төтен сарды. Бибинур йөткеренеп этләрнең акрынакрын чигенгәнен шатланып күзәтеп торды. Чыршы тирәли

тоташ ут яна иде. Ул ал яулыгын тотып алып җиргә егылып төште, янбашы бик авыртты. Тик куркуы шулкадәр көчле иде, авырту шундук онытылды, ул мүкәләп чыршы астыннан чыкты, җиргә утырды. Этләр дәшми-тынмый гына артка чигенделәр дә бераздан бөтенләй күздән югалдылар.

Ул, үрмәли-үрмәли чыршыга якын ук килеп, кытыршы кәүсәгә аркасын терәп утырды... Юеш, пычрак көлле күлмәге белән җәрәхәтләрен сыпырды, бит алмасына коры яфраклар ябышып калды. Кинәт аның күкрәгенә нидер килеп бәрелгән күк булды, тирә-якта чыршы ботаклары янудан якты диярлек булса да, күз аллары тоташ караңгыланды һәм аңа бик җиңел, бик рәхәт булып калды. Ул елмайды һәм йокыга китте...

Төш күрде...

Төшендә ул урман елгасы өстеннән оча башлады. Елгадан тарлавыкка күчте. Ике яктан да сансыз-исәпсез ишекләр тезелеп киткән иде. Ачык ишекләрдән таныш йөзләр дә чагылып-чагылып кала. Менә Габдуллаҗанның ап-ак чырае күренде. Менә кечерәк ишектән Гайшә чыгып килә иде. Читтә Галикәйнең хәтәр тырпайган мыегы күренде. Нигә ул монда соң әле, дип уйлады Бибинур. Тарлавык бетте, караңгылык куерды, ул оча-оча кап-каты шома стенага килеп бәрелде. Кайда соң моның ишеге дип эзләде, ишек табылмады.

«Эчке күлмәгемнең ямаулы икәнен теге гәҗитәдән килгән кеше дә, Миңлегөл дә күрерләр инде!» дип әрнеп уйлады.

Якында гына, дүрт якта да этләр улашырга тотынды.

Тик боларны Бибинур ишетмәде.

Иртән чалт аяз, кояшлы көн иде. Сабан туе алдыннан Аксыргак авылында гына була торган бәхетле, куанычлы шимбә иртәсе яралды...

Март—октябрь, 1979 ел

Повестьның сюжеты. Повесть сюжетын: Бибинурның яшьлектәге мәхәббәте, картлыктагы мәхәббәте, туганы Зөһрәбануга мөнәсәбәте, балаларын яклавы дип берничә сызыкка бүлеп өйрәнү эшне җиңеләйтергә тиеш. Ләкин сюжетны сөйләп чыгу әсәрнең эчтәлеген таптык дигән сүз түгел әле. Эчтәлекне анализ нәтиҗәсендә табабыз. Әсәрне өлешләргә таркатуның максаты аның төзелешен табу булганга, бәйләнешкә кереп, өстәмә эчтәлек бирердәй өлешләр эзлибез. Бу эшне әсәр сюжетын бик яхшы белгәндә генә башкарып була.

Биремнәр һәм сораулар

1. Сюжет сызыкларының һәрберсендә диярлек берничә вакыйга бар. Шуларны җыеп бөтен бер сюжет, бер вакыйга итеп күз алдына китерегез. Тәмамлануын күрсәтегез. Бик кыска итеп шуны әйтеп бирегез.

2. Сюжет сызыкларының үзара бәйләнешләре дә булырга тиеш. Шул бәйләнешне табыгыз.

Әсәрнең төзелеше. Әсәргә эчтәлек өсти торган вакыйгаларын автор ничек кенә булса да үзенең укучысына күрсәтергә тырыша. Шундый вакыйгаларның берсе — буа тавышы. Бу тавыш әсәрнең башыннан ахырына кадәр ишетелеп тора. Аңа Бибинур карчык та, автор да кат-кат бәя бирәләр. Тиктомалга кабатламавын искәртеп, Аяз Гыйләҗев аны иң хәтәр вакыйгалар янына куя, әнә шул вакыйга белән бәйләп карарга өнди. Буа тавышы белән бәйле вакыйгалар, ягъни турыдан-туры буага караган вакыйгалар әсәрнең бер өлеше була ала. Икенче өлешне ачыкларга керешкәнче, бу образ эчтәлеген ныклап өйрәник.

3. Буаның үзенә генә караган сыйфатларны табыгыз һәм 1 нче, 2 нче, 3 нче h. б. дип дәфтәрләрегезгә язып куегыз.

4. Буа тавышы Бибинурга яки авторның үзенә нинди вакыйгалар белән бәйле рәвештә ишетелә башлый? Ул вакыйгалар башкаларыннан кай яклары белән аерылып торалар?

5. Бу тавыш Бибинурга ничек тәэсир итә? Һәм ул аңа карата нинди мөнәсәбәттә?

Повестьның буа тавышы белән бәйле өлеше әсәр эчтәлеген кайсы яктан ачыклый һәм баета? Бу сорауга җавап бирү өчен, вакыйгаларның башкаларын өйрәнергә тиешбез. Әмма алар күп һәм төрле. Искә төшерик: Бибинур көтелмәгән эш эшли — яраткан егетенә кияүгә чыгудан баш тарта да яратмаган кешесенең хатыны була. Икенче төрле әйткәндә, бер нәрсә ниятли, шуның киресен эшли.

Сюжет сызыкларының башкалары да шуңа охшашлы көтелмәгән борылыш ясавын күрәбез. Башка вакыйгаларда да укучы бер нәрсә көтеп торганда, шуның киресе белән очраша. Кыскартып: сюжетның ахыры баш өлеше белән каршылыкка килә дип әйтергә мөмкин.

Бу алымны Аяз Гыйләҗев күп кабатлый. Шуңа күрә аны язучының стиль үзенчәлеге дип бәялибез.

6. Сюжеттагы шундый көтелмәгән борылышларның башкаларын да табыгыз.

7. Бибинурның яшьлек мәхәббәте ни өчен шулай көтелмәгән борылыш белән тәмамлана?

8. Көтелмәгән дәвамы булган башка вакыйгаларга да шундый ук сорау куегыз һәм аларга да җавап бирегез.

9. 7 нче биремдәге сорауга Бибинур үзе: «Ятим балаларны кызгандым»,— дип җавап бирә, үзен аклар өчен башка сәбәпләр дә таба. Ләкин бу җавап Бибинур карчыкның үз аңлатмасы гына әле. Яшь, чибәр кызның үз теләге белән үзен үзе бәхетсез итүенә авылдашлары бөтенләй башка бәя бирәләр. Берәүләр аны кызганалар, икенчеләре акылсызлыкта гаеплиләр.

Ә авторның үз бәясе нинди?

Аяз Гыйләҗев, әлбәттә, үз бәясен повестенда турыдан-туры сөйләп тә биргән булыр иде. Әмма кеше хисләрен бер генә мәгънәле эчтәлек бирә ала торган төшенчәләр белән әйтеп бирергә мөмкин түгел. Моның өчен әдәбиятның үз алымнарыннан файдаланырга кирәк. Аяз Гыйләҗев тә шулай итә.

Авторның Бибинур мәхәббәтенә карата бәясен әсәрнең кайсы урыныннан белеп була?

10. Повестьта авторның башка вакыйгаларга биргән бәясен дә әйтегез.

Хәзер табышларны гомумиләштерик. Мондый нәтиҗә ясыйк: повестьның беренче өлеше буа тавышы булса, икенчесе — вакыйгаларның табигый юлдан тайпылуы, үзенә үзе каршылыкка килүе. Без аларны нәкъ менә шул уртак сыйфатларына нигезләнеп гомумиләштерәбез һәм бөтен бер өлеш дип исәплибез.

Икенче өлештәге һәр вакыйга каршылыкка корылган, һәр каршылык «Ни өчен?» дигән сорау тудыра. Җавапсыз сорауларга проблема, диләр. Димәк, әсәрнең икенче өлеше тоташ проблемалардан гыйбарәт.

Икенче өлешне җыйдык, гомумиләштердек һәм иң әһәмиятле ягын таптык. Хәзер повестьның беренче өлешенә кире әйләнеп кайтабыз һәм аның ни өчен өзлексез кабатланып торуын белә алабыз. Буа тавышы әлеге сорауларга җавап була алмыймы? Авторның әйтәсе килгән фикере шул тавышның мәгънәләрен тапкач ачыкланмыймы?

Әсәрнең төзелешен, ягъни буа тавышы эчтәлегенең төп вакыйгаларга бәйләнешен табу — эчтәлек табу дигән сүз.

Аяз Гыйләҗевнең стиле. Стиль язучының яраткан алымнары булуын яхшы беләбез. «Җомга көн, кич белән» повестенда Аяз Гыйләҗевнең аеруча яратып кулланган алымы — сюжет сызыкларын парадокс итеп төзү.

Парадокс **дип күпчелек тарафыннан кабул ителгән фикерләргә, күзаллауларга кискен рәвештә каршы булган, кеше ышанмаслык булып тоелган фикер яки күзаллауларга әйтәләр.**

Укучы сюжеттагы һәр табигый булмаган борылышка игътибар итә һәм: «Нигә болай булды соң әле?» — дип үзенә үзе сорау бирергә мәҗбүр була.

Җавапны ул әсәрнең буеннан-буена сузылган, күп тапкыр кабатланган метафора-вакыйга белән бәйләнештә таба. Җавапта әсәрнең эчтәлеге ята.

«Җомга көн, кич белән» повестеның бу төзелеше Аяз Гыйләҗев иҗат иткән әсәрләрнең күбесенә хас. Моңа кадәр без өйрәнгән авторларда очрамаган бу алым Аяз Гыйләҗевнең иҗат үзенчәлеге, стиле дип әйтә алабыз.

Повестьны укыганда игътибар иткәнсездер, әдип вакыйгаларны әле бер персонажы, әле икенчесе авызыннан сөйләтә. Алар һәрберсе вакыйгаларга үз бәяләрен бирәләр, бу бәяләр күп очракта бер-берсенә капма-каршы була. Көтмәгәндә, битараф бер күзәтеп торучы булып, автор үзе хикәяләргә керешә. Ләкин аның яраткан алымы — үзе персонажга әйләнеп әсәр вакыйгаларына бәя бирү. Шундый чакта ул үзен әсәр эчендә бик иркен тота: бу парадоксны аңламаслар ахры дип, борчылып, Бибинур уйларын, аның эшләгән эшләрен аңлатырга керешә. Фәлсәфәгә бирелеп китә, хәтта, лирик герой вазифасын үтәп, үзенең хисләре турында да сөйли башлый. Пафоска бирелергә дә күп алмый. Укучысына мөрәҗәгать итеп, аңа да акыл биреп ташлый.

Хикәяләү алымындагы бу үзенчәлеген Аяз Гыйләҗев башка әсәрләрендә дә кабатлый. Шуңа күрә интонациянең еш үзгәрүен шулай ук стиль үзенчәлеге дип саный алабыз.

Стиль әсәр төзелешен тулыландыра, эчтәлекне ачарга ярдәм итә, аны аңлата.

Нәтиҗә

Бибинур әби буа тавышын иң шатлыклы чагында да, башын кая куярга белми йөргәндә дә ишетә башлый. Буа тавышы — читтән килгән өн. Әмма ул Бибинурның үзенә генә ишетелә һәм аны гына борчый, каядыр өнди, нидер эшләргә кыстый. Бу тавыш аның игътибарын җәлеп итеп кенә калмый, һәр эшенә катнаша.

Нинди тавыш соң ул? Кайгы белән шатлыкны уртаклашып, ни эшләргә кирәклекне сүзсез генә әйтеп торучы тавыш.

Буа бит ул — туган җир билгесе. Туган ил табигатенең тавышы. Ул Бибинур әбигә туган туфрак хисе аша тәэсир итә дияр кемдер. Бибинур әби карарларын үзе кабул итә, әмма моны ул туган туфрак хисенә буйсындырып эшли. Нәкъ менә шул хис Бибинурның шәфкатьлеген мәхәббәтеннән өстен чыгара. Ятим балаларга ярдәм итү омтылышын даими, тотрыклы бәхет дип ышандыра. Карт Габдуллаҗан өенә китерә.

Мәхәббәт ул кеше ихтыярына буйсынмыйча килә, аңардан рөхсәт сорамыйча китә. Ул, буа шаулавы кебек, кешене үз көченә буйсындыра, аның ихтыяр көчен, акылын җиңә һәм бөтенләй мәгънәсез булып күренгән эшләр эшләтә.

Шуңа күрә кемдер буа шаулавын мәхәббәт ул, дияр. Аны мәхәббәт итеп тә кабул итәргә була.

Бибинур үз гомерендә егетләрне яратырга өлгерми кала. Үги балалары өчен ул җанын да кызганмый. Әмма балалары шундый ук хис белән җавап бирә алмыйлар. Балаларга булган мәхәббәт тә үги балаларны кызгану, шәфкатьлек күрсәтү булып кына кала. Ә бит адәм баласы үз гомерендә әле үзенең оныкларын да яратып өлгерергә тиеш. Кеше мәхәббәтнең шундый өч төрен үтсә генә бәхетле була ала. Бибинур оныкларын, дөресрәге, үги балаларының балаларын бөтенләй күрми. Аның мәхәббәте, буа кебек, иреккә чыга алмыйча кала. Ул, буа кебек, азлап кына, ләкин тавышланып, зарланып кына ага. Ләкин мәхәббәт хисе иреккә чыгарга ашкына. Моның өчен ул уңайлы шарт кына көтеп ята. Ниһаять, шарт туа, авылга нечкә күңелле, кешеләрне хөрмәт итә торган, матурлыкка гашыйк кеше килә. Һәм Бибинур күңелендә буылып торган мәхәббәт тышка бәреп чыга. Хәзер ул Җиһангирны уллары итеп тә, оныклары итеп тә ярата. Үз егетенә, иренә, улларына, оныкларына булырга тиешле мәхәббәт бөтенләй башка кешегә багышлана. Әмма ул кеше шундый мәхәббәтләрнең барысына да лаек.

«Буа тавышы кечкенә елгачыкның ирек даулавы, моңы, зары. Шуңа күрә ул мескен Бибинур карчыкның да тормышта үз урынын, кешечә яшәргә шарт, ирек, хокук даулавына метафора булып килә» дигән фикер дә туарга мөмкин.

Бу фикер белән дә килешәбез. Ирексезлекнең нидән гыйбарәт булуын ачыклыйк. Бибинур әби бөтен гомере буе башкаларга ярдәм итә. Ул — шәфкать анасы — башкача яшәүне күз алдына да китерми. Ярдәм итүне ул кемгәдер яхшылык

эшләү дип тә уйламый. Шәфкатьлелек — Бибинур әбинең гадәти яшәү рәвеше. Шуңа күрә ул танышына да, таныш булмаган кешеләргә дә, дошманнарына да ярдәм итәргә генә тора. Шул максатында яшьлеген дә, мәхәббәтен дә, гомерен дә кызганмый.

Яхшылык һәрвакыт кешеләргә яхшылык булып кайткан. Элек шулай булган. Ләкин заманалар үзгәргән, заманалар белән бергә кешеләр дә үзгәргәннәр. Яңа заман үзгәрткән кешеләр өчен риясыз игелек кирәкмәс бер сыйфатка әйләнгән. Бибинур карчыкны аңламыйлар һәм аңларга теләмиләр дә. Намусыни кушса, Бибинур шуны эшли. Аның һәр кылган гамәле — үзе өчен табигый гамәлләр. Зөһрәбану аның турында гайбәт таратып йөри — Бибинур сеңлесеннән үч алырга җыенмый да, киресенчә, ничек кенә булса да аны бәхетле итү турында борчылып уйлана. Үстереп кеше иткән балалары ташлаганнар — Бибинурның иң зур кайгысы шуларны кешеләр каргышыннан аяп калу.

Бибинурның мәшәкатен дә, кайгысын да авыл халкы аңламый, шуңа күрә әби үз эченә йомыла, үз эчке дөньясы белән яши башлый. Аны берәү дә рәнҗетми, ирегән кысмый. Әмма Бибинур шуңа карамастан ирексез: ул ялгызлыгы, йомыклыгы, кайгыларын кешеләр белән уртаклаша алмавы белән ирексез.

Йомгак

Әмирхан Еники белән Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә төп игътибар кеше язмышын сурәтләүгә юнәлтелә. Икесендә дә ул — олы кешеләр язмышы. Икесендә дә өлкән кешеләр язмышының иң зур драмасы — заман белән уртак тел таба алмауда.

Бу конфликт бик үзенчәлекле: өлкәннәр буыннар арасындагы җепләрнең өзелүен күреп борчылалар, бәйләнешне торгызырга тырышалар. Ә аларның уллары белән оныклары картларга каршы көрәшмиләр. Алар олылар әйткәнне, гомумән, колакларына да элмиләр. Бу каршылык гаилә эчендәге проблема чикләренә генә сыешмый.

Әдипләрнең икесендә дә буыннарны туган туфрак хисе бәйләп тора. Ә бабайлар буынын балалар буыны белән бәйләүче туган туфрак хисен һәр ике әдип милләтне яшәтә ала торган иң куәтле көч дип исәпли.

Аерым кешеләр язмышы, шул рәвешле, милләт язмышы югарылыгына күтәрелә.

Әмирхан Еники һәм Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә дә өлкән буын вәкилләре үзләренең язмышларын милләт язмышы белән бәйләмиләр. Милләт үзе аларның иң изге ышанычларын таптап, изеп китә. Әдипләрнең икесен дә милләтнең үзен үзе һәлак итүе борчый. Икесе дә туган туфрак хисен югалтуны әхлаксызлык дип бәялиләр.

Алай да әдипләр бөтенләй үк өметләрен өзеп бетермәделәр. Әлегә татар халкында үзен милләт буларак саклап калырлык көч барлыгын күрсәттеләр. Аны һәр әдип үзенчә атады һәм үзенчә тасвирлады. Бу көчне Әмирхан Еники әлегә авыл кешеләрендә сакланып калган туган туфрак хисендә, Аяз Гыйләҗев исә игелек хисендә күрде. Әдипләр бу көчнең яшь буынга күчүен дә күрсәттеләр: Клара белән Җиһангир — шул өметне дәлилләүче геройлар.

Гамил Афзал

(1921—2003)

Гамил Афзал 1921 елның 23 маенда Татарстанның Акташ районы Такталачык авылында туа. Әтисе Гыймазетдин абзый Магнитогорск шәһәренә төзелешкә күчеп килгәндә, Гамилгә ун яшь була. Бу шәһәрдә ул мәктәптә укый, металлургия комбинатында слесарь, ышкылап шомартучы булып эшли. Авыру сәбәпле, эшеннән китәргә мәҗбүр була. Соңрак гомуми торакта комендант, хәтта бер артельнең тегү цехында мөдир булып та эшли. Сәламәтлеге начарлану сәбәпле, хезмәтен ташларга мәҗбүр була.

Әле тормыш юлын башларга да өлгермәгән яшь егет авыр хәлдә кала. Ни эшләргә? 1954 елны булачак шагыйрь апасы янына Башкортстанга китә. Матур табигатьле Шәрип һәм Заболотский авылларында Гамил Афзал ун ел яши. Монда ул сәламәтлеген шактый ныгыта, актив рәвештә шигырьләр яза башлый.

Гамил Афзалда хәтта язучылар арасында да сирәк очрый торган сыйфат — дөньяны үткен фикер аша уздырып күрә алу сыйфаты бар. Ул кешеләр белән сөйләшкәндә дә үзе аз гына да көлмичә, сүзләренең эченә бөтенләй башка, капма-каршы фикер салып әйтә. Сине мактап утырса, бераз уйлагач абайлап аласың, иптәшләрчә генә тәнкыйтьләп утыра икән.

Әмма юморист буларак, Гамил Афзалда аеруча кыйммәтле сыйфат — аның үзеннән-үзе көләргә яратуы. Шагыйрь башкалар белән аралашканда да, шигырьләрендә дә, мин үземне тәнкыйтьлим бит дип аз гына да уйламыйча, үзеннән-үзе көлә.

Үзеннән көлгән булып, ул кешеләрнең һәм җәмгыятьнең төрле кимчелекләрен фаш итә.

Гамил Афзал — шуның өстенә сүзнең яңгырашын бөтен нечкәлекләре белән тоя торган кеше. Табигый юмористлыгы белән кушылып, шигырьләрендәге ритмик һәм рифма тудырган көй аның әсәрләрен укып туймаслык итә.

1965 елдан алып Гамил Афзал Әлмәт шәһәрендә яшәде.

ЯЗМЫШЛАР

Кара син болынлы бу якны,
Болында чәчәкләр ничаклы;
Болында чәчәкләр төрләләр
Гомерләр,
гомерләр,
гомерләр.

Карыйсың уңга да, сулга да,
Гүяки балыклар елгада;
Гүяки тирбәлгән камышлар
Язмышлар,
язмышлар,
язмышлар.

Ничаклы тапталган нахакка,
Ничаклы киселгән сабакта
Баш тәрткән хуш исле бөреләр
Тереләр,
тереләр,
тереләр.

1964 ел

ЕЛМАЯМ УЙЧАН ГЫНА...

Кулларыма һуш китәрдәй чәчкәләр җыйсам да мин,
Юлларыма бер карыйм да елмаям уйчан гына.

Юл буенда, шау болында зур кибән куйсам да мин,
Дауламыйм да, шауламыйм да, елмаям уйчан гына.

Аугa чыккан арыслaндай бик горур торсам да мин,
«Кит» дигәндә юл бирәм дә елмаям уйчан гына.

Үз эчемдә, тар кабыкта тауга тау орсам да мин,
Ут кабып та, су кабып та елмаям уйчан гына.

1968 ел

ГОМЕР КИТАБЫ

Егермедә үсәм, дисең,
Дошман килсә кисәм, дисең;
Утны-суны кичәм, дисең,
Дәртле йөрәк исән, дисең.
Ә еллар бара тора,
Елгалар ага тора.

Кырык яшьтә булам, дисең,
Тоткан җирдән борам, дисең;
Ташны ташка орам, дисең,
Патша кебек торам, дисең.
Ә җилләр исә тора,
Малайлар үсә тора.

Алтмыш адым бардым, дисең,
Ташлы юлга тардым, дисең;
Тешем белән, түшем белән
Буразналар ярдым, дисең.
Ә еллар бара тора,
Елгалар ага тора.

Әле миңа сиксән, дисең,
Сындырырмын типсәм, дисең;
Карчыгым да исән, дисең,
Тагын әзрәк үсәм, дисең.
Ә җилләр исә тора,
Оныклар үсә тора.

Йөзне кырлап торам, дисең,
Торып тамак кырам, дисең;
Бер теләгем үтәлмәде,
Эчләремдә буран, дисең...
Ә еллар бара тора,
Елгалар ага тора.

1969 ел

«Язмышлар» шигыренә анализ

Шигырьнең эчтәлеге лирик герой хисенең сәбәбен табудан башланганга, сәбәп эзлибез.

Строфалар бер-берсенә охшамаганнар. Беренчесендә әдип — гомерләр, икенчесендә — язмышлар, ә өченчесендә бөреләр турында сөйли. Өч темага багышланган өлешләр арасындагы бәйләнешне табу өчен, өлешләрнең һәрберсенә аерым-аерым тукталыйк.

Беренче өлештә кешеләрнең гомерләре чәчәкләр белән чагыштырыла. Чәчәкләрдән гомерләргә матурлык һәм төрлелек сыйфатлары күчә.

Икенче өлештә язмышларның камышка һәм балыкка охшаганлыгы әйтелә. Язмышларга балыкларның һәм камышларның бертөрлелеге, салкынлыгы күчә.

Ике өлеш арасындагы бәйләнешне табыйк.

Ни өчен гомер язмышка әйләнгәч ямьсезләнгән? Бу сорауга әдип җавап бирми. Әмма уйланырга ярдәм итә. Гомер — шәхес гомере, табигатьнең бүләге, табигый рәвештә бәхетле булырга тиешле тормыш. Ә менә тормыш шәхесләрне югалта, кешеләрне бәхетсезлекләре белән тигезли.

Җавап эзләп соңгы өлешкә күз салабыз.

Өченче өлештә җавап шактый ачык әйтелгән. Монда кешеләр бөреләргә охшатыла. Бөреләрдән кешеләргә кешелекләрен бөре хәлендә генә булса да саклап калган хуш ис матурлыгы һәм яшәү көче күчә. Әмма нигә бөре? Ни өчен кеше гомере, беренче строфадагы кебек, матур һәм төрле чәчәкләр белән кабат чагыштырылмый?

Чөнки беренче строфада кешенең бәхеткә һәм шатлыкка хакы барлыгы турында әйтелсә, хәзер хакыйкать әйтелә: бөре ул — сабаклары киселгән, тапталган, кимсетелгән чәчәк, җан иясе. Ул — кешеләрнең түземлеге һәм авторның киләчәккә өмете. Тиешле шартлар туу белән, бөреләр яфрак ярачаклар бит, чәчәкләргә әйләнәчәк. Бу сорауны ул сорау билгесе куймыйча гына һәр шигыренә диярлек кертә. Әлеге сорауга җавап таба алмаў — авторның даими борчуы булып шигырьнең эчтәлегенә керә.

Хәзер хис сәбәпләре ачыкланды: ул — кешеләрнең бәхеткә хокуклары булып та гомерләре буе бәхетсезлектә яшәве, шәхесләрен югалтуы. Ул — илдә хөкем сөргән хаксызлык һәм кансызлык. Әмма шул ук вакытта авторның үзендә һәм башкаларда күреп алган өмет бөресенең исән булуы.

Шул сәбәпләр тудырган катлаулы хискә шигырьнең эчтәлеге, дибез.

Гамил Афзалның кабатлаулар һәм кыска-кыска, өзек-өзек җөмләләре, әледән-әле пауза ясарга мәҗбүр иткән интонациясе укучыны уйланырга чакыра һәм үзенең хис дәрәҗәсен күрсәтә. Без әсәр эчтәлегенә хис дәрәҗәсе дә керүен яхшы беләбез.

Биремнәр һәм сораулар

1. «Елмаям уйчан гына...» шигыренә анализ ясап, эчтәлеген табыгыз.

2. Бу ике шигырь эчтәлекләрендәге бәйләнеш турында сөйләгез.

3. «Гомер китабы» шигырен ике өлешкә бүлегез. Өлешләр, гадәттәгечә, бер-берсенә каршылыкта торырга тиешләр.

4. Эчтәлек шул өлешләрнең бәйләнешләрендә икәнлеген беләбез. Еллар үткән саен картая барган кеше белән бәйле эчтәлекне сөйләгез.

5. Гамил Афзал шигырьләренә яшәеш, замана турында фәлсәфи фикер салырга ярата. Шул фикерне табыгыз һәм аны автор кичерешенең сәбәбе итегез. Шулай итсәк, шигырьнең фәлсәфи эчтәлеген табабыз.

* * *

Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә,
Җан өшерлек хәлләр күрмәдем.
Штраф та түләмәдем бер дә,
Суд ишеген ачып кермәдем.
Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә.
Һәр таңында кояш белән торып,
Җанга алдым дөнья сагышын.
Гомер буе билдән пычрак ерып,
Ап-ак көе калды намусым,
Һәр таңында кояш белән торып.

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз. Лирик геройга бәя бирегез. Бу шигырь Гамил Афзалның кайсы шигырен хәтерләтә? Ике шигырьнең уртак ягын һәм аермасын әйтеп бирегез.

* * *

Ахмак килә: күкрәк кага, гайрәт ора...
Явыз килә: тозак сала, хәйлә кора.
Гадел акыл сабыр гына карап тора,
Көлемсерәп, урый-урый мыек бора.

* * *

Чабаклар йөзгән Иделдә
Чәчләрем юганым бар.
Чәчәкләр үскән җиремдә
Кибәннәр куйганым бар.

Йолдызлар янган көнемдә
Энҗеләр җыйганым бар;
Арыслан ята күңелдә,
Кулымда куяным бар...

* * *

Һәр яфрагы тере кебек,
Табигатьнең сере кебек
яшел эңгер,
Ак каеннар арасыннан
Япькелт нурлар коя кемдер
җилбер-җилбер..

* * *

Ай нурына чумган яшел тынлык
Йолдызларга карап бер сүз көтә,
Ә йолдызлар күз кысалар шундук
Сүз әйткәнче бик күп гасыр үтә.

Биремнәр

1. Шигырьләргә анализ ясагыз. Аларның башка шигырьләр белән бәйләнешен табыгыз.

2. «Һәр яфрагы...» һәм «Ай нурына...» шигырьләрендә тема үзгәрә. Табигать матурлыгына соклану башка шигырьләрдәге тормыш ямьсезлеге белән нинди бәйләнешкә керә ала?

ТӘВӘККӘЛ ӘБИ

«...Кәҗәбезгә печән беткән,
Колхозныкы хәләл икән,
Тәвәккәлгә тугыз җирдән
Хак Тәгалә бирәм дигән.

Хәерле кыл үзең, Ходай!..»
Гайни әби чыкты юлга,
Аның белән бергә китте
Чана тартып Сәрвәретдин.

Бара болар, һаман бара,
Ак кар ява һәм төн кара.
Карлы дала уртасында
Гайни әби кибән таба.

— И Ходаем, үзең сакла,
Кяферләрнең күзен капла,
Сәрвәретдин, балакаем,
Син карап тор, мин йолкаем!

Печән төяп, чана тарткан
Кара төндә нинди юлчы? —
Аркасына мылтык аскан
Килде чыкты каравылчы.

— Атам! — диде мәхәббәтсез...
Әби калды тәһарәтсез,
Үкчәсенә китте җаны,
Басып тора хәрәкәтсез.

— Тфү, әстәгъфирулла!
Бәбекәем, Хәбибулла,
Эңгер-меңгер,
Син күр — мин күр,
Печән бирде Ходай юлда...

— Минемчә, ялгышкан Алла,
Үз печәне булмаганга,
Колхозныкын җибәргән ул, —
Идарәгә җәвитсә бул!

Идарәгә әби барды,
Күзләреннән яшь чыгарды,
Ул намазчы, изге килеш...
Котыртучы шайтан, имеш!

1955 ел

СӘЛӘХЕТДИН АБЗЫЙ СӨЙЛИ

Дүрт малаем дүрт урында,
Газетта алар турында
Язалар, сөенә күңел,
Мактанып әйтү түгел.

Алар район күркесе лә,
Начальниклар дүртесе дә,
Сокланып туймый күңел,
Мактанып әйтү түгел.

Бер министр кызын димли,
Кызы фәрештәгә тиң, ди,
Ләкин малай кирәкми, ди,
Мактанып әйтү түгел.

Кабинетта уңга-сулга
Кычкыралар телефонга,
Мал табалар бик җиңел,
Мактанып әйтү түгел.

Базарга да левковуйда,
Абзарга да левковуйда,
Башкалага кучу уйда,
Мактанып әйтү түгел.

Бер төрик әле, Сәйфулла,
Янчыгым юк минем монда,
Калган акча сандыгымда,
Мактанып әйтү түгел.

1956 ел

Биремнәр

1. Сатирик әсәрләр төзелешен исегезгә төшерегез. «Тәвәккәл әби» шигыренә анализ ясагыз.

2. «Сәләхетдин абзый сөйли» шигырен башка сатирик әсәрләрне ике өлешкә бүлгән кебек бүлегез. Әсәрнең эчтәлеген табыгыз.

Гамил Афзал хәсрәте. Тормыш авырлыгы белән шул еллардагы пропаганда арасындагы каршылыкны шагыйрь үзенең беренче шигырьләрендә үк:

Безнең тормыш михнәт, мәшәкатьтән
Җыелган диеп,
Коелган диеп,
Барам, барам, алда максат ерак,
Җиңелмәм, димен,
Чигенмәм, димен,—

дип язып чыга.

Тормыш гаделсезлеге тудырган үкенеч хисе Гамил Афзалның хәтта табигать матурлыгына сокланып язган шигырьләрендә дә шомлы моң булып ишетелеп тора.

Ләкин Гамил Афзал тормыш гаделсезлеген язу белән генә канәгатьләнми. Гаделсезлекнең сәбәпләрен эзли. Гаделсезлекнең сәбәбен беренче чиратта кешеләрнең шул гаделсезлек белән килешеп яшәүләрендә күрә.

«Елмаям уйчан гына...» шигырендә:

Аута чыккан арысландай бик горур торсам да мин,
«Кит» дигәндә юл бирәм дә, елмаям уйчан гына,—

ди. Ә «Чабаклар» шигырендә тагын да ачыграк итеп:

Арыслан ята күңелдә,
Кулымда куяным бар,—

дип язып чыга.

Күңелендәге арыслан гайрәте һәм кулындагы куркак куян каршылыгын әдип үз эчендәге каршылык, үз фаҗигасе итеп яза. Әмма намус белән куркаклык арасындагы эчке көрәш совет кешеләренең гомумән яшәү рәвеше, ягъни бөтен ил фаҗигасе иде. Гамил Афзал бу теманы татар әдәбиятында беренчеләрдән булып күтәрде.

Гамил Афзал илнең бу фаҗигасе турында уйлана, аңа фәлсәфи бәя бирә, киләчәкнең дә билгесезлегенә борчыла.

Тормышның гаделсезлеге, авырлыгы, кешеләрнең, үз эчләрендә конфликтка кереп, икегә бүленеп яшәүләре — кешеләрнең гомерләре, язмышлары бит. Кеше гомере буена бәхетсез булып яши һәм бу халәтеннән чыгар юлны белми.

«Язмышлар» шигырендә әдип кеше гомерен матур чәчәкләргә охшата. Бар да матур, бар да төрле-төрле гомерләр. Әмма һәрберсен бер үк төрле язмыш көтә дип белдерә автор.

Ничаклы тапталган нахакка,
Ничаклы киселгән сабакта
Баш төрткән хуш исле бөреләр
Тереләр,
тереләр,
тереләр,—

дип, кешеләрнең бөре хәлендә генә булса да исән калып яшәргә омтылуына гаҗәпләнә.

Яшәгән кебек яшәүнең мәгънәсезлеге, кешеләрнең бозык заманга ярашуы Гамил Афзал шигырьләрендә лирик герой хисләренең төп сәбәпләре булдылар. Бу тема әдипне гомере буена борчып, хәсрәткә батырып тора. Мондый эчтәлекле шигырьләр, билгеле, заман рухын чагылдырмадылар. Әмма шундый хәтәр елларда да татар әдәбияты хакыйкать кыйбласына карап юл тотты дип, горурланып әйтә алабыз. Монда, әлбәттә, Гамил Афзалның өлеше бик зур.

* * *

Аю йөргән урман арасында
Күзгә кебек юллар саласы,
Дулкын кебек кылган даласында
Иген игеп, йортлар саласы.

Нәрсә кирәк адәм баласына?!

Җирне казып җәүһәр табасы да
Күккә карап йолдыз санасы...
Идел белән Чулман арасында
Изү чишеп печән чабасы.

Нәрсә кирәк адәм баласына?!

Дугаларга тасма тагасы да
Җил җилләтеп туйга барасы;
Кызлар биреп, кызлар аласы да
Чык суыдай гөлгә тамасы.

Нәрсә кирәк адәм баласына?!

Йөрәктәге кылыч ярасына
Савыктыргыч бальзам саласы;
Сугыш белән сугыш арасында
Бер кинәнеп яшәп каласы.

Нәрсә кирәк адәм баласына?!

1971 ел

Шигырьгә анализ

Шигырьнең күп өлеше теләк рәвешендә язылган. Теләкләрнең барысы да изге, матур. Ләкин нигә бу матурлык бары тик теләк кенә соң? Теләкләрнең дә хыялдагылары, көч

җитмәстәйләре була. Ә Гамил Афзал ни өчендер, теләгән кабатлый-кабатлый, гап-гади нәрсәләрне булдыра алмавы турында яза. Иген игү һәм йортлар салу кеше эшләмәслек эшмени? Печән чабу адәм баласы булдыра алмаслык эшме?

Үти алмаслык теләк итеп гап-гади гамәлләрне атау безнең игътибарны каршылык буларак җәлеп итәргә тиеш.

Бу сорауга җавап табып өлгерә алмадык, шагыйрь безне тагын уйга калдыра: «Нәрсә кирәк адәм баласына?!» дигән соравын һәм өндәвен кабатлый. Автор кабатланган бу юлы белән ни әйтергә тели? Сибгат Хәким кебек «Башка берни дә кирәкми» димәкче буламы? Әллә бу юлда «Гап-гади эшләрне башкару өчен адәм баласына ни җитми? Нигә ул печәнен чаба алмый, игенен икми, җәүһәрен эзләми һәм ял итми» соравы бармы?

Җавапны соңгы юлдан табабыз. Кешегә ни җитми? Тыныч тормыш җитми. Кешенең тынычлап эшләр өчен әле сугыштан бушаганы юк. Аның әле ярасы да төзәлмәгән, ул кулына чалгы да, көрәк тә тота алмый, алай да тормышлар тыныч вакытта хыялда гына булса да яшәп калу, ягъни кеше эшләргә тиешле гап-гади эшләрне эшләп калу турында хыяллана.

Хәзер кабатланган юлның мәгънәләре ачыклана.

Адәм баласына тынычлык кына кирәк. Тынычлык булса, ул үз бәхетен үзе таба ди кабатланган юл. Әмма шул ук юлда: безнең бәхет ул — җиң сызганып печән чабу, йортлар төзү, ашлык үстерү. Безгә шул да җитә дигән фикер дә ята.

Хәзер теләк белән тормыш шартлары арасындагы каршылык аңлашыла: бу каршылыкны «бездә яшәр өчен шартлар юк, кеше бәхетсез» дип ачыклыйбыз.

Хәзер безгә сугышларның нәрсә икәнлеген генә ачыклыйсы кала.

Бирем

Шигырь язылган елны истә тотып, авторның хакыйкатькә мөнәсәбәте турында сөйләгез.

* * *

Җитәкчеләр килә, китә,
без калабыз әле.
Җәһәннәмнәр сүнә — бетә,
без янабыз әле.

Аждаһаның күзенә карап
елмаябыз әле.
Без барабыз әле...

1990 ел

Шигырьгә анализ

Охшаш урыннарны җыябыз. Җитәкчеләрнең килеп китүе, җәһәннәмнәрнең сүнүе — хәрәкәт, үзгәреш. Иң соңгы юлдагы «барабыз»да хәрәкәт — алга китү. Ләкин дөньялар күпме генә үзгәрмәсен, без үзгәрмибез. Шигырьнең икенче өлешендә торгынлык. «Әле» сүзен кабатлый-кабатлый, Гамил Афзал гадәтенчә бу сүзгә дә өстәмә мәгънәләр сала. «Без калабыз әле»,— ди. «Әле» сүзе «бүген исән, иртәгә ни буласын кем белә» һәм «без калырга булдык әле» мәгънәләрен белдереп килә. «Әле» сүзен кабатлап, шагыйрь беренче өлештәге хәрәкәт-үзгәрешкә торгынлыкны каршы куеп кына калмый, хәрәкәтнең, үзгәрешнең, гомумән, юклыгы турында әйтә.

Җитәкчеләр килеп киткән, әмма тормыш үзгәрмәгән. Бер җитәкче урынын икенчесе алыштырган. Без алдагыларына елмайган кебек, монысына да елмаябыз. Үзгәреш бармы? Юк, җәһәннәм, ягъни җәһәннәм кебек тормыш бетте, дими Гамил Афзал, ә бу тормыш алмашынып тора, ди. Без һаман җәһәннәм утында янып торгач, димәк, шундый ук җәһәннәмдә яшибез дигән сүз.

Түбәндәге шигырьгә үзегез анализ ясагыз һәм **Г. Афзалның** башка шигырьләре белән бәйләнешкә кертергә тырышыгыз.

* * *

Ярлы кеше яманыр да юаныр, ди,
Яңадан да шәп булыр дип уйланыр, ди,
Кесәләрдә алтын-көмеш булмаса да,
Эшем бара, кайгы юк дип куаныр, ди.

Мин дә шулай, ятсам да бер, торсам да бер,
Өстәлемдә бер бит кәгазь, каләм әзер,
Көн буена газапланып бер сүз язам,
Менә, димен, шөкер әле, алга барам...

1990 ел

Хәй Вахит
(1918—1978)

Габделхәй Каюм улы Вахитов 1918 елның 2 декабрендә Татарстанның Биектау районы Мәмдәл авылында туа.

Җиденче сыйныфны тәмамлагач, Казандагы театр техникумына укырга керә. Тәмамлый алмый, техникум ябыла. Чистай районының Яңа Роман авылында укытучы булып эшли. 1937 елны кабат Казанга килә һәм өч ел буена музыка училищесында укый. Аны тәмамлагач, җыр-бию ансамблендә җырчы була. Сугыш башлану белән, армиягә китә һәм туганүскән илләренә сугыш беткәч кенә әйләнеп кайта. Кайту белән, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә, аны тәмамлагач, Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Шуннан соң үзенең төп һөнәре итеп язучылык эшен сайлый һәм гомеренең соңгы көненә кадәр пьесалар, музыкаль комедияләр, опералар өчен либреттолар яза.

Әдәбиятка балалар өчен шигырьләр, әкиятләр язып килгән Хәй Вахит 1961 елда иҗат иткән «Беренче мәхәббәт» пьесасы белән дан казана. Аннары драматург «Рәхим итегез!» (1961), «Кайда соң син?» (1963), «Карлыгач канат кага» (1965), «Соңгы хат» (1966), «Күк капусы ачылса» (1967), «Туй алдыннан» (1969) һ. б. пьесаларын ел саен диярлек язып тора. Бу пьесалар бар да күп еллар буена сәхнәләрдә уйналып килделәр. 60—70 нче елларда театр мәйданын Хәй Вахит тотты дип, икеләнүсез әйтергә мөмкин.

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

(Өч пәрдәле драма)

КАТНАШАЛАР:

Тәлгать.
Рәхилә.
Сәлим Гәрәевич — урта мәктәп директоры.
Камилә — Сәлимнең хатыны.
Госман Әкбәрович — укытучы, 27 яшьтә.
Нурсәнә — фермада сыер савучы. Рәхиләнең дусты, 21 яшьтә.
Әпсәләм — Нурсәнәнең ире, 19 яшьтә. Терлекчелек фермасында эшли.

Вакыйга бүгенге көндә авылда бара.

Беренче пәрдә

Сәлим Гәрәевичләр йорты. Зур бүлмә. Зал пөхтә җыештырылган, диван, өстәл, урындыклар куелган. Җәй башы. Тышта тәрәзә каршында алмагач. Пәрдә ачылганда сәхнәдә берәү дә юк. Сул яктагы бүлмә эченнән кемнеңдер скрипкада яңа вальс уйнаганы ишетелә. Бераздан коридор ишеген шакылдаталар.

Рәхилә тавышы *(бүлмә эченнән)*. Күк-кү...

Вальс агыла да агыла. Бераздан тагын ишек шакылдаталар.

Рәхилә тавышы *(бүлмәдән)*. Керегез!

Тәлгать күренә. Юл киеменнән. Рәхилә чыга, каршында танып булмаган кешене күреп туктала. Көй ярты юлда өзелә.

Тәлгать. Исәнмесез! Миңа мәктәп директоры Сәлим абый кирәк иде. Хат китергән идем.

Рәхилә. Ә мин аның кызы булам. Куегыз әнә өстәлгә.

Тәлгать. Үзе кайчан кайтыр икән? Җавап алырга икенче керермен. *(Ишеккә юнәлә, Рәхилә аның юлын бүлә.)*

Рәхилә. Утырыгыз! Утырыгыз, утыр. *(Тәлгать утыра.)* Так... сезне кем дип беләбез инде?

Тәлгать. Мин еракган, быел унынчы классны тәмамладым, унҗиде яшьтә, комсомол, өйләнмәгән — егет кеше. *(Җитди.)* Без әни белән икәү генә тора идек. Быел... әле күптән түгел генә мин аны җирләдем. Әтием юк.

Рәхилә. Сугыштан кайтмадымы? Кем иде?

Тәлгать *(кискен)*. Минем әтием юк. Булмаган!

Рәхилә. Алай икән... Хәзер институтка керергә җыенасызмы?

Тәлгать. Җыенмыйм.

Рәхилә. Нишләп, сынау бирә алмам дип куркасызмы әллә?

Тәлгать Рәхиләгә күтәрелеп карый да чыгып китә. Рәхилә шунда Тәлгатьнең онытып калдырган кепкасын күреп ала. Тәлгать кире керә, кепкасын эзли. Рәхилә кепканы артына яшереп тора, аннан башына кия. Тәлгать моны күргәч елмаеп куя. Көлешәләр.

Рәхилә. Бу хат кемнән соң?

Тәлгать. Әнидән. Ул аны элек язган булган. Күңеле сизенеп. Хәле авырайгач, мине чакырып алды да: «Улым, мин тормыштан китәм инде, сине ышанып калдырырга кешем дә юк»,— диде. Шунда ул сезнең әтиегезне исенә төшерде. Алар кайчандыр бергә укыган булганнар. Минем киләчәкне ул әтиегез кулына тапшырды. Күрәсең, ул мине һаман балалыктан чыкмаган дип исәпләгәндер инде. Шушы хатны бирде.

Рәхилә. Нәрсә язылган соң анда?

Тәлгать. Белмим. Укымадым.

Рәхилә *(гаҗәпләнеп)*. Укымадыгыз? Китсәнә?! Ничек түзә алдыгыз? Хәзер укыйбыз аны. *(Конвертны ерта башлый.)*

Тәлгать. Рөхсәт итмим.

Тәлгать Рәхиләгә ташлана. Тартышалар. Үзе дә сизмәстән, Рәхилә Тәлгатьнең кулын тешли. Икесе дә тынып калалар. Рәхилә аңына килә, хатны өстәлгә куя.

Рәхилә. Сезнең әниегез белән минем әти бергә укыганнар, дисезме әле? Алай булгач, без танышлар икәнбез. *(Кул суза.)* Танышлар гына түгел, дуслар.

Тәлгать тә Рәхиләгә кулын бирә.

Әйдә, «син»гә күчәбез! Без бит үз кешеләр. Килештекме? Булды! Минем исемем — Рәхилә. Ә егетләр Раечка дип йөртәләр. Сине ничек дип атыйк?

Тәлгать. Мине кызлар Тәлгатьчик дип йөртәләр.

Рәхилә. Тәлгать? Матур. Үзеңне әйтмим, исемең матур, дим. Тәлгать, син нишләп минем белән бер дә кызыксынмыйсың әле? Неприлично?

Тәлгать. Ничәнче классны бетердең?

Рәхилә. Кияүгә чыга алмасам, быел институтка керәм... Тәлгать, өегездә кем калды соң?

Тәлгать. Өебез юк, фатирда тора идек.

Рәхилә. И, алайса, син бездә торырсың.

Тәлгать. Юк, юк. Кирәкми, Рәхилә.

Рәхилә. Слушай, кал. Миңа да күңелле булыр иде. Сөйләшергә дә кеше юк. *(Тәрәзәдән күреп.)* Әни кайтып килә, кер менә бу бүлмәгә. Тының да чыкмасын. Әшне башта әти белән йөртергә кирәк. Әнинең тәртәгә тибеп куюы бар. *(Җилкәсеннән этеп, Тәлгатьне бүлмәгә алып кереп китә.)*

Камилә кайтып керә. Бүлмәдән Рәхилә чыга.

Камилә. Әтиең кайтмадымы?

Рәхилә. Юк. Әни, бүлмәгә кереп, миңа комачаулап йөрмә. Дәрес хәзерлим.

Шулвакыт бүлмәдән Тәлгать килеп чыга.

Тәлгать. Ябылып ятарга күпме мөмкин... Исәнмесез.

Рәхилә. Әни, ул безнең якын танышыбыз, әти янына дип килгән.

Камилә. Күреп торам, әтисе янына дип килгән, кызы янына кергән. *(Тәрәзәдән күреп.)* Әнә үзе дә кайтып килә.

Коридорда Сәлим Гәрәевич күренә. Киемнәре тузанга буялып беткән.

Сәлим. Трактор ватылган иде, төзәтешергә туры килде.

Камилә. Синең шул булыр инде. Сал, әйдә, костюмыңны, сал. *(Сәлимнең костюмын салдырып ала да бакчага чыгып китә.)*

Тәлгать. Исәнмесез.

Рәхилә. Әти, таныш бул, Тәлгать. Ул сиңа хат алып килгән. Менә.

Рәхилә чыгып китә.

Сәлим. Хат? *(Кабаланып хатны укый. Үзгәрә, таркау фикерен тупларга тырыша.)* Тәлгать! Менә син нинди икәнсең! *(Күкрәгенә кыса, маңгаеннан үбә.)*

Тәлгать. Әни минем сезнең янга килүемне теләгән иде. Ә мин аның теләген үтәми булдыра алмадым.

Сәлим. Монда әниең сине эшкә урнаштыру турында сораган.

Рәхилә керә.

Рәхилә. Әти, Тәлгатьнең торырга да урыны юк әле. Ул бездә торырга тиеш.

Тәлгать. Мин сездә кала алмыйм.

Камилә керә, костюмны элеп куя.

Сәлим. Тәлгать, ашыкма. Сиңа бездә калырга кирәк. Урын иркен. Аннан соң...

Рәхилә. Ишеттеңме этинең боерыгын?! Әйдә мин сине урнаштырам.

Рәхилә Тәлгать белән бүлмәгә кереп китә.

Камилә. Тәлгать дидеңме? Ул — Тәлгатьме?

Сәлим. Әйе, Камилә. Кара, ул ничек үскән, тәмам егет булып җиткән. Чибәр. Характерлы булырга охшый.

Камилә. Ул бездә кала дисеңме әле? Бар икән! Миңа тыныч кына яшәргә насыйп түгелдер инде. Теләсә нәрсә әйт, мин аның бездә торуына каршы.

Сәлим. Тәлгать бездә тормыйча, кемдә торсын. *(Ярсуын басарга, үзен кулга алырга тырыша.)* Синдә көнчелек көчле. Юкка бит, урынсызга.

Камилә. Көнләшергә дә хакым юк икән. Син шул мине яратмыйсың. Яратсаң, минем теләгемне аяк астына салмас идең.

Сәлим *(хатны суза)*. Мә укы, йөрәгең басылыр. Мин ата, үз баламны үзем танымыйм! Мин аның ничек үскәнен, ничек яшәгәнен дә белмәдем. Бу бит — гафу итмәслек эш.

Камилә. Бар, аягына егыл, тезлән. *(Гаепләп.)* Син хәзер дә аңа үз малаең икәнлекне әйтмәдең түгелме соң?

Сәлим. Юк, иң элек Тәлгатьне бу сөйләшүгә әзерләргә кирәк. Баланың күңелен сындырып ташлавың бар.

Камилә. Ә менә мин хәзер үк аны чакырып алам да дөресен әйтәм дә бирәм. Дөреслекне белгәч, ул монда калмаячак.

Сәлим. Акылыңны җуйма!

Камилә. Акылым үзем белән. *(Кычкыра.)* Тәлгать!

Тәлгать керә.

Тәлгать... ни... Әгәр кечкенә димәсәң, син әнә шул бүлмәдә урнашырсың.

Тәлгать. Рәхмәт. Минем өчен борчылмасагыз иде. Мин бит әле...

Сәлим. Беркая да китмисең. Әниең миңа ышанган икән, син инде... тыңла.

Камилә *(Тәлгать кереп киткәч)*. Бел аны, әнисе килеп йөрмәсен.

Сәлим. Ни сөйлисең, ул бит кабердә.

Камилә *(коелып төшә)*. Нигә соң әйтми торасың? Ә мин тагын...

Кухняга узалар. Рәхилә белән Нурсәнә чыга.

Нурсәнә. Рәхилә җаным, мин синең яныңа йомыш белән килгән идем бит. Теге Гайнижамал апа декретка чыкты, аның урынына фермага сыер савучы кирәк иде.

Рәхилә. Ә? Ха-ха-ха... Син нәрсә, әллә миннән сыер саудырмакчы буласыңмы? Унны бетереп сыер саварга!

Әпсәләм керә. Нурсәнәдән яшьрәк күренә, мыек үстергән.

Әпсәләм (*күзе гармунга төшә, кулына ала, әкрен генә уйный башлый. Җырлап та җибәрә*).

Алым син, Нурсәнә,
Гөлем син, Нурсәнә,
Яныма килсәнә,
Кулыңны бирсәнә.

Бүлмә ишегендә Рәхилә, Тәлгать күренә.

Рәхилә. Тәлгать, таныш булыгыз, Нурсәнәнең иптәше.

Нурсәнә (*таныштыра*). Исеме — Сәлам. Исәнмесез дигән сүз була.

Сәлим керә.

Сәлим. Ә, Әпсәләм... Сезне туегыздан соң күргән дә юк бит әле.

Камилә керә.

Камилә. Нихәл соң, Әпсәләм, буламы?

Әпсәләм. Эш харап бит әле безнең, Сәлим абый. Колхозда сыерлар саны артканнан-арта бара, ә көтүче юк.

Рәхилә. Сезгә йөкләмә үтәргә кирәк дип, Тәлгать көтү көтсенме? Ха-ха-ха...

Тәлгать (*Рәхиләгә карап тора да Әпсәләмгә борылып*). Уйлап карарга кирәк. Сезнең белән кайчан сөйләшергә була?

Әпсәләм. Хет хәзер.

Тәлгать. Әйдә, алайса.

Әпсәләм, Тәлгать, Нурсәнә, алар артыннан Рәхилә дә чыга.

Камилә. Кара бу Әпсәләм белән Нурсәнәне, Тәлгатьне тәмам үз якларына аудардылар түгелме соң? Боларга юл куйсаң, Рәхиләне дә үзләре белән алып китәрләр (*тәрәзәдән күреп*). Госман безгә таба килә. Инде Рәхиләгә вакыт җиткән. Артыннан Госман кебек кеше йөргәндә шатланып риза булырга кирәк. Ул Госманны ярата. Алар бәхетле булыр.

Сәлим. Госман беләнме?! Әнә кара, анда укучы балалар чүп утый, ә ул, укытучы, кырдан кайтып килә. Ничек киенгән!

Сәлим кухняга кереп китә. Госман аны күреп кала. Госман ак чалбар, ак костюмнан.

Госман. Сәлим Гәрәевич өйдә юктыр дисәм...

Камилә. Кәефе юк, авырып тора. Сез аңа игътибар итмәгез, Госман. Рәхилә, кызым!

Камилә кухняга кереп китә. Рәхилә залга чыга.

Госман. Рәхилә, күгәрченем, әгәр дә син булмасаң, мин бу бусагадан атлап керә алмас идем.

Рәхилә. Сез герой, Госман абый.

Госман. Герой түгел мин. Бәхетле кеше. Син минем гомер юлымның башында ук килгән бәхетем бит. Син бит минем язмышымның бүләге. Карачы, нинди буй-сын, нинди күзләр!

Рәхилә. Госман абый, оялтасыз.

Госман. Рәхилә, күгәрченем, мин тагын кабатларга мәҗбүрмен: безгә вакыт җитте. Көтә алмыйм. Әле дә күп чыдадым. Син укыганда ярамады. Үзең беләсең, укучысына өйләнде дип «Чаян» га ук әләктерерләр иде.

Рәхилә. Җәй көне туй ясап, илдә булмаган мөгезне чыгарабыз инде.

Госман. Мин мөгез чыгарам.

Пәрдә.

Икенче пәрдә

Шул ук күренеш. Тышта көчле яңгыр ява. Көн кичкә авышкан. Рәхилә кайтып керә, юешләнгән. Өстендәге плащын салып элеп куя, аяк-киемен алмаштыра. Күңеле күтәренке. Кухнядан Камилә чыга.

Камилә. Әйтмәдемме мин сиңа. Барып йөрмә, дидем, сыер саву синең эшең түгел, дидем.

Рәхилә. Мин бит вакытлы гына. Сүз тыңлап кына. *(Мандолина чиртә башлый. Үзе уйный, үзе вальс ритмына хәрәкәтләнә.)* Трам-тара-рам... Тара-рарам... Ә сыерлар мине оштатылар. Берсе иснәргә үк тотынды. Ә берсе, сыртыннан сыйпаган идем, миңа телен күрсәтте. Кил, янәсе, таныш булыйк.

Камилә. Ә син?

Рәхилә. Мин дә күрсәттем. Танышырга сорагач, танышыйк, дидем.

Камилә *(бот чабып).* Булса да булыр икән. Тәлгать тә шундамы?.. Кем булып соң ул анда, мөдирме, ярдәмчесеме?

Рәхилә. Көтүче.

Камилә. Һе, тәки үзенекен иткән икән.

Тәлгать, азрак соңрак Сәлим кайтып керә. Кулында кәгазьгә төрелгән бер кисәк әйбер.

Сәлим. Тәлгать, Рәхилә, йә белегез, нәрсә алдым?

Рәхилә. Кая, төргәкнең серен ачыйк әле. *(Төргәкне сүтә.)* О! Костюм! Рәхмәт сиңа, әти, Тәлгать исеменнән.

Тәлгать. Ни өчен сез миңа бүләк аласыз? Әнинең сезнең шикелле дуслары күп булгандыр, барысы да миңа бүләк бирә башласа, кая китә. *(Костюмны кире куя.)* Юк, алмыйм, рәхмәт.

Сәлим *(икеләнеп костюмны бөгәрләп тора да читтәге урындыкка ташлый).* Син этиеңне белмим дисең инде? Ә син аның минем кебек кеше булуын теләр идеңме?

Тәлгать. Ул бит... кеше түгел, ә... кабахәт. Ул сезнең кисеп ташлаган тырнагыгызга да тормый. Әни аның исемен әйткән булса, ихтимал, нәрсә булса да кылган булыр идем. Мин аны, мин анымы... Әнине шулай җәберләгәне өчен мин аны... Сәлим абый, аның аркасында әни күпме газап кичерде, күпме яшь түкте. Әниемнең шулкадәр иртә кабергә керүен мин аннан гына күрәм.

Сәлим. Ашау ягыннан кысырынкылык күрмәгәнсездер ич?

Тәлгать. Төрле чак булды инде.

Галстук Тәлгатьнең муенын буа, ахры. Ул аны сала да, бүлмәсенә алып кереп китә. Рәхилә аның артыннан керә. Сәлимнең башы салынган. Ул газаплы уй кичерә.

Камилә. Сәлим, болай булмый ич инде, Тәлгатькә дөресен сөйләп бирергә кирәк. Бәлки, аңлар... Үз-үзеңне генә бетерәсең.

Сәлим. Аның алдында, әнисе алдында гаебем зур. Сөйләргә мөмкин, ләкин акланырга мөмкин түгел.

Сәлим белән Камилә кухняга уза. Тышта яңгыр. Рәхилә тагын кулына мандолина ала, тагын шул таныш вальс моңы салмак кына тирбәлә. Ишектә Тәлгать күренә, кулында китап, ул да музыканы тыңлый.

Рәхилә *(үзе уйный, үзе сөйли).* Бүген клубта «Отелло» буласы иде, синең белән барырмын дигән идем. Ни өчен диген? Отелло кебек ярата белергә өйрәнмәссең микән, дим.

Тәлгать. Беләсеңме?

Рәхилә *(уйнавыннан туктапып)*. Беләм.

Тәлгать. Белсәң әйтеп кара, нәрсә дим?

Рәхилә. Китап укыган булып икәү бергә утырыйк әле дисең.

Тәлгать. Һе, әйдә, утырыйк. *(Янына утыра.)* Беләсеңме, мин ни әйтергә телим...

Рәхилә. Беләм.

Тәлгать *(карап тора)*. Беләсең? Йә, әйт.

Рәхилә. Кочагымарак кереп утыр, дип әйтергә телисең.

Тәлгать. Һем... Әйдә, кил, утыр.

Рәхилә. Телисең икән, пожалуйста, миңа барыбер. *(Тәлгатькә сыенып утыра.)*

Тәлгать. Беләсеңме мин ни телим...

Рәхилә. Беләм.

Тәлгать *(туктапып кала)*. Тагын беләсең? Нәрсә?

Рәхилә. Мине кочаклап алып үбәргә телисең.

Тәлгать. Үбәргә? Әйдә, булган икән булсын. *(Рәхиләне үбәргә җыена, ләкин тегесе тайпыла да, Тәлгатьнең борын төбендә үк бармак янап, җитез генә кузгалып китә.)*

Рәхилә. Тәлгать, мин синең көтүгә йөрүләреңне вакытлы шаяру гына, дип уйлый идем. Ә син, ахры, чыннан да шунда калырга җыенасың. Тәлгать, тирәнгә керәсең, ташла. Син бит директор булырлык кеше.

Тәлгать. Нигә, мин хәзер дә директор ич. Көтү директоры!

Рәхилә. Сиңа укырга кирәк, эшләргә кайчан да өлгерерсең, качмас.

Тәлгать. Рәхилә матур киенсен өчен, тәмле ашасын өчен кемнәр эшләргә тиеш соң?

Рәхилә *(ихлас күңелдән)*. Беләсеңме, Тәлгать, без бит юллар чатында торабыз. Кайсыннан китсәк, шул безнең гомер юлыбыз булачак.

Тәлгать. Мин эшләргә булдым. Миңа әнием васыять итеп әйтеп калдырды: улым, хезмәтне ярат, диде ул. Эш сөйсәң, бәхетле булырсың, диде.

Рәхилә. Тәлгать, киләчәгебез турында уйларга кирәк. Китик Казанга, керик укырга. Икәү бергә лекциягә йөрербез. Кичләребезне бергәләп уздырырбыз.

Тәлгать. Без биредә дә бергә була алабыз. Бергә эшкә йөрербез, бергәләп укырбыз.

Рәхилә *(кискен)*. Теләсә нәрсә диген, мин сине ул юлдан җибәрмим. Көтү көтәргә мин сиңа рөхсәт бирмим. Бел менә, бирмим.

Тәлгать *(Рәхиләгә карап торгач).* Аңламыйм мин сине.

Рәхилә. Аңламыйсыңдыр шул. Нишлим соң, тагын нинди сүзләр табыйм? Тәлгать... Синең әллә бөтенләй йөрәгең юкмы?! Син соң... *(Әйтеп бетерми.)* Әй, сиңа сөйләдең ни, сөйләмәдең ни. *(Өзгәләнеп.)* Кал шунда хайваннарың арасында. Кал, югал. Бер дә кызганмыйм, ичмасам.

Тәлгать. Мин кызгануга мохтаҗ түгел! *(Бүлмәгә кереп китмәкче була.)*

Рәхилә *(йөрәге белән әрнеп кычкыра).* Тәлгать!

Тәлгать туктала, борыла, Рәхилә янына килә, ике беләгеннән тотып күзләренә текәлә. Шулай алар бер-берсенә шактый гына карашып торалар.

Тәлгать. Юк, Рәхилә, мин сине түгел, син мине аңларга тиешсең! *(Чыгып китә.)*

Сәлим белән Камилә керә.

Сәлим. Рәхилә кызым нигә борчыла?

Рәхилә. Син борчылмаганга борчылам. Тәлгать китү китә, ә синең исең дә китми.

Камилә. Рәхилә дим, нишләвең синең?! Сәлим, Тәлгатьне укырга урнаштыру чарасын күрәбезме әллә? Бәлки, Госман ярдәм итәр, аның шәһәрдә танышлары бер кетү. Абыйсы институтта укыта ич.

Сәлим *(тузынып китә).* Син нәрсә? Телең нәрсә сөйләгәнне колагың ишетми! *(Шунда ук сүрелә.)* Ах, Тәлгать, Тәлгать... Әйдә, сөйләшсәң сөйләш инде.

Ишектә Госман. Аны күргәч, Сәлим урыныннан ук кузгала, әмма Камилә сиздермичә генә аны итәгеннән тотып кала.

Госман. Сәлам бирдек! Сәлим Гәрәевич, Камилә Шакировна, мин сезне аңламыйм. Ишеткәч тә, үз колакларыма үзем ышанмадым. Рәхиләне фермага сыер саварга йөртәсез, диләр бит.

Сәлим. Йөрсә, укасы коелмастыр дип беләм.

Госман. Шушындый вакыттамы? Институтка әзерләнә торган вакытта?! Белмим, сезгә нәрсәм килешми торгандыр инде. Дөресен әйтим, минем өстән ронога язган язуыгызны укыдым. Сез анда сүзгә саранлык күрсәтмәгәнсез.

Сәлим. Әйе, яздым. Бурычым шулай кушты. Хезмәтне яратмый, укучыларны хезмәт белән тәрбияләргә игътибар итми, дип яздым. Нигә, шулай түгелмени?! Бу хакта бер генә мәртәбә әйтелмәде бит инде. Педсовет утырышында да күп

сөйләнде. Сез үзегез хезмәтне кара эш дип исәплисез. Сез аңа чирканып карыйсыз.

Госман. Бу турыда минем үз карашым бар... Ә мин җитди мәсьәлә турында сөйләшергә кергән идем. Мин сездән Рәхиләнең кулын сорарга килдем. Әгәр дә каршы булмасагыз...

Камилә. Ай, Ходаем икән, нишләп каршы булыйк ди. Атасы дим, Госманның эшендә җитешсезлекләр бар икән, төзәлер әле. Шулай бит, Госман?

Госман. Без инде Рәхилә белән күптәннән вәгъдәләшкән идек.

Сәлим. Белмим, мин сезнең үзегездән башка кешене ярата алуыгызга ышанмыйм. *(Кереп китә.)*

Камилә. Сез борчыла күрмәгез инде, җайланыр. Аның бүген кәефсез чагы. Әле үзе дә сезнең белән сөйләшергә дигән иде. Тәлгатьне институтка урнаштыру өчен ярдәм итмәс микән, дигән иде.

Госман. Сәлим Гәрәевич үзе үтенәме? Миннән? Чит кеше өчен?

Камилә. Нишләп чит булсын. Тәлгать аның малае ич.

Госман. Шулаймыни? Димәк... Әһә! Сәлим Гәрәевичнең үтенеченә килгәндә... булдырабыз аны. Татулык хакына. Тик менә... Сәлим Гәрәевич ронога язган язуын алса икән.

Рәхилә керә. Башкалар киенеп кинога китә.

Госман. Рәхилә, мин синең соңгы сүзеңне ишетергә телим. Тотабыз да иртәгә авыл Советына барып язылышабыз. Йә иртәгә, йә беркайчан да!

Рәхилә. Ай, башым әйләнеп китте. *(Урындыкка утыра.)*

Госман. Йә, булдымы, килештекме? Аңла син мине, Рәхилә. Отпуск вакытым, ә мин ялга да китмәдем. Кем өчен дисең? Инде син мине кире кагасың икән, мин китәргә мәҗбүр булачакмын.

Тәлгать кухнядан чыга, бүлмәсенә үтмәкче була. Ләкин ирексездән туктала.

Госман. Әти-әниең ике куллап риза, синең сүзеңне көтәләр. Йә, язылышабызмы?

Рәхилә. Иртәгә үк?

Госман. Алтыным минем, гәүһәрем! Вәгъдәләшү хакына! *(Госман Рәхиләне кочагына алып үпмәкче була, Рәхилә карыша.)* Ярый, ярый, күпне көткәнне иртәгә кадәр генә көтәрмен. *(Тәлгатьне күреп.)* Тыңлап торасыз?! Егет кеше эше түгел.

Тәлгать. Мин укыган романнарда бакчада вәгъдәләшәләр иде. Сандугачлар гына ишетсен дип. *(Үз бүлмәсенә кереп китә.)*

Госман тагын Рәхиләне кочагына алмакчы була, ләкин шул чакта Тәлгать бүлмәдән чыга. Кулында чемодан.

Рәхилә. Тәлгать, син кая болай? Ни булды? Төнгә каршы... *(Тәлгать каршына төшә.)* Җибәрмим. Әйт, кая барасың?

Тәлгать *(Рәхиләгә)*. Кирәк икән, мин сөйли алам. Ләкин үзеңә генә.

Госман. Иртәгә кадәр. *(Госман икеләнеп торганнан соң, чыгып китә.)*

Тәлгать. Тик бер шарт: мин сөйләгәндә дә, сөйләп бетергәч тә, миңа бер сүз дә дәшмисең. Ризамы?

Рәхилә. Йә, риза.

Тәлгать. Әгәр шарт куймасаң, синең әллә ни уйлавың бар. Арага керә, ялынып йөри дип әйтер идең, ә ахырдан көләр идең. Шарт куешкач, син алай уйлый алмассың... Әллә ничек кенә булды, үзем дә сизми калдым, мин сине кинәттән яраттым. Беренче күрүдә үк! Синең янында булу минем өчен иң татлы бәхеткә әверелде. Дөнья тагын да матурланып китте. Моннан китәргә тиеш булсам да, мин синнән аерылып китә алмадым. Мин ышанган идем, син дә мине сөярсең, без бергә булырбыз дип өметләнгән идем. Ә син башканы сөясең икән, аның белән вәгъдәләштең. Мин сиңа үпкәләмим. Мин синең бәхетле булуыңны, бары тик бәхетле булуыңны гына телим. *(Кулына чемоданын ала, чыгып китә. Рәхилә бер урында басып кала. Үзе генә ишетерлек итеп «Тәлгать» исемен кабатлый.)*

Пәрдә.

Өченче пәрдә

Елга буе. Болынлык, камышлык. Ферманың җәйге утары урнашкан җир. Уң якта, яр буенда таган асылган. Бер чиләктә аш пешә, икенчесендә чәй кайный. Таган янында күчмә өстәл. Бераз түрдәрәк елга ягына авышып үскән кәкре каен. Әпсәләмнең иңендә гармун. Яңа марш уйный. Үзе уйный, үзе таган тирәсендә йөренә. Бидон күтәреп Нурсәнә белән Рәхилә керә.

Нурсәнә. Бу аш бик тәмле булыр инде: гармун уйнап кына пешерәсең.

Әпсәләм. Ите азрак, шуңа тырышам.

Рәхилә. Бүген мин дә төш күрдем. Ялтыравыклы туфлиемне киим дисәм, олтаны тузган, имеш. Чыгарып ыргыттым. Аның өсте ялтыравыклы булуыннан ни файда, олтаны яраклы булмагач.

Әпсәләм. Әһә. Туфлиеңне чыгарып ташлавың — киявеңне ташлавың ул.

Нурсәнә. Син юрарсың инде.

Әлсерәп-тирләп **Камилә**, аның артыннан **Госман** керә. Камилә кулында сумка.

Рәхилә. Әни, нишләп йөрисез?

Камилә. Сезнең арттан килдек — качкыннар артыннан.

Рәхилә. Әти килмәдемени?

Камилә. Куып җитәрмен дигән иде.

Госман. Мин синнән, Рәхилә, мондый вәгъдәсезлекне көтмәгән идем. Укырга кергәнче ял итәргә кирәк. Ә син бирелә...

Рәхилә. Мин биредә ял итәм. Бәлки, миңа бу эш ошыйдыр. Сез бит: «Монда эшләргә ярамый, ярамый» — дип, гел тукып килдегез. Тукта әле, мин әйтәм, ярамый торган эш ничек була икән, дим. Сынап карарга булдым. Баксаң-күрсәң, күңелне үстерә торган хезмәт икән.

Госман. Ни сөйләгәнеңне үзең аңлыйсыңмы син?!

Сәхнә артыннан сыер куган, чыбыркы шартлаткан тавышлар ишетелә башлый.

Рәхилә *(еррактан күреп)*. Тәлгать көтүне елгага алып төште. Нурсәнә, табынны әзерләргә кирәк.

Нурсәнә белән Әпсәләм өстәлне күчерә.

Нурсәнә *(эш арасында)*. Рәхилә, теләсәң ни әйт, миңа синең ялтыравыклы туфлиең бер дә ошамый. Олтаны тотрыксыз. Чыгарырга да ташларга гына.

Әпсәләм *(ул да эш арасында)*. Хәзер ялтыравыклы туфлинең модасы чыкты инде.

Сәлим килеп керә.

Сәлим. Менә килеп тә җиттем. Һа, кара бу хозурлыкны! Болын дисеңме, елга дисеңме!

Әпсәләм *(кулы белән кәкре каенга күрсәтә, ә аңа Госман сөялгән)*. Кәкре каен үзе генә дә ни тора?

Камилә, Нурсәнә, Сәлим елга буена төшеп, **Әпсәләм** өйгә кереп китә. Госман белән Рәхилә генә кала.

Г о с м а н. Рәхилә, күгәрченем, кичә биргән вәгъдәңне онытмагансың дип беләм. Хәзер авылга кайтабыз да язылышабыз!

Р ә х и л ә *(газапланып)*. Госман абый, зинһар, аңлагыз инде.

Г о с м а н. Яратмыйсың?! Син мине яратмыйсың. Әйе, әйе, мин сизеп килдем моны.

Р ә х и л ә. Алай булгач, нигә соң яратмаган кешегә кияүгә чыгарга кыстыйсыз? Мин сезне аңлый алмыйм, Госман абый.

Г о с м а н. Синең кемне яратканыңны да беләм мин. Сизми дисеңме әллә? Көтүчене! Ләкин бик каты ялгышасың. Син бервакытта да, беләсеңме, бервакытта да аның белән була алмаячаксың!

Р ә х и л ә *(сагая)*. Әйтеп бетерегез.

Г о с м а н. Әйтәм, башта син каенга сөял. Югыйсә егылып китәрсең. *(Рәхилә үзе дә сизмәстән каенга сөялә.)* Тәлгать — синең абыең! Бертуган абыең! Менә кем ул сиңа! *(Рәхилә коелып төшә, телсез кала.)* Йә, ник дәшмисең?! Ә син үзең уйлап кара, ни өчен килде ул сезгә?

Р ә х и л ә *(уйлана)*. Әйе, әйе... мөмкин... бик мөмкин... аһ! *(Каенга каплана.)*

Г о с м а н. Ярар, борчылма. Киләчәгеңне абыең белән бәйли алмыйсың бит инде. Шулай булгач, икеләнеп торасы да юк. Әйдә, киттек!

Р ә х и л ә. Юк! Миңа бигрәк тә хәзер фермада калу кирәк. Эш кирәк миңа, эш. Онытылырга! Фәкать эш белән генә онытылырга мөмкин. Госман абый, менә шул: канатларым каерылгач, ярдәмегезне тәкъдим итәрсез, яме? Әлегә бит канатларым каерылмаган. Ә бәлки, каерылмас та!

Р ә х и л ә тиз генә китеп бара. Елга буеннан Н у р с ә н ә күтәрелә, өйдән Ә п с ә л ә м чыга.

Ә п с ә л ә м. Госман абый, кыз капризланып тордымы урлыйлар да китәләр. Әйдә, булмаса, үзем булышам.

Н у р с ә н ә. Әгәр, Госман абый, көтүче булып карасагыз? Рәхилә көтүчеләрне ярата бит.

Г о с м а н. Ә?! *(Ачуыннан буылып чыгып китә. Әпсәләм белән Нурсәнә көлешеп калалар.)*

Н у р с ә н ә *(Рәхиләне күреп ала)*. Рәхилә, сиңа ни булды?

Р ә х и л ә *(яшь аралаш)*. Ул миңа абый. Бертуган абый. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Т ә л г а т ь күренә. Иңендә чыбыркы. Кружканы тотырып су алып эчә. Икенче яктан Р ә х и л ә керә.

Т ә л г а т ь. Рәхилә, сиңа ни булды? Кем, кем сине рәнҗетте? *(Рәхилә яшь тулы күзләре белән Тәлгатькә күтәрелеп карый, әмма дәшми.)* Кадерлем, сөеклем минем!..

Р ә х и л ә *(калтыранып китә).* Әйтмә, әйтмә, кирәкми.

Су буеннан башкалар күтәрелә. Сәлимнең кулында талчыбык-таяк.

К а м и л ә *(сөртенә-сөртенә килә).* Һай, су буеның рәхәтлеге. Сулу алып җибәрдем.

С ә л и м. Ә, Тәлгать!..

Т ә л г а т ь. Исәнмесез.

С ә л и м. Ә шулай да, Тәлгать, бәлки әйтерсең, безнең өйдә нәрсә килешмәде сиңа?

Ә п с ә л ә м. Ягез әле, утырышыйк. Болынымның ямен, ашларымның тәмен, суларымның шифалыгын татып китегез.

Өстәл тирәли утыралар. **Г о с м а н** керә.

Ә п с ә л ә м. Әйдәгез, Госман абый, табынга рәхим итегез.

Г о с м а н. Минем эчәсем генә килә. *(Камилә янына килә.)* Камилә Шакировна, сез Сәлим Гәрәевич белән сөйләштегезме?

С ә л и м. Сез ни турында?

К а м и л ә. Теге ронога язган язуыңны кире алырга уйласаң, җаен табарга була икән.

С ә л и м *(үзгәреп китә, Госманга).* Сез нинди махинация корасыз?

Г о с м а н. Әгәр дә сезгә минем ярдәмем кирәк икән, минем өстән язган язуыгызны үз кулыгыз белән ертып ташларга тиешсез.

С ә л и м. Әгәр мин теләмәсәм?

Г о с м а н. Анысы сезнең эш. Әгәр сезне Тәлгатьнең язмышы борчымый икән, әгәр сез аның шушында югалып калуын күтәрә аласыз икән, ул чагында... чамалагыз... *(Борылып китәргә уйлый, каршында Тәлгать басып тора.)*

Т ә л г а т ь. Нәрсә дидегез? *(Кычкыра.)* Туктагыз! Сез нәрсә, һаман да Тәлгать белән авыз чайкыйсыз?! Тәлгать көтү көтә, югалып кала, имеш. Сезнең анда ни эшегез бар?! Ә бәлки, ул шатланып, горурланып эшли торгандыр. Бәлки, аның үзенең хыяллары, планнары бардыр?! Беләсегез килсә, Тәлгать быел институтка заочно укырга керәчәк!

Г о с м а н. Син ни дип миңа ташландың әле? *(Сәлимгә күрсәтә.)* Әнә кемгә ташлан. Сине урнаштыруны сорап ул бит миннән үтенде. Әтиең!

Т ә л г а т ь *(тынып кала. Госман әйткән сүзнең мәгънәсен аңларга тырыша).* Әти?.. Сез?..

К а м и л ә. Әйе, Тәлгать, ул синең әтиең.

С ә л и м. Тәлгать... улым...

Т ә л г а т ь *(кисәк читкә борыла).* Ә!.. Әнкәй, әнкәй! Сине кабергә илтеп тыгучы кеше менә кем икән, әнкәй бәгърем! *(Тәлгать ниндидер кискен карарга килә: Сәлимнең яңагына сугарга ниятләнеп, алга атлый. Сәлим яңагын яшерми. Тәлгать шулай да кулын күтәрә алмый. Эчке өзгәләнү белән.)* Бар да бер: яңагыма сукты дип исәпләгез. *(Тәлгать өй читендәге кадакка элеп куйган костюмы янына китә.)*

Р ә х и л ә. Тәлгать, акылыңа кил.

Тәлгать туктала. Авыр тынлык.

Г о с м а н. Так, Сәлим Гәрәевич, менә сез нинди кеше икәнсез. Үз баласын язмыш хөкеменә ташлаучы! Үзегез шундый җинаятьче була торып, ничек соң сезнең минем өстән язарга кулыгыз күтәрелде?! Аңладым мин сезне! Әйе, без бергә эшли алмыйбыз. Или мин, или сез!

Ә п с ә л ә м *(үзалдына).* Ай, уч төбем кычыта. Чыдар хәл калмады.

Г о с м а н. Сәлим Гәрәевич, онытмагансыздыр дип беләм...

С ә л и м. Нәрсәне?

Г о с м а н. Малаегызны институтка арт ишектән кертүне сорап, миңа мөрәҗәгать итүегезне.

С ә л и м. Ышаныгыз. Менә шаһитлар алдында әйтәм: булды шундый җинаятем. Кирәк икән, ронога да әйтермен.

Г о с м а н. Анысы кирәк булмастыр. Ронога болай да билгеле булыр! Үз баласын тәрбияләмәгән кеше укытучы булып эшли алмый. Андый кешенең класска түгел, мәктәп бусагасыннан атлап керергә дә хакы юк! Әйе, әйе, хакы юк!

С ә л и м *(Госманга).* Сез мине авырлык китерү белән куркытырга уйламагыз. Иң авыры аның менә монда. *(Күкрәген күрсәтә.)* Вөҗдан газабы аның авыры.

Г о с м а н. Нигә дип сез моңа кадәр дәшми килдегез? Яшереп калырга уйладыгызмы?

К а м и л ә *(Госманга).* Абау, нинди усал кеше икәнсез!

Г о с м а н. Сезнең бу эшегез менә нәрсәгә китереп җиткерде: малаегыз белән кызыгыз... Сезнең аркада бертуган балаларыгыз — абыйлы-сеңелле — бер-берсенә гашыйк булдылар.

Рәхилә Нурсәнәнең күкрәгенә каплана.

Камилә. Ничек?

Сәлим. Сез нәрсә сөйлисез?

Рәхилә. Ай... *(Йөгереп чыгып китә.)*

Сәлим *(кычкырып).* Рәхилә! Дөрес түгел бу!

Камилә. Әйе, әйе, дөрес түгел! Рәхилә, дим, Рәхилә! *(Госманга.)* Сез дөрес сөйләмисез, башта белергә кирәк, ә сез... Белмисез икән, белегез. Рәхилә безнең — балалар йортыннан тәрбиягә алып үстергән кызыбыз. *(Нурсәнә белән Әпсәләм катып кала.)* Ай, кайда соң ул? Рәхилә, Рәхилә, дим. Нурсәнә җаным, бар йөгер, артыннан йөгер!

Нурсәнә *(айнып).* Рәхилә... *(Чыгып китә.)*

Госман. Әһә, монысын да яшереп килдегез? Кеше язмышы белән шулай уйныйлармы? Бу нинди моральгә сыя?!

Әпсәләм. Булмады инде бу, әйткәнне аңламадыгыз, ахры. Карале, китәсезме, юкмы? *(Өстенә бара.)* Юкса!

Госман. Без әле очрашырбыз!

Госман китә. Тау артыннан Рәхилә килә. Аның артыннан Нурсәнә килә.

Рәхилә. Мин... ятим баламы?

Камилә. Рәхилә, кичер безне. Тәрбиягә алып үстергән бала икәнлегеңне без синең үзеңә белгертмичә килдек. Ятимлекне сизмәсен дип. Хәтта авыл халкы сиңа белгертмәсен дип, элекке районнан күчеп үк киттек. Буйга үсеп җиткәч әйтербез дигән идек тә, үсеп җиткәнеңне сизми дә калганбыз. Юк, бередә әтиең гаепле түгел, мин... Минем сине үз балам итәсем килде.

Рәхилә *(күзендә яшь).* Мин... мин ятим баламы? Минем үз әнием юкмыни? Минем әтием — миңа эти түгелмени?

Камилә. Минем сине ачуланган чакларым да булгандыр инде, рәнҗи күрмә, Рәхилә.

Рәхилә. Ни сөйлисең син! Юк, юк, ишетергә дә теләмим. Син минем үз әнием! *(Янына килә.)* Әни!..

Камилә. Рәхилә, кызым, үз кызым! *(Тынлык. Алар янына Сәлим якыная. Камиләнең күзендә яшь бөртекләре.)*

Рәхилә *(Сәлимгә).* Син әтием түгел дип мине кем ышандыра алыр? Беркем дә, бервакытта да! Сез миңа тырнак белән дә чиртмәдегез, кадерләп, иркәләп кенә үстердегез. Сез — минем үз әтием, үз әнием!

Рәхилә әтисе һәм әнисенең кочакларына сыена. Тәлгать чыбыркысы янына китә.

Сәлим. Тәлгать, син кая болай? *(Тәлгать туктала, Сәлим аның янына килә. Тәлгать дәшми.)* Син нишләмәк буласың? Ярамый! *(Тәлгать Сәлимнең күзләренә карый. Әмма бер сүз дә дәшми.)* Ах, кичерә алсаң иде син мине. Беләм, мин гаепле, бик гаепле. Менә бит... Яраттым бит мин сине, улым!

Тәлгать. Бәлки, мин дә сезне ошатканмындыр, тик...

Камилә. Ялгышасың бит, Тәлгать, уйлап кара: Рәхилә булып Рәхилә, Сәлимнең үз баласы булмаса да, «әти» ди, ә син...

Тәлгать. Үз гомеремдә минем дә «әти» дип әйтәсе килгән чакларым күп булгандыр. Иптәш малайларым аталарының кулларына тотынып-җитәкләшеп узганда, «Эх, минем дә әтием булса иде!» — дип калган вакытларым аз булмады.

Сәлим *(үзалдына әйткәндәй).* Бала...

Тәлгать. Әни миңа сезнең исемегезне дә әйтмәде. Димәк, ул сезгә нык рәнҗегән. Сез бит аны авырлы хәлендә ташлап киткәнсез, аның бөтен тормышын җимергәнсез. Сез үзегез турында гына кайгырткансыз. Малаегызның язмышы да сезне кызыксындырмаган. Юк, мин сезне «әти» дип атый алмыйм.

Рәхилә. Тәлгать!

Тәлгать. Ышанычыгызны аклый алмадым. Йөкләмәгезне үтәү өчен миннән башка гына көрәшерсез инде. Мин монда кала алмыйм, китәм.

Рәхилә. Җибәрмим, беркая да җибәрмим! Үзем дә китмим, сине дә җибәрмим! Киләчәгемне мин беренче мәртәбә шулай ачык күрәм. Син ачтың аны. Ул мине үзенә дәшә. Мин аңа икеләнмичә, тайпылмыйча, ашкынып барам. Синең белән бергә, җитәкләшеп барам! Син минем бөтен тормышымны әйләндереп ташладың. Тормышның бу кадәр матур икәнлеген белми идем әле мин. Әнә шул камышларны да, менә бу кәкре каенны да, әнә андагы көтүеңне дә — барысын да, барысын да яратам. Ишетәсеңме, яратам! Беренче мәртәбә!

Урманнан кайтучы яшьләр хоры ишетелә башлый.

Пәрдә.

1960 ел

«Беренче мәхәббәт» пьесасында хаксызлыкка ярашу темасы

Гамил Афзал үзенең шигырьләрендә хаксызлыкка ярашу темасын күтәрә, аны кабатлавы белән заманга хас күренеш дип исбат итә, дидек. Бу тема башка әдипләрдә дә күтәреләме?

Шулай булса, без аны 50—70 нче еллар әдәбиятының эчтәлегенә кергән темаларның берсе дип әйтә алачакбыз.

«Беренче мәхәббәт» пьесасын шул максатны күздә тотып өйрәник.

Пьесаларда тема конфликтларны өйрәнеп табыла. Төп конфликт дип Сәлимнең вөҗдан газабы кичерүен әйтә алабыз. Нәкъ менә Сәлим ялгышы Тәлгать кичерешләрен дә, Камилә борчылуларын да, Рәхилә хәсрәтен дә тудыра.

Үзәк конфликтны Сәлимнең яшьлегендәге ялгышуы һәм үкенече, ә Тәлгать белән очрашкач, газабы тудыра, дия алабыз. Әмма автор конфликтын тирәнәйтә, кискенләштерә. Сәлимнең иң зур хәсрәте — хатасын танып үкенүдә түгел, үзенең хаксызлыгын белеп тә, гомере буена шуны кабатлап, шул хаксызлыгы белән ярашып-килешеп яшәвен аңлавында. Сәлим гомере буена борчыла, үкенә, әмма үзенең баласы һәм аның анасы язмышы белән бөтенләй диярлек кызыксынмый. Үз җаен җайлап яши бирә.

Биремнәр һәм сораулар

1. Пьесадагы Сәлимнән башка персонажларның хаксызлыкка ярашу темасына кагышлы холыкларын әйтеп чыгыгыз.

2. Әпсәләм белән Нурсәнәнең тышкы конфликтлары да, эчке конфликтлары да юк. Алар үз-үзләреннән дә, тормыштан да канәгать. Икесе дә бәхетлеләр: уйнап-көлеп, шатланып яшиләр. Әсәрдәге төп теманы күз алдында тотып, бу ике персонажга нинди бәя бирер идегез? Аларга автор нинди бәя биргән?

3. Госман — Әпсәләм белән Нурсәнәнең киресе. Госманга да шундый ук бәя бирегез.

4. Сәлим яшьлектә эшләгән хатасыннан башын кая куярга белми йөри, үзе шул ук вакытта тагын бер хата ясый: Тәлгатьне институтка арткы ишектән генә кертмәкче була. Сәлимнең бу эшенә бәя бирегез.

5. Камилә беренче пәрдәдә Тәлгатьне үз өйләрендә калдыруга башы-аягы белән каршы тора, әмма бер минут та үтми, кинәт калырга кыстый башлый. Нигә шулай итә?

6. Рәхилә дә үз-үзенә каршы килә: үзе Тәлгатькә авылдан китәргә, ак эшкә күчәргә куша, үзе шундый ук «кара» эштә авылда калуны хуп күрә. Рәхиләнең мондый карарына бәя бирегез.

7. Пьесаның сюжеты чишелмәгән конфликтлар белән тәмамланды: чишелмәгән конфликтларны табыгыз. Шуларны дәвам итеп, сюжетны үзегезчә тәмамлагыз.



Туфан Миңнуллин
(1935 елда туган)

Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 елның 25 августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Олы Кариле һәм Кама Тамагы сельполарында хисапчы булып эшли. Казанда бухгалтерлар әзерләү курсын тәмамлый. Чирәм җирләргә үз теләге белән китеп, Кустанай өлкәсендәге бер совхозда баш бухгалтер булып эшли. 1956—1961 елларда Туфан Миңнуллин Мәскәүнең М. С. Щепкин исемендәге Театр училищесында укый. Минзәлә театрында актер булып эшли. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында да берничә ел артист хезмәтен башкара. Шул ук вакытта драматург буларак та таныла башлый. 1964 елда театрдан китә.

Шуннан соң Туфан Миңнуллин телестудиядә һәм «Чаян» журналында эшләп ала. Әмма театрга булган мәхәббәте җиңә — драмалар язу белән генә шөгыльләнергә керешә.

Туфан Миңнуллин Татарстан Язучылар берлегенең рәисе итеп сайлана. СССР парламентының депутаты булып тора.

Кайда гына эшләмәсен, ни генә язмасын, Туфан Миңнуллин үзе булып кала алды. Аның һәрвакыт үз фикере булыр. Үз фикерен ул берәүдән дә яшермәс, теләсә кайсы җыелышта, мәкаләсендә, үзара сөйләшкәндә дусларына турыдан-туры әйтеп салыр.

Җитди театрларның үз драматурглары булырга тиеш. Заманында театрны Кәрим Тинчурин тотты. Берара халык Нәкый Исәнбәт театрына йөрде. Аннары — Хәй Вахит. Соңгы елларда театрның төп драматургы — Туфан Миңнуллин. 1962 елда язылган «Безнең авыл кешеләре» пьесасыннан соң әдип «Азат», «Күрше кызы», «Миләүшәнең туган көне», «Нигез

ташлары», «Йөрәк янар өчен бирелгән» пьесаларын сәхнәгә менгерә. «Диләфрүзгә дүрт кияү» комедиясе белән татар җәмәгатьчелеген нык кына көлдереп алганнан соң, «Ир-егетләр», «Канкай угылы Бәхтияр», безгә таныш «Әлдермештән Әлмәндәр», «Адәм баласына ял кирәк», «Моңлы бер җыр», «Монда тудык, монда үстек», «Әниләр һәм бәбиләр» һ. б. күп санлы пьесалар, повестьлар, хикәяләр иҗат итте.

ДУСЛАР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

(2 кисәк, 5 күренешле драматик новелла)

КАТНАШАЛАР:

Нурислам — рәссам, буйдак.
Миләүшә — артистка, тол хатын.
Рәфис — элек шигырь язган, хәзер әдәбият галиме.
Сәҗидә — Рәфиснең хатыны.
Фәһим — композитор.
Эльмира — Фәһимнең хатыны.
Гайнулла — химик, фәннәр кандидаты.
Галия — Гайнулланың хатыны.
Рөстәм — Рәфис белән Сәҗидәнең малае.
Гөлфия — Гайнулла белән Галиянең кызы.

Беренче кисәк

I күренеш

Нурисламның ике бүлмәле фатиры. Балконы да бар. Катнашучыларның Рөстәм белән Гөлфиядән башкалары барысы да сәхнәдә. Алар һәрвакыт шулай: бәйрәмнәрне, туган көн мәҗлесләрен бергәләп уздыралар. Болар җан дуслар — үз сүзләре, үз җырлары, үз серләре, үз эчемлекләре. Барысы да үз тормышларыннан, эшләреннән үзләре канәгатьләр шикелле. Ирләрнең яше 40 белән 45 арасында, хатыннар, әлбәттә, өч-дүрт яшькә яшьрәк. Бүгенге җыелуның сәбәбе: Нурислам яңа картина язып тәгалләгән — шуны карарга килгәннәр. Пәрдә ачылганда ул картина сәхнә алдында тора. Катнашучылар, төрлесе төрле җиргә урнашып, шул картинага төбәлгәннәр.

Рәфис *(ниһаять, сүзен башлап)*. Булган бу. Зур күргәзмә залының түренә элеп куясы гына бар. Һәм берәр премия дә эләктерәчәксең, Нурислам. Кил, кулыңны кысарга рөхсәт ит. *(Нурисламның кулын кыса.)* Ни өчендер мин синең йөзеңдә шатлык күрмим, дус кеше.

Нурислам. Башкаларыгыз ни әйтер бит әле?

Фәһим. Чираттагы уңышың белән котлыйм, Нурислам.

Гайнулла. Эх, егетләр!.. Шәп бит, ә?!

Нурислам. Нәрсәсе шәп, Гайнулла?

Гайнулла. Факт буларак шәп. Син шундый нәрсә иҗат иткәнсең. Белер-белмәс фикер әйтеп сезне көлдерергә җыенмыйм. Мин химик кына.

Миләүшә. Аны бит күргәзмәдә химиклар да караячак, Гайнулла.

Гайнулла. Карасыннар, соклансыннар. Ә мин алар сокланганга сокланам. Чөнки алар минем дустым картинасын күреп сокланачаклар. *(Галиягә.)* Шәп бит, ә, Галия?

Галия. Син әйткәч, шәп булмый нишләсен.

Нурислам. Сезнең фикерегез ничек, Эльмира ханым?

Эльмира. Фикеремне әйтмәскә мөмкинме? Ничә айлар эшләгән хезмәтеңне бер карауда бәяләү уңайсыз. *(Ул арада Нурислам картинаны бер читкә алып куя, өстәлгә ике-өч шешә шампан һәм бокаллар чыгарып утырта.)*

Рәфис *(шешәне ачып, бокалларга шампан сала)*. Йәгез, тоттык, күтәрдек. Нурисламның бу һәм киләчәктәге уңышлары өчен. *(Күтәреп эчеп куялар.)*

Гайнулла *(тиктомалдан кычкырып җырлап җибәрә).*

Исә җилләр, исә җилләр,
Исә җилләр файдасыз;
Төнлә төшләремдә күрәм,
Көндез әллә кайда сез.

Барысы да кычкырып көләләр.

Рәфис. Гайнулланың үз репертуары.

Галия. Гайнуллага тимәгез, җырласын, өйдә мин аны биетермен.

Рәфис. Син Гайнулланы биеткән кебек берәү аюны биетсә, аю атказанган артист булыр иде.

Гайнулла *(тагы кычкырып җырлап җибәрә).*

Исәсе җил исәр инде,
Одеял ябынсам да;
Юк канатларым очарга,
Никадәр сагынсам да.

Эх, егетләр! Күңелле сезнең белән. Өйлән әле син, Нурислам, дөньясын тетрәтеп, туй ясыйк әле.

Нурислам. Кәтәм дә кәтәм, табып бирмисез бит хатын.

Гайнулла. Атаң башы!.. Менә Миләүшә. Миләүшә, чык әле Нурисламга кияүгә, җир җимертеп, туй ясыйк әле.

Миләүшә. Сөйләшергә сүзегез беттеме әллә?

Рәфис. Нурислам, кыста инде кунакларыңны, синең өең.

Эльмира. Берәрегез, ичмасам, матуррак тост әйтсәгез иде. Ничә ел һаман бер сүз: тоттык, күтәрдек... Исәнлеккә-саулыкка... Уңышларыбыз өчен...

Гайнулла. Ташлагыз әле... Тост, тост, ни пычагыма кирәк ул?

Рәфис. Туктагыз. Миңа, мәсәлән, бернинди яңа тост кирәкми. Матурлап-сырлап әйтелгән тост — ул үзенә күрә ярыш. Минем, мәсәлән, берегезне дә узасым килми. Аннан соң мин кемнең ни әйтәсен алдан ук белеп торам. Фәһим, мәсәлән, болай дип әйтәчәк: «Дуслар, бүген без бергә. Әйдәгез, бүгенге шатлыклы көн хөрмәтенә бокалларыбызны күтәрик».

Көлешәләр.

Фәһим. Ә үзең ничек?

Рәфис. Минме? Мин... Әй, беткән баш беткән, элеп куйыйк — кибә торсын. Дөресме?

Тавышлар. Дөрес.

Гайнулла. Ә мин ничек, мин?

Рәфис *(Гайнулла булып)*. Эх, егетләр! Белмисез, ат урлауның тәмен, ләззәтен белмисез, тишек борыннар. *(Җырлап җибәрә.)*

Көлешәләр.

Эльмира. Нурислам ничегрәк әйтер иде?

Нурислам. Рөхсәтегез булса, үзем өчен үзем әйтим әле, егетләр. Аны Рәфис белми, дип уйлыйм, бүтәннәр дә белмидер, ихтимал. Мин аны бер авыл агаеннан ишеттем. Утырыгыз, тыңлагыз, шактый озын ул. Димәк, болай... Борын-борын заманда бер авылда бер бөкре егет яшәгән, ди. Бөкре булганына бик кимсенгән, ди, егет. Кызлар аны санга сукмыйлар икән. Көннәрдән бер көнне урманда йөргәндә егет ниндидер ят тавышлар ишеткән. Тавыш килгән якка киткән һәм бер урман аланына килеп чыккан. Ә аланда пәри туе икән. Аландагы меңләгән пәри тәгәри-тәгәри, сикерә-сикерә бииләр икән, ә үзләре: «Чәршәмбе, чәршәмбе»,— дип кычкыралар икән. Егет аптырашта калган. Ник дисәң, ул көнне чәршәмбе түгел икән, җомга икән. Нишләп әле җомга көнне чәршәмбе дип

кычкыралар бу пәриләр, дип, егет: «Бүген чәршәмбе түгел, җомга!» — дип кычкырып пәриләрне төзәтергә теләгән. Ләкин уеннан кире кайткан. Меңләгән пәри чәршәмбе дип кычкырганда, берүзем җомга дип кычкыру килешмәс, дип уйлаган. Һәм шунда, үзе дә сизмәстән, пәриләргә кушылып: «Чәршәмбе, чәршәмбе»,— дип кычкыра башлаган. Егет янына туй атасы — карт пәри килгән: «Ни өчен чәршәмбе дип кычкырдың, бүген бит җомга көн»,—дигән. «Меңләгән пәри чәршәмбе дип кычкырганда, берүзем җомга дип әйтергә базмадым»,— дигән егет. «Инде алай икән, бездән сиңа ни кирәк?» — дип сораган пәри. «Бөтен нәрсәм җитеш. Хәтта артыгы да бар, шуннан котыла алмыйм»,— дип, егет бөкресен күрсәткән. Карт пәри егетнең аркасыннан сыпырган икән — бөкредән җилләр искән, төп-төз егеткә әйләнгән.

Гайнулла. Эх! Уйлап чыгара бит халык!

Нурислам. Егет авылына кайткан. Күрше авылда тагын бер егет яши икән. Ул әлеге егет янына килгән. «Әйт әле, зинһар, ничек котылдың бөкреңнән?» — дип сораган. Төз егет ничек булганын сөйләмәгән. «Җомга көнне урмандагы фәлән урынга бар» — дип, пәриләр туй ясаган аланның адресын биргән. Җомга көнне киткән күрше авылның егете урманга, эзләп тапкан аланны. Пәриләр: «Чәршәмбе, чәршәмбе»,— дип кычкыралар икән. «И мескеннәр,— дип уйланган егет,— пәри дисәң пәриләр шул, бүген җомга көн икәнен дә белмиләр»,— дип, пәриләрне кызганган, һәм: «Бүген чәршәмбе түгел, җомга!» — дип кычкырган. Егет янына теге карт пәри килгән. «Ни өчен меңләгән пәри коллектив белән чәршәмбе дип кычкырганда берүзең җомга дип кычкырасың?» — дигән. «Дөресе шулай, бүген җомга бит»,— дигән егет. «Дөресе шулаймыни? Бүген җомгамыни? Сиңа бездән ни кирәк соң?» — дип сораган. «Зинһар өчен, менә шуңардан коткарыгыз»,— дип, егет бөкресен күрсәткән. Карт пәри егетнең аркасыннан сыпырган икән — егетнең бер бөкресе янына икенче бөкре үсеп чыккан.

Фәһим. Шуннан?

Нурислам. Шуннан шул. Шундый хәл булган, ди, борынборын заманда.

Рәфис. Борын-борын заманда икәне аңлашылды. Мәгънәсе ни?

Гайнулла. Эх, егетләр! Шәп бит бу! Мондый әкиятне авылда гына уйлап чыгаралар.

Фәһим. Сабыр ит, Гайнулла... Әкиятме бу, Нурислам, әллә тостмы?

Нурислам. Тост.

Фәһим. Нәрсә өчен эчәбез инде, алайса, әйтеп бетер.

Нурислам. Мин белмим. Өзеп әйтә алмыйм. Әкият миңа ошаган иде, шуңа күрә сөйләдем.

Фәһим. Юк, Нурислам, син бушка сөйли торган кеше түгел. Сине без егерме ел беләбез.

Эльмира. Бу бокалны — курыкмыйча дөреслекне әйткән егет өчен күтәрәм.

Миләүшә. Ә курку-курыкмауның монда ни катнашы бар? Ул бит карт пәринең бөкре өстәячәген белми әйткән. Әгәр дә белгән булса?

Эльмира. Белгән булса да җомга дип кычкырыр иде. Дөреслек, хакыйкать аның күңелендә ята. Ул алдаша белми.

Галия. Алдашмыйм дип ике бөкре күтәреп йөрисем юк.

Нурислам. Әйдәгез, кайсы егет өчен эчкәнебезне бер-беребезгә әйтми генә эчәбез.

Гайнулла. Юк, мин кычкырып әйтеп эчәм. Меңләгән пәри чәршәмбе дип кычкырганда, җомга дип дөреслекне ярып салган егет өчен! *(Эчеп куя.)*

Эльмира. Мин дә. *(Авыз итеп куя.)*

Рәфис. Мин Нурисламның ни әйтергә теләгәнен аңламыйча, бокалны кулыма алмыйм.

Миләүшә. Ә мин алам. *(Авыз итеп куя.)*

Галия. Гайнулладан узып сүз әйтергә куркам мин. Гайнулла ни дисә, шул дөрес.

Рәфис. Тәк... Монысы булды. Сәҗидәкәй!..

Сәҗидә. Әйдә, кайтабыз. Барлы-юклы башымны әйләндермә.

Рәфис. Без өчәү калдык. Нурислам, әйтеп бетер тостыңны.

Нурислам. Мин әйттем. *(Эчеп куя.)*

Рәфис. Киттек, Сәҗидә.

Сәҗидә. Шушында килсәк, гел тәмсезләнеп таралабыз.

Нурислам. Туктагыз әле, нинди тәмсезләнү? Рәфис, сине үпкәләтерлек сүз әйтмәдем ич!

Рәфис. Син минем генә түгел, барыбызның да хәтерен калдырдың, Нурислам. Дуслар арасында киная булмаска тиеш. Килешмәгән эш эшләсәк, турыдан-туры йөзгә бәреп әйтергә мөмкин, киная белән сөйләшү — дошманнар эше.

Нурислам. Кызык кеше син, Рәфис...

Гайнулла. Эх, егетләр! Рәхәт сезнең белән!

Алай итү булмасын,
Болай итү булмасын,
Монда булган — монда калсын,
Гаеп итеш булмасын.

Фәһим *(кычкырып).* Тукта инде, Гайнулла. Ни җырың юк, ни моңың юк.

Пауза.

Гайнулла. Менә сиңа кирәк булса. Нигә соң аны әлегә хәтле әйтмәдең.

Фәһим. Монда җитди сүз бара. Ә син җүләр сатасың.

Гайнулла. Шулаймыни? Гафу итегез, алайса. Сау булып торыгыз алай булгач. *(Чыгып китә, аңа Галия иярә.)*

Нурислам. Туктале, Гайнулла... *(Алар артыннан чыга.)*

Саҗидә. Рәфис, син кайтасыңмы, юкмы?

Рәфис. Кайтам инде, кайтам. Эт эчәгесе булдың.

Саҗидә. Кем? Минме? Икенче тапкыр синең белән аягымны атлап чыксаммы? *(Кырт борылып чыгып китә, аның артыннан Рәфис иярә. Пауза.)*

Эльмира. Нурисламга бәйләнүегез миңа аңлашылмады, Фәһим. Гайнулланы рәнҗетүең ошамады.

Фәһим *(Нурислам кергәнне күреп).* Йә, ничек, Нурислам?

Нурислам. Киттеләр.

Фәһим. Без дә китәбез. Әкиятең белән ни әйтергә теләгәнеңне, бәлки, хәзер төшендерерсең?

Нурислам. Кабатлап әйтәм, мин ишеткәнемне генә сөйләдем.

Эльмира. Мин сине аңладым бугай, Нурислам.

Нурислам. Рәхмәт.

Фәһим. Йә Нурислам дус, сау булып тор. Картинаңны карарга килеп, әкият тыңлап китәбез.

Китәләр. Нурислам аларны озатып керә дә креслога утыра. Бүлмәнең икенче читендәге креслода Миләүшә.

Миләүшә. Дусларың үпкәләде. Башта үзеңне мактаттың да аннан үпкәләттең.

Нурислам. Юкка үпкәлиләр. Мин аларны үпкәләтер өчен сөйләмәдем.

Миләүшә. Ни өчен?

Нурислам. Уйландырыр өчен.

Миләүшә. Ни турында?

Нурислам. Ничек яшәвебез турында.

Миләүшә. Ничек яшибез соң без?

Нурислам. Белмим.

Миләүшә. Мин бүген монда кунам.

Нурислам. Әйдә, озатып куям.

Миләүшә. Типкәләп чыгарырга уйласаң, уеңнан кире кайт, караул кычкырачакмын.

Нурислам. Ни булды сиңа?

Миләүшә. Ә сиңа?! Сиңа ни булды? Кайда ул мине яраткан Нурислам?!! *(Кинәт елап җибәрә.)* Кума мине. Юатма, кыйна, аяк астына салып тапта. Бөкре үсеп чыксын. Зифа буйлы буласым килми. Йә, кочакла, аркамнан сыйпа, котылыйм, бөкреләремнән котылыйм.

Нурислам. Бүген инде соң.

Миләүшә. Йа Ходай!.. Кемнәр соң без синең белән?

Нурислам. Дуслар. Әйе, гап-гади дуслар.

Миләүшә. Ярата идең бит...

Нурислам. Ярата идем. Һәм син аны бик яхшы белә идең.

Миләүшә. Нигә соң, алайса, соңладык?

Нурислам. Зифа буйлы буласың килде.

Миләүшә. Бүген җомга дип кычкырырга курыктыммы? Әйе, әйе, курыктым. Синең белән икәүдән-икәү генә калмаска тырыштым. Нурисламга сылана дип әйтүләреннән шикләндем. Ләкин үзең дә бит шуңа риза идең.

Нурислам. Авызы пешкән өреп каба, Миләүшә. Бер тапкыр синең алдыңа тезләнгән идем, син риза булмадың — мине тезләнгән килеш калдырып кияүгә чыктың.

Миләүшә. Әйе, шулай шул, шулай. Син хаклы. Шулай да син мине кума, ярыймы? Менә шушында гына утырып төн үткәрим... *(Нурисламның картинасы янына бара, картинага каплаган пәрдәне күтәреп карый.)*

Нурислам *(пәрдәне ябып куя).* Кирәкми. Карадың ич инде.

Миләүшә. Фикеремне әйтмәдем. Тагын бер карап фикеремне әйтергә телим.

Нурислам. Кирәкми. Мактарсың дип куркам.

Миләүшә. Миңа ул, чыннан да, ошады.

Нурислам. Минем үземә ошамый.

Миләүшә. Алайса, үзеңә ошамаган эшеңне нигә дусларыңа күрсәттең?

Нурислам. Әнимнең барып чыкмавына тагын бер кат ышану өчен.

Миләүшә. Ышандыңмы соң?

Нурислам. Ышандым.

Миләүшә. Мактадылар ич.

Нурислам. Аннан соң, картинаны чиктә алып куеп, шампанскийга ябыштык, анекдотка күчтек. Әгәр дә ул әйбәт булса сөйләшми түзә алмас идегез. Ничаклы буяу әрәм иттем, ничаклы вакыт. Нәтиҗә... Менә шундый хәлләр, Миләүшә... *(Миләүшәнең иңенә кулын сала.)*

Миләүшә. Кагылма!

Нурислам *(кулын алып)*. Кагылма дип, әллә кай вакытларны искә төшердең. Телисеңме, мин сиңа бер әкият сөйлим?

Миләүшә. Кирәкми.

Нурислам. Монысы куркыныч түгел... Борын-борын заманда...

Миләүшә. Кирәкми!.. Ишетәсеңме, кирәкми!.. Кирәкми!..

Ут сүнә.

Икенче кисәк

II күренеш

Ут яна. Ут караватта сузылып яткан Сәҗидәне яктырта. Менә ул башын күтәреп карый.

Сәҗидә. Нишләп йөрисең инде?.. Рәфис!.. Рәфис дим!

Рәфис *(ут яктысына керә. Ул махровый материалдан тегелгән озын халат кигән)*. Нәрсә үкерәсең, монда мин. Беркая китмәгән Рәфисең. Стеналары кара кафельле, зәңгәр чынаяк унитазлы бәдрәфтә утыра. *(Бераздан Рәфиснең тавышы караңгыдан ишетелә. Күрәсең, ул диванга барып яткан.)*

Эч поша, Сәҗидә. Нигә сөйләде ул әкиятен Нурислам? Нигә ул әкият күңелгә кереп кадалды? Нигә ачуланышып кайтып киттек. Чәршәмбе булса ни дә, җомга булса ни...

Сәҗидә. Нигә сөйләгәнен аңламадыңмы? Аңламасаң, миннән сорыйлар аны, пырлап йөрмиләр.

Рәфис. Нигә сөйләде соң, әйт.

Сәҗидә *(торып утыра)*. Көнләшә ул Нурисламыгыз.

Рәфис. Нидән?

Сәҗидә. Данызгыздан.

Рәфис. Дан? Нинди дан? Минем кандидат булуым миңа нинди дан өстәде? Фәһимнең нинди даны — җыр язудан узалганы юк. Бер балетын унбиш ел яза. Миләүшә — уртакул артистка. Гайнулла нинди ачыш ясады? Нурисламның даны безнекеннән зуррак: ул дәрәҗәле күргәзмәләрдә катнаша. Юк, монда бүтән нәрсә... Син Шәһитне беләсең бит?

Сәҗидә. Миләүшәнең ташлаган ireme? Йә, беләм.

Рәфис. Хәтерлисеңме, Миләүшәнең туган көнендә бездән аерылганы, үзен үзе әллә кемгә куйганы өчен Шәһиткә бәйләнгән идек. Шәһит бездән вак кешеләр дип көлгән иде. Без үпкәләп кайтып киттек. Һәм бүтән очрашмадык. Нурислам... Шәһит сүзләрен кабатлады бит. Әкият сөйләгән булып бездән көлде. Янәсе, безнең бәябез сукыр бер тиен. Бездән көләргә аның ни хакы бар. Үзе кем ул кадәрле? Бүгенге картинасы да әллә ни түгел бит.

Сәҗидә. Нигә мактадың соң, алайса?

Рәфис. Чыннан да, Сәҗидә, нигә мактадым?.. Күңелен кайтарасы килмәде. Иҗат бит.

Сәҗидә. Ата каз кебек берүзе. Ялгызы җенләнеп ята да әкият уйлап чыгара.

Рәфис. Үз гомереңдә, ичмасам, бер мәгънәле сүз әйт, Сәҗидә.

Сәҗидә. Син әйтә алмаганны нигә мин әйтим.

Рәфис. Сиңа рәхәт яшәве, Сәҗидә: син томана. Мин дә томана. Миңа да рәхәт. *(Халатын салып ыргыта. Юрган астына кереп ята.)*

Пауза.

Рәфис *(кинәт сикереп тора).* Сыйпама минем аркадан! Сыйпама!.. Барлы-юклы бөкремне бетерәсең. *(Бераздан торып ут яктысыннан чыга. Сәҗидә күтәрелеп карый.)*

Сәҗидә. Нишлисең?

Рәфис *(караңгыда).* Киенәм.

Сәҗидә. Кая барасың? Ник дәшмисең? Кая барасың дим... *(Торып, Рәфис янына бара.)* Чишен хәзер үк. Чишен дим.

Ут яктысында әзмәвердәй егет пәйда була, трусик белән майкадан. Ул — Рөстәм — Сәҗидә белән Рәфиснең малае.

Рөстәм. Вы чё тут расшумелись?

Сәҗидә. Әнә этиең чыгып китәм ди.

Рөстәм. Ну и хорошо, а чё тут шуметь.

С а җ и д ә. Беләм мин аның кая барганын. *(Рөстәмгә.)* Бар син дә аның белән чык.

Р ө с т ә м. Еще чё не хватало. Чё он, маленький что ли. Как-никак кандидат наук.

С а җ и д ә. Барыбер үзеңне генә җибәрмим.

Р ө с т ә м. Умора. Как дети. Чё она, ревнует что ли? Дура.

Р ә ф и с. Ни дидең?! Син?! Әниеңә?!

Р ө с т ә м. Ладно, ладно, не петушись, старик. *(Тыныч кына китеп бара.)*

Ут сүнә.

III күренеш

Ут яна. Балконда янәшә утырган Ф ә һ и м белән Э л ь м и р а н ы яктырта. Икесе дә җылы киемнәрдән.

Э л ь м и р а. Нурисламның бу картинасы мине аптырашта калдырды, Фәһим... Картинасының җаны юк. Яратып язмаганы сизелә. Ул аны үзе дә белә, ахры.

Ф ә һ и м. Сөйләшми генә утырыйк әле, Эльмира. Дөньяны тыңлап утырыйк.

Э л ь м и р а. Дөньяны балконнан гына тыңлап булса иде... Ә гомер үтә... Үтә... һаман бер сүз, бер җыр. Мин инде ярый, минем кулымда бүтәннәр язган дәреслекләр, программа, мин шулар буенча укытырга тиеш. Ә син? Син нәрсә эшләдең? Сизәсеңме, син елдан-ел сүз сөйләргә остара барасың. Ә синең төп эшең сүз сөйләү түгел бит, музыка. Дөрес, радиодан җырларың бертуктаусыз яңгырый, ләкин мин куана алмыйм — һаман бер җыр. Минем опера-балет театрында утырасым килә. Сәхнәдә син язган балет яки опера. Кул чабулар...

Ф ә һ и м. Халык кул чапмаячак. Аңа симфонияләр кирәкми, аңа җыр кирәк. Гап-гади җыр. Мәҗлесләрдә җырларлык.

Э л ь м и р а. Юк!! Юк!.. Юк...

Ф ә һ и м. Меңләгән кеше чәршәмбе дип кычкырганда, ни өчен җомга дип кычкырырга.

Э л ь м и р а. Бозма Нурисламның әкиятен. Ул кеше димәде, пәри, диде.

Ф ә һ и м. Кемнәр соң, алайса, пәриләр? Ни әйтергә теләде ул әкияте белән?..

Э л ь м и р а. Ни әйтергәме? Әгәр Нурислам әкиятен сөйләмәгән булса, без төн уртасында монда утырмас идек. Җыен юкбар сөйләп утырыр идек.

Фәһим. Синең белән монда утырып ни кырдык?

Эльмира. Юк, Фәһим. Уйландың син, уйлана башладың.

Фәһим. Кызык син, әйтерсең башка чакта уйланмыйм. Эчем тулы ут. Син әйткәннәрне мин белмиммени? Күптән беләм. Башны җүләргә салып кына йөрим. Шулай да ни әйтергә теләде Нурислам?

Ут сүнә.

IV күренеш

Ут янып Гайнулла фатирының идәнен яктырта. Идәндә **Гайнулла** чалкан ята. Янында ун-унбер яшьлек кызы **Гөлфия** басып тора. **Галия** урындыкта утыра.

Гөлфия. Әти, тор, чалбарыңны буйыйсың.

Гайнулла. Кремплен ыштан буялмый ул, кызым.

Галия. Ятсын, кызым, ятып туйгач торыр әле. Әйдә, без йоклыйбыз.

Гайнулла. Әти дә йокласын, әни дә йокласын.

Йокы, йокы, йокы...
Безне алга илткән йокы,
Безне кеше иткән йокы...

Гөлфия. Иртәгә чалбарыңны үтүкләмибез.

Гайнулла *(көйләп)*. Үтүкләрмен, кызым, үтүкләрмен. Кремплен чалбар бөгәрләнми ул, кызым. *(Торып утырып.)* Гөлфия, кил әле, утыр әле яныма.

Гөлфия килеп аңа сыена.

Телисеңме, мин сиңа бер әкият сөйлим. Борын-борын заманда, кызым, бер авылда бер егет яшәгән. Урманны бик яраткан егет. Эче пошса, урманга китә икән дә көннәр буе шунда йөри икән... *(Туктап кала.)* Кызым, бер сорау биримме мин сиңа?

Гөлфия. Әкият сөйләмисеңме?

Гайнулла. Әгәр дә мәгәр, кызым, без әниең белән менә бүген — җомга көнне — чәршәмбе, чәршәмбе дип биесәк, син ни әйтер идең? Яле, Галия, икәүләп чәршәмбе дип такмаклыйк әле.

Галия. Үтәсең лә үзәкләремә, Гайнулла.

Гайнулла. Йә инде, телең калмас. Чәршәмбе, чәршәмбе.

Гайнуллага Галия кушыла.

Чәршәмбе, чәршәмбе.

Гөлфия тәгәрәп көлә.

Нигә көләсең, кызым?

Гөлфия *(көлә-көлә такмаклый)*. Чәршәмбе, чәршәмбе.

Гайнулла. Әгәр дә без әниең белән чәршәмбе дип чынлап әйтсәк?

Гөлфия. Белмичәме?

Гайнулла. Белмичә әйтсәк. Төзәтер идеңме безнең ялгышны?

Гөлфия. Ничек инде төзәтмисең ди.

Гайнулла. Әгәр дә белеп, юри әйтсәк? Юк, кызым, аңламыйсың.

Гөлфия. Аңлыйм, әти.

Гайнулла *(аягүрә басып)*. Аңласаң әйт, тишек борын, бүген нинди көн?

Гөлфия. Җомга.

Гайнулла. Юк, чәршәмбе.

Гөлфия. Җомга.

Гайнулла. Син ялганла, алдаш! Миңа кушылып чәршәмбе диген.

Гөлфия. Ни өчен?

Гайнулла. Миңа синең шулай диюең кирәк. Син минем сүзне кабатларга тиеш. Әгәр кабатламасаң, мин сиңа бүтән беркайчан да кызым дип әйтмәячәкмен.

Галия. Җитәр, Гайнулла. Син «ә» дигәндә, мин «җә» дип торган да җиткән.

Гайнулла. Юк, әйтсен. Гөлфия кабатласын! Бүген — чәршәмбе.

Гөлфия *(куркыбрак калган)*. Ярый, чәршәмбе булсын!

Гайнулла. Бүген — җомга...

Гөлфия. Җомга.

Гайнулла. Бүген — чәршәмбе!..

Гөлфия. Чәршәмбе.

Гайнулла. Барыгыз! Йоклагыз. *(Идәнгә сузылып ята.)* Йоклагыз дидем.

Гайнулланың холкын яхшы белгәнгә, Галия Гөлфияне җитәкләп алып чыгып китә. Бераздан Гөлфия әйләнеп керә.

Гөлфия. Әти, бүген — җомга... Син чәршәмбе дисәң дә, мин җомга дим. Кыйнасаң да җомга дим.

Гайнулла. Әниең өйрәттеме?

Гөлфия *(паузадан соң)*. Ул. Әти, син миңа кычкырмыйсыңмы инде?

Гайнулла. Юк, кызым, кычкырмыйм. Гафу ит, ярыймы. Үзем очына чыга алмаган мәсьәлә белән сине тинтерәткәнгә гафу ит.

Галия, әкрен генә чыгып басып, Гайнулланы күзәтә.

Авылны яратам мин, кызым. Җирне яратам. Шәһәрегезне җенем сөйми. Агроном булам дидем. Әти белән әни аяк терәп каршы тордылар, шәһәргә кудылар. Мин җомга дидем, алар чәршәмбе дип такмакладылар. Җиңделәр. Хәзер әнә кайтып та күренмисең дип әрлиләр. Йә, кем инде мин шәһәрдә? Ни файда күрде инде миннән химия? Беләм мин аны. Бәлки, яхшы да беләмдер, ләкин яратмыйм мин аны. Күлем монда булды, күңелем анда булды, дигәннәр бабайлар. Үсеп җиткәч аңларсың. Әйбәт, акыллы, чибәр егетләр күп булыр, ратканың бер булыр. Күңелеңә хыянәт итмәскә кирәк... Җирне сагынам... Хәзер көз, җир йокыга әзерләнә.

Ни җырың юк, ни моңың юк, ди Фәһим. Җырым да бар, моңым да бар — тавышым үземнеке түгел... Мин барыбер җомга дип әйткән егет өчен эчтем, Галия. Ә менә ни өчен Нурислам сүзен өзеп әйтмәде? Нәрсә ул, әллә беренче егетне акларга маташамы? Юкка кайтып киттек без, әнисе. Нурисламның әйтәсе сүзе калды. Ул безне картинасын күрсәтү өчен генә чакырмады.

Галия. Бар соң, тыңлап бетереп кайт.

Гайнулла. Ә нигә? Барам.

V күренеш

Ут янганда **Миләүшә** белән **Нурислам** беренче күренеш азагындагы килеш, кара-каршы утыралар. Миләүшә тагын елаган, күз яшьләрен сөртә.

Миләүшә. Минем ни әйтергә теләгәнемне беләсеңме?

Нурислам. Беләм. Без бит дуслар. Бер-беребезнең ни әйтергә теләгәнен белеп торабыз.

Миләүшә көлеп җибәрә, аңа Нурислам да кушыла.

Миләүшә. Нигә көләбез?

Нурислам. Без бит дуслар. Бер-беребезнең нигә көлгәнен белеп көләбез. Син аптыраганнан көләсең, мин син аптырап көлгәннән көләм. Бер кочаклыйм мәллә үзеңне, Миләүшә дустым? Әллә нигә кинәт сине кочаклап үбәсем килде.

Миләүшә. Валлаһимы?

Нурислам. Валлаһи. *(Миләүшәне кысып кочаклап үбә. Аннан кулларына күтәреп алып өстәлгә бастыра. Өстәлдәге шешәләрне, бокалларны идәнгә сыпырып төшерә.)* Җырла, Миләүшә. *(Үзе катыргы кәгазь, карандаш алып идәнгә утыра.)* Җырла.

Миләүшә. Җырламыйм. Картайдым, Нурислам. Җинаятьчеләр без. Япа-ялгыз картайдык. Беләсеңме, Нурислам, мин бит Шәһитне синең хакка ташлап киттем. Һәм ни оттым? Минем ирем Шәһит һаман да Шәһит, икенче берәүгә өйләнеп яши бирә, балалар үстерә. Ә мин?.. Ә син?.. Борын-борын заманда, минем туган көнемдә, син безнең өйгә исереп килеп кереп, Шәһитне үтерәм дип җикеренгән чакта, Шәһит безнең барыбызны да вак кешеләр дип атаган иде. Рәфисне дә, Фәһимне дә, сине дә. Әллә инде ул хаклы булып чыкты...

Ишектә звонок. Миләүшә өстәлдән сикереп төшә.

Үзем ачам. *(Рәфис белән Саҗидәне ияртеп керә.)* Рәфис, ни булды?

Саҗидә. Ул сезнең белән сөйләшергә килде.

Рәфис. Саҗидә, Алла хакы өчен...

Саҗидә. Җитәр, түздем, дәшмәдем. Мине курчак шикелле бер читкә утыртып куеп, теләсә ни сөйләшәсез. Мин томана, имеш. Сез акыллылар. Бармы акыллы сүз сөйләшкәнегез? Коры куыклар. Минем — эчемдәге тышымда. Сезнең эчегездә дә юк, тышыгызда да. *(Миләүшәгә.)* Сиңа сүзем шул: әйләндермә безнең ирләрнең башын! Әгәр дә тагын Рәфис янына якын киләсе булсаң, кара аны, куелган тешләреңне коеп төшерермен.

Нурислам *(Саҗидә янына килеп култыклап ала. Балконга алып чыга).* Саҗидә ханым, сез бик туры сүзле хатын, йөзгә бәреп әйтәсез. Эчегездәген бушатып, бүлмәнең һавасын бозмагыз. Без бишенче катта, Саҗидә ханым... Ләкин икенче тапкыр Миләүшәгә тел тидерсәгез, өегезгә юл шушында булыр.

Саҗидә. Әллә ыргытырсыңмы? *(Бер Нурисламга, бер Рәфискә, Миләүшәгә карап тора да елап җибәрә.)* Чукынышып бетегез. *(Рәфисне читкә этеп чыгып китә.)*

Миләүшә. Бар, Рәфис, куып җит.

Рәфис дәшми, идәндәге пыяла ватыкларын җыюны дәвам итә.

Рәфис. Беркая да китмәде ул, ишек төбендә генә тора. Суыныр да керер. Ә сез монда шешәләр атышып нишләдегез?

Нурислам. Өйләнгән кешеләр ничегрәк яшиләр икән дип сынап карадык. Ни өчен килергә булдыгыз, Рәфис?

Рәфис. Беләсеңме нәрсә, Нурислам, һәрнәрсәнең чиге була. Әгәр дә үзеңне бездән өстен куеп, безне мыскылларга уйласаң, ниятең барып чыкмас. Бер-беребезнең бәясен бик яхшы беләбез. Дусларыңның фикере синең өчен бер тиен тормый. Син генә тәти егет. Янәсе, без чәршәмбе дип кычкырабыз, син — юк. Кайчакларда мин чәршәмбе дип кычкырганмын икән, син дә җомга дип кенә яшәмәдең. Без дуслар, әйдә, теләсәң, дуслар булып калыйк, тирәнгә кермик.

Саҗидә керә.

Саҗидә *(Рәфиска).* Кайтасыңмы син, юкмы?

Ишектә янә звонок. Нурислам ишекне ача. Фәһим белән Эльмира керәләр.

Нурислам. Рәхим итегез, түрдән узыгыз. Өстәлне яңа гына җыйган идек. Саҗидә ханым, сез аш-суга оста, чәй кайнатып эчерегез безгә. Ярдәмчеләр кирәк булса, Эльмира белән Миләүшәне алыгыз.

Саҗидә әкрен генә кухняга кереп китә, аңа Эльмира белән Миләүшә ияре.

Дәвам ит, Рәфис.

Рәфис. Мин әйтәсен әйттем.

Нурислам. Юк, син башладың гына. Ни әйтеп башлаганың Фәһимгә дә мәгълүм булсын. Һәрнәрсәнең чиге була, диде Рәфис. Үзеңне өстен куеп, безне мыскылларга уйлама, диде. Үзең дә җомга дип кенә яшәмәдең, диде...

Ишектә звонок.

Нурислам. Гайнулла!.. Молодец, Гайнулла! *(Барып ишек ача. Гайнулла белән керә.)*

Гайнулла. Мине кайтарып җибәрделәр дә үзләре утыралар. Килдем әле, Нурислам. Йөрәк түзмәде. Тик сез көлмәгез, ярыймы? Сез күптәнге дуслар, мин — яңа. Мин аңларга килдем. Әкиятең гыйбрәтле, Нурислам, ләкин... Нигә син сүзеңне әйтеп

бетермәдең? Дөньяда ак бар, кара бар. Ак белән караны бутап булмый. Мин дөреслекне әйткән егетләр яклы, кешене кеше иткән нәрсә — дөреслек, хаклык. Алдашып, яраклашып яшәүчеләр дә бардыр, дөреслекне әйтергә куркучылар да бардыр: бәхәсләшмим. Ләкин нигә сез, нигә без, бердәм булып, икеләнмичә, яшәсен җомга дип кычкырган егетләр дип, бокалларны күтәрмәдек? Нигә бәхәс купты? Әллә соң без үзебезнең сафлыгыбыздан шикләнәбезме? Күңелләребезгә кер кунганмы?

Нурислам. Мин ни әйтергә тиеш? Аңлыйсыз бит инде, егетләр. Нигә аңламаган булып кыланасыз. Аңламаган булсак, яңадан җыелмас идек.

Хатын-кызлар чәй алып чыгалар.

Иң яхшысы, чүкердәшеп чәй эчик.

Эльмира. Чәй эчик тә таралышыйк, чәй эчик тә таралышыйк. Рәхәт, тыныч, өс бөтен, тамак тук.

Нурислам. Эльмира, син башлап җибәрәсең дә, аннан миңа бәйләнәләр. Гаепләргә ашыкма син мине, Рәфис! Кем сезне мыскылларга җыена! Әкиятне авыл агаеннан ишеткәч, иң элек үзем турында уйладым мин. Үткән тормышыма, иҗатыма анализ ясадым. Әллә ни эш кылганым юк икән, шул ачыкланды. Өстән-өстән генә яшәлгән. Иң аяныч, дуслар, безнең дуслыгыбызга шикләнә башладым әле мин. Чын дуслык микән ул? Дуслыгыбыз да өстән-өстән генә түгелме? Шулайдыр. Шуңа күрә һаман бер сүз сөйлибездер без, урынлыга да, урынсызга да бер-беребезне бик тиз мактыйбыздыр. Нигә мактадыгыз сез мине бу юлы? Йөрәкне әрнеткәне — без барыбыз да саега барабыз. Тирәнгә кермик димә, Рәфис, тирәнгә керик. Су читендә чупырдаудан ни мәгънә, вак балыклар гына су читендә йөзә. Чөнки анда су җылы.

Рәфис. Зур балыклар вак балыктан үсә.

Нурислам. Кырыкны уздык, күпмегә үстек?

Фәһим. Анысы аңлашылды...

Нурислам. Аңлашылмады, Фәһим. Һәрхәлдә, син аңламадың. Эчтән генә мине ахмакка санап көлеп утырасың. Сиңа пәриләрнең кем икәнлеген генә белергә кирәк. Әйтимме кемнәр икәнен? Мин сөйләгән әкияттәге пәриләр — безнең күңелебезгә кереп оялаган үшәнлегебез, ваемсызлыгыбыз, тәти булып күренергә тырышуыбыз... Алар туй ясый да туй ясый, без һаман бер сүз сөйлибез: чәршәмбе, чәршәмбе, чәршәмбе... Шуның чаклы күнегелгән: дөньяның, тормышның бүтәнчә

булуын күз алдына да китермибез. Менә ни өчен сүземне әйтеп бетермәдем мин, Гайнулла. Өзеп әйтә алырлык хәлдә түгел. Ике бөкре белән яшәгәнче, бер бөкредән котылып кызларны гашыйк иттерү начармыни?

Г а й н у л л а. Мин барыбер икенче егет өчен эчәм.

Н у р и с л а м. Мин дә сиңа кушылам, Гайнулла. Ләкин кеше кесәсенә кергәндә, урлашырга ярамый дип кычкырган карак кебек булу әллә ничек, оят.

Р ә ф и с. Нигә шулчаклы куертасың?

Н у р и с л а м. Ярый, синеңчә булсын, Рәфис, куертмыйк. Нигә кирәк? *(Чокырын күтәреп.)* Йә, ни өчен эчәбез? Борын-борын заманда пәриләр җомга дип әйткән өченме?.. Ни өчен эчәбез?

Пәрдә.

1977 ел

Пьесаның сюжеты. Пьесада вакыйга сюжеты юк диярлек. Дуслар бергә җыелалар, юк-бар сөйләшеп утыралар да, Нурисламга үпкәләп, өйләренә таралышалар. Аннары кабат җыелалар. Ләкин без әсәрләрдә, бигрәк тә пьесаларда, кичереш катламы барлыгын һәм бу катламның сюжеты булуын беләбез. Сюжетның шул сызыгын өйрәник.

Нурислам сөйләгән кечкенә генә әкият персонажларның бөтен хисләрен бутап-болгатып ташлый. Хисләр ничек үзгәрә? Үзгәрү сәбәпләре нинди, кичерешләрнең дәрәҗәләре ничек үсә? Башлап шул сорауларга җавап эзлик.

Дуслар арасында бары тик Нурислам кичерешләре генә үзгәрми. Дөресрәге, үзенә үзе бәя бирерлек югарылыкка күтәрелгәннән соң, ул, билгеле, борчылган да, икеләнгән дә. Ләкин хәзер кискен бер карарга килгән һәм пьеса барышында да карарын үзгәртми. Дусларының да шундый яки шуңа охшашлы карарга килүенә өметләнә.

Нурислам иптәшләрен сынамакчы була. Бу сынау аның үзе өчен дә, дуслары өчен дә кирәк. Ләкин дусларының ихласлыгын сынау җиңел генә түгел. Бу бит — күп еллар буена җан дуслар булган кешеләргә ышанмау дигән сүз. Моңа алар ничек карарлар? Үпкәләп, бергә узган зур бер гомерне юкка чыгарып, челпәрәмә китермәсләрме?

Нурисламның бу борчуына тагын берсе өстәлә. Чакырылган кунаклар арасында беренче мәхәббәте — Миләүшә дә бар.

Миләүшә кайчандыр аның мәхәббәтен кире каккан. Һәм моны Нурислам бик зур кимсенү итеп кабул иткән иде. Хәзер алар икесе дә ялгыз яшиләр. Бер-берсен һаман яраталар. Ләкин дуслар булып кына яши бирәләр. Нурисламның, үпкәсен йотып, Миләүшәгә үз хисләрен әйтәсе килә. Әмма әкият мәгънәсен ул ничек кабул итәр?

Нурислам кичерешләре үзгәрми, дидек. Ә башка персонажларда кичерешләр үзгәреше сюжет сызыгы була аламы? Башкаларның кичереш хәрәкәтен үзегез табыгыз.

Биремнәр һәм сораулар

1. Рәфис белән Саҗидә кичерешләре турында сөйләгез.
2. Фәһим белән Эльмира кичерешләре турында сөйләгез.
3. Гайнулла белән Галия хисләренең хәрәкәте турында сөйләгез.

Пьесаның төзелеше. Туфан Миңнуллин пьесасының жанрын драматик новелла дип атаган.

Новелла дип кыска сюжетлы хикәяләргә әйтәләр.

Пьесага анализ ясаганда, чәчмә әсәрләр төзелеше үзенчәлеген дә искә алырга тиешбез. Шуңа күрә әсәрне, чәчмә әсәрләрдәге кебек, ике вакыйгага бүлеп өйрәнәбез.

Нурислам сөйләгән әкият вакыйгаларның һәрберсенә бәя бирә. Әкият — метафора-вакыйга буларак, табыласы өлешләрнең берсе. Димәк, өлешләрнең икенчесе калган вакыйгалардан җыелырга тиеш.

Өлешләр табылганнан соң, аларны аерым-аерым өйрәнеп, араларындагы бәйләнешне (охшашлыкны) табарга һәм метафора-вакыйга аша төп өлешкә бәя бирергә кирәклекне без инде яхшы беләбез. Хәзер шул эшләрне башкарыйк.

4. Әкияттән калган өлешләрне вакыйгаларга бүлеп чыгыгыз. Бер өлешкә җыела торган булгач, күрәсең, аларныңниндидер уртак яклары (төзелешләре яки эчтәлекләре) бардыр.

5. Беренче өлешне — әкият вакыйгасын өйрәнегез: аның төп вакыйгаларга бәя бирерлек урыннарын, сыйфатларын язып чыгыгыз.

6. Һәр вакыйгага, әкият эчтәлеген файдаланып, бәя бирегез.

7. Хәзер пьесаның темасын табып була — табыгыз.

8. Пьесада әкияттән башка метафора-вакыйгалар табыгыз һәм аларның пьеса эчтәлегенә керткән өлешен әйтегез.

9. Хәй Вахит персонажларының кичерешләрен көчәйткәннән-көчәйтә барды һәм әсәренең ахырында гына иң югары дәрәҗәсенә җиткерде. Туфан Миңнуллин персонажлары кайсы пәрдәдә һәм ни өчен нәкъ менә шул пәрдәдә аеруча нык кайгыралар?

Шәриф Хөсәенов
(1929—1999)

Шәриф Нургали улы Хөсәенов 1929 елның 26 ноябрендә Татарстанның Буа районы Өчмунча авылында туа. Мәктәпне ул үз авылында, күршедәге Килдураз авылында һәм Буа шәһәрендә укып тәмамлый. Казанның медицина институтына керә, аны тәмамлагач, табиб булып эшли башлый һәм гомере буена үзенең һөнәренә тугрылыклы булып кала.

Студент елларында «Профессор кияве» исемле пьеса яза һәм беренче әсәре белән үк театрга талантлы драматург килүен хәбәр итә. 1960—1962 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Шунда укыганда «Зөбәйдә — адәм баласы», ә тагын җиде елдан «Әниемнең ак күлмәге» (Әни килде) исемле пьесалар яза. Берсеннән-берсе уңышлы чыккан бу әсәрләре, төрле телләргә тәрҗемә ителеп, илебезнең төрле шәһәр театрларында куелды.

Шәриф Хөсәенов аз язды, ләкин аның һәр әсәре, җәмәгатьчелекне шаулатып, бәхәсләр тудырып, зур бер вакыйгага әйләнде. Аның әсәрләрендә хәтта таныш тема да нәкъ менә Шәриф Хөсәенов чишелеше белән чишелә. Авторның беренче карашка сәер булып тоелган темалары да, уйлап карасаң, күпләрне борчыган тема булуы ачыклана. Шуңа күрә аның аз санлы әсәрләре дә әһәмиятләре ягыннан күп санлы әсәрләргә тиңләшеп яши бирәләр.

Шәриф Хөсәенов кактуслар үстерергә яратты. Тәрәзә төпләренең һәркайсында йөзләгән таш чүлмәкләрдә төрле-төрле кактуслар үсеп утырыр иде. Ул бит үзе дә, кактуслары кебек чәнечкеле, кешеләргә бәясен чеметтереп әйтә белде. Аны барыбер яраталар иде.

ӘНИЕМНЕҢ АК КҮЛМӘГЕ

(Әни килде)

(Өч пәрдәле драма)

КАТНАШАЛАР:

Ана — 75 яшьтә.
Максуд — Ананың беренче улы, 53 яшьтә.
Саимә — Максудның хатыны, 51 яшьтә.
Альфред — аларның улы, 32 яшьтә.
Ислам — Ананың икенче улы, 51 яшьтә.
Расиха — Исламның хатыны, 35 яшьтә.
Рәйхан — аларның кызы, 7 яшьтә.
Инсаф — Ананың өченче улы, 47 яшьтә.
Сәяр — Ананың төпчек улы, 27 яшьтә.
Римма — Сәярнең хатыны, 21 яшьтә.
Гөлчирә — Ананың кызы, 35 яшьтә.
Зөләйха — Сәярнең квартира хуҗасы.
Әлмөхәммәт — Зөләйханың каенатасы, 89 яшьтә.
Гөлсем — авылдан килгән кыз.
Баянчы егет — сүзсез.

Беренче пәрдә

Ике бүлмәле квартираның аркылы киселеше. Сулда — зал. Уңдагы бүлмә бик кечкенә. Андагы бар җиһаз —иске тимер карават, ике урындык, ак пәрдә белән капланган кием элгеч һәм иске этажерка.

Бер-берсенә уралып, Сәяр белән Римма керә. Икесенең дә өсләрендә туй киемнәре. Римманың куены чәчәкләр белән тулы. Ишек төбендә үк туктап, озак итеп үбешәләр.

Сәяр. Ниһаять, без үзебез генә! Син минеке! Минем законлы хатыным! *(Римманы үбә.)* Хозяйка бүген өйдә булмаячак! Үзебез генә булабыз бүген өйдә!

Римма. Рестораннан ашыгыбрак киттек. Иптәшләр гаеп иткәннәрдер.

Сәяр. Җүләркәем! Берәүне дә күрәсем килми! Гомеремнең иң бәхетле көнендә синең белән икәү генә буласым килә! Бүген дөнья безнеке, Римма!

Римманы күтәреп алып үбә башлый. Озак итеп, звонок шалтырый. Артта шау-шу, көлешү. Залга Максуд, Саимә, Альфред, Инсаф һәм баянчы егет керә. Максудның кулында зур кәрзин, аннан берничә шешә муены күренеп тора. Саимә чәчәкләр тоткан. Альфред пирог куелган поднос күтәргән. Инсаф таякка таянган һәм, ике аягы да протез булу сәбәпле, шактый аксый.

Максуд. Ха-ха-ха! Әле сез бездән яшереп өйләнешеп йөрисезмени? Барып чыкмады! *(Ишек төбенә килеп кычкыра.)* Әйдәгез, әйдәгез, бирегә кертегез! *(Ике кеше диван-караватны идән уртасына куеп чыгып китәләр.)* Ха-ха-ха! Туйларыгыз котлы-мөбарәк булсын, законлы никах белән! *(Көлешә-көлешә яшьләрне котлыйлар.)*

Сәяр *(аптырап).* Кайдан белдегез сез?!

Саимә. Әйтмә, әйтмә, Максуд! Зурайган, зурайган! Институт бетергән, янәсе, инженер булган! Ай-һай!

Максуд *(диван-караватка тотынып).* Ягез, кая куябыз?

Зөләйха. Әнә теге якка! Аларның бүлмәсе әнә тегендә!

Күмәкләшеп диван-караватны күтәреп алалар да уңдагы бүлмәгә узалар, андагы тимер караватны җыеп алып, урынына диван-карават куялар.

Римма *(диван-караватка утырып).* Рәхмәт сезгә, зурлагансыз!

Сәяр *(Инсафка).* Ә син, абый, ничек Казанда?

Инсаф. Туйга килдем!

Максуд. Әле тагын кунаклар була! Ислам белән Расиха!

Сәяр. Тфү, чёрт! Соң, мин әйтә килдем сезгә, өйләнсәм, туй ясамыйм дидем! Безнең бернинди сыебыз юк! Үзебез дә ресторанда гына ашап чыктык.

Максуд. Оятсызлар! Бүләкнең өстенә менеп утырдылар да бер чынаяк чәй дә кызганалар. Үпкәләдек! *(Килүчеләрне зал ягына куалап чыгарып, ишекне биклэп ала.)* Кияү келәте. Менә утырыгыз шунда!

Сәяр *(ишекне тартып).* Абый, ач!

Максуд. Абыең ач булмас ул, абыеңның ризыгы үзе белән. Саимә, бушат кәрзиннәрне!

Килүчеләр, көлешә-көлешә, үзләре алып килгән кәрзиннән өстәлгә ашамлыклар чыгаралар. **Зөләйха** савыт-саба һәм приборлар китерә. Звонок. **Ислам, Расиха, Рәйхан** керә.

Расиха. Исәннәрмесез!

Максуд. Бик озак җыендыгыз, бүләкнең хәтәрен сайладыгыз, ахры!

Ислам. Чакырмаган туйга нинди бүләк ди аңар!

Максуд *(тәрәзәдән үрелеп нидер күзәтүче Исламнан).* Сез нәрсә, машинагыз беләнме?

Ислам. Шулай иде лә. Янында ике малай маташа... *(Тәрәзәдән йодрык селки.)*

Расиха *(тәрәзәдән үрелеп карап).* Киттеләрме? Халык бик әшәке хәзер. Әле беркөн капка төбендә өч минут торган арада, кадак белән тырнап, машинаның өстенә оятсыз сүз язып киттеләр. Чын! Яшьләр кайда соң? *(Сәяр ишек дөбердәтә.)* Ай Алла, бу ни хәл бу?

Сәяр. Безне Максуд абый бикләде, Расиха җиңги! Ач әле!

Ислам. Абый, инженер булгач, понимаешь, туганнарыннан хурланадыр ул, бәлкем! Тик без хатынны кеше почмагына алып кайтмаган идек, кесәдә диплом булмаса да.

Расиха. И, болай күңелле түгел лә, Максуд абый!

Максуд. Бик күңелле. Илле яшькә җитеп мондый кызык туй күргәнем юк иде әле.

Бокалларга эчемлек салалар.

Тотыгыз бокалларыгызны. Барыгызга да мәгълүм, җәмәгать, бүген безнең төпчек энебез Сәяр үзенең кәләше белән языльшып кайтты...

Әйдәгез, җәмәгать, әнә шул юньсезләр саулыгына күтәрик әле!

Эчәләр. Көлешә-көлешә капкалыйлар.

Зөләйха. Шаярдыгыз, җитәр. Чыгарыгыз инде яшьләрне.

Максуд. Тавышка куям! Кем дә кем... *(Сүзен әйтеп бетерми, төрле яктан «Чыгар!» «Чыгар!» дигән тавышлар ишетелә.)* Равил, музыка! *(Баянчы туш уйный.)*

Максуд ишекне ача. **Сәяр** белән **Римма** чыга. Яшьләрне түргә утырталар. Альфред бокалларга эчемлек сала.

Максуд. Әйдәгез, җәмәгать, яшьләр исәнлегенә!

Саимә. Әче!

Альфред. Горько!

Күмәкләп. Горько! Горько!

Сәяр белән Римма үбешәләр. Барысы да эчәләр.

Максуд *(Зөләйханың кемнедер каршы алуын күреп).* Кем бар анда, Зөләйха ханым?

Зөләйха. Әткәй ул. Туганнарны күрергә дип, авылга кайткан иде, шул кайтты.

Максуд. Табын янына чакырырга кирәк!

Сәяр чыга, **Әлмөхәммәт** картны ияртеп керә.

Сәяр. Әйдә, утыр, бабай. Бирәрне җибәрәсеңме?

Әлмөхәммәт. Ярый алайса, яшьләр исәнлегенә булсын. *(Эчә.)* Бу кемнәрең була соң инде синең, Сәяр?

Сәяр. Туганнарым, бабай. Менә бусы — иң олы абыем, заводта мастер булып эшли. Монысы — аның хатыны Саимә җиңги, трамвай йөртүче. Менә бу — минем икенче абый, бабай. Әле күптән түгел генә пенсиягә чыгып, Магадан өлкәсеннән кайтты. Йорт алып, Казанда тора хәзер.

Әлмөхәммәт *(Исламга)*. Бик яшь күренәсең түгелме соң?

Ислам. Минем стаж горняцкий, бабай, подземный. Шахтерлар пенсиягә илле яшьтән чыгалар.

Сәяр. Бусы — аның хатыны Расиха җиңги. Ә менә монысы, бабай, өченче абыем — Инсаф абый. Ватан сугышы инвалиды.

Әлмөхәммәт. Туганнарың күп икән, Сәяр... Зур байлык бүләк иткән үзегезгә әти-әниегез!

Расиха. Иптәшләр, тыңлагыз! Хәзер сезгә Сабирова Рәйхан җыр җырлап күрсәтә. Яле, кызым!

Рәйхан *(урындык өстенә басып җырлый)*.

Әрнемә, сызлама, юксынып йөрәгем,
Сагынып, саргаеп, өзелмә үзәгем.
Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә
Карлыгач шикелле талпынып һәр язда!

Көлешү, кул чабулар. Кунаклар җырны күтәреп алалар. Звонок. Зөләйха ишек ачарга чыга. Бераздан ишектә Ана белән Гөлсем күренә.

Саимә *(абына-сөртенә Анага каршы йөгерә)*. Һай, җаным, әни килде ич! Әни килде, Максуд!

Барысы да ишек төбенә җыелалар. Ананы уратып алалар. Гаҗәпләнү авазлары, исәнләшү.

Максуд. Төпчегең өйләнде бит, әни, туй бүген!

Сәяр. Юк-юк, әни, туй мәҗлесе түгел бу!.. Мин туйсыз гына өйләнергә булган идем дә, әни... менә алар әллә кайдан ишеткәннәр дә бәреп керделәр! Син рәнҗемә инде, әни, туй түгел бу!.. Менә таныш бул, әни, бу минем... бу синең киленең була. Исеме — Римма...

Ана акрынлап үзен кулга ала. Алгарак узып, Сәяр белән Римманы күкрәгенә кыса. Ананың итәгенә Рәйхан сарыла.

Ана *(Рәйханны күтәреп алып)*. Кызым Рәйхан лабаса бу! Нинди зур булып үскән минем кызым.

Сәяр. Әни, менә бу апа — минем квартир хозяйкам!

Зөләйха. Исәнмесез. Танышу качмас. Башта әниегезне табын янына утыртыгыз.

Ана. Өстемне алыштырам.

Саимә. Соңыннан алыштырырсың, әни, соңыннан!

Ана. Юк, соңыннан түгел, хәзер алыштырам! Улымның туенда бу килеш утырырга, мин соң... *(Саимә белән бергә чыгалар.)*

Максуд *(Сәярдән).* Әнигә хәбәр итмәгән идеңмени?

Сәяр. Юк дип әйттем бит инде!

Максуд *(Гөлсемгә).* Бик озак эзләп йөрмәдегезме соң, сеңлем?

Гөлсем. И, сорамагыз инде, абый! Башта әбинең олы малаена барган идек...

Максуд. Менә мин ул — әнинең олы улы. Безнең йортларны сүттеләр бит, сеңлем!

Гөлсем. Шуннан әбинең поселоктагы малаен эзләп киттек. Көч-хәл белән эзләп тапсак — капкалары бикле. Шуннан әби әйтә, Казанда минем тагын бер улым бар бит әле, адресы гына юк, ди. Киттек справочныйны эзләп.

Ананы култыклап, Саимә керә. Ананың өстендә озын итеп тегелгән ап-ак ефәк күлмәк, зәңгәрсу камзул, башында ак ефәк яулык белән ефәк шәл, аякларында читекле читек. Бу киемнәрдә Ана бөтенләй яшәреп, матурланып киткән.

Саимә. Урынның иң дәрәҗәлесе сиңа бүген, әни! *(Ананы өстәлнең иң түренә, Сәяр белән янәшә утырталар.)* Күрегез әле, безнең әнинең матурлыкларын!

Максуд. Вәт, безнең әни! Әни нинди дә, без нинди! *(Корсагын бәргәләп куя.)*

Расиха. Әни, ничек болай бер дә хәбәр итмичә киләсе булдың?

Ана. Менә Гөлсем. Әйдә булгач, әйдә дип күземне дә ачырмады.

Зөләйха Анага чәй кертеп бирә.

Саимә. Әни! Яшь киленне яраттыңмы соң, нигә бер дә дәшмисең?

Ана *(акланган кебек).* Ул хакта сөйләшергә вакыт юк лабаса әле... *(Торып басып.)* Төкле аягы белән килсен! Улымны яраткан кешене мин яратырмын! *(Муеныннан гәрәбә муенсаны алып Риммага кидерә.* Киленнәрдән бәхетем бар минем, берегездән дә авыр сүз ишеткәнем юк!

Максуд. Бергә тормаганга күрә генә шулай ул, әни!

Ана. Нишлисең бит, улым, бергә торырга насыйп булмаган. Лачындай җиде малай үстердем — җидесе җиде якка очты да таралды. Өч кыз бала үстергән идем, алары да туган ояларын ташлап очып китте... Карасана, абыстай шикелле җәелдем дә утырдым! Күчтәнәчләремне чыгарырга онытканмын лабаса! *(Гөлсемгә.)* Кызым, әйдә, булыш әле миңа! *(Гөлсем белән коридорга чыгалар.)*

Саимә. Һай, җаным, бигрәк күңелле көн булды ич бу!

Гөлсем чемодан кертеп куя. Ана зур кәрзин күтәреп керә.

Максуд *(Исламга).* Әни әйтә, киленнәрдән бәхетем бар, ди. Безнең генә хатыннардан бәхет булмады!

Саимә. Өйгә кайтасың барын онытма! *(Ана күчтәнәчләрен чыгара башлый.)* Һай, бу тиклем җиләкне кем җыеп бетергән моны?

Ана. Үзем җыйдым. Куегыз шунда табынга.

Саимә. Һай, бу тиклем дә хуш исле итеп кайната белерсең икән, әни! *(Ананың колагына иелеп.)* Әни, күчтәнәчләреңнең барысын да чыгарып бетермә, безгә дә алып барырсың!

Ана *(төргәк биреп).* Менә монысы — каклаган каз. Берәрегез кайтмасмы дип саклаган идем, кайтмадыгыз да быел... *(Чемоданга күрсәтеп.)* Әнә өчегезгә өч йөз күкәй, санап алырсыз. *(Инсафка.)* Синең Казанда икәнеңне белмәдем инде, улым...

Ана *(Рәйханга күкәй биреп).* Мә, кызым, пешкән күкәй сиңа!

Ислам. Ашамый ул күкәй, әни. Безнең үзебездә егерме тавык, коеп кына торалар.

Рәйхан ананың итәгенә менеп утырып муенына урала, колагына нидер пышылдый.

Зөләйха. Бигрәк ярата икән инде бу кыз әбисен!

Саимә. Яратмаска — әни үстергән Рәйхан ич ул! Сигез айлык чагында әнигә кайтарып аттылар да, алты ел буе әбисендә үсте ич ул Рәйхан!

Максуд. Ярый, сүзне туктатыйк! Әни, син гаеп итмә инде, без берәрне тотыйк! Әниең бәхете тулып торсын әле! Дөньяда иң якын кешебез булган, барыбыз өчен дә кадерле әни саулыгына эчәбез!

Эчәләр.

Саимә *(тәрәзә янына килеп).* Уф, әллә яңгыр яварга җыена — авыраеп торам!

Максуд. Син авырайган саен яңгыр ява башласа, Җир йөзен әллә кайчан су баскан булыр иде инде!

Көлешү.

Саимә *(Инсафка).* Син нишләп сөйләшми утырасың — телеңне йоттыңмы әллә?

Ана *(Инсафның башыннан сыйпап).* Кечкенәдән шулай оялчанрак булды шул ул Инсаф. Оялчан булса да, батыр йөрәкле иде үзе. Бервакыт Инсаф белән Ислам, янә дә Кәрим Иделгә су коенырга төшеп киткәннәр. Кәрим бата башлаган. Ислам җан-фәрманга чабып кайтып керде. Кәрим Иделгә төшеп батты, ди. Шуннан олылар Идел буена йөгереп төшсәләр — Инсаф Кәримне яр кырыена сөйрәп чыгарган. Ничә яшьтә булгандыр инде ул чакта, унөч-ундүрттән артык түгелдер. Кәрим үзеннән зуррак бит әле, Ислам белән бер елгы...

Ислам. Ярый инде, әни, үткән эшкә салават! Син миңа шуны әйт: кайчан үзеңне Казанга алып киләбез? Әйдә Казанга күчеп кил, әни! Үзебездә торырсың! Сине әллә кайчан аннан алып китәргә кирәк иде дә, понимаешь, миннән башка моны эшләүче булмады. Инде менә мин кайттым, әни. Күп акча белән кайттым, баеп кайттым!

Саимә. Кара боларны! Сездән алда әнинең олы малае белән олы килене бар шул әле монда, алар нәрсә әйтер бит. Юк-юк, әни, киләсе булсаң беркемгә дә түгел, үзебезгә киләсең!

Расиха. И Ходаем, үзләренең кеше сараенда яшәгәннәрен белми!

Саимә. Яшәсә! Яңа йорт салынып беткәнче генә ич ул, көзгә хәтле генә! Тиздән безгә яңа квартира бирәчәкләр, әни.

Ислам. Алып киләсе булгач, әллә кайчан алып киләләр аны! Нигә мин кайтканчы суздыгыз?

Инсаф. Әти үлгәч, мин аны Чистайга алып китмәкче идем — бармады.

Ислам. Абыйга килсәң рәтле тормыш булмаячак сиңа, әни! Саимә ул ашаган табагын юарга да иренә!

Саимә. Әллә әнине ни өчен үзегезгә китерәсегез килгәнне белмиләр дип уйлыйсызмы? Бөтен йорт эшен әнигә ташлап, эшкә кермәкче була ич ул Расиха! Картайган төшкә стажы юк ич аның!

Инсаф. Үзебезгә кил, әни! Бездә сиңа бер эш тә булмаячак.

Римма. Безне санга да сукмыйсыз. Без дә бар ич әле монда. Әллә сез әнине бездән артыр дип уйлыйсызмы? Шулай бит, Сәяр?

Сәяр. Шулай булмыйча! Көнләшә башласа, үзенә кибеттән бер бәби алып кайтып бирербез — тик уйнап утырсын!

Ислам. Анысын булдырырсыз ла!

Расиха. Әнидән бала караттып ятмакчы — хитрый!

Ана. Тәмле сүзләрегез өчен рәхмәт, балалар! Бәхәсләшмәгез, килмим. Турысын гына әйткәндә, кирәгем бар әле минем анда. Тизрәк кайт, әби, дип өзгәләнеп калды бригадир әле менә хәзер дә. Районнан берәр кеше килсә, йә булмаса Казаннан, барысы да кич кунарга миңа килә.

Максуд. Ярый, җитте, аптыратмагыз әнине. Үзе теләгәнчә яшәсен. Инде берүземә генә авыр дип әйтә икән — килсен. Без тугызау. Тугызыбыз өчен дә әни — кадерле кунак. Әйдәгез, бер биеп алабыз! Равил, музыка!

Баянчы вальс уйный. Сәяр белән Римма, Альфред белән Гөлсем вальс әйләнә. Вальс бетә. Баянчы бию көе уйный. Максуд бии. Максуд Саимәне чакыра. Саимә алпан-тилпән бераз бии дә Ананы чакыра. Ана җай гына биеп китә. Аның хәрәкәтләрендә искиткеч матурлык һәм грация, күзләрендә яшьлек шаянлыгы. Килен белән Ана икәүләп бииләр.

Саимә *(көчкә бии-бии)*. Ух! Уф! Һай, җаным, үтерәсең ич, әни!.. Расиха, тор тизрәк, монда киленнәрне биетеп үтереп китте!..

Ана белән Расиха бии. Ниһаять, Расиха, үзенең Ана белән ярышырга чамасы юклыгын аңлап, кул селти дә утыра.

Саимә. Күр әле, җен икән безнең әни! *(Сикереп торып, яңадан Ана белән бии башлый.)* Барыбер сине ардырам, әни!

Бию иң кызып җиткән моментта, **Гөлсем** йөгереп керә һәм Ананы кочаклап ала.

Гөлсем. Туктатыгыз! Төне буе йокламаган карчыкны үтермәкче буласызмы әллә?

Саимә. Ярый, алайса, бераз ятып ал, әни! *(Ананы култыклап сулдагы бүлмәгә алып чыгалар.)*

Ана. Рәхмәт, кызым... Сез миңа карамагыз, күңел ачыгыз. Мин менә шунда азрак башымны гына терәп торам...

Сәхнә әйләнә. Сул яктагы бүлмә тамашачы күз алдыннан югала. Залда күңел ачу дәвам итә. Гөлсем Максуд янына килә.

Гөлсем. Абый, бер генә минутка бире килегез әле!.. Әйтсәм дә уңайсыз инде, абый, әйтмәсәм дә... Вакытсызрак чакка туры килдек... Әбинең эш начар бит, абый. Бик начар авыруы бар әбинең. *(Сумкасыннан бер кәгазь чыгарып бирә.)* Менә.

Пауза.

Максуд *(кәгазьне укып)*. Ислам! Инсаф! Сәяр! Килегез әле!

Туганнар Гөлсем янына җыелалар. Кәгазь кулдан-кулга күчә. Төркемгә Саимә, соңрак Расиха килеп кушыла.

Инсаф. Кем куйган диагноз бу?

Гөлсем. Район больницасында куйдылар. Ул инде ай буе морфий эчеп кенә тора. Авыртуны баса торган шундый бер дару бар.

Саимә *(кулларын угалап, еларга җиткән хәлдә әрле-бирле йөренә)*. И Ходаем, нишлибез инде хәзер? Әни үзе беләме соң?

Гөлсем. Үзендә шундый авыру барлыгын әбигә әйтергә ярамый, апа.

Инсаф. Операция ясатсаң?

Гөлсем. Операция ясаудан узган, абый... Авылга җибәрмәгез инде сез аны. Берүзе бит ул анда, су алып бирер кешесе дә юк.

Ислам *(гаять дәрәҗәдә уйга калып)*. Йогышлы түгелме бу авыру?

Гөлсем. Бу авыру йогышлы түгел, курыкмагыз.

Пауза.

Максуд. Нишлибез соң инде хәзер? Ислам! Булмаса, син бүген әнине машинаңа утырт та үзеңә алып кайтып тор, ә иртәгә...

Зөләйха. Сабыр итегез! Әниегез арып юл килгән кеше, йокласын. Егерме биш ел больницада медсестра булып эшлим, гозерем төшкәндә кире какмыйлар иде. Заведующий белән сөйләшеп, мин аны иртәгә үк больницага салып куйыйм. Тагын бер тикшергәннән зыян булмас, дип уйлыйм. Инде яшьләр турында уйларга кирәк. Ни генә булмасын, аларның беренче кичләре. Минемчә, кайсыгыз да булса яшьләрне үзенә алып китсә, яхшырак булыр.

Сәяр. Без беркая да бармыйбыз.

Расиха. Ай Алла, сәгать унынчы киткән! Ислам, кайтырга вакыт! Кайда, үзебезнең өлеш күкәйләрне ала китим әле!.. *(Чемоданнан сумкасына күкәй тутыра башлый.)*

Саимә. Санап азапланма, ал да кит бөтенесен!.. Бик кызык ягыгыз белән ачылып киттегез бит әле сез...

Ислам. Ә без теләсә кайсы ягыбызны ачып күрсәтергә можем! Әйдә, кызым!

Расиха. Ярый, сау булыгыз... Безгә дә килеп утырыгыз, Сәяр!

Ислам, Расиха, Рәйхан чыгалар.

Саимә. Миңа да китәргә вакыт. Сау булыгыз!

Максуд. Рәхмәт, сеңлем! *(Гөлсем чыга.)* Сәяр, әйдәгез безнең белән!

Сәяр. Без беркая да бармыйбыз! Барыгыз, китегез! *(Инсафка.)* Ә син, абый?

Инсаф. Мин бүген больницага кереп ятарга тиеш идем...

Сәяр. Ярый, ят. Без монда синнән башка да эшләрбез, ят!..

Максуд, Саимә, Инсаф, Альфред һәм баянчы егет чыгалар. Зөләйха белән Әлмөхәммәт аларны озаткан арада, Сәяр моңаеп басып торган Риммага карап ала да янына килә.

Сәяр. Син бик борчылма әле, Римма. Күңелем һич ышанмый. Ышанасым килми.

Римма. Синең башка сүзең юкмы?

Сәяр. Бәлки әле операция ясарлар. Терелер. Кайгырма, Римма, тынычлан!

Римма. Идиот! Идиот!..

Римма башындагы фатасын салып Сәярнең битенә ыргыта, ике кулы белән йөзен каплап, кычкырып елый башлый.

Пәрдә.

Икенче пәрдә

Вакыйга шунда ук бара. Сәяр, өстенә җиңел пальто кигән хәлдә, тәрәзәдән карап тора. Римма керә.

Сәяр. Римма! Әнине бүген больницадан чыгаралар. Әйдә, тиз генә барып алып кайтыйк әнине!

Римма. Ә ни өчен моны без эшләргә тиеш? Без әле өйләнештек кенә. Син юньләп эшли башламаган! Кеше өендә торабыз! Безне берәү дә гаепли алмый.

Сәяр. Әнине больницага без илтеп салдык. Димәк, алып кайтучы да без булырга тиеш.

Римма. Мин бармыйм! Каравын да миннән башка эшли аласың икән — бар, алып кайт! Ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән. Үкенече калмаган...

Сәяр. Римма!!!

Римма. Нәрсә шулкадәр кычкырасың — синең өчен генә әниең үләме соң?! *(Сәяр, чалт иттереп, Римманың яңагына сугып җибәрә.)* Менә син нинди! Синең әле мондый һөнәрең дә бармыни?

Максуд белән Саимә керә.

Саимә. Нихәл, сеңлем!.. Нәрсә булды сиңа, авырмыйсыңдыр бит?

Римма. Тугыз бала арасында тормышның иң рәте-чираты булмаганы без. Ни өчен без карарга тиеш ул карчыкны?!

Саимә. Син дә әниең килене ич! Без инде үзебез картаеп барабыз, акыллым, үзебезне карарга вакыт җитеп килә.

Римма. Әгәр бүген үк берәрегез алып китмәсә, мин тормыйм! Китәм! *(Сулдагы бүлмәгә кереп китә.)*

Артта аяк тавышлары. Ананы култыклап, Сәяр белән Зөләйха керә.

Саимә *(каршы килеп Ананы култыклап ала).* Кайттыңмы, әни, җаным?!

Ана. Тотмагыз мине, тотмагыз, мин үзем дә йөри алам! *(Карангалап.)* Яшь килен кайда соң әле?

Саимә. Ә, юк, өйдә, әни... яшь килен теге якта...

Сәяр Римманы алып керә.

Ана. Исәнме, кызым!

Римма. Исәнмесез!

Саимә *(Римма янына килеп).* Х-хе, чәчемне матурлыйм дип, әнине каршыларга соңга калды!.. *(Артта ыгы-зыгы.)* Кемдер бар!

Ана һәм Риммадан башкалар ишеккә юнәләләр. Гөлчирә, Ислам, Расиха керә.

Ана *(Гөлчирәнең аркасыннан сөеп).* Йә, булды, булды, кызым. Утыр, сөйлә! Балалар исән-саулармы?

Гөлчирә. Олысын лагерьга җибәргән идек, әни,— лагерьга. Илдус атналык садикта, Рөстәм күрше карчыкта калды.

Ана *(Сәярдән).* Улым, апаңны бикәчең белән таныштырдыңмы соң?

Сәяр. Апа, менә таныш бул, бу — минем хатын!

Гөлчирә (Римма белән күрешеп). Гөлчирә!

Римма. Римма.

Гөлчирә. Кайтасым да кичә генә билгеле булды, юньле бүләгем дә юк. *(Бераз уйлап торганнан соң, бармагыннан йөзеген салып Риммага кидерә.)* Бәхетле булыгыз!

Римма. Рәхмәт!

Сәяр. Ярый, әни!.. Сине ялыктырырга ярамый! Әйдә, ятып ал! *(Гөлчирәгә күз кысып.)* Гөлчирә апа да азрак ял итсен.

Ана, Сәяр, Гөлчирә, Саимә уңдагы бүлмәгә чыгалар.

Зөләйха. Кухняга чыгып сөйләшегез, әнә тегендә! Әниегез азрак ял итсен!

Максуд, Ислам, Расиха кухняга таба китәләр. Сәхнә әйләнә. Безнең алда Зөләйха квартирасының кухнясы.

Максуд. Ишеттегезме, Сәярнең хатыны китәм, ди! Әнисен карыйсы килми!

Ислам. Хы-хы-хы!

Саимә, Гөлчирә керәләр. Гөлчирә өстәл янына утыра да битен кулы белән каплап елый башлый. Сәяр белән Римма керә.

Гөлчирә. Диагнозы дөрес булып чыктымы? *(Сәяр баш селки.)* Үләсен үзе сизә микән?

Сәяр. Әни врачына әйткән. Мине тикшереп азапламагыз, кызым, мин барыбер үләм, бу минем әҗәл авыруым, дигән.

Саимә. Сәяр! Ул бит хәлем әйбәтләнә дигән була!

Сәяр. Безне борчымас өчен генә! Сез әнине белмисез, аның табигате шундый. Үзенә авыр икәнлеген ул бервакытта да безгә әйтмәячәк.

Максуд. Ярый, туганнар! Әни юкта сөйләшеп алыйк әле. Нишлибез? Без карый алмыйбыз. Без үзебез кеше сараенда торабыз. Яшь киленнең карыйсы килми. Исламнар алмый!

Гөлчирә. Ни өчен?

Ислам. Чөнки мин үзем пенсионер. Хатын чирле. Ашказаны авырта.

Гөлчирә. Абый! Минемчә, әнине карау ул — бик зур честь, дәрәҗә...

Ислам. Алай бик зур дәрәҗә булса, ал да кит үзең белән Ташкентка! Честе дә, дәрәҗәсе дә үзеңә булыр!

Сәяр. Сәламәт чакта йөрмәгәнне, нишләп барсын инде ул шунда кадәр!

Гөлчирә. Бөтен союзга таралган бит аның туганнары да! Инсаф абыйны санап булмый.

Максуд. Инсафның башы больницадан чыкмый. Тагын Казан больницасында ята.

Гөлчирә. Апалар еракта. Хафиз абый белән Таһир абыйны да санап булмый.

Расиха. Тегесен санап булмый, бусын санап булмый, бер безне санап була! Ничава не знаю, бөтенесен дә санарга! Кайтып карасыннар чиратлашып! Кайтмасалар — кеше яллап карат-сыннар, акча түләп. Үзебезнең чират җиткәч, кемне дә булса без дә ялларбыз.

Гөлчирә. Акыллы сүз түгел, Расиха.

Расиха. Син генә бик акыллы!

Гөлчирә *(Исламга, ялварып диярлек)*. Абый! Әнине сез карарга тиеш!

Ислам. Ни өчен без? Сезнең карарга хәлегездән килмәгән өченме? Ярый ла мин хәзер Казанда! Ә кайтмаган булсам? Магаданский областьта калган булсам, нишләр идегез?

Гөлчирә. Менә мин дә шуны уйлап торам. Тормышның иң авыр вакытында син ун ел төрмәдә утырдың. Әти үлеп китте! Әни бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр колхозда эшли, ә хезмәт көненә бер грамм ипи бирмиләр. Әни коры сөяккә калды. Ачлыктан гына түгел, гаиләгә син күрсәткән хурлыктан да! Беләсеңме, әни синең өчен күпме яшь түкте? Хурлыктан урамга чыгарга оялган көннәре дә күп булды аның...

Ислам. Минем өчен хурланасы юк! Минем документла-рым чиста. Минем судимость снята!

Гөлчирә *(катгый)*. Шулай, абый! Язмыш синең кешеле-геңне сынар өчен тагын бер имтихан куя. Теге вакытта абын-гансың, инде дә абынма! Әйдә, машинаңа утыртабыз да алып кайтабыз әнине сиңа!

Ислам *(мескенләнеп)*. Шәфкатьсез кешеләр сез. Мин ничә ел төрмәдә утырдым, понимаешь. Төрмәдән чыккач, унбиш ел шахтада эшләдем! Якты кояшны күрмәдем! Инде, понимаешь, кайтып, бер кеше төсле яши генә башладым дигән идем — мә сиңа! Башка берәүләр булса әйтерләр иде, абый, син инде болай да рәхәт тормыш күрмәдең, тынычлап яшә инде диярләр иде!.. *(Үкереп елый башлый.)*

Зөләйха керә.

Расиха. Алып кайтмаска иде аны больницадан! Ник алып кайткан? Кем алып кайткан — әнә шул карасын!

Зөләйха. Оятсызлар! Берничә ай гомере калган әниегезне карамас өчен талашасыз! Кеше гомере буе да карый! Куалап чыгар үзләрен Сәяр, тормасыннар монда ачу китереп!

Чемодан күтәреп, Римма керә.

Римма. Болай булгач, мин принципиально китәм!

Зөләйха. Әй, китсәң китсәнә! Салып торып җибәрермен! Бар кит! Инкубатор чыгарган кияү эзлә! *(Римма чыга.)* Мин карармын әниегезне! Гомерем буе авыру карадым, үлмәдем. Тормагыз монда талашып! Ярып чыгарганны көтәсезме әллә?!

Пәрдә.

Өченче пәрдә

Вакыйга шунда ук бара. Ана ике кулы белән тәрәзә төбенә тотынган хәлдә урамга карап тора, өстендә туйда кигән ак ефәк күлмәк. Әлмөхәммәт алгы планда намаз укый.

Ана. Быел кыш үзен иртә күрсәтә, бабай,— кар ява! Урам ап-ак булды!

Әлмөхәммәт. Ап-ак булып озак тормый ла ул. Бездә монда кар җиргә төшеп өлгерми, пычракка әйләнә. Авылдадыр инде ул чын кар.

Альфред керә.

Альфред. Исәнме, әби!

Ана. Яхшы, улым. Үзең нихәл?

Әлмөхәммәт. Ярый, мин тегеләрнең бәлешләрен апап чыгыйм әле. Тәмле булса, сиңа да алып чыгармын.

Әлмөхәммәт чыга.

Ана. Хафиз абыеңнан хат-хәбәр юкмы? *(Альфред иңбашын селкетеп куя.)* Үзең ни эш бетереп йөрисең?

Альфред. Нормально! *(Машина тавышы. Ана, торып, тәрәзәгә бара башлый.)* Ул мин утырып килгән такси, әби!.. Әби! Синең бер биш сум акчаң юкмы? Әнә шул таксига түлисе бар иде.

Ана. Трамвайлар йөрмимени бүген?

Альфред. Әй, бер бик чибәр генә кыз бала бар, әби. Сәгать алтыда киногa барырга булган идек. Синең янга да килеп

өлгерәсе бар!.. Түләргә акча юк. Кошелёгым өйдә онытылып калган.

Звонок.

Ана. Хафиз абыең кайтып килмиме?

Альфред ишек ача. Инсаф керә. Кулында гади генә сумка. Ана белән кочаклашып исәнләшә.

Ана. Утыр, улым. Озак яттың да инде, улым, бальниста!

Инсаф. Туеп беттем, әни, үзем дә! Йә, нихәл соң инде, терелмисеңме әле?

Ана. Зыянлы түгел, улым! Сәярнең хатынын практикага җибәрделәр.

Альфред. Син нәрсә, әби, Римманы мин әле генә капка төбендә күрдем!

Ана. Син башка берәр кешене күргәнсең.

Инсаф *(Альфредка)*. Ну, синең эшләр ничегрәк соң әле, егет? Миңа акча кирәк булыр бит.

Ана *(Альфредның аптырап калуын күреп)*. Нәрсә, синнән дә алып тормагандыр бит?

Инсаф. Әллә синнән дә сорыймы?

Ана. Шушындый баһадир хәтле гәүдәң белән эшләми йөрисеңме, улым?

Альфред. Хәзер яшьләр сезнең кебек түгел шул, әби. Без башкачарак яшәргә яратабыз.

Ана. Күңел ачуны һәркем ярата, әмма күңел ачып булсын өчен эшләү кирәк. *(Инсафка күрсәтми генә акча төенчеген Альфредка төртә.)*

Альфред *(төенчекне тиз генә яшереп)*. Сау булыгыз! *(Чыга.)*

Максуд белән Саимә керә.

Ана. Үзегез генәме? Кайтучылар юкмы?

Саимә. Шушы көннәрдә Мәйсәрә кайтып төшәргә тиеш, әни.

Ана. Хафиз турында хәбәрегез юкмы дип соравым минем. Сәяр телефонга чакырам дип киткән иде, кайтмый да кайтмый...

Саимә. Ул бер кәтү баланы ничек үстереп бетердең икән син, әни? Безнең монда берсе белән дә башлар катып бетә. Унысын да кеше иткәнсең...

Ана *(тирән сулап)*. Унысын да булмады шул, кызым!

Саимә. Кемне әйтәсең, әни? Исламнымы?.. И әни, үз балаң булгач, нинди генә булса да яратыладыр күк ул миңа. Менә безнең Альфред... Чукынган малай, кайчак шулхәтле ачуларымны китерә, әни — барыбер яратам шуны.

Посылка күтәреп, **Сәяр** керә.

Ана. Сөйләштеңме абыең белән?

Сәяр. Хафиз абый өйдә юк, Халисә җиңги белән сөйләштем...

Ана. Әйт дөресен! Ни булган абыеңа? Авырыймы?.. Әллә яралаганнармы?.. Үтергәннәр? Күңелем сизгән иде!..

Сәяр. Хафиз абый исән-сау, әни! Командировкага җибәргәннәр аны.

Ана. Сөйләмәгез! Ул инде унике ел армия хезмәтендә, ун көннән ун көнгә хаты килмичә бер генә тапкыр да калмады!

Саимә *(Сәяр алып кайткан посылканы караган булып).* Һай, җаным, нинди бәхетле карчык син, әни! Посылканы яудырып кына торалар бит үзеңә!

Ана. Берни ашый алмаган әниләрен посылка белән күмделәр, үзләре кайтмыйлар!

Ислам, Расиха, Рәйхан керә. Рәйханның өстендә мәктәп формасы. Исәнләшү.

Ана *(Рәйханны кулы белән чакырып).* Кил, кызым!

Расиха. Юк-юк, әбисе. Рәйханга синең янга барырга ярамый! Грипп булган Рәйханга. Әбисенә грипп иярер дип курка ул.

Ана *(Расиханың Рәйханга сугып җибәрүен күреп).* Әллә балага суктың инде, Расиха?

Ислам. Суксын, әни. Бик иркәли башласаң, әнә абыйларның Альфреды кебек була ул аннары!

Саимә. Ник, ни булган безнең Альфредка?

Ислам. Булмаган! Миннән биш сум акча сорап кергән, таксига түлисе бар, ди.

Саимә. Бирдеңме соң?

Ислам. Нишләп бирим!

Саимә. Биш сумыңны алып Казаннан чыгып качар дип курыккансың шул!

Ислам. Йөрмәсен дуңгыз дагалап! Аңа бит утыз тулган!

Максуд. Барып чыкмады, әни, безнең малай! Бер-ике генә атна эшли дә ташлый, бер-ике генә атна эшли дә ташлый. Хатыны куалап чыгарды, алимент түләп тора!

Ислам. Милиция килеп эшкә керергә кушкач, Альфредны дворник итеп урнаштырган булганнар, әни! Ә Альфред себерми ишегалдын, эшкә киткәнче, абый белән Саимә себереп китә. Менә шул акчадан Альфредның малаена алимент тотып калалар инде, хы-хы-хы!

Саимә. Бик килешә инде, о! Балалы кешегә кеше баласыннан көлү ярамый ул. Әнә үзегезнеке үсә, аның кем буласын белгән юк әле!

Максуд. Әнисе яклап бозып бетерде, әни, Альфредны!

Саимә. Бер дә бозмаган! *(Елый-елый.)* Тик кенә торыгыз! Һай, җаным, менә сине кем бозды икән! Сугышка бармыйча качып яткансың! Кем өйрәтте соң сине шуны эшләргә? Әниме?

Ана *(битен куллары белән каплап)*. Аh!..

Сәяр *(Анасын кочаклап)*. Чыгып китегез! *(Максуд, Саимә, Ислам, Расиха, Рәйхан кухня ягына узалар. Аларга Инсаф иярә.)*

Пауза.

Сәхнә әйләнә. Зөләйха квартирасының кухнясы.

Инсаф. Кешедән оят! Тугыз баласы була торып, әни кеше өендә үлеп ята! Бөлүдән курыксагыз, түләгән булыр идек үзегезгә, акчалата!

Ислам. Төкерәм мин сезнең акчагызга! Теләсәм, мин әнине үлгәч кабергә куймыйча, акча белән күмеп куя алам! Сез минем өчен борчылмагыз! Әни миңа фатиха бирәчәк. Соңгы елларда, понимаешь, аңа миннән дә күп акча җибәреп торган кеше булмады. *(Кесәсеннән бер төргәк почта квитанцияләре чыгара.)* Менә! Менә болар бөтенесе соңгы унбиш ел эчендә әнигә мин салган посылкалар һәм акчалар. Менә, ай саен унбишәр, егермешәр сум салып барылган!

Саимә. Барсаң! Рәйханны әнигә кайтарып атканда сигез ай да тулмаган иде, әни шуны алты яшькә тиклем тәрбияләп үстерде. Бала караучы нәнкеләргә аена алтмышар сум түлиләр. Җибәреп бардыңмы соң әнигә алтмышар сум?!

Максуд *(Расиханың Рәйханга шап иттереп сугуын күреп)*. Нишләп көйсезләнә соң бу бала?

Расиха. Әни янына керәм дип аптырата! Кереп, әбинең башыннан гына сөеп чыгыйм әле, ди!

Саимә. Йогышлы авыру түгел ич ул, нигә котыгыз чыкты?

Расиха. Саклану зыян итми, Саимә апа! *(Рәйханга.)* Бар, әнә урамга чыгып уйный тор. Кара аны, әбиең янына керәсе булма! *(Рәйханны төрткәләп чыгарып җибәрә.)*

Максуд *(Инсафтан)*. Син Казанда озак буласыңмы әле?

Инсаф. Министр янына керәсе бар әле, машина алып булмый. Ватылып бетте инде. Яңасын сорап язган идем дә, чират җитми.

Ислам. Ничек инде чират җитми, понимаешь! Ватан сугышы инвалидларына почет зур лабаса аларга, хы-хы-хы!.. Әле менә гараж түбәсен капларга калай кирәк булды. Бер җирдә дә юк калай! Военторгка кереп, биш-алты орден колодкасы сатып алдым да күкрәккә кадап киттем райсобеска. Хы-хы-хы! Анда бер малай утыра икән. Бер кулны менә болай асылындырып барып кердем мин моның янына. Алдына пенсия книжкесен чыгарып салдым. Мине сугыштан кайткан берәр полковник дип уйлады бугай. Хы-хы-хы!

Расиха. Хә-хә-хә!

Саимә. Кайда соң бу дөньяда справедливость?! Син, Инсаф, сугышның башыннан ахырына кадәр йөреп ике аягыңны өздереп кайттың — инвалид машинасы ала алмый йөрисең. Ә дезертир булып йөргән кеше «Волга» машинасына утырып әйттерә!

Ислам. Справедливость? Тапкан сөйләргә сүз — справедливость! Эзләмәгез сез аны! Менә син ничә яшьтә инде, абый? Күпме булачак инде синең пенсияң? Җитмеш сумнармы? Ә үзең сугышта булдың! Мин бармадым сугышка, шуның өчен төрмәдә утырдым. Төрмәдән чыккач, унбиш ел шахтада эшләдем дә горняцкий стаж белән илле яшьтән пенсиягә чыктым. Үзем шул унбиш ел эчендә бер мәртәбә дә шахтага төшеп карамадым! Хәзер менә аена йөз егерме сум пенсияне алып, түшәмгә төкереп ятам, понимаешь! Менә сиңа справедливость! Эзләмәгез сез аны!

Инсаф. Ә мин әйтәм, бар ул справедливость! *(Көч белән Исламга китереп суга.)* Менә ул справедливость! *(Тагын суга.)* Менә ул справедливость, гад!.. *(Ислам идәнгә ава, Инсафны Максуд белән Саимә килеп тота.)* Әле син без фронтовиклардан көлеп маташасыңмыни? Син бит, сволочь, безнең җиңелүне теләп яткансың! Әгәр дошман Казанга килеп җитсә, син бит фашист ялчысы булачак кеше идең, падла!

Ислам. Минем судимость снята! Минем документларым чиста! *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә күрәсеңме? Җавапка тарттырырга да күп алмам!

Инсаф *(Исламның кәгазен ертып)*. Тарттырып кара мине җавапка!

Ислам *(идәндәге кәгазь кисәкләренә ташланып)*. Минем судимость снята дип яздырып алган справкамны ертты! Үтерәм бит мин сине моның өчен, галах!

Инсаф. Әтәчләнмә! Син мине үтерә алмыйсың! Мине үтерсәң, синең үзеңә үлем җәзасы булачак бит, ә син моннан куркасың!

Сәяр керә.

Сәяр. Әни йокыга китте... Бүген мин Халисә җиңги белән сөйләштем. Сугышчан заданиене үтәгән вакытта, Хафиз абый һәлак булган...

Сәхнә әйләнә башлый. Рәйхан күренә. Ана яткан бүлмәгә таба бара. Ул акрын гына Ана янына килә дә тиз генә Ананың башыннан сөеп ала. Йөгереп ишеккә бара, кухнядагы тавышларга колак салып тора: яңадан Ана янына килә, яңадан Ананы сөя башлый. Ана күзләрен ача. Рәйхан читкә йөгерә.

Ана. Ник анда качтың, кызым? Кил яныма! Кил инде, бер сөйим әле үзеңне!

Рәйхан. Синең янга барырга ярамый!

Ана. Ник?

Рәйхан. Синдә рак бар!

Ана. Кем әйтте?

Рәйхан. Әти әйтте. Әни дә әйтте.

Ана *(үзен кулга алып)*. Миндә рак юк, кызым! Әтиең сиңа дөрес әйтмәгән. Кил!

Рәйхан *(кулларын җәеп йөгерә-йөгерә)*. Әбием, алайса, син үлмисең! *(Ананың итәгенә сикереп менеп, муенына урала.)*

Расиха йөгереп керә.

Расиха. Рәйхан! *(Йөгереп Рәйхан янына килә башлый, ләкин Ананың Рәйханны күтәреп тора башлавын күреп, кото чыгып кире йөгерә.)* Ислам! Ислам! Кер әле тизрәк, Ислам!..

Бүлмәгә Ислам, Максуд, Саимә, Сәяр һәм Инсаф керәләр.

Ана. Минем йогышлы авыруым юк, мин врачтан сорап чыктым.

Расиха. И әни, карт кешедә йогышлы авыру булса да гаеп түгел инде. Сакланганны саклармын, дип әйткән бит Алла. Бала җәл бит...

Ана. Бала җәл була шул ул. Егерме беренче елның көзендә балалар арасында тамак чире чыкты, минем дә бер балама

йокты. Эт тә чыкмаслык бер кичтә баламны төреп күтәрдем дә авылдан илле чакрымдагы Тәтеш бальницасына киттем. Бөтен бальницаларына бер сестра. Күп-күмгәк булган баламны ачып кына карады да, бу баланың җаны чыгасы гына калган, ярдәм күрсәтүдән узган, диде. Баланда дифтерит, кара аны, берәр җиргә кермә, югыйсә башкаларга да дифтерит ияртерсең! — дип кычкырып калды. Кайтырга чыктым. Ярты юлга җиткәч, балам гаргарәгә[1] килде. Көчкә тын ала. Нишләп болай авыр сулый соң бу бала, әллә тын юлына берәр нәрсә кергәнме? — дип, авызын ачып карасам — авызы тулы лайла! Менә ни өчен!.. Аптырагач, баламның авызына авызымны куйдым да шул лайланы суырдым!.. Ничек өйгә кайтып җиткәнемне белмим. Үпкәм кабарудан савыга башлап аңыма килгәндә, балам инде йөгереп йөри иде!

Расиха. И, менә бит! Кайсы балаң иде ул, әни?

Ана. Ул бала — синең ирең. Мин аңа ике мәртәбә тормыш бүләк иттем. Шуңа ул әнә шулай яхшы булып чыкты, тугач та миндәр каплап үтерәсе нәрсә!..

Ислам башын түбән иеп чыгып китә.

Расиха. И, алай димә инде, әни! Вакыты җиткәч, барыбыз да үләрбез!

Ана. Ул инде минем өчен күптән мәет. Аналар өчен балалар шулай. Кайберләре вафат булсалар да, мәңге исән, чөнки алар намус белән үлгән балалар. Кайберләре икмәк черетеп яшәсәләр дә — мәет!

Инсаф. Әни, сиңа борчылырга ярамый! Ятып тор, әни!

Ана. Мин бик күп яттым инде, улым, алда — ятасыларым тагын да күп. Менә сез өч айдан бирле минем белән курчак уены уйныйсыз. Сәярнең хатыны нинди практикага киткәнен дә, ни өчен кеше өендә ятуымны да, авылга ник җибәрмәвегезне дә — барысын да беләм бит мин. Ана кешенең колагы ишетмәсә, йөрәге ишетә... Минем күп яшисем калмады. Васыятем шул: кеше булыгыз! Куркак җан булудан сакланыгыз! Кеше куркак булса, үзенең җанын саклап калу өчен, теләсә нинди түбәнлеккә бара. Атасын да, Анасын да, Ватанын да сата!

Пәрдә.

1968 ел

[1] Гаргарәгә килде — гырылдый башлады.

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз.

Йомгак

Гамил Афзалның лирик герое кебек, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин, Шәриф Хөсәенов пьесаларындагы персонажлар да үз-үзләре белән конфликтка керәләр. Бу эчке конфликтларның барысы да әхлакка нигезләнгәннәр. Лирик геройларының рухи халәтен гомумиләштереп, Гамил Афзал: «Арыслан ята күңелдә, Кулымда куяным бар»,— ди икән, бу кыска гына шигырендә лирик героеның үзен үзе аңлау дәрәҗәсенә җитүе, үзен икейөзле кеше итеп бәяләве турында яза. Лирик герой үзенә үзе әхлак кануннарыннан чыгып кире бәя бирә һәм хатасын төзәтергә көче җитмәгәнгә хәсрәтләнә.

Хәй Вахит белән Туфан Миңнуллин персонажлары да — үзләрен үзләре аңлаган кешеләр. Алар да күңелләрендә арыслан яшереп ятулары өчен борчылалар. Шәриф Хөсәенов исә шул ук теманы башкача чишә. Аның герое гаделсезлек белән килешеп кенә калмый, шуның белән горурлана һәм мактана да.

Күңелдә яткан арысланны ничек уятырга? Арыслан бит ул — кешеләрнең тирә-юньдәге хаксызлыкны, гаделсезлекне, ялганны күреп эчтән генә ачулануы, ризасызлыгы. Ә кулдагы куян — тыштан елмаю, хаксызлыкка күз йому, гаделсезлекне гаделлек дип санау, ялганны башкалар белән бергә хакыйкать дип сөйләп йөрү. Ничек итеп үзең белән үзең ризалашып, эчтән елап, тыштан көлеп яшәүдән арынырга? Әсәрләрдәге уртак проблема шундый. Аны әдипләр төрле кешеләрнең бәгырен ашаган, аларны бәхетсез иткән төп сәбәпләрнең берсе итеп күрсәтәләр.

Кешеләрнең ялган белән килешеп яшәүләрен һәм шуның белән горурлануларын язу идеологиянең асылын фаш итү иде.

Сибгат Хәким
(1911—1986)

Сибгат Хәким (Таҗи улы Хәкимов) 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның Арча районы Күлле Киме авылында туа. Үз авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый, Казанга килеп, Татрабфакка укырга керә. Икенче курстан аны Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчерәләр. Укуын тәмамлагач, Татарстан дәүләт нәшриятында бер ел мөхәррир, аннары «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1941 елның июнендә шул эшеннән армиягә китә. Хәрби курслар тәмамлагач, 1942 елдан алып дошманнарга каршы башта взвод, аннары рота командиры булып сугыша.

1944 елның язында Сибгат Хәкимне тагын хәрби курсларга җибәрәләр. Курслар тәмамлангач, 1946 елга кадәр Молдавиядәге чик буе гаскәрләрендә хәрби газетада эшли.

Аннан Казанга кайтып элеккеге урынында, «Совет әдәбияты» журналында эшләп алгач, иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Беренче шигырьләрен төрле газета-журналларда бастырып килә һәм, шул әсәрләрен туплап, «Беренче җырлар» исемле китабын чыгара. Сугышка кадәр язылган бу әсәрләренең күбесен шагыйрь Габдулла Тукайга багышлый. Тукай яшь шагыйрьне яшьлеге, кыюлыгы белән дә, фаҗигале язмышы белән дә кызыксындыра. Сибгат Хәким бөек шагыйрь иҗаты-

ның сәяси тирәнлегенә, андагы сатираның үткенлегенә соклана. Тукай шигыренең төгәллегенә, һәр сүзенең мәгънәлелегенә чын күңелдән гашыйк була. Тукайны ул гомере буена ярата, аңа багышлап дистәләрчә шигырьләр һәм поэмалар иҗат итә.

Сугыш еллары әдипнең дөньяга карашын нык үзгәртә. Күпләр сугышта үлү бәхете турында язганда Сибгат Хәким үз күзе белән күргән сугышны тасвирлый. Үлемне көн дә күргән кешеләрнең күңелләре ката, ләкин аңа гадәти бер вакыйга итеп карый алмыйлар. Шагыйрь дә моның белән берничек тә ризалашмый. Сугыштан әдип үз хакыйкате белән кайта һәм сугыш темасын язуны дәвам итә.

Сугышта алган авыр тәэсирләрне басар өчен, тормышның үзеннән ниндидер юаныч табарга кирәк иде. Бу юаныч аның өчен туган ягы булды. Сибгат Хәким туган як табигатенең матурлыгы, кешеләр арасындагы җылы мөнәсәбәт, мәхәббәт турында күп санлы шигырьләр язды. Ул шигырьләрнең күбесе хәзер дә җыр булып җырлана. «Фазыл чишмәсе», «Белсәң иде», «Казакъ дусларга», «Гел кояшка карый тәрәзәләрең», «Сез һаман бергә икән», «Кем уйлаган», «Башка берни дә кирәкми», «Бер тауда ун чишмә» җырларының авторы да — Сибгат Хәким. Алар күптән халык җырлары булып киттеләр.

ДИҢГЕЗ КҮЗЕ

Өзек

(Легенда)

Еш кына мин шулай:
Ташый да дәртләрем,
Актара башлыймын
Күңелем дәфтәрен.
Анда бар уйларым:
Сөюнең сагышы,
Йокысыз походлар,
Илемнең язмышы —
Барысы бер моң булып
Саклана һәрчакта.

1955 ел

ӘЛЕ ҺАМАН КУРКЫП УЯНАМЫН

Әле һаман куркып уянамын
Төшемдә мин төшеп әсиргә.
Нигә мине әзәрлекли сугыш,
Саныймы ул таза, яшь иргә?

Тулы килеш яшьлегемне салдым,
Күпләр хәтта салды башларын...
Нигә мине әзәрлекли сугыш,
Шулмы җитми, шулмы аз тагын?

Сугышсыз бер илле ел яшәүне
Нык беркеткән идем хыялга...
Нигә мине әзәрлекли сугыш,
Әйтерсең лә хаксыз мин ялга?

Хафалана, беләм, борчыла җир,
Еш уята мине ул, дәшеп...
Җан урынында түгел, җир үзе дә
Килә төсле яңа урнашып.

1961 ел

ҮРЛӘРЕҢНЕ МЕНГӘЧ

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Рәшәң белән битем юдың син,
Һәрвакытта бергә уртаклаштың,
Уртаклаштың барын-югын син.

Үрләреңне менгәч, туган ягым,
Әкрен дәшеп, мине туктаттың...
Бар җылысын тоеп ятармын күк
Үлгәч тә мин синең туфракның.

1965 ел

ӘЙ МӘКТӘБЕМ

Әй мәктәбем, очкан оям минем,
Үз оясын һәрбер кош табар...
Бик ерактан күренсен дип, үргә
Юри салган сине осталар...

Озак уйлап бер сүз әйткән алар:
Монда укыр кеше, бел шуны;
Дүрт ягында — дүрт олы юл әнә,
Дүртесе дә булыр борчулы...

Дүрт ягында — дүрт озын юл ята,
Тәрәзәләр синең томанлы;
Кайчан гына кайтмыйм, үрдән миңа
Шул сагышлы күзләр төбәлде.

1965 ел

ЧӘЧКӘЛӘР

Никадәрле матур булмасыннар,
Гүзәл булмасыннар чәчкәләр,
Чәчкәләр дә күтәрелеп карый,
Исемнәре белән дәшсәләр...

1964 ел

ҖЫЛЫ СҮЗ

(Конюх авызыннан)

— Әйтә алмыйм йоклады дип атлар,
Борыннарын төртеп солыга,
Бары белән ач итмәдем, ләкин
Үз вакытында бирдем суны да.
Председатель үзе йөргән ат бу,
Артык кума, утыр, кил, энем!
Алай-болай булса, түләр өчен,
Туфрагы да җитәр Кименең.
Мин колхозда утыз еллап конюх,
Тай ат булды минем аркада.
Оныталар, энем,
Кайчагында
Бер җылы сүз кирәк атка да...

1956 ел

БЕР БӘЙГЕДӘ КҮРГӘН ИДЕМ АНЫ

Бер бәйгедә күргән идем аны,
Килә иде алмачуарда.
Кычкырдылар юлны яклап:
Каула, солдат, алга чыгарма.

Күргән кешем бер аяксыз иде...
Һәр адымда яшерен сер тора;

Ник җилкенде икән? Бик әз генә
Эләккән ул атның сыртына.

Атына дәрт биреп, куәт биреп,
Килә җилпеп сыңар канатын.
Эзли кебек фронт юлларыннан
Ул үзенең сынган канатын...

1962 ел

КОЧАГЫНА АЛСЫН, КАЙНАТСЫН

Аргач, кайчак бер читкәрәк китәм,
Җаным бераз сулу алсын дим...
Зур диңгезнең — халык тормышының
Ишетеп торам ләкин тавышын мин.

Ярга ничек бәрелүеннән аерам
Дулкыннарның зурын, вакларын;
Барын тоям, барысы үтеп керә
Коймалары аша капканың.

Булмый икән җанны биклап куеп,
Баш очында тыныч ай батсын...
Мең борчулы шул тормышым тизрәк
Кочагына алсын, кайнатсын.

1961 ел

КАМЫЛ

Әллә ничек әрнеттереп шунда
Кыштырдавын тойдым камылның;
Туган җирнең ялганмыйча яткан
Кылларына гүя кагылдым.

1955 ел

ТӘРӘЗӘ РАМНАРЫ

Гыйльметдин ясый ул
Тәрәзә рамнары.
Керә дә утыра
Авылның таңнары.

Уздыра остасын
Казанның, Өфенең...
Керә дә утыра
Шул килеш офыгың.

Томалый кайвакыт
Күңелсез бураннар...
Язларны алдан ук
Сизәләр бу рамнар.

Иртән моң иң элек
Кагыла рамнарга,
Кагыла рамнарга,
Тик кирәк аңларга.

Гыйльметдин эшли ул,
Уйлый ул күп нәрсә...
Калтырый бу рамнар,
Күк кинәт күкрәсә...

Елмайсын иде бер
Бар дөнья аннары:
Ник шунда шатлыктан
Шартламый рамнары...

1963 ел

ЕЛГАНЫҢ БОРЫЛГАН ТӨШЕНДӘ...

Г. Халиткә

Елганың борылган төшендә,
Бик хәтәр төшендә елганың
Тал тора, таза бер тал тора,
Еламый, көтмә син елавын...

Ташыган язгы су бозлары
Шул талга бәрелгән, сугылган,
Зур бозлар кысканнар — иңрәгән,
Кайчакта җиргәчә сыгылган.

Җилкәсе суелган, күп түзгән
Калын, киң җилкәсе яралы,
Яшәгән шушында, үстергән
Шушы җир һәм шушы яр аны.

Тамырдан төрле чүп, тамырлар
Ачылган, яфракка ярлы ул...
Күпме ел ярүзе саклаган,
Саклаган куркыныч ярны ул.

Елганың борылган төшендә,
Тугайда чәчәкләр-сабыйлар
Ишәя яз саен, тик талга
Нигәдер бер күз дә салмыйлар.

1965 ел

Безнең максат — Сибгат Хәким иҗатына бәя бирү. Моның өчен әдипнең барлык әсәрләренә анализ ясап чыгу бик яхшы булыр иде, ләкин бу эш мөмкин түгел. Шуңа күрә әдип иҗаты турында, гомуми фикер әйтү өчен, төрле елларда төрле темаларга язылган берничә әсәрен сайлап алдык һәм шул әсәрләр арасындагы бәйләнешләрне табу белән чикләнербез. Әмма әсәрләргә анализны төрле максат белән ясыйлар. Анализ нәтиҗәсендә әдипнең дөньяга карашын, яраткан темаларын, аны борчыган проблемаларны, стилен өйрәнергә мөмкин.

Без өйрәнәсе проблема билгеле: безне шагыйрь иҗатындагы кеше һәм тормыш мөнәсәбәте кызыксындыра. Эшкә керешкәнче, бирелгән теманы ачыклый төшик һәм ваграк сорауларга таркатыйк: Сибгат Хәким әсәрләрендә лирик герой тормышка нинди бәя бирә? Үз-үзенә нинди бәя бирә? Лирик герой бәясе белән автор бәяләре арасында каршылык юкмы?

Биремнәр

1. Сибгат Хәким иҗатына бәя бирең инша язачакбыз. Язачак иншагызның темасын уйлагыз.

2. Үзегез тапкан темага иншагызның планын төзегез һәм шуңа нигезләнеп инша языгыз.

Равил Фәйзуллин
(1943 елда туган)

Равил Габдрахман улы Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Татарстанның Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Котлы Бүкәш авылы мәктәбен тәмамлагач, Казан университетының тарих-филология факультетында белем ала. Армиядә хезмәт итә. Аспирантурага укырга керә. Бу вакытта инде Равил Фәйзуллин үзенчәлекле стиль белән иҗат итүче, фәлсәфи фикерле шагыйрь булып танылырга өлгерә. Шуңа күрә аны Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасына җитәкче итеп җибәрәләр. Аннан кайткач, Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре вазифасын башкара.

Равил Фәйзуллин «Аҗаган», «Монологлар һәм диалоглар», «Мәрмәр», «Гадиләргә гимн» исемле шигырь җыентыклары белән әдәбиятка килеп керә һәм шуннан соң күп санлы китаплар бастырып чыгара.

Равил Фәйзуллин беренче шигырьләрен мәктәптә укыганда ук яза башлый. 60 нчы елларда «Казан утлары» журналында «Нюанслар иле» исеме астында ике-өч кенә юллы шигырьләрен бастыра. Бу шигырьләрнең рифмалары да, ритмик тәртипләре дә булмый. Гомумән, алар без күнеккән шигырьләргә охшамыйлар. Шигырьләрнең үзенчәлеге — метафоралардан оста файдалануда. Дөресрәге, яшь шагыйрь метафора булырлык образ таба да аның бер ягын күрсәтеп куя. Бу образ-метафора мәгънәсен ачарлык вакыйганы укучы үзе уйлап табарга тиеш була. Берәүләр — бер эчтәлек, ә икенчеләре бүтән эчтәлек табалар.

Соңрак шагыйрьнең газета һәм журналларда, ел саен диярлек чыгып килгән китапларында дистәләрчә шигырь һәм

поэмалары дөнья күрә. Бу шигырьләрендә автор метафора була алырлык сурәтләр таба алу осталыгын тагын бер тапкыр исбатлый.

Равил Фәйзуллинның шигырь китаплары бер-бер артлы дөнья күрделәр. Аның шигырьләре немец, француз, поляк, гарәп, рус, башкорт, кыргыз, азәрбайҗан, чуваш, литва, эстон, грузин телләренә дә тәрҗемә ителеп басылып чыктылар.

* * *

Халык әле кышта яши.
Миндә яз инде күптән!
Зилзилә буран эченнән
зәңгәрлек күрәм күктә.

Таңнарда уята мине
кыр казлары тавышы.
Ни җан белән кумак кирәк
күңелгә кергән язны!

Үзем теләп кертәм аны,
каршысына йөгерәм...
Иртә чишенгән җанымның
туңачагын да беләм.

Кешеләр сәерсенәләр:
бу суыкта кем яна!
Бәлки, сәер язым белән
бәхетле мин — дивана!

Халык әле кышта яши.
Миндә инде яз күптән!
Тау көртләр ерып килүче
зәңгәр бәхетемне көтәм.

1973 ел

Шигырьнең эчтәлеге. Лирик герой өметенең тормышка ашуына чын күңелдән ышана. Аның өмете — бәхет. Шуңа күрә өметенә ышаныч тудырган шатлыкның да чиге юк. Шигырьне беренче кат укуда күзгә ташланган эчтәлек шундый. Тагын бер кат игътибар белән укыйбыз һәм әсәрнең каршылыкка корылганлыгын абайлыйбыз. Лирик герой күңелендә яз, ә урамда кыш. «Халык әле кышта яши» дип эдип ике мәртәбә кабатлый. Зилзиләле буран, урамда кар көртләре, ди.

Күңел язын ачыклыйбыз. Күңел язы дип автор лирик геройның шатлыгына әйтә. Ә шатланыр сәбәп бирәү генә. Нәрсәнедер өмет итү, нәрсәгәдер ышану. Лирик герой өметенең тормышка ашмавын да белә, ләкин барыбер өметләнә. Һәм шул өмете белән яши. Алай гына да түгел, хәтта шатлана да. Өмете булганга шатлана.

Хәзер безгә өметнең ни булуын ачыкларга кирәк. Соңгы юлда әйтелгән җавап — бәхет — безне канәгатьләндерми. Бәхет — яз кебек үк гомуми сүз. Башка юлларга күз салыйк. «Буран эченнән зәңгәрлек күрәм күктә»,— ди Равил Фәйзуллин. Соңгы юлда тагын кабатлый: «Зәңгәр бәхетемне көтәм»,— ди. Күк зәңгәрлеге ул аяз көн, яктылык, җылылык, кояш булуын белдек.

Күктәге зәңгәрлек лирик геройның беренче мәхәббәте түгелме? Аннан да зуррак бәхет буламы?

Бәлки, тормыштагы кышлар, бураннар бетүенә өмет өзеп, лирик герой үз бәхетен үзе уйлап чыгаргандыр да шуны түземсезлек белән көтәдер. Равил Фәйзуллин 1973 елда ук тормышка зилзиләле буран, тау көртләре дип бәя бирә. Үзенең шул тормыш салкыныннан котылып, хыялында гына булса да яз дөньясында яшәп калуы турында сөйли. Шуңа күрә лирик герой шатлыгының сәбәбе күңел дөньясы, бик зур теләк, өмет тудырган хыял дип нәтиҗә чыгарабыз. Хыялны чын итеп сурәтләгән әсәрләргә романтик әсәрләр дигән идек. «Халык әле кышта яши...» шигыре дә романтик рухта язылган дияргә хакыбыз бар.

Яз лирик геройда көтмәгәндә уянган мәхәббәтме, әллә күңел тудырган башка дөньямы? Әйдәгез, метафораларның эчтәлеге чиксез була дигән кагыйдәне искә төшерик. Җавапларның берсен дә инкарь итмик.

* * *

Башны салларга салып
китәсе иде агып...

Бер күңел булыр иде!
Шатлыгым ургыр иде,
йә сыктап сулгыр идем.

Башны салларга салып
китәсе иде агып.
Дәшер иде әле дулкыннар
бер шагыйрь җанны танып...

Сентябрь, 1966 ел

Биремнәр

1. «Халык әле кышта яши...» шигырендә кыш-яз метафорасының мәгънәләре ничек ачыла? Мәгънәле урыннарын табыгыз.

2. «Башны салларга салып...» шигырендә салларга утырып ялгыз калу белән юану табарга тырышу бар. Хис дәрәҗәсе бар. Хиснең сәбәбе юк. Сәбәпне ничек табабыз?

3. Равил Фәйзуллинның лирик герое урынына үзегезне куеп карагыз, салда үзегез агып барасыз итеп күз алдына китерегез. Сез үзегезнең теләсә нинди хисегез яки теләсә нинди хәбәр турында яза аласыз. Әмма үзегез яки нинди дә булса күренеш турында язганда, һичшиксез, агып баручы салны метафора итегез, аның сыйфатларын бәя бирү өчен һәм эчтәлек арттыру өчен файдаланыгыз. Язмагыз мәкалә дә, хикәя дә, шигырь дә булырга мөмкин.

* * *

Вулканнар бар диңгез төбендә,
Әллә ниләр кайный күңелдә.
Бар җиһанга яр саласы ла!..
Ярар, сабыр, калсын бүгенгә.

Иртәгесен иртүк уй туа:
«Без бит бу дөньяга ир туган!
Ярыл, фикер! Чишел, тойгылар!
Чыгарып сал, башка ни тулган...

Кичен янә шәфәкъ күгендә,
әллә ниләр сызлый күңелдә.
Ирексездән иреннәр көйли:
Янартаулар — диңгез төбендә.

Гыйнвар, 1966 ел

Шигырьнең фокусы. «Янартаулар диңгез төбендә» юлы ике мәртәбә — баштан да, ахырдан да кабатлана. Ике мәгънә белән, төп өлешкә метафора булып килә. Шигырьнең бөтен эчтәлеген үзенә җыеп тора. Шуңа күрә бу сурәткә шигырьнең фокусы дибез. Төп өлешнең эчтәлеге безгә башка әдип әсәрләреннән таныш: хакыйкатьне ачып саласым килә, ләкин куркам, ди лирик герой. Конфликтлы кичерешен үзе әйтеп бирә. Метафора-фокус шул конфликтның кискенлеген, кичереш дәрәҗәсен һәм даимилеген күрсәтә. Диңгез төбендәге янартаулар ялкыннарын диңгез төбендә сүндерәләр. Аларның дәһшәтле куәте су астында биек-биек таулар ясый ала. Әмма кеше күзенә күренми. Төптәге ут тышка чыкмый. Бәлки, бервакытта да чыкмас. Лирик геройны менә шул борчымыймы?

Бирем

Шигырь эчтәлеген алда өйрәнгән ике шигырь эчтәлегенә ничек бәйләп була? Сөйләгез.

ҖИЛФЕРДӘҮЧЕ КЕРЛӘР ҖЫРЫ

Без елый белмибез
Авыр булсак та,
яшькә мул булсак та,
елый белмибез.

Без җырлыйбыз бары:
җилфердәп торсак та,
кыштырдап куйсак та,
бары җырлыйбыз.

Без сансыз күптөрле,
ә җырыбыз — бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел.

Без бик күп төслеләр.
Безнең арада —
бар сары, алы да...
Төсен җуйганнар да,
манылганнары да...

Безне киючеләр —
кешеләр төрле.
Үзләре кебек үк
җырлары төрле.

Безнең җыр — мәңгелек,
безнең һаман бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел.

Пуля тишә безне,
сода кисә безне...
Юк, сыкрану түгел,—
әйтү бу сүзне.

Кешеләр мәңгегә
киткәндә бездән,
яшь агызып түгел,—
кул болгап калабыз,
җырлап калабыз.

Без авыр булсак та,
яшькә мул булсак та,
елый белмибез,—
бары җырлыйбыз без.

Ә җыр һаман бер:
Кояш турында гел,
Җил турында гел...

1965 ел

Шигырьнең ике эчтәлеге. Эчтәлекнең берсе, күзгә ташланып торганы — җилфердәүче керләр. Алар әлегә юешләр, җилдә, кояшта кибәләр, шуңа күрә аларның бар белгәне — җил белән кояшка дан җырлау. Керләрне содаларга салып юалар, төрле төсләргә маналар. Аннары алар тагын җилфердәп кояш белән җилгә дан җырлыйлар.

Эчтәлекнең икенчесен абайлау җиңел, әмма табу өчен шактый эш эшлисе бар әле.

Равил Фәйзуллин безнең эшне җиңеләйтә. Табышмак төзегән кебек, кер сыйфатларына кергә хас булмаган кеше сыйфатларын куша. Аларның күз яшьләре дә бар, алар җырлыйлар, кул болгыйлар, озаталар. Автор үзе әйтеп тора бит, керләр — кешеләр, ди. Шуңа күрә кер сыйфатларының кешегә ятымлы сыйфатларын, ягъни мәгънәләрен эзлибез.

Шигырьнең исемен уку белән уйланырга мәҗбүр булабыз. «Җилфердәүче», ди Равил Фәйзуллин. Бауга эленгән түгел, нәкъ менә җилфердәүче керләр. Бу сүз артыннан нинди сүз килгәнен укучы бик яхшы белә. Җилфердәүче флаг, әләмнәр әллә кайчан фразеологик әйләнмәгә әверелгән иде инде.

Бер төшенчәгә очрап, шунда ук аңа бәйле башкасын искә төшерүгә *ассоциатив бәйләнеш* диләр.

Ләкин без көткән әләм урынында кер сүзен күреп, шунда ук бу сүзнең ике мәгънәсен искә төшерәбез: юылган кием-салым һәм пычрак. Бу ике эчтәлекнең мәгънәсе шигырьдәге башка образлар бәйләнешендә генә табыла ала.

Шигырьнең кабатланган урынына игътибар итәбез. Җыр кабатлана. Керләр гел бер җыр җырлыйлар, кояшны, җилне мактыйлар. Бүтән берни белмиләр. Уйга калабыз: җил белән кояш керләрне киптерә. Ә юешлек шигырьнең үзендә күз яшьләре диелгән. Димәк, керләр үзләрен киптергән, еламаска өйрәткән җир белән җилгә дан җырлыйлар. Киптерү ул керләр өчен яхшы, әмма керләрнең мәгънәсе башка икән, мәңге еламаслык итеп, ягъни кызгану хисен, кайгыру, шатлану хисен бетерү кешеләрдән карачкы ясау була. Шулай булгач, ни өчен керләр үзләрен киптерүчеләргә дан җырлыйлар?

Хәтерне эшкә җигик. Шигырьнең башында ук ассоциатив бәйләнеш булгач, бәлки, уртасында да эчтәлек шундый бәйләнеш белән табыладыр. 60—70 нче еллар укучысы кояшның яз китерүче, матур киләчәк символы булуын яхшы белә. Һади Такташ иҗатын яки Хәсән Туфан шигырьләрен хәтерләгән укучылар бу әдипләрнең кояш белән җилгә нинди мәгънәләр бирүен шулай ук яхшы беләләр. Кояш белән җил бер үк вакытта начар да, әйбәт тә булып чыга.

Безне беренче чиратта керләр мәгънәсе борчый. Без аларны кешеләргә охшатып киттек. Әмма нинди кешеләр? Анысына җавап таба алмадык. Шигырьгә әйләнеп кайтыйк. Анда керләрдән башка тагын кешеләр дә бар.

Шигырьдә кешеләр турында: алар да төрле дип әйтелә. Ләкин, керләрдән үзгә буларак, кешеләрнең үз җырлары бар.

һәркемнең үз җыры. Тик алар үз җырларын җырлыймы соң?

Күрәсең, җырлый алмыйлар. Чөнки кешеләр әлеге гел бер җыр җырлаучы күлмәкләрне кияләр һәм аларның җырлары күлмәк җыры булып чыга.

Кешеләр ни кияләр? Хәзер без керләрнең икенче мәгънәсен дә искә төшерә алабыз. Шулай иттек исә, кеше өстендәге кер эчтәлеге шунда ук ачыклана. Хәзер кешеләр өстендәге кием безнең тышкы йөзебезгә әйләнә. Аңа бәя бирелә. Өс киеменең кер булуы да, гел кояшны, җилне мактап торуы да бәя була.

Бирем

Күрәсез, шигырьнең эчтәлеге тулысынча әйтелмәде. Конспект яза торган дәфтәрләрегезгә әсәргә анализны һәм анализ нәтиҗәләрен, әсәрнең тулы эчтәлеген табып языгыз.

УЕН

Борынгы уен, дигәч,
ырымлы уен, дигәч,
ләззәтле, тәмле, дигәч,
уйнавы ямьле, дигәч,—
нигә кермәскә, дидем,
уенга барып кердем.
Кешедән калышмаска!

Уенда юк кем генә!
Монда утлар, монда балкыш,
гүя монда көн генә.
Читтән карап торганда,
бәхетле бер гөр генә!
Үзең кергәч күрәсең,
күргәч бераз беләсең!

Монда әллә нәрсәләр!
Кайчак хәрәмләшәләр.
Алдаса да юрамалый,
тәмле сүз эндәшәләр.

Монда бар — газиз хисләрен
ваклап оттырганнар да.
Бар шомалар. Гомерләрен
уенга корганнар да.
Бар мәгънәне, бар хәйләне
аңлап бетү дә кыен.
Бу әллә кызык уен,
бу әллә бозык уен?

Бу әллә нинди уен!
Туктыйм инде, дип уйлыйм.
Үзем уйныйм, үзем туймыйм...
Бүтәннәр юри уйныйлар,
мин юләр чынлап уйныйм,
ихлас ышанып уйныйм,
Барсын беләсе килә.
Кайчак көләсе килә.
Уендашлар шаркылдыйлар,
миңа күз яше килә...

Бу әллә нинди уен!

Июль, 1971 ел

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ ясагыз.

2. Эчтәлеген алдагы шигырьләр эчтәлеге белән бәйләнештә ачыклагыз.

3. Темалары, эчтәлекләре охшаш шигырьләрне гомумиләштереп нәтиҗә ясагыз.

САУБУЛЛАШУ

Р. К.-кә

Аңласаң аңла хәлемне,
аңламасаң, синең эш...
Мин бүген яшьлегем белән
саубуллашырга тиеш.

Елармын да, җырлармын да —
гармуным кулларымда,
Син мине ялгызым җибәр
яшьлегем юлларына.

Су буйларын айкыйм ялгыз,
чыгыйм сукмакларга.
Ташкан күңелем сыяр микән
бу кичке офыкларга.

Кочыйм барып яшь талларны,
сугылыйм баланнарга.
Шашынып бер ауныйм әле
җиләкле аланнарда.

Тауларга йөгереп меним —
яшеннәр оясына.
Кешеләр: «Юләрме әллә»,—дип
уйласа уйласыннар!

Учак урыннарын табып,
яңакны куясы ла!
Сабантуй булган мәйданда
тын басып торасы бар...

Таныш зәңгәр тәрәзләргә
үтим әле чирткәләп.
Үксез маэмай малайларын
маңгаеннан иркәләп...

Бүген яшьлек эзләреннән
гизәсе дә гизәсе!
Саубуллашам... Араны бит
барыбер бар өзәсе!

...Таңга кадәр йөрдем ялгыз:
Җырладым да уйнадым.
Үзем ап-аек булсам да,
исерек иде уйларым.

«Миңа хәзер түгел инде
унсигез дә унтугыз...»
Күкләрне ярып кычкырдым:
«Сез мине онытыгыз!»
Елларга каршы кычкырдым:
«Сез мине онытыгыз!
Оялчан йөзле, хыялый
егетне онытыгыз!
Онытыгыз!»

Йолдызларга «хуш»
дидем мин,
«хуш» дидем дулкыннарга.
Талчыбыктан балчык аткан
керәшәле ярларга.

«Хуш» дидем мин мәктәбемә,
кучмә пристаньнарга...
Саубуллашыйк егет булып,
әй сез, яшьлек ярлары!
Ник гел күңелдә сакларга
туй кергән капкаларны!

Шашкын хисле тиле еллар,
хушыгыз сез, хушыгыз!
үткән безнең януларны
киләчәккә кушыгыз!
Хушыгыз!

...Нинди хәл бу? Ник ишетим
Бер җавап сүз —«хуш» сүзе?
Ник күренсен «сау бул!» дигән
бер ишарә, кул изәү!

Нинди хәл бу? Ялваруга
бар табигать саңгырау!
Бар да искечә — бар да яхшы,
бар да исән, бар да сау!
Һаман тормыш, һаман көрәш,
Һаман яшәү, һаман шау!

...Айныдым да аңладым мин,
шундый итеп аңладым!
Мин яшьлегем белән тагын
саубуллаша алмадым...

Февраль, 1975 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьне, яшьлек белән хушлашу һәм хушлаша алмау дип, ике өлешкә бүләбез. Аннары өлешләрне җентекләп аерым-аерым өйрәнәбез. Беренче өлештәге хис эчтәлеген сәбәпләрен тапкач ачыклыйбыз.

Хушлашу өлешендәге хис сәбәпләрен табыгыз. Хис байлыгын мөмкин кадәр күбрәк ачарга тырышыгыз.

2. Икенче өлеш хис сәбәпләренә ярлы. Яшьлек белән хушлаша алмау лирик герой өчен үкенечме, хәсрәтме, ачумы... Нәрсә? Бу өлештәге хисне атап әйтегез.

3. Шигырьнең эчтәлеге ике өлеш эчтәлекләренең үзара бәйләнешендә табыла, дибез. Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.

ЗӘҢГӘР КҮКТӘ БЕР АК БОЛЫТ

Зәңгәр күктә бер ак болыт
җәйге эссе челләдә.
Аккош булып тибеләнә
җәйрәп яткан күлләрдә.

Ә һәр күлнең үз юравы:
ак болыт — аңа гына!
Керфек-камышлар эченә
бу бәхет таман гына!

Шул уйда һәр тымызык су
үзе йөзендәгегә —
коедагы да, баздагы да,
тояк эзендәге дә...

Ә болыт йөзе челләдә...
Күк йөзе — зәңгәр-зәңгәр!
Болытның да үз хыялы —
«Тулышып җитсәм әгәр,
ташлап бушлыкның катларын,
җиргә төшеп килешкә,
кушылыр идем тамчы булып,
чишмәгә йә инешкә».

1991 ел

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз.

Равил Фәйзуллин шигырьләре

Шигырьләрнең күбесендә ялган хакыйкать эчендә яшәргә дучар булган шәхес кичерешләре тасвирлана. Равил Фәйзуллинның лирик герое үзенең аяныч хәлен яхшы аңлый. Гаделсез тирәлектән ничек булса да качарга тырыша. Әмма ялганнан, башны салларга салып, су агымы җаена агып кына качарга мөмкин түгел. Барыбер берзаман ярга туктарга кирәк була, ә ярда шул ук тормыш, кая гына барсаң да шул ук тирәлеккә барып чыгасың. Тирәлекне шагыйрь бозык уен дип бәяли. Теләсә дә, теләмәсә дә шул уенда үзенең дә уйнарга мәҗбүр булуына сыкрана. Үз җыры булган кешегә һаман бер генә җыр, дан җыры гына җырларга мәҗбүр итүләренә хәсрәтләнә.

Алтмышынчы елларда әдәбиятка бер төркем талантлы яшьләр килде. Алар өлкән буын кебек хакыйкатьне интегеп эзләмәделәр. Өлкән буын тәҗрибәсен бик әйбәт үзләштерделәр. Яшь булсалар да, күлмәк җырының хакыйкать булмавын яхшы белделәр. Шуңа күрә аларны «Хакыйкать, хаклык кая?» дигән сорау борчымады. Яшь буынның күңелен аеруча «Бу тормышта намуслы кешенең урыны кая?» дигән проблема бимазалады. Бу проблеманы Равил Фәйзуллин беренче шигырьләрендә үк күтәрде. Шәхес аның шигырьләрендә тормыштан күңел дөньясына качып юаныч эзләмәде. Аның лирик герое үз җырын җырлый алмау өчен үрсәләнде. Ләкин ул фаҗигасендә үзен дә гаепле санады. Равил Фәйзуллин шигырьләрендәге лирик герой хисләренең төп сәбәбе шул иде. Үз гаебеңне таныл, аны төзәтә алмау үкенече күп шигырьләренең эчтәлеге булды.

Равил Фәйзуллинның лирик герое көчсез. Ул кешенең эчке фаҗигасен язу белән бергә, аны шул фаҗигагә китергән тирәлекнең гаделсезлеген дә бик хәтәр бәяләп сурәтли. Шул бәясен укучыларына ачык күрсәтә, ләкин идеология сагында торучылардан бик оста яшерә дә белә. Әдипнең күпчелек шигырендә объектив эчтәлек астында авторның әйтәсе килгән сүзе — субъектив эчтәлеге ята. Габдулла Тукай башлап җибәргән, Һади Такташ, Хәсән Туфаннар үзләренең стиле итеп сайлаган ике эчтәлекле әсәрләр 60—70 нче елларда татар әдәбиятының стиленә әйләнде дип нәтиҗә ясый алабыз.

Равил Фәйзуллин ике эчтәлекне сурәтләнгән күренешнең төрле сыйфатларына башка мәгънә бирү юлы белән тудыра. Бу алым,— гомумән, татар язучыларының ятатып кулланган

алымы. Әмма Равил Фәйзуллин әлеге алымны аеруча оста файдалана. Әйтик, бауга эленгән кер үзе шигырьнең тәмамланган вакыйгасын тәшкил итә. Шул ук вакытта кешенең тышкы гамәле, икенче «Мине» сыйфатларын да ача. Кер чайкаучы кызлар турында («Кер чайкыйлар кызлар») язса, кер чайкау вакыйгасыннан әллә никадәр мәгънә чыгара:

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!

Уйларны да, керләр кебек,
ак иткәнче, пакь иткәнче,
ах, чайкарга иде!

Сагышларны ике куллап,
кысып-кысып, кысып-кысып
сыгарга иде!

Шатлыкларны иң өстенә
сыйган кадәр, сыйган кадәр
өяргә иде!

Чын җырларны — җилфердәргә —
биеккәрәк, биеккәрәк
эләргә иде!

Кер чайкыйлар кызлар.
Тезләрендә — Кояш!
Күзләрендә — Яз!

Ярым ачык күкрәкләре
оялган күк бераз...

1964 ел

Алай гына да түгел. Шигырь эчтәлекләренең бер-берсенә бәйләнгәнлекләрен әледән-әле күрсәтеп бара. Бу бәйләнешне сез «Кер чайкыйлар кызлар» һәм «Җилфердәүче керләр җыры» шигырьләре арасында да күрә аласыз.

Карт балыкчы турында язса, әлеге алымнан файдаланып, аның язмышын көймә сыйфатлары аша әйтеп бирә.

Равил Фәйзуллин сурәтләгән теләсә нәрсә метафора дәрәҗәсенә күтәрелергә ашкынып тора. Фикерне яшереп әйтүгә ихтыяҗлык, гомумән, сәнгатьчә фикерләү төренә әйләнә. Равил

Фәйзуллин, мәхәббәт турында, туган ягын сагынуы, яшьлеге турында язса да, төп фикерен шигырьләрендәге бәйләнешләр ихтыярына тапшыра. Менә, мәсәлән, «Илһам биреп» исемле шигыре:

Илһам биреп, җыр тудырткан
Сөйкемле хатын-кызлар,
Сезне илаһига санап
баш иям алдыгызда.

...Ә синең алда имим—
син мине сөйгән өчен!
Сиңа дип язган җырымны
«иң гүзәл!» дигән өчен!

Бәлки, ияр идем. Куркам,
калган чагында ялгыз,
миннән отып, горур башың
иеп куярсың ялгыш.

Гыйнвар, 1973 ел

Бу шигырьдә дә автор әйтәсе килгән фикерен әйтми калдырган. Аны табар өчен шартлар гына тудырган. Ни өчен лирик герой күп санлы сөйкемле хатын-кыз алдында баш ия, ә үзенә иң якын кешесенә баш ими? Шул сорауга җавап алсак, бу шигырьнең эчтәлегендә мәхәббәт хисе белән бергә фикер дә барлыгын беләбез. Лирик шигырь эченә фикер салу — әдипнең тагын бер үзенчәлеге, дип әйтә алабыз.

Рафаил Төхфәтуллин
(1924—1994)

Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин 1924 елның 1 гыйнварында Татарстанның Арча районы Яңа Иябаш авылында укытучы гаиләсендә туа. Тугызынчы сыйныфны Яңа Кенәр мәктәбендә тәмамлый һәм Донбасска китә. Анда Горловка шәһәрендә ФЗӨ мәктәбендә укый. Шахтада күмер чабучы булып та эшләп ала. 1941 елда эвакуация белән туган ягына кайта. Монда ул унынчы сыйныфны тәмамлый, курсларда укып тракторчы һөнәрен үзләштерә. Сугыш еллары... 1942 елның августында армиягә алалар. Башта пулеметчылар, аннары элемтәчеләр отделениесе командиры булып авыр сугыш юлы үтә. Орденнар, медальләр белән бүләкләнә. Ике тапкыр яралана, контузия ала. Сугыштан 1945 елда гына әйләнеп кайта. 1957 елга кадәр Яңа Кенәрдә чыга торган «Кызыл юл» район газетасында җаваплы секретарь булып эшли. Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып кайткач, иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Бу вакытта инде Рафаил Төхфәтуллин үзен хикәя остасы итеп танытып өлгергән була. Аның авыл тормышына багышланган кыска-кыска хикәяләре дөнья күрә. Ә «Таныш гөрелте» исемле беренче китабы — хикәяләр җыентыгы —1954 елда басылып чыга. Тагын дүрт елдан ул Әлмәткә күчеп килә һәм нефтьчеләр тормышы белән ныклап танышкач, нефтьчеләрнең хезмәтен, төрле җирләрдән җыелган кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен сурәтләп «Җиләкле аланнар», «Китә казлар», «Акбүз ат» исемле повестьлар яза.

Рафаил Төхфәтуллин персонажлары — хезмәт яратучы кешеләр. Тормыш аларны бик кыен хәлләргә куя, әмма алар рухи ныклыкларын югалтмыйлар, үзләре теләгән бәхетне яуларга тырышалар.

ТАНЫШ КӨЙ

I

Бала йоклый. Йодрыкланган нәни кулларын ян-якка ташлаган. Нәфис буынтыклы аяклары, тездән җиңелчә бөгелеп, түшәккә сеңгән. Чыклы чиядәй иреннәре үзенә бик килешле җитдилек белән кысылган. Рәхәт ялга талып йомылган күзләрне саклаучы озын керфекләре, хәзер тагын да озынрак күренеп, бик якын, бик кадерле нарасый йөзгә сөйкемлелек өсти...

Ана елмая, ягымлы, назлы сүзләр пышылдый: «И минем сөеклем, и минем чибәркәем, усалкаем минем...» Куллары бик сак, бик йомшак итеп «усалкай»ның ефәктәй чәчләрен, алмадай битләрен, кайдадыр тырналып өлгергән йомры тезләрен сыйпый. Йокла, улым, йокла... мүкәләп йөреп, чыгырыңны этеп, күпме юл үттең син... Әтиең кайткач сөйләп, аны куандырырга һөнәрең дә артты: комод белән өстәл арасын, беркая ябышмыйча, тәпи-тәпи үттең. Борыныңны, битеңне буяп, боткаңны үзең ашап бетердең...

Әле генә синең тавышың, синең мәшәкатең белән тулып торган өй, эче тып-тын булып калды. Тик моңарчы ишетелмәгән яки игътибар ителмәгән якын басудагы трактор гөрелдәве генә хәзер бик ачык яңгырап тора башлады. Бу — шулай әти кеше үзен сиздерә. Алар анда туңга сөрәләр.

Әтиеңнең кайтам дигән вакыты күптән үтте инде, ләкин ишек артында таныш аяк тавышының һаман да ишетелгәне юк. «Син пешергән ашны ашарга, мондый якын басудан гына түгел, башка авылдан кайтырга да иренмим мин, карчык»,— дигән була тагын үзе...

Гөлфия, чигә торган эшен алып, улының нәни караваты янына килеп утырды. Баягы шул күңел күтәренкелеге урынына, хәзер инде аның күңелен нигәдер әрнүле бер тынычсызлану биләп бара иде.

Нигә кайтмый инде?.. Тракторына берәр хәл булдымы әллә дисәң, тигез гөрелдәвенең бер минутка да туктаганы юк.

И улым, син дә йокладың, ичмасам, синең белән бөтен дөньям онытыла иде.

Энә, бармакларның күнегелгән хәрәкәтләренә буйсынып, торган саен җитезрәк йөри, ләкин күзләр, ак полотнога һаман ныграк текәлә барса да, кулларның эшен ничектер күрми иде.

Ә трактор тавышы, бер ерагаеп, бер якын ук килеп, һаман гөрли бирә.

Кинәт Гөлфия үзенең күңел тынычсызлыгының сәбәбе Заһидның вакытында кайтмавында гына түгел, ә менә шушы гөрелдәүдә дә икәнен эчке бер сизенү белән төшенеп алды. Әйе, берьюлы бик шатлыклы да, шактый ук күңелсез дә истәлекләрне уятып, нәкъ менә шушы тигез гөрелдәү, менә шушы таныш тавыш тибрәтә аның күңел кылларын...

II

Моның ничек башланганын Гөлфия үзе дә хәтерләми... Ул — Нәҗип Вәлитов — бераз оялчан карый торган, балаларча саф зәңгәр күзле, үзенең озын буен кеше күзеннән яшерергә теләгәндәй, гәүдәсен алга табарак сузып йөри торган егет иде. Гөлфия аны беренче тапкыр МТС конторасында күрде. Газеталардан аның турында байтак укыганы булгангамы, Гөлфиягә бу егет шунда ук күптәнге танышы кебек тоелган иде. Шуңадыр, ахры, икенче елны Нәҗип алар колхозында эшләргә билгеләнгәч, үзенең шушы агрегатка прицепщик итеп тәкъдим ителүен Гөлфия, күптәннән көтелгән хәбәр кебек, бер дә гаҗәпләнмичә каршылады.

Чәчүгә чыгарга бер ай чамасы калгач, Нәҗип үзе дә бирегә килеп житте. Менә ул Гөлфиянең йөзенә карамыйча гына, бик җитди тавыш белән аңа бер-бер артлы сораулар яудыра:

— Моңарчы кайда эшләгән идегез?.. Ниме?.. Тагылма машиналар белән танышмы соң?..

Шулай да, Нәҗип никадәр генә коры сөйләшмәсен, Гөлфиягә бу сүзләрне ишетү ничектер күңелле булды.

Сүз арасында Нәҗип, бик азга гына Гөлфиянең күзләренә карап алып, кызу-кызу әйтеп куйды:

— Ә мин сезне, ни бит... Күргәнем бар. Хәтерегездәме, узган көзне район күргәзмәсендә... Хәер, сез үзегез белмәдегез...

Күп дигәндә биш-ун минутлык сөйләшү иде бу. Шуннан соң Нәҗип атна буе биредә күренмәде. Ләкин аның бу сүзләре, бигрәк тә тотлыга-тотлыга әйтеп куйган соңгы сүзләре, Гөлфиянең колак төбендә бик ягымлы булып гел яңгырап тордылар. Ниндидер гаҗәп бер эчке шатлык белән тулып үтә башладылар аның көннәре... Их, тизрәк чәчү башлансын иде инде. Туйганчы бер карыйсы иде бу эчкерсез саф зәңгәр күзләргә. Кем белә, аны көткән бәхет нәкъ менә шушы күзләрдәдер, бәлки...

Ләкин чәчүгә чыгып, көннәр буе бергә эшли башлагач та, бу бик якындагы бәхет һаман да үзен көттерде.

Беркөнне, ниндидер эш чыгып, Гөлфиягә Нәҗип эшли торган сменага түгел, аның алмашчысы эшләгән сменага килергә туры килде. Ләкин Гөлфия килгәндә, Нәҗип әле китмәгән, шунда бер читтә, күк плащлы, ачулы һәм арыган йөзле берәү белән сөйләшеп тора иде. Гөлфия аның:

— Күзләре нәкъ Ладыниманыкы[1] кебек карый аның... Шундый... Хәтерегездәме, «Себер җире турындагы хикәя» киносындагы...— дигән сүзләрен ишетеп калды.

Гөлфияне күргәч, Нәҗип аңа каршы атлады:

— Фотограф бу... Газетадан килгән,— дип, ашыгып-ашыгып аның колагына пышылдады ул.— Мин аны син килгәнче юри көттердем. Ни бит...

Рәсем газетада басылып чыкты. Алар трактор янында нәрсә турындадыр бик бирелеп сөйләшеп торган кыяфәттә басып торалар. Нәҗип шундый матур итеп, шундый үз итеп Гөлфиянең күзләренә караган.

Их, тәгаен аның күңеле ялгышмаган, тәгаен аны көтә торган әлеге зур бәхет нәкъ менә шушы аңа бик матур, бик сөйкемле итеп караучы уңган егет, ахры...

Ләкин нигә соң ул рәсемгә төшкәндә генә Гөлфиягә шулай бик яхшы итеп карый да, мондый гына вакытта нигә бер дә алай карамый икән? Киресенчә, газетадагы бу рәсемнән соң тагын да җитдирәк сөйләшә башлады. Хәтта еш кына ачулана да иде:

— Син тагын агрегатыңны майламагансың, кулыңны салып тәясе кыз... Машина — майлауны, кызлар иркәләүне ярата дигәнне ишеткәнең бармы синең? Менә егетеңме яки анда иреңме бер дә иркәләми башласа, шунда белерсең әле... Тракторны да өйрәнергә вакыт инде сиңа.

Бик күңелсез була иде Гөлфиягә Нәҗип болай ачуланган вакытта.

Чыннан да, Гөлфия машинага игътибарлырак карый башладымы, Нәҗипнең ачуы бик тиз бетеп тә китә, һәм ул — тракторның төзелеше, аның теге-бу төзексезлекләрен ничек бетерергә кирәклеге турында рухланып сөйли башлый иде.

Көз көне Гөлфия тракторчылар курсына укырга китәргә теләген белдергәч, Нәҗип чын күңелдән шатланды:

— Менә молодчина, Гөлфия!.. Менә яхшы. Ни бит... Бергәбергә эшләве бик күңелле булыр. Шундый итеп эшләрбез...

---

[1] Ладынина — танылган кино артисты.

Лəкин аларга бергə-бергə эшлəргə туры килмəде. Гөлфия курстан кайтасы көннəр алдыннан Нəҗип тə укырга китеп барды. Ике елдан механик булып кайтачак...

Нəрсə, якындагы гына бəхетнең шулай итеп ерагаюы микəнни? Нигə ике-өч көнгə генə булса да көтмəгəн инде. Ничек сагынган иде бит Гөлфия бу зəңгəр күзле егетне...

Ул кайчандыр үзе прицепщик булып эшлəгəн агрегатка ук билгелəнде, кайчандыр Нəҗип тоткан рульне тотып эшли башлады. Бу тракторның һəр винты Нəҗипне хəтерлəтə: мотор да, тигез гөрлəп, Нəҗипне сагынып җырлыйдыр кебек иде...

Аның өлкəн тракторчысы итеп, Нəҗипкə капма-каршы буларак, бервакытта да җитди була белмəүче, барысы да аны «Кара малай» дип кенə йөртə торган, кап-кара чəчле, чем-кара күзле егет билгелəнде. Ул да Нəҗипне яхшы белə иде, тракторны кабул итеп алганда ук, ап-ак тешлəрен ялтыратып əйтеп куйды:

— Кем арбасына утырганыңны белеп утыр, кызый. Элекке хуҗалары вакытында сезонга мең гектардан артыкны биреп барган икəн, моннан соң да шуннан ким эшлəмəскə тиеш бу трактор.

«Кара малай», чыннан да, Нəҗип тракторының данына тап төшерерлек эшлəмəде. Тик менə Гөлфиянең генə эше бик үк яхшыдан түгел иде. Əйбəт кенə эшлəп торганда, йə мотор кирелəнə, йə башка берəр бəла килеп чыга да тора. Их, Нəҗип, Нəҗип, нигə киттең инде син?.. Бергə-бергə эшлəсəлəр, Гөлфия дə болай җəфаланмас иде...

Беркөнне, төнге сменада эшлəгəндə, электрожиһазларга əллə ни булды. Фараларны һич яндырып булмый. Мотор да кирелəнə...

Айсыз караңгы төн иде. Вак кына яңгыр сибəлəп тора. Тирəяк тып-тын. Прицепщик малай бригадирны чакырырга китте. Гөлфия, күзгə төртсəлəр дə күренмəслек дөм караңгыда, ялангач кыр уртасында, мескенлəнеп торган трактор янында берьялгызы басып калды. Бик күңелсез һəм нигəдер куркыныч та иде. Гөлфия шунда, əле суынып өлгермəгəн радиатор сырына башын куеп, басынкы, өзгəлəнүле тавыш белəн тыела алмыйча үксеп елап җибəрде...

— Нəрсə, тузбаш егылып төшəргə дə өлгердемени əле?

Гөлфия кинəт ишетелгəн бу таныш тавыштан сискəнеп китте. Каршыда кап-караңгыда ап-ак тешлəр ялтырап күзгə

чагылды. Инде менә шул гына җитмәгән иде! Кәл, әйдә, көл, тәпәлә егылганчы, тәмам бетер...

Үксүен тыярга тырышып, тагын да мәсхәрәлерәк көлү ишетергә җыенды Гөлфия. Ләкин бу үтергеч көлү нигәдер үзен бик озак көттерде. Көттерде, әмма бөтенләй көтмәгәндә, чын ахирәтчә бик тирән итеп сулап куюы ишетелде:

— Зарар юк, Гөлфия, хәзер акылга утыртабыз аны, бик тиз буйсындырырбыз.— «Кара малай»ның тавышы Гөлфия моңарчы бервакытта да ишетмәгәнчә ягымлы, йөрәккә үтемле, йомшак һәм шул ук вакытта боекмас-шат та иде.— Хәзер көйгә китерәбез аны, Гөлфия, бер дә кайгырма.

Ул, нурларын Гөлфиянең күзенә төшермичә генә, үзенең кесә фонарен яктыртып җибәрде һәм тракторның ян капкачын ачып, сөйләнә-сөйләнә, анда нәрсәләрнедер боргалый, караштыра башлады.

Тиздән тирә-юньне яктылыкка күмеп, фаралар ялт итеп кабынып киттеләр. Гөлфия, күзләре чагылудан керфекләрен кагакага, яшь аралаш елмаеп куйды.

— Әйдә, Гөлфия, хәерле юлга!

Алар бергәләп моторны кабызып җибәрделәр, бергәләп тегесен-монысын караштырдылар, һәм трактор талгын гына урыныннан кузгалып китте. «Кара малай» да Гөлфия янына, утыргыч арасындагы кечкенә мәйданчыкка менеп басты.

Яңгыр һаман сибәли иде әле. Шунда Гөлфия бу яңгырның гаҗәп җылы, рәхәт икәнлеген тойды: биткә сафландыргыч дәва бөркегәндәй генә сибәләп тора. Биткә генә түгел, ничектер бөтен барлыгына бөркелә кебек тоела башлады аңа бу искиткеч шифалы дәва...

Алар смена ахырына кадәр бергә эшләделәр, бергәләп тракторга тиз-тиз техник карау үткәрделәр. Вагонга кайткач, тимер мич каршысына янәшә үк утырып, юешләнгән киемнәрен киптерделәр.

Үз сменасына эшкә китәр алдыннан, «Кара малай» бригаданың гомуми милке булган тальянны кулына алып, гаҗәп матур аһәңле бер көй уйнап җибәрде. Гөлфия әлегә аңлап бетермәгән бик күп нәрсәләр турында сөйли иде бу көй...

Гөлфиянең хисләре болай да мөлдерәмә, болай да менәменә ташырга тора иде. Аз гына кузгалса да, бу рәхәт ташкын ургылып ага башлаудан курыккандай, Гөлфия, сулышын да сак кына алып, утырган урынында изрәп хәрәкәтсез калды.

— Нинди яхшы син... «Кара малай»...— дип, иреннәрен чак кына кыймылдатып, үзе дә сизмәстән әйтеп куйды ул.

«Кара малай», уйнавыннан туктап, тыйнак кына елмайды.

— «Кара малай...» Кара булгач, яхшы була ди микәнни?

— Юк, чыннан да әгәр, Заһид...

Ул елны көз гадәттән тыш яңгырлы килде. Табигать тискәреякларын күрсәтә башладымы, тракторның да киреләнә торган гадәте бар аның. Беренче елын гына эшләүче тәҗрибәсез тракторчы кызга ул инде бигрәк тә үч итә. Кайчандыр Нәҗип кулында андый көйсезләнүнең нәрсә икәнен дә белмичә җырлап эшләгән НАТИ да Гөлфиягә еш кына үч итеп карады. Үч итеп карады, әмма дөньяда Нәҗиптән башка тагын әле, базык таза гәүдәле, мәңге боекмас шат күңелле «Кара малай» — Заһид та барын белми иде ул, күрәсең.

Фаралар белән булган вакыйгадан соң, НАТИ Гөлфия эшләгәндә аз гына кирәмәт тавышлар чыгара башладымы, Заһид әллә ни арада гына ялт итеп килә дә чыга торган булып китте. Килеп чыга да, ап-ак тешләрен ялтыратып елмая-елмая, тракторны хәзер «акылга утырта», Гөлфия янына басып, кычкыра-кычкыра нәрсәдер сөйләп, аның белән бер-ике әйләнә, җир башында кулларын Гөлфиянең иңбашы аркылы рульгә сузып, җайлап кына тракторны үзе бора, бу вакытта аның гаҗәп кайнар бите Гөлфиянең битенә якын ук килә, сулышы колакны бик рәхәт кытыклап тора иде... Соңрак, трактор бер дә тискәреләнмәгәндә дә килеп чыга башлады ул.

Һәм менә шушы болай гына караганда дорфа һәм кешедән көләргә яратучан кебек, ә чынлыкта нинди кече күңелле егет үзенең киң җилкәләре белән Гөлфиянең йөрәгендәге икенче бер кешене — оялчан табигатен ясалма җитдилек белән капларга тырышучы, машинаны җаны-тәне белән яратучы Нәҗипне — бөтенләй диярлек каплап тора башлады. Гөлфия моны башта үзе дә сизмәде, дөресрәге, сизмәскә тырышты. Ләкин кояш җылысын сизмәскә мөмкин булмаган кебек, хисләрнең ялкынлануын да игътибарсыз калдырырга мөмкинме соң? Әгәр инде кабынып кына килүче бу ялкын дөрләп өлгермәс борын, икенчесе кабынып килә икән — ике ут уртасында калып та күзеңне йомып утырырга маташып кара әле!

Юк, күз йомып утырмады Гөлфия. Ләкин чәчәк атучы гөлләр кояш җылысыннан туямыни? Ә яшьлек мәхәббәт җылысыннан ничек туйсын?

Һәм бу җылы — ул елгы гадәттән тыш яңгырлы көзге көннәрне Гөлфия өчен язгы кояшлы көннәргә әверелдерде.

Ләкин язгы кояшлы көннәрнең берсендә кинәт кенә яшенләп яңгыр явып үтүчән була. Нәҗипнең беренче курсны бетереп ялга кайту хәбәре дә Гөлфиягә шундый яшендәй тәэсир итте. Әмма Нәҗип белән очрашуны Гөлфия бер дә болай булыр дип көтмәгән иде. Егет юньләп исәнлек-саулык та сорашып бетермәс борын, техник караудагы кебек бик җентекләп, тракторны тикшерергә тотынды. Аның йөзе җитди-ачулы, ләкин һич тә элеккечә зыянсыз ачулы түгел, чын-чынлап ачулы иде.

— Тәмам эштән чыгаргансыз бит машинаны!.. Сезгә нәрсә, норма гына тулсын, ә машина ничек туза, анда сезнең эшегез юк. Сине курста нәрсәгә генә өйрәттеләр соң?

Эшләдеме, әллә баскан урынында сыны катып смена буена һаман шулай басып тордымы ул,— Гөлфия боларның берсен дә ачык хәтерләми. Ләкин шунысы бик истә: гадәтенчә ап-ак тешләрен ялтыратып, көр күңел белән Заһид бирегә килеп чыккач, Гөлфия аңа ярсый-ярсый нәрсәдер кычкыра башлады.

Икенче көнне, чүп өстенә чүмәлә булып, НАТИ тагын көйсезләнә башлады. Бер җир буе китеп өлгермисең, тигез генә гөрелдәп эшләгән мотор пыр-пыр килә башлый да, куе зәңгәр төтен бөркеп, шып сүнә... Юк, Нәҗип дөрес әйтә, Гөлфиядән бервакытта да юньле тракторчы чыкмас, ахры... Нишләргә инде? Заһид чакырсаң да килмәс инде ул. Нигә килсен, кичә ничек хәтерен калдырды бит... Нишләргә соң?

— Гөлфия, карале... Мин вагоннан ук ишетеп, белеп торам, карбюратор тыгылган бит синең. Бөтенләй пустяк. Өф-өф итеп, бер өреп кенә җибәрәсе бар.

Гөлфия артына әйләнеп караса, куе кара кашларын күтәрә төшеп, бөтен чырае белән елмаеп, Заһид басып тора. Нинди сөйкемле иде ул бу вакытта! Хәтта артык сөйкемле иде бугай... Елмаючы ике пар күз бергә очраштылар да берьюлы аска текәлделәр. Күпмедер секундтан соң аларның күзләре яңадан очрашты, һәм менә нәкъ шушы караш аларның язмышын хәл итте дә бугай инде...

Бер атнадан соң Гөлфиягә конверт өстенә зур итеп «лично» дип язып куелган хат килеп төште. «Гафу ит, Гөлфия, мин теге көнне, кызып китеп, көзнең быелгы шартларын исәпкә алып бетермәгәнмен. Шулай да машинага сак карау турында бервакытта да онытма син, акыллым, яме».

Әгәр бу хат моннан берәр ай элек килсә, Гөлфия аны тыныч кына укый алыр иде микән? Әмма хәзер инде бу юллар Гөлфиядә бары тик егеткә карата нигәдер кызгану, ә үзендә ниндидер җиңеләю сизелгән елмаю гына уятты. Их, Нәҗип, машинага сак карау турында әнә ничек кайгыртасың син, ә менә кешегә сак карау турында бөтенләй онытасың... Үзең үк: «Машина — майлауны, кызлар иркәләүне ярата»,— дия идең бит. Ә шул сүзләрне үзең үк нигә искә алмыйсың икән...

...Нәҗип курсны тәмамлап кайтканда, Гөлфия ана булырга җыена иде инде.

III

Заһид иркәләүчән һәм көр күңелле егет кенә түгел, бик игътибарлы ир, йорт тотар хуҗа да булып чыкты. Бергә тора башлаганнарына ярты ел да узмагандыр, алар МТС усадьбасы тирәсендәге яңа оешып килә торган урамда җыйнак кына өй салып чыктылар. «Бергә тора башлавыбыз истәлеге»,— дип, Заһид шул көнне үк тәрәзә каршысына ике төп алмагач утыртып куйды. «Куна тактасы өчен дә күршегә керү уңайсыз»,— дип, яисә: «Савыт-сабаны өстәлдә тоткач тузанлана»,— дип, Гөлфиянең авызыннан чыгып өлгерми, Заһид ни арададыр куна тактасы струклап өлгерә, МТС мастерскоенда шкафын да ясап алып кайта иде.

Ә инде тиздән үзенең ата булачагын да белгәч, Заһид Гөлфияне ике куллап күтәреп кенә йөртмәде. Нәнинең дөньяга килеренә дүрт-биш ай алдан ук МТС дирекциясенең Гөлфияне ремонт эшләреннән азат итүенә ирешә. Эшкә киткәнче суын ташып, утынын ярып кертеп, булачак анага авыррак тоелган бөтен эшләрне дә үзе карап китә иде ул.

Бала, бераз тернәкләнеп, башын-кулын тота ала башлагач, Гөлфия яңадан тракторга утыру турында сүз ача башлады. Ләкин кая ул, Заһид моңа теше-тырнагы белән каршы иде.

Соңрак, ана кешегә кулай эшен дә үзе табып кайтты: «МТС буфетында эшләүче кыз укырга китә икән, тот та кабул итеп кал, Гөлфия. Көнгә күп булса, дүрт-биш сәгать эшләрсең. Аңарчы гына туган апа да балага күз-колак булыр».

Гөлфия карышмады. Буфетта эшләгәч, бөтенләй үк әрәмтамак булып калмый бит әле. Аннан соң, аңардан юньле тракторчы чыгуы да чамалы. Ярый ла теге вакытта гел Заһид булышып торгач та... Һаман-һаман аңа салынып кына эшләп булмас шул ул...

Үзе дә шуны искә алып тракторга җибәрмәү ягындадыр әле.

Нәҗип белән алар бик сирәк очрашалар иде. Очрашсалар да, Нәҗип тиз генә исәнләшә дә ашыгып үз юлына китеп бара. Буфетка да бер дә йомышы төшми иде, ахры, аның.

Шулай да беркөнне ул бик шат күңел белән буфетка килеп керде. Керде дә, шаян гына сөйләнә-сөйләнә, иң яхшы ризыкларны гына сайлап ашарга алды, йөз граммнан да тартынып тормады. Бу соңгысы аның телен тагын да ачып җибәрде бугай, гадәттәге җитдилеген бөтенләй ташлап, җәелеп сөйләп китте ул:

— Нинди зур яңалыклар чыгып тора бит хәзер МТСта, Гөлфия, ә? Нинди генә машиналар кайтмый. Яшелчә утырту машиналары, ашлама сипкечләр... Санап та бетерә алмассың. Сентябрь Пленумы карарын укыгансыңдыр... Әйе-е... Ни... өчәүләп бер килеп утырыгыз әле, Гөлфия. Илдарчикны да алып. Барысы турында да бер иркенләп сөйләшеп утырыр идек. Син укырга ярата идең бит. Казаннан яңа китаплар алып кайттым. И, бушап булмый дип... Әйе, ераграк ерагын... Ниме?.. Үзеңнең тормышлар ничек соң? Илдарчик үсәме?.. Минме? Менә шулай йөрим инде... Баш кашырга да вакыт калмый кайчак. Институтка заочно укырга кердем бит, кичләрен контроль эшләр белән утырам... Ю-ук, нинди комачаулау ди ул... Дуслар хөрмәтенә вакыт тапмыйлар диме соң. Чыннан да, килеп утырыгыз әле. Никадәр күп бит сөйләшәсе сүзләр. Әйе-е... Ә шулай да буфет ярлы әле синең. Баер, конечно, шик тә юк. Ләкин ни... Синең өчен таррак бу буфет. Нигәме? Соң, киң кырларда күкрәк киереп эшләргә күнеккән тракторчы өчен шушы кысан буфет ничек сулышларыңны бумасын ди... Әллә үзеңнең тракторчы икәнеңне дә оныттыңмы?.. Әйе, обязательно керәм әле, Илдарчик янына керәм...

Ул, сүзеннән кинәт кенә туктап, тирән генә бер сулап куйды да ашыгып чыгып та китте. Аннан соң буфетка тагын берничә кеше кереп чыкты да инде менә керүче дә юк. Тып-тын булып калды. Тик каядыр еракта ялгыз гармунчының нindидер моңсу да, ашкынулы да бер көй уйнавы ишетелә. Бик таныш көй бу. Кайда ишеткәне бар соң әле Гөлфиянең бу көйне?

Гөлфия, моңаеп, шушы таныш көйне тыңлап тора башлады. Көй бер ерагая, бөтенләй бетә, тагын якында гына ишетелә башлый... Кем уйный икән соң аны шулкадәр оста итеп,

йөрәккә үтә торган итеп?.. Их, ичмасам, уйнамасын иде, бәгырьнең әллә кай җирләрен авырттырып, чеметеп-чеметеп ала бу көй...

Караңгы төшеп килә иде инде. Аның күңелендә артык моңсу бүген. Болытлы, яңгырлы көннәрдә генә шулай була. Ә нигә шулай моңсу? Иртә белән генә, хәтта бая гына да алай түгел иде ич... Ах, Нәҗип гаепле. Нәкъ ул кереп чыкканнан соң шулай моңсу булып калды. Нигә икән? Бары тик бу көннәрдә барысы да сөйли торган шатлыклы хәбәрләр генә сөйләде ич ул. Ә шулай да йөрәктә моң калды. Никадәр генә шат сөйләшмәсен, күзләре ничектер сагышлы карый иде бугай шул аның. Шуңадыр... Ә бәлки, бер дә аңа түгелдер, тиздән Нәҗипнең инженер булачагын, ә үзенең шушы кысан буфетта калуын сизү шулай йөрәккә моң салгандыр...

Әлеге көй һаман да ишетелеп тора иде әле. Гөлфия ишек-тәрәзәләрне дә яхшылап ябып килде. Юк, һаман да ишетелә. Өйгә кайтышлый юл буе да ишетелеп торды ул көй. Тик, өй ишеген ачып кереп, бер кулын әнисенә таба суза-суза каршыга мүкәләп килгән Илдарны күтәреп алып күкрәгенә кыскач кына, бу көй ишетелми башлады...

...Һәм менә Илдарны йоклаткач, кулына чигә торган әшен алып бирегә килеп утыруга, әлеге көй, трактор гөрелдәвенә кушылып, яңа көч белән тагын яңгырый башлады. Гөлфия шунда гына аңлап алды: берәү дә, беркайда да уйнамый ул көйне, ә бары тик Гөлфиянең колак төбендә шулай яңгырап тора лабаса... Әйе, таныш көй. Тукта, моннан ике ел элек вагондагы тимер мич каршысында юешләнгән киемнәрне киптереп утырганда, Заһид уйнаган иде түгелме соң шушы көйне? Биткә сибәләгән җылы яңгырга тәңгәл килеп, күңелгә бөркелүче гаҗәп шифалы дәва турында, аның кулларына бик күндәм буйсынып, горур гөрелдәп эшләүче куәтле трактор турында, киң җилкәле, боекмас шат күңелле гармунчы егет турында һәм Гөлфия аңлап бетермәгән тагын, тагын бик күп нәрсәләр турында сөйләүче көй... Аннары тагын нәрсә турында иде әле? Үзең дә аңлап бетермәгән нинди яшерен моңнары бар икән соң ул йөрәкнең? Ә нигә нәкъ менә Нәҗип сүзләреннән соң гына шулай яңгырый башлады әле бу көй? Гаҗәп, кайчандыр кызның күңелен биләгән уйчан егетнең шат күзләре хәзер аның тормыш юлдашы булган шат егетнең ашкынулы-моңсу көен хәтергә китереп төшерә... Нинди бәйләнеш бар соң монда? «Синең өчен таррак бу буфет... Киң кырларда күкрәк киереп

эшләргә өйрәнгән тракторчы өчен шушы кысан буфет ничек инде сулышларны бумасын ди...» Юк, буфет кына түгел, нигәдер өйдә дә бөркү бүген. Бөркү дә, кысан да... Ә Нәҗип тиздән инженер була...

IV

Ул ишектән чыкканда, вак кына сибәләп яңгыр ява башлаган иде. Салкынча җил дә исә. Караңгы.

Каршыга автомашинамы, тракторны килә иде. Сыңар фаралы машина якынлашты. Бер дә автомашина да, трактор да түгел, мотоцикл икән... Ул арада мотоцикл Гөлфия янына килеп җитеп, кинәт туктады.

— Ә мин сиңа аманәт сүз алып кайтып киләм, Гөлфия, Заһид әйтте...

Гөлфия туктап калды. Йөрәге каты-каты тибеп куйды. Ләкин шунда ук ул, урыныннан кузгалып, адымнарын тагын да кызулатты.

— Ә мин үзем шунда барам, Нәҗип...

— Гөлфия...

Гөлфия аның сүзләрен ишетмәде. Аяклары, барган саен, кызурак атлый иде. Бераз баргач, ул артына әйләнеп карады. Сыңар фара һаман да баягы урында хәрәкәтсез тора иде әле.

Юкка гына тыңлап бетермәде ул Нәҗипне... Ярыймы соң шулкадәр дорфа булырга. Ә хәзер егет үпкәләп тә калды бугай инде үзенә...

Ә бит үзе нәкъ менә Нәҗип янына барырга дип, барысы, барысы турында уртага салып сөйләшергә дип чыккан иде түгелме соң әле ул? Хәтергә тирән үк сеңгән таныш көйне яңадан яңарта алган икән, ул көйнең тагын, тагын нәрсәләр сөйләвен дә аңлатып бирер иде, бәлки, Нәҗип... Юк, юк, кирәкми, ул көй Заһидныкы. Әнә үзе үк әйтте бит: «Ә мин үзем шунда барам»,— диде... Заһидның аманәтен тыңлыйсы иде тизрәк. Бая буфетта күңелгә бер моң салып киттең инде син, Нәҗип, артык кирәкми, кирәкми...

Үрне күтәрелүгә, туңга сөрүче тракторның акрын гына кыймылдаучы пар-пар фаралары яктырып күренде. Үндагы фаралар аеруча якты яналар. Гөлфия туп-туры шунда атлады.

Аның күңеле ялгышмаган икән. Гөлфия якынлашуга, трактор туктады да, аннан Заһид сикереп төште.

— Гөлфия! Син нәрсә?.. Мин Нәҗипкә әйткән идем бит, бүген икенче сменага калдым. Кереп әйтеп чыгармын дигән

иде бит Нәҗип... Гөлфия, ачуланма инде син, шулай туры килде, алмашчым авырып киткән, ә тизрәк төгәллисе бар. Яңгыр да сибәләп тора, иртәгә бигрәк бозылып китүе бар көннең...

Заһидның шат тавышы Гөлфиягә авыр төш күреп ятканда назлы гына дәшеп йокысыннан уяткандай тәэсир итте.

— Юк, Заһид,— диде ул, ышанычлы тавыш белән,—иртәгә көн аяз булачак, мин беләм, менә күрерсең...

— Аяз булса, бигрәк яхшы... Син бар, тизрәк кайт инде, Гөлфия, туңасың. Илдар нишли, йоклап калдымы? Бар, ул да уяныр йә.

— Юк инде, Заһид. Кайтырга дип килмәдем мин. Илдар янына син кайтасың. Ә мин калам. Эшкә дип килдем мин. Үзем утырам тракторга.

— Гөлфия, нәрсәгә инде юләрләнәсең...— Заһид Гөлфиянең кулларын кысып тотып алды.

— Юләрләнмим, Заһид, ә менә моңарчы, чыннан да, юләр булганмын...— Гөлфиянең тавышы кинәт калтырап китте:— Заһид, җаным, аңла, кысан ул минем өчен буфет. Сулышларны буа... Заһид, аңла инде... Сагынам мин тракторымны. Шундый итеп эшләрбез бергә-бергә. Ә Илдарны яслегә бирербез...

— Анысы шулай, Гөлфия, анысы дөрес... Тик менә... Ни бит... Кыскасы, Илдарның энесе яки сеңлесе өчен авыргарак килмәсме дим мин.

Гөлфия башын күтәреп, баягыча шат көлеп җибәрде.

— И-и, син аның турында икән... Юк, Заһид, бер дә авырлык килмәс. Декретный отпускка кадәр әле, у-у, никадәр вакыт бар... Бар кайт инде син... Аш шунда, карават астында...

— Кайда-а?

— Карават астында. Мин аны термоска салып, юри шунда яшереп куйган идем. Син кайтышка теге, ничек диләр әле, сюрприз хәзерлим, янәсе...

Трактор җайга гына урыныннан кузгалып китте. Яңгыр инде туктап килә. Җир башына кадәр дип, Заһид та Гөлфия янына басты. Мотордан ят тавышлар ишетелми. Заһид теге вакыттагы гадәтенчә, мотор тавышын басарга тырышып кычкыра-кычкыра, нәрсәдер сөйләп бара.

Шунда әлеге көй Гөлфиянең колак төбендә тагын да ачык булып яңгырый башлады. Биткә сибәләгән җылы яңгырга тәңгәл килеп, күңелгә бөркелүче гаҗәп шифалы дәва турында, аның кулларына бик күндәм буйсынып, горур гөрелдәп

эшләүче куәтле трактор турында, киң җилкәле, боекмас шат күңелле егет турында һәм... Менә хәзер ул вакытта аңлашылып бетмәгәннәре дә аңлашыла башлады кебек: сөйгән кешең белән сөйгән эшеңдә бергә-бергә эшләүнең нинди зур бәхет икәнлеге турында һәм, шуларның барысына да өстәп, Нәҗип әйткәнчә, нинди искиткеч көннәрдә яшәвебез турында...

1953 ел

Биремнәр һәм сорау

1. Хикәянең төзелешен табыгыз.
2. Өлешләрендәге бәйләнешләр аша эчтәлеген сөйләгез.
3. Хикәядә шәхеснең үз урынын эзләү проблемасы бармы? Булса, сөйләгез.

Хикәягә анализ ясыйк. Хикәя жанрының үзенчәлеген искә төшерик. Бу жанрга кергән әсәрләрнең уртак сыйфатлары бар: алар сюжет эчендәге вакыйгаларга бүленә.

Әсәрне вакыйгаларга бүлә башлаганчы, гадәттәгечә, иң күп кабатланган урыннарга һәм хикәянең исеменә игътибар итәбез.

Кабатланган эпизод — бер тынып, бер көчәеп ишетелә торган ерактагы көй. Фокус булуын күрсәтер өчен, автор көйне әсәренең исеме иткән — «Таныш көй» дигән.

Вакыйгаларга бүлик. Әсәр Гөлфиянең Нәҗипкә һәм Заһидка булган мәхәббәте турында.

Гөлфиянең Нәҗипкә карата мәхәббәте егетне бер күрү белән уяна. Нәҗипне хәтта исенә генә төшерсә дә, кыз бөтен дөньясын оныта. Акылы белән Гөлфия егетнең кимчелекләрен дә күрә. Ләкин мәхәббәт җиңә. Гөлфия, мәхәббәтенә җавап ала алмыйча, акылы белән хисен бәхәсләштерә-бәхәсләштерә, егеттән җылы сүз көтә.

Гөлфиянең Заһид белән танышуы ачудан башлана. Кыз егеткә авыр-авыр сүзләр әйтеп ташлый. Ләкин, егетне якыннанрак белгән саен, аңа хөрмәте арта, хөрмәте дуслыкка, дуслыгы мәхәббәткә әйләнә.

Ә фокусыбыз кая китте соң әле? Заһид уйнаган гармун көе кабатланган эпизодларны кабат укыгыз. Көй, мәгънәләргә байый-байый, Гөлфиянең беренче мәхәббәте белән Заһидка булган мәхәббәте арасындагы күңел бәхәсен чагылдыра бит.

Ә хисләр бәхәсе әле тәмамланмаган. Әсәр ахырында Гөлфия Нәҗип сүзләрен юкка гына искә төшерми бит.

Илдар Юзеев
(1933—2004)

Илдар Гафур улы Юзеев 1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында туа. Үз авылында урта мәктәпне тәмамлый, Казан Дәүләт педагогия институтының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. Аннары күп еллар буена төрле журналларда эшли: «Пионер» журналының җаваплы секретаре, «Чаян» һәм «Казан утлары» журналларында бүлек мөдире булып хезмәт итә. Мәскәүдә Югары әдәби курсларда белемен күтәреп кайта. Шуннан соң бөтен көчен яшь авторларның осталыгын үстерү эшенә бирә. Язучылар берлегендә әдәби консультант, аннары яшь авторлар белән эшләү буенча Берлек идарәсенең председатель урынбасары хезмәтен үти.

Илдар Юзеев — гаять дәрәҗәдә игелекле, үз хәсрәтен шаянлыгы белән берәүгә дә сиздермичә яшерә белә торган, үткен телле, нечкә күңелле шагыйрь. Болынга чыкса, кеше ишетми торган үлән кыштырдаганын ишетә, күккә караса, бүтәннәр абайламый торган нурлар кисешүен күреп ала. Табигатьнең кечкенә генә ярасы өчен дә чын күңелдән борчыла, ә дуслары хәсрәтенә үзләреннән дә ныграк хәсрәтләнә торган кеше.

Унсигез яшендә «Таныш моңнар» поэмасы белән кырыс күңелле тәнкыйтьчеләрне дә шаккатырды студент егет. Бу поэманы эзләп укыдылар, радиодан тапшыруларын ишетеп, институтка керә алмаган бер кызның хәсрәтен уртаклашып еладылар. Поэманы хәзер дә радиодан әледән-әле тапшырып торалар. Инде әллә ничә мәртәбә тыңлаган кешеләр аны хәзер дә рәхәтләнеп тыңлыйлар һәм яшереп кенә яшь бөртекләрен сөртеп алалар.

Хәсрәтнең олысы-кечесе юк. Илдар Юзеев үзе кебек бер яшь кешенең шул кечкенә хәсрәтен дә зур хәсрәт итеп кабул иткән һәм башкалардан да шул баланы кызгандыра алган.

Илдар Юзеев чәчәк күрә дә шул чәчәк тудырган хисләре эченә чума. Хәзер хисләр үзләре чынбарлыкка әвереләләр, дулкынланалар, бер-берсен куышалар һәм... фикерләр туууга сәбәп булалар.

Әнисе җибәргән мәтрүшкәләргә карый да шагыйрь, шунда ук үзенең йөгереп уйнап үскән болынын искә төшерә, улына җибәрү өчен мәтрүшкә төреп торган әнисен күз алдына китерә. Шул чакта әнисе ни уйларга мөмкин? Илдар Юзеев, билгеле, шул чакта әнисенең ни уйлаганын яхшы белә. Әмма ул инде мәтрүшкәләрнең бер сыйфаты —кипкән булуы турында уйлана башлый. Мәтрүшкә кешеләргә кай ягы беләндер охшаган бит. Аның бу сыйфаты хис тә, уй да тудырырга тиеш. Автор мәтрүшкәләрнең үзләренә мөрәҗәгать итә: «Әни миңа ни әйтергә теләгән?» — дип сорау бирә. Хәзер күңел тудырган вакыйга эченә мәтрүшкәләр актив рәвештә катнашалар. Алар әни әйтәсе сүзне әйтәләр, әмма мәтрүшкәләр хәбәр әйтүчеләр генә түгел, алар бер үк вакытта үзләренең фаҗигаләреннән дә зарланалар. Илдән аерылган кеше, безнең кебек кибә, диләр. Илдән аерылу фикерен куәтләп, аңа хис өстиләр, фикерне тәмам итәләр.

Илдар Юзеев тормыштагы вакыйгаларны шулай кабул итә. Шунда ук вакыйганы хисләренә урап ала. Әмма зур вакыйга зур фикер тудыра. Моның өчен шигырь калыбы гына җитми инде. Поэма язарга туры килә. Төрле елларда ул «Әнкәй», «Фәрит — Фәридә», «Идел —Даугава», «Язылмаган поэма», «Өчәү чыктык ерак юлга...», «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау», «Канкай угылы Бәхтияр», «Карурман», «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» һ. б. поэмалар иҗат итә.

Илдар Юзеев язган пьесаларны Татарстандагы барлык театрлар да, шул исәптән Башкорт, Мари, Тува, Каракалпак Республикасы театрлары куялар. Автор «Янар чәчәк», «Бөркетләр кыяга оялый», «Кыр казлары артыннан», «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?», «Бәхетемнән узып барышлый», «Онытылмас бәет», «Гомернең алты сәгате» кебек хәзер дә төрле сәхнәләрдә әледән-әле уйналып килә торган пьесалар иҗат итә. Аның пьесалары да, шигырьләре кебек, хискә бай. Аларның конфликтлары — кичерешләр конфликты. Персонажлары да, лирик геройлары кебек, күңел дөньялары эчендә яшиләр. Ә автор

үзе читтән карап елмаеп тора һәм тамашачыга: минем персонажлар бик күп кайгыралар, яраталар, шатланалар, хыялланалар, хисләрен яшермиләр, ә менә әсәрдә әйтелгән фикерне, хөрмәтле тамашачым, үзең табып кара, ди. Һәм дөрес әйтә, Илдар Юзеевнең пьесаларында да кичерешләр фәлсәфи фикер тууга сәбәп булалар.

КАЛДЫР, АККОШ, КАУРЫЕҢНЫ...

Калдыр, аккош, каурыеңны.
Кояш нурына маныйм.
Күңел җылысын салыйм да
Хисләрдән утлар ягыйм.

Калдыр, аккош, каурыеңны,
Мин аны изге саныйм,
Аккоштай саф ак кәгазьгә
Җылы хис булып тамыйм.

Ак кышларны яндырырлык
Учаклар булып яныйм,
Аккошларны калдырырлык
Утлы җыр булып тамыйм,—
Калдыр, аккош, каурыеңны...

1973 ел

ЮЕШ ТӘ ДЫМ...

Юеш тә дым... Дым да юеш...
Яңгыр да яңгыр...
Ә син яңгыр яуганда да
Яшен булып ян бер!

Нур да кояш... Кояш та нур...
Их, бер тамчы яңгыр!
Ә син бар җир янганда да
Яңгыр булып яу бер!..

1975 ел

ӘЙ КЕШЕ...

— Әй Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?..
— Чүлләрдә сусаган кешегә
Чишмәдән су илтеп барышым.

— Әй Кеше, кайларга юл тоттың.
Юк анда туганың-танышың?
— Ачлыктан тилмергән, йөдәгән
Балага нан илтеп барышым.

— Әй Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
—Диңгездә бәлагә очраган
Корабка ярдәмгә барышым.

— Әй Кеше, кайларга юл тоттың.
Юк анда туганың-танышың?
— Йорт-җирен су баскан кешегә
Диварлар төзергә барышым.

— Әй Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Барасы юлыма корылган
Диварны сүтәргә барышым.

1976 ел

АЙ СОНАТАСЫ

Төн.
Тын.

Тиздән — таң атасы.
Урамнарда
Илаһи моң:
«Ай сонатасы».
Җир тирбәлә
Галәм-бишегендә.

Ә Ай — әни
Көйли бишек җырын:
«Балам, уян,
Ишет әнкәң моңын».
Җир уянды
һәм ишетте көйне...
Тик ай соңгы нурын сипкән иде,
Бөтен моңын, нурын Җиргә биреп,
Ул таң белән сүнеп киткән иде...

1975 ел

МИН ТАБАРГА ТИЕШ

Әтиемнең күзләрендә
Узганнан сорау табам:
«Бигрәкләр дә ашыгасың,—
Сабыррак булчы, балам?!»
Улым күзләрендә күрәм
Киләчәкнең карашын:

«Тизләт, әти, адымыңны,
Акрынрак барасың!»
Бара торган киләчәкнең,
Узганның, Бүгенгенең
Мин табарга тиеш мәңге
Аерылмас берлеген!

1975 ел

САЛКЫН ҖИРНЕ ҖЫЛЫТКАНДЫР КЕШЕ

Салкын җирне җылыткандыр Кеше
Ут чыгарып чакма ташлардан,
Тик шулай да бик нык ышанам мин:
Тормыш мәхәббәттән башланган.
Ике йөрәк берчак табышкандыр
Берсен-берсе эзләп, тилмереп.
Җирдә йөрәк дигән җылы булган
Утлардан да алда, иң элек...
Кеше акылыннан калалмыйча
Еллар тизрәк алга чапкандыр,
Парны, электрны, атомнарны
Гашыйк җаннар уйлап тапкандыр.
Заман... Тизлек... Юлдаш-ракеталар...
Нинди акрын булган юл башы...

Кеше тизрәк җитәр максатына
Сөю булса даими юлдашы.
«Кем баласы?» диеп сорасагыз,
Мин — мәхәббәт, сагыну баласы,
Шашып яратулар бездән соң да
Оныкларга күчеп каласы...
«Бу ноктада тормыш бармы?» диеп,
Галәм түрләреннән кем дәшәр?
Сөю хисен йөрәк югалтмаса,
Җир суынмас мәңге,
җир яшәр!

1977 ел

Илдар Юзеевнең лирик герое. Аның лирик герое — бөтен Галәм, Җир язмышы өчен җаваплы Җир-Галәм кешесе. Ул — бер үк вакытта гади бер кеше дә һәм Җир-Галәмнең бер кисәге дә. Ул — дөньяга бәя бирүче дә, шул ук вакытта бәяләнүче дөнья үзе дә. Лирик геройның борчылу сәбәбен Илдар Юзеев үзе әйтеп бирә:

Гармония юк шул бу Җирдә.
Мин тәртипкә салам дөньяны
Тик, кызганыч, бары шигырьдә...—

ди.

Ә «Мин табарга тиеш» шигырендә өч заманның берлеген, ягъни заманнарның тоташкан ноктасын табарга тиеш дип белдерә.

1 нче бирем. Илдар Юзеев шигырьләрендәге лирик геройга биргән бәяне исбат итегез, ягъни: а) барлык шигырьләргә хас герой икәнлеген күрсәтегез; ә) төрле шигырьләрдә сурәтләнгән лирик геройларның уртак якларын табыгыз.

Шигырьләрдәге фикер. Тормышны шагыйрь Җир белән Галәм янәшәсенә куеп тасвирлый. Шуңа күрә тормыштагы көнкүреш ваклыклары да, мәхәббәт-хәсрәтләр дә гадәти вакыйга булып калмыйлар, илаһи күренешләрнең чагылышы булып башка мәгънә алалар. Хәзер тирә-юньнең чикләре чиксезераклыкка сузыла, төпсез биеклекләргә менә. Әмма чикләр барыбер күренәләр. Чөнки лирик герой аларны башка күз белән — Галәм кешесе булып күрә. Хәзер бу лирик герой үзе җиңел күзаллый торган тарафлар эченә вакыт килеп керә. Әмма вакыт үзе дә, аның заманнары да — бүтәннәр, чиксезлекләре күренеп тора торган вакыт һәм заманнар. Тарих та, чорлар да, кеше язмышлары да — шул галәмәт заманнарның кисәкләре генә. Автор заманнарның кисешкән урынын табарга хыяллана. Дөньяда яшәүнең мәгънәсе шунда булуына ышана.

2 нче бирем. Фикер белән хис шигырьләрдә, кагыйдә буларак, берберсенә кушылып киләләр. Әмма, әсәргә анализ ясаганда, безнең аларны аерырга хакыбыз бар.

Шигырьләргә кабат күз йөртеп чыгыгыз, кискә фикер катнашкан шигырьләрне табыгыз һәм андагы фикерләрне үзара ялгарга тырышыгыз.

3 нче бирем. Шигырьләрендә Илдар Юзеев яшәү мәгънәсен күрсәтәме? Исбат итеп сөйләгез. Сорауга җавап тапсак, автор фәлсәфәсе турында нигезле фикер йөртә алачакбыз.

Шигырьләрдәге хис. Илдар Юзеев үзенең иң зур теләген әйтә: ул — дөньяны тәртипкә салу. Әмма шунда ук бу максатына ирешә алмаячагын, тәртипне, кызганычка каршы, фәкать шигырьдә генә урнаштыра алуын да кисәтә. Димәк, шигырьләрдә тасвирланган тәртип белән тормыштагы тәртипсезлек каршылыкка килә. Бу каршылыкны без теләк белән чынбарлык каршылыгы дип тә, тормышка ашмаган теләк каршылыгы дип тә әйтә алабыз.

Илдар Юзеев шигырьләрендәге бу каршылыкны белү безгә бик әһәмиятле, чөнки әсәрләрдәге хис сәбәпләренең ул иң

даимиен, иң көчлесен табарга ярдәм итә. Хәзер без икеләнмичә, шигырьләрдәге матурлык, тормыштагы тәртип — шагыйрьнең юануы дип әйтә алабыз. Бу шигырьдә фәкать юану гына булса да, без аның артында хәсрәт ятуын яхшы беләбез. Ул хәсрәтнең башка шигырьләрдә булуына аз гына да шикләнмибез. Шуңа күрә аерым шигырьнең тулы эчтәлеген текстара бәйләнештән беләбез.

4 нче бирем. «Тамсын ул» шигыренең тулы эчтәлеген табыгыз.

ТАМСЫН УЛ

Күңелемдә ялтырап
Кояш чыкты,
Һәм күземнән мөлдерәп
Бер яшь чыкты.
Кояш нурын күпме генә
Сипмәсен,
Кипмәсен ул сөенеч яше,
Кипмәсен.

Оялмамын кешеләрдән,
Сөртмәмен,
Үз шатлыгым итеп кенә
Йөртмәмен.
Ак кәгазьнең битләренә
Тамсын ул,
Кешеләргә шатлык алып
Барсын ул!..

1976 ел

5 нче бирем. Илдар Юзеевнең «Ак бүрек, каз... могҗиза!» исемле мәкаләсе әдәби әсәр язу серләренә багышлана. Мәкаләсендә шагыйрь үз иҗатының кайбер үзенчәлегенә дә туктала.

Мәкаләне инша дип күз алдына китерегез. Аңа башка исем уйлап табыгыз. Планын төзегез. Төп фикерен табыгыз.

Ак бүрек, каз... могҗиза!

Балачакта әти миңа ак бүрек алып кайтты. Башка малайларда да бар андый бүрек, берние белән дә аерылып тормый. Шулай да беркөнне минем шул ак бүрегем малайлар алдында дан казанды.

Без, билгеле инде, бүрекләрне дә салмыйча, иң алда, сәхнә янындагы идәнгә тезелеп утырдык. Икенче пәрдә башланыр алдыннан, укытучыбыз — «артист» Язит абый сәхнәдән генә минем ак бүрегемне сорап алды да югалды. Пәрдә ачылды. Акгвардиячеләр, җырлый-җырлый, авыл халкыннан талап алынган казларны йолкыйлар. Карыйм: акгвардияче киемендәге Язит абый кулында каз — минем ак бүрек! Мактанып, күрәсезме диеп, малайларга төртәм. «Кит аннан, нинди бүрек

булсын, каз ич ул!» диләр тегеләр. Күпме генә тырышсам да, малайларның ышанасылары килмәде. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә икеләнеп калдым. Соңыннан, Язит абый «каз»ны минем башка чәпәгәч кенә, аның минем бүрек икәненә ышандык. Шул көннән соң малайлар минем үземә түгел, бүрегемә бер чакрымнан сәлам бирә торган булдылар.

Әдәбиятта шартлылык дигәндә, мин шул вакыйганы искә төшерәм. Әдәбият тормышның нәкъ үзе түгел, ул — чынбарлыкның чагылышы. Ә аны дөрес чагылдыру өчен, язучы шартлы алымнар кулланмый булдыра алмый.

Мин теоретик түгел, шунлыктан үз тәҗрибәмнән чыгып җавап бирергә уйлыйм. «Тынлык белән сөйләшү» поэмасын язарга мине тормыштагы бер факт этәрде.

...Бер мәктәпнең унынчы сыйныф укучылары 1941 елны мәктәпне тәмамлаган егетләр-фронтовиклар белән очрашырга уйлыйлар. Аларны эзли башлыйлар һәм очрашу көнен дә билгелиләр. Ә очрашуга бер егет тә килә алмый: аларның барысы да Ватан сугышында корбан булган икән!

Бу материал прозаик кулына эләксә, ул шушы вакыйгадан да, бәлки, хикәя язган булыр иде. Поэма язганда, тормыш факты бөтенләй төшеп калды. Әсәрнең алымына ярашлы рәвештә, мин символик образга — Тынлыкка мөрәҗәгать иттем. Балалар әлеге корбаннарның символы — Тынлык белән очрашалар. Бер минут Тынлык, Хиросима Тынлыгы, Гамьсез Тынлык, Җир-ана, Бала телгә килеп сөйли башлыйлар.

Романтик рухтагы әсәрләр язганда, миңа еш кына символик образлар уйлап табарга туры килә. «Өчәү чыктык ерак юлга...» поэмасында Фазылҗанны үз артыннан ияртүче бәндәне — Төн кешесе итеп алдым.

«Онытылмас бәет» драмасында Ак әби, Ак бабайларга контраст итеп, Кара әби образын бирдем. «Кыр казлары артыннан» драмасындагы Борынгы кеше, «Сандугачлар килгән безгә» моңсу комедиясендә Тимер кеше — символик характердагы образлар.

«Мәңгелек белән очрашу» трагедиясендә исә жанр, геройлар, тел-стиль, сюжет — барысы да фантастик алымга буйсынган. Кешелек алдында торган иң зур проблема: Җирдә, Күктә, Суда сугышны булдырмау; Җирне, Күкне, Кешене саклап калу; Узган, Бүгенге, Киләчәкне бер ноктада очраштырырга омтылу — әнә шундый алымны таләп итте.

Минемчә, шартлы, символик, фантастик алымнарны язучыга катлаулы реалистик чынбарлыкны масштаблырак, гомумиләштеребрәк, аның фәлсәфи асылын бер фокуска туплабрак бирергә ярдәм итә. Әмма һәр язучының тормышны чагылдыру өчен үз алымнары бар. Югарыда күрсәтелгән чаралар да мин кулланган алымнарның кайберләре генә...

Язучы нинди генә шартлы алым кулланмасын, укучыларын ышандырырга тиеш. Укучылар, тамашачылар минем ак бүрекләремне каз итеп кабул иткәннәрме, юкмы — анысы алар иркендә...

1984 ел

САГЫШЛЫ МИРАС

Булганбыз без әре халык, тере халык,
Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.
Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:
Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз.
Ни әйтсәң дә, Алыплардан яралганбыз,
Шул нигездә торасыбыз, корасыбыз.
Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз,
Бабайларның бик сагышлы мирасы без.
Алып бабай тубалыннан чәчелгәнбез,
Үсмәсен дип чиру[1] булып килгән ятлар.
Өзелмәслек тамырдан без, нәселдән без,
Җанга сеңгән моңсу җырлар, риваятьләр.
Ак син, җырым, Ител сыман дулкынланып,
Тыңла бала, шул дулкынны уйга талып.
Бабаң менгән рухи урдән төшә күрмә,
Төшә күрмә, Алыплардан калган халык.

2008 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырь эчтәлеген сөйләү өчен, «Алыплар» сүзенең мәгънәсен белергә кирәк. Белегез.
2. Эчтәлектә үгет бар. Ләкин әсәр эчтәлеге үгет түгел. Жанрын ачыклап, әсәрнең эчтәлеген табыгыз.
3. Шигырьне ятлагыз.

---

[1] Чиру — гаскәр.

Гөлшат Зәйнашева
(1928—2005)

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туа. Бала чагын Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында әтисе ягыннан туган апасы тәрбиясендә үткәрә. Хуҗәмәт авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары Минзәләдә педагогия училищесында, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Мөгаллимлек эшенә ике дипломы булса да, Гөлшат Зәйнашеваны язу-сызу эше күбрәк кызыксындыра. Кечкенәдән җыр яратучы кызны шигырьдәге көй, гармония үзенә тарта. Ул Татарстан радиокомитетында башта әдәби тапшырулар мөхәррире булып эшли. Аннан Татарстан китап нәшриятына күчсә дә, радиокомитетка кабат кайта һәм бу юлы инде музыкаль тапшырулар мөхәррире вазифасын башкара.

Гөлшат Зәйнашева — ике дистәгә якын китап авторы. Шигырь китаплары, пьесалар һәм... җырлар. Аның текстына көй язмаган композитор, ул җырларны җырламаган артист юк. Гөлшат Зәйнашеваның сүзләре үзләре җырлап, көй чыгарып тора. Шигырьләрендә һәр сүз үз урынын тапкан, башка сүзләр белән мәгънә ягыннан түгел, авазлар чиратлашуы, авазларның бердәй яңгырашы белән бәйләнгәннәр.

Гөлшат Зәйнашева шигырьләрендәге көй — композитор язган көй түгел. Ул — шигырьнең үз көе. Алар гаять катлаулы хисләр хәрәкәтен кабатлыйлар. Нәрсәнеңдер формасы, алымы түгел, көйләр — үзләре кичерешләр.

Шагыйрәнең берничә әсәре белән танышыйк.

ХАКЛЫК ДИҢГЕЗЕН КИЧӘРГӘ!..

Мәгънәсез бәндә сүз алды,
Мәгънәсез сүзләр сөйләде.
Чәчрәп чыктым аңа каршы,
Ярсу йөрәгем түзмәде.
Акны кара дип раслап, ул
Өстен чыгарга тырышты.
Мине мәгънәсез, дивана,
Берни белми дип орышты.
Дәгъвалашып яшәп кайчак
Чынлап калам мәгънәсезгә.

Акны кара диючеләр
Яши әнә дәгъвасыз да!..
Акны кара диеп мин дә
Ялган яклап барыйм микән?..
Болганчык су өсләрендә
Тыныч кына агыйм микән?..
Юк, акмаска тыныч кына!..
Ташланырга дулкыннарга!..
Хаклык диңгезен кичәргә,
Чоңгыллары булса да алда!

1975 ел

Публицистик лирика. Шигырьнең эчтәлеген автор үзе турыдан-туры сөйләп бирә. Яшәешнең ике төрен күрсәтә һәм сорау куя: ялган белән яшәргәме, әллә хаклык беләнме? Чорның төп проблемасына әйләнгән бу сорауга җавап әзер кебек: билгеле, хаклык белән яшәргә кирәк!

Әлеге сорауга җавап шулай җиңел генә бирелсә, ул — чор әдәбиятының үзәк проблемасына әйләнмәс иде. Бу очракта: «Тормышта минем урыным кайда?» соравына җавап эзләргә тиешбез. Икенче төрле әйткәндә, фәлсәфи фикер. Ә проблема мондый: ялган белән яшәү җиңел. Ялган белән хаклыкны җиңү берни тормый, чөнки хаклык ялгызлыкта кала ул. Әмма болай яшәсәң, ялганчы буласың, башында акылың булса, күңел тынычлыгыңны югалтасың. Дөреслек белән яшәү авыр. Дөреслек өчен көрәшүче кеше бервакытта да югары менә алмый, ә түбәнгә тәгәри — тормыш шундый. Әмма аның каравы күңел тынычлыгы аласың. Шуларның кайсын сайларга?

Шагыйрә үзен борчыган бу сорауга да турыдан-туры җавап бирә: хаклык өчен көрәш юлын сайларга кирәк, ди.

Фикерне турыдан-туры әйтеп язу бу очракта Гөлшат Зәйнашеваның кимчелеге түгел. 60—70 нче елларда рус әдәбиятында да, татар әдәбиятында да публицистик лирика жанры активлашып китә. Хәзер безгә гадәти булып тоелган дөрес сүз 60—70 нче елларда әле һәркем өчен тансык сүз иде.

Публицистика дип шулвакыт өчен әһәмиятле сәяси һәм иҗтимагый темалар күтәргән әсәрләргә әйтәләр.

Башка күп санлы әдипләр кебек, Гөлшат Зәйнашева да әсәрен шул жанр таләпләренә буйсындырып иҗат итә.

Укучылар шигырьнең аеруча киеренке урынына — лирик геройның бер мәгънәсез диванадан да җиңелеп калуына игътибар итәргә тиешләр. Җиңелүнең сәбәбе билге (знак яки метафора) белән аңлатылган: тормышны автор болганчык су дип атый. Әмма барыбер дулкыннарга (күп мәгънәле билге-знак) ташланырга әзер тора. Хаклыкны көрәшеп кенә алып булуына шикләнми.

УЙЛАРЫМ — АК ЧЕЛТӘР

Аһ, зифа буйларың,
Мин күреп туймамын,
Гел сиңа үреләә
Ак челтәр уйларым.
Көн туа алланып,
Чык тама балланып,
Дөньяда син барга
Яшим мин куанып.

Йөрегән юлларың
Тын гына буйлармын.
Гел сиңа үреләә уйларым.
Яз килә Иделгә,
Моң салып күңелгә,
Дөньяда мин барын
Син белмисеңдер дә!
Яшим мин куанып.

1965 ел

Шигырьнең көе. Гөлшат Зәйнашеваның хатын-кыз гына таба ала торган «ак челтәр уйлар»ы, ул челтәр уйларның, үрмә гөл кебек, яраткан кешегә үрелүе — үзләре генә дә бер шигырьгә җитәрлек табыш. Өстәвенә шагыйрә мәхәббәт хисенең сафлыгын, матурлыгын, йөгәнсезлеген сөйләп торучы шул гүзәл табышын дәртле көйгә төреп җырлап күрсәтә. Сез дә кычкырып, хисләнеп укыгыз әле: «а» авазы кат-кат калкып чыга да суза, суза... Суза гына башлый, аны «р» авазы бүлдерә. Тегесе калкып чыга, монысы бүлдерә. Бераздан аларга назлы, ягымлы «л» авазы килеп кушыла һәм алар барысы бергә,

бер-берсен бүлә-бүлә, мәхәббәтенең матурлыгына үзе сокланып туя алмаган кыз баланың шомлы шатлыгы турында сөйләрләр.

И ЯФРАКЛАР СЕРЛӘШӘ!..

И яфраклар лепердәшә,
И яфраклар серләшә!..
Ни булган бу күңелемә —
Яфраклардан көнләшә!..

Яфракларның телен белмим,
Ләкин серләрен беләм.
Яфраклардай бер серләшик
Без икәү синең белән.

Бер серләшик, лепердәшик
Шул яфраклар телендә.
Сүзсез бер җыр, сүзсез бер моң
Уянган чак күңелемдә.

Усакларга карап торам,
Яфраклары серләшә.
Яфраклар ник серләшмәсен,
Тамырлары берләшә!..

Җир куенында тамырлары,
Җир куенында — тирәндә!..
Яфраклардан да көнләштем,
Мин шулай сәер бәндә!..

1968 ел

Биремнәр

1. Бу шигырь эчтәлеген үзегез табыгыз.

2. Өйрәнгән шигырьләргә нигезләнеп, Гөлшат Зәйнашеваның иҗатына бәя бирегез. Җырларын хәтерегезгә төшерегез.

ЙОМГАК

60—70 нче, хәтта 80 нче елларда да татар әдәбияты күтәргән мөһим проблемаларның берсе — тормышта кешенең үз урынын табу проблемасы булды. Аны чишәргә омтылмаган бер генә әдип тә юк. Ул, әлбәттә, милли әдәбиятка гына хас проблема түгел иде. Проблеманы тормыш үзе куйды. Хәзер ялганны ялган дип исбат итүнең кирәге калмады. Дөрес, партия җитәкчеләре алышына торды, әмма идеология аңа карап аз гына да үзгәрмәде. Элеккечә караны ак — акны кара диделәр. Кешеләр шул ялганны кабатларга һәм үзләренә мәҗбүри таккан яшәү тәртибен кабул итәргә тиеш булдылар. Теләмәгән эшләрен эшләп, югарыдан ни кушсалар, шуны үтәп йөрүләрен дәвам иттеләр. Элеккечә үк тыңламаучылар эзәрлекләнде. Әмма, сугыштан соңгы еллардан аермалы буларак, кешеләр хәзер үзләренең нинди мескен хәлдә яшәүләрен яхшы беләләр иде.

Әдәбиятта кешенең тормышта үз урынын эзләү проблемасын җаваплылык хисе тудырды да инде. Халык аңындагы үзгәрешләр «Мин бу тормышта ни эшләргә тиеш? Мин кем?» дигән сорауларны куйды.

Татар әдәбиятында бу проблема шәхеснең үз эчендәге конфликты рәвешендә куелды. Шәхес (герой һәм лирик герой) үзенең яшәү рәвешенә каршы чыкты. Икегә бүленде. Бер яктан, дөреслекне кычкырып әйтеп, башкача яшәргә омтылды, икенче яктан, шул ук шәхес, үзен үзе тыңламыйча, искечә, мескен булып, куркып яши бирде.

Әдәби әсәр геройлары, тормышны үзгәртми торып, үзең белән үзеңне килештереп булмаячагын аңладылар һәм үзләрендә тормышны үзгәртерлек көч калмаганлыгын таныдылар. Шуңа күрә үзләренә үзләре катгый сорау куйдылар: тормышка җайлашыргамы, әллә бөтен авырлыкларын күрә торып, хаклык өчен көрәшкә чыгаргамы?

Татар әдипләре юлның соңгысын сайладылар. Күреп үттек: алар сүзләрендә тордылар. Татар әдәбияты 60—80 нче елларны

да сер бирмәде, гаделлек өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында булды.

Татар әдәбияты беренче чиратта кешегә шәхес итеп бәя бирде. Моның өчен ул аны идеология һәм хакимият җирлегеннән аерып алырга тиеш булды. Кеше ирекле табигать баласы, Галәм җисемнәре белән тиңләшерлек Галәм өлеше булып күтәрелде. Ул, көнкүреш ыгы-зыгысыннан югары күтәрелеп, яшәешнең мәгънәсе турында уйлана башлады. Заманны заманга бәйләп торучы көч мәхәббәт дигән нәтиҗәгә килде.

Лирика жанры, фәлсәфи фикерне эченә алып, колачын, куәтен киңәйтте һәм арттырды.

Галәм киңлекләре югарылыгында укучы белән сөйләшү әдипләрдән стиль үзгәртүне сорады. Татар әдәбияты болай да метафораларга бай иде. Хәзер алар янына күп санлы символлар килеп басты. Әсәрләрдә ике эчтәлекнең дәвам итүе, символлар артуы — татар әдәбиятында Язучы — Укучы диалогы тулысынча хөкем сөрә башлады дигән сүз.

«Яңа чорга килеп кердек... Хуш,— дип язды әдибебез Әмирхан Еники «Кояш баер алдыннан» исемле китабында,— үзебез сайлаган режим безгә нәрсә бирде. Иң беренче нәтиҗәбез: елап, сыкрашып булса да, ниһаять, базар мөнәсәбәтләренә кердек. Авызыбызны ачып, гаҗәпләнеп калдык...

Әйтергә кирәк, мин инде утырган язучы, күп нәрсәгә минем үз карашым, үз мөнәсәбәтем бар. Шул сәбәпле мөмкинлекләр чыгу белән үк мин үземне борчыган мәсьәләләр турында яза башладым.

Иң мөһиме — язганнарым нәрсәләр турында... Бу — татар халкының язмышы, бу — Татарстанның киләчәге... Мин Татарстаныбызны киләчәктә Европа тибындагы чын демократик, югары цивилизацияле бер мәмләкәт итеп күрергә теләр идем».

Күп еллар буена татар әдәбиятын хакыйкать юлыннан әйдәп барган аксакалыбыз безгә 90 нчы еллардан башланган яңа чор үзенчәлекләрен әйтеп калдырган. Яңа идеал — чын демократик бер мәмләкәт, төп тема — милләт язмышы, төп проблема — «тотрыксыз, ышанычсыз» тормыштан хакыйкать эзләү, дигән.

Әдәбият үзенең чираттагы яңа чорын башлап җибәрде, сез, хөрмәтле укучылар, әнә шул яңа тормышны тотрыклы, ышанычлы итәргә җиң сызгандыгыз. Уңышлар телибез сезгә.

ПУБЛИЦИСТИКА

Әнә шундый укый башлап ахырына җитүеңә шикләндерә торган авыр төшенчә ул «публицистика». Ләкин шул авыр төшенчә эчендә гап-гади *публика* сүзе ята. Үзебезчә әйтсәк, «халык» яки «иҗтимагый» мәгънәләрен аңлаткан барыбызга да яхшы таныш сүзләр. «Публицистика» төшенчәсенең эчтәлеге мондый: **«Көндәлек тормыштагы актуаль күренешләргә һәм проблемаларга багышланган әсәрләр төре».**

Публицистика да, әдәбият кебек, жанрларга бай. Аларга «хәбәрләр», «мәкаләләр», «очерклар», «фельетоннар» һ. б. керә.

Шуларның дүртесе белән танышыйк.

Хәбәрләр. Хәбәр — газета жанры. Нинди дә булса факт турында язылган кыска язма. Әйтергә кирәк, җитез, түземсез жанр. Язылу белән шунда ук газетага бас та чыгар аны. Хәер, сүзне бездән күпкә тәҗрибәлерәк Һади Такташка бирик. Без аны шагыйрь, драматург дип кенә беләбез. Ә бит ул — гомере буена газета-журналларда эшләгән һәм дөнья кадәр хәбәрләр, очерклар, фельетоннар язган күренекле журналист та. Хәбәр язарга өйрәнүчеләргә ул менә нинди киңәш бирә.

Ничек хәбәр язарга?

«Ничек хәбәр язарга?» дигән сорау белән бергә, «Нәрсә турында язарга» дигән сорауны да куярга кирәк.

Безнең хәбәрчеләребез күп вакытта яхшы гына яза да беләләр. Ләкин язган хәбәрләренең әһәмияте бик аз була. Яки бөтенләй юк нәрсәләр турында язалар. Оста гына яза белә торган хәбәрче тота да шундый хәбәр яза.

«Безнең авылда Халик Галиевнең бик усал эте бар. Шул эт тол карчык Миңҗамал әбинең күлмәген кабып өзгән. Андый этләрне бәйдә тотарга кирәк». Бу хәбәрнең авыл стена газетасы өчен нәни генә әһәмияте булса да, бишәр мең укучысы булган журнал өчен әһәмияте бөтенләй юк...

«Нәрсә турында язарга, нинди хәбәр файдалы?» дигән сорауга кыска гына җавап бирү авыр. Бик күп нәрсәләр

турында язарга мөмкин. Көндәлек эш язуга материалны үзе бирә. Шуның белән бергә, совет эшләре турында язганда, «безнең совет яхшы эшли» дигән сүз белән генә чикләү җитми. Ничек яхшы эшли, эш юллары, авылга китергән файдалары турында тәҗрибә юлларын язарга кирәк.

Бу материал сайлау турында булды. Инде ничек язу турында тукталып үтик.

Бер хәбәрне язу өчен бер дә зур язучы булу кирәкми. Аның өчен бары син үзең нәрсә уйласаң, шуны язу гына кирәк. Безнең бик күп иптәшләр матурлап «китапчарак» язарга телиләр. Маташа-маташа «китапча» булып чыкмый да — ташлыйлар. Бу — ялгыш юл. Менә шул хәбәрне язарга уйлаганда, тотарга да сөйләгәнчә итеп язарга кирәк. Алай язу авыр да түгел, укыр өчен дә сөйләгәнне тыңлаган кебек матур була. (*Һади Такташ.* Әсәрләр. Өч томда. 3 т.— 48—50 б.)

Бирем

Һади Такташ хәбәр язарга өйрәнүчеләргә ике таләп куя. Беренчесе: хәбәрдә әһәмиятле факт булырга тиеш, ди. Икенче таләпне дә шулай ике-өч сүз белән генә әйтегез. Таләпләрнең икесен дә дәфтәрләрегезгә язып, кем таләпләре булуын да теркәсәгез, Такташ мәкаләсенең конспектын язган буласыз.

«Мәгърифәт» газетасыннан ике мисал китерик.

МӘРХӘМӘТ ЯҢГЫРЫ

Шушы көннәрдә генә Саба районындагы Олы Кибәче халкы Хак Тәгаләнең тагын бер могҗизасына шаһит булды. Җәйнең эссе челләсе бөтен табигатьне әлсерәтә. Агачлар, үләннәр интегә, кешеләргә сулар һава җитми. Йөрәк, кан тамырлары хасталары белән авыручылар, хәлсезләнеп, түшәккә егыла.

Әнә шундый көннәрнең берсендә авылның мөхтәрәм кешеләре — Маһинур Габделхәева, Тәслимә Шакирова, Нәсимә Хәсәнова, Мәскүрә Хәбибуллина, Әлфинур Гатиатуллина, Хашига Шәрәфиева, Тәслимә Сәгыйтова, Суфия Шәрипова — иген кырларына юл тоталар. Басуга чыгып кичке намазларын укыйлар һәм Ходайдан ялварып яңгыр сорыйлар. Иртәгесен инде, бөтен табигатькә яшәү көче биреп, шифалы яңгыр ява. Димәк, Хак Тәгалә әле безне онытмаган, димәк әле, Ул безне ишетә. Димәк әле, безнең киләчәккә өметебез бар дигән сүз бит бу! (*Нәсим Акмал.* «Мәгърифәт».— 7 июль.— 2007 ел.)

Биремнәр

1. Хәбәр көндәлек вакыйгага турында. Вакыйга, һичшиксез, әһәмиятле. Ул кешеләрдә өмет, киләчәккә ышаныч тууы турында. Авыл халкының бердәм булып Ходайдан ярдәм соравы — онытылган гореф-гадәтебез. Ләкин соңгы елларда милли нигезебезгә әйләнеп кайту — бик тә актуаль проблема.

Хәбәрнең соңгы юлларында автор вакыйгага, шатлана-шатлана, бәя бирә. Шатлануын ничек белдек?

2. Хәбәрдә проблема да бар. Аңлатыгыз.

ХИСМИ ЧИШМӘСЕНЕҢ ЯШЬЛЕГЕ

— Сабантуйга да бу кадәр халык җыелмаган иде. Күр әле, нинди күңелле! Уены-җыры дисеңме! Ул биючеләрне әйт! Чәй белән коймагына кадәр хәзерләгәннәр бит! — Авыл халкы Чишмә бәйрәмен оештыручыларга әнә шулай рәхмәт укыды.

Бер яктан яшен уйнатып, күкрәп кара кучкыл яңгыр болыты килә, икенче яктан таң яктысы беленә. Ә Югары Курсаның үзәк урамында, тау битендә бәйрәм гөрли. Күрше авыллар да килгәннәр. Район мәдәният йорты директоры Булат Гайнуллин (Югары Курса егете), иң оста һәвәскәрләрне җыеп кайтып, авылдашларын сөендерде. Биючеләр, җырчылар чыгышын «Аулак өй» күренеше алыштыра.

Ә Чишмәне Югары Курсада туып үскән, бүген «Водоканал» оешмасында инженер булып эшләүче Дамир Хәбибуллин хәләл хезмәт хакына төзекләндергән. Шуңа да Дамирның сыйныф җитәкчесе Зөбәрҗәт Галләмованың шатлыгы эченә сыймый:

— Хисми чишмәсен яңадан эшлиләр дигәнне ишеткәч бер сөенсәм, Дамир эшләтүен белгәч, шатлыгымның чиге булмады,— диде.

Хисми чишмәсенең тарихын да халыкка укытучы сөйләп бирде:

— Хисмәтулла чишмә чыккан яр өстендәге урамда яшәгән. Яр буйлап бәреп чыккан чишмәләр бик күп була. Хисми агай, менә шуларның берсен казып, һәркем килеп су алырлык чыганак ясый. Улы Шәймулланың үз баласы булмагач, Исрафил исемле малайны тәрбиягә алып үстерәләр. Хисми абый нигезендә хәзер Исрафилның улы Ирек яши. Изге нигездә хатыны Зөлфия белән балалар үстерделәр.

...Авыл халкы, яшәгән урынны матур төзек итеп тотарга кирәклеге хакында искә төшереп тору өчен, Чишмә бәйрәмен ел саен уздырырга булды. (*Чулпан Гатауллина.* Арча районы, Югары Курса авылы // «Мәгърифәт».— 18 август.— 2007 ел.)

Биремнәр

1. Хәбәрдәге факт — чишмә бәйрәме. Фактның актуальлеген аңлатыгыз.
2. Хәбәрдә тагын бер мөһим тема бар. Теманы табыгыз.
3. Хәбәрдә шатлык та бар. Хиснең ияләре, сәбәпләре турында сөйләгез.

Мәкалә. Мәкалә белән хәбәр — икесе бертөрлерәк язмалар. Мәкалә дә газета-журналлар өчен языла. Күләме дә газета битенең бер өлешенә сыярлык кына була. Ул да тәмамлану белән дөнья күрергә ашыга. Шуңа күрә кайчакта хәбәрне дә мәкалә дип йөртәләр. Ләкин алар арасында аерма да бар. Мәкалә фактларның эчендә казынырга ярата. Казына башладымы, проблема туа. Мәсәлән, Һади Такташның «Ничек хәбәр язарга?» язмасы хәбәр турында, ләкин үзе мәкалә. Мәкаләнең исеме үк эчтәлегендә проблема барлыгын әйтеп тора. Мәкалә яшьләрне хәбәр язарга өйрәтә. Язган хәбәрләренең кимчелекләрен күрсәтә.

Очерк жанры. «*Очерк* — реаль тормышта булган вакыйгаларны, анда катнашкан кешеләрне үзгәртмичә сурәтли торган кечкенә күләмле әдәби әсәр»,— дип аңлата күренекле татар әдибе һәм галим Нәкый Исәнбәт.

Фәндә кабул ителгән бу билгеләмәне кыскартып әйтсәк: очеркны мәкалә белән хикәя кушылмасы дияргә була.

Очеркта автор вакыйгаларга анализ ясый. Анда катнашучыларга үз сүзләре белән бәя бирә. Очеркның башка әдәби жанрлардан аермасы шуннан гыйбарәт. Очеркка тормыш вакыйгасын журналист үзе эзләп таба. Ә газета, яки журнал биргән тема булса, эзер теманы ача торган тормыш вакыйгасы эзләргә чыгып китә. Тема белән идея күп очракта тормышның үзеннән табыла.

Мисаллар белән танышыйк.

МИН КАЕН БУЛАЛМАДЫМ

Әнкәй мине авыр тудырган. Мине якты дөньяга китергәннән соң хәле җиңеләймәгән, гомерлеккә өзлегеп калган.

Әнкәй ак каеннар ярата иде. Безнең өйнең тәрәзә алдында ак каен үскән. Мин аны хәтерләмим. Сабый чагымда күрә алмый калдым. Әнкәй табигатенең бер сыйфаты күчкәндерме, мин дә гомерем буе каеннарга гашыйк. Һәрбер поэмамда диярлек каеннар, туган ягым каеннары... Каләмдәшләрем дә, үзем дә каеннарны гүзәл кызга тиңлибез, «каен сеңелләр» дип дәшәбез. Хәзер инде мин ак каенны әнкәйгә тиңлим.

Шулай беркөнне әткәй мине — ике яшьлек сабыйны күтәреп тәрәзә янында басып тора икән. Тышта көчле яңгыр ява, күк күкри, яшен яшьни. Каеныбыз, давылланган чәчләрен — яфракларын туздырып, җиргә кадәр иелә, нидер әйтергә тели кебек... Урында яткан әнкәй, белгән догаларын укый-укый:

— Яшен яшьни, кит тәрәзә яныннан! — ди.

Әткәй тыңламый.

— Курыкма, әнкәсе, безгә тими ул!

Сүзен әйтеп бетерергә өлгерми, коточкыч шартлау өйне тетрәтә. Әткәй идәнгә барып төшә. Урында яткан әнкәй мине көчле куллары белән эләктереп ала. Башта мине яшен суккан дип куркалар, бераз вакыт узгач, мин кычкырып елап җибәрәм...

Һушларына килеп тәрәзәгә карасалар, өй алдындагы каенны яшен суккан. Ак каеныбыз, яшеннең утергеч көчен үзенә юнәлтеп, мине коткарган.

Әнкәй дә, ак каен сыман, тормышның бөтен авырлыгын үзенә алып, авырып, мине саклап калган. Хәзер мин әнкәйне ак каенга тиңлим. Мин генә каен булалмадым. Әнкәйне авырулардан, үлемнән саклап кала алмадым. (*Илдар Юзеев.* Февраль, 1996 ел.)

Күренеп тора: очерк ананың — улына, улының әнисенә мәхәббәте турында. Мәхәббәт темасына язылган әсәрләр бик күп. Ничек күп булмасын — мәхәббәт хисе бит ул! Бу темага язмаган әдипне чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Менә шул күп әсәрләрнең уртак яклары темаларында гына чагыла. Уңышлымы, алай ук түгелме — әдипләр барысы да үзләренчә язалар.

Илдар Юзеев тә шулай итә. Очерк жанры кушканча, тормыштагы вакыйганы ничек бар, шулай сөйләп бирә. Ләкин

авторның максаты — хәбәр әйтү генә түгел, укучысын хисләр дөньясына кертеп тәэсирләндерү. Ә хисләрне сурәтләү коралы әдәбият алымнарында гына. Илдар Юзеев үзе сөйләгән ак каенда метафора куәте күреп ала. Ә каен сыйфатларында әнисенең сыйфатларын күрә. Каен да, әнисе дә, кечкенә Илдарны яшәтер өчен, үзләрен корбан иткәннәр. Охшашлык авторга, әнисен ак каенга тиңләр өчен, нигез-метафора була. Илдар Юзеев әнисе мәхәббәтен дә, әнисенең үзенә, үзенең әнисенә булган мәхәббәтен дә ак каенга тиңли.

Ә очеркның икенче өлешендә автор, каен булып, авыру әнисенә ярдәм итә алмавына үкенә.

Бирем

Язманың очерк булуын исбат итегез.

Әдәби тәнкыйть (рецензия). Әдәби әсәргә бәя бирүче, аның эчтәлеген аңлатучы язманы «әдәби тәнкыйть», ә язма авторын «тәнкыйтьче» дип йөртәләр. «Тәнкыйть» төшенчәсе жанр атамасында бар, ә билгеләмәсендә юк, диярсез. Бар. «Тәнкыйть» тә бар, «мактау» да. Алар икесе дә, «мин монда» дип кычкырып торсам, тыйнаксызлык булыр дип, «бәя» сүзе эченә кереп яшеренгәннәр.

Әдәби тәнкыйть жанрының иң мөһим ике өлешен таптык кебек. Ләкин бу жанрның төп вазифасы мактау белән кимчелек күрсәтү икән дисәк, дөрес булмас.

Талантлы тәнкыйтьче Д. В. Веневитинов Пушкинның «Евгений Онегин» әсәренә тәнкыйть мәкаләсе яза. Мәкалә белән танышып чыккач, шагыйрь тәнкыйтьчегә:

«Мин яратып һәм аеруча игътибар белән укып чыккан бердәнбер мәкалә бу. Башка мәкаләләр йә гаепләүдән, йә ялагайланып мактаудан гыйбарәт»,— дип бәя бирә. Ләкин бөек әдип әдәби тәнкыйтьнең нинди булырга тиешлеген аңлатмаган.

Аның каравы аңлатманы әдәбият энциклопедиясе ачыклый.

Тәнкыйтьче үзенең мәкаләсендә укучысы белән әңгәмәгә керә. Укучысына әсәрне аңлата, укучы уен үз фикеренең агышы эченә кертә. Әдәби әсәрне укып чыккач туган беренче тәэсирен саклап, әсәр аңлауның тирәнрәк катламында уйланырга ярдәм итә.

Шуңа күрә әдәби тәнкыйтьчене укучының укытучысы дияргә була.

Ә хәзер мисал белән танышыйк.

БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫНА СӘЯХӘТ

Сез бу китапны укыдыгызмы әле?

Гадәти китап түгел бу. Аны язучы абыйлар, апалар түгел, ә укучылар үзләре иҗат иткәннәр. Рәсемнәрне дә үзләре ясаганнар, әсәрләрне дә үзләре язганнар. Ә язучылар, рәссамнар бу китапны кулларына алдылар да: «Безгә алмашка килүче сәләтле балалар бар икән ич!» — дип сөенделәр. «Иркен минем туган илем» дип исемләнгән бу җыентыкта 73 укучы әдәби әсәрләре белән, 19 укучы рәсемнәре белән катнашкан. Сан ягыннан бу гаҗәп күп. Әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә шушы кадәр яңа көч килеп керсә, нинди күңелле булыр иде, ә?

Гадәттә, бала тәүге тапкыр атлаганда, егыла-егыла бара, шуның шикелле яшь иҗатчылар да әле әйбәт кенә атлап китәләр, әле тотыныр әйбер таба алмагандай сөрлегеп куялар. Бу бик табигый. Ә менә Ренат Шәмгунов чаңгы кигән дә җырлый-җырлый шуып киткән:

Авылыгыз Барыш ул,
Күп кешегә таныш ул;
Мин дә бардым Барышка
Чаңгы белән ярышка.

Без дә анда ярыштык,
Күпләр белән таныштык,
Шуннан бирле дуслар белән
Бик күп хатлар языштык.

Ренат, мөгаен, бу шигырьне язганда, бармакларын бөгеп, иҗекләрне санап утырмагандыр. Сәләтле кеше шигырьдәге ритмны күңеле белән тоя. Аның шигырендә дә ритм җырлап тора.

Ритм-рифманы үзләштермичә торып, шагыйрь булу турында хыялланып та булмый. Әмма бу әле — зарури таләпләрнең берсе генә. Шагыйрь, образлы фикер йөртүе белән башкалардан аерылып торса гына, үзенчәлекле тавышка ия була ала. Менә сезгә бер шигырь:

БУРАН

Камыт күрмәгән тай кебек
Дулый урамда буран.
Шул буранны капылт кына
Йөгәнләп алмак булам.

Атларны бит өйрәтәләр
Ярсып торганнарын да;
Менә шулай итсәң икән
Шушы бураннарны да.

Әнәс Газизуллин язган бу шигырьдә образлы фикер йөртүгә омтылыш бар. Камыт күрмәгән тай белән буранны чагыштыру укучының күз алдына буран картинасын китереп бастыра.

Шамил Әхмәтшинның «Мин авылымны яратам» исемле прозаик язмасына игътибар итегез. Автор әле аны хикәя дип атарга да батырчылык итмәгән, дөрес эшләгән. Әмма ул киләчәктә, үз өстендә тырышып эшләгән очракта, хикәяләр яза алыр иде. Менә аның этюдыннан бер өзек:

«Ул чакта мин әле 4—5 яшьләрдә генә идем. Абый белән балыкка киттек. Елга буена төшкәч тә, абый кармагын суга салды. Ә мин калкавыч төшүдән барлыкка килгән боҗрасыман дулкыннарның, тарала-зурая барып, бер-бер артлы ярга бәрелеп сүнүләрен күзәтеп тордым. Кармагын салды да абыем каядыр читкәрәк китте. Мин калкавычка карап утыра башладым. Менә ул селкенеп куйды, ә аннан түбән таба шуып китте. Мин кыюланып сапка ябыштым һәм аның белән бергә үзем дә шуа башладым. Күрәсең, зур балык эләккән иде.

Тартыша торгач, суга ук барып төштем. Ул чакта мин әле йөзә дә белми идем. Тавышка абыем йөгереп килгән. Килсә, мин дә юк, кармак та юк. Без инде су астында булганбыз. Абый, тиз генә суга ташланып, мине ярга чыгарган.

Әйе, булды бервакыт шундый хәл. Менә шуннан соң әйтеп кара инде син, безнең авылның суы кечкенә яки елгасының балыклары вак дип. Юк, әйтә алмыйсың. Безнең авылның бер генә дә килмәгән җире юк. Бу фикер белән килешмәгән кешенең минем кебек уңайсыз хәлдә генә калуы бар».

Бу өзекне укып чыгу белән, мин бу елганың зурлыгына да, балыкларының эрелегенә дә ышандым. Чөнки автор, укучыны ышандыру өчен, кызыклы алым, вакыйга таба белгән. Автор

«безнең авылыбыз искиткеч матур, гүзәл, якын, кадерле» дип күпме генә кабатлап торса да, мин моңа ышанмас идем.

Үзем яшь дусларымны мактыйм, шул ук вакытта шүрләп тә куям. Ни өченме? Менә ни өчен. «Ялкын» журналында эшләгәндә, мин бик сәләтле бер укучыны белә идем. Гаҗәеп матур шигырьләр яза иде ул. Мактап җибәрдек без моны. Шушы мактау сүзләре аңа килешмәгән. Ул мәктәптә борынын күтәреп йөри башлаган. Укуга да игътибарын киметкән. Шигырьләрен дә ашык-пошык кына язып җибәрә бу. Шуннан соң без аның бастырып чыгарырлык шигырьләрен тапмадык. Ул үзенең сәләтен үстерү өстендә эшләмәде, масаеп бер урында таптанып калды.

«Иркен минем туган илем» җыентыгында катнашкан авторлар әле искә алган гыйбрәтле вакыйганы кабатламаслар һәм иҗатка җаваплы карарлар, дип уйлыйбыз.

Шунысы шатландыра: укучылар үзләренең көчләрен әдәбиятның төрле жанрларында сынап карыйлар. Шигырь дә, хикәя дә, нәсер дә, әкият тә, мәсәл дә, фельетон да язалар. Кайсы гына әсәрне укып карасаң да, аларның үз дөньясын күрәсең. Бу китапны укыгач, мин үземне балалар дөньясына сәяхәткә барып кайткан кебек хис иттем. Ә иң күңеллесе — безнең әдәбиятыбызга килергә ашкынып торучы, төрлечә җырлый, сөйли, көйли, оста рәсем ясый белә торган талантлар белән очраштым.

Сезнең белән киләчәктә зур әдәбият мәйданында очрашасы килә. (*Илдар Юзеев*)

Бирем

Илдар Юзеев рецензиясендә әсәр авторларын мактый да, гафу үтенгән кебек, тыйнак кына тәнкыйтьләп тә ала, авторлары белән әңгәмәгә дә керә. Шуны исбат итегез.

ГОМУМИ ЙОМГАК

Сугыш еллары һәм аннан соңгы еллардагы әдәбият

Быел татар әдәбиятын өйрәнүне сугыш еллары белән башлап киттек. Сугыш еллары һәм 60—70 нче еллар әдәбияты дип чорларга бүлдек. Һәр чорның үз темасы барлыгын белдек.

Темалар үзгәрүенә тарихи вакыйгалар сәбәп булды.

Бу елларда халык сугыш афәтен кичерде. Сугыштан соң кабат репрессияләр көчәеп китте. Идеология аны, гадәтенчә, сыйнфый көрәшнең көчәйгәннән-көчәя баруы дип аңлатты. Репрессия шул ук сугыш, бу юлы инде ил эчендә үз халкына һөҗүм итү иде.

Партиянең XX съезды илне тагын бер тапкыр тетрәтте. Анда Н. С. Хрущев күпләр сизенеп тә әйтергә базмаган хакыйкатьне ачып салды. Зур ялган фаш ителде: дошман дип бер гаепсезгә хөкем ителгән кешеләрнең хаксызга атылулары, төрмәләрдә утыруы мәгълүм булды. Хаксызлыкның шундый акыл җитмәслек дәрәҗәдә зур булуына халык ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Лагерьлардан, төрмәләрдән кайтучылар андагы тормыш турында сөйләделәр. Хакыйкать ачылганнан-ачыла барды. Озак еллар буена ялганга ышанып яшәү мәгълүм булгач, кешеләр илдә дә зур үзгәрешләр булыр дип көттеләр. Үзгәрешләр булды, әмма идеология дә, яшәү рәвеше дә үзгәрмәде.

Хәзер 70—80 нче еллар — торгынлык еллары дип бәяләнде. Әмма торгынлык ул — үзе зур вакыйга. Нәкъ менә шул елларда күпчелек кеше тормыш рәвешенең яраксызлыгын ачык күрде. Идеологиянең бер сүзенә дә ышанмады. Ләкин шул ук вакытта яраксыз система тудырган кагыйдәләргә буйсынып яшәргә мәҗбүр булды. Болай яшәү көлке дә, фаҗига да иде.

Әмма идеология сүз генә түгел, эш тә иде бит. Партия өйрәтүенчә, милләтләр әкренләп-әкренләп бетәргә, аларның

гасырлар буена тупланган мәдәни байлыклары, тормыш-көнкүреш гадәтләре, телләре, һиндидер уртак бер мәдәниятне баетып, рус теленә кушылырга тиеш иде. Бу тәгълимат тора-бара үзенең нәтиҗәләрен дә бирә башлады. Татар мәктәпләре бер-бер артлы ябылды, рус мәктәпләренең саны артты. Халыкның күпчелеге үз телен онытты.

Милләт бетү, югалу алдында тора иде. Татар халкы өчен 80 нче елларның иң зур вакыйгасы шул булды.

1991 елда башланган реформаны, чынлыкта илнең астын өскә китергән революция белән генә чагыштырып була. Ниһаять, әдипләр сәяси хакыйкатьне дә, милләт фаҗигасе турында да ачыктан-ачык әйтү хокукы алдылар.

Бу елларда иҗат иткән әдипләр шул тарихи вакыйгаларның кешеләр язмышындагы чагылышы турында яздылар. Күбрәк ачылган саен аңлавы кыенлаша барган хакыйкатьнең төрле якларын күрсәттеләр.

Хакыйкать эзләү — матур әдәбият алдында торган төп вазифаларның берсе. Революциядән соң бу тема аеруча актуальләшә, ләкин әле хакыйкать эзләү, ягъни проблема булудан узмый.

Совет солдаты сугышта чиксез батырлыклар күрсәтте. Әмма җиңү дә бик кыйммәткә төште. Татар әдәбияты сугыш елларында да чынлыкка тугрылыклы булып калды. Сугышчыларның батырлыкларын күрсәтү белән бергә, сугыш афәтенең кешеләр язмышы өстеннән йөрүен дә ачык сурәтләде.

Сугыш елларында туган бу хакыйкать бик кечкенә иде. Әмма ул бар иде һәм татар әдәбияты аны төкми-чәчми, лирик герой кичерешләре белән бәйләп күрсәтә алды.

Милләт язмышы турында хәтта партиянең XX съездыннан соң да язу түгел, кычкырып сөйләргә дә ярамый иде. Алай да әдипләр идеология кысасы беркадәр йомшарудан оста файдаландылар. Милләт язмышы турындагы борчулы сүзләрен тарихи романнар, повестьлар эченә керттеләр. Милләтнең үткән тарихын чагылдырган актуаль мәсьәләләр турында сөйләделәр.

Максат — халыкта елдан-ел сүнә барган милли горурлык хисен тәрбияләү иде.

Әдипләр татар халкының гореф гадәтләре, өлкән буын холкы, туган туфрак хисе турында яздылар. Бу елларда хакыйкать милли мәсьәлә булып киңәйде.

Бер яктан, әдипләр идеологиянең ялган булуын яхшы беләләр, икенче яктан, шул идеология нигезендә корылган шартларга ярашып яшәргә тиеш иделәр. Уй белән гамәл арасында каршылык туды.

Торгынлык елларында татар әдәбияты күтәргән төп проблема кешенең үзен үзе танып белү проблемасы булды. Кешеләрне «Мин кем?» соравыннан бигрәк «Мин нигә мондый?» соравы борчыды. Бу сорауның нигезендә шәхеснең теләге белән гамәле арасындагы каршылыкны чишә алмау проблемасы ятты. Шигырьләрдә һәм поэмаларда лирик герой икегә аерылды. Үз-үзе белән конфликтка керде.

Сорауда шәхеснең тормышта тоткан урыны проблемасы да бар иде.

Әдипләр: «Тормыштагы гаделсезлекләрне мин бик яхшы күрәм. Әмма аңа ничек җавап бирәм?»— дип, үзләренә үзләре сорау бирделәр. Күләмле әсәрләрдә геройлар бу сорауга җавап таба алмыйча җәфа чиктеләр. Лирик геройларның һәм персонажларның үз-үзләре белән конфликтка керүе җәмгыятьнең үз эчендә конфликтка керүе иде. Җәмгыять кичергән бу драма хакыйкать темасының психологик эчтәлеге булды. Татар әдәбияты аны шул рәвешле тасвирлады да.

1991 елда башланган реформа дистәләрчә еллар буена хакыйкать дип йөртелгән ялганның — ялган, ялган дип сүгелгән хакыйкатьнең хакыйкать булуын ачыктан-ачык әйтте. Система үзе — яшәргә хаксыз, бозык система, диде.

Ил демократик юлга басты. Татар әдәбиятының яңа чоры башланды. Бу чорга фәнни анализ ясарга иртәрәк әле. Әлегә бу чор әдәбияты үзенең темасын, стилен, кыйбласын эзли.

Моңа кадәр сүз әдәбиятның реалистик юнәлеше турында барды. Идеология үз көчендә булганда, аны яклаучылар һәм пропагандалаучылар да була. Татар әдәбиятында тормышның көннән-көн матурлануы, дөньяда совет кешесеннән дә бәхетле кеше булмавы турында язылган әсәрләр күп булды. Бу темага күбрәк шигырьләр язылды. Юкны — бар, теләкне чын итеп күрсәтүләрен искә алып, бу әсәрләрне романтик метод белән язылган әсәрләр дип әйтә алабыз.

Ялган эчтәлеккә корылган әсәрләр камил була алмыйлар. Әмма аларның авторларына бәя биргәндә, ялган яздылар дип әйтүдән сак булыйк. Илдәге бәхетне мактап язган әдипләр турында алар үзләре язганга ышанмаганнар дип әйтергә безнең бер генә нигезебез дә юк. Шунысын да онытмыйк: хакыйкатьне

ачып салган әсәрләр фәкать романтик рухта язылган әсәрләр фонында, алар күләгәсендә генә туа алдылар.

Романтизм методы аеруча 70—80 нче елларда көчәеп китә. Бу метод белән иҗат итүче әдипләр дә хыялларын чын итеп язалар: алар галәм буенча әйләнеп йөриләр, болытлар белән сөйләшәләр, кояшка таба очып китәләр. Әмма бу очракта җирдән аерылу тормыш куйган сорауларга җавап эзләү алымы яки җир тудырган хәсрәтләрдән юану булды. Романтизм методы белән язылган әсәрләрнең эчтәлеге реаль иде.

Әдәби чорлар һәм бәйләнешләр

1. Әдәбият чорлары. Татар әдәбиятының иң борынгы чорын төрки әдәбияты чоры дип йөртәләр. Бу чор әдәбиятының иң күркәм ядкәре — Йосыф турындагы кыйсса. Без аны гомумкешелек өчен әһәмиятле булган кеше сыйфатлары турында язылган дидек. Ул сыйфатларның барысын да кешеләрнең үзара тату яшәве өчен кирәкле чаралар дияргә була.

Кыйссада татулыкның иң яман дошманы — кешеләрнең сабырсызлыгы. Сабырсызлык котылгысыз рәвештә усаллыкка китерә. Ә усаллык шулай ук котылгысыз рәвештә җәзасын ала. Әмма усаллык хатасын аңлап гафу үтенсә, тәүбә итсә, аны гафу итәргә тиешләр.

Сабырлык, усаллык, тәүбә итү, гафу итү — боларның һәммәсе кыйссада бик мөһим аерым тема дәрәҗәсенә менгерелә. Һәр вакыйгада усаллыкны шәфкатьлелек җиңеп чыкканга, борынгы әдәбиятның эчтәлеген шәфкатьлелек тантана итү дип әйтәбез. Борынгы әдәбиятта проблема юк. Бәхәссез хакыйкать кенә бар. Йосыф кыйссасы татар әдәбиятының алдагы чорлары өчен әйтерсең лә план язып калдыра.

«Идегәй» дастанында усаллык тантана итә. Вакыйгаларның һәрберсе үч алу — үлем белән тәмамлана. Шуңа күрә без аны усаллык тантанасы дип атадык. Шуның белән бергә, дастан авторының кешеләрдәге сабырсызлыкка җаны әрнүен дә әйттек. Шәфкатьлелек темасы бу әсәрдә дә бар, ләкин хәзер инде ул әсәрнең идеясенә, ягъни автор теләгенә әйләнә.

Чорларның тагын бер аермасын әйтеп үтик. Борынгы әдәбиятның иң беренче ядкәрендә гомумтөрки халкы мәнфәгатьләре күз алдында тотыла. Төрки-мөселманнарны рухи тәрбияләү максат итеп куела.

«Идегәй» дастаны дәүләтләр чиге белән канәгатьләнә. Дәүләтләр мәнфәгатен күздә тота.

XVI—XVIII гасыр әдәбиятына сабырлык тантанасы дип исем бирдек. Бу чорда иҗат иткән Мәүла Колый, Утыз Имәни кебек әдипләр кешеләрне әхлаклы булырга, хезмәтне яратырга чакырдылар, мәгърифәтнең файдасы турында яздылар. Әмма шуларга ирешү өчен, кешеләрне сабыр булырга өндәделәр. Бу чор әдәбияты татар халкы мәнфәгатен күздә тота. Әлеге чор әдәбиятының эчтәлеге — сабырлык, ә идеясе мәгърифәтле булу иде.

Мәгърифәтчелек XIX гасыр әдәбиятының эчтәлегенә әйләнә. Муса Акъегет, Каюм Насыйри, Кандалый һәм башка әдипләр укып белем алуны үзмаксат итеп куйдылар. Максат татар милләтен алдынгы милләтләр югарылыгына күтәрү иде. Белем алу шуның бер чарасы дип исәпләнде. Җәмгыятьтәге бөтен бозыклык, усаллык белемсезлектән килә дип уйладылар мәгърифәтчеләр һәм белемле булуны усаллыкка каршы көрәш чарасы итеп тә кузалладылар.

XX йөз башы әдәбияты эчтәлегендә мәгърифәтчелек идеясе күп урын били. Әмма, тарихи шартлар үзгәрү сәбәпле, татар әдәбияты да үзәк темасы итеп милләт темасын ала. Бу чор әдипләренең төп идеяләре — милләткә мөстәкыйльлек бирү. Азмы-күпме ирек алу өчен дә, милләт үзен яшәргә хаклы итеп күрсәтергә тиеш иде. Әдипләр, милләтнең абруен яулау өчен, беренче чиратта берләшергә кирәк дигән фикердә тордылар. Ирек яулау билгеле чор әдәбиятының идеясе булды.

Совет чоры әдәбиятының төп темасы хакыйкать булуын күрдек. Әдипләр бу тема белән милләт язмышын да, шәхес язмышын да бәйләделәр. Игътибар үзәгендә үз-үзе белән конфликтка кергән шәхес торды.

Күрәсез, әдәбият, кыенлыкларга да карамастан, үскән, яңарган. Аның эчтәлегендә сәяси тема күп булган.

Кешелек турында яза башлап, дәүләтләр, халыклар, милләтләр, гаиләләр һәм шәхес матурлыгын тасвирлау дәрәҗәсенә кадәр үскән.

Татар әдәбияты үзенең иң борынгы чоры күтәргән темаларга тугрылыклы булып кала. Тормышка андагы әхлак сыйфатларыннан файдаланып бәя бирә.

2. Әдәбиятның бәйләнешләре. Татар әдәбияты да, башка халыклар әдәбияты кебек, беренче чиратта үз халкының авыз

иҗаты тәэсирендә яши һәм үсә. Бу тәэсирне ул һәрвакыт сизеп тора һәм аның чиксез бай сәнгать алымнарыннан өзлексез файдалана.

Безнең әдәбиятның чишмә башы — гомумтөрки әдәбият. Ул, мөстәкыйль әдәбият булып аерылгач та, төрки халыклар әдәбияты белән бәйләнешен өзми.

XVIII—XX йөзләрдә әдипләргә төрек һәм гарәп әдәбиятының тәэсире көчле була. Бик күп төрек һәм гарәп әкиятләре, мәзәкләре, хикәя-шигырьләре тәрҗемә ителә. Аларның шактые мәдрәсә дәреслекләренә дә кертелә.

XX йөз башында әдипләрнең Көнбатыш Европа әдәбияты белән кызыксынулары көчәя. Кызыксыну соңрак даими өйрәнүгә күчә. Әмма татар әдәбиятының бик тиз үсеп китүенә һәм бүгенге көн дәрәҗәсенә җитүенә беренче чиратта рус әдәбиятының йогынтысы зур булды.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Хакыйкать эзләү

Әхмәт Ерикәй

Кыя 9

«Кырлар көйдерелгән җиргә киттем...» 10

Җил 12

«Караңгыда гына сугыш тынды...» 12

Шәйхи Маннур

Чәчәкләр һәм снарядлар 14

Шәрәф Мөдәррис

Парча 15

Минем моңым 15

Сибгат Хәким

Куллар 16

Әхмәт Фәйзи

Әүхәдинең хатыны Майшәкәр белән саубуллашуы 17

Әмирхан Еники

Бер генә сәгатькә 19

Муса Җәлил

Әйдә, җырым! 32

Чулпанга 33

Хуш, акыллым 36

Окоптан хат 37

Кичер, илем! 39

Соңгы үпкә 43

Ышанма 44

Дуска 45

Җырларым 47

Кошчык 48

Төрмәдә төш 49
Күлмәк 51
Гашыйк һәм сыер 53

СУГЫШТАН СОҢГЫ ЕЛЛАРДАГЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Хакыйкать тудырган фаҗига

Ибраһим Салахов
Тайгак кичү 59
Хәсән Туфан
Агыла да болыт агыла 102
Тынма, давыл! 105
«И диалектик кануннар...» 106
Илдә нилəр бар икән? 106
Кайсыгызның кулы җылы? 107
Тамчылар ни диләр? 110
Уралдан үтешли 111

Хакыйкатьне тарихтан эзләү

Гомәр Бәширов
Туган ягым — яшел бишек 114
Нурихан Фәттах
Ител суы ака торур 149
Гариф Ахунов
Идел кызы 198

Әхлак нигезләрен өлкән буын вәкилләреннән эзләү

Әмирхан Еники
Туган туфрак 246
Әйтелмәгән васыять 266
Аяз Гыйләҗев
Җомга көн, кич белән 289

Хаксызлыкка ярашуның холыкка әйләнүе

Гамил Афзал
Язмышлар 324
Елмаям уйчан гына... 324
Гомер китабы 325
«Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә...» 327
«Ахмак килә, күкрәк кага, гайрәт ора...» 327
«Чабаклар йөзгән Иделдә...» 328

«Һәр яфрагы тере кебек...» 328
«Ай нурына чумган яшел тынлык...» 328
Тәвәккәл әби 328
Сәләхетдин абзый сөйли 329
«Аю йөргән урман арасында...» 331
«Җитәкчеләр килә, китә...» 332
«Ярлы кеше яманыр да юаныр, ди...» 333
Хәй Вахит
Беренче мәхәббәт 335
Туфан Миңнуллин
Дуслар җыелган җирдә 354
Шәриф Хөсәенов
Әниемнең ак күлмәге 373

Тормышта үз урыныңны эзләү

Сибгат Хәким
Диңгез күзе 395
Әле һаман куркып уянамын 395
Үрләреңне менгәч 396
Әй мәктәбем 396
Чәчкәләр 397
Җылы сүз 397
Бер бәйгедә күргән идем аны 397
Кочагына алсын, кайнатсын 398
Камыл 398
Тәрәзә рамнары 398
Елганың борылган төшендә... 399
Равил Фәйзуллин
«Халык әле кышта яши...» 402
«Башны салларга салып...» 403
«Вулканнар бар диңгез төбендә...» 404
Җилфердәүче керләр җыры 405
Уен 407
Саубуллашу 408
Зәңгәр күктә бер ак болыт 409
Рафаил Төхфәтуллин
Таныш көй 414
Илдар Юзеев
Калдыр, аккош, каурыеңны... 429
Юеш тә дым... 429

Әй Кеше... 429
Ай сонатасы 430
Мин табарга тиеш 430
Салкын җирне җылыткандыр кеше 431
Тамсын ул 433
Ак бүрек, каз... могҗиза! 433
Сагышлы мирас 435
Гөлшат Зәйнашева
Хаклык диңгезен кичәргә!.. 437
Уйларым — ак челтәр 438
И яфраклар серләшә!.. 439

Публицистика 442
Гомуми йомгак 451

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе для 11 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье

Казань. Издательство «Магариф». 2008

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
11 нче сыйныфы өчен дәреслек

Өченче басма

Редакторы *З.М.Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л.С.Золондинова*
Рәссамы *В.А.Малякин*
Компьютерда биткә салучысы *Г.Р.Галимҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л.Р.Вафина*
Корректорлары *Г.Г.Мөхәммәтҗанова, С.З.Гыймалетдинова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 04.07.2008.
Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Офсет басма. «Школьная» гарнитурасы.
Басма табагы 29,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 26,05 + форз. 0,39.
Тиражы 4300 д. Заказ Т-808.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ХАКЫЙКАТЬ

ГАЛӘМ ҺӘМ ГЕРОЙ

ШӘХЕСНЕҢ КАРШЫ ЯКЛАРГА БҮЛЕНҮЕ

РОМАН
КҮПМӘГЪ-НӘЛЕЛЕК
РОМАН